# КАҺАРМАН КАЛӘМЕ

## Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучылары иҗатыннан үрнәкләр

КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 2010

УДК 821.512.145-1:3(01)
ББК 84(2Рос=Тат)-4:5я1
К12

Редколлегия:
*З.Р.Вәлиева, И.М.Ибраһимов, Р.Г.Фәйзуллин, Д.С.Шакиров, Л.М.Шәехов, Ф.И.Фәтхетдинова*

Төзүчеләре:
*Вакыйф Нуриев, Лилия Сафиуллина*

**Каһарман** каләме : шигырьләр, хикәяләр, әсәрләрдән өзекләр / төз. В.Нуриев, Л.Сафиуллина ; кереш сүз авт. И.Ибраһимов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 223 б.
ISBN 978-5-298-01924-8
Бу китапка Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучыларының тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүматлар һәм аларның кайбер әсәрләре тупланып бирелде.

УДК 821.512.145-1:3(01)
ББК 84(2Рос=Тат)-4:5я1
ISBN 978-5-298-01924-8
© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Нуриев В.В., Сафиуллина Л.Н., төзү, 2010

### «ИҢ ДӘҺШӘТЛЕ УТКА КЕРӘМЕН»

Татарстан Язучылар берлеге бинасының икенче катында фирүзә төсендәге калын диварга истәлек тактасы эленгән. Анда Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучыларның исемнәре күгелҗем мәрмәргә алтынсу төсендәге хәрефләр белән уеп язылган.

1941 елның 22 июнендә немец-фашист илбасарлары илебезгә бәреп кергәч, халык белән бергә язучыларыбыз да көрәшкә күтәрелә. Сугышның беренче елында гына да 25 каләм иясе (аларның дүртесе Язучылар берлегенең идарә әгъзасы) фронтка китә: Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Әхмәт Исхак, Абдулла Алиш, Хәйретдин Мөҗәй, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри, Нури Арсланов, Гали Хуҗи, Әнвәр Давыдов, Зәки Нури, Зыя Мансур һәм башкалар.

Төньяк-көнбатыш, Беренче һәм Икенче Белоруссия, Ленинград, Беренче һәм Өченче Украина, Воронеж, Волхов һәм башка фронтларда татар телендә газеталар чыга. 1942–1943 елларда бер төркем язучылар, шул исәптән Гадел Кутуй, Афзал Шамов, Мәхмүт Максуд, Әхмәт Ерикәй, Риза Ишморат, Габдрахман Әпсәләмов, Ибраһим Гази, Абдулла Әхмәт, Гомәр Галиев, Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур, Гамир Насретдинов, Әхмәт Фәйзи, Шәрәф Мөдәррис һәм башкалар фронт газеталары редакцияләрендә эшлиләр. Аларның язмаларын, әдәби әсәрләрен бер хис, бер уй, бер максат берләштерә – Ватанны саклап калырга!

1943 елны Мәскәүдә Совет язучылары берлеге президиумы утырышы була. Көн тәртибендә төп мәсьәләләрнең берсе – татар язучыларының хисабы. Бөек Ватан сугышы барганда алар ниләр майтарып яталар икән? Докладны ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гази Кашшаф ясый. Шунда ук Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Кави Нәҗми, фронттан кайткан Гадел Кутуй, Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садрилар чыгыш ясый. Совет язучылары берлеге җитәкчесе Александр Фадеев гаҗәпкә кала. Татарстан Язучылар берлеге үзенең әгъзаларының 20 процентын сугышта югалткан да бит инде!

Дәһшәтле көннәр дәвам итә. Корбаннар саны арта тора. Бу сугышта Татарстан 31 язучысын, 22 журналистын югалта. Илебездә бу кадәр югалту кичергән Язучылар берлеге бүтән юк.

Бөек Җиңүнең 65 еллыгын каршыларга әзерләнеп йөргән көннәрдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә яу кырында һәлак булган язучылар турында китап чыгару мәсьәләсе күтәрелгәч, яңадан истәлек тактасы янына

килеп бастым. М.Җәлил, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, А.Алиш, Н.Баян, Х.Мөҗәй исемнәре халкыбызның йөрәк түрендә. Д.Фәтхи, К.Басыйров, М.Вәдүт, М.Әблиев, Х.Рахман, М.Гатау, Ш.Гәрәй, Ә.Камал, М.Мостафин, М.Мамин, Х.Кавилар мөстәкыйль җыентыкларын чыгарып өлгергәннәр. К.Вахит, М.Гаяз, М.Әхмәтгалиев, Г.Галиев, Ә.Гыймадов, А.Аитов, И.Шәфиев, И.Закиров, Ә.Әминев, С.Мөлековларның иҗаты исә бөреләнеп кенә килгән чак. Киләчәккә зур иҗади планнар белән янып, канатларны тагын да ныгытырга теләп йөргән чак. Их син, сугыш! Канлы, утлы, рәхимсез сугыш!.. Шушы тактаны ачканда, өлкән язучыларыбызның үзара сөйләшеп торулары искә төшә:

– Әблиев әйбәт драматург булыр иде.

– Мамин исә Такташ турында саллы фәнни хезмәт язды.

– Мөсәгыйть Мостафин хикәяләр остасы иде...

Сугыш барысын да үзенчә хәл итә. Каһарман-шагыйрь Фатих Кәримнең түбәндәге шигъри юлларын тетрәнмичә укып буламы?!

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен.
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Яуда һәлак булган татар язучылары турында мәгълүматларны, аларның әсәрләрен туплап китап чыгару яңалык түгел. Заманында эзтабар-язучы Самат Шакир моны эшләгән иде. Ул төзегән «Алар сафта» дигән китап чыкканга да чирек гасыр вакыт үтеп киткән икән. Бу чорда тулы бер буын үсеп җитте. Димәк, әлеге китапны яңартуны вакыт үзе сорый. Яу кырыннан әйләнеп кайта алмаган татар язучыларын, каһарман каләм ияләрен без белергә, онытмаска тиеш.

Китапта каһарман язучылар алфавит тәртибендә бирелә. Аларның биографияләре тулыландырылды, тормыш һәм иҗат юллары киңрәк яктыртылды. «Алар сафта» китабы чykканнан соң үткән 25 елда тормыш, вазгыять бик нык үзгәрде. Бу китапка кергән шигырь, хикәяләрнең, әсәрләрдән өзекләрнең дә бүгенге көнгә, бүгенге чорга авываздаш булырлыклары сайлап алынды.

Китапның татар халкыннан татар сугышчыларына, татар сугышчыларыннан татар халкына язылган хатларыннан башлануы да зур мәгънәгә ия. Халкыбызның, шул исәптән фронттагы татар язучыларының уртак уе, гаме белән сугарылган, аларның җан авазы, күңел сүрәсе булган күләмле вә киң колачлы бу хатларга китап укучылар битараф калмас дип ышанабыз. Фронтовиклар язган хатны безгә – Татарстан Язучылар берлегенә – Әхмәт Исхакның хатыны Гөлсем Исхакова алып килеп бирде. Иренең архивын барлаганда тапкан ул аны. Рәхмәт Сезгә, Гөлсем ханым!

Дошманга каршы штык белән дә, каләм белән дә көрәшергә көч тапкан, ялкынлы йөрәкле, курку белмәс каһарман язучыларыбызның рухы шат булсын!

**Илфак Ибраһимов**,
Татарстан Язучылар берлеге рәисе

## ИКЕНЧЕ БЕЛОРУССИЯ ФРОНТЫНЫҢ ТАТАР СУГЫШЧЫЛАРЫННАН ТАТАР ХАЛКЫНА ХАТ

Әй, гакыллы, якты йөзле безнең газиз аталар,
Саф күңелле, пакь йөрәкле, мәрхәмәтле аналар!

Әй, бер сукса тимер өзгән корыч куллы агалар,
Ак яулыклы, алъяпкычлы, нурлы йөзле апалар!

Әй, аксакал, изге җанлы, тугры сүзле бабалар,
Киләчәкнең чәчәкләре – безнең сабый балалар!

Әй, безнең иркә хатыннар – тормышыбыз дуслары,
Күңел тоткан кызларыбыз – җәйге таңның нурлары!

Тибрәнеп аккан елгалар, болын, калку, чишмәләр,
Туган учак, таныш яклар, урам, тыкрык, бистәләр!

Ямьдә балкыган авыллар, сахра, урман, тугайлар,
Барча иптәш, һәммә дус-иш, күрше-колан, туганнар!

Җиңү, шатлык көннәрендә алдык кулларга каләм
Язарга сезгә җавап-хат, язарга сезгә сәлам.

Юлыксын шунда сүзебез, – урман, таулар аркылы, –
Кайда яңгырый туган тел, безнең тел, татар теле.

Ишетсен безне Идел-йорт – һәммәбезнең әнкәсе –
Кайда борын-борынгыдан бәйләнгән татар чәче.

Тыңла безне, әй, туган җир, Ленин, Сталин тудырган,
Тигез, бөек, нык семьяга әгъза булып кушылган, –

Һәм тынычта хезмәт белән иң зур орден казанган,
Хак сугышта ныклы булып, эшчән булып дан алган, –

Балкып һаман җиңүләрдән, уңыштан, казаныштан,
Гөрләп үскән республика – бәхетле Татарстан!

Октябрьдән ялкынланып, очып төшкән чаткыдан
Зур, якты һәм саф ут булып мәңгелеккә балкыган, –

Хезмәт, иҗат казанында чирек гасыр кайнаган,
Багларында чут-чут итеп былбыллары сайраган, –

Кырларында бодай үскән, күлендә аккош очкан
Әй матур җир, әй газиз җир, туган җир – Татарстан!

Тыңла безне, көнгә каршы энҗедәй ялтыраган,
Шат шау-шулы кичке Казан, бәхетле таңлы Казан! –

Бөек Тукай йөрәк хисен, җырларын багышлаган
«И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!»

Җитсен сезгә уйларыбыз, якты булып, зур булып,
Ярсу солдат йөрәгеннән агып чыккан нур булып!

Барсын сезгә сәламебез, колач җәеп, киң булып,
Туган кырны сөеп, сыйпап, иртән искән җил булып!

Авыр сугышларда безгә көч, куәт, илһам салып,
Сәлам-хатыңны җибәргән кадерле туган халык! –

Бу давыллы зур көрәштә вәхши яуларга каршы
Батыр улларын күтәргән сугышчы – татар халкы!

«Сәлам сиңа, кайнар сәлам барча кызың-улыңнан,
Без зур җиңү тантанасын яулап алган урыннан, –

Йөрәк каннарыбыз аккан Кояш батыш ягыннан,
Идел-йортка ерак җирдән – ярсу Балтыйк ярыннан!

Без бүген синең улларың һәм сугышчы – кызларың,
Бик сагынып туган якның рәшәләнгән кырларын,

Саклап сиңа җылы хисләр җанда, йөрәк төбендә,
Хат язабыз бүген менә бәхетле җәй көнендә.

Шатлыгыбыз дәрья булып ярга сыймый ташканда,
Хат язабыз кыска ялда, тезеп җырга, дастанга.

Ирешсен сиңа хатыбыз мәңгелек китап булып,
Яуда җиңгән улларыңнан сугышчан хисап булып.

Юлыксын якты җырыбыз, саф көмеш күк ак булып,
Республика бәйрәмендә утырсын кунак булып.

Барсын сиңа, туган халык, безнең йөрәк җылыбыз,
Данлы бәйрәм хөрмәтенә балкып туган җырыбыз!

Җитсен дә ул горур кичеп тауны, суны, урманны,
Бәян итсен туганнарга безнең якты уйларны...

...Алган идек синең хатны язгы җепшек буранда,
Көньякта безнең җиңүнең тәүге таңы туганда.

Без ул вакыт башкаладан бик-бик якында идек,
Смоленщина кырларында, Вязьма ягында идек;

Без ул вакыт, канга батып, утлар аркыла идек,
Одер буена юллар салып, Сожга ашкына идек;

Килде синең сәлам-хатың күңел күген нурлатып,
Саф йөрәктән, пакь намустан ант иттек без шул вакыт:

Ант иттек без туган җирне явызлардан сакларга,
Соңгы тамчы канга чаклы Ватан хакын хакларга;

Башлаганны тәмамламый юлда туктап калмаска,
Җиңми торып кылычларны кыннарына салмаска;

Үч алырга фашистлардан янгын көлләре өчен,
Белоруссия, Украинаның канлы төннәре өчен;

Үч алырга, үч, канлы үч, халык кайгысы өчен,
Төрмә, богау, «җаналгыч»лар – барсы, барсысы өчен!

– Ант иттек без һәм тагын да ыргылдык утлар булып,
Барды бу үч мина, снаряд, бомба һәм уклар булып.

Үттек тарихта данлыклы киң һәм озын юллардан,
Смоленск шоссесыннан, калку, иңкел, урманнан.

Үттек алга, җиңүләрдән көч, рух алып тагын да,
Данлы маршал Рокоссовский гаскәрләре сафында.

Бардык алга батырларча, кичеп янгын кайнарын,
Һаман саен көнбатышка төртеп сугыш мәйданын.

Һәм үткән ел, июнь килгәч, чәчәкләнеп, нурланып,
Проня ярыннан һөҗүмгә – киттек алга кузгалып.

Киттек алга Днепр, Прут, Неман, Нарев аркылы,
Ургып барды Германиягә бөек һөҗүм ялкыны.

Килеп торды безгә һаман юлбашчының рәхмәте,
Күрде безне бөек Москва, бөтен совет дәүләте.

Беләккә көч, тәнгә куәт, йөрәккә илһам салып,
Һәр көн саен башкалада күкрәде безгә салют.

Онтылырмы бу эссе җәй, юллардан очкан тузан?
Коткарылды Белоруссия – хәсрәттә янган туган.

Азат итеп совет халкын, полклар алга барды,
Сарылды безнең кочакка, елап, белорус карты.

Балкыды кызыл комачтан азат совет кырлары,
Чәчкә сипте безнең өскә Гродно, Лида кызлары.

Үтеп чыгып туган илнең, газиз Ватанның чиген,
Уздык тагын озын юллар, коткарып поляк җирен.

Җитте вакыт: шатлык хисе басты шунда күңелне,
Безнең алда дошман өне – немец җире күренде.

Шушында Харис Фатыйхов, ярсый-ярсый йөрәге,
Ерак юллар үткән тубын Пруссиягә төзәде.

Гөрселдәде баһадирның бер-бер артлы туп шавы,
Төтенләнеп, актарылып, тузды немец туфрагы.

Бу шат көнне һәм бу тупны мәңге онытмас тарих,
Германиягә башлап атты Чистайда туган Харис!

Азат булды мәңгелеккә илнең соңгы карышы,
Күчте шулай Германиягә мина, снаряд тавышы.

Ерак калды Ватаныбыз – аксыл томан артында,
Көнен – якты нурлы кояш, төнен – ак ай астында.

Калды тынып аның чиксез, мөкатдәс киңлекләре,
Күчте аннан канлы сугыш, ут-ялкын диңгезләре.

Халкыбызда тагын да зур, сүрелмәс шатлык туды,
Төште соңгы җиңүләрдән балкыган таңның нуры!

Килде бу ел, суык гыйнвар, күрелмәгән дан белән,
Нарев ярыннан һөҗүмгә – киттек алга, таң белән.

Бу матур таң ядкарь булып калыр мәңге тарихта –
Колач җәйде бөек һөҗүм Бобр белән Наревта.

Актык алга ташкын булып, дошман явын җимереп,
Соңгы җиңү якынлыгын йөрәк белән сизенеп.

Киттек алга, көнбатышка, кичеп поляк җиреннән,
Уздык Млава, Дзялдоводан, үттек прусс чигеннән.

Бардык алга Пруссиядән, ачтык немец капкасын –
Кайтарырга илдә аккан күз яше һәм кан хакын.

Күтәрелде Германиягә совет халкы кылычы,
Басты болыт немец күген үлем, дәһшәт болыты.

Илтте безне, алга әйдәп, үч һәм нәфрәт ялкыны
Дойтш Эйлау, Мариенбург һәм Эльбинг аркылы.

Барды алга туган илнең мең-мең батыр баласы.
Бәрелде көйгән йөзләргә дымсу диңгез һавасы...

Үттек ут һәм кылыч белән, Балтикага юл ачып,
Нәләт төшкән прусс җирен як-ягыннан уратып.

Чапты язгы гөрләвекләр, көнгә каршы ялтырап,
Барды армия көнбатышка шөһрәт, данга яңгырап,

Үттек кичеп батырларча киң, тирән Висла суын,
Яңгыратты безнең корал урман, тау һәм яр буен.

Барды лачын-баһадирлар, уттай ташып, ярсынып,
Померания – немец җирен урталайга ярдырып.

Чигенделәр илбасарлар, күрми алда ак-кара,
Кысылды дошман диңгезгә, ныклы тимер алкага.

Онытмабыз Кезлин, Штольп, Нойштадт, Бютов янын,
Омтылдык без ярсып алга, тазартып Балтыйк ярын.

Онытмабыз дөрләп янган канлы сугыш төннәрен,
Данциг, Гдыня төпләрендә көчле штурм көннәрен,

Сугышларда азат итеп Гдыня белән Данцигны,
Ачтык кабат Польша өчен ябык торган Балтыйкны.

Артиллерия утларыннан Одер артын күкрәтеп,
Күрелмәгән баһадирлык, фидакарьлек күрсәтеп,

Юлда нинди киртә очрый – җиңеп чыгып барын да,
Ыргылдык без Штеттиннан көнбатышка тагын да.

Үттек кичеп батырларча, – җәеп һөҗүм утларын, –
Померания, Мекленбург, ерак Рюген утравын.

Үч алдык без явызлардан, нәфрәтләрне ут итеп,
Фашизмның бандаларын кырып, таптап, юк итеп.

Тәмамланды безнең поход кояш батыш ягында –
Борын-борынгыдан таныш ерак Эльба ярында.

Киң дөньяга хөр, мәһабәт совет гимны яңрады –
Күтәрелде рейхстагка безнең Җиңү Байрагы.

Бөек Җиңү – алтын кояш, безгә нурын балкытты,
Күрде шунда совет халкы иксез-чиксез шатлыкны.

Килде жиңү, сугышларда яулап алынган җиңү,
Тарих кулы белән безгә алдан язылган җиңү;

Җиңү, җиңү, алмаз нурга, ямьгә коенган жиңү,
Канлы кырда өлеш-өлеш дүрт ел җыелган җиңү!

Сөйде безнең аркабыздан тиңсез җиңү бәхете,
Тышауланды явызларның илбасарлык нәфесе.

Тарихта бу дошман өне – бу явыз җир, бу яткыр
Тетрәнде безнең куәттән инде ничәнче тапкыр!

Үтәп чыгып көрәшләрдә сугышчылык бурычын,
Төгәлләдек җиңү белән Бөек Ватан сугышын!

Авыр булды без үткән юл, йөрәкләргә сауды кан,
Үлем җиле, ялкын, тимер бәреп торды каршыдан.

Без алга, алга ыргылдык, бер чабып, бер тукталып,
Үтәп изге хәрби антны, аның белән рухланып.

Дивизияләр җиңү яулап алга агылган чакта,
Кыю, тәвәккәл коммунист барды алдынгы сафта.

Шаулый якты мактау җыры бездә кичен, таңында
Александр Жемчужников – кыю парторг хакында.

Изәп канлы кулъяулыгын, дусларын алга дәшеп,
Барды куркусыз большевик, дошманга утлар чәчеп.

Көчле, батыр арысландай, үчкә сусап, ярсынып,
Кичте шулай рус егете көчле сугыш ялкынын.

Берни түгел тән ярасы, куәт булса йөрәктә, –
Шөһрәт алды Жемчужников Ватан өчен көрәштә.

Тотып канлы партбилетын, ярсып, дошманга каршы
Батыр йөрәк – безнең Закир Җамалетдинов барды.

Алды үч, канлы каты үч, күпме немец-каһәрдән
Шөгер егете, большевик, яу күрке һәм каһарман.

Пуля тишкән партбилетын мәңгелек иткән батыр,
Сакланып телдә, дастанда, җырланып җырда калыр!

Керде ыргып сугышларга, мылтыгын алга төбәп,
Шәрифулла Хәмидуллин – коммунист, батыр йөрәк.

Барды алга сугышчылар юлбарыстай ярсынган
Шәрифулла Хәмидуллин – кыю парторг артыннан.

Үлем белән ул, бермә-бер кискен сугышка кереп,
Җиңеп чыкты әкияттәге үлмәс баһадир кебек.

Минометтан утлар чәчеп, ярсып, дошманга каршы
Кыю, сугышчан коммунист Габдерахманов барды.

Габдерахманов Шәйхинур – ул һичвакыт җиңелмәс,
Канга батар, ташка катар, бер карыш та чигенмәс.

Ул – ут йөрәк, курку белмәс, сугышта алга карар,
Туган урыны – Татарстан, милләте аның – татар.

Биреп канын, бөтен көчен, сәләтен, илһамын,
Яклый сугышчан коммунист халык хакын, ил хакын.

Ватан өчен сугышларда алып дошманның котын,
Илтте безне җиңүләргә большевик – батыр токым.

Баһадирлар алга барды, кичеп төтен болыты,
Ашкындырды йөрәкләрен изге партия билеты.

Безне җитәкли агабыз – мәңге көчле рус халкы,
Бар кабилә, бар халыкның иң тугры бер дус халкы.

Ул керде канлы сугышка, нәфрәтен хәнҗәр итеп,
Безне бергә беректереп, бербөтен гаскәр итеп.

Кичтек без аның артыннан көрәштә уттан-судан,
Командир да, дус та булды ул бөек, өлкән туган.

Үрнәк булды сугышларда, һәрвакыт алда барып,
Җитәкләде безне алга ул олуг, көчле халык!

Ул – безнең борын-борыннан бертуган кардәшебез,
Ул – безнең илдәш, табындаш, нәселдәш, кандашыбыз.

Ул бара килер тарихка, дан белән балкып бара,
Уртабыздан, мәгъруранә, тау сыман калкып бара.

Кичтек без аның артыннан гарасат ташкыннары,
Илтте безне аның шанлы сталинчыл маршаллары.

Рух бирде безгә сугышта ныгыган, үскән союз,
Бөек халыклар дуслыгы, сынауны үткән союз.

Без бер семья, таза йодрык, бергә килеп береккән –
Рус, татар, казах, молдаван, үзбәк, әрмән, төрекмән.

Бер үк безнең, аерылгысыз – һәммәбезнең теләге.
Уртак безнең Ватаныбыз – бөек дуслык терәге.

Булса расчетта биш кеше – биш өлкәдән бишесе:
Кайсы татар, кайсы таҗик, кайсы Алтай кешесе.

Калса татар яраланып, ярдәмгә чуаш килде,
Грузин ясап операция, белорус канын бирде.

Без алга, алга омтылдык, тотынышып кулга-кул,
Җомагыл, Тойвэ, Карабай, Федор, Сурен, Мулланур;

Без алга, алга ыргылдык бәхетле дөнья өчен,
Уртак идеал, уртак ватан, зур, бөек семья өчен.

Якты дуслык торды, җанга балкучан нурын сузып,
Калды җиңү, бердәмлеккә мәңгелек шаһит булып.

Рух бирде безгә сугышта, канлы кырларда һаман
Шәфкатьле иркә анабыз – мөкатдәс бөек Ватан.

Чакырды безне сугышка туган илнең быргысы,
Чакырды саф, изге тойгы – патриотлык тойгысы.

Тугры без бөек Ватанга бөтен җаныбыз белән,
Хисләребез, күз яшебез, йөрәк каныбыз белән.

Тугры без илгә – Ватанга – соңгы сулышка чаклы,
Изге безгә бөек Москва, һәм бөек совет халкы.

Ватан, ватан, алтын бишек, изге, шәфкатьле ватан,
Бөтен дөнья каршысында данлы, шәүкәтле ватан!

Җаныбыздан, каныбыздан җире кыйммәтле ватан,
Зур тарихлы, күп халыклы һәм күп милләтле ватан!

Багышладык мәңгелеккә канны-җанны шуңарга,
Аның кайгысы, шатлыгы, дәрте белән суларга.

Рух бирде безгә сугышта, хәтергә төшеп һаман,
Артта калган бөек тарих, данлыклы үткән заман.

Рәсәй-ватан башкаеннан күпме тарих кичерде,
Юк бүтән ил, күпне күргән, безнең зур ил шикелле.

Күрде һаман солдат күзе алда төнен, көндезен,
Александр Невскийның үткер очлы сөңгесен.

Күренде күзгә Альплар, Смоленщина кырлары,
Суворовның, Кутузовның зур, мәһабәт сыннары.

Басса да киң тугай өстен ут-төтен пәрдәләре,
Балкыды шунда аларның тылсымлы шәүләләре.

Торды безгә сугышларда, рух, куәт, илһам салып,
Рәсәйдә үткән тарихың синең дә, туган халык!

Торды хәтердә борынгы Идел-йорт лачыннары –
Данлы Ливон, Бородино, Перекоп батырлары.

Акбүз атның дагасыннан ташта чаткы чәчрәтеп,
Үткен йөзле кылычларын яшен кебек яшьнәтеп, –

Бу көндә дә барды сыман атка менгән улларың,
Рус белән бергә Берлинга ярып кергән улларың.

Сугышкан безнең балалар туган җир өчен янып,
Рус белән бергә тарихның гүзәл битләрен язып.

Тарих аларның даннарын язган алтынга каеп,
Үттек авыр сугыш юлын булып шуларга лаек.

Шул тарих балкып һаман да безнең күзгә чагылды;
Рәсәй өчен, киң ил өчен сугышларга чакырды.

Зур мирас калды үткәннән, – йөзгә кабатлап шуны,
Бөек Ватан сугышында меңнәрчә батыр туды.

Яңгырый безнең фронтта батыр егетләр даны,
Күктә йолдыз күпме булса – шунча аларның саны.

Алар тиңсез дан алдылар бу зур сугыш көнендә,
Пултуск, Торунь, Грауденц, Лауэнбург төбендә.

Дан алдылар, танылдылар бөтен дөнья алдында,
Штеттин, Росток, Пренцлау, Ангермюнде астында.

Һәм тагын да бар дөньяга, киң тарихка балкыды
Константин Рокоссовский – зур һөҗүмнәр маршалы.

Илтте безне җиңүләргә, шанда, шөһрәттә шаулап,
Рокоссовский – полководец, сталинчыл батыр солдат.

Җитәр өчен җиңү дигән изге, гадел теләккә,
Безне батыр генераллар алып барды көрәшкә.

Барып җитеп сезгә бу җыр горурланып сөйләсен
Сталинчыл оста, тапкыр генераллар шөһрәтен.

Сулап явыз Германиягә ут, тимер дәһшәтләре,
Барды генерал-лейтенант Чанышев гаскәрләре.

Илтте безне солдатларда якты хөрмәт казанган
Якуб Чанышев – генерал һәм сугышчы-каһарман.

Бу зур көрәш, бөек еллар күтәрде аның намын,
Гражданнар сугышында яктырып туган даны.

Кичеп поход чакрымнары һәм сугыш мәхшәрләре,
Барды гайрәтле генерал Булатов гаскәрләре.

Омтылдык без ярсып алга кургаш яңгыр астыннан,
Фатыйх Булатов – генерал һәм сугышчы артыннан.

Кертте ул безне сугышка чыныктырып, ныгытып, –
Мактан, Казан, аның белән, һәм горурлан, Тымытык!

Вөҗдан безне, «Үч ал!» диеп, сугышка-яуга илтте,
Хәбиб Ганиев – генерал җитәкләп алга илтте.

Бирде рух безгә көрәштә җитәр өчен максатка,
Ул – большевик, нык җитәкче, ул – якын дус солдатка.

Баһадирлар Германиягә кистереп, ярып керде,
Безне батыр офицерлар сугышка алып керде.

Ашкындык без алар белән, үчкә – үч, канга кан сорап,
Каһәр төшкән дошман җире торды алда калтырап.

Күп алар бездә данлылар һәм озын ул бездәге
Оста, тапкыр офицерлар, генераллар тезмәсе.

Җырлыйбыз без җырыбызда, шаулатып гасырларны, –
Бездәге Алтын Йолдызлы шөһрәтле батырларны.

Менә Герой Гыйззәтуллин, батыр егет Хамазан,
Күкрәгенә Алтын Йолдыз – данлы билге кадаган.

Ул – киң Днепр елгасыннан башлап кичкән баһадир,
Көчле егет, корыч өзгән, броня тишкән баһадир;

Дошманның күпме танкысын, тубын ваткан баһадир,
Хак сугышта, зур һөҗүмдә шөһрәт тапкан баһадир.

Менә Герой Гайнетдинов, егет җитез, фидакарь.
Җиңеп чыкты дошман өерен күп булса да никадәр.

Гайнетдинов Мөхәммәтдин – Герой булган сугышчы,
Су өстеннән, ут астыннан чыбык сузган сугышчы,

Һәм иң алдан, горурланып, ярга менгән сугышчы;
Уттан – суга, судан тагын утка кергән сугышчы.

Менә Герой Габдуллаҗан Булатов – сабыр егет,
Сугышта – шашкын баһадир, гайрәтле, батыр егет.

Пулеметының көпшәсен кызарганчы кыздырып,
Көчле уттан немецларны дистә-дистә кырдырып,

Авыр сугышлар юлыннан давылдай үткән кеше,
Балтачта туып, сугышта Геройга үскән кеше.

Менә Герой безнең Вилдан Хәбиев – ашкын егет,
Җиңелмәс, артка чигенмәс, гайрәтле, ялкын егет.

Минометының дәһшәтен дошманнарга күкрәтеп,
Сугышларда алдан барып, безгә үрнәк күрсәтеп,

Дошман явын бик күп кырып, җимергән, куган кеше,
Булып нурлы Алтын Йолдыз, балкырга туган кеше.

Күп алар бездә, Геройлар, сугышларда калкучы,
Даннары Алтын Йолдызда еракларга балкучы.

Җырлыйбыз без җырыбызда горурлык белән тагын,
Меңнәрчә якташ батырлар, каһарман уллар данын.

Гөрләсен җыр, шауласын җыр, данга күмеп мактасын
Гади укчы, тупчы, сапер, гади совет солдатын.

Бар бездә бөтен фронтта данлы исеме шаулаган,
Танк белән дистә-дистә гитлерчыны таптаган,

Дошман җирен басып үтеп, көрәшләрдә дан алган,
Әсәт Шахманов – сугышчы, танкчы егет, каһарман.

Бар аның якын дуслары, өч батыр һәм нык егет:
Лаптев, Мищинин, Игумнов – барсы арыслан кебек.

Лаптев – танк командиры, каны – кайнар, рус каны.
Татар, казах һәм белорус – кырындагы дуслары.

Барды аларның танкысы, киң юл салды чылбыры, –
Тапталды, җирдә сытылды фашист – үләт кыргыры.

Барды аларның танкысы, сулап бөтен сулышка,
Дүрт кыю дус, игзәк туган, керде бергә сугышка.

Кем дисәгез – очып барып эскадрилья алдыннан,
Штурм ясап, дошман явын кырган, изгән, яндырган? –

Ул – офицер Хәлиуллин Мисбах, егет, яшь батыр,
Бөгелмәдән яуга килгән, көрәштәш, якташ батыр.

Бар бездә – сугып яшендәй, дошман явын җимергән,
Аркылы фронт сызыгын, «тел»ләр тотып китергән,

Төннәрендә пычак булып, дошманнарга кадалган,
Данлы Әскәров Гарәфи – разведкачы каһарман.

Бар аның якын дуслары – игзәк туганнар төсле,
Берсе Емченко Николай, Салихов Әхәт берсе.

Берсе ятып саклап калды, икесе «тел»гә ташланды,
Шулай итеп, бу өч батыр кыен эшләр башкарды.

Шулай алар бергә-бергә булып батыр һәм чыдам,
Суктылар барып дошманга җанлы яшеннәр сыман.

Алдылар бергә дошманнан ярсулы солдат үчен,
Емченконың Украинасы, семьясы, йорты өчен.

Кем дисәгез – дошман өчен үлем тынын сулаткан,
Төзәп немец танкларына һәлак иткеч туп аткан? –

Ул – безнең Гариф Харисов, бездә данлы, хөрмәтле,
Омтылышлы зур һөҗүмнәр аның исемен гөрләтте.

Самолетның винты белән төнге күкне ярдырган,
Һәлак иткеч бомбаларын дошманнарга яудырган

Ул – Мәгубә Сыртланова, гвардияче батыр кыз,
Идел-йортта канат ярган лачын йөрәк, лачын кыз.

Бар аның бер көрәштәше, юлдаш, иптәш, дус кызы,
Тоня Розова – штурман, курку белмәс рус кызы.

Ирек, шатлык, хокук, бәхет, азатлыкны саклауда,
Рус кызы һәм татар кызы барды алгы сафларда.

Суктылар алар дошманга, ут-яшен күк булдылар;
Мәгубә – илтте очкычны, Тоня – койды бомбалар.

Кичтеләр алар бергәләп бөек сугыш ялкынын,
Кара төннәр караңгысын, болыт, томан, яңгырын.

Дәһшәтле сугыш алласы – артиллерия көченнән
Күп фашистны, күп киртәне кырып, ватып бетергән

Ул – Җиһаншин, ул – Габдулла, туган яктан бер батыр,
Дивизионын алга илткән, чыныккан, тимер батыр.

Пехота – кырлар патшасы, бар шунда бер сугышчы,
Уттан-судан алга барды, үтәп барлык бурычны.

Бик күп кырды дошманнарны бу пехота укчысы.
Ул – Габдулла Насыйбуллин, җитез егет, ут кеше.

Бар аның бер көрәштәше, бер яшь егет, мут егет,
Чыныктылар алар бергә сугыш кырында йөреп,

Ул яшь егет – азәрбайҗанлы Мөхәррәм Кәрим углы.
Үттеләр алар бергәләп жиңүгә илткән юлны.

Барды алга бу ике дус, барын бергә кичереп,
Яуның барлык бетон өнен, киртәләрен җимереп.

Барды алга бу ике дус, үтеп чит-ят басудан,
Берсе – безнең туган яктан, берсе килгән Бакудан.

Өстә һаман бер-бер артлы мина, снаряд улашты,
Шунда да нык, батыр сапер батальонга юл ачты.

Бу – үлемсез, көчле егет, гвардиянең саперы
Ваһап Шаһиев – сугышчы, Татарстан батыры.

Барды сугыш бер тынып та, бер кабынып яңадан,
Шунда Завьялов – командир ауды җиргә ярадан.

Килде шулчак Рәхмәтуллин аңар ярдәм бирергә,
Карамыйча өстән яуган ут, ялкын һәм тимергә.

Каршы яктан нинди көчле утлы җилләр исмәсен,
Килде Касыйм коткарырга командирын, иптәшен.

Алсу каннан ап-ак карлар бизәкләнгән урыннан
Алып чыкты русны татар, йолып дошман утыннан.

Батыр егет, командирын калдырмады әҗәлгә,
Калды Завьялов исән-сау, тагын йөз ел яшәргә.

Безнең Касыйм Рәхмәтуллин – җитез, батыр, чыдамлы,
Утлы кырдан берне түгел, йөзне йолып чыгарды.

Бөтәрләнеп утлы давыл купты бөтен якларда,
Шәмси Вәлиев – рядовой, пулеметтан атканда.

Кырды шулай палачларны Шәмси – татар солдаты,
Ураз Җаббаров – төрекмән бирде патрон тасмасы.

Күбәү алар баһадирлар, безнең сафта барсы да,
Күкрәкләрен өчәр-дүртәр орден, медаль балкыта.

Әй сез, безнең көрәштәшләр, уйдаш, якташ, илдәшләр,
Ата-ана, кардәш, дус-иш, тугрылыклы иптәшләр!

Безгә ярдәм иттегез сез, гайрәт, куәт китереп,
Бергә янып, бергә сулап, барын бергә кичереп.

Безгә ярдәм иттегез сез, бик күп авырлык күреп,
Көнне-төнне бергә ялгап, маңгай тирләре түгеп;

Батырларча чыдам булып, ял-йокыдан ваз кичеп,
Заводларда, кырда эшләп, юллар төзеп, таш кисеп.

Улларыгыз Ватан өчен батырларча сугышты,
Тоеп сезнең мәхәббәтне, сезнең җылы сулышны.

Торды безнең күз алдында фабрика корпуслары,
Арча, Сарман, Әлки, Кайбыч, Азнакай колхозлары.

Эшләдегез бер семьяга, бер отрядка тупланып,
Безнең бөек җиңүләрдән канатланып, рухланып.

Гөрләде күктә очкычлар, күкрәде тупларыбыз,
Рәхмәт сезгә болар өчен, сугышчан дусларыбыз!

Күз ачкысыз кышкы буран китсә дә кырны күмеп,
Туңдырмады сезнең кием, сезнең колаклы бүрек.

Булды һаман безнең өчен сезнең йөрәк хисегез,
Илһам, сәләт, талантыгыз, бөтен гакыл көчегез.

Фән, техника, культурада алтын битләр яздыгыз,
Килеп торды безгә һаман сезнең иҗат яктыгыз.

Шушы сезнең фидакарьлек, хезмәттәге батырлык –
Мәңге-мәңге онтылмаслык, тарихларда калырлык!

Шулай, дуслар, батырларча хезмәт итеп тагын да,
Ватан өчен, халык өчен багышлагыз барын да!

Илгә һәр көн үсеш бирсен сезнең эшчән кулыгыз,
Яуда җиңгән батырларга лаеклылар булыгыз!

Борылмагыз каршы яктан көчле җилләр бәрсә дә,
Артсын хезмәт җимешегез тагын өч-дүрт мәртәбә!

Яулагыз колхоз кырында, яхшы эшләп, зур уңыш,
Һичвакыт та, һичкайда да күрелмәгән мул уңыш!

Тормышыбыз – киң туган ил, данлы, кадерле ватан,
Корычланып, колач җәеп, ныгысын, үссен һаман!

Без, үтәп сезнең наказны, илгә шатлык китердек,
Явыз фашист урдаларын изеп, таптап бетердек!

Үч алдык без явызлардан, үтәп вөҗдан кушканын,
Яптык барып Берлиндагы ут һәм сугыш вулканын!

Үттек кичеп кылыч белән барлык утлы сызыктан,
Германияне мәңгелеккә биздерергә кылычтан.

Без, үтәп маршал, юлбашчы, бөек Сталин боерыгын,
Күтәрдек изге, мәңгелек, тиңсез Җиңү байрагын.

Өстебездә җилфердәгән шушы байракка карап
Ант итәбез, сугышчан ант, халкыбыз, сиңа кабат:

Йөрсәк тә без туган илдән ерак җирдә, читләрдә –
Изге булып, якты булып, Ватан торыр хисләрдә!

Туган Кызыл Армия өчен бөтен көчне салырбыз,
Аның барлык кануннарын төгәл үтәп барырбыз!

Биек тотып җиңүченең мәртәбәсен һәм данын,
Хәзер торырбыз үтәргә илнең бөтен фәрманын!

Мең яшәсен ныклы Союз – якты бәхет терәге!
Башкалабыз бөек Москва – туган илнең йөрәге!

Мең яшәсен туган җирдә канат ярган лачыннар!
Рус коралын данга күмгән һәм җиңүчән батырлар!

Мең яшәсен Кызыл Армия – тимер куллы сакчыбыз!
Эштә тырыш, яуда батыр һәм патриот халкыбыз!

**Хатка кул куйдылар:**

Генерал-лейтенант *Якуб Чанышев*, Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, II дәрәҗә Суворов, I дәрәҗә Кутузов орденнары һәм «ЭККАның XX еллыгы» медале белән бүләкләнгән; генерал-майор *Фатыйх Булатов*, Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, II дәрәҗә Суворов һәм «Мактау билгесе» орденнары кавалеры; генерал-майор *Хәбиб Ганиев*, Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; Советлар Союзы Герое өлкән лейтенант *Габдуллаҗан Булатов*; Советлар Союзы Герое лейтенант *Хамазан Гыйззәтуллин*; Советлар Союзы Герое кече лейтенант *Вилдан Хәбиев*; Советлар Союзы Герое өлкән сержант *Сәетнәфи Сәетвәлиев*; Дан орденының тулы кавалеры кызылармеец *Хөсәен Зарипов*; Дан орденының тулы кавалеры кызылармеец *Даян Булатов*; подполковник *Солтан Газизов*, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз һәм «Мактау билгесе» орденнары кавалеры; подполковник *Сергей Кожевников*, Ленин ордены, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм ике Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; подполковник *Нургали Байбиков*, ике II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм өч медаль иясе; майор

*Кәшаф Юмаев*, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; Татарстан АССР Верховный Советы депутаты майор *Алексей Марков*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; майор *Гани Гыйльманов*, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; майор *Шәриф Булатов*, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; майор *Хикмәт Моратов*, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сталинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; капитан *Хаҗи Фәттахов*, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сталинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; фронтовик-шагыйрь *Шәрәф Мөдәррис*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия капитаны *Насыйп Гобәйдуллин*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; капитан *Җиһанша Кашшапов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; капитан *Хаҗи Булатов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; кызылармеец *Миңлезариф Шадаев*, II һәм III дәрәҗә Дан, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Мөхәммәт Сөбханкулов*, III дәрәҗә Дан ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Вәли Җиһаншин*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; капитан *Сөләйман Хәеров*, Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; кызылармеец *Габделхәй Кәбиров*, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм ике Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; кече лейтенант *Каюм Габдерәхимов*, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; кече лейтенант *Ибраһим Әхмәров*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; фронтовик-язучы *Хатип Госман*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Гаделша Алешин*, II һәм III дәрәҗә Дан, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; гвардия старшинасы *Кутуз Галиев*, II дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм дүрт медаль иясе; гвардия өлкән лейтенанты *Мәгубә Сыртланова*, Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Кавказ оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Әлтәф Гайнетдинов*, III дәрәҗә Дан ордены кавалеры; кызылармеец *Муллый Ягъфәров*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; кызылармеец *Әхәт Салихов*, II һәм III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән сержант *Габдерахман Галимов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; медицина хезмәте өлкән лейтенанты *Ләлә Габбасова*, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән; капитан *Абдулла Әхмәдиев*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Галим Нуретдинов*, I дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры; кызылармеец *Равил Гайнетдинов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән лейтенант *Сәмигулла Мөхәммәтдинов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия старшинасы *Рөстәм Халитов*, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; фронтовик-язучы *Гамир Насрый*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; старшина *Шамил Хәйруллин*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Хәмит Хөсәенов*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; кызылармеец *Хәйретдин Айзәтов*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Әхмәтҗан Хәсәншин*, Кызыл Байрак ордены кавалеры; кече сержант *Мөсәтдика Шаһиәхмәтова*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия өлкән лейтенанты *Фәрваз Хөсәенов*, Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; сержант *Ирек Халиков*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия өлкән лейтенанты *Дәминдар Паскиев*, ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән; сержант *Петр Сафронов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Касыйм Рәхмәтуллин*, Кызыл Байрак ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; майор *Абдулла Янбарисов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; лейтенант *Габделхәй Салеев*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; кече сержант *Җәүһәр Шакирова*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән сержант *Сәгыйть Бәдретдинов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; старшина *Якуб Мостафин*, III дәрәҗә Дан ордены һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; Татарстан АССР Верховный Советы депутаты сержант *Рәхим Шәрипов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; өлкән сержант *Каюм Фәсхетдинов*, II һәм III дәрәҗә Дан орденнары, «Батырлык өчен» һәм «Ленинград оборонасы өчен» медальләре белән бүләкләнгән; кызылармеец *Гариф Шәймурзин*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия кызылармеецы *Рәхимҗан Әхмәдиев*, III дәрәҗә Дан ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Нурмөхәммәт Мәһдиев*, ике медаль иясе; кызылармеец *Шакир Вәлиев*, өч медаль иясе; фронтовик-язучы *Атилла Расих*; сержант *Әнвәр Байтимеров*, II дәрәҗә Ватан сугышы, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Җәүһәр Гәрәева*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия сержанты *Заһидулла Фәтхуллин*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; ефрейтор *Хатип Сәхабетдинов*, «Сугышчан

хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән сержант *Муллагали Мостафин*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; гвардия сержанты *Габдулла Едиханов*, I дәрәҗә Ватан сугышы, III дәрәҗә Дан, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; өлкән сержант *Нигъмәт Фәррахов*, Кызыл Йолдыз һәм III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры; өлкән сержант *Тәзкирә Әхмәдиева*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Хаҗи Фәезов*, III дәрәҗә Богдан Хмельницкий ордены кавалеры; старшина *Мансур Мостафин*, III дәрәҗә Дан ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; медицина хезмәте капитаны *Гөлйөзем Хәмидуллина*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; фронтовик-художник *Мәхмүт Усманов*; кече лейтенант *Сәхи Галиуллин*, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Сабур Хуҗасәетов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе һәм башкалар.

Хатка барлыгы 4000 нән артык кеше кул куйды.

*Шагыйрь Аитзәк Аитов 1908 елның декабрендә хәзерге Саратов өлкәсенең Дергач районы Алтата авылында крәстиян гаиләсендә туа. Сабый чакта ук әтисез калып, җиде яшеннән үз көнен үзе күреп үсә: көтү көтә, ялчылыкта йөри. Октябрь инкыйлабыннан соң, хакимият вәгъдә иткән яңа тормыш кору идеяләре белән рухланып, авылда беренчеләрдән булып комсомолга языла. 1928 елда район комсомол комитеты яшь егетне Мәскәүгә кыска мөддәтле курсларга укырга җибәрә. Укуын тәмамлап кайтканнан соң, А.Аитов туган төбәгендә төрле җаваплы урыннарда эшли, 30нчы еллар башында берникадәр вакыт авыл советы рәисе булып та тора. Аннары Донбасска китеп, шахтер хезмәтен башкара. Шушы елларда ул бик мавыгып әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый: шигырьләр, очерклар, мәкаләләр яза. Алар шул елларда (1930–1937) Донбасста (Сталино шәһәрендә) татар шахтерлары өчен чыгып килгән «Пролетар» газетасында даими басылып торалар.*

*Ватан сугышы башлануга, А.Аитов фронтның алгы сызыгында. 1941 елның 23 октябрендә Смоленск өлкәсендәге Демидов шәһәре өчен барган сугышларның берсендә ул дошман пулясыннан һәлак була.*

*Аитзәк Аитовның зур булмаган шигъри иҗатында шул чор өчен характерлы темалар – авылны күмәкләштерү, илне саклау, комсомол яшьләр тормышы, хезмәт темалары яктыртыла. Шагыйрь иҗат мирасыннан аерым үрнәкләр 1961 һәм 1985 елларда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкларда урын ала.*

**САКТА**

Саргылт бөдрә чәчле,
Соры күзле,
Шат күңелле егет син идең.
Кулыңа мылтык алып постка бастың,
Кызылармеец дустым, син бүген.
Мин беләмен сине, трактор заводында
Деталь әзерләдең, егетем,
Аерылдың син сөйгән станоктан,
Теләп алдың сакчы билетын...

* * *

Ярга бәрелә, ярга таба чәчелә,
Ярның битен үбә дулкыннар,
Ярдан ашып, ярны узмак була,
Ярга сузыла шаулы дулкыннар...
Исмә, давыл, тукта!
Тынлык сакласыннар дулкыннар!
Әнә кемдер төннең уртасында
Яр битендә утыра явыз уй уйлап...
Әллә, караңгы төннән файдаланып,
Бандит сер алырга чыкканмы?
Әллә адашканмы?
Әллә аны кемдер

Бугазыннан барып тотканмы?
Әй, якын килмә!
Юкса сакчы мылтык төзи кара шәүләңә...
Бу – безнең чик!
Никадәрле дулкын котырса да,
Сакчы сизгер тора ил өчен,
Чигенмәс ул дошманнардан куркып,
Үлсә үләр туган җир өчен!
Караңгы төн сезгә файда бирмәс,
Без җуябыз кара шәүләне,
Ай качса да болыт астына,
Сакчы күрер качкын гәүдәне.

*1935*

**ЧАҢГЫДА**

Кышны ямьсез диләр,
Ялганлыйлар,
Булдыксызлар гына шулай ул,
Ударникка салкын кыш та дус:
– Чаңгың белән кил, ди,
Суза кул.
Ябалактай ак кар төшкәч тә,
Бизәк ясап аңар,
Чаңгычылар үтә болыннан,
Ерак юллар тиз-тиз якынлаша,
Җил дә керми безнең куенга.
Выж... киләсең,
Чаңгың алга йөгерә,
Тән кызыша, күкрәк киңәя,
Даулап китсә чаңгың,
Ауналасың,
Йөрәк батырлана, сөенә...
Вәлине әйтәм,
Рабфак егетен,
Откатчица Мәрьям белән бергәләп
Киң яланда
Ап-ак кар өстендә
Чаңгы шуалар аунап-тәгәрәп.
Мәрьям – тырыш кыз ул,
Откаткада вагон куган күк,
Чаңгыда да шуа-өйрәнә,
Кара чәчен җил тарата,
Кабаланып шуып килгәндә.
Вәли белән кулга-кул тотынып,
Карны үбә алар чаңгысы,
Әй күңелле,
Парлап йөгерәсең,
Бер-береңнән артта калышмый.
Эшчән кызлар,
Эшчән егетләр
Кышның ямен шулай табалар,
Кыр казлары кебек
Сафка тезелеп,
Чаңгычылар кырга китәләр.

*1938*

*Совет чоры татар балалар әдәбиятының күренекле вәкиле һәм 1941–1945 еллардагы Ватан*

*сугышы каһарманы Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Спас районы) Көек авылында урта тормышлы игенче гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. Аның ата ягыннан бабасы Нурулла шушы авылның нәселдән килгән указлы мулласы булып, әтисе Габделбари абзый, дүрт ел солдат хезмәтендә йөреп кайтканнан соң, ата йортында күбрәк хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгән – иген иккән, умарта караган. Табигате белән киң күңелле һәм үз заманы өчен алдынгы фикерле кеше буларак, ул өйгә төрле газета-журналлар алдырган, балаларын кече яшьтән үк хезмәткә өйрәтергә, белемле һәм тәрбияле итәргә тырышкан. Абдулланың әнисе Газизә апа да авыл халкы арасында укымышлы хатын булып саналган, әдәбиятны бик яратып, шигырьләр һәм бәетләр чыгарырга һәвәс булган. Абдулла шушы тату, хөр фикерле һәм хезмәт сөючән ишле гаиләдә кечкенәдән үк зирәк һәм зиһенле малай булып үсә, алты-җиде яшьләрендә әнисеннән укырга-язарга өйрәнә, аннары авылдагы ибтидаи (башлангыч) мәктәптә укый.*

*1917 елда тугыз яшьлек Абдулланы әтисе үзләреннән унбиш чакрым ераклыктагы Ямбакты авылы мәдрәсәсенә илтеп бирә. Абдулла монда 1919 елга кадәр укый. 1919–1921 елларда туган авылларына күрше Бураково дигән рус авылында яңа ачылган совет мәктәбендә укуын дәвам иттерә, аннан Спастагы (1991 елдан Болгар шәһәре) педагогия техникумы каршында оештырылган җидееллык рус мәктәбен тәмамлый (1927). Мәктәптә уку елларында, фәннәрне бик яхшы үзләштерү белән бергә, драма һәм әдәбият түгәрәкләре, музыкаль кичәләр оештыру, стена газеталары, кулъязма журналлар чыгару кебек мәдәни эшләрдә башлап йөрүчеләрнең берсе була, үзе дә шигырьләр, кечкенә күләмле хикәя-парчалар язуда каләмен тибрәтә башлый.*

*1927 елның җәендә А.Алиш Казанга килә һәм Казан җир төзү техникумына укырга керә. Техникумда уку чорында (1927–1930) аның әдәбият белән кызыксынуы тагын да арта: ул шәһәрдәге әдәбият түгәрәкләренә мавыгып йөри, техникумда кулъязма рәвешендә чыгып килгән «Кызыл төзүче» исемле газета һәм «Яңа белгеч» дигән журнал идарәсенең актив әгъзасы була, техникум һәм яшьләр тормышы турында язган хәбәрләре, мәкаләләре белән республика көндәлек матбугатында да катнаша башлый. 1929 елда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында «Абдул Алишев» имзасы белән яшь авторның «Әти, эчмә!» дигән беренче хикәясе басылып чыга. Аннан соң күп тә үтми, балалар тормышын, аларның җәмгыятькә файдалы хезмәттә катнашуларын һәм күңелле ял итүләрен тасвирлаган «Бозлар акканда», «Нәни кооператор», «Отряд умартасы» кебек кечкенә хикәяләре дөнья күрә.*

*Җир төзү техникумын тәмамлагач, 1930 елның гыйнварыннан көзенә кадәр А.Алиш Минзәлә кантоны җир бүлегендә мелиоратор булып эшли, аннан, 1931–1932 елларда, янә Казанга кайтып, Казгрэс (ТЭЦ №1) төзелешендә гидротехника буенча десятник һәм Казан шәһәр канализациясе төзелешендә техник-бригадир вазифаларын башкара. 1933 елда әдәби зәвыкка ия булган яшь белгечне Казанда татарча чыга торган «Техника» журналының җаваплы сәркәтибе итеп билгелиләр. 1937 елдан Ватан сугышы башланганга кадәр А.Алиш «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы редакциясендә һәм Татарстан радиокомитетында әдәби мөхәррир хезмәтендә. 1936 елдан башлап, төп эшеннән аерылмыйча, Казан педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Бер үк вакытта А.Алиш балалар арасында әдәби түгәрәкләр оештыру юнәлешендә бик актив эшли. 1933 елдан ул җәмәгать эше тәртибендә әүвәл Мулланур Вахитов исемендәге завод каршындагы, аннары Казанның Үзәк пионерлар клубы, Идел буе районының балалар китапханәсе, 1936 елдан «Пионер каләме» журналы редакциясе каршындагы әдәби түгәрәкләргә җитәкчелек итә, өлкән дус һәм остаз буларак, дистәләрчә балаларның әдәби сәләте ачылуга эчкерсез ярдәмен күрсәтә. Казаннан читтә яшәүче яшь каләмнәр белән хатлар алыша, әдәби иҗат эшенең серләре хакында аларга үзенең фикер-карашларын, киңәш-теләкләрен язып җибәрә, матбугатта махсус балалар иҗатына багышланган мәкаләләр бастыра. Соңыннан әдәбиятта исемнәре танылган Җәвад Тәрҗеманов, Гарәфи Хәсәнов, Рафаил Төхфәтуллин, Мәхмүт Хөсәен, Самат Шакирлар нәкъ менә Абдулла Алишның турыдан-туры иҗади ярдәме һәм киңәшләре белән рухланып әдәбият мәйданына аяк басалар.*

*30нчы еллар – Абдулла Алишның әдип буларак иң күп язган, әсәрләре белән үзен яшь укучыларга таныткан чор буларак та үзенчәлекле. Аның балалар өчен «Отряд флагы» (1931), «Дулкыннар» (1934), «Ант» (1935) исемле хикәя җыентыклары, «Йолдыз» (1935), «Кечкенә тоткын» (1941) исемле пьеса-лары (беренчесе А.Әхмәт белән берлектә язылган), 1940 елда «Илгиз белән икебез» һәм «Минем абый» исемле ике шигырь китабы басылып чыга. Язучы зурлар өчен дә нәтиҗәле эшли: күмәк хезмәт темаларына багышланган күпсанлы очеркларын, яшьләр арасында мәхәббәт, гаилә кору кебек әхлакый мәсьәләләрне яктырткан «Яңа килен» (1931), «Тиздән туй» (1939), «Кыйммәтле җәүһәр» (1940) исемле хикәяләрен, «Күршеләр» (1934, А.Әхмәт белән берлектә язылган) исемле дүрт пәрдәле пьесасын язып бастыра, 1932 елда исә аның Татарстандагы шул чор зур төзелешләреннән Казгрэсны аякка бастыруда хезмәт энтузиазмын чагылдырган, шул хезмәт киеренкелеге шартларында кешеләр арасында яңача мөнәсәбәтләр формалашуын заманга хас идея-эчтәлек таләпләре яссылыгында шактый җанлы итеп, романтик күтәренкелек белән сурәтләгән «Якты күл буе» (1933) исемле*

*күләмле повесте дөнья күрә.*

*Шулай да Абдулла Алишны балаларның сөекле язучысы итеп таныткан әдәби өлкә ул әкият-хикәят жанры әсәрләредер. Әдипнең «Капкорсак патша» исемле беренче әкияте 1934 елгы «Пионер каләме» журналының 2 нче санында басылып чыга һәм нәни укучылар арасында бик тиз популярлык казана. Шуннан соңгы биш-алты ел эчендә (1935–1941) А.Алиш ике дистәдән артык әкият һәм хикәятләр иҗат итә («Нечкәбил», «Сертотмас Үрдәк», «Койрыклар», «Мактанчык Чыпчык белән тыйнак Сыерчык», «Песиләр һәм Күселәр», «Чуар тавык», «Бал Корты һәм Шөпшә», «Кем көчле?», «Бикбатыр белән Биккуркак», «Чукмар белән Тукмар», «Куян кызы», «Бик яхшы сабак алды Ябалак», «Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык» һ.б.). Нигездә, рифмалы ритмик проза калыбында, балалар психологиясенең бөтен нечкәлекләрен тоеп, композицион яктан төзек-җыйнак, уку өчен кызыклы-маҗаралы, музыкаль яңгырашлы итеп, сурәтләү чараларына бай, образлы тел белән язылган бу әкиятләр һәм хикәятләр нәниләрнең акыл сәләтен, фантазияләрен үстерүдә, кечкенәдән үк балаларда хезмәтне ярату, ата-анага, олыларга ихтирам саклау, гадел, намуслы булу, әйләнә-тирә табигатькә, терек дөньяга сак караш булдыру кебек әхлакый, әдәплелек сыйфатларын тәрбияләүдә бүгенге нәни укучылар өчен дә үзләренең әдәби-сәнгати әһәмиятләрен югалтмыйлар. А.Алиш әкиятләренең зур тиражлар белән кат-кат басылулары һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп уңыш казанулары да шул хакта сөйли.*

*Ватан сугышы башлангач, А.Алиш 1941 елның июль аенда армиягә алынып фронтка озатыла һәм солдат-радист сыйфатында Орел өлкәсендә барган оборона сугышларында катнаша. Шул елның 12 октябрендә Брянск шәһәре тирәсендәге канлы бәрелешләр вакытында чолганышта калып, ул немец-ларга әсир төшә. 1941 елның кышын Литвадагы хәрби әсирләр лагеренда тотканнан соң, 1942 елның язында фашистлар аны Чехословакиядәге Сандау шәһәренә күчерәләр. Ахырда ул Польшадагы Седльце шәһәренә, аннан Берлин янындагы Вустрауга килеп эләгә. Монда А.Алиш Германия гаскәри көчләре составында татар әсирләреннән төзелгән «Идел-Урал легионы»нда антифашистик яшерен оешма әгъзасы Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, аларга кушылып, тиз арада яшерен оешманың иң актив әгъзаларының берсенә әверелә. Бераздан ул татар легионерлары өчен Берлинда рәсми чыгарыла торган «Идел-Урал» газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша һәм, шундагы урыныннан файдаланып, типография ысулы белән антифашистик листовкалар, өндәмәләр бастыруны җайга сала. «Идел-Урал легионы»ның немец офицерлары җитәкчелегендә белорус, украин, поляк, француз партизаннарына каршы сугышка җибәрелә торган гаскәри берәмлекләрен баш күтәрергә, партизаннар ягына чыгарга өндәгән бу листовкалар татар легионерлары арасында А.Алиш аша, турыдан-туры аның катнашында таратылалар. Җәлилчеләр оешмасының антифашистик актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар әсирләреннән төзелгән батальоннарның яртысына якыны партизаннар ягына күчеп, партизан отрядлары белән бергә фашист гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша, ә легионерларның калган гаскәри берәмлекләрен немец командованиесе таратырга яисә чит илдәге төбәкләргә күчерергә мәҗбүр була.*

*1943 елның августында яшерен оешманың эше ачылып, А.Алиш һәм башка җәлилчеләр кулга алына һәм төрмәләргә ябыла. Яшерен оешманың үзәген тәшкил иткән унбер җәлилчене әүвәл Берлиндагы Моабит төрмәсендә тоталар, аннары Дрезден шәһәрендәге Плетцензее төрмәсенә күчерәләр. 1944 елның февралендә шунда А.Алишка һәм аның көрәштәшләренә суд була. Фашистик хәрби суды аларны «дәүләткә каршы җимерү эше» алып баруда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында хөкем карары гамәлгә ашырылып, әсирлектә фашизмга каршы тиңсез көрәш алып барган унбер татар каһарманының (Абдулла Алиш, Әхәт Атнашев, Абдулла Баттал, Галәнур Бохараев, Фуад Булатов, Муса Җәлил, Гайнан Курмаш, Фуад Сәйфелмөлеков, Әхмәт Симаев, Зиннәт Хәсәнов, Гариф Шабаев) гомерләре өзелә.*

*Абдулла Алишның тоткынлыкта әдәби иҗат эше белән шөгыльләнгәнлеге дә мәгълүм. Сугыштан соң 50нче елларда ук аның унбишләп шигыре хәрби әсир Нигъмәт Терегулов күчермәләрендә илгә кайтып ирешә. Боларга тагын әсирләр лагеренда А.Алиш белән аралашкан һәм аның кайбер шигырь-ләрен ядка алып, хәтерләрендә саклап кайткан элеккеге әсир Газыйм Кадыйров һәм Тәлгать Гыймрановларның күчермәләрен («Сагынам илемне», «Иркәм хаты», «Тормыш дустыма», «Кыр казлары», «Төн. Бүлмәдә тыныч кына утырам ялгыз...» һ.б.) өстәргә мөмкин. Алар үз вакытында һәммәсе дә матбугатта басылалар, ә Н.Терегулов алып кайтканнары, рус теленә дә тәрҗемә ителеп, «Три поэта-воина» (1979) исемле җыентыкта дөнья күрәләр. Болар, әлбәттә, тоткынлыкта А.Алиш иҗат иткән әсәрләрнең кечкенә бер өлеше генә. Әдипнең «Бик күп уйланылган һәм язылган әсәрләр безнең белән мәңгелеккә китәләр...» дигән сүзләре дә шуны раслый. А.Алишның тоткынлыкта язган һәм безгә инде билгеле булган шигырьләре туган илгә, туган халкына тугрылык, мәхәббәт хисләре белән сугарылган, аларны үзләренең идея-эчтәлекләре белән Муса Җәлилнең мәшһүр «Моабит дәф-тәрләре»ндәге шигырьләр белән аваздаш диярга мөмкин.*

*Әсирлектә фашизмга каршы алып барган тиңсез батырлыгы өчен Абдулла Алиш вафатыннан соң I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.*

*Абдулла Алишның әсирлектә фашизмга каршы шәхси көрәше батырлык, фидакарьлек үрнәге буларак халкыбыз күңелендә яши бирә, әдәби мирасы татар балалар әдәбиятының җуелмас рухи хәзинәсен тәшкил итә. Туган авылы Көектә аңа һәйкәл куела, мемориаль музее эшли, Казанда Республика балалар иҗаты үзәге (1961–1991 елларда А.Алиш исемендәге Пионерлар һәм укучылар сарае) әдипнең исемен йөртә. 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе карары белән балаларга атап язылган иң күренекле әсәрләр өчен Абдулла Алиш исемендәге еллык бүләкләр булдырыла.*

*А.Алиш – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҖЫР

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.

Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип.
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем иреклe булсын, дип.

Ничек тели җаның, шулай яшә,
Кара кашлы кызлар үзеңә,
Дисәләр дә, әйтер идем: кирәк түгел,
Кайтам мин, дип, зәңгәр күземә.

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

## ТУГАН ИЛГӘ

Булгач давыл ничек шауламасын,
Чайкалмасын камышы,
Ярсый йөрәк, дулкынлана, –
Авыр-авыр сагышы!

Беренче кат күзем кояш күргән
Җирләр ерак калды.
Тирә-ягым, күзге болыт кебек,
Кайгы чорнап алды.

Туган илем, барлык рухым сиңа,
Барсы синең өчен!..

Якынлыгың синең белмәдем мин
Ерак китми торып,
Ничек яшьлек тәмен без белмибез
Картлык килми торып!

## ИКЕ УЛЫМ БАР

*Алмаз белән Айвазга*

Һәрбер эшне җитез эшли торган
Корыч кебек ике кулым бар,
Ике кулым кебек үсеп килгән
Булышчым бар: ике улым бар.

Ике күзем минем – үткен күз,
Күрә кайда дошман посканын,
Ике күзем кебек ике улым
Сизгер саклар илнең постларын!

Шуышмасын дошман тирә-якта,
Колакларым яхшы ишетә,
Мин үлсәм дә, ике улым кала,
Алар ишетер икесе ничек тә.

Ике аягым минем чыдам булды,
Ерак поход чыккан чакларда.
Аякларым кебек ике улым да
Сынатмаслар әле ятларга!

## НИЧЕК КИЛЕР ҮЛЕМ

Көрәш куа утлы давыл бөркеп,
Үлем кайный тирә-ягымда.
Ничек килер үлем? дигән сорау
Һич килмәде минем башыма.

Шаян угы кургаш кисәгенең
Туры килсә минем йөрәккә,
Калган булыр идем авып шунда,
Ирешә алмыйча изге теләккә.

Явыз ачлык үзенең канлы кулын
Күп уйнатты минем тирәмдә,
Тимерчыбык белән уратылган
Хәтфә кебек яшел чирәмдә.

Үлеп калган булсам инде күптән,
Азык булыр идем кортларга,
Тоткын булып кабат килмәс идем
Менә мондый салкын йортларга.

Хәзер үлем тагын басып тора,
Баш очымда кайрый хәнҗәрен,
Тик белә алмыйм, тешне кысып
Сыкрый-сыкрый, дуслар, үләрмен.

Китмәс, ахры, бер кат минем яннан,
Шартлап тора һаман кичләрен.
Янгын чыгып янып үләрменме?
Белмим инде, ничек үләрмен.

Гильотинмы кисәр газиз башны,
Искәртмәстән яки атарлар,
Ачлык белән буып үтерерләрме
Яки биек дарга асарлар.

Ничек килер үлем – белеп булмый,

Тик билгеле шунсы хәзергә:
Тынмас, ахры, мине алып китми
Үзе белән салкын кабергә.

Ни булса да – горур үлем бит ул,
Европаның урта өлешендә.
Мондый үлем – бәхет. Теләсә дә,
Тими әле бик күп кешегә.

Күпме кәгазь языла безнең хакта,
Бәлки, кабат аны укырлар.
Иптәше өчен кеше корбан була,
Шундый инде безнең гасырлар.

Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә, ахры, кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхете өчен бирергә.

## КӨТМӘ ИНДЕ, КӨТМӘ...

*Әнигә багышлыйм*

Әнә үрдәк бәбкәләре белән,
Ә син ялгыз үзең барасың,
Син, көнләшеп аның бәхетеннән,
Моңсу гына озатып каласың.

Кая китте синең балаларың,
Арслан күк батыр улларың?
Өмет белән һаман күзәтәсең,
Кайтырлар, дип, киткән юлларын.

Былтыр койган алма какларын син,
Чикләвекләр җыеп киптереп,
– Аларга! – дип, һаман саклыйсыңмы,
Сагыш белән көтеп, тилмереп?

Төшләреңдә һаман алар белән,
Көндезләрен укып хатларын,
Теткәләнгән кәгазь битләренең
Һәрбер сүзен инде ятладың.

Язлар килер, чәчәк исе бөркеп,
Сыерчыклар кире кайтырлар.
Яңарырлар шунда йөрәгеңдәге
Бертуктаусыз янган кайгылар.

Бал кортлары очар, күбәләкләр
Берсен-берсе куышып уйнарлар.
Чәчәкләргә күмелеп торсалар да,
Куандырмас сине тугайлар.

Җир тетрәткән давыл уты, бәлки,
Карлар белән эреп югалыр,
Дөнья тынып калыр. Йөрәкләрдә
Кавышу хисе кабат кузгалыр.

Өчесенең берсе кайтмасмы, дип,

Син күтәрсең һаман аларны,
Ишек каккан саен кочакларга
Хәзерләнеп сөйгән балаңны.

Көтмә инде, көтмә, изге карчык,
Җир куенында ята улларың,
Чәчәкләргә биреп, илгә булган
Мәхәббәтле керсез уйларын.

## КЫР КАЗЛАРЫ

Бүген иртән күрдем кыр казларын,
Көнчыгышка таба киттеләр.
Канат җилпи-җилпи каңгылдашып,
Тигез сафка тезелеп үттеләр.

Юллар озын сезнең, кыр казлары,
Урал таулары аша чыгарсыз.
Канатыгыз юлда тузанланса,
Агыйделгә төшеп юарсыз.

Әйтер идем, әгәр телен белсәм,
Әманәтем алып кит, диеп,
Туган авылым аша юллар тотсаң,
Сөйгәнемә сәлам әйт, диеп.

* * *

Төн. Бүлмәдә тыныч кына утырам ялгыз,
Күк йөзендә минем кебек ялгыз йолдыз.

Ул сүнмәде таң атканчы, Чулпан микәнни?
Көтте, ашыгып, алсу Кояш кайтып җиткәнне.

Һәр көнне ул таң атканчы тора постында,
Тапшыра җаваплы эшне Кояш дустына.

Әй син, Чулпан, серле йолдыз, ничек армыйсың?
Күп йөзләгән еллар кичеп сүнеп калмыйсың?

Күр син мине: әгәр кичтән йокым туймаса,
Җуямын исәнлегемне, күзем кан баса.

Әйтегезче, иң бәхетле кем соң дөньяда?
Нигә мин дә йолдыз түгел йә гөнаһсыз яшь бала?

Син биектә, син иректә, иң бәхетле син генә!
Күк йөзендә урын булса, ал яныңа мине дә.

Тәүбә, тәүбә, тәүбә итәм, менмимен мин биеккә,
Бар теләгем: сөйгән халкым чыксын иде иреккә.

*Мөхәммәт Шәриф улы Әблиев 1900 елның 15 июлендә Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы Даныш авылында крәстиян гаиләсендә туып үсә. Кече яшьтән үк, авыл мәдрәсәсендә уку белән бергә, төрле ялλы эшләрдә көнлекче булып эшли. 1915 елда Казанга килеп, 1917 елга кадәр бай йорт-*

*ларында хезмәт итә. Хакимият башына большевиклар менгәч, заводта ташчы, туку фабрикасында эрләүче һөнәрен үзләштерә. 1920–1921 елларда партия-совет мәктәбендә укып аны тәмамлагач, берникадәр вакыт янәдән туку фабрикасында яшьләр арасында укыту-тәрбия эшләре алып бара. 1921 елда большевиклар партиясенә әгъза булып кереп, үзе теләп Кызыл Армиягә языла һәм 1922 елда тарихта басмачылар дип йөртелгән, асылда, Урта Азиядәге милли азатлык хәрәкәте тарафдарларына каршы юнәлтелгән сугышларда катнаша, соңыннан Төньяк Кавказдагы гаскәри берәмлектә элемтә буенча партия вәкиле булып хезмәт итә.*

*1923–1928 елларда М.Әблиев әүвәл Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбен, аннары Мәскәүдә икееллык хәрби-сәяси курсларны тәмамлый. Шуннан соң аны янә Урта Азиягә җибәрәләр. Ул анда рота политругы һәм рота командиры булып хезмәт итә, басмачыларның актык көчләрен юк итү операцияләрендә актив катнаша.*

*1932–1936 елларда М.Әблиев – Ленинградтагы Хәрби-сәяси академия курсанты. Аны уңышлы тәмамлагач, ул Казандагы укчылар полкында инструктор һәм хәрби комиссар сыйфатында гаскәри хезмәтен дәвам иттерә, 1939–1940 елларда исә СССР җитәкчелеге провокация юлы белән башлаган совет-фин сугышы хәрәкәтләрендә катнаша.*

*М.Әблиев Ватан сугышының беренче көннәреннән үк укчы дивизиянең сәяси бүлек комиссары сыйфатында фронтның алгы сызыгында сугыша һәм, күп тә үтми, дошман пулясыннан һәлак була.*

*Каләм иясе буларак М.Әблиев 20нче елларда яза башлый. Башта ул проза жанрында көчен сынап карый: «Минем дустым сугышта» исемле хикәя, «Ком улы», «Итекче кызы» исемле повестьларын иҗат итә. Соңга таба драматургия жанрына игътибарын юнәлтә. Аның 1923–1925 елларда язылган «Ике туй» пьесасы 1925 елда Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбенең драма түгәрәге тарафыннан сәхнәгә куелып, матбугатта уңай бәя ала. Шулай да М.Әблиевне драматург итеп таныткан әсәр – «Шәмсекамәр» драмасы. XIX гасырның икенче яртысындагы татар авылы тормышын, андагы социаль тигезсезлек, дини фанатизм шартларында тирән хисле, яшь, чибәр крәстиян хатынының фаҗигале язмышка дучар ителүен оста итеп, җанлы картиналарда сурәтләгән бу драма 1937–1938 елгы театр сезонында Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелып зур уңыш казана һәм аннан соң да озак еллар буе профессиональ һәм үзешчән театр сәхнәләреннән төшми уйналып килә. Дөрес, 30нчы елларның урталарында – авылны күмәкләштерү, кулакларны сөргенгә сөрү, дингә, дин әһелләренә каршы репрессияләр көчәйгән чорда язылып, укучы һәм тамашачы күңелендә сыйнфый куралмаучылык тойгысын уятуны максат итеп куйган бу әсәрнең халыкны диннән биздерүдә, аңарда дини нигилизм, рухи ярлылык тәрбияләүдә тискәре роль уйнавын да бу урында әйтеп үтәргә кирәктер.*

*Ватан сугышы алды елларында М.Әблиев «Лейтенант» исемле яңа пьеса яза башлый, ләкин ул аны ахыргача эшләп бетерә алмый.*

*М.Әблиев – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## ШӘМСЕКАМӘР

*(Драмадан өзек)*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Камәр.
Разия.
Сәләхи.
Гарәфи.
Галим.

Идел буенда болынлык. Кызыл, сары чәчәкләр арасында арба тәртәләренә төяп печәннән ясалган куыш. Бер читтә чәй кайнату өчен таган. Артта ара-тирә дулкынлы суның ярлары күренә. Пәрдә күтәрелгәндә, Камәр кабык арбага салган баласын тартып эштән кайта. Ара-тирә кошчыклар тавышы
белән еракта чалгы кайрау ишетелгәли.
Камәр, баласын йоклатып, аш әзерләргә кайткан.

Камәр. Әлли, бәлли, бәлли-бәү,
Әлли, бәлли, бәлли-бәү,
Ай син, балам, кечкенәм,
Баллы балам, төш кенәм,
Дәү булып үс тизрәк,
Безгә кул көче кирәк.
Эм, эм, йокла, балам, җан бәгърем,
Йокла, йокла син тизрәк,

Әлли, бәлли, бәлли-бәү.

Шул вакыт еракта Разияның җыр тавышы ишетелә.

Җыр. Сандугачым, былбылым, быел кайгылы елым,
Кайгырмас идем быелын, читкә китә былбылым.
Камәр (*елмаеп*). Йоклады.

Баланың өстенә яба. Шул вакыт Разия күренә. Ул, аяк очларына гына басып, җитез генә Камәрнең күзләрен каплый.

Камәр. Әбәү!.. Кем бу?
Разия. Көнме, төнме?
Камәр (*Разияның кулларын тотып*). Разия?
Разия. Көнме, төнме? Әйт, җибәрмим.
Камәр. Төн.
Разия. Төн, сөйгәнең кем?
Камәр. Аларны такмаклар вакытым үткән инде. Җибәр әле, Разия.
Разия. Иң элек әйт, әйтмәсәң, җибәрмим.
Камәр (*Разияны кытыклый башлый*). Җибәр, дим...
Разия. Җибәрмим, җибәрмим. Иң элек әйт. Мин уйладым, шулмы?
Камәр. Әйе, шул.

Разия, көлеп, кулларын җибәрә.

Чү, шаркылдама, баланы уятасың.

Разия. Бетте, бетте. Камәр апай, җаным, ачулана гына күрмә. Мин җүләр, мин тиле, мә! Дөнгечлә, кирәгемне бир шуның өчен. (*Аркасын бирә.*)

Камәр. Фу, тинтәк. (*Елмаеп, китә.*)

Разия. Минем әле чыбык-чабык җыярга дип баруым иде.

Камәр. Шунда миңа да җыярсың әле, Разия. Әсгатьне ташлап китеп булмый.

Разия. Ярый, Камәр апай. Әсгать йокладымыни? (*Килеп ачып карый.*)

Камәр. Тимә инде, уятырсың.

Разия. Бетте, бетте, Камәр апай. Мин яратып кына... Кайчан минем дә шул Әсгать төсле кечкенәм булыр икән, әй. (*Көлә.*)

Камәр (*елмаеп, йомшак кына*). Җүләр.

Разия чыгып китә. Камәр көйләп йөри, шул вакыт Сәләхи килеп керә.

Сәләхи. Нихәл, Камәр, исәнме? (*Камәр куышка кереп китә, Сәләхи артыннан бара.*) Ник дәшмисең, авырыйсыңмы әллә?

Камәр (*куыштан атылып чыгып, бала янына бара*). Сәләхи абый, йомышың булса, зинһар, әткәй үзе кайткач килерсең.

Сәләхи. Камәр, мин сине кызганам. Хафизың инде ташлады да китте үзеңне, ул зимагур кайтмаска уйлый, диләр.

Камәр. Кирәкми, Сәләхи абый, бар, кит.

Сәләхи. Белмим, миңа карата мондый салкынлык сиңа каян килә торгандыр. Гел генә караңгы чырай күрсәтәсең. Заманында мин синең баең идем бит.

Камәр. Алла хакы өчен бар, кит, Сәләхи абый. Бәйләнмә миңа.

Сәләхи. Камәр, мин синең бәхетле булуыңны күрәсем килә. Өйләренә җил керсә, бәрелерлек әйберләре булмаган Юныс картларда яшьлегеңне әрәм уздырасың. Син яхшы аргамакларда утырып, асыл күлмәкләр киясе хатын.

Камәр. Үзең киеп утырып йөр. Мине асыл күлмәкләрең белән кызыктыра алмассың.

Сәләхи. Ташла, Камәр, шул зимагурыңны, ә баладан ничек котыласын без беләбез.

Камәр. Синдә байлык эчендә изелгәнче, Хафиз белән ярлылыкта булса да рәхәтләнеп тору мең өлеш артык.

Сәләхи. Әгәр дә мине аңласаң, мин сине хур итмәм, Камәр... (*Камәрне эләктереп ала.*)

Камәр. Син нишлисең, оятсыз! (*Тартылып ычкынып китә.*) Асрау чагымда интектерүләрең җитмәгән, хәзер балам бар өстенә мыскылларга телисеңмени?!

Сәләхи. Юк, җаным, юк. Мыскыллау турында уйламыйм да, мин сиңа асыл ефәк белән...

Камәр. Оятсыз син, пычрак кеше...

Сәләхи. Камәр! Минем кем икәнне беләсеңме?

Камәр. Бик беләм. Гөлбануның матурлыгын алдың да, матурлыгы беткәч, биләнке ясап аерып җибәрдең. Миңсылуны, йөкле чагында тибеп, вакытсыз гүргә керттең. Сәлимәнең синең белән яманаты чыгып хур булды. Хәзер мине дә алар эзеннән җибәрмәкче буласыңмы? Юк, һичбер вакытта да.

Сәләхи. Камәр, син телеңне алай бик озынайтма. Әгәр минем ачуыма туры килсәгез,

тончыгасыгызны бел дә тор. Усаллыкка киткәндә, мин сезгә барыбер рәхәт күрсәтмәм.

Камәр. Ике күземнән аерылырга риза булырмын, әмма Хафизны ташлап андый кабахәтлеккә барырга гомеремдә дә риза булмам.

Сәләхи. Уйла, Камәр, мин бит сиңа яхшылыкка әйтәм... (*Разия килгәнне күреп, тиз генә чыгып китә.*)

Камәр. Минем арттан эт шикелле ияреп йөрмә.

Разия җырлап керә.

Разия. Менә, Камәр апай, чыбыкларның менә дигән яхшыларын җыйдым. Икебезгә дә җитәр.

Камәр. Ярый, Разия, рәхмәт.

Разия. Менә, Камәр апай, азрак җиләк тә җыйдым, авыз ит.

Гарәфи Хафизның сандыкларын күтәреп керә.

Камәр. Гарәфи абый, кемнеке ул сандык?

Гарәфи. Ха-ха-ха... Сөенче, Шәмсекамәр. Сөенче...

Камәр. Ә?..

Гарәфи. Хафизыңны алып кайттым... Ха-ха-ха... Сезнең монда икәнне белгәч, авылга да кайтмаган. Перевоздан чыккач, минем арбага салды да үзе печәнчеләр янында калды.

Камәр. Кайда дисең?

Гарәфи. Сәйфулла староста җир турында язган прошениеләрен алып кайткан диме шунда...

Камәр. Ул бит көзсез кайтмам дигән иде! Нигә кайтты икән?

Гарәфи. Ха-ха-ха... юл эше ул, чорт знает, белер хәл юк.

Камәр. Хатында да кайтуы турында бернәрсә дә язмаган иде.

Гарәфи. Сине сагынгандыр, сине юл буе авызыннан төшермәде, бик сорашты, ни эшләп йөри, ди. Безнең бай бик тузып йөри, ярый, мин китим әле. (*Китә.*)

Камәр. Рәхмәт, Гарәфи абый, рәхмәт.

Разия. Нинди шатлык! Камәр апай, Хафиз абый да кайткач, сез кыр эшләрен тиз бетерерсез инде.

Камәр. Шатлыгым эчемә дә сыймый, үзен күрәсем килде, әллә нәрсәләр сөйләшермен төсле. (*Бала янына килеп.*) Балам, бәгърем, атаң кайткан, диләр.

Разия. Камәр апай, ул нәрсә белә соң? Тимә, йокласын.

Камәр. Әллә ни эшләп йөрәгем сикерә башлады. (*Пауза.*) Нигә болай кинәт кайтырга булды икән?

Разия. Хафиз абый яхшы кеше ул. Син дә акыллы шул, ярлы булса да егетнең менә дигәнен сайлагансың. Синең хакта аңа никадәр яман сүзләр ишеттермәделәр. Ул аларга әйләнеп тә карамады. Менә шундый ирең булса икән.

Камәр. Нәрсә сөйлисең син, Разия?

Разия. Билләһи менә, Камәр апай, дөресен әйтәм.

Камәр (*көлеп*). Әллә Хафиз абыеңа үзеңнең күзең төшә башладымы, бик тырышып мактыйсың?

Разия. Менә кирәк булса. (*Пауза.*) Кит аннан. Камәр апа, җаным, ни эшләп алай дип әйтәсең? Башыма да килгәне юк. Икмәктер, кояштыр әгәр. Матурны матур дип кенә әйтүем.

Камәр. Мин аны үзем дә бик яратам шул, Разия. Менә әле бу салга киткәчтен дә сагынып үлә яздым. Ярый әле юанычка Әсгать булды.

Разия. Хафиз абыйны бөтен авыл ярата. Ул батыр, гайрәтле кеше бит. Аннан Сәләхиләр дә куркып торалар.

Камәр. Шулай шул. (*Пауза.*) Тик менә нигә кайтты икән ул, Разия? Киткән чакта сал эшләре беткәч затонда урнаша алсам, яхшы гына эшли башлагач та сезне дә алдырырмын дип киткән иде. Кайчан гына котылырбыз бу авыр көнкүрештән.

Разия. Анысы инде, Камәр апай, эш табу кайда да бик җиңел түгел, диләр. Югары очның шәһәрдән кайткан Әхмәтҗан Сафасы әйтә: «Дөнья кайда да бер, кайда барсаң да бер эттәхият», – ди.

Камәр. Шулайдыр инде. (*Пауза.*) Әле тик менә шушы Сәләхи эттән котылыр идем дип тора идем. Җаныма тиде бит. Хафиз кайткач кирәген бирер иде үзенең.

Разия. Хафиз абыйны бик көнче дип сөйлиләр. Камәр апай, шулаймыни?

Камәр (*көлеп*). Белмим. Нигә кайтмый инде үзе? (*Юлга чыгып карый.*)

Разия. Күренмиме?

Камәр. Галим ялгыз гына кайтып килә.

Разия. Нәрсә булды икән соң?

Галим керә.

Камәр. Нәрсә булды? Ни эшләп болай вакытсыз кайттың, Галим?

Галим. Әти кайтмадымы әле?

Камәр. Юк шул әле. Нәрсә булды, Галим?

Галим. Эшләр сүтелде, җиңги. Үрәдник җир сорап язган кәгазьләрне алып килгән. Үлгәннәрнең җирләре тагы тугыз елсыз биреләчәк түгел, ди, пүчтәк, үлгәннәрнеке түгел, тере калганнарның җире дә Сәләхи кулына кереп бетә язган. Халык тоже башын ими, бугазга-бугаз ябышып кычкырышалар. Сәләхи белән старостаны кыйный яздылар.

Разия. Дөмпәчлисе калган үзләрен. (*Үзе дә сизми җиңен сызгана.*)

Камәр. Галим, Хафиз нигә кайтмый инде? Әллә инде җир турында эткәйгә булышырга кайтканмы?

Галим. Ну... абый молодец соң, җиңги. Сәләхи кебек эт җаннарга махы бирми. Крестьяннар старостаны чорнап алган җиргә җиткәч, арбадан сикереп төшеп калды да, эшнең нәрсәдә икәнен сорашып белеп, менә кыздыра башлады тегене, ул арада Сәләхи дә килеп җиткән. Нигә кайттың, зимагур, ди. Шуннан абый кызды. Синең башыңны юк итәргә, дип аңа ташланган иде, Сәләхи старостага әйтеп, абый белән бер унлап кешене кулга алдыртты. Синең этиең дә алар белән эләкте, Разия.

Камәр. Шулайдыр дип кенә башыма килгән иде аны.

Разия. Этием, бәгырем, харап кына булган икән. (*Елап җибәрә.*)

Галим. Әнә сезнең шул елау да сыкрау булыр инде. Тукта әле, ичмасам, син елап йөрәккә тоз салма, пүчтәк ул елау.

Камәр. Елама, бәгырем, елама, Разия. Алар юлбасарлар түгел бит. Җәмәгать өчен талашалар.

Разия. Ә аларны җибәрерләрме икән, Галим?

Галим. Җибәрмәсәләр, без аларны үзебез коткарырбыз.

*1929–1936*

*1941–1945 еллардагы Ватан сугышында һәлак булган зур бер төркем татар язучыларының берсе Әхтәм Әмин улы Әминев 1918 елда хәзерге Башкортстан Республикасының Илеш районы Әнәс (Әнәч) авылында крәстиян гаиләсендә туа. 1933 елда җидееллык авыл мәктәбен тәмамлагач, Свердловск (хәзерге Екатеринбург) шәһәрендәге педагогия техникумына укырга керә. Шул елларда Свердловск шәһәрендә татар телендә чыга торган «Социализм юлы» газетасында язышა башлый, шунда беренче шигырьләрен бастыра.*

*1937 елны Ә.Әминев укуын дәвам итәр өчен Казанга килә һәм Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтихан тотып, сугыш башланган елны институтны тәмамлап чыга. Шул ук елның декабрендә ул фронтка китә һәм берничә айдан, 1942 елның апрелендә, Калуга өлкәсендә барган бәрелешләрнең берсендә каты яраланып, аңына килә алмыйча вафат була.*

*Ә.Әминевнең зур булмаган шигъри иҗатыннан аерым үрнәкләр Татарстан китап нәшрияты 1961 һәм 1985 елларда нәшер иткән «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкларга һәм «Оч, Галия!», «Ил чигендә» дип аталган ике шигыре «Татар поэзиясе антологиясе»нең икенче томына (Казан, 1992) кертелә.*

**ОЧ, ГАЛИЯ!**

Кара бөдрә чәчең кыңгыр салып,
Мәктәбеңнән кайткан чагында,
Сөйләдең син миңа укуыңда
Булган уңышларың хакында:
– Зур шатлык бу миңа, зачетымны
Отличнога бирдем бүген дә.
Тиздән менә, тиздән мин очармын
Илебезнең зәңгәр күгендә...
Данлы эшкә булган ашкынуың
Чыккан иде алсу йөзеңә,
Йөрәгеңнән чыккан шатлык нуры
Балкый иде матур күзеңдә.
Бүген, Галия, синнән хәбәр алдым,
Син язасың миңа хатыңда
Укуыңны яхшы тәмамлавың
Һәм очучы булуың хакында...
Әйе, Галия, безнең илебез генә
Данлы эшкә дәрт һәм көч бирә.
Бездә генә мөмкин белем алу,

Бездә генә хөрмәт кешегә.
Очучы кыз!
Эшең белән котлыйм!
Син очасың илебез күгендә.
Оч, Галия, җитез лачыннардай,
Оч, Галия, канат үзеңдә!

*1937*

**ИЛ ЧИГЕНДӘ**

Ярларыннан ташкан
Ташкыннардай,
Амур ага, Амур чайкала.
Күбекләнеп аккан елга суы
Дулкыннарын бәрә ярларга.
Батыр егет илнең чиген саклый
Шаулап аккан елга янында,
Горурлана постта торуы белән
Чәчәк аткан яшьлек таңында.
Батыр егет илнең чиген саклый,
Винтовкасын тоткан кулына.
Ерткыч фашистларга каршы булган
Нәфрәт уты яна канында.
Ул каршылый сызылып аткан таңны
Постта килеш, Амур янында.
Горурлана постта торуы белән
Чәчәк аткан яшьлек таңында.

*1937*

*Шагыйрь Мөхәммәт Ибраһим улы Әхмәтгалиев 1920 елның 21 февралендә Казан шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1938 елда Яңа бистәдәге 13 нче номерлы татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1938–1941 елларда Казан дәүләт педагогия институтының биология факультетында белем ала. Ватан сугышы башлангач, 1941 елның көзеннән 1942 елның гыйнварына кадәр Татарстанның Буа районында ныгытмалар казу эшендә була, аннары берничә ай Ленинградтан Казанга күчерелгән Калинин исемендәге заводта станочник булып эшли. 1942 елның 22 маенда фронтка җибәрелә һәм 1943 елның 21 августында Смоленск шәһәре тирәсендә барган каты сугышлар вакытында дошман пулясыннан һәлак була.*

*М.Әхмәтгалиев 1934 елда яза башлый. Беренче шигырьләре 1935 елда «Мехчы», «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында, «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналы битләрендә дөнья күрә, соңга таба «Туган ил» (1938), «Шат балалык» (1938), «Очкыннар» (1940) кебек күмәк җыентыкларда һәм альманахларда басыла. 1941 елда ул үзенең шигырьләре тупланган беренче җыентыгын басмага әзерли, әмма сугыш башлану сәбәпле, җыентык матбугатка чыкмый кала. Бары тик сугыштан соң гына яшьли һәлак булган шагыйрьнең балалар өчен «Балык тотканда» (1957), «Тегүче куян» (1959), «Елак батыр» (1960) исемле кечкенә-кечкенә өч шигъри китабы нәшер ителә. Шигырьләре шулай ук Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйрьләре әсәрләреннән төзелгән «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкларга һәм «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) басмаларына да кертелә.*

*М.Әхмәтгалиевнең шигырьләре эчтәлек ягыннан бәхетле балачак, комсомол, илне саклау, котыпны җиңү кебек шул чор поэзиясе өчен характерлы темаларга багышлана. Аның шагыйрьлек сәләте бигрәк тә кече яшьтәге балалар өчен язган шигырьләрендә («Ата һәм бала», «Балык тотканда», «Бишек җыры», «Үгез», «Сеңлем бәхете» һ.б. ) ачык күренә.*

**БЕРЕНЧЕ КӨН**

Әтәч кычкырды күптән,
Кояш елмайды күктән.
Тәмле төшләр күрдек без,
Күктә очып йөрдек без.
Бүген иртә уяндык,
Көнгә карап куандык.
Их, сикердек, шатландык,
Кош кебек канатландык.
Сентябрьнең бере ич,
Бүген уку көне ич,
Сикерешеп тордык без,
Бит-кулларны юдык без.
Ашап-эчеп киендек,
Шау-гөр килдек, сөендек.
Яңа сумканы алдык,
Китап-дәфтәрләр салдык.
Бик күңелле сөйләшеп,
Шаулашып та гөрләшеп,
Иң беренче мәртәбә
Җыйналдык без мәктәпкә.

*1939*

**МИҢА УНСИГЕЗ ЯШЬ**

Бүген миңа унсигез яшь тулды.
Унсигез кыш туган көнемә.
Алсу яшьлегемә карап көләм,
Бәхетемне уйлап сөенәм.
Йөрәктәге тиңсез шатлыгымны
Сөйлим сезгә, якын туганнар.
Мин китәрмен Кызыл Армиягә
Егерме яшь тулгач туганга.

Мин шатланып киләм урам буйлап,
Мамык карлар ява юлыма.
Миңа бар да шатлык белән карап
Елмаешкан кебек тоела.
Ә урамда бүген февраль җырлый,
Горурланып февраль елмая:
Кызыл Армияне котлап бүген,
Чәчәкләнеп мамык кар ява.

Корыч адым белән атлап килгән
Кызыл сакчыларның авазы
Җиргә генә сыймый, күтәрелә,
Яңгырата зәңгәр һаваны.
Ат өстендә килә яшь егетләр,
Шлемнарда йолдыз яндырып,
Алар үтә яшьлек җырын җырлап,
Яңгыратып якты дан җырын.
Биешәләр елгыр аргамаклар,
Тузгыталар мамык карларны.
Иртән искән йомшак кына җилдә
Дулкынлана ефәк яллары...
Их... Нинди гүзәл йомшак кышкы көн,
Чәчәкләнеп мамык кар ява.
Февраль котлый данлы армияне –
Горурланып февраль елмая.

Миңа бүген унсигез яшь тулды.
Ике елдан ярсу атларда
Мин китәрмен сөйгән Ватанымның
Якты тынычлыгын сакларга!

*1940*

**АТА БЕЛӘН БАЛА**

– Бирче, эткәй, орденыңны,
Матурлап тагыйм әле.
Бөтен җирдә, синең кебек,
Мин дә макталыйм әле.
– Юк шул, улым, күчми һич тә
Балага ата даны,
Үзең укуда һәм эштә
Яулап алмасаң аны.
Үсәрсең дә, сумка тотып,
Мәктәпләргә барырсың.
Яхшы укыгач, яхшы эшләсәң,
Син дә орден алырсың!

*1940*

*Хикәяләр авторы һәм тәрҗемәче Кәшфи Басыйров (Кәшшаф Хәбир улы Басыйров) 1906 елның 17 апрелендә хәзерге Башкортстан Республикасының Бәләбәй районы Мәтәүбаш авылында туа. 1917–1921 елларда Бәләбәй шәһәрендәге алты еллык рус-татар мәктәбендә, 1922–1927 елларда Бәләбәй педагогия техникумында укый, аннары алты ел чамасы Дүртөйле (Башкортстан), Кукмара (Татарстан) төбәкләре авылларында һәм Казанда балалар укыта. 1934 елның көзеннән 1942 елга кадәр Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият бүлегендә корректор, техник редактор һәм тәрҗемәче булып эшли.*

*1942 елның гыйнварында К.Басыйров армиягә алына һәм 1943 елның 16 гыйнварында фашистларга каршы сугышта һәлак була.*

*Кәшфи Басыйров әдәбиятка хикәяче булып килә. Аның «Сәлимҗан», «Алар онытылмыйлар», «Авылда» исемле беренче хикәяләре 1925 елда басылып чыга. Аннан соң «Безнең юл» журналында «Минем сөюем» дигән шактый күләмле әсәре, 30нчы елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары»), «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналларында «Ликвидаторлар», «Секретарь», «Көзге юллар буйлап» исемле, нигездә, авылдагы күмәкләшү чоры вакыйгаларын тасвирлаган хикәяләре дөнья күрә. Соңыннан, 1958 елда, бу хикәяләр «Танышлар» исемле аерым җыентыкка тупланып яңадан басылып чыга.*

*К.Басыйровның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге аеруча мактауга лаек. Кыска гына иҗат гомере эчендә ул татар теленә шактый гына матур әдәбият әсәрләре тәрҗемә итә. Алар арасында Ю.Лебединскийның «Неделя» («Бер атна», 1936), немец язучысы В.Бредельнең «Испытание» («Сыналу», Г.Хәбиб белән уртак тәрҗемә, 1936), М.Лермонтовның атаклы «Герой нашего времени» («Безнең заман герое», 1937), Н.Гогольнең мәшһүр «Мертвые души» («Үле җаннар», 1947) романнары, В.Короленко, А.Чехов һ.б. рус язучыларының проза әсәрләре бар.*

*Кәшфи Басыйровның аерым тәрҗемәләре (Н.Гогольнең «Үле җаннар»ы) китап булып вафатыннан соң гына басылып чыга.*

**СЕКРЕТАРЬ**

Эш сәгате үткән. Йомышларын үтәргә килүче кешеләр дә юк. Канцеляриянең үзендә эшләнәсе эшләр дә тәмам булган, хәтта барлык әйберләр дә җыеп куелган иде. Шулай да Гали утыра бирде. Ул башта әле генә үзе җыештырган бүлмәсендәге әйберләрнең: рәсемнәрнең, плакатларның, игъланнарның, шкафларның урнашу рәвешен караштырды. Аларның кайберсен яңадан барып төзәтте, сыпырып-сыпырып алды. Ә соңыннан, һәммәсе тәмам булгач, ишеккә табарак китте дә инде бүлмәдәге әйберләрнең урынлы тору-тормауларын тикшереп түгел, ә бүлмәнең җыйнаклыгына, күңелгә ягымлылыгына рәхәтләнеп, рәхәткә чумып басып торды. Стеналар елмайдылар. Гали үзе дә көлеп куйды. Ул, арлы-бирле йөренеп, инде күптән үк кайтып киткән председатель белән телефоннан

сөйләшеп алды. Аннан соң стена буендагы диванга барып утырды.

Гаҗәп кеше бу председатель. «Йә, кайт инде, Гали, ял алды көнне вакытында кайт, әниең тәмле ашлар да пешергәндер», – диде ул Галигә. Тәмле ашлар шикелле үк, тәмле уйлар да булганын белмиме икәнни соң ул? Менә хәзер канцеляриягә Калинин килеп керсен иде дә карасын иде. Нәрсә әйтер иде икән? «Бу бүлмәдә бер минут торасым килми» дип әйтер идеме икән яки «синең бүлмәдә, Гали, эштән соң ял итеп, рәхәт уйларга чумып утырырга да була» дип әйтер идеме икән? Председательчә уйласаң, эшләнәсе эш эшләнгән, бүлмә дә яхшылап җыештырылган булса, артык берни дә кирәкми булып чыга. Җыйнак җыештырылган бүлмәдә вакыт-вакыт ялгыз калып, шулай ук үз уйларыңны да җыйнаклап алуның тәмле аш шикелле үк тәмле булуын белми, ахрысы, бу председатель.

Каршы яктагы ачык форточкадан җил Галинең йөзенә үк искәндәй булды. Шунда ук форточка аша тыштан тавыш та бәреп керде. Күрше Галимулла хатыны Бәдәр тавышы. Әмма тәмле телле дә бу хатын. Таныш кешеме, түгелме, олымы, кечеме – һәркайсына тәмле тел белән дәшә. Әнә әле дә ул, кемнедер үгетләп: «Шулай итә күр инде, аппагым», – дип сөйли. Ә кызы, Камәр, алай түгел. Бу яктан ник әнисенә охшамады икән ул?

Көз көне, беренче кар яву белән, Галинең бүлмәсен, канцелярияне, алар менә шушылай бүгенге кебек яңабаштан Камәр белән икәүләп җыештырганнар иде. Шунда Камәр Галигә әйтә куйды:

– Бүлмәңне җыештыра башладың исә, мине искә төшерерсең, Гали, яме?! Ләкин менә бу плакатны алмаштырма, мин кайтканчы шунда үз урынында торсын. Мине сагындың исә, шуңа карап куярсың. Әнә теге уртадагы тракторчы кыз миңа бераз охшаган бит, әйеме? Әгәр инде мин кайтуга бу плакат урынында булмаса... мин үпкәләрмен...

Гали аның бу сүзләрен яратты, әлбәттә. Аларны искә төшергәч, ул менә әле дә елмаеп куйды. Ләкин шул көнне үк Камәр тагын икенче бер сүз дә әйтте. Бүлмәне җыештырып бетергәннән соң ул үзенең пилоткасын, перчаткаларын кигәч, иң элек кулын кулга, ә аннан соң сулагай куллап Галинең аркасына сукты. Галинең анысына да исе китми, андый сугу иптәшләрчә, яратып сугу гына ул. Ләкин шунда ук Камәр аңа болай диде:

– Их, Гали, Гали... нинди егет син... Ник син шундый ябык? Үзең ап-аксың...

Күптән әйтелгән шул сүзләр өчен менә хәзер кинәт кенә Галинең кәефе кырылып киткәндәй булды. Ул гына да түгел. Шулай ук бер мәктәптә укып үскән Яхъя үткән көздән элекке көзне армиягә алынган иде. Ул да алынып кайтуы белән бер карыш үсте. Ни өчендер менә хәзер Гали Камәрне дә, Яхъяны да мактанып торалар төсле фараз итте. Камәрне дә, Яхъяны да «ачы теллегә» санады. Үз-үзен, секретарь кешене, кечкенәгә санап куйды.

Ләкин мондый уйлар тиз киттеләр. Форточка аша Галимулла хатыны Бәдәрнең тавышы тагын очып керде. Ул бу юлы инде тәмле телләнеп сөйләми, ә үзенең кече кызын шактый коры сүзләр белән генә кыздыра иде. «Шуның өчен дә елап торасыңмы? Синең урыныңда Камәр апаң булса, моңа елау түгел, йөзен дә чытмас иде...» – дип сөйләнде ул. Гали, бер ноктага текәлгән күзләрен күтәреп, тирә-ягына, стеналарга карап алды. Стенадагы тракторчы кыз, тракторда барган килеш артына борылып, елмаеп кул болгый иде. Галигә ул бу юлы, чынлап та, Камәрдер кебек тоелды. Гали әле хәзер генә үзенең башына килеп киткән юләр уйлардан көлеп куйды. Ул, җиңеләеп, урыныннан торды да йөреп китте. Канцеляриянең түрендә торган Калинин, башын әле бер якка, әле икенче якка борып, бүлмәне күзәтте. Соңыннан, Гали туктагач, ул аңа туры карап торды. Аннары, аз гына елмаеп, баш каккандай булды. Галинең күңеленә тагын рәхәт булып китте. Ул форточканы япты да кайтырга чыкты.

Биби, җидееллыкны шулай ук Галиләр белән бергә тәмамлаган кыз, өч ел инде каникулга кайтмаган иде. Урамда Галигә әнә шул Биби очрады. Бибинең, аттан төшеп, чемоданнарын күтәргән килеш, өенә кайтып барышы иде. Тыкрыктан менгәндә, Гали аның чемоданын күтәрешеп менде. Шул арада сөйләшкәндә, Биби: «Мин сезгә бүген үк барырмын әле, Гали, синең белән сөйләшәсе сүзем бар», – дип әйтте. Иң элек Галине күрүенә шатланганлыгын белдерде, йөзе дә нурлы иде. Көлеп, елмаеп сөйләште.

Гали укудан, тормыштан артка калырга тырышмый һәм үзен артка калган итеп санамый иде. Ләкин Бибине күргәннән соң аңа бераз гына икенче уй төште. Дөресрәге, литфак студентыннан яхшы ук тартынып куйды ул. Шуңа күрә ул өенә кайткач та, Биби белән очрашырга әзерлекнең башы итеп, стенадагы кечкенә бер бит исемлекне алып, өстәл тартмасына яшерде. Анда, бу бер бит исемлектә, дөнья әдәбияты классиклары һәм аларның һәркайсының берәр әсәренең исеме язылган иде. «Литфак студенты көләр», – дип уйлады Гали. Биби аңа: «Бары сигез генә язучыны, аларның да берәр генә әсәрен беләсеңме?» – дип әйтер төсле тоелды. Чынлап та, Биби шул кичне үк килде. Билгеле, ул Галигә үзенең «сөйлисе сүзен» шунда ук сөйли башламады. Башта, якын танышларча итеп, исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сөйләштеләр. Гали Бибигә: «Син бик үскәнсең, тазаргансың», – дип, Биби Галигә: «Син бик чибәрләнгәнсең», – дип якыннарча, эчкерсез, күңелле һәм көлкеле сүзләр әйтешеп алдылар. Ул арада Камәр килеп керде. Ул да шулай ук дусларча ачык йөз белән һәм кулын ерактан китереп сугып күрешергә, кайчан һәм ничек кайтуы турында әйтергә генә өлгерә алды. Мәктәп директоры килеп керде. Директор сүз өчен кесәгә керә торган кеше түгел иде. Биби белән таныш түгеллегенә кара-

мастан, ул аның белән дә танышларча күреште, юмарт сөйләште. Галинең тәкъдим итүенә генә канәгатьләнмичә, үзе турында һәм Гали турында яңа титуллар өстәп куйды:

– Таныш булыгыз, авылның драмтүгәрәк җитәкчесенең иң өлкәне булам. Ә менә бу, Гали иптәш, безнең маэстро һәм нәфис сүз остасы. Аның концертларын һәм чыгышларын радиодан быел, шаять, ишеткәнсездер. Бер чүлмәкче, бер чиләкче бүген безгә килмәкче дигәндәй, без аның белән менә шулай очрашабыз да торабыз инде...

Шуннан соң директор, бик кадерле нәрсә шикелле итеп, үз кулындагы китапны ике куллап Галигә тоттырды. Бу кыланыш Гали өчен яңа түгел. Директор яңа чыккан китапларны күп кешедән алда белә, башта ала һәм алган саен дус итеп Галигә күрсәтә. Гали яратып куйса, ялынып сораса, үзе яңадан алмакчы булып, хәтта аңа биреп тә куя. Ләкин бүгенге китап, «Крылов мәсәлләре» исемле бу татарча китап, директор белән Галинең икесе өчен дә чынлап та бертигез кадерле китап иде. Егетләр сөенештеләр. Гали шунда ук этажеркадан бер-ике бит кульязма суырып алып кызларга күрсәтте. Болар авылдагы көчләр белән тәрҗемә ителгән мәсәлләр, тетелеп беткән кәгазьләр иде.

Директор, Галигә карап:

– Әллә соң сөенечтән «Карга»ны хәзер үк сөйләп ташлыйсыңмы? – дип сөйләнеп алды. Ә үзе, көлдереп, очынып, мәсәлләрне берәмләп укып чыкты.

Вакыт менә шулай үтте дә китте. Биби үз сүзләрен Галигә бары урамга чыккач кына, кайтканда гына сөйли алды. Ләкин бу вакытта да ул Гали белән ялгыз гына түгел иде. Галине уртага алып, Камәр белән өчәүләп атлыйлар иде.

– Гали, – диде Биби, – мин синнән шуны сорамакчы идем: мин быел тәмамлыйм бит. Миңа Карамалы авылын тәкъдим итәләр, шуңа син ничек карыйсың?

Гали үзенең хор түгәрәге белән Карамалыга концерт бирергә баруын, аның колхоз председателен сөйләп көлдерде. Халыкка һәм бигрәк тә председательгә Галиләрнең чыгышы бик ошаган, күрәсең. Ул артистларны өйләренә озатканда килгән чаналары белән түгел, ә яхшы чана, яхшы атлар җигеп озаттырган. Карамалының Совет председателе күргән саен Галине үзләренә чакыра икән. Безгә бик шәп клуб мөдире кирәк, акчасын кызганмыйм, тиешле органнар белән үзем сөйләшермен, ризалык кына бир, дип үгетли икән.

Биби Галине үзенәрәк кысты:

– Чынлап та, Гали, менә шәп булыр иде... Мин вәгъдә бирәм алайса... Ләкин синең баруыңа ышанып... – дип сөйләнде ул.

Капка төпләренә җитеп саубуллашканда да шул ук сүзләрне кабатлады.

Ә Камәр моңа ышанып җитмәде. Ул Галине шаярып сөйли дип уйлады. Курста чакта Камәр янына МТС директоры үзе килгән иде. Ул МТСка киләсе яңа механизаторлар турында, шул исәптән Галине дә МТСка алу турында сөйләгән иде. Гали белән икәү генә калгач, Камәр сүзне шул турыда алып барды. Капкага җитеп аерылышканда, Галинең кулын җибәрми торды.

– Әйеме, акыллым, барасың бит? Бергәләп эшләрбез, вәгъдә, яме, аппагым? – дип сөйләнде.

Камәр ишектән кереп киткәнчегә хәтле Гали китми торды. Аз гына шаку белән, ишектә Галимулла хатыны Бәдәрнең: «Синме, җаным?» – дип сораган тавышын Гали тагын ишетте. Ә юлда кайтканда ул бер генә турыда, Камәрнең «Яме, акыллым...» дигән йомшак тавышы турында гына уйлады. Рәхәт иде.

Кайту белән Гали яңа хат ачты. Яхъядан иде.

«Гали, шушы айларда гына мин ике тапкыр сине тыңладым. Безнең авыл концерты бу, ә җитәкчесе минем иптәшем, дип әйткәч, иптәшләрем бигрәк күңел куйдылар. Алар бигрәк синең сөйләвеңне яраталар. Барысы да сиңа шушы хатны язып җибәрергә үтенделәр. Сезнең җырлар безне дәртләндерделәр. Мин авыл советында сезнең ничек эшләвегез турында да укып барам. Зур булмаса да, үземнең дә уңышларны язып җибәрергә булдым. Иң күңеллесе шул: төрле урында, төрле эштә эшләсәк тә, бер эш өчен янабыз. Эшлә, яхшы эшлә, дустым. Совет кешеләренең тыныч хезмәтен өзәргә теләүчеләрнең берсенә дә ирек бирмәбез! Кече командир Яхъя».

Галигә тагын рәхәт булып китте. Шушы минутта аның канцеляриядә утырасы килде. Күңеле белән ул берара шунда китте. Бер-бер артлы килеп торучы колхозчыларның, хатын-кызларның, укытучыларның, врачларның, ясле хезмәткәрләренең сорауларына шулай ук бер-бер артлы җавап биреп тору, йомышларын үтәп, канәгатьләндереп җибәрү аның үз күңелендә дә канәгатьләнү, үзенә, үзенең көченә ышаныч тудырды. Мондый тойгы бер үк вакытта аны тынычсызландырып та җибәрде. Ул өстен чишенде, өстәл тартмасындагы исемлекне яңадан үз урынына, стенага элеп куйды, галстугын бушатты да укырга утырды. Белмим Бибидән, белмим Камәрдән калган тойгылар аны дулкынландыра иде.

*1939*

**АРТИСТКА ҺӘМ ШАХТЕР**

*(Артель председателе авызыннан)*

Минем артельдә шундый егетләр бар, шәһәрдән йөреп кайттың исә, күңелле итеп, дусларча итеп сорашырга керешәләр.

– Йә, шәһәрдә ни хәлләр бар, кемнәрне күрдең, без ясаган изделиеләр турында нәрсәләр ишеттең, аларны алалармы, яраталармы, ниндиләрен күбрәк алалар, сөйләп җибәрче, председатель, – диләр.

Аларның шулай сорашуларына күңелем бик була. «Сөйләп җибәрче, председатель» дигән сүзләрендә үземне якын күреп дәшүләрен ишетәм, «без ясаган изделиеләрне яратып алалармы?» дигән сүзләрендә производствога үз итеп караганлыкларын, эш белән кызыксынуларын ишетәм. Шуңа күрә шәһәрдән йөреп кайткан саен аларның һәрбер соравына озаклап, озын-озын итеп, күңелләре булганчы җавап кайтарам, сөйләп бирәм. Ваклыкларына хәтле калдырмыйм. Әйтик, безнең артель ясаган пеналны магазиннан алып чыгып баручы берәр укучы баланы күрсәм, кайткач, шунысына хәтле сөйлим. Иптәшләремнең дә күңелләре бик була. Шундый «әһәмиятсез» сүзләрне дә, әкият тыңлаучы балалар шикелле, нык күңел биреп, керфек тә какмый тыңлыйлар. «Ә син аны ныклабрак карамадыңмы, бер почмагында минем инициал юк идеме, ул мин ясаган пенал булгандыр әле...» – диләр.

Алар миннән үзебез ясаган изделиеләр турында гына түгел, ә шәһәрдәге яңалыклар турында да сорашалар.

Безнең авыл шәһәргә бик үк якын түгел югыйсә. Ике йөз егерме километр. Шулай да артельдәшләрем республикабызның үзәк шәһәрен яхшы беләләр. Анысына да күңелем була. Әйтик, алар, мин шәһәрдән кайткан саен: «Театрда булдыңмы?» – дип сорыйлар. Әгәр спектакль аларга таныш булса, актерлар турында, кайсы рольне нинди артист башкаруы турында сорашалар. Аннары шул спектакльне, шул спектакльдә уйнаучы республика артистларының үзләрен, уеннарын тикшерергә керешеп китәләр. Безнең авылның артель членнары республика артистларының фамилияләрен генә түгел, ә үзләрен дә ничек алай беләләр соң? Бик гади. Театрга йөрү – безнең членнарның көндәлек ихтыяҗларына кергән нәрсәләрнең берсе ул. Ә инде республика театрларын карарга омтылу бигрәк тә шулай. Була отпуск вакытлары, була ял көннәре. Ике йөз егерме километр ара безнең машиналар өчен дүрт сәгатьлек юл ул. Икенчедән, үзәк шәһәрнең артистлары, яхшы уйнаулары белән дан чыгарган артистлар, безнең авыл шикелле авылларга үзләре үк килеп спектакльләр куялар лабаса. Үткән җәйне генә, әйтик, Академия безнең авылга бөтен составы белән килде. Унбиш грузовик, унике легковой. Утырдылар да килделәр. Нәрсә әйтерсең? Безнең илдә машинага кытлыкмы әллә? Җәйнең күкрәп торган матур чагы иде. Икәвесен фатирга үземә үк алып кайттым. Хатыным ояла төште. Өем җыелмаган. Шундый зур кешеләргә уңайсыз туры килмәгәе, ди. Буламы соң? Килеп кергән уңай белән чишенеп ташладылар. Киттеләр буага. Минем анда көймәм бар. Тал төбеннән өстерәп тә чыгардым. Киттек йөзеп. Судагы төнбоекларга, ярдан, биек үлән араларыннан суга салынып торган чәчәк көлтәләренә карап җырлап җибәрделәр. Су уртасында көймәгә басып, башлары белән суга чумышырга тотындылар. Атказанган зур артистлар дип берәү дә әйтмәс. Мин дә чумам. Балалар шикелле уйныйбыз. Ә кичен, бөтен тирә-як авылларны таңга калдырып, спектакль бирделәр. Халыкның яше-карты, артистларның уйнауларын күрүгә генә канәгать итмичә, иртәгесен урамда, су буенда үзләрен күрергә, үзләре белән бергә йөрергә, сөйләшергә, бергә булырга тырыша.

Күңелле әнә шулай яшәү. Хәер, төп мәсьәләгә кайтыйк.

Шәһәргә бу килүемдә мин концертка бардым. Менә бу юлы булды соң артельдәшләремә сөйләр сүз!.. Баштан ук сөйләп биргәндә, менә ничек булды ул.

Антрактта халыкның бөтенесе дип әйтерлек запас ишектән, җәйге ишектән, бакчага чыкты. Битне, башны, бөтен гәүдәне иртә җәй төненең тәмле исле саф һавасы сыйпап алды. Шуның белән бергә биредә кинәт тын булып калгандай тоелды: аяк тавышлары ишетелмәс булды, ишектән тыгылып чыккан халык та, тавышсыз-тынсыз, сизелмәстән эрегән шикелле, каядыр таралды. Мин хәзер генә өзелгән концертның, бигрәк тә соңгы номерларны башкарган җырчының, зифа буйлы, чибәр һәм яшь артистканың, соклангыч моңы тәэсире астында яши идем әле. Күңелем матур, нечкә хисләр белән тулган иде, шул хисләрдән аерыласым килми иде. Шау-шуны, хәтта төрле якларга күз йөртеп мавыгуны да теләми идем. Хәер, башкалар да шундый ук кичерештә иделәр булса кирәк. Алар да өелешеп түгел, ә тарау йөрергә, тын йөрергә тырышалар иде бугай. Көчле лампалар белән яктыртылган яшел һәм яшь яфраклы акация, чаган куаклары арасыннан, зәңгәр буяулы яңа беседкалар арасыннан аларның берәм-сәрәм үтеп-үтеп китүләре генә күренә иде миңа. Тагын да дөресрәк итеп әйткәндә, бакча һәм андагы халык минем күз алдымда менә болай сурәтләнә иде: бакча үзе – бик көчле лампа белән яктыртылган зур өстәл өсте, бакчадагы куаклар, агачлар, беседкалар – өстәлне тутырып торучы букетлар, вазалар, кувшиннар, ә бакчадагы халык шул өстәл өстендәге лампа яктысында, чәчәк араларында талгын гына, тавыш-тын чыгармый гына очып йөрүче төрле төстәге күбәләкләр шикелле иде.

Мин, егерме-утыз яшәр бер тирәккә сөялеп, сукмак буенда басып тора идем. Тартып торуымны

күреп булса кирәк, кемдер ут сорады. Тиз генә кабыздым. Башында өр-яңа очлы түбәтәй, өстендә яңа гына үтүкләнгән кыйммәтле костюм, буе-сыны матур, йөзе крашка, җилгә каралган, чыраенда, гәүдәсендә тазалык, көчлелек сизелә, ләкин адымнары гамьсез... Бу кешедә дә чын мәгънәсе белән ял итеп йөрү сизелә иде. Менә ул каршыдан килгән ике кеше белән очрашты. Аңа дусларча сүз куштылар. Карасам, берсе – җырчы, артистка. Алар озак күрешми торган якын дусларча ялкынланып күрештеләр. Сылу артистка күз керфекләрен сирпеп елмайды, шатланды. Алар култыклашып йөреп киттеләр. Бер круг кешеләредер, монысы командировкадан яки отпускыдан, курорттан кайткандыр, кайткач шулай күрешәсең инде аны, дип уйлап алдым мин...

Икенче көнне иртә белән мин кайтырга чыктым. Поезд озак кузгалмый торды. Минем әллә ни багажым бармыни, бер чемодан гына, тоттым да платформага – иркенгә чыктым. Карасам, перронда җырчы артистка. Өстендә дулкынланып торган, мул, юка ал күлмәк. Тигез асфальттан җилфердәп, сәхнәдәге шикелле очыныбрак атлап, берүзе киң юл ярып, туп-туры вагон тәрәзәсенә таба бара. Тәрәзәдә – кичәге очлы түбәтәйле кеше. Ул гәүдәсен күкрәгенәчә тышка чыгарган. Тәрәзә алдында аның кызылсу кыйгач буйлы матур галстугы җилферди. Ул, рәхәт елмаеп, кулларын артисткага таба сузып тора. Мин тәрәзәгә якын гына идем. Артистканың вагонга таба сузылган кулында кечерәк агач шкатулка күргәч, йөрәгем кинәт әллә нишләде.

Шкатулка өр-яңа, ул магазиннан гына чыккан, ул безнең артель изделиесе – шахмат тартмасы иде. Күз ачып йомган арада минем хәтеремә артельдәшләремнең «Син аның почмагындагы инициалын карамадыңмы, ул мин ясаган әйбер түгелме икән?» дигән сораулары килеп төште. Чынлап та, бу, бәлки, мин ясаган шахматтыр? Тагын бер генә секунд ара булса, мин аның почмагын карамастан ук, тик капкач өстендәге гравюрага күз төшереп алганда да, кем эше икәнен аера алачак идем. Ләкин вакыт көтмәде, тартманы вагон тәрәзәсендәге куллар кочаклап алды. Артистка икенче кулы белән шул ук очлы түбәтәйле кешегә зур чәчәк букеты тапшырды. Вагонның барлык тәрәзәләрендәге йөзләр елмайды, андагы кешеләрнең һәммәсе дә артисткага баш иде, саубуллашып кул болгады. Очлы түбәтәйле кеше артистка белән берничә тапкыр күңелле сүз алышты, кат-кат хушлашып баш иде. Менә ахырда ул кеше елмая биреп миңа да баш каккандай булды, мин дә аңа баш идем һәм, башкача ни дип әйтергә дә белмәгәнлегемнән, үзем дә белештермәстән:

– Ул шахмат – безнең авыл артеленең изделиесе, аны без эшләдек, уйнаганда безне дә искә алыгыз... – дип әйтеп җибәрдем һәм шунда ук артисткага таба борылдым.

Артистка керфекләрен сирпеп елмайды.

– Шулаймыни? Алайса, мин аны үзебезнең авыл кешесенә бүләк итеп бирдем. Әнә теге көлеп торганы, түбәтәйлесе, безнең авылныкы, минем авылдаш, шахтер ул, авылга кайткан, тагын да шахтерлар алып китә... – диде.

Моңа ялгап сүз кушарга миндә запас сүз табылмады. Ашыгып, каушап, чемоданымны ачтым. Анда шундый ук фасонда, ләкин кесәгә сыярлык кечкенә һәм тагын да пөхтәрәк эшләнгән шахмат гарнитурасы бар иде. (Мин шәһәргә үрнәккә дип аларны берничәләп алып килгән идем.) Тартманы алдым да артисткага суздым.

– Мин менә монысын сезнең үзегезгә бүләк итимче, кабул итеп алыгызчы, – дидем.

Артисткам тагын елмайды.

– Сез соң үзегез кайдан? – дип сорады ул.

Мин тартманың эчендәге маркага, анда язылган авыл исеменә күрсәттем, шул артельнең председателе икәнемне әйттем, ахырда: «Мин кичә сезнең концертыгызда булдым, чын күңелдән үтенәм», – дип өстәдем. Ул тартманы алды. Матурлыгын, кечкенәлеген әйтеп, сокланып карап торды да, менә монысын минем үземә бүләк иттеләр, дип, тартманы шахтерларга күрсәтте.

Мин вагоныма йөгердем.

Менә бу күңелле булды соң...

Әмма артельдәшләрем сорашырлар да инде. Алар барыннан да бигрәк артисткага тапшырылган гарнитураның кем эше булганлыгы белән кызыксынырлар. Ләкин, минемчә, мәсьәлә анда түгел. Тартма кайсыбыз тарафыннан эшләнгән булса да – барыбер. Аны, безнең авылда ясалган тартманы, - артистка кеше – сәнгать кешесе – бүләккә дип, яратып сатып алган. Аның бүләген алыр кешеләр шахтерлар булган. Хикмәт әнә шунда! Сылу артисткалар ярата торган сәнгать әйберләре шахтерларның көндәлек тормышларына – табыннарына керә. Хикмәт әнә шунда!

*1939*

*XX гасыр совет чоры татар шигъриятенең күренекле вәкиле Нур Баян (Нур Галим улы Баянов) 1905 елның 15 маенда хәзерге Татарстан Республикасының Актаныш районы Әнәк авылында колхозчы гаиләсендә туа. Хуҗалык көчсез, тормыш авыр булганлыктан, Нурның әтисе Галим абзый үз балаларын җәйге айларда читкә акча эшләргә җибәрә торган була. Нур да, мәктәптә укулар бетеп каникул җитүгә, ел саен диярлек читкә китеп, төрле җирләрдә яллы эшләрдә йөреп кайта. 1921 елгы ачлык аны туган авылыннан бөтенләй чыгып китәргә мәҗбүр итә. Ул Пермь шәһәренә барып, кара*

*эшче булып яллана, ә 1923 елда укуын дәвам итү теләге белән Казанга килә һәм Татар-башкорт хәрби мәктәбенә курсант булып языла. Шушында укыганда аның әдәби иҗат эше дә башланып китә. Ул авыл тормышы, Гражданнар сугышы, илне саклау темаларына беренче шигырьләрен яза. 1925 елдан башлап матбугатта аның исеме инде тәмам үз булып китә.*

*1928 елда Нур Баян Казанда чыга торган «Кызылармеец» исемле хәрби газета редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша. Шул ук елда аның «Уракчы кызлар», «Җимерелгән окоплар» исемле тәүге ике шигъри җыентыгы басылып чыга.*

*1929–1930 елларда Н.Баян «Колхоз яшьләре» журналы редакциясендә сәркәтип булып эшли, аннары аны Чаллы төбәк газетасына баш редактор итеп билгелиләр. Газетада эшләү, авылларга чыгып йөрү аңа авыл җирендәге үзгәрешләргә, крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүгә караган бай фактик материал тупларга мөмкинлек бирә. Соңыннан, шуларга таянып, ул үзенең «Клеверлы кырлар» (1929), «Яңгырлы төн» (1933) кебек поэмаларын һәм күпсанлы лирик-публицистик шигырьләрен иҗат итә.*

*1932 елда Н.Баян яңадан Казанга кайта һәм 1932–1938 еллар арасында әүвәл Татарстан Язучылары берлеген оештыру комитетында эшли, аннары Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир һәм матур әдәбият бүлегенең өлкән редакторы-мөдире вазифаларын башкара. 1938 елдан Ватан сугышы башланганчыга хәтле ул фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Бу елларда ул «Гөләндәм» исемле шигъри повестен (1939), «Җимерелгән дворец янында» (1940), Г.Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»ына ияреп «Карәхмәт» (1940) поэмаларын яза, нәшриятта «Язгы төн» (1939), «Туган авыл» (1941), «Шат җырлар» (1941) дигән шигъри җыентыклары басылып чыга. Әдәби иҗат эшчәнлегендәге уңышлары өчен һәм Совет Татарстаны төзелүенә егерме ел тулу уңае белән совет хөкүмәте аны «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкли.*

*Нур Баян Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә һәм ахырга кадәр диярлек әүвәл полк партия оешмасының сәркәтибе, аннары дивизия газетасы редакторы һәм, ниһаять, полк командирының сәяси эшләр буенча урынбасары сыйфатында фронтның алгы сызыгында хезмәт итә, сугыш кырында күрсәткән батырлыклары өчен I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. Сугыш шартларында да ул әдәби иҗат эшен туктатмый, ватандарлык хисләре белән сугарылган шигырьләрен яза («Өч бөркет» җыентыгы, 1942), поэма һәм либретто язуын дәвам итә. Ләкин Җиңү көненә нибары унбиш көн кала, 1945 елның 23 апрелендә, Австрияне азат итү өчен барган соңгы сугышларның берсендә подполковник, шагыйрь Нур Баян дошман пулясыннан һәлак була.*

*Формасы ягыннан Һ.Такташ шигъри традицияләре йогынтысында үсеп, үз заманының тормыш сулышын, бигрәк тә күмәкләшү чорында татар авылындагы иҗтимагый-социаль үзгәрешләрне публицистик пафос белән чагылдырган Нур Баянның иҗат мирасы XX гасыр совет чоры татар поэзиясенең үзенчәлекле бер өлешен тәшкил итә.*

*Н.Баян – 1934 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

* * *

Минем өстән пуля яуса да,
Җәрәхәттән каннар тамса да,
Халкым өчен постта торырмын,
Халкым өчен туры булырмын.

Авырлыклар миңа килсә дә,
Барыр юлым дошман киссә дә,
Тереләй бирелмәмен дошманга,
Хыянәт итмәм Татарстанга!

Кая гына аяк бассам да,
Тик бер генә пуля атсам да,
Сөйгән халкым өчен барысы да,
Туры улың, халкым, мин сиңа.

*1943*

## САНДУГАЧКА

Кызык кош син, сандугачым-дустым,
Туп ярыла, ә син сайрыйсың,
Тормыш итәр өчен туган илдә,
Ояң өчен куак сайлыйсың.

Матур ил шул безнең илебез,
Ал чәчәкле безнең җиребез.
Их, яшисе килә илемдә,
Һич үләсе килми тигенгә.

*Көньяк-көнбатыш фронт*
*1943*

**САНИТАРКА**

Елмаясың миңа, очрашканда,
Иркәләнеп кулың сузасың,
Ә кайчакта, урман кызы сыман,
Букет тотып яннан узасың.

Яратам мин сине ут кырында
Шат булганың өчен һаман да,
Җырлыйсың син, күңел юатасың,
Сиңа киләм артык арганда.

Хәтерлимсең, кичә командирны
Коткардың син авыр үлемнән,
Ут кырыннан аны алып чыктың,
Кан тамчылый иде йөзеннән.

Син коткарган егет герой иде,
Сөеклесе иде Ватанның,
Сакчы улы һәм якчысы иде
Тиз киләчәк матур ал таңның.

Ут көрәше бетеп, ялан тынгач,
Очрашсак без бер үк табында,
Хәтерләрбез көрәш барган чакны
Текә таулы Донец ярында.

*1943*

* * *

Тирә-якта үлән чәчәк аткан,
Каен яфрак ярган урында
Кара күзем алга төбәп ятам
Тирән окоп һәм киң болында.

Кулымдагы җитез автоматның
Алга төбәп куйдым көпшәсен,
Мин хат яздым, тизрәк җитсен хатым,
Зәңгәр күзем яшен түкмәсен.

Хатым китте йомшак таңгы җил күк,
Гомер дустым, сөйгән ярыма,
Ә мин калдым сугыш яланында,
Караңгы төн. Бомба ярыла.

Яңгыр сыман өскә пуля ява,
Бала елый кебек еракта,
Гүя үкси анда хәлсез ана,
Иркәм тавышы килә колакка.

Ярсып-ярсып атам һәр пулямны,

Ватан өчен, туган ил өчен,
Балам өчен, атам-анам өчен,
Назлап сөйгән нечкә бил өчен.

*1942*

* * *

Хат язсам да инде бармас төсле,
Ахры, ерак киттем илемнән,
Бала чакларымда уйнап йөргән,
Чия чәчәк аткан җиремнән.

Ерак киттем. Бөдрә чәчле таллар
Көтәләрдер таныш җырчысын,
Көтәләрдер кырлар, биек таулар,
Шат күңелле еллар юлчысын.

Борчылмагыз, мине белгән дуслар,
Шат җырчыгыз сезне онытмас,
Бер кайтыр ул, якты кояш сыман,
Дошманнарны җирдән корыткач.

*Май, 1943*
*Донец*

## УЙЛАНГАНДА

– Сау бул... – диден чыгып киткән чакта,
Күзләремә тутырып карадың.
Килми миңа хәзер сәлам хат та.
– Сөям, – диден, нигә алдадың?

Иреннәрең минем битләремне
Яндырырдай итеп үпкәндә,
Мин ышандым сиңа. Мәхәббәтем
Калдырдым мин чыгып киткәндә.

Акларсыңмы минем мәхәббәтне?
Ә мин сине өзелеп сагынам,
Ник сагынам сине мин бу хәтле,
Рәсемеңә синең табынам.

Тәүфыйгыңны әгәр бозмасаң син,
Кабат әле бергә булырбыз.
Алма кебек уллар үстерербез,
Матур тормыш, иркәм, корырбыз.

*Май, 1943*
*Донец*

*Касыйм Вахит (Касыйм Мисбах улы Вахитов) 1916 елның 16 мартында хәзерге Башкортстан Республикасының Әлшәй районы Нигъмәтулла авылында урта хәлле крәстиян гаиләсендә туа. 1935 елда Дәүләкән педагогия техникумын тәмамлап, шул ук төбәкнең Искәндәр авылындагы тулы булмаган урта мәктәптә (ТБУМ) укытучы булып эшли башлый. 1937 елда Казанга килә һәм педагогия институтына укырга керә. Ватан сугышы башлануга, әле яңа гына институтның татар филологиясе бүлеген тәмамлаган Касыйм Вахит үзе теләп фронтка китә һәм сугышның беренче көннәреннән үк алгы сызыкта булып, 1942 елның 4 октябрендә Сталинград өчен барган канлы бәрелешләрнең берсендә дошман пулясыннан һәлак була. Сугышчан иптәшләре аны Шелемка дигән авыл янындагы туганнар*

*каберлегенә җырлиләр.*

*К.Вахитның беренче шигырьләре 1932–1933 елларда Уфадагы «Коммуна» исемле өлкә газетасында (хәзерге «Кызыл таң») басыла башлый. Соңрак ул Татарстандагы көндәлек матбугатта – «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары»), «Чаян», «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналларында актив язышa. Аның шигъри тезмәләре шулай ук яшь язучыларның «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940), «Очкыннар» (1940) исемле күмәк җыентыкларына да кертелә. Яшь шагыйрь, өйрәнү чоры кичереп, шигъри форманы төрләндерү юнәлешендә тәҗрибәләр ясый, поэзиянең төрле жанрларында көчен сынап карый. Аның зур булмаган әдәби мирасыннан «Сөйләнмәгән әкият» исемле поэмасын, Көнбатыш Украинаны СССРга кушу вакыйгасын хуплап язган «Егет турында баллада»сын, юмористик шигырьләрен һәм кечкенә лирик парчаларын атап үтәргә мөмкин. Касыйм Вахитның иҗат мирасыннан аерым үрнәкләр сугыштан соңгы чорда нәшер ителгән «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) һәм «Утлы еллар поэзиясе» (1972) исемле басмаларында урын ала.*

## УЛ

Авырлыклар килсә миңа, ул булыша,
Бөтен кешеләрдән якын ул;
Тормышымны нурландырып тора,
Минем өчен гәүһәр, алтын ул.
Бар шатлыкны бергә бүлешәбез,
Тамчы суны бүлеп эчәбез,
Ут, ялкынны бергә без үтәбез,
Агым суны бергә кичәбез.
Көне буе аны күрми торып,
Кайттым исә яллар итәргә,
Битләремнән сыйпап сөя-сөя,
Күмелдерә кайнар хисләргә.
Аның белән бергә чакларымда
Урын бетә авыр хисләргә,
Кайгым булса, чынлап кайгыралмыйм,
Аптырадым, хәзер нишләргә?
Ул дигәч тә гаебемә кереп,
Еракларга сузма уеңны.
Кызыксынсаң әгәр, сиңа әйтим,
Ул – анасы минем улымның.

*1941*

## ҮЧ

Ял итәргә килеп туктый гаскәр,
Каршы ала колхоз өйләре.
Карап тора буйга җиткән сылу,
Урам киртәсенә сөялеп.

Озын походларны үткән гаскәр
Килеп туктый сусап, талчыгып.
Йөгерә-йөгерә безгә ул китерә
Чишмә суларының салкынын.

Сугышчының шаян сүзенә дә
Илтифатсыз, дәшми, җавапсыз.
Сугышчылар һаман сүз сузалар:

«Бигрәк эре, бигрәк гаҗәп кыз!»
Йөзләрендә шиңгән алсулыклар,
Күзләренең боек карашы.
Әллә ничек сиңа серле бага –
Һәм терелтә йөрәк ярасын...

*

Немец бандалары басып алды
Гөрләп торган шаулы авылны,
Хурладылар көчләп хатын-кызны,
Таладылар соңгы кабымны.

Урам буйлап камчы хөкем сөрде,
Авыл торды канлы яшь түгеп...
Безнең Валя, Валя, гүзәл Валя
Югалтты шул үзенең яшьлеген.

Багалмадай йөзле сылу Валя
Чандыр офицерга ошаган.
Шакшы фашист,
Гүзәл рус кызының
Ачы күз яшенә сусаган.
Ак кар битен саргылт ай үпкәндә,
Валя үткән авыл урамын.
Һәм шул көнне сакчы ишетеп торган
Яп-яшь кызның үксеп елавын.
Күкселләнеп кышкы таң атканда,
Кыз чагында үткән урамын
Хатын булып үтеп киткән Валя,
Кайнар күз яшенә уралып.
Шулай Валя өйгә кире кайткан,
Тик яшьлеге кире кайтмаган,
Уйчанланган, йөзе аксылланган,
Ашамаган, берни капмаган.

Озын походларны үтеп гаскәр
Ял итәргә бүген туктаган.
Яшь комиссар күптән эш өстендә,
Кояш әле, ялкау, чыкмаган.
Күзен алмый карап торган кебек
Сөйгән кызын артык яратып,
Ак кәгазьгә төшеп эрегәндәй
Комиссарның үткер карашы.
– Иптәш комиссар!
Мине частегызның
Сугышчысы итеп алыгыз!
Намусым даулап барам үч алырга,
Пулеметчик итеп языгыз...

*

Колонналар булып безнең гаскәр
Көнбатышка узган чагында,
Күзләрендә ачы нәфрәт тоткан
Уйчан кызны күрдем тагын да.
Пар ат җиккән җиңел тачанкада
Пулеметы белән ялгызы:

Ил алдында үзенең намусын яулап,
Үч алырга китте ил кызы.

*1942*

* * *

Яшьлегемнең асыл чәчәгенә,
Тормышымның асыл гөленә,
Нинди генә җылы сүзләр әйтим,
Тәбрик итеп, туган көнеңә.

Күкрәгемә кочып сөяр идем,
Җитми анда, иркәм, колачым,
Яннарына очып кайтыр идем,
Булсам таулар гизгән бер лачын.

Татыр идем иренең кайнарлыгын,
Якын булсам әгәр яныңда,
Минем теләк: көрешергә булсын
Килер майның шушы таңында.

*1942*

## ТӘРӘЗӘҢНЕ АЧ ТА

Яшеренмә син яшеннән,
Давылдан качма.
Җәйнең хәтәр көннәрендә
Тәрәзәңне ач та.
Күкне күзәт, тибрәндерми
Керфек очыңны.
Бик якын итеп хәтерлә
Ерак дусыңны.
Яшен алсын бүлмәңдәге
Төннең карасын,
Сибелдереп чәчләреңне
Давыл тарасын.
Давыл, давыл, ул бит минем
Тере хәбәрем,
Якын яшен, ялкын яшен –
Минем сәламем.
Мин сулармын, давыл җирдә
Тынмаса әгәр,
Мин янармын соңгы яшен
Сүнгәнгә кадәр.

*Вәдүт Кашшаф улы Мифтахов 1915 елның 20 ноябрендә Татарстан АССРның Сарман районы Яхшы Каран авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа. 1931 елны Сарман җидееллык мәктәбен тәмамлый. Шул ук елны Лубян урманчылык техникумына укырга керә. Аннан соң Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.*

*Мифтах Вәдүт озак еллар Питрәч районы Шәле урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Беренче шигырьләре 1933–1934 елларда газета-журналларда басылып чыга. Яшь шагыйрьнең беренче китабы 1939 елны дөнья күрә.*

*Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк шагыйрь гади солдат булып туган илен саклауда катнаша. Фронтта ул, комсомол-шагыйрь буларак, командованиенең һәртөрле җаваплы заданиеләрен үти, гади солдаттан полк комсоргы булып күтәрелә.*

*М.Вәдүт Мәскәү янындагы сугышларда катнаша, Ватаныбызның йөрәге булган Мәскәү шәһәрен*

*күкрәген куеп саклый.*

*М.Вәдүтнең тормышы аның иҗаты чәчәк атып килгән вакытта өзелә. Ул 1942 елның 30 мартында сугыш кырында батырларча һәлак була. Яшьлеккә дан җырлаучы солдат-шагыйрь М.Вәдүтнең җәсәде Тула өлкәсе Арсеньев районы Рыдань авылында җирләнә.*

## ҖЫР

Тал-тирәктә сайрый сандугач,
Сызылып алтын таңнар атканда,
Тавышкае өзә үзәкне,
Моңаясың өзелеп сагынгач;
Гыйшык уты дөрләп капканга,
Басып кына булмый йөрәкне,
Басып кына булмый йөрәкне.
Сандугачкай, сайра, туктама,
Кояш алтын нурын сипкәнче,
Мин тыңлармын сине, йокламам,
Күрешер минутларым җиткәнче.
Тирбәләдер җилгә тал-тирәк,
Сандугачкай канат кагына:
Яшь йөрәккә сөйгән яр кирәк,
Яшь йөрәккәй ярын сагына.
Сандугачкай канат кагына,
Сайрый-сайрый яшел тирәктә,
Тавышкае өзә үзәкне.
Җанашымны өзелеп сагынам,
Гыйшык уты яна йөрәктә,
Басып кына булмый йөрәкне,
Басып кына булмый йөрәкне.
Тирбәләдер җилгә тал-тирәк,
Яшь йөрәккә сөйгән яр кирәк,
Сөяр өчен ярлар күп була,
Саф күңелле чын дус – пар кирәк.

## ТИМЕРЧЕЛӘР

Тирән-тирән сулап, һава өргеч
Кара күмерләрне яндыра.
«Чакы-чокы» чүкеч чыңгылдавы
Бертуктаусыз тора яңгырап.
– Өрдер өргечләреңне,
Яндыр күмерләреңне лә,
Күтәр чүкечләреңне,
Һап!..
Чакы-чокы-чак!..
Очкын оча утлы күмерләрдән,
Алтын йолдыз сибелә диярсең.
Алмаш-тилмәш суга өлгер куллар,
Чүкечләргә тик күз иярсен!
Егет булсаң,
Хезмәт итеп,
Күрсәт син көчләреңне лә,
Күрсәт син көчләреңне!
Һап!..
Чакы-чокы-чак!..

Чагылып китә маңгай тирләреңдә
Күмерләрдән төшкән яктылык.
Җыр кушыла чүкеч тавышына,
Беләкләрнең көчен арттырып.
Өрдер өргечләреңне,
Яндыр күмерләреңне лә,
Күтәр чүкечләреңне,
Һап!
Чакы-чокы-чак!

*Габдулла Гали улы Галиев 1920 елның 20 июнендә Татарстан Республикасының Теләче районы Шәдке авылында мөгаллим гаиләсендә туа. 1935 елда Шәдкедәге җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанга килеп педагогия институты каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы чорда аның әдәби иҗат эшчәнлеге башлана. 1939 елда Татарстан дәүләт нәшриятында яшь авторның «Яшел бөреләр» исемле зур булмаган шигъри китабы дөнья күрә, тагын бер елдан (1940) «Үсәбез» дигән озын шигыре аерым китапчык булып басылып чыга.*

*Габдулла Галиев, 1939 елда гаскәри хезмәткә алынып, Ватан сугышының беренче көннәреннән үк сугыш хәрәкәтләренең алгы сызыгында була. 1941 елның сентябрь аенда Украинадагы Каменец-Подолский шәһәрен саклау өчен барган бәрелешләрнең берсендә ул дошман пулясыннан һәлак була.*

*Г.Галиевнең әдәби иҗатыннан бер төркем шигырьләр С.Шакир төзеп чыгарган «Алар сафта» (1961, 1985) исемле җыентыкта урын ала.*

## БАТЫРЛАРГА

Табигатьнең усал көчләренә
Буйсынмыйча, безнең кешеләр
Томанлы һәм салкын боз иленә
Самолетта барып төштеләр.

Батырларның алсу йөзләрендә
Җиңү дәрте – шатлык уйнады,
Пропеллерга килеп бәйләнсә дә
Карт Котыпның әче бураны.
Кызыл флаг бозлар уртасында
Дулкынлана Котып җиленнән.
Котыптагы тиңсез батырларга
Кайнар сәлам бәхет иленнән.

Шуып йөргән бозлар төркеме дә,
Әче суык җилле буран да
Киртә була алмый дан эшенә,
Бөтен шартлар бездә булганга.

Дан эшләре һаман күтәрелә,
Тиздән инде безнең батырлар
Хыял булып торган бөек эшкә –
Марска да барып кайтырлар.

*1937*

## АК КАЕН

Мул уңышлы кырның уртасында
Үсеп тора ялгыз ак каен.
Яфрак ярып һәр ел каршы ала
Чәчәкле һәм матур май аен.

Бер истәлек булып каен үсә
Яшь батырның кабере өстендә.
Якты кояш аңа нурын сибә,
Җыр җырлана аның исменә.

Давыл елы иде, Камил дигән
Яшь көрәшче ялкын эченнән
Җиңеп, яулап алгы сафта барган,
Ләкин шунда гомере киселгән.

Ирек өчен сугыш кырларында
Тынган аның кайнар йөрәге.
Гайрәт биргән көрәш улларына
«Алга!» дигән соңгы сүзләре.

Ирек таңы безнең күгебезгә
Нурлар чәчеп җәйгәч канатын,
Сафа бабай аның каберенә
Утырткан бер каен агачын.

Җәелеп киткән кырның күкрәгендә
Мактау биреп якын-тирәгә,
Яфракларын селкеп әкрен генә
Хозурланып каен тирбәлә.

Егерме ел узган, каен үскән,
Еллар саклый батыр юлларын.
Каен җырлый хәзер шаулап үскән
Яшь батырның кайнар җырларын:

«Кызганмабыз данлы гомерне дә
Хезмәт халкы өчен көрәштә.
Ирек алып, давыл көннәрендә
Без ирештек бөек теләккә!»

*1937*

*Шагыйрь Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин) 1913 елда хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән районы Тозау авылында игенче гаиләсендә туа. Башлангыч мәктәпне туган авылында, җиде сыйныфны Әлмән крәстиян яшьләре мәктәбендә укып тәмамлагач, 1931 елда шул төбәктәге Мартыново авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Ләкин, матди хәле авыраю сәбәпле, укуын ташларга мәҗбүр булып, шул ук Мартыноводагы ятим балалар йортының мөдире сыйфатында хезмәт юлын башлый. 1934 елда аны Сафакүл район үзәгендәге башлангыч үрнәк мәктәбенә мөдир итеп куялар. Шунда эшләгәндә, ул «Колхозчылар тавышы» дигән төбәк газетасында актив язышa – шигырьләрен, көндәлек тормыш вакыйгаларына багышланган мәкаләләрен бастыра. Яшь шагыйрь һәм хәбәрченең исеме Чиләбе һәм Свердловск шәһәрләрендә чыга торган «Коммунист» һәм «Социализм юлы» газеталары битләрендә дә күренә башлый. Озакламый аны Чиләбегә «Коммунист» газетасы редакциясенә эшкә чакырып алалар. 1937 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының читтән торып уку бүлегенә кабул ителә. 1938 елда «Коммунист» газетасы чыгудан туктагач, Макс Гатау Чиләбедәге татар мәктәпләренең берсендә директор булып эшли, ә 1940 елның көзендә әти-әнисе яшәгән Сафакүлгә кайтып, Ватан сугышы башланганчыга хәтле урындагы татар урта мәктәбендә тарих фәне укыта, бер үк вакытта мәктәпнең директоры вазифаларын да башкара. 1939 елда Казанда Макс Гатауның Урал табигатен, Уралдагы индустриаль төзелеш күренешләрен, күмәк хезмәт тантанасын чагылдырган лирик шигырьләре тупланган «Урал мәхәббәте» исемле кечкенә җыентыгы басылып чыга. Шагыйрь икенче җыентыгын да басмага әзерли, ләкин, сугыш башлану сәбәпле, китап чыкмый кала.*

*Макс Гатау 1941 елның июлендә фронтка китә һәм шул ук елның 20 ноябрендә Калинин (хәзерге Тверь) өлкәсендәге Гаврилово авылы янында барган сугышларның берсендә һәлак була.*

*Макс Гатауның зур булмаган әдәби мирасыннан бер төркем шигырьләр 1961, 1985 елларда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкка һәм ике шигыре («Безнең нәсел», «Комбайнчы») «Татар поэзиясе антологиясе»нең икенче томына (1992) кертелә.*

## БЕЗНЕҢ НӘСЕЛ

Көрәшләрдә җиңеп яшәр өчен,
Бәхет өчен туган кеше без.
Йөз еллардан соңгы буыннарны
Таң калдырыр безнең эшебез.

Бездә кеше йөз ел гомер итеп,
Агарса да кара чәчләре;
Йөрәгендә саклап алып бара
Яшьлегенең алсу чәчәген.

Безнең нәсел өчен каберләр юк,
Мәңге үлмәс данлы эшебез.
Көрәшләрдә җиңеп яшәр өчен,
Бәхет өчен туган кеше без!

## КОМБАЙНЧЫ

Җый, комбайнер, җый
Иген уңышын!
Чәчәккә бизә
Илнең тормышын.
Арыш башлары
Түбән иелгән.
Дулкынлана ул
Җәйге җил белән.
Шаула, комбайн,
Шаула көн саен!
Сине киң кырлар
Көтте масаеп.
Мул уңышыбыз
Чиста җыйналсын!
Бер генә башак та
Җирдә калмасын!
Шаулат, комбайнчы,
Шатлык җырларын.
Яңгырап торсын
Иген кырлары.
Җый, комбайнчы, җый
Иген уңышын!
Уңышлар бизи
Илнең тормышын.

*Шагыйрь Мансур Гаяз (Мансур Гаяз улы Гаязов) 1917 елның 5 октябрендә Мари Республикасының (хәзерге Мари Эл) Бәрәңге районы Бәрәңге авылында дөньяга килә. Бәрәңге педагогия техникумында белем ала, аннары шул ук Бәрәңге авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. 1938–1940 елларда армиядә хезмәт итә. Ватан сугышы башлану белән фронтка*

*китеп, фашизм илбасарларына каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, берничә тапкыр яралана. Ләкин аңа җиңү көннәрен күрергә насыйп булмый: 1943 елның 19 ноябрендә Белоруссиянең Витебск өлкәсе Усково авылы өчен барган бәрелешләрнең берсендә егерме алты яшьлек шагыйрь дошман - пулясыннан һәлак була. Мансур Гаяз – сугыш алды елларында әдәбият мәйданына чыгып, кыска гына вакыт эчендә исемнәрен танытып өлгергән, ләкин, иҗади талантларын ахыргача ача алмыйча, Ватан сугышы фронтларында халыклар азатлыгы өчен гомерләрен биргән зур бер төркем татар әдипләренең берсе. Ул 1936 елда яза башлый. Алты еллык иҗат гомерендә (шуның ике елы фронт шартларында) ул чордашларының җанлы образларын, уй-хисләрен сурәтләгән күп кенә лирик шигырьләр, «Тормышны сөю», «Испанка» исемле ике поэма иҗат итә. Алар сугышка кадәр яшь язучыларның «Алмаш» (1938), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940) исемле күмәк җыентык һәм альманахларында басылып чыга. Иҗат эшчәнлеген ул сугыш шартларында да алып барырга тырыша: фронт газеталарында ватандарлык хисләре белән сугарылган публицистик шигырьләрен һәм очерк язмаларын бастыра.*

*1959 елда Татарстан китап нәшрияты, шагыйрьнең иҗат мирасыннан сайлап алынган әсәрләрне туплап, аерым китап бастырып чыгара. Аның бер шәлкем шигырьләре шулай ук Ватан сугышында һәлак булган язучыларның әсәрләре тупланган «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) исемле күмәк җыентыкларда һәм «Татар поэзиясе антологиясе» (1956, 1992) басмаларында да урын ала.*

## ЧИКТӘ

Чик.
Салкынча һәм җилсез көзге иртә.
Биек таулар... Нарат урманы...
Тирән тынлык күңелләрне борчый,
Хисләр тынгысызлый уйларны.
Өстә шаулап торган күксел урман.
Аста кара, тирән упкыннар.
Сөзәк кенә төшкән ташлы ярлар.
Үзәнлекләр. Уйсу урыннар.
Сузыла атлас кебек зур җәйләүләр,
Күгелҗем вак күлләр тезмәсе
Һәм күренә күл өстендә уйнап
Җитез үрдәкләрнең йөзгәне.
Дымлы һава рәхәт кенә тибри,
Нинди ямьле, матур яшел көз!
Болытлардан вак энҗеләр коела,
Күк күкрәүсез, якты яшенсез.
Һичбер нәрсә бозмый чик тынлыгын
Һәм күренми күзгә беркем дә.
Пограничник ята посып кына
Шунда, яшел куак төбендә.
Күзәтә ул чикнең тынычлыгын,
Шуңа биреп уен, күңелен,
Озатып кала күздән югалганчы
Хәтта очкан кошлар төркемен...

*1939*

## ЭСКАДРОН БАРА

Эскадрон бара.
Һава тын, коры.
Яңгырап кала
Тояклар җыры.

Егетләр тыныч,

Шәп аргамакта.
Билләрдә – кылыч,
Башларда – каска.

Җиңеп дошманның
Канлы сафларын,
Чистартып илнең
Изге туфрагын,

Далалар буйлап
Эскадрон чаба,
Барган юлында
Киртә юк аңа.

Каршылый безне
Авыллар, өйләр,
Түземсез көткән
Апа, әниләр.

Ягымлы караш
Һәм җылы сүзләр.
Яшь белән балкый
Шатлыклы күзләр.

Егетләр батыр,
Мактауга ия.
Бу сафта бара
Комсомолия!

*1944*

## АНА ВАСЫЯТЕ

Озын юл буйлап сузыла
Ямь-яшел болын.
Шул юлдан ана көрәшкә
Озата улын.

Чагыла сабыр йөзендә
Борчулы төсе,
Җемелди керфек очында
Бөртек энҗесе.

Улының батыр йөзенә
Юнәлтә күзен,
Һәм сөйли аңа иң соңгы
Кадерле сүзен:

«Барасың изге көрәшкә,
Якты күз нурым,
Кызганма каның, кирәксә,
Ак булсын юлың!

Таза тәнеңдәге куәт
Һәм яшәү көчең
Бир көрәшкә үзең теләп
Илебез өчен.

Син күңелемдәге куаныч

Һәм йөрәк парәм,
Яшьнәсен кулыңда кылыч
Сафларда алдан.

Сез күрсәтегез илемнең
Көчен, куәтен,
Дошман өстендә дәһшәтле
Үлем күкрәсен.

Зур көрәш юлында гомерең
Чикләнсә әгәр,
Сөелеп телдә йөрерсең
Һәм даның яшәр.

Бөек көрәштә бергә без –
Күп түгел ара,
Сезнең йөрәктә аналар
Җылысы бара.

Тар-мар ит дошманны, улым,
Таза-сау йөре,
Җиңү белән үтсен юлың,
Аннан кайт кире...»

*1941*

**САГЫНУ**

Син мәктәптә кердең аңыма
Шигырьләрең җылысы аркылы,
Йөрәгемдә туды шул вакыт
Сиңа булган сөю ялкыны.

Уйларымны биләп алдың син,
Бөтен тынычлыгым югалттың,
Иң беренче башлап күңелдә
Саф шигъри көчләр уяттың.

Авыр булды... үлем хәбәрең
Килеп җиткәч газет битендә.
Шул вакытта түккән яшьләрем
Бүгенгедәй әле исемдә.

Ара ерак булса, хат йөри,
Күңелеңне шулар юата.
Сине югалтуның ярасы
Кайгырып та бетми, елап та.

Нинди генә адрес язсам да
Беләм хатым барып җитмәсен,
Ахрысы, син шулай гомергә...
Сагынып яшәр якын иптәшем!

Кулларыңны кысар идем бер,
Күрсәм әгәр исән чагыңда,
Алып килер идем шигырьләр
Ярдәм сорап синең яныңа.

Ләкин синең белән булырга
Туры килмәс инде гомергә,
Күрешсәк тә икәү без, абый,
Очрашырбыз бары шигырьдә.

Чикләнмәде әле яшәвең,
Синдә яңа гомер кабынды,
Кучердең син бөек сәнгатькә
Каләм белән йөрәк каныңны.

Син – халыкның мәңге онытылмас
Шат күңелле сөйгән шагыйре,
Әле синең зәңгәр күзләреңдә
Күпме яшәү дәрте бар иде!

Син йөрәктән алып җырладың,
Якын иде шуңа уйларың,
Әле бит син азат тормышның
Матурлыгын сөеп туймадың.

Килеп чыккан идең кояшка,
Үтә-үтә авыр юлларны,
Тавышың киткән саен еракка,
Күтәрелә бардың югары.

Дошманнарга булдың аяусыз.
Тынгы бирмәдең һич аларга,
Белә идең үткен сүзләрне
Кай җиренә, ничек кадарга.

Әле синең язар җырларың,
Тагы да матур булыр иделәр,
Тик гомерең белән киселде
Чишмә булып агар шигырьләр.

Шаулы тормыш белән шигырьләрең
Ерак юллар аша барырлар
Һәм яшьләрне иҗат эшенә
Чакыру тавышы булып яңгырар.

*1941*

## ТЕТРӘСЕН ДОШМАН

Туган илнең ике ягыннан без,
Юлларыбыз бергә очрады.
Бер дошманга карап юнәлтелгән
Кулда үткен штык очлары.

Көрәшләрдә җиңү өчен кирәк
Ихтыяр һәм тимер чыдамлык.
Бар ул бездә! Туплар гөрселдәгән
Үлем кырларында сыналдык.

Дошман тәнгә кызу тимер басты
Һәм чыгарды чукып күзләрне.
Күкрәкләргә йолдыз рәсемен уйды,
Тәндә калды итек эзләре.

Күрелмәгән мондый җинаятьне

Хәтерләргә күңел тарсына,
Безнең йөрәкләрдә булмас аңа
Кызганулы хис бер тамчы да!!

Сыялмыйча кайный күкрәкләрдә
Тирән ачу, ачы нәфрәт,
Бәр башына – чикәләрен җимер,
Чыксын ике күзе чәчерәп!!

Тетрәт аны, һич аяма көчең,
Чумсын канга – тура, телгәлә!
Үзе башта тешләгәне өчен
Этkә күсәк таза эләгә.

*1943*

*Шамил Гәрәй (Шамил Мөхәммәтгали улы Гәрәев) 1916 елның 31 декабрендә Казан шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа. Бик яшьли әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Җиденче сыйныфта укыган чагында, 1931 елда, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында аның балалар өчен язган шигыре басылып чыга, тагын бер елдан «Сигналчы җыры» исемле китабы дөнья күрә. Шуннан соң, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә (1931–1941), Шамил Гәрәй Татарстан дәүләт нәшриятында тагын дүрт шигъри җыентыгын («Звено җыры», «Флюра», «Тормыш иртәсе», «Тормыш чәчәкләре») һәм балалар өчен бер очерк китабын («Яңа совхозда») бастырып чыгара. Нигездә, яшь укучыларга адресланган һәм туган ил, бәхетле балачак, туган табигать турындагы уй-хисләрен шактый тәэсирле итеп чагылдырган бу шигырь китаплары белән Ш.Гәрәй үзен үсеп килүче өметле шагыйрь итеп таныта. Ул шулай ук әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә сәләтен күрсәтә. «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналларында аның тәрҗемәсендә А.Чехов хикәяләре, М.Лермонтов шигырьләре, украин фольклорыннан үрнәкләр һәм аерым басма рәвешендә Л.Квиткоының «Бишек җыры» (1940), А.Бартоның «Уенчыклар» (1941) исемле китапчыклары басыла.*

*Ватан сугышы башлангач, Ш.Гәрәй фронтка китә. Мәскәү янында барган каты сугышларның берсендә сугышчан иптәшләре белән чолганышта калып, ул фашистлар кулына әсир төшә һәм фашизм коллыгының бөтен авырлыкларын башыннан кичерә. Инде җиңү көне килеп, әсирлектән йолып алынса да, аңа туган каласы Казанга кайтып яшәргә һәм әдәби иҗат хыялларын тормышка ашырырга насыйп булмый – 1946 елның 22 мартында Польшаның Гливице шәһәрендә әсир тоткыннарны тикшерү лагеренда вафат була. Китапларыннан тыш Шамил Гәрәйнең шигъри иҗатыннан үрнәкләр «Алар сафта» (1961, 1985) һәм «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) басмаларына да кертелә.*

## ИКЕ ТУГАН

*(Баллада)*

Барыгыз да аягүрә торыгыз!
(Корбаннарны искә алабыз.)
Әй, бәхетле яшьләр, якты көннең
Тарихын сез кайтып карагыз!
Сез күрерсез алар түккән канның
Ел да кызыл чәчәк атканын,
Сөякләренең бөек ил нигезендә
Гранит ташы булып ятканын.

### I

Алар һаман минем күз алдымда
Ирек өчен сугышып йөриләр...
...Язгы бер кич иде. Минә алар
Шаулап өйгә кайтып керделәр.
– Әнкәй! Без фронтка барабыз,

үзебез теләп,

Бүген кичен, ахры, китәрбез,
Син тыныч бул, әнкәй,
Деникинны
Җиңгәч тә без кайтып җитәрбез.

Әйтерсең лә менә яшен сукты,
Сикереп торды ана сискәнеп,
Сизмәде ул хәтта кулындагы
Кашыгының төшеп киткәнен.
– Ах, Ходаем! Әллә син дәме? – дип,
Унбиш яшьлегенә карады.
Кайнар яшьләр...

яшьләр барыбер басмас

Йөрәктәге авыр яраны!
Күңеле тулып, ана үкси иде,
Тәрәзәгә табан борылып.
Яңгыр тамчылары пыяладан
Төшә иде аска егылып.
Гөрләшәләр иде күгәрченнәр
Шул чагында кәрниз астында,
Моңсулык бар иде ниндидер бер
Аларның да бүген тавышында.
Зурысы килеп сөйде аркасыннан:
– Елама син, әнкәй, елама,
Хәл кылынган чакта ил язмышы,
Елаудан соң эшләр буламы?!
Бер үтенеч әйтте кечесе,
Юлга әзерләнеп эш беткәч:
– Күгәрченнәр... әнкәй, син аларны
Туйдырырсың инде, мин киткәч...

## II

Зур походлар кичеп, хәл җыйганда,
Яңгырады сугыш җырлары,
Кечесенең нечкә саф авазы
Аерым-аерым булып чыңлады.

*

Сабый чакларында сөекле ана
Җәйгән җылы йомшак урында
Алар тыныч-рәхәт йоклый иде,
Берни белми кайгы турында.
Яңгыр койган төндә шинель ябынып
Менә тагын бергә яттылар.
Җылылыкны бүген бер-берсенә
Елышып яткач кына таптылар...

*

Әйтерсең лә яңгыр юып киткән,
Шундый якты зәңгәр күк йөзе,
Йомшак искән җилләр тирбәлдерә
Болындагы чәчәк диңгезен.
Агып ята елга үзенә яуган
Снарядлар белән болганып.
Көймә өсләренә күпер салып,
Батальон кичте елганы.

Дошман явы килә... Өлкәне
Пулеметын корды аларга,
Ә кечесе җитез кулы белән
Лента биреп торды аңарга.
Тамак чатнап кибә...
Басар өчен
Пулеметның кызып ярсуын,
Үз авызыннан өзеп эчерде аңа
Флягада булган бар суын.

Тукта, бу нинди хәл булды әле,
Без җиңәбез менә дигәндә,
Канатлары сынган лачын төсле
Авып төште кечесе чирәмгә.
Туган каны өчен тамырларда
Үч ялкыны дөрләп кабынды,
Авыр кайгы килгән бу минутта
Шундый зур көч каян алынды?
Чалгы белән чабып үтелгән күк,
Бер-бер артлы дошман кырылды...
Тукта, бу нинди хәл булды соң бу,
Өлкәне дә ауды, егылды...

**III**

Масайдылар аклар штабында,
Кызылларны, имеш, җиңгәннәр:
Кан эчендә һушсыз яткан җирдән
Туганнарны алып килгәннәр.
Пенсне аша карый карт офицер,
Китерергә тырышып сүз җаен,
Мәсхәрәле көлеп, өлкәненә
Соңгы тапкыр бирә соравын:
– Хәшәрәт җан!
Шулай, бернәрсә дә
Әйтмим сезгә, дисең инде син,
Ләкин оныта күрмә, моның хакын
Яшь гомерең белән түлисең...

Илгә биргән антын үтәде ул,
Эчендәге серен чишмәде.
Энҗе бөртеге күк тешләрен
Ныграк кысты, бер сүз дәшмәде.
Күтәрелде маузер көпшәсе...
Кечесе сикереп алга ташланды:
– Син үзең... син үзең хәшәрәт!.. –
Утлы сүзләр шулай башланды.
Кычкырды ул:
– Ерткыч!.. Буржуй нәгъләт!
Дөмегерсең барыбер тиз көннән! –
Ачы күз яшьләре канга кушылып,
Ермачланып акты битеннән.
Ул: «Яшәсен...» – диде, тәмамларга
Бирмәделәр, курок тарттылар,
«Коммунизм!» – диеп яңгырады
Өлкәненең тавышы...
Аттылар...

**IV**

Алар һаман минем күз алдымда
Ирек өчен сугышып йөриләр...
...Сагынып үзләренең яшь дусларын,
Күгәрченнәр эле дә гөрлиләр...

*1938*

## БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

Җәй иртәсе,
Торып,
бакча якка
Тәрәзәмне ачсам киереп:
Син үтәсең көлеп
күз алдымнан,
Дулкынланып, ташып, сөенеп.

Бакчадагы шомырт
Көлеп торган
Күзләреңне искә төшерә...
Ахры,
Бу табигать
бөтен матурлыгын
Сиңа гына биреп бетерә!

Унсигезенче язым үтеп китте...
Болай булырмын дип сизмәдем,
Бүген менә килдең,
Синең белән
Бергә китә язды күзләрем.

Иделдә дә йөздем,
Курку белми,
Дулкыннарны кисеп атылдым.
Бүген синең төпсез күзләреңә
Батып калмаммы соң, акыллым?

Көрәшләрдә янып,
Корыч төсле
Ныгыган иде минем йөрәгем,
Ә син бүген шундый йөрәккә дә
Мәхәббәтнең тамырын җибәрдең...

Күрәм,
шундый җитезлек белән син
Резецыңда винтлар кырасың.
Кызыл байрак алган цехыгызның
Тиңсез күрке булып торасың.

Күрдем синең,
спорт мәйданында
Йөгереп өстен чыккан көчекне,
Күрдем
Батырлык һәм матурлыкның
Командиры булган кешене!

Киләчәкне күбрәк сөйгән саен,
Бүгенге көн эшне сөйдерә,

Һәм эшемне күбрәк сөйгән саен,
Өзелеп сөям менә сине дә.

Шуңа мәллә,
Көн дә киң тормышка
Тәрәзәмне ачсам киереп,
Син үтәсең көлеп
күз алдымнан,
Дулкынланып, ташып, сөенеп...

*1934*

**УРМАН БУЕНДА**

Җәйге урман.
Нарат агачлары
Гаскәр кебек тезелеп киткәннәр.
Җиләк урыны –
Яшел куаклыклар
Урман буен бизәп үткәннәр.
Салмак кына
Йомшак искән җилләр
Яфракларны селкеп шаулата,
Җырчы кошлар
Агач арасыннан
Сузып җырлап урман яңгырата.
Без үтәбез
Көн дә шул урманнан,
Сигнал белән бергә җырлашып,
Яңрап кала урман,
Без киткәндә
Алга таба кырлар буйлатып.
Рәт-рәт булып,
Менә бүген дә без
Җырлап үттек урман арасын.
Урман матур,
Таза алмаш өчен,
Тәрбияли һәрбер баласын.

*1937*

*Әхмәт Гыймадов – 1941–1945 еллардагы Ватан сугышында һәлак булган яшь татар язучыларының берсе. Ул 1915 елда Казан шәһәрендә басмаханә эшчесе (хәреф җыючы) гаиләсендә туа. Казанның Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә җиде сыйныф белем алгач, фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбенә укырга керә һәм аны тәмамлаганнан соң Казан заводларында слесарь булып эшли. Шул елларда ул производство, эшчеләр хезмәтен яктырткан хикәя-язмалары, хәбәр-мәкаләләре белән көндәлек матбугатта катнаша башлый. 1937 елда яшь хәбәрчене үзе эшләгән заводның күптиражлы газетасына редактор итеп куялар. Хикәяләрендә ул әдәби чаралар белән яңа тормыш төзүче эшче образларын, аларның хезмәт энтузиазмын гәүдәләндерергә омтыла. Бер үк вакытта ул балалар әдәбиятында да көчен сынап карый, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында героик-романтик рухтагы хикәяләрен («Пионер Владик», «Мигуэль» һ.б.) бастыра. Аның революциягә кадәрге Казан һөнәрчеләре тормышы турында «Юллар» исемле повесть язарга керешүе дә мәгълүм.*

*1943 елның башында Әхмәт Гыймадов фронтка җибәрелә һәм шул ук елның октябрь аенда сугыш кырында һәлак була. Язучының зур булмаган әдәби иҗатыннан бер әсәр – узган гасырның 30нчы елларында Испаниядә барган гражданнар сугышы хәлләрен СССРда сыену урыны тапкан испан баласы авызыннан сөйләтү рәвешендә 1938 елда язылган «Мигуэль» дигән хикәя С.Шакир төзеп чыгарган «Алар сафта» (1961, 1985) исемле җыентыкка кертелгән. Ә.Гыймадов турында өстәмә мәгълүматларны һәм бәяләмәләрне шулай ук Ә.Синегуловның «Туплар һәм музалар» (1969), З.Мәҗитовның «Сугышчан поэзия» (1975) дигән китапларыннан да табарга мөмкин.*

## МИГУЭЛЬ

Диңгезнең биек ярында тау өстенә салынган зур таш йорт күренә. Диңгезгә карап торган террасаны кипарис, пальма, мандарин агачларының яшеллеге урап алган. Йортның мәрмәр колонналары, ак таш стеналары кузнең нурын алырлык булып җемелдиләр. Тирә-якның маягы шикелле булып тора бу йорт. Аның зәңгәр күккә таба сузылган башнясы өстендә кызыл флаг җилферди. Бу йортка балалар санаторие урнашкан.

Террасага ял итүче балалар төркеме җыйналган; алар зур кызыксыну белән диңгез өстен күзәтәләр.

Кара диңгез өсте эреле-ваклы көзге кисәкләре шикелле ялтырый. Көнбатышның горизонт сызыгына кереп китәргә торган кояштан нур көлтәсе сибелә. Алар алсу тасма булып диңгез өстенә сузылалар.

Өстенә кыска җиңле ак күлмәк кигән түгәрәк йөзле үзбәк кызы белән кыйгач кара кашлы әрмән пионеры шул матурлыкны сокланып карыйлар иде.

Залдан террасага чыга торган ишек ачылды. Аннан шаулый-шаулый тагын бер төркем балалар килеп чыкты. Балалар өстенә матроска кигән, коңгырт бөдрә чәчле, кояшта янып бронза төсенә кергән йөзле испан малае Мигуэль тирәсендә кайнашалар. Аларның Мигуэльдән Испаниядәге вакыйгалар турында сөйләтәселәре килә. Мигуэль янында аның белән бергә СССРга килгән башка испан балалары да күп. Алар да аның сөйләвен сорыйлар. Террасадан торып диңгез өстен күзәтүче балалар да Мигуэльне Испания турында сөйләргә кыстаучыларга кушылдылар.

Мигуэль Росасның СССРда тора башлаганына бер ел инде. Ул Испаниядән III Интернационал исемендәге үрнәк балалар йортына килеп төште. Бу санаторийда аның икенче кат ял итүе иде. Ул башка испан балаларына караганда рус телен яхшырак белә. Күп вакыт, куллары белән тезен кочып, зур кара күзләрен кайда булса да төби дә уйланып утыра. Мондый вакытларда аның күңеле еракка – фашистлар золымы, капиталистлар изүе астында бөлгенлеккә төшерелгән испан хезмәт ияләре янына китә. Ул аларның бер сынык каткан икмәк өчен тилмереп йөргән төссез, ябык, хәлсез балаларын күз алдына китерә дә үзенә:

– Менә бөтен җирдә Совет илендәге шикелле мул, бәхетле тормыш булса иде! – ди. Һәм бөтен дөнья пролетариаты революциясе өчен көрәшкәндә үзенең зур буласын уйлап горурлана: – Без бирербез ерткыч фашистларның кирәкләрен! – дип куя.

Ул хәзер дә, санаторийдагы балалар үзенең сөйләвен үтенгәч тә, Испаниядә булган канлы көрәш кырларын күз алдына китерде. Аның йөзен уйчанлык басты, ләкин ул уйчанлык бу юлы тиз югалды. Аның үзен һәм иптәшләрен кадерләп тәрбияләүче Советлар иленә хезмәт итәсе килде. Үзенең ялгыз булмавын, СССРда яшәвен хәтерләп, күбәләк шикелле очынды, шатланды ул. Һәм бераздан тирә-ягын урап алган иптәшләренә карады.

Балалар Мигуэльнең сөйләвен тыңларга әзерләнделәр. Аларның һәркайсы малай тирәсенәрәк урнашырга тырышты. Мигуэль, иптәшләрен бераз шаяртып алырга теләп, диваннан торды да чыбыктан үрелгән дуга табанлы креслога күчеп утырды. Балалар, кинәт дулкынланган диңгез өсте шикелле кайнашып, җанлы кыршау ясап, Мигуэльне әйләндереп алдылар.

Мигуэль креслода тирбәлә-тирбәлә сөйли башлады:

– Кара болытлар айсыз төндә күк йөзенә яктылык шәүләсе сибүче йолдызларны да капладылар. Бискайя провинциясенең көнчыгыш ягы куркыныч караңгылыкка уралды.

Май аеның болытлы иртәсе иде. Мин каты шартлау һәм челпәрәмә килеп ватылган тәрәзә пыялалары, шүрлектән коелган савыт-сабалар тавышына куркып йокымнан уяндым. Бу вакытта өйдәгеләрнең барысы да аяк өстендә иде инде. Бабай кулына кыска көпшәле мылтык тоткан һәм калтыранган куллары белән аңа патрон тутыра. Дәү апам белән кече апам Амалия түрдәге зур кәрзин янында кабаланалар: аларның берсе кәрзиннән күлмәкләрне алып идәнгә ташлый, ә икенчесе аларны кулына ала да озын тасма сыман итеп телә; аларның ашыкканлыклары күренеп тора. Сүзләреннән мин апаларымның яралылар өчен бинт әзерләгәнлекләрен аңладым. Амалия минут саен: «Тизрәк бул, җаным», – ди иде.

Әнием кечкенә энем Адроданы күкрәгенә кыскан да бүлмәнең бер башыннан икенче башына туктаусыз йөреп тора. Адрода йөрәк өзгеч тавыш белән елый. Ул каты курыккан иде.

Мин йокы исереклегеннән тиз айныдым һәм безнең Дуранго шәһәрен фашистларның күп мәртәбәләр һавадан бомбага тотуларын, берничә атнадан бирле шәһәр тирәсендә каты сугышлар баруын хәтерләдем. Мин шунда ук урынымнан сикереп тордым да барып бабайны кочакладым.

– Бабай, кая барасың? – дип сорадым мин аңардан.

Ул, кулын алга таба сузып, гайрәтле тавыш белән:

– Фашист этләре, кара күлмәклеләр безнең актык сыныкларны тартып алырга килләр. Мин, улым,

аларга каршы көрәшергә барам, – диде.

Ул минем маңгаемнан үбәргә дип иелде. Мин аның көмешләнгән чәчен сыйпадым.

– Йә, хуш, улым, – диде ул, аркамнан сыйпый-сыйпый, һәм чыгып китте.

Бабай киткәч, мин әбием янына килдем. Аның эчкә баткан тонык кара күзләре яшькә чыланган иде.

– Җир упса иде шул кара кулмәклеләрне, – ди иде ул ике сүзнең берендә.

Аның яшьле күзләренә карап мин дә чак кына елап җибәрмәдем. Тик үземнең ир бала булуымны хәтерләп, түздем, иренемне тешләрем белән кыстым да:

– Елама, әби, елама, – дидем.

Әби күз яшенә йотлыга-йотлыга сөйләп китте:

– Ничек еламаска, семьябызның соңгы ир кешесе – бабаң да китте бит. Хәзер ничек яшәрбез инде?

Ничек кирәк алай мин аның елавын туктатырга теләдем. Ләкин аның йөрәгендәге тирән сагышларны кузгаткан нәфрәтле яшь чишмәсен коры сүзләр, иркәләүләр белән генә тыеп булмауны мин аңламаганмын. Ул елый-елый өй эчендәге әйберләрне йорт алдында торган җигүле атка ташуында дәвам итте.

Мин нишләргә белми торганда, яныма кече апам Амалия килеп чүгәләде. Ул, Кызыл Хач билгесе бәйләгән кулын миңа сузып:

– Йә, хуш, Мигуэль, мин дә китәм, – диде. Һәм сыңар кулы белән мине күкрәгенә кысып, маңгаемнан, бит алмаларымнан кат-кат үпте. Соңыннан ул әни каршысына барып басты да нидер әйтергә теләде. Шунда аның кара күзләре әнинең кайгылы йөзенә төбәлде, аның йөрәге әрнеп китте, ул:

– Кайгырма, әнием, хуш, – диде дә батыр адымнар белән ишеккә таба атлады. Бераздан ватык тәрәзәләр аша Амалия сөеп көйләгән җыр тавышы ишетелде.

Ул арада дәү апам да бер бәйләм киң тасма кисәкләре алып урамга ашыкты.

Мин, кая барырга белми, идән уртасында катып калдым.

Урамнан пулемет тыкылдаган, мылтык атылган тавышлар өзлексез ишетелә. Бомбага тоту көчәйгәннән-көчәя бара. Урамнарның буеннан-буена яшен вакытындагы кебек күзне чагылдыргыч утлы сызыклар чагылып үтә. Сирәк-сирәк кенә снарядлар шартлый. Ул, җир белән иркен күктә йөзгән болытларны кушарга теләгән шикелле, төшкән урынындагы бөтен нәрсәне һавага чөя. Югарыга күтәрелгән утлы чаткылар арасында таш, туфрак, агач кисәкләре күзгә чалына. Куркыныч. Ватык тәрәзәләрдән кергән төтен катыш дары исе сулышны кыса. Ул да булмый, дошман өстенә арысланнар шикелле ташланучы халык армиясе сугышчыларының көчле тавышлары яңгырый. Бу тавышлардан фашистларга, интервентларга каршы көчле нәфрәт аңкый.

«Аделанде1» тавышлары мине җанландырды. Мин дә, баррикадаларга ташланырга теләп, ишеккә таба йөгердем. Ләкин әбием минем юлыма төште.

– Кая барасың? – диде ул. – Миңа әйберләрне чыгарышырга булышыр идең.

Нәкъ шул вакытны ишектән әтием күренде. Мин аны өч айдан бирле күргәнем юк иде инде. Ул мин йокыдан торганчы өйдә булган, күрәсең, аңа әби дә, әни дә гаҗәпсенүле караш ташламады, тик мин генә әтинең кочагына атылдым. Ул мине сөйде, иркәләде. Аннан соң кесәсеннән апельсин алып бирде. Әти белән әни бераз сөйләшеп тордылар.

Әти зур кәрзинне чыгарырга булышу өчен генә өйгә кергән икән. Ул озак тормады, аның «Тизрәк булыгыз, безнең патроннарыбыз бетте, чигенәбез» дигән сүзләре әле дә минем колак төбемдә яңгырый. Бик аянычлы итеп әйткән иде ул шул сүзләрне.

Минем күңелем нәрсәдер сизгән шикелле булды. Мин як-ягыма каранып алдым да әти артыннан урамга чыктым. Үзебез торган йорттан бераз җир киткәч, күзләрем бомбовозга төбәлделәр. Кинәт ул безнең өй турында бомбалар яудыра башлады. Берничә минуттан соң фашист козгынын безнекеләр кадалдырып төшерделәр төшерүен, ләкин...

Мигуэль сөйләвеннән туктады. Аның авызыннан чыккан соңгы «ләкин» сүзе башка сүзләре шикелле көчле яңгырамады. Ул сүз аның йөзенә кинәт бәреп чыккан сагышы белән бергә йотылган шикелле булды. Бу вакыт террасада бермә-бер арткан, Мигуэльнең сөйләгәнен тыңлаучы балалар авызларын ярым ачып аңа карап торалар иде. Соң гына килгәнгә, утырырга урын калмаганлыктан, барьерга атланган зәңгәр күзле рус пионеры, түземсезләнеп:

– Йә, йә, шуннан? Әниләрең нишләде? – дип сорады Мигуэльдән.

Мигуэль җавап бирмәде. Аның йөзенә карарга да куркыныч. Бәлкем, ул үкси-үкси елаган да булыр иде, ләкин иптәшләре аның күңелен күтәрделәр. Испан балалары аның Советлар илендә яшәвен исенә төшерделәр. Шуннан соң малайның күңеле яңадан күтәрелеп китте. Ул сөйләвен дәвам иттерде:

– Ләкин бу вакыт без тора торган йорт җир белән тигезләнгән иде инде. Мин: «Әни!.. Әби!.. Адрода!..» – дип кычкыра-кычкыра йортыбыз янына кире чаптым һәм, йорт урнашкан урынны чама белән билгеләп, әниләрне эзләргә керештем. Башым әйләнә, кулларымны җәеп, кемнедер кочакларга теләгән шикелле барам. Күзләрем бернәрсә дә күрми, чөнки алар яшь белән тулган. Тыным кысыла иде. Кинәт мин нәрсәгәдер абынып егылдым. Шуннан теземә тезләнеп, кулым белән яшем сөрттем.

Өстемә кинәт бозлы су коелган шикелле булды. Калтырандым, елый да алмас булдым. Минем каршымда теткәләнгән гәүдә ята иде. Гәүдәнең йөзеннән бернәрсә дә танырлык түгел. Кара чәч кан белән аралашкан. Бары кием-салымнарыннан, ничектер гәүдәдән аерылып бетмәгән аяк кисәкләреннән генә мин аны таныдым. Ул минем әнием иде. Мин һушымнан язып бик озак шунда аунап ятканмын. Кояш төшлеккә авышкач, ява башлаган яңгыр мине тәмам чылаткач, йөрәккә үткән салкын мине аңыма кайтарды. Әниемнең канлы иткә әйләнгән гәүдәсе янында мин озак утырдым... Аны ташлап китәсем килмәде. Мин, аның белән берни дә эшли алмаслык кечкенә булуыма көенеп, әбиемне эзләргә киттем.

Ләкин аның гәүдәсенең кисәкләрен дә таба алмадым. Шуннан, хәсрәт белән тулы башымны түбән иеп, билгесез юнәлеш белән урам буенча атладым...

Бу вакыт шәһәрдә атыш тавышлары сирәгәйгән иде инде. Минем күзләрем югары урам чатыннан килеп чыккан атлылар төркеменә төште. Төркемнең алдыннан ике немец офицеры белән бер итальян фашисты килә. Алар миннән 9–10 адымнар гына ераклыкта җыелып торган иптәшләрем өстенә кылычлар белән ташландылар.

Мин, аларның миңа да тиюләреннән куркып, ташландык йортларның берсенә чаптым, һәм соңыннан шул йортның чормасына мендем дә ерактан урамга карадым. Мин иң элек теге балаларның туракланып ташланган гәүдәләрен күрдем.

Шәһәргә басып кергән канечкеч фашистларның саны арткannan-арта барды. Алар ач бүре шикелле бер йорттан икенче йортка йөгерәләр. Аларның кайсылары кергән йортларыннан мендәр, одеял, кайсылары төрле киемнәр, кыйммәтле җиһазлар сөйрәп чыгаралар иде.

Менә мин яткан чормага каршы яктагы йортның капка төбенә бер төркем фашистлар килеп туктады. Ул йортта итекче Хосе тора. Ул күзгә күренерлек зур бай түгел. Шулай да яхшы тормышлы. Хосе хөкүмәт белән фашистлар арасында сугыш башланганнан бирле бер якка да катнашмаучыларның берсе иде.

– Безнең өчен барыбер, – ди торган иде ул.

Ә менә бүген фашистлар аның мастерскоен ватып керделәр. Йорт эчендәге әйберләрен таладылар. Соңыннан Хосеның буйга җиткән ике кызын, ялынуларына, аһ-зарларына карамастан, ташландык йортларның берсенә сөйрәделәр. Аларның йөрәк өзгеч ачы тавышлары, елаулары, кемнәндер ярдәм сораган авазлары, ә соңрак дәһшәтле тавыш белән гырылдаулары минем чәчләремне үрә торгызды. Йөрәгем чемердәде. Варварларның гаепсез хатын-кызларны, балаларны болай мәсхәрәләвенә чыдый алмый:

– Этләр! Бандитлар! – дип кычкырып җибәрдем. Шуннан соң мин үзем белән ни булганын да белмим.

Мин бары тик бер-бер артлы ярылган снаряд тавышына уянып киттем. Тышта кич якынлашып килә иде инде. Тирә-ягым ярым караңгы. Эчем борып-борып авырта. Ашыйсым килә башлады. Тамак та кипкән, эчәсе килә.

«Әтиләр кайда икән? Алар шәһәргә кире һөҗүм итмиләр микән?» дигән фикер белән әлеге ярыктан тагы урамга карадым.

Бу вакытта урамнан зур-зур броневикларга, автомобильләргә төялгән, баштанаяк коралланган герман, итальян интервентлары һәм марокколылар шәһәргә керәләр иде.

Шәһәр бераз тынычланган шикелле булды. Мин чормадан төштем дә Хосеның фашистлар газаплаган кызларын эзләргә тотындым һәм күршедәге йортның ишегалдында ул кызларны эзләп таптым. Аларның берсе сарай астында, икенчесе йортка керә торган баскыч янында ята иде. Аларның авызларына чүпрәк тутырганнар. Теш казналарын көчләп каерганга, авыз читләре ертылган. Кеше чыдый алмаслык газаплаудан күзләре атылып чыгардай булып зур ачылган һәм калайланган, икесенең дә куллары артка каерып бәйләнгән. Тәннәре нәкъ көл төсле. Шул минутта мин әбием сөйләгән җен-пәриләрне хәтерләдем. Мине курку чолгап алды. Күзләремне кулым белән томалаган хәлдә, алар яныннан урамга ташландым.

Шул көннән башлап мин урам малае булып киттем.

Яңгырлы көн. Мин Дуранго шәһәренең зур базары чатында калтыранып торам. Узган-барганнарга кулларымны сузам да: «Бер сынык икмәк бирсәгезче», – дим.

Кайбер кешеләр, кара күлмәклеләр күрүдән куркыпмы, ялт-йолт итеп як-якларына караналар да кулыма ни булса да төртеп китәләр. Ә кайсылары миңа бөтенләй игътибар итми, кырын карап узалар. Баштарак тамагымны туйдырырлык ризык таба алдым, ә соңга таба бер валчык икмәк күрмәгән көннәрем дә күп булды.

Шулай ачлыктан бөрешеп чат башында утырган киң маңгайлы һәм гаҗәеп калын, куе кара кашлы, башына салам эшләпә, өстенә тузган блуза кигән, култык таякларына таянган бер кеше минем каршыма килеп туктады. Ул миңа исемем белән дәште.

– Мигуэль, әйдә, тиз бул! Минем белән... – диде ул.

Мин ул кешене башта танымадым. Тик аның квартирасына кергәч кенә Амалия янына килеп йөргән комсомолецлар арасында шушы кешенең дә булуын хәтерләдем. Ул хәзер бик нык үзгәргән. Аның

балавыз шикелле саргайган йөзе, арык гәүдәсе фашистлар тарафыннан җәзаланган булуын әйтеп тора. Ә теге чакта ул таза, ять-яшь егет иде.

Фашистлар җәзалаганнан соң гариплəнгән хәлендә дә Рафаэльнең комсомол исеменә тап төшермәве, халык ирке өчен көрәшүе миндә аңа карата чын мәхәббәт уятты. Бу кеше дә, апам да – икесе дә комсомол эшчеләре иде. Ул апамны белә торгандыр, бәлки, ул минем әтием турында да берәр нәрсә әйтер дип уйлап алдым мин һәм:

– Рафаэль абый, әйтегез әле, минем әтием кайда? – дип сорадым.

Ул минем соравыма җавап бирергә ашыкмады. Башта минем өстемдәге ертылып беткән күлмәкләрне салдырды, миңа юынырга булышты. Соңыннан яңа күлмәк кидертте, кара сукно чалбар бирде. Ул да булмады, Рафаэль абыйның сеңлесе Мария кулына ике пар балалар башмагы белән носкилар күтәреп кайтып керде. Ул башмакларның бер парын һәм носкиларны миңа бирде. Минем элек шулай матур киенгәнем юк иде. Әле артыма, әле яныма әйләнеп карыйм, матур ашыйсы килү дә онытыла язды, шатлык эчкә сыймый иде. Шул вакыт: «Бу әйберләр кемнеке?» – дип сорыйсым килде минем.

Рафаэль абый миңа туганнарча матур караш ташлап елмайды да:

– Бу киемнәрне безгә Советлар иленнән җибәргәннәр, Мигуэль, кара, алар безне ничек кайгырталар, – диде, һәм ул киемнәрнең Дуранго шәһәрен фашистлар басып алыр алдыннан гына бирегә җибәрелүен, бу көнгә кадәр аларны яшергән урыныннан чыгарырга мөмкинлек булмавын, шулай ук шәһәрдә калган балаларга да берничек тә ярдәм итә алмаганлыкларын аңлатты.

Күп тә үтмәде, Рафаэль абый минем белән Марияне ашарга дәште. Өчәүләп тәмле аш ашаганда гына ул миңа әтием турында сөйләде:

– Ул югалмас. Арнольд белән мин сезне очраштырырмын әле. Тик син беркемгә дә берни дә сөйләмә, – диде. Соңыннан: – Ә Амалия турында ни дә әйтә алмыйм, – дип өстәде.

Мин нигәдер күпне белергә, сорашырга яратам. Аш янында Мариянең әнисе күренмәгәч, аның турында да сораштым.

Рафаэль абый бер сеңлесенә, бер миңа уңайсызланып карады да, көрсенеп:

– Аның инде унбиш көннән бирле өйгә кайтканы юк. Көн саен диярлек эзлим мин аны, тик таба алмыйм. Әллә фашистлар берәр нәрсә эшләтеп ташладылар инде үзен, – диде.

Мариянең күзләреннән энҗе бөртеге кебек яшь тамчысы тәгәрәде. Ул, күзен куллары белән каплап:

– Әнием, күз нурым, әгәр алар сине үтергән булсалар, мин синсез ничек яшәрмен? – дип, елый-елый, анасының стенага эленгән рәсемен барып кулына алды. Ул карточканы бер кулы белән яңагына кысты, икенче кулы белән аны акрын-акрын гына иркәләгән күк сыйпады.

Мин Рафаэль абыйдан Мариянең әнисе турында соравыма үкендем. Үземнең дә күңел тулды. Бәлки, мин дә елап җибәргән булыр идем, тик Рафаэль абый:

– Елама, сеңлем, әнә Мигуэльдән үрнәк ал, – дип әйтергә өлгерде.

Мин батыраеп киттем һәм Рафаэль абыйга Марияне юатырга булыша башладым.

Икенче бер вакытта, Мария юк чагында, Рафаэль абый миңа Мариянең әнисе Кормель Соловарраның фашистлар тарафыннан күптән үтерелүен әйтте.

Мин Рафаэль абыйның сөйләгәннәреннән кабахәт фашистларның, Дурангоны басып алганнан соң, Мариянең әнисе Кормель Соловарраның лабораториясенә кереп, ничә еллар буе эшләгән тәҗрибәләрен ватып-җимереп чыгуларын һәм соңыннан аны газаплап үтерүләрен аңладым...

Мигуэль сөйләвеннән туктады да, үзе утырган креслога таянып торган иптәшенең иңбашына төртеп:

– Әсгать, утны кабыз әле. Мин сезне күрмим. Бәлки, сез йоклый торгансыздыр, – дип куйды.

Мигуэльнең сөйләгәннәрен бирелеп тыңлый торгач, хәтта үзләрен аның белән бергә Испаниядә йөрүче итеп хис итә башлаган балалар, фикер юнәлешләрен рәтләү өчен, берничә секундка гына тынып тордылар да бердән гөрләделәр:

– Ник тыңламаска, әйдә сөйлә, сөйлә!

Кайсыдыр электр лампочкасының включателен борып җибәрде. Караңгыланып килгән терраса эченә аксыл яктылык сибелде. Иптәшләренең үзен тыңлавына ышанган Мигуэль дәвам итте:

– Әнә шул көннән бирле мин Рафаэль абыйда тора башладым. Мария белән дә аерылмас дуслар булып киттек.

Рафаэль абый өйгә бик сирәк йә биш көнгә бер генә, анда да кичләрен генә кайткалап киткәли торган иде. Ул өйгә кайткан араларда безгә шәһәрдәге фашистларның кабахәтлекләре турында сөйли торган иде.

Шулай көннәрнең берендә Рафаэль абый өйгә кайтты да мине бер читкә дәшеп алды. Һәм, кулыма язулы кәгазь тоттырып:

– Мә, шушы кәгазьне әтиең янына еш килеп йөри торган Бартельгә илтеп тапшыр! – диде. – Тик кара, андый-мондый эш булса, һичкемгә берни әйтәсе булма. Язуны юк ит!

Мин, үземнең шундый зур эшкә яравыма шатланып, урамга ташландым.

Урамнар бүген гадәттәгегә караганда да тын. Шәһәр халкы бар да өйләренә кереп бикләнгән. Алар тавышсыз-тынсыз гына нәрсәгәдер әзерләнәләр кебек. Кайбер кешеләр, йорт алдына чыгып, ары-бире карап алалар да тагын өйләренә кереп югалалар. Фашист дружинниклары үзләренең вәхшәтлекләренең, ерткычлыкларының тантанасын итәләр. Алар кабакларга җыелганнар. Эчәләр. Анасын суйган бозау тавышлары чыгарып акыралар... Кабакларга якынрак урнашкан кешеләр эчләреннән генә: «Эчегез, эчегез, актык эчүләрегез булыр», – дигән кебек, тәрәзәдән урамга серле караш ташлыйлар.

Безнең йорт белән Бартель өе арасындагы ерак юлны мин озак йөрдем. Өстемә йөкләнелгән эшне үтәп өйгә кайтканда, капка төбендә күзәтчелектә торган Мария миңа:

– Җыелыш бара, бик шаулап йөрмә! – диде.

Мин аяк очларыма гына басып ян бүлмәгә кердем. Рафаэль абыйны дәшеп, аңа үзем күргәннәрне сөйләдем дә тәрәзә төбенә килеп утырдым.

Күп тә үтмәде, җыелышта катнашучыларның берсе, комсомолец Педро, капкадан атылып чыкты да шәһәр читенә таба йөгерде. Аның шәһәрдән берничә километр ераклыкта урнашкан зур партизаннар отрядының һөҗүмгә әзерлеген белү өчен җибәрелгән булуын мин соңыннан гына белдем.

Мин кайтканга байтак вакыт узгач, өй яныннан Бартель узып китте. Күп тә үтмәде, якында гына гырылдаган тавыш ишетелде. Мин ирекле-ирексез башымны ачык тәрәзәдән урамга суздым. Минем тәнем эсселе-суыклы булып китте. Бартель Марияне капка баганасына сөягән дә, ач бүре шикелле, тырнакларын аның бугазына батырганнан-батыра иде... Мин, үземне-үзем белешмичә:

– Ал пычрак кулыңны! Эт! – дип кычкырып җибәрдем.

Минем тавышны ишетеп Бартель каушады булса кирәк. Ул Мариянең бугазыннан кулын кинәт тартып алды. Ләкин соң иде инде. Мария чалгы белән киселгән зәңгәр чәчәк кебек егылды. Бартель аңа беренче ярдәм күрсәтергә җыенган кеше шикелле кылана башлады. Ул, кулы белән ишарә ясап, шыпырт кына:

– Монда төш әле, су алып чык... – дип эндәште.

Мин башта бу хәлгә ничек дип тә карый алмадым.

Тик башымны тәрәзәдән тартып алганда бер төркем кара күлмәклеләрнең монда таба килүен күргәч кенә, вакыйганың нигезенә төшендем.

«Кара, хыянәтчене, фашист олтанын ялаучыны, Марияне буып үтерүе җитмәгән, мине дә...» дигән фикер яшен тизлегендә минем башымнан узды. Шунда ук мин Рафаэль абыйлар утырган бүлмәгә атылып кердем. Беренче секундта бераздан туачак куркынычлы вакыйганы күз алдына китерүдән минем күз кабакларым җемелдәделәр. Икенче секундта мин ишеккә каршы якка урнашкан кечкенә көзгедә үземнең гадәттән тыш куркыныч төс алган йөземне күрдем. Хәзер ул бер кыза, бер боз шикелле салкыная иде. Үз-үземне белешмәстән мин канатын җәйгән лачын шикелле үземә таба килгән озын буйлы, түгәрәк кара сакаллы бер коммунистның биленнән кочып алдым һәм куркудан, Марияне кызганудан елый башладым.

Ул, аркамнан сыйпый-сыйпый:

– Нигә елыйсың? – дип әйтеп бетерергә өлгермәде, мин Бартельнең фашистлар яклы булуын, әле генә аның Марияне буып үтерүен, фашистлар төркеменең өйгә таба килүен әйттем. Өстәл тирәсенә урнашкан кешеләр кинәт аякларына бастылар. Рафаэль абыйның туганы Базилло, Мариянең үтерелүе турындагы сүзне ишетү белән, йорт алдына ташланды. Озын буйлы, бөдрә кара чәчле, базык таза гәүдәле Больманте өстәлдәге листовкаларны җыеп кесәсенә тыкты.

Мин моннан берничә көн генә элек ул листовкаларны таратып йөргәнне хәтерләдем. Ул листовкалар фашистлар тылындагы халыкны варварларга каршы көрәшкә чакыра иде.

Шул арада тышта шартлау тавышы ишетелде. Шунда ук кара түгәрәк сакаллы, озын буйлы кеше ишегалды ягына караган тәрәзәгә яшен тизлегендә ташланды.

– Базиллоны үтерделәр! – диде ул, тәрәзә янында басып торган хәлдә, ачу катыш нәфрәтле тавыш белән.

– Их, кабахәт шпион Бартель, эт токымы!!! – диде кайсыдыр.

Бу вакыт Больманте тыштагы ишекләрне бикләр өчен бүлмәдән чыгып киткән иде инде. Базиллоның үтерелү хәбәрен ишетү белән, җансыз әйбер шикелле катып калган җиремнән калтыранып китеп, мин дә тәрәзә янына килдем. Базилло баскыч төбендә чалкан ята, күгелҗемләнеп калган тәнле Мария аның уң беләгенә йөзтүбән капланган. Кайсыдыр:

– Аны атканнар, – диде.

Базиллоның аркасына аткан булсалар кирәк. Ул газапланып җиргә ауган да чалкан төшкән. Аның күкрәк сөякләре чәрдәкләнгән, тәнендәге ит кисәкләре умырылып чыккан. Мин ачынып Базилло өстенә карап торганда, Больмантеның көчле тавышы яңгырады:

– Бирелергә ярамый... Безне халык көтә... Тезләнеп яшәгәнче, аягүрә торып үлү яхшырак!!! – диде ул. – Бәлки, Педро фашистларга эләкмәгәндер.

Рафаэль абый бик ерактан йөгереп килгән кебек тыны беткән, әлсерәгән кыяфәт белән миңа карады да:

– Кара күлмәклеләр кайсы яктан килделәр? – дип сорады.

– Педро киткән яктан килделәр, – дидем мин.

Озынча борынлы, җәрәхәтле башын марля белән бәйләгән Астурия эшчесе сакалын кашый-кашый стенадагы кечкенә түгәрәк тәрәзәгә карап торган җиреннән чак кына ишетелерлек тавыш белән:

– Һавадагы торнага ышанып булмый! – диде һәм, кинәт җанланып, батыр ир тавышы белән:– Әйтегез әле, менә бу түгәрәк тәрәзә...

Ул кулларын тәрәзәгә сузганда, мин үземнең шул тәрәзәдән кереп Мариягә ишек ачканымны хәтерләдем һәм шул секундта ук:

– Мин тәрәзәдән сыя алам бит, – дидем шатлыклы тавыш белән.

Ишекләрне бикләп кергәннән соң, ишегалдына караган тәрәзә янына сыенып, тышкы ишек янына килгән фашистларга отпор бирергә әзерләнгән Больманте, тәрәзәдән күзләрен алмый гына:

– Мигуэль, син ул тәрәзәдән чыгып котыла алырсың! Бәлки, безне дә коткарырсың, – диде.

Мин, гаҗәпсенеп:

– Ничек?! – дип кычкырып җибәрдем.

Түгәрәк кара сакаллы, озын буйлы кеше белән берничә яшь егет мине урап алдылар да бүлмә уртасындагы өстәл янына алып килделәр һәм кыска-кыска гына җөмләләр белән миңа партизаннар отряды урнашкан урынны әйттеләр.

Мин кечкенә тәрәзәдән ишегалдына, аннан койма аша тыкрыкка төштем дә бар хәлемә йөгерергә тотындым. Артымнан бер-бер артлы аткан, сүгенгән тавышлар ишетелеп калды.

Менә эшчеләр бистәсенең кара урамнары: җимерек, кыегайган, кыйшайган йортлар... Кайбер урыннарда снаряд төшеп шартлаудан казылган зур воронкалар караңгыда төпсез упкын шикелле булып күзгә чалыналар. Әнә әле моннан берничә генә көн элек фашистлар кулы белән җимерелгән шахта. Күпме аталар, аналар калды бу шахта астында. Бу шахта тирәсендә акылдан язып елаучыларның күз яшен җыйсаң, бер күл булыр иде.

Мин йөгерәм. Урамдагы коточкыч вакыйгаларны искә төшерә торган урыннар артта калды. Менә мин анда-монда үсеп утырган агачлыклар буена җиттем. Бу урында әле күптән түгел генә куе яшеллеккә уралган ял паркы иде.

– Бу ерткычлар агачларны да корыталар, – дип куйдым мин үз-үземә.

Менә мин патрульдә торган үзебезнең кеше янына якынайдым. Мин аңа өйдәгеләр биргән язуны калдырдым. Анда аңа телеграф, телефон чыбыкларын кисү эшен башкарырга әйтелгән иде.

Аның яныннан киткәч, шактый вакыт түш белән шуышып барганнан соң, мин аякларыма бастым һәм тагы бар хәлемә йөгерергә тотындым. Тау аралыгына җитеп килә идем, кинәт:

– Тукта, кем килә?! – дигән тавыш яңгырады.

Мин калтыранып киттем. Ни дип тә әйтергә белмәдем. Хәрәкәтсез калдым. Ә икенче секундта үз-үземне тыя алмый алга атладым. Капкынга эләкмәгәем, партизаннар отрядына җитү өчен мин бу тау аралыгын узарга тиеш дигән уй башымнан яшен тизлегендә узды.

– Тукта! – диде ул, кабатлап.

Мин туктамадым. Менә безнең арабыз да якын гына калды. Шул вакыт дозорда торган теге кеше миңа өченче мәртәбә:

– Тукта! – дип кычкырды. Ул шунда ук мылтык көпшәсен миңа төбәде.

Мин ирекле-ирексез кулларымны югары күтәрдем дә туктадым. Теге кеше мылтыгын төбәгән хәлдә минем каршыма килеп туктады да:

– Сиңа ни кирәк? – дип сорады.

– Мине начальнигыгызга җибәрегез, – дидем мин аңа туры гына.

Ул, мине икенче кеше кулына тапшырып, штабка озатты. Анысы мине җиргә кертеп эшләнгән чатырларның берсенә урнашкан штабка китерде. Бу вакыт мин партизаннар отрядына эләгүемә тәмам ышанган идем инде.

Штабта мин өстенә регуляр халык армиясе киеме кигән, тәбәнәк буйлы, җыйнак кына мыеклы кешене күрдем һәм аннан:

– Партизаннар отрядының командиры сез буласызмы? – дип сорадым.

Ул җавап бирәсе урында башта үзе миңа сорау бирде:

– Син кайдан? Кем син?

Мин, ашыгуымнан сүзләремнең берсен икенчесенә кушып:

– Дуранго шәһәреннән мин. Арнольд улы Мигуэль.

Кара мыеклы кешенең йөзенә шатлык кабынды. Ул ишек төбендә торган сакчыга:

– Тизрәк комиссар Арнольдны монда чакырырга! – дип боерды.

Мин әтиемне хәтерләдем. Аның портретын күз алдына китереп бастырган хәлдә, дулкынланып:

– Сез кем соң? – дип кабат сорадым.

– Мин – партизаннар отряды командиры, – диде ул.

Мин командирга шәһәрдә булган вакыйгалар турында ашыгып сөйли башладым. Соңыннан кара

сакаллы, озын буйлы коммунист биргән язуны күлмәгемнең җөеннән алып аңа суздым.

Партизаннар белән шәһәрдәге коммунистлар һәм эшчеләрнең алдан ук бәйләнеше булган икән. Командир, мин сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, язуны күзен йөртеп кенә укыды.

– Никадәрле зур көч куелган әзерлекнең һәм кыйммәтле, акыллы кешеләрнең харап булуы бар... Тизрәк, тизрәк, аларга ярдәмгә! – диде ул. Һәм чатырдан йөгереп чыкты. Шунда ук аның калын базык тавышы ишетелде. Ул арада палаткага әтием атылып килеп керде. Мин бу очрашу шатлыгыннан нишләргә дә белми калдым. Әтиемнең дә беренче секундта йөзендә гаҗәпсенүле караш бар иде. Ул мине кулларын җәеп килеп кочты да иң җылы сүзләр белән иркәли башлады.

Мин Амалия турында сорыйм дип авызымны гына ачкан идем, әтием, алдан ук сизгән кеше шикелле:

– Мигуэль, апаң Амалия дә монда бит. Ул – пулеметчы. Әйе, әйе, пулеметчының да нинди генә әле, – диде. Аның соңгы сүзләре көчлерәк, яңгыравыклырак ишетелде.

– Дәү апа? – дидем мин.

Әтием, бер ишеккә таба, бер миңа карап:

– Ул да монда, сиңа аның белән калырга туры килер, – диде. Һәм, кулларымны кысып:– Ярый, улым, без очрашырбыз әле, – диде дә чатырдан чыгып китте.

Бу вакыт партизаннарның барысы да стройга тезелгән иде инде. Күп тә үтмәде, ат тояклары тавышы ишетелде. Ә берничә секундтан, җир өстенә эленеп торган кара пәрдәне ертып, ак ат өстенә атланган яшь егет командиры каршына килеп туктады. Ул, еш-еш сулыш алып:

– Шәһәрдә фашистлар паникага бирелгән. Телефон, телеграф чыбыклары өзелгән. Провинциянең партия комитеты секретаре Больманте безнең тизрәк килеп җитүебезне таләп итә. Алар камалып алынган йорттан эшчеләр һәм шәһәр халкы ярдәме белән бәреп чыкканнар.

Менә әтием белән бергә читтә басып торган командирның бер-бер артлы бирелгән корыч командасы яңгырады.

Мин чатыр буенда басып торам. Каршымнан җанлы соры колонна үтә. Җиңүгә ышанган күңел сөенә. Кулларым үзлегеннән югары күтәреләләр. Менә янымнан гына җигүле тачанка үтә. Тачанкада берничә кеше күренә. Аларның берсе минем апам. Аның башында кызыл яулык. Өстендә, элеккечә, гимнастерка.

– Җиңгәнче сугыш, апам. Комсомол билетыңны пуля ертмасын. Но пассаран![1] Пассаремос![2] – дип кычкырдым мин...

Мигуэль сөйләвеннән туктаганнан соң, тыңлаучыларның күбесе беразга тынып калды. Балаларның барысының да куллары фашизмга нәфрәт белән йомарланган иде. Бу вакыт куе зәңгәр күккә тулган ай күтәрелеп килә иде инде. Кинәт, тынлыкны ярып, ял итүче балаларны кичке ашка дәшеп, санаторийның сигналчысы быргы уйный башлады. Балалар гөрләшеп кузгалдылар.

*1938*

*Татар халкының каһарман улы, герой-шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә.*

*Муса укуын башта авыл мәктәбендә, аннары Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсәдә уку елларында (1914–1917) матур әдәбият белән кызыксына, Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев әсәрләре белән якыннан танышып, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кульязма журналга урнаштыра бара.*

*Большевиклар хакимияткә килгәч, «Хөсәения» мәдрәсәсе Мәгариф комиссариаты карамагындагы урта педагогик белем бирү мәктәбе итеп үзгәртелә, Муса бу мәктәпнең алдынгы укучыларыннан берсе була.*

*1919 елны, Гражданнар сугышы чорында, унөч яшьлек Мусаның «Бәхет» исемле шигыре «Кечкенә Җәлил» имзасы белән фронт газетасында басылып чыга. Шуннан соң аның көрәш рухы белән сугарылган романтик шигырьләре матбугат битләрендә еш күренә башлый.*

*1919–1921 елларда яшь шагыйрь туган авылында һәм Оренбургта яшүсмерләр арасында эшли, бер үк вакытта Оренбург хәрби-сәяси мәктәбендә алты айлык курсларда укый. Аны тәмамлагач, 1922 елның көзендә Казанга килеп, «Татарстан» газетасы идарәсенә эшкә урнаша, ә 1923 елдан Татрабфакта (эшче яшьләрнең югары уку йортларына керү өчен әзерләнү факультеты) укый башлый. Газета-журналларда даими рәвештә шигырьләре, мәкаләләре басыла, 1925 елда исә Казанда «Барабыз» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә.*

*1925–1927 елларда М.Җәлил коммунистик яшьләр оешмасының Орск шәһәр комитетында һәм Оренбург губерна комитетында инструктор булып эшли. 1927 елда аны комсомолның Бөтенсоюз киңәшмәсенә Мәскәүгә делегат итеп җибәрәләр. Киңәшмәдә ул Үзәк Комитетның татар-башкорт бюросына әгъза итеп сайлана һәм шунда эшләү өчен Мәскәүдә калдырыла. Бюроның тапшыруы буенча, М.Җәлил беренче совет татар балалар журналларын («Кечкенә иптәшләр», «Октябрь*

*баласы») оештыруда якыннан катнаша һәм 1932 елның ахырына кадәр («Октябрь баласы», Казанга күчеп, «Пионер каләме» исеме белән чыга башлаганчы) шул журналларның җаваплы мөхәррире булып эшли. Бер үк вакытта (1927–1931) ул Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать бүлегендә укып югары белем ала.*

*1933–1934 елларда М.Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли, газетачы-хәбәрче буларак, күп кенә сәнгать остаханәләрендә, авыл җирләрендә була, халык тормышы белән таныша, Мәскәү төбәгендә яшәүче татарлар белән якыннан аралаша. 1934 елда шагыйрьнең шигырьләре һәм поэмалары тупланган күләмле җыентыгы («Орденлы миллионнар») дөнья күрә, шул ук елны сайланма шигырьләре рус теленә тәрҗемәдә дә («Стихи Мусы Джалиля») аерым китап булып басыла.*

*1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театрына профессиональ кадрлар әзерләү өчен Татар опера студиясе оештырылгач, М.Җәлилне шунда әдәби бүлек мөдире итеп эшкә чакыралар. Шагыйрь үзе өчен яңа бу хезмәткә дәртләнеп тотына, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә опера сәнгатенең специфик үзенчәлекләрен, классик опера һәм балет либреттоларының язылыш хасиятләрен профессионал-белгеч дәрәҗәсендә үзләштереп, студиядә зур оештыру эшләре алып бара: үз тирәсенә татарлардан дистәләрчә шагыйрьләрне һәм композиторларны туплый, аларны сәнгатьнең әлеге катлаулы тармагында иҗат итәргә рухландыра, либреттолар язарга булыша, беренче милли татар операларының тууына турыдан-туры иҗади ярдәмен күрсәтә. 1938 елда студиядә укуларны тәмамлап Казанга кайткач та, ул яңа ачылган Татар опера һәм балет театрының әдәби бүлек җитәкчесе булып эшләвен дәвам иттерә.*

*Композиторлар белән аралашу, музыка дөньясы белән тыгыз бәйләнеш шагыйрьнең үз иҗатында да яңа үзгәрешләр туууга китерә: әсәрләрендә лирик җылылык, музыкальлек, нәфислек, халыкчан табигыйлек хасиятләре көчәя, җыр һәм романслар иҗат итүгә игътибары арта. «Сагыну», «Җир җиләгем», «Җырым булсын бүләгем», «Карашларың» кебек, хисләрнең сафлыгы һәм тирәнлеге белән аерылып торган шигырьләр, композиторлар тарафыннан музыкага салынып, халыкның яраткан җырларына әвереләләр. Әдипнең иҗатында бөтенләй яңа жанр – драматик поэма жанры да барлыкка килә. «Алтынчәч» (1935–1941), «Илдар» (1940) драматик поэмалары нигезендә композитор Нәҗип Җиһанов соңыннан үзенең атаклы операларын иҗат итә. Шагыйрьнең 1934–1941 еллар арасында язган лирик шигырьләре, җырлары, «Алтынчәч» һәм «Хат ташучы» (1938) кебек поэмалары сугышка кадәрге татар поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы буларак тәкъдир ителәләр.*

*Сугыш алдыннан берникадәр вакыт М.Җәлил Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе вазифаларын да башкара. 1939 елны Казан хезмәт ияләре аны шәһәр Советына депутат итеп сайлыйлар. Ватан сугышын ул шушы җаваплы урыннарда хезмәт иткән җәмәгать эшлеклесе һәм популяр җырлары, дистәгә якын шигъри китабы белән халыкка танылган әдип сыйфатында каршылый.*

*1941 елның июлендә аны гаскәри хезмәткә алалар. Башта ул Казан гарнизонында хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге хәрби сәясәтчеләр әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә немецлар якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә күчерелә. 1941 елның декабрендә укуны тәмамлагач, өлкән политрук М.Җәлил Мәскәү аша фронтка озатыла (февраль, 1942). Ул Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган русча «Отвага» («Батырлык») исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби мөхбире итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә, Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, хезмәттәшләре белән бергә чолганышта калып, М.Җәлил каты яраланган хәлендә фашистлар кулына эләгә. Шул көннән аның тоткынлыктагы газаплы һәм каһарманнарча кыюлык белән узган кыска гомер этабы башлана.*

*М.Җәлил һәм җәлилчеләрнең, яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы алып барган каһарманлыклары турында дистәләрчә китаплар – романнар, кыйссалар, драма әсәрләре һәм поэмалар языла, кинофильмнар төшерелә. Иң мөһиме, Җәлил һәм аның көрәштәшләре, ахыргы сулышларына кадәр туган халкына турылыклы калып, тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр.*

*1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә (барысы да татарлар) Дрезден шәһәрендә хөкем оештырыла. Хәрби мәхкәмә аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше алып бару»да гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләре Абдулла Алиш, Гайнан Курмаш, Фуад Сәйфелмөлекев, Фуад Булат, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Баттал, Әхәт Атнашев һәм Гәлләнур Бохараевларның гомерләре өзелә.*

*Тоткынлык шартларында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен М.Җәлилгә вафатыннан соң (1956 елда) «Советлар Союзы Герое» дигән исем бирелә, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты – бөтен дөньяга мәгълүм «Моабит дәфтәрләре» – СССРның ул вакыттагы иң зур бүләге – Ленин премиясенә лаек була.*

*«Моабит дәфтәрләре» – Җәлил шигъриятенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә*

*шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына тирән ышанычы, туган халкына чиксез мәхәббәте гажәеп тәэсирле, эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә. Моабит шигырьләре, Россиядәге барлык милли телләргә тәрҗемә ителүдән тыш, инглиз, француз, испан, алман, гарәп, төрек, кытай, япон, мадьяр, румын, чех һәм башка чит ил халыклары телләрендә дә кат-кат матбугатта басылалар.*

*Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗаттагы батырлыгына багышлап йөзләрчә мәкаләләр, фәнни хезмәтләр, монографияләр язылган, әдәби әсәрләр-шигырьләр, поэмалар, романнар, драмалар һәм сәнгать әсәрләре иҗат ителгән. Әдәби һәм сәнгать әсәрләреннән, мәсәлән, Шәйхи Маннурның «Муса» (1968), Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла болыт» (1977) романнарын, Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» (1956), Риза Ишморатның «Үлмәс җыр» (1955), Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» (1981) драмаларын, Сибгат Хәкимнең «Торыгыз, Мусалар», «Немец дәфтәреннән» исемле шигъри циклларын, Әнвәр Давыдовның «Муса абый» повестен (1964), Нәҗип Җиһановның Әхмәт Фәйзи либреттосына язылган «Җәлил» операсын (1957) һәм башка сәнгатькәрләрнең Муса Җәлил образын сынлы сәнгатьтә тудырган күп кенә әсәрләрне күрсәтеп үтәргә мөмкин. 1966 елда Казан Кремле каршындагы мәйданга каһарман шагыйрьгә һәйкәл куела. 1968 елда Муса Җәлил исемендәге Республика яшьләр премиясе булдырыла, 1970 елда Минзәлә шәһәрендә мемориаль музее, Казанда музей-квартирасы ачыла.*

*М.Җәлилнең әдәби мирасы, бигрәк тә тоткынлыкта иҗат иткән шигырьләре бөтендөнья поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы булып тора. Аның әсәрләре кешеләрдә матур, гуманистик тойгылар уята, аларны яшәешнең матурлыгын күрергә, аны кадерле белергә һәм аның өчен көрәшергә чакыра.*

## ӘЙДӘ, ҖЫРЫМ

Җырым, синдә минем гәүдәләнде
Илне сөйгән йөрәк тибешем.
Җырым иде антым:
«Яшәсәм дә,
Үлсәм дә тик туган ил өчен!»
Ал кояшлы бәхет бакчасында
Чәчәк аткан нәфис гөл төсле,
Сугарылып халкым назы белән,
Җимешләнеп җырым җитеште.
Чагылдырды җырым шат илемдә
Данлы, иркен, рәхәт яшәүне.
Чишмә төсле җырым тамчысыннан
Яшь күңелләр үсте, яшәрде...

Килде фашист...
Дуңгыз борны белән
Керде җимереп илем капкасын.
Эшкә җикте
бөтен Европаны
Ваткан, кискән канлы балтасын.
Вакыт җитте...
хәзер ярты юлда
Куеп торып тыныч эшемне,
Багышларга Ватан сугышына
Үземне һәм каләм көчемне.

Аргамагым, әйдә канатлан да
Җил булып оч сугыш кырына.
Җырым утын корыч сөңге итеп
Мин күтәрдем хәзер кулыма.

Каләмемне салдым юл сумкама,
Автоматым тактым аркама.

Фашистларга каршы пуля һәм җыр
Бил каешымда бергә саклана.

Җыр таратса эфир дулкынына
Илнең данлы хезмәт тавышын,
Фашистларның хәзер баш очында
Бомба булып җырым ярылсын!..

Яңгыра, җыр, халык байрагының
Утлы сүзе булып һавада.
Канатландыр җиңү дәрте белән
Йөрәкләрне кырда, калада.

Әйдә, җырым, безгә вакыт җитте
Сугыш кырын айкап үтәргә.
Кара җанын тетеп фашизмның,
Үләксәсен ташлыйк этләргә.

Әйдә, җырым,
батыр җиңү дәртен
Алып керик ялкын эченә.
Мин калмасам җирдә,
син калырсың
Һәйкәл булып үлмәс эшемә.

## КИЧЕР, ИЛЕМ!

Кичер мине, илем, синең бөек
Исемең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмалмадым
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомрем өчен сатмадым.
Волхов шаһит: изге сугыш антын
Соң чиккәчә керсез саkладым.

Мин курыкмадым өстән яңгыр төсле
Яуганда да туплар, ядрәләр,
Каушамадым кан һәм үлек белән
Тулганда да тирә-әйләнәм.

Алда, артта, уңда һәм сулымда
Киселсә дә юлым күкрәгем
Яраланып канга төренсә дә,
Көчсезләнеп, мин яшь түкмәдем.

Мин алдымда күрдем шыр сөяктән
Котылгысыз үлем шәүләсен.
Кил син миңа, үлем, бары гомрем
Коллык белән төгәлләнмәсен!

Мин түгелме дуска хат язучы
«Борчылма, дип, тормыш юлдашым,
Соңгы тамчы каным тамса тамсын,
Тик антыма таплар кунмасын!»

Мин түгелме шигырь утым белән
Ант итүче канлы сугышта?
«Үлемгә, дип, ачы нәфрәт белән
Елмаермын соңгы сулышта».

«Соң чиктә, дип, синең мәхәббәтең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын».

«Тыныч булыр йокы, тормышымны
Бирсәм, диеп, туган ил өчен».
Ышан, илем, шушы ант сугарды
Йөрәгемнең соңгы тибешен!

Язмыш көлде, үлем кагылмыйча
Үтте яннан, минем тирәләп.
Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
Пистолетым итте хыянәт!

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени
Баш ияргә шуннан башкага!

Ышан, илем, шундый бөркет идем
Мин дә соңгы минут килгәндә,
Әзер идем, мәгърур канат җәеп,
Ташланырга ярдан түбәнгә.

Нишлим, сугыш дустым-пистолетым
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
Һәм хурлыклы юлдан атлатты.

Тоткынлыкта хәзер мин... һәр көнне
Көн чыгышын комсыз күзәтәм.
Шигырь булып чыга үч ялкыны
Яраланган лачын йөрәктән.

Көн чыгышы дуслар кулындагы
Байрак булып көн дә кызара.
Белмисез лә, дуслар, тоткын күңел
Күкрәктәге җәрәхәттән түгел,
Канлы үчтән шулай кыза ла!

Тик бер өмит: кара август төне
Илтер мине шунда җитәкләп.
Өстен килер түбән әсирлеккә
Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.

Тик бер өмит, дуслар: сезнең сафта
Табар соңгы көрәш теләген
Яраланган, ләкин тар коллыкка
Баш имәгән керсез йөрәгем.

## ШАГЫЙРЬ

Төн утырып шагыйрь шигырь язды,
Ак кәгазьгә тамды яшьләре.
Тышта давыл иде: бертуктаусыз
Күк күкрәде, яшен яшьнәде.

Җил ишектән кереп өстәлдәге
Кәгазьләрне чәчте, туздырды.
Аннан, чыгып тышка, йөрәк яргыч
Ачы тавыш белән сызгырды.

Тау-тау булып дәрья дулкынланды,
Яшен сукты калын имәнне.
Эчпошыргыч шомлы тынлык басты
Тирәдәге карсак өйләрне.

Тик төн буе шагыйрь бүлмәсендә
Ут балкыды көннән яктырак.
Давылланып, аның йөрәгеннән
Ак кәгазьгә хисләр актылар.

Шагыйрь торды тынып таң алдыннан,
Язганнарын җыйнап яндырды.
Үзе китте чыгып...
Җил басылды,
Давыл тынды, ал таң кабынды.

Төн утырып шагыйрь нәрсә язды?
Нинди хисләр аны ярсытты?
Язганнарын биреп җил иркенә,
Таңда үзе кая ашыкты?

Сез сорагыз аны исәр җилдән,
Яшеннәрдән, дулкын тавыннан
Һәм сорагыз ямьсез төнне куып,
Таң тудырган көчле давылдан.

## БҮРЕЛӘР

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.

Күпме кан, күпме яшь ат ите!
Ялтырый бүренең күзләре.
Бит моны, төн буе атышып,
Тураган кешеләр үзләре.

Бүреләр башлыгы карт бүре,
Исереп кешеләр канына
Йөргәндә, сискәнеп туктады
Бер авыр яралы янына.

Яралы ыңраша, саташа,
Каенга терәгән башкаен.
Кызганып егетне, җил белән
Тибрәнеп сыкрана ак каен.

Кызганып егетне, елыйлар
Миләүшә һәм лалә чәчәге.
Тәгәри үләнгә чык түгел,
Гөлләрнең гөнаһсыз яшьләре.

Карт бүре егетне иснәде,
Аптырап күзенә карады,
Һәм кинәт нидәндер сискәнеп,
Бер читкә тайпылды яралы.

Яралының зәгыйфь сулышы
Бәрелде бүренең борнына.
Юк, бүре тимәде,
сак кына
Борылып юнәлде юлына.

Таң белән килделәр кешеләр,
Күрделәр яралы егетне.
Яртылаш ул тайган исеннән,
Шулай да яшәве өмитле.

Кешеләр егетнең тәненә
Кыздырып шомполлар бастылар.
Туйганчы җәфалап,
соңыннан
Ялгыз ак каенга астылар.

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.

Бүреләр, аһ... ләкин бүреләр
Бу кадәр үк ерткыч түгелләр.

## ЯШЬ АНА

Авыл яна... шәфәкъ нуры булып
Уйный күктә янгын шәүләсе.
Күмерләнгән өйнең тупсасында
Аунап ята ана гәүдәсе.

Алты айлык бала елый-елый
Капшый анын сулган күкрәген!
Ятып суыра, туктап карап тора,
Үксеп уа аннан күзләрен.

Палач үзе кача көн[батышка],
Өстерәлә ватык көймәсе.
Куа аны арттан ядрә булып
Ана каны, бала күз яше.

Күрше кызы Сәрвәр базда иде,
Иштеп чыкты бала тавышын.
Кинәт, куркып, сүзсез катып калды,
Үлгән килеш күреп танышын.

Ул баланы алды кочагына,
Яшен сөртте, үпте, юатты.
Алып кайтты, җылы сөт эчерде,
Кулларына алып уйнатты.

Ул сикертте аны тезләрендә,
Ана дәрте анда кабынды.
Бала көлде, аннан: «Әннә!» – диеп,
Күкрәгенә анын сарылды.

Сәрвәр әле бары унҗидедә,
Тормыш аңа яңа башлана.
Ул елмая ана назы белән,
Ана бәхте белән шатлана.

Сез күрерсез, шундый матур итеп
Ул баланы карар, үстерер.
Тәрәзәдән һәр кич яшь ананың
Дәртле бишек җыры иштелер.

Күңлем оча минем канатланып,
Аның җырын тыңлап узганда.
Рәхмәт сиңа, илем! Шундый йөрәк
Биргән өчен безнең кызларга.

**ДУСКА**

*А. А.*

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип,
Без алмадык сатып гомерне,
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?!

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?!

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне.
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Шатландыра безне көн дә илнең
Бер-бер яңа уңышын ишетү;
Нинди зур көч читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү!

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп,
Ил битемә минем төкерсә?!

Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,
Йөрәк минем моңа үчекмәс.
Кешеме мин илем үги иткәч,
Җирдә миңа эчәр су беткәч?!

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер
Ил гомренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бары аның яктысы.

Батырлык һәм илгә турылыкны
Шушы үлем белән белдерик.
Безнең яшьлек шушы хисләр белән
Данлы иде, көчле иде бит!

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә диеп уйлама!

Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда!

## ИШЕК ТӨБЕНДӘ

Үтеп барам шулай урам буйлап,
Парадныйда күрәм бер бала.
Звонокка үрелә, буе җитми,
Аптырагач, карап уйлана.

Мин балага киләм:
– Әллә, – димен, –
Звонокка буең җитмиме?
– Җитми шул, – ди.
– Кая, үзем басыйм.
Бернеме, – дим, – әллә икеме?

– Биш, – ди. Басам.
Шуннан бала әйтә:
– Абзыкай, син нинди йөрәкле!
Әйдә качыйк хәзер, хуҗа чыкса,
Икебезгә дә бирер кирәкне!

## ҖЫРЛАРЫМ

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онтылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе.
Шигъремдәге чынлык, ут һәм сөю –
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигъремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына

Башны тоткан килеш язына.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

*Шагыйрь Исхак Кадыйр улы Закиров 1911 елның 14 сентябрендә Казан шәһәрендә туа. Мулланур Вахитов исемендәге татар урта мәктәбендә укый. Шунда укыганда, бер төркем укучылар ундүрт яшьлек Исхак Закиров мөхәррирлегендә «Ислам баласы» исемле иҗтимагый-сәяси һәм дини-милли эчтәлектәге кулъязма журнал чыгара башлыйлар. Журнал 1925 елдан 1928 елга кадәр дәвам итеп (барлыгы 37 сан), җирле ОГПУ органнары тарафыннан туктатыла, балигъ яшьтә булмаган укучы авторлары мәктәптән куыла, өлкәннәрдән 12 нче мәчет имам-хатибы Якупов, мөәзин Ш.Ибраһимов, Исхакның әтисе Кадыйр Закиров һәм журналның соңгы балигъ яшьтәге мөхәррире З.Абдуллин хөкемгә тартылалар. Тикшерү барышында журналга «Хакыйкать йолдызы» исемле яшерен оешманың органы булган дигән сәяси мөһер сугыла һәм гаепләнүчеләрнең һәркайсына хөкем карары чыгарылып төрлечә җәза бирелә.*

*Мәктәптән куылган Исхак шулай да урта белем алуга ирешә, аннан соң читтән торып укып Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый. 1934–1941 елларда ул әүвәл Татарстан дәүләт нәшриятында, соңыннан Татарстан Язучылар берлегендә бухгалтер булып эшли.*

*Бөек Ватан сугышы башлану белән, Исхак Закиров фронтка җибәрелә, бик күп канлы бәрелешләрнең шаһиты була, совет гаскәрләре белән бергә Белоруссия җирләрен азат итү сугышларында катнаша, шәхси батырлыклары өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. 1944 елның 14 июлендә Витебск өлкәсенең Гордилово авылы янында барган бәрелешләрнең берсендә Исхак Закиров, ротаны һөҗүмгә күтәреп, дошман ныгытмаларын атакалаганда каһарманнарча һәлак була. Аның соңгы батырлыгы үлеменнән соң II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән билгеләп үтелә.*

*И.Закировның шигырьләре көндәлек матбугатта 1929 елдан басыла башлый. Шагыйрьнең иҗат мирасы зур түгел, ләкин шул кечкенә мирасta да аның поэтик фикер йөртә белүе, тормыш күренешләрен, кеше йөрәгендәге хис-тойгыларны шигъри тел белән әйтеп бирергә омтылуы ачык күренә. Шигырьләренең күпчелеге патриотизм, интернационализм, батырлык темаларына багышланган. Бу темалар шагыйрьнең Ватан сугышы чорында иҗат иткән шигырь һәм очерк язмаларында аеруча калку төс ала. Сугыш елларында аның шигырьләре һәм очерк язмалары «Алга, дошман өстенә!» дигән фронт газетасында һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә басыла.*

*Шагыйрьнең шигъри иҗатыннан аерым үрнәкләр «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) һәм «Утлы еллар поэзиясе» (1972) кебек җыентыкларда урын ала.*

**АНАГА**

Син сөйдең ике балаңны,
Зур өметләргә төреп.
Иркәләдең, төн йокыңнан
Тәмлерәк итеп үбеп.

Үстеләр алар чәчәктәй,
Гөл кебек тормышыңа.
Һәр эшеңдә зур таяныч –
Пар канат булып сиңа.

Инде фашист этләренә
Ут сибә бөркетләрең.
Син дә батырлан, чыгарма
Күз яшең бөртекләрен.

Зур көрәштән бит үзең дә
Читтә калмыйсың, ана.
Улларың белән фронтка
Үз йөрәгең дә бара.

*1941*

**КОМАНДИР**

Бер великан каты баскан кебек
Бергә атлый рота адымын.
Ә командир тыңлый шатлык белән
Ротасының җырлап баруын.

Колоннасы аңа бала кебек,
Аталарча сизгер күңеле,
Дошманнарны кыйнап бер сыналган
Ротасына бәйле гомере.

Белеп тора һәрбер көрәшченең
Ни эшләвен, ничек яшәвен.
Тотып ала, оста аучы кебек,
Моңаюның серле сәбәбен.

Йөрәгендә аның хаклык яна,
Туры әйтә йөзгә гаебен,
Син белмәгән җирдән күрә белә
Вөждан белән эшләү кадерен.

Сугышчылар, бәлки, туганын да
Алай сөя алмый торгандыр,
Кирәк икән, аңа яшәвеңне
Бирә торган якын туган ул.

Бервакытта шулай караңгы төн,
Ярып кердек дошман сафына.
Приклад белән штык ут уйната,
Салкын карга агып кан туңа.

Ә командир шунда өч дошманны
Юлбарыстай кире какканда,
Җилкәсенә аның, ялт-йолт килеп,
Дүртенче бер мылтык ташлана.

Моны күргән өч-дүрт сугышчыдан
Командирга ярдәм сузылды,
Тик дошманның саны күп булганга,
Һич бушатып булмый кулыңны.

Юл арчуны шунда бер армеец
Штык көче белән башкарды,
Шул секундта үз гәүдәсен куеп,
Сөйгән командирын саклады.

Ул армеец шулай һәлак булды...
Ә командир үчле ачудан
Рота белән дошман сафын таптый,
Зур шәһәргә юллар ачыла.

Дәртләндерә аның командасы,
Нинди бәхет аңа иптәшлек.
Бриллиант күк аның вөжданы саф,
Дуслык уты мәңге сүнмәслек.

*1941*

## АВТОМАТЫМ

Автоматым минем, якын дустым,
Аның белән булган чагында,
Мин үземдә сәләт, көч табамын
Фрицларны кырып салырга.

Ул һәрвакыт бергә үзем белән,
Төн үткәрә җылы кочакта,
Ә көндезен кайнар чәй эчкәндә,
Ул да карый янган учакка.

Салкын көндә, яңгыр яуган чакта,
Палаткага бергә сыена,
Минем белән бергә утка керә,
Агым суда бергә коена.

Серләребез килешә, телен аңлыйм.
Иркәләргә үзен иренмим,
Аның уты, көчле тавышы аша
Җиңү тавышын тыңлыйм илемнең.

Автоматым минем, якын дустым,
Ышанычым аңа какшамас,
Һичкайчан ул миңа хыянәт итмәс,
Беркайчан да мине ташламас.

*1944*

*Рахман Ильяс (Габдрахман Вәкил улы Ильясов) 1908 елның 15 мартында элекке Казан губернасының Зөя өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Апас районы) Карамасар авылында туа. Аның әтисе Вәкил абзый, нәсел шәҗәрәсе буенча игенче катлавыннан булса да, бөтен гомерен диярлек Грозный нефть учакларында нефтьче булып уздыра. 1919 елның җәендә ул үзенең гаиләсен дә шунда алып китә. Яшүсмер Габдрахман Грозныйда гомуми белем алуын дәвам иттерә, 1924 елда нефть чыгару вахтасында слесарь өйрәнчеге булып эшли башлый, ә 1925–1927 елларда ФЗӨ мәктәбендә укый. Аны тәмамлагач, яңадан вахтадагы эшенә кайта. 1929 елда аны Грозныйдагы Шәрекъ халыклары клубы идарәсенә рәис итеп билгелиләр.*

*1931 елда Р.Ильяс Казанга килә һәм Татар коммунистлары университетына (ТКУ) укырга керә. Ел ярым укыгач, яңадан Грозныйга кайта һәм 1933 елга кадәр нефтьчеләр өчен чыга торган газета редакциясендә әдәби хезмәткәр һәм хәбәрче булып эшли.*

*1933 елда Р.Ильяс, татар язучылары даирәсенә якынрак булу өчен, бөтенләйгә Казанга кайтып төпләнә. Ул газета редакцияләрендә, Татарстан радиокомитетында әдәби хезмәткәр, мөхәррир, 1934 елда барлыкка килгән Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант, аннары Главлит вәкиле булып эшли. Ватан сугышы башлангач, үзе теләп фронтка китә һәм рота командиры сыйфатында Украина җирләрендә барган канлы бәрелешләрдә катнаша. Харьков шәһәре тирәсендәге шундый бәрелешләрнең берсендә, 1943 елның 23 августында, Рахман Ильяс батырларча һәлак була. Совет хөкүмәте аны вафатыннан соң Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкли.*

*Рахман Ильяс әдәбият мәйданына 30нчы елларның башында нефтьчеләр һәм тау халыклары тормышыннан алып язылган хикәяләре белән килеп керә («Кем гаепле?», «Таулар арасында», «Мин синең белән», «Чыныгу», «Шәрифҗамал» һ.б.). Нефть чыгару учакларында хезмәт энтузиазмын, социалистик ярыш һәм заманында бик актуаль саналган «корткычлыкка каршы көрәш» темаларын яктырткан «Горизонт» (1933–1934) повесте язучының иҗатында аеруча күренекле урын тота. Әсәрдә эшчеләр тормышы реалистик вакыйгалар һәм үзенчәлекле кеше образлары аша шактый киң һәм ышандырырлык итеп яктыртыла. Әдипнең шушы ук нефтьчеләр һәм тау халыклары тормышына багышланган берничә сәхнә әсәре дә бар («Фонтан», «Танышлар», «Таулар тетри»). Аның соңгы әсәрләреннән булган «Таулар тетри» (1941) пьесасында Грозный нефтьчеләренең Гражданнар сугышында катнашуы күрсәтелә.*

**ГОРИЗОНТ**

*(Повестьтан өзек)*

Батырҗан белән Нәгыймәне пулемет командасы командиры якындагы бер казак авылына сөт алырга җибәрде. Ул вакыт Батырҗан унтугызынчы яше белән генә бара иде. Нәгыймә егерме бишләрдән узган иде инде. Шулай булуына да карамастан ул бик яшь чырайлы, нәфис буйлы, зур зәңгәр күзле кыз иде. Озакка сузылган канлы көрәш Батырҗан белән Нәгыймәнең йөрәген бергә нык бәйләде. Алар берсенә берсе «әшнә» дип исем бирделәр. Бөтен команда аларны «әшнәләр» дип йөри башлады.

Ике әшнә авылга якынлашканда, чиркәү колоколы кичке бишкә сукты. Ә авылдан кире кайтканда, кояш баткан иде инде. Кич караңгы, һава шактый тын. Тик сирәк-сирәк ишетелгән мылтык тавышлары белән артта калган авылда эт өрүләре генә тынлыкны бераз бозалар иде.

Нәгыймә:

– Әшнә, мин арыдым, бераз ял итмибезме? – диде.

Батырҗан каршы килмәде.

Юлдан берничә метрлардагы куаклык артына барып ятты. Әшнәсе артыннан Нәгыймә дә калмады. Ул да Батырҗанга якын ук килеп яшел чирәмгә сузылды.

Батырҗан, сүзсез озак ятканнан соң, Нәгыймәгә таба борылды.

– Нигәдер бик күңелсез, әшнә, – диде.

Нәгыймә елмаеп куйды:

– Ә миңа киресенчә... – Ул Батырҗанның кулын тотты: – Син тирә-ягыңа кара, Батырҗан, әнә нинди биек таулар, аларның башларын калын кар катлавы каплаган. Анданиләр генә юк дип уйлыйсың...

Нәгыймә Батырҗанның күзләренә карады. Батырҗан карашын болытлы күккә төбәгән дә нәрсәдер уйлана кебек. Гүя ул Нәгыймәнең сүзләрен тыңламый. Нәгыймә, хәтере калгандай, Батырҗанның кулын ычкындырды.

– Син мине тыңламыйсың да, – диде ул.

– Киресенчә, рәхәтләнеп тыңлыйм. – Батырҗан Нәгыймәнең кулын сыйпады. Аның күзләренә карап нәрсәдер әйтергә теләде. Ләкин Нәгыймә моны сизмәде булса кирәк. Ул үз уйларына баткан иде. Һәм кинәт кенә торып утырды.

– Беләсеңме нәрсә, Батырҗан? – диде.

– Әйтеп кара, әшнә.

– Минем Казбек тавы башына менәсем килә. Мин сугыш беткәч тә аның башына менәрмен, юк, мин үзем генә түгел, без синең белән икәү...

Нәгыймә сүзләрен әйтеп бетерә алмады, Батырҗан кинәт кенә сузылып аның муеныннан кочаклап алды да үзенә тартты.

– Мин риза, синең белән кая барырга да риза. Яратам мин сине, Нәгыймә, – диде.

Бу беренче мәхәббәт иде. Батырҗан үзенең яратуын, матур буяуларга буямыйча һәм тартынып тормыйча, гади сүзләр белән аңлатты. Ләкин бу гади сүзләр астында күңел сафлыгы, чын мәхәббәт сизелә иде.

Нәгыймә үзенең Батырҗаннан берничә яшь олы булуын уйлап алды да сискәнеп киткәндәй булды. Ләкин муеныннан Батырҗанның кулларын алып ташламады, киресенчә, аңа елышарак төште.

Батырҗан белән Нәгыймә, бер-берсенә нәрсә әйтергә белмәгән төсле, сүзсез озак тордылар.

Берникадәр вакыттан соң Нәгыймә Батырҗанның чәчләреннән сыйпады да:

– Әйдә киттек, Батырҗан, соңга калмыйк, – диде.

...Шушы вакыйга Батырҗанның күңелендә озак еллар буена онытылмаслык хатирәләрнең берсе булып калды. Шул кичтән соң алар тагын да дуслана төштеләр, бер-берсенә тагын да якынайдылар. Ләкин ул вакыйга артык кабатланмады. Алар бер-берсен иркәли алмадылар. Канлы көрәш, күпләрне аерган кебек, аларны да аерды.

Юк, Нәгыймәгә Казбекка менү насыйп булмады. Бу гади хыял гамәлгә ашмады. Грозный шәһәреннән чигенгән вакытта Батырҗан Нәгыймәнең канлы гәүдәсен генә күреп калды. Снаряд ярчыгы аның башына тигән һәм ул кан эчендә ята иде.

Батырҗанга Нәгыймә әле дә менә шул хәлендә ята кебек күренде. Ул, күзләрен йомып, битен кулы белән каплады.

*Ватан сугышына кадәр совет чоры татар әдәбиятында фәнни-популяр, сәнгатьле-документаль жанр әсәрләре белән танылган Хәмит Кави 1906 елны хәзерге Чуашстан Республикасының Козлов районы Әлмән авылында укытучы гаиләсендә туа. 1920–1926 елларны Казанда педагогия техникумында, аннары читтән торып Көнчыгыш педагогия институтының биология*

*факультетында (1926–1931) белем ала. 1926 елдан бирле Казандагы урта мәктәпләрдә, техникумнарда биология һәм география фәннәре укыта.*

*Х.Кави, бик яшьтән география, геология фәннәре белән кызыксынып, студент чагында һәм укытучылык эше белән шөгыльләнгән елларында ук илнең төрле почмакларына сәяхәтләр ясый, үзенең күргәннәре турында фәнни-популяр характердагы очерклар, мажаралы хикәя-повестьлар яза. 1929–1939 еллар арасында аның унлап китабы басылып чыга. Шундыйлардан «Кавказ таулары аркылы җәяү» (1930), «Идел буенда йөрү юллары» (1931), «Боз диңгезенә таба» (1932), «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) исемле китаплары яшүсмерләр һәм мәктәп укучылары арасында популярлык казаналар. Язучы республиканың географик үзенчәлекләре, казылма байлыклары, халыкның көнкүреше, мәдәнияте турында көндәлек матбугатта дистәләгән очеркларын һәм хикәяләрен бастыра.*

*1941 елның сентябрендә Хәмит Кави фронтка китә һәм Совет Армиясе командиры сыйфатында Идел буеннан көнбатыш чикләргә кадәр сугышчан юл уза. 1944 елның 15 июлендә Украинаның Волынск өлкәсендәге Друженополь дигән авыл тирәсендә барган сугышларның берсендә ул батырларча һәлак була.*

## КИЛЬДИН АТАВЫ

Кооператив әйберләрен алырга килгән кеше кырыйга безне дә алып чыкты. Шушы төшү белән Кильдин атавында бер атна тордык. Килгән кешеләр мәктәп йортына урнашалар икән, без дә шунда кереп урнаштык. Мәктәпнең бер бүлмәсендә ике өстәл, бер караватбар иде. Караватка Соловьев, өстәлләргә Фиш белән мин урнаштык. Шулай итеп, тын гына тора башладык. Атау буйлап көне буе йөргәч, кичке унберләрдә кайтып мич ягып җибәрә идек. Мич янып кызгач кына, тагын утын салып, йокларга ята идек. Бары беренче көн генә дөрес эшләмәдек. Мич сәгать унда ягылды, сәгать уникеләрдә бүлмә тәмам кызу иде. Без сәгать икегә кадәр укып яттык. Яткан вакытта бүлмә җылы булса да, иртәнге сәгать сигезләрдә мин суыкка калтырап уянып киттем. Бу суыкта артык ятарга мөмкин булмагач, утын ярып тагын мичне ягып җибәрдек. Шуннан соң гына тагын йоклап китеп булды. Минем юрганым юка булганга күрә, ахрысы, суык миңа катырак тәэсир итә иде. Беренче көнне суыкның тәмен татыганга, икенче көнне кичке унда мичне ягып, йокларга ятканда да сүндермәдек.

Ашау мәсьәләсе дә Кильдинда уңай хәл ителде. Күршедә генә тора торган бер хатын безгә ашлар пешереп бирергә булды. Монда балыкка аптырау юк. Балык кирәк булса, диңгез кырыена барабыз да яңа гына тотып кайткан балыкчылардан балык алабыз. Иң яратып ашаган балыгыбыз – камбала балыгы. Камбаланың бер ягы ак, икенче ягы коңгырт төстә була. Ике күзе дә коңгырт төсле ягында урнашкан. Камбаланың бер ягы ак булу диңгез төбендә бер ягы белән ятып азык сагалавыннан килә. Менә шул балыкны сатып алып (аның берсе өч-дүрт килограмм чамасы була) аш пешерүчегә бирә идек. Алып кайтканда, камбалалар әле тере булалар, кулдан сикереп төшеп аптыраталар. Аш бөтенләй диярлек шул балыктан пешерелә иде. Беренчегә балык шулпасы бирелә, ә икенчесенә шул ук балык кыздырыла иде. Көн дә балык ашларын төрләндереп тә ашадык. Кайбер көннәрдә треска балыгы да алгаладык.

Кильдин атавы бик кечкенә атау түгел. Аның озынлыгы – 15, киңлеге 5 километрлар бар. Шуның көньяк-көяш чыгышы ягындарак авыл урнашкан. Торучыларның күбесе руслар, аз гына Норвегия кешеләре дә бар. Атауның тарихы кызык кына. Монда иң элек Соловки атавындагы монахлар килеп урнашканнар. Алар берникадәр торгач, диңгез караклары аларны үтереп киткәннәр. Аларның каберләре исеме белән аталган бер күл белән атау борыны бар. Авыл тора торган борынны «Кабер борыны» дип йөртәләр. Монахлардан соң монда Ириксин исемле Норвегия кешесе килеп урнашкан. Аның нәселе атауда әле дә бар. Монахларның кабере булган кебек, аның нәселеннән булган кешеләрнең дә атауда каберләре саклана. Монда Ириксин салдырган йортлар калган. Хәзер ул йортларда госторг конторы урнашкан. Аннан соң Кильдинга руслар килгәннәр. Хәзер авылда күп йортлар салынган. Җәй көне кышкыга караганда атауда кешеләр күбрәк булалар. Җәен монда балык тотар өчен төрле җирләрдән балыкчылар җыела. Кыш айлары җитеп, балык сезоны үткәч, алар өйләренә таралалар.

Атау табигый яктан да бай. Күп җирдә ярыйсы гына үлән дә үсә. Кильдин кешеләре аны чабалар, сарык, сыер кебек хайваннар да асрыйлар. Мичкә ягар өчен атауда торф бик күп. Торф катлавының 3 метрга җиткән җирләре бар, диләр. Шифер, сланец исемле промышленностька кирәкле ташлар да бар. Җиргә сузылып кына үсә торган булса да, агачлар да бар. Су кырыенда очып йөри торган кошларның исәбе-хисабы юк. Акчарлаклар Иделдә кечкенә булалар бит, монда алар каз зурлыгында. Кырыйдагы зур-зур ташларда утырган яки су өстендә очып йөри торган акчарлаклар санап бетергесез. Алар көндез диңгездә балык тоталар, кич кырыйдагы зур ташларга кунаклап йоклыйлар. Кильдинда үрдәкләр дә аз түгел. Башка төрле кошлар да монда иркен торалар. Аларны атучы юк. Бары бер мәртәбә генә госторг кешесенең акчарлак атканын күрдем. Аның итен яратмыйлар, бары йоны өчен генә аталар икән.

Кильдинның һавасы да яхшы. Монда җәй көне түгел, кыш көне дә зур суыклар булмый. Баренц

диңгезенә кадәр агып килә торган җылы агым – Гольфстримның[1] монда да тәэсире җитә. Кильдин 70 нче төньяк янәшә сызыгына[2] берничә минутлар гына җитмәгән урында торса да, Гольфстрим агымының тәэсире белән аның тирәсендә диңгез кыш көне дә катмый. Гольфстрим җылылыгы тәэсире белән Кильдин үсемлекләргә дә бай.

Монда җәй көне 2–3 ай кояш бер дә баемыйча, кыш көннәрендә 2–3 ай бер дә чыкмыйча тора. Без җәйге озын көннең актыкларындарак килгәнбез икән. Алай булса да, без кояш батамы, юкмы икәнлеген карарга бардык. Ачык диңгез атауның төньягында, ә авыл көньягында урнашкан булганга, бөтен атауны аркылы үтеп барырга туры килде. Атауның авыл урнашкан җирләре тәбәнәк. Ә калган урыннары таулардан тора. Шуңа күрә элек озак кына тауга менәргә туры килде. Тау менү бераз ардырса да, тирә-якта матур күренешләр ачылганга, урман өстеннән барган шикелле сырышып үскән йомшак агачлар өстеннән барганга, рәхәт тоелды. Юлда берничә күл һәм алар тирәсендә сазлыклар очрады. Мин бер җирдә болан мөгезе таптым. Кильдинда хәзер боланнар булмаса да, элек булган, -ахрысы.

Тау башына менеп җиткәч, ачык Баренц диңгезенә матур күренеш ачылды. Алда да, уңда да, сулда да җир күренми. Ерактан караганда, дулкыннар диңгезне шадраландырып торалар. Офыкка якынлашып килә торган кояшның озын яктылыгы дулкыннарның селкенүен тагын да матуррак итеп күрсәтә. Җиргә якынрак урыннарда әкрен генә шуышып балыкчы көймәләре бара. Аларның кайберсе җилкәннәрен төшергән дә бер урында торып балык тота.

Тау башында бераз карап торгач, тауның төньяк кырына да төштек. Төньяк кырында мүкләр дә үсми. Ялангач ташлар гына. Ташлар өстеннән озак бармадык, кояшның батуын карарга әзерләндек. Бу вакытта сәгать төнге 12 иде. Кояш офыкка якынлашкан, озакламый батарга тора. Кояшның бата башлаган урынын билгеләп ташлар куйдык та, батуны карарга әзерләнеп, ташлар өстенә утырдык. Кояш һаман кояш чыгышына таба бара-бара офыкка бата башлады. Элек аз гынасы офыкка керде. Шул арада көнчыгышка таба әллә никадәр җир күчеп тә өлгерде. Тагын бераз карап торгач, кояшның өч чиреге офыкка батты. Бу вакытта сәгать икенче яртылар булганга, йокларга кайтырга гына тора идек, моңа кадәр батып килә торган кояш тагын күтәрелә башлады. Шулай итеп, кояшның чиреге дә батып җитә алмады. Без килгәнчегә кадәр кояш бөтенләй батмый торган көннәр булган. Хәзер исә озын төньяк көненең актыгы якынлашып килә.

Атау буйлап без, кояш карарга барганда гына түгел, башка вакытларда да йөргәли идек. Шулай бер мәртәбә атауның көнчыгыш ягына таба да барган идек. Көнчыгыш ягында таулар 80 метрлар биеклегендә бик текә дарлар белән бетә икән. Көн ягыннан шул тауларга менеп, текә ярларның кырыена килеп карадык. Без килә генә башлаган идек, ярдан берничә кош, очып китеп, кычкырып очып йөри башладылар. Шул тирәдә генә аларның оялары бар, без аларны куркытып чыгарганбыз икән. Без, читкәрәк китеп, шуышып барып, ярның кырыена ук килдек. Текә яр өстеннән карау бераз куркытса да, күңеллелек тә бирә икән. Биек ярның бер кырыенда зур-зур ташлар ята. Кайбер урыннарда ул зур ташларны суүсемлекләре чолгап алган. Дулкын шаулап зур ташларга бәрелә. Кошлар шул тирәдә генә балык тотар өчен очалар. Таштан ташка сикереп, бер ак төлке – песец (төлкедән кечерәк, тиресе кыйммәтле бер җәнлек) йөри. Ул килгән урыннан кошлар читкәрәк очалар. Качып кына барган шикелле, шуып кына бер җилкәнле балыкчы көймәсе дулкыннарга менә.

Буш вакытларда шулай атауда йөрү күңелле. Төньяк табигатенең матурлыгына исең китәр. Кабер күлен үтеп, бераз көнчыгышка табарак баргач, агачтан бер маяк ясап куйганнар. Кайвакытларда шуның янына барып та диңгезгә карап утыра идек.

Буш вакыт булдымы, Соловьев шигырь яза. Ул кайвакыт Шолом Алейхем исемле язучының хикәяләрен укый. Бервакыт Фиш аңар:

– 70 нче төньяк дәрәҗәсендә[1] син Шолом Алейхемның беренче укучысыдыр, – диде. Шуннан соң миңа карады да: – Син 70 нче төньяк дәрәҗәсенә килеп җиткән беренче татар туристы, – диде.

Мин көлдем дә:

– Сез татарлардан миннән башка 70 нче дәрәҗәгә килеп җиткән кешеләр юк дисезмени? – дидем.

Аннан соң Фиш:

– Без монда бер интернационал икәнбез. Син – татар, мин – еврей, Соловьев – рус, – диде.

Соловьев белән Фиш Кильдинга карап йөрер өчен генә килмәгәннәр. Аларны Ленинградтагы кичке кызыл газета хәбәрчесе итеп мондагы тормышны язарга җибәргәннәр. Кильдинда халык өч төрле кәсеп белән тора. Күбесе, балык тотып, аны кооперативның шхуналарына илтеп сата. Кайберсе йод табу эшендә эшли. Кайберләре ак төлке (песец) үстерә.

Атауда күп кеше балык тоту белән шөгыльләнә. Диңгездә, авыл турысында һәрвакыт төрле балыкчы көймәләре тора. Аларның барысын да бер исем белән монда халык «савыт» дип йөртә. Савытлар төрле-төрле була. Әгәр дә зур җилкәнле көймә булса, аны «шхуна» яки «скутир» диләр. Моторлы һәм җилкәнле зуррак көймәләрне «бот» дип атыйлар. Боттан кечерәк моторсыз җилкәнле көймәләр «йола» дип атала. Бер-ике кеше генә утырырлык көймә «пашка» дип атала. Балыкчылар балык тотарга күбрәк йола белән йөриләр. Көн матур булып, диңгездә дулкын булмаса, авылда бер

генә балыкчы да калмый. Алар атау тирәсендә генә диңгездә йөреп балык тоталар.

Аз гына давыл чыга башлагач, балыкчылар авылга кайталар. Балыкны тоту белән генә аның эше бетми. Кырыйга чыкмыйча гына балыкның эчен чистартып суга ташлыйлар. Шул вакытта йола тирәсенә акчарлаклар җыелып очып йөри башлыйлар. Балыкларның башы да кисеп алына. Ләкин ул суга ташланмый. Балыкның башы, киптерелеп онга тартылгач, җир ашлау өчен яхшы нәрсә була. Шуңа күрә аны киптереп, түкләргә бәйләп, Россиягә яки чит илләргә җибәрәләр. Балыкларның эче чистартылып, башы өзеп алынгач, аны кооператив шхунасына китереп салалар. Шхунаның командасы аны шунда ук тозлап куя. Балык сатылгач, балыкчылар, өйләренә кайтып, йокларга яталар. Җәтмәләре бозылган булса, аларны ямыйлар. Йолаларда йөреп балык тоту эше колхоз кешеләре яки аерым кешеләр кулында. Моңардан башка балыкны күп тота торган рыбтрестларның тралерлары бар. «Тралер» дип конус формасындагы җәтмәне корыч бау белән диңгез төбенә төшереп, өстерәп барып балык тота торган көймәгә әйтәләр.

Трал белән диңгез төбендәге балыкларны гына тоталар. Баренц диңгезендә треска, пикша, камбала балыклары тотыла. Россия бу эшкә күптән түгел генә керешкән. 1910 елдан 1915 елга кадәр Баренц диңгезендә бары 4 тралер булган. 1920 елда исә 12 тралер, 1927 елда аларның саны 17 гә җиткән. Хәзерге вакытта тралерларның саны тагын да күбрәк. Трал базасы Мурманск шәһәрендә урнашкан. Кильдинда күбрәк йолаларда йөреп балык тотучылар гына тора.

Беренче бөтендөнья сугышына кадәр Баренц диңгезендә Англия, Германия, Бельгия, Голландия тралерлары балык тотканнар. Аларның иң күп тоткан балыклары камбала булган. 1914 елгы сугыш алдыннан инглизләр Баренц диңгезеннән 13000 тонна камбала тотканнар. Камбала балыгы шуннан соң бу диңгездә бик нык кимегән.

Тралерларның йола белән балык тотуга караганда тагын бер уңайлы яклары бар. Балыкны тоту, эчен чистарту, башын өзү, тозлау – барысы да үзендә эшләнә. Траллы көймәләр күп кенә механизмнар белән җиһазландырылган. Шуның өчен анда эшләве җиңел, балык та күп эләгә.

Кильдин атавындагы халык балык тоту белән генә тормый. Монда Советлар Союзы өчен әһәмияте зур булган йод чыгару эше бар. Чит илдән йод алу өчен безнең әллә никадәр акчабыз китә. Ә тырышканда, шул ук йодны үзебездә дә табып була. Без көн саен диярлек йөрергә маяк янына бара торган идек. Аның янына барганда, «Кабер күле» исемле күл яныннан үтәргә туры килә. Беренче көнне үк шул күл тирәсендә эшчеләрнең, печән җәйгән шикелле, тырмавычлар белән нәрсәдер таратып йөргәннәрен күрдек. Бу кызык эш күренгәнгә, туктап карап тордык. Сораша торгач, аларның йодлы суүсемлекләрен таратып киптереп йөрүләре аңлашылды. Күлдән ерак түгел, диңгез кырыенда зур гына шомарып беткән ташлар ята. Давыл вакытында диңгез дулкыннары кырыйга күп кенә суүсемлекләрен чыгарып ташлый икән. Шул үсемлекләрне барып карап йөрдек. Монда төрле-төрле үсемлекләр бар. Коңгырт төстәге фукус исемле үсемлекләрнең урман чикләвеге зурлыгында һава капчыклары була. Диңгездән алты сәгать су керә (прилив), алты сәгать су кире диңгезгә чыга (отлив). Су кергән вакытта фукуслар үсә торган ташлар да су астында кала. Шул вакыт һава капчыклары үсемлекләрне күтәреп тора. Су чыга башлагач, үсемлекләр әкренләп егыла барып, су чыгып беткәч, ташлар өстендә ятып кала. Менә шул фукуслардан йод табыла. Коңгырт үсемлекләрдән башка шул ук ташларда тагын яшел суүсемлекләре белән багрянка исемле суүсемлекләре дә үсә. Су чыккач ачык калган урында үскән суүсемлекләренә «литораль үсемлекләре» диләр. Ул диңгез өстеннән алып 4,1 метр тирәнлеккә кадәр төшеп үсә. Йод ясала торган үсемлекләрдә литораль аз була. Йод күбрәк диңгезнең сублитораль исемле икенче катлавында. Сублитораль катлавы 4,1 метрдан башлап 55–65 метрларга кадәр бара. Давыл вакытларында сублитораль катлавында үсә торган ламинария суүсемлеге кырыйга ыргытыла. Шул үсемлекләрне эшчеләр җыеп алып киптерергә тараталар. Кибеп өлгергәч, яндыралар, көле заводка йод эшләү өчен җибәрелә. Эшчеләрнең суүсемлекләрен таратып киптереп йөргәннәрен озак кына карап торгач, йод эшенең мөдире Зиминга киттек. Ул безне бик яхшы каршы алды. Хәзерге вакытта эш ничек барганын сөйләп бирде. Йод табу эше монда быел гына оештырылган икән. Хәзер 16 эшче эшли. Юештә эшләрлек яхшы кием бирелә. Кильдин атавы йод ясарга яраклы ламинария суүсемлегенең күплеге ягыннан СССРда беренче урында тора икән. Көзгә таба атауда йод заводы салынырга тиеш. Кипкәч, ламинариядән 20 % коры үсемлек, коры үсемлектән 5 % ка якын йод чыга.

Зимин эшнең авырлыгы турында зарланып алды:

– Кайвакытта киптерергә дип ламинарияне җиргә таратып куясың, яңгыр явып китә яки томан була. Аны тагын киптерергә кирәк була. Үсемлекләрне коры җиргә салмыйча, берәр җәймәгә салып, яңгыр вакытларында лапас астына кертеп торсаң яхшы булыр иде. Әгәр дә чи көенчә яндыра торган булса, тагын да яхшырак булыр иде. Ул вакытта лапаслар да ясап торырга кирәк булмас. Ленинградтан бер шундый мич җибәрделәр. Монда без аның белән эшләп карадык, мич эшкә ярамады. Мин үзем дә бер мич уйлап чыгардым. Аны язып җибәрдем әле, ни диярләр.

Зимин – 45 яшьләрдәге кеше, сөйләгән сүзләренә караганда, акыллы кеше булырга охшый. Үзе тотынган йод табу эшен ничек булса да яхшырак куярга тырыша.

Без аңардан:

– Нигә соң тизрәк үзегезнең уйлаган лапасларыгызны ясамыйсыз? Нигә тизрәк завод салмыйсыз? СССРга йод бик кирәк бит, – дип сорадык.

Зиминның үзенең дә бу эшләрне тизрәк эшләтәсе килә, ләкин аның сәбәпләре бар икән.

– Хәл кылынмаган бер нәрсә бар әле. Монда ак төлке кыйммәт тора. Аның тиресен чит илдә 400 тәңкәләргә кадәр алалар. Шуның өчен Кильдинда ак төлке үрчетеп, аның тиресен чит илгә сатарга алып китәчәкләр (аннан алынган акчага чит илдән машиналар алачаклар, билгеле). Менә шул ак төлке яшәгәндә, бу атауда башка бернәрсә дә яшәмәскә тиеш, диләр госторг кешеләре. Ак төлке сарыкларны үтергәләде, өйләргә кереп, төрле әйберләрне алып чыгып китә иде. Халык, шуңа ачуланып, аны куып йөри башлады. Кешеләр ак төлкегә төрле нәрсәләр ашаталар. Шуңа күрә госторг, Кильдин атавындагы бөтен кешене башка җиргә күчереп, Кильдинда ак төлкеләр белән аларны караучы берничә кеше генә калдырырга уйлый. Ә минемчә, киресенчә эшләргә кирәк. Ак төлке белән аларны караучылар үзләре башка берәр атауга күчәргә тиешләр. Менә моннан ерак түгел генә кечкенә Болан атавы бар. Аларны шунда күчерергә мөмкин. Ул вакытта атауда балыкчылар да, йод заводы да кала ала. Ул вакытта монда сыер, сарык асрарга да мөмкин булачак. Кильдин атавында тагын шифер, сланец, торф табу эшләрен дә оештырырга мөмкин булачак.

Ул бераз уйланып торды һәм өстәп куйды:

– Минемчә, шулай. Белмим, үзәктә ничек хәл кылырлары, – дип сүзен бетерде.

Без дә, аның сүзләренә кушылып, чыгып киттек.

Ак төлке атауга төшкәч үк безнең күзебезгә чалынган иде. Авыл урамында бер мәче тын гына ята иде. Аның янына коңгырт төстә, төлкедән аз гына кечерәк, мәче шикелле шома басып йөри торган бер җәнлек – ак төлке килде дә өстенә сикермәкче булды. Мәче сикереп торды да үзе ак төлкегә карады. Ак төлке мәченең койрыгыннан эләктереп алырга никадәр тырышса да булдыра алмады. Ул мәченең койрык ягыннан килә генә башлый, мәче алды белән әйләнә. Шулай озак кына маташкач, ерактан нечкә генә улаган тавыш ишетелде. Әлеге ак төлкене иптәше чакыра икән. Мәче шуннан соң гына котыла алды.

Ак төлкеләр авылга күбрәк кич белән киләләр икән. Аларга теләсә нәрсә ашатырга ярамый, без печенье белән шикәр ашатып карадык. Печеньене беренче ыргытканда бераз кимерде дә ташлап китте. Шуннан соң бер шакмак шикәр ыргыттык. Ул арада икенче ак төлке килеп, беренчесеннән шикәрне талап алды...

Икенче бервакыт мин урамда китап укып ята идем. Китапка бирелеп, яныма ак төлке килгәнне сизми дә калганмын. Ак төлке тын гына килде дә минем китапны алып китә башлады. Мин сикереп тордым. Ул алай да китмәде. Минем китабым белән маташа бирде. Китапка аягымны каты итеп китереп баскач кына бераз читкә китте. Читтә дә, күп кенә вакыт китмичә, минем арткы яктан килергә маташты. Бары икенче якта иптәшен күргәч кенә шул якка чапты...

Тавык асрарга мөмкин булмаганга, аны асрамыйлар икән. Ә эт асрарга бөтенләй кушылмаган. Төнлә ак төлкеләр үзләренең нечкә итеп улаулары, яшь этләр шикелле өрүләре белән һаваны яңгыраталар.

Ак төлкене асрау эше белән кызыксынып, госторгка бардык. Алар ак төлке асрауга зур әһәмият бирәләр. Практикага килгән студент Васильев үз эшләре турында сөйләде:

– Кильдин атавы ак төлкеләр үрчетергә бик уңай. Тирә-якта су кыш көне дә катмаганга, аларның качып китүләреннән куркыныч юк. Монда аларга ояларга да урыннар күп. Аларга ашарга кошлар да, балыклар да күп. Шуңар күрә госторг монда ак төлке питомнигы ясарга булды. Командор атауларыннан 100 пар зәңгәр песец китереп, монда җибәрдек. Урамда йөри торган ак төлкеләр җәй көне генә коңгырт төстә булалар. Кыш көне алар ак төскә керәләр. Менә шул вакытта аларның тиресе кыйммәт йөри. Командор атауларыннан китерелгән 200 ак төлке 40000 сум тора. Алар, монда килгәч, быел 150 % ка арттылар. Хәзер безгә, чыгымнарын исәпләгәндә, һәр ак төлке 349 сумга төшә. 1938 елда аларның саны 2544 башка җитәчәк. Ул вакытта бер песец үзебезгә 42 сумга гына төшәчәк. Соңгы елларда бер генә ак төлкене дә үтермәскә уйланыла. Чөнки башка җирләрдә дә оештырыла торган питомникларга тере ак төлкеләр кирәк булачак. Күршедәге кечкенә Болан атавына да ак төлкеләр җибәрергә уйланыла. Чөнки Кильдин атавы 1500 баштан артык ак төлкене сыйдыра алмас кебек. Ак төлкеләрдән башка, Кильдинга кара-коңгырт көмеш сыман төлкеләр дә җибәрү уе бар.

*1932–1934*

*Әгъзам Камал (Әгъзам Камалетдин улы Камалетдинов) 1918 елның 21 гыйнварында Татарстан Республикасының Апас районы Үтәмеш авылында крәстиян гаиләсендә туа. 1931–1934 елларда үз авылларындагы җидееллык мәктәптә (ТБУМ) укый, аны тәмамлагач, Казанга килеп, финанс-экономика техникумында белем ала. 1937 елда техникумны тәмамлап, берникадәр вакыт Татарстанның Тәкәнеш районында үз белгечлеге буенча эшләгәннән соң, ул яңадан Казанга кайта һәм 1938–1939 елларда «Чаян» журналы һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1939 елның көзендә армия сафларына чакырылып хәрби курсларны тәмамлагач, сугыш башланганга кадәр анда кече командир булып хезмәт*

*итә.*

*Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Әгъзам Камал алгы сызыкта сугыша. Канлы бәрелешләрнең берсендә яраланып, шактый вакыт госпитальдә дәвалана, аннары Саратов шәһәрендәге хәрби училищега укырга җибәрелә. Училищены офицер дәрәҗәсе алып тәмамлаганнан соң, Әгъзам Камал кабат үз гаскәри берәмлегенә – Сталинград фронтына кайта һәм, андагы хәлиткеч сугыш операцияләрендә күп мәртәбәләр катнашып, 1943 елның 16 маенда дошман пулясыннан һәлак була.*

*Ә.Камал мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый. Казанга килгәч, аның шигырьләре республика көндәлек матбугатында, альманахларда, күмәк җыентыкларда еш басыла. 1938 елда яшь шагыйрьнең «Җилфердә, байрак!», ә 1939 елда «Һәйкәл янында җыр» дигән шигырь җыентыклары дөнья күрә.*

*Ә.Камалның кырыс сугыш шартларында язган шигырьләре фронт газеталарында, «Кызыл Татарстан»да һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында да басыла.*

*Фронтовик шагыйрьнең аерым иҗат үрнәкләре һәм үзе турында мәгълүматлар «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) исемле җыентыкларда урын ала.*

## ИЮЛЬ КИЧЕНДӘ

*Кеше – ул горур яңгырый.*
*М.Горький*

Мин беренче тапкыр түгел инде
Басып торам сирень төбендә.
Әй табигать, яшел яфракларың
Җырым кебек якын күңелгә.

Шаулагыз сез, усак яфраклары,
Шаулагыз сез, бөдрә каеннар,
Сезнең кебек мин дә бәхетлемен,
Тик йөрәктә кайгы эзе бар:

Бу кабердә йоклый комсомолец –
Утлы давылларны кичүче,
Яшь гомерен халык бәхте өчен,
Ирек таңы өчен бирүче.

Теләкләре аның бөреләнеп
Чәчәк атты безнең елларда;
Чайковский язган көй шикелле,
Исме яңгырый безнең җырларда.

Һәр яз саен кабер өстендә
Матур кызыл гөлләр үсәләр,
Ә аларны сөеп, тирбәлдереп,
Йомшак җылы җилләр исәләр.

Нурларына айның төренеп,
Мин шушында киләм кичләрен,
Мин йотылып карыйм үзәннәргә,
Дулкынлана минем хисләрем.

Сандугачкай сайрый очынып,
Ә мин җырлыйм аңа кушылып:

«Без бергә үстек,
Без бергә кичтек
Ядрәләр яуган
Дәһшәт кырларын;
Без яулап алдык
Бәхетле гомер,
Себердек илдән
Дошман яуларын.

Син күрә алмадың
Безнең көннәрне,
Бу кабер сине
Вакытсыз алды,
Гасырлар буе
Балкып янарга
Күкрәгеңдәге
Йолдызың калды».

Мин уйларга чумып йөрим монда
Хыялга бай июль кичендә,
Һәм мин үткән көннәр истәлеген
Күз алдыннан бер кат кичерәм.

Ә шул хисләр белән бөреләнеп
Чәчәк ата минем җырым да,
Орден таккан яшьлек сафларында,
Байракларның алсу нурында.

Яңгыра, җыр, таулар киңлегендә,
Яңгыра, җыр, безне чакырып,
Дошман өсләренә дәһшәтле көч –
Утлы яшен булып яктырып!

*1938*

## БРОНЕПОЕЗД

*«Кызыл Татарстан»*
*бронепоездына*

Кайчагында шундый вакыт була,
Үлем каршысында ятасың,
Тамырларга бетмәс дәртләр тула,
Килеп чыкса шунда якташың.

Бара иде сугыш тимер юлда,
Җирне казып фашист урнашкан.
Пулеметлар юлны буды сулда,
Автоматлар буды уң яктан.

– Менә-менә алка ябылыр да
Без калырбыз дошман кулында.
Санга артык дошман ябырылыр да
Һәлак булыр күпләр шушында, –

Дип торганда, бронепоезд килде,
Алга куеп көчле күкрәген,
Йөрәкләргә шатлык тулган иде,
Тыңлаганда аның күкрәвен.

Блиндажлар ишелделәр кинәт,

Күккә очты башлар, ак ташлар,
Әйтеп куйды яшь сугышчы Зиннәт:
– Рәхмәт сезгә, рәхмәт, якташлар!

Бронепоезд һәр көн безнең сафта,
Ишеткәнсең инде хәбәрне.
Ул катнашты азат иткән чакта
«Н» дип исемләнгән шәһәрне.

Без беләбез: аның һәр винтында
Халык көче, халык сумнары.
Без фронтта, ә сез тирән тылда,
Һәм байраклар безнең югары!

Бәлки, җырым сезгә барып җитәр,
Ул сөйләсен сезгә, мактасын.
Һәрвакытта безгә ярдәм итәр
Бронепоезд – минем якташым!

*1942*

**КҮПЕР**

Ул күрде дә ике текә ярны
Тоташтырып торган күперне:
«Үз эшеңнән кыйммәт нәрсә бармы?» –
Дип уйлады... аннан төкерде.
Кул селтәде...
«Партизаннар, аңлыйм,
Тотыналар авыр бу эшкә...
Тик дошманга кичү итә алмыйм,
Совет күперен...
Алга, җиңешкә!»
Күпер буйлап көчле күкрәү үтте,
Куркып очты күлдән үрдәкләр.
Чыш-пыш килеп суга авып төште
Кинәт кызган тимер өрлекләр.
Поезд оча игътибарсыз дулап,
Бәреләә пар,
Киләә мең аваз.
Ләкин юкка...
Туктый алмый, улап
Су төбенә китте паровоз,
Һәм вагоннар изелделәр чатнап,
Кайдандыр ут ачты пулемет.
Тимер юлдан тантаналы атлап,
Зур һәлакәт үтте бу минут.
Су айкалды.
Язгы бозлар сыман
Калкып чыкты астан үлекләр.
Гөмбә кебек йөзеп йөрде озак
Үрмәкүчле тимер бүрекләр.
– Украина, – дип, бер партизан әйтте, –
Дошман өчен, ай-яй, яман җир!
«Тәртип белән» безнең кулдан үтте
Дүрт эшелон, иптәш командир!

*1943*

*Совет чоры татар поэзиясенең күренекле вәкиле Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов) 1909 елның 9 гыйнварында Россиянең элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан*

*Республикасының Бишбүләк районы) Ает авылында мулла гаиләсендә туа. Мәктәпкә кергәнче үк укырга-язарга өйрәнә, аннан авыл мәктәбенең ике сыйныфын тәмамлый. 1922 елда абыйсы Габдулла Кәримов (шагыйрь Ярлы Кәрим, 1901–1937) аны үзе белән Бәләбәй шәһәренә алып китә һәм педагогия техникумының әзерлек сыйныфына укырга урнаштыра. Монда ике ел укып әзерлек курсын тәмамлагач (1924), шул ук абыйсы ярдәмендә Казанга килеп, бер ел яшүсмер балалар йортында тәрбияләнә. 1925–1929 елларда Казан җир төзелеше техникумында укый. Әдәби иҗат эше белән җитди шөгыльләнә башлавы да шушы студентлык елларына карый. 1926 елдан республика газеталарында яшь каләм тибрәтүченең көндәлек яшьләр тормышына багышланган мәкаләләре, фельетоннары, соңга таба балалар өчен хикәяләре һәм шигырьләре күренә башлый. 1928 елдан Казанда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») дигән махсус газета чыгарыла башлагач, унтугыз яшьлек студент-әдипне газетаның редколлегиясе составына кертәләр һәм идарәнең җаваплы сәркәтибе итеп билгелиләр. Техникумдагы укуын дәвам иткән хәлдә, Ф.Кәрим бу газетада бер ел эшли, аннары, 1929 елда техникумны тәмамлагач, «Крәстиян гәзите» идарәсенә әдәби хезмәткәр булып күчә. 1930–1931 елларда ул «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Атака» (татар пролетар язучылары оешмасының басмасы) журналларында җаваплы сәркәтип хезмәтендә була. 1931 елның көзендә армиягә алынып, 1933 елның гыйнварына кадәр Идел буе хәрби округының Казанда татар телендә чыга торган «Кызылармияче» дигән газетада хәбәрче-корреспондент булып хезмәт итә.*

*Армия хезмәтеннән кайткач, Ф.Кәримне Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегенә җитәкче итеп билгелиләр. Монда ул 1937 елның маена кадәр эшли. Бу – Ф.Кәримнең иҗат һәм җәмәгать эшендә кайнап, әдип буларак үсү һәм формалашу еллары. 1929 елдан хәвефле 1937 елга кадәрге чагыштырмача кыска вакыт эчендә аның ун китабы басылып чыга (икесе – проза, сигезе – шигъри җыентыклар). Иҗатта туктаусыз эзләнү, уку һәм тормышны өйрәнү аңа, беренче әсәрләрендә әле нык сизелгән декларативлыктан арынып, уй-хисләрен шигырьдә торган саен үтемлерәк, табигыйрәк яңгыраштa, камилрәк формада чагылдыру юнәлешендә осталыгын үстерергә юл ача. 30нчы еллардагы күмәк хезмәт, яшьлек һәм мәхәббәт романтикасын ихлас садәлек, эмоциональ күтәренкелек белән гәүдәләндергән лирик шигырьләре, «Яшен яктысы» (1932), «Җиденче мич» (1932), «Тавышлы таң» (1933), «Илле егет» (1934), «Аучылар» (1934), «Аникин» (1936) кебек поэмалары белән ул үзен татар поэзиясенең үзенчәлекле шигъри моң-авазга ия булган талантлы бер вәкиле итеп таныта.*

*Иҗат дәрте белән шулай илһамланып, совет хакимияте төзегән тормыш тәртипләренә, яңа җәмгыятьнең гаделлегенә ихластан ышанган һәм үзенең шагыйрьлек талантын, бөтен иҗади көчен бөтенләе белән шул «гадел» җәмгыять хакына сарыф итәргә әзер булып яшәгән егерме тугыз яшьлек шагыйрьне 1938 елның 3 гыйнварында кинәт кулга алалар. Тентү вакытында барлык язулы дәфтәрләрен, кульязмаларын җыеп төяп алып китәләр. Аларның күп өлеше соңыннан НКВД подвалларында юкка чыга. Әдип өстенә бернинди дәлилсез-нисез, фәкать НКВД кабинетларында махсус уйлап чыгарылган «фактлар» нигезендә «милләтче», «пантөрекче», «буржуазия ялчысы», «Советка каршы коткы таратучы», әдәби әсәрләрендә «кулаклар идеологиясен үткәрүче халык дошманы» шикелле коточкыч нахак гаепләр ташлана. Шул «гаепләре» өчен тоталитар режимның урындагы мәхкәмәсе 1939 елның 14 мартындагы ябык утырышында Ф.Кәримне ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм, шуңа өстәп, тагын биш елга гражданлык хокукларыннан чикләргә дигән хөкем карарын игълан итә. Бу карар белән килешмичә, әдип, берничә тапкыр кассацион гаризалар язып, үзенең гаепсез икәнлеген исбатлап карый, ләкин аның гаризаларына игътибар итүче булмый. Нәтиҗәдә шагыйрьне озак та үтми этап белән төньякка – сәяси тоткыннар лагерена (совет концлагерена) озаталар. Бары тик шундый ук «гаепләр» белән төрмәләрдә утырып, соңыннан акланып чыккан язучы Кави Нәҗми һәм генерал Якуб Чанышевларның Ф.Кәримне гаепсез итеп күрсәткән гаризалары бер-бер артлы барып ирешкәч кенә, СССР Югары мәхкәмәсе Ф.Кәримнең «җинаять эше»н яңадан тикшерүгә куярга мәҗбүр була. Бу тикшерү барышында шагыйрьне төньяктагы ерак лагерьдан Казан төрмәсенә кире кайтаралар. Ниһаять, 1941 елның 1 декабрендә, инде Алмания белән канлы сугышлар барган көннәрдә, Ф.Кәримне иреккә чыгаралар. Ләкин бер шарт белән: ул «үз теләге белән» фронтка китәргә тиеш була. Чыннан да, бер үк вакытта сәер дә, кешелексез дә булган бу шартны үтәп, шул ук декабрь аеның утызында Ф.Кәрим фронтка чыгып китә.*

*1942 елның февраленнән 1945 елның февраленә кадәр, ягъни өч ел буена, Фатих Кәрим фронтның алгы сызыгында була, солдат һәм кече офицер, взвод командиры сыйфатында Мәскәү яныннан алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сугышчан юл уза, Украинаны, Белоруссияне, Карпат илләрен азат итүдә катнаша, ике тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Әсугыш бетәргә санаулы көннәр калганда, 1945 елның 19 февралендә, Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә утыз алты яшьлек шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була. Күмелгән урыны шундагы туганнар каберлегендә.*

*1941–1945 еллар арасында ул тугыз поэма, ике повесть, бер драма әсәре һәм йөздән артык исемдә шигырь иҗат итә. Сан ягыннан гына түгел, сыйфат һәм идея-эчтәлек ягыннан да шагыйрьнең бу чор*

*әсәрләре иҗатта яңа биеклеккә күтәрелү, камиллеккә ирешү мисалы булып торалар. Аның поэзиясендә сугыш чынбарлыгының катлаулы фәлсәфәсе, фашизмга каршы җанын кызганмый көрәшкә күтәрелгән гади солдатның сугыш кырындагы батырлыгы, эчке кичерешләре, ватандарлык хисләре, сөйгәненә, гаиләсенә, апа-сеңелләренә, абый-энеләренә, әти-әнисенә, туган җиренә, туган халкына булган олы мәхәббәте, тыныч тормышка сусау-җирсү сагышлары гаҗәеп тәэсирле, эмоциональ тирәнлек белән сурәтләнәләр. Ф.Кәримнең төрмә камераларында күңел дәфтәренә теркәп саклап калдырган, сугыш тынган араларда солдат землянкалары, окоп ышыкларында иҗат иткән лирик шигырьләре, «Гөлсем» (1942), «Идел егете» (1942), «Кыңгыраулы яшел гармун» (1942), «Үлем уены» (1942), «Партизан хатыны» (1943), «Өмет йолдызы» (1944) поэмалары, «Тимер һәм тимерче» кебек балладалары (1942), Муса Җәлилнең Моабит циклы шигырьләре белән бергә сугыш чоры татар поэзиясенең иң югары ноктасын тәшкил итәләр.*

*Фронтта Ф.Кәрим үзенең әдәби мирасын чәчмә әсәрләр белән дә баета: «Шакир Шигаев» исемле драма (1943), «Разведчик язмалары» (1942) һәм «Язгы төндә» (1943) исемле ике повестен иҗат итә. Бу әсәрләр дә, поэзиясе кебек үк, сугыш афәтенә, фашизмга, тираниягә каршы юнәлтелгән нәфрәт хисләре белән сугарылган.*

*Ф.Кәрим – 1934 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## АНТ

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә – балам. Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...

Бәлки, соңгы тапкыр күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.

Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!» – ди ул күңеленнән,
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.

Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм.

*1942*

## ВАТАНЫМ ӨЧЕН

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында,
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,

Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

*1942*

**БЕЗДӘ ЯЗДЫР**

Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы, төннәр айлыдыр,
Идел буендагы бакчаларда
Сыерчыклар ярсып сайрыйдыр.

Кошлар моңы уятадыр сине,
Челтәр-пәрдәләрне күтәреп,
Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз
Чәчәк аткан гөлләр үтәли.

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман-кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изрәп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

Фашист тырнагына капкан кеше
Сыкрамыйча монда тын алмый,
Янган авылларның төтеннәре
Язгы таңның нурын томалый.

Фашист илгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.
Яшен уты белән күккә язып әйтәм:
Язы юкның яшәү хакы юк!

*1942*

**КЫР КАЗЫ**

Тирән окопта каршылыйм
Икенче язны;
Язгы таңда безнең якка
Кайта кыр казы;

Кайта диңгез артындагы
Ерак иллердән,
Һәм яши ул төнбоеклы
Тонык күлләрдә.

Әй, кыр казы, түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,

Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Каләм ясап каурыеңнан,
Язгы ялкында
Ут эченнән язьйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Дәһшәтле сугыш кырында
Сөйгән халкымның
Мин кояшым итеп йөртәм
Йөрәк ялкынын.

Халкыма бәхет, дан даулап
Үтә көннәрем;
Анабыз-җирне кочаклап,
Бәлки, үләрмен.

Үлсәм, җырларымда калыр
Сөю, сагышлар;
Кыр казы йөзгән күлләрдә
Шаулар камышлар.

*1944*

**РАЗВЕДЧИК ЯЗМАЛАРЫ**

*(Повестьтан өзек)*

Көзге кояшның салмак алтын нурлары таңгы офык артыннан югарыга сибелгән вакытта, без урман эчендәге аланда яңа гына казылган кабер янында тора идек. Ак тактадан ясалган гробта баштанаяк хәрби кием кигән Акморат ята. Яралы башы ак марля белән бәйләнгән. Гроб янына Акморатның разведка кораллары куелган: бер ягында автомат, икенче ягында күп фашистларның йөрәгенә кадалган үткер хәнҗәр...

Йомшак кар өстеннән акрын гына кыштырдап подполковникның автомашинасы килеп туктады. Подполковник машинадан төшеп кабер янына килде. Аннары без аның кабер өстенә басып сөйләгән ялкынлы сүзләрен тыңладык. Алар Акморат һәм, Акморат кебек, Ватан өчен сугыш кырында батырларча корбан булган йөрәкле егетләр турында иде.

Без, Акморатның якын иптәшләре, батыр егетнең гробын кабергә төшерергә әзерләндек. Шул вакыт түбәннән генә, нәкъ безнең баш турыбыздан, канатлары кызыл йолдызлар белән бизәлгән тиз йөрешле өч бомбардировщик очып үтте. Алар элекке төнне дошман тылында без Акморат белән икәү актарып йөргән урманга таба юл тоттылар.

Без Акморатны кабергә төшердек. Төшерүебез булды, еракта, дошман тылында, каты гөрселдәгән тавышлар ишетелде. Бөтенебез дә борылып шул якка күз салдык. Акморат белән икәү планын төшергән урман эченнән, ургылып-ургылып, ялкын катнаш кара төтен күтәрелә, урманның көле күккә оча иде. Минем йөрәк әллә ни эшләп җилкенеп китте. Тын гына борылып, мин кабердә яткан Акморатка күз төшердем. Түзмәдем, тирән дулкынлану белән Акморатка – сугыш кырындагы иң якын дустыма соңгы аерылышу сүзләремне әйттем:

– Тыныч йокла, иптәш! Үлсәк тә, бушка үлмибез без. Каһәрле дошманның көлен күккә очырып үләбез. Күрәсеңме, без синең белән эзебезне калдырып үткән дошман тылындагы урманда дошман, аның көче, корал белән тутырылган складлары бер-бер артлы шартлыйлар. Алар кара төтен булып күккә күтәреләләр. Җил аны ерактагы таулар артына илтеп тарата, юк итә.

Ә без калабыз! Ата-аналар, туганнар, иптәшләр, якын дуслар кала!

Сөйгән халык кала. Туган ил кала!

Туган илнең күкрәп торган урманнары, шаулап аккан елгалары, яңгырап торган таулары, киң тугайлары кала. Без төзегән яшәп туймаслык матур тормыш кала!

*1942,*
*Көнбатыш фронт*

*Язучы Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев) 1903 елның 28 ноябрендә элекке Саратов губернасының Кузнецк өязе (хәзер Пенза өлкәсенә керә) Татар Кынадысы авылында мул тормышлы крәстиян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала. 1912 елда әтисе Нурмөхәммәт абзый, игенчелек хезмәтен ташлап, гаиләсе белән Самара губернасындагы Алексеевка дигән авылга күчә һәм бертуган Кутуевларның күн заводында эшли башлый. Гаделша шунда рус мәктәбендә белем алуын дәвам иттерә. 1917 елда бертуган Кутуевлар дүрт гаилә бергә Самара шәһәренә күчеп киләләр. Булачак язучының белем алуы һәм әдәби сәләтенең ачылып китүе өчен монда шартлар тагын да уңайлана төшә. Мәктәптә уку белән бергә ул шәһәрдәге мәдәни клубларның берсендә рус язучысы Александр Неверов оештырган әдәби түгәрәккә йөри, рус телендә өйрәнчек беренче шигырьләрен яза, ныклап торып шул чордагы яңа рус поэзиясе, аерым алганда, В.Маяковский иҗаты белән якыннан таныша.*

*1920 елда унҗиде яшьлек Г.Кутуй белем алуын дәвам иттерү һәм бигрәк тә татар әдәбиятына якынрак булу өчен Казанга килә һәм политехника институтының химия факультетына укырга керә. Ләкин ике курсны тәмамлагач, төгәл фәннәргә күңеле ятмыйча, институтта укуын ташлый да Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбендә әдәбият укытучысы булып эшли башлый. Шушы чорда аның әдәби иҗат эшчәнлеге дә активлашып китә. 1923 елгы «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының дүртенче-бишенче саннарында «Яшь футурист шагыйрь» дигән баш белән Г.Кутуйның бер бәйләм шигырьләре басылып чыга. 1924 елда исә «Көннәр йөгергәндә» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Нигездә, рус футурист шагыйрьләренә һәм В.Маяковский шигырьләренең тышкы формасына ияреп язылган, аерым уңышлы чагыштырулары, образлы тәгъбирләре булса да, тулаем аңлаешсыз һәм сәер яңгыраган бу шигырьләр ул заманның әдәби тәнкыйтендә зур шау-шу кузгаталар, татар шигъриятенең үткәндәге уңай традицияләрен инкяр итү сыйфатында каты тәнкыйтькә очрыйлар. Тора-бара иҗатындагы бу мавыгуларны Г.Кутуй үзе дә таный һәм, алардан әкренләп арына барып, 20нче елларның икенче яртысында иҗат иткән шигъри әсәрләрендә үзенең уй-хисләрен реалистик сурәтләү чаралары ярдәмендә бирергә омтыла башлый.*

*1925 елда Г.Кутуй Казан шәрекъ педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1929 елда институтны тәмамлап чыккач, 30нчы еллар дәвамында Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтында гыйльми сәркәтип, мәктәпләрдә һәм Казан авиация техникумында әдәбият укытучысы булып эшли.*

*Әдипнең 20нче еллардагы әдәби иҗаты жанр төрлелеге белән аерылып тора. Ул шигырьләр, хикәяләр, пьесалар яза, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»), «Красная Татария» (хәзерге «Республика Татарстан») газеталарында, «Безнең юл», «Яңалиф», «Авыл яшьләре», «Чаян» журналларында күпсанлы фельетоннар, очерклар, мәкаләләр бастыра, Татар академия театрының һәр яңа спектакленә диярлек рецензияләр язып бара. Үз чорының төрле иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләренә багышланган «Балдызкай» (1926), «Директор Җәмилев» (1926), «Күк күгәрчен» (1929), «Җавап» (1929), Мулланур Вахитовның тарихи шәхесен сәхнәдә гәүдәләндерүне максат итеп куйган «Казан» (1927) исемле пьесалары Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала. Кызганыч ки, бу биш пьесадан өчесенең («Директор Җәмилев», «Җавап», «Казан») текстлары сакланып калмаган. Әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә, публицистикасында әдип совет хакимияте тудырган яңа дәүләтчелек шартларында әдәбият-сәнгатьнең торышы, иҗтимагый роле, үсеше мәсьәләләренә караган, кайбер очракларда ул заман өчен шактый субъектив яңгыраган фикерләрен дә әйтеп чыга. Дөрес, әдипнең шигырьдә формаль сурәтләү чаралары белән мавыгулары, башлыча шәһәр зыялылары – укытучылар, студентлар, музыка, сәнгать кешеләре тормышыннан алып, нигездә, әхлакый темаларны яктырткан пьесалары, хикәяләре, публицистикасында алга сөргән фикер-карашлары үз чиратында рәсми идеологиягә буйсындырылган матбугатта еш кына каты тәнкыйть утына да очрый. Алай гына да түгел, тарихта «Җидегән» исеме белән мәгълүм ниндидер, соңыннан ачыкланганча, дөньяда бөтенләй булмаган яшерен милли-сәяси оешмада әгъза булып торуда гаепләнеп, 30нчы еллар башында Гадел Кутуй һәм тагын биш «җидегәнче» (Н.Исәнбәт, Г.Минский, С.Кудаш, Т.Ченәкәй, С.Агиш) җавапка да тартылалар. Гадел Кутуй, каләм хезмәте белән яшәү мөмкинлегеннән мәхрүм калып, шактый еллар укытучылык эше белән шөгыльләнергә мәҗбүр була. Бары тик 1935 елда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының тугыз-уникенче саннарында атаклы «Тапшырылмаган хатлар» повесте басылып чыккач кына, әдипнең абруйлы исеме яңадан матбугат иреге ала.*

*Г.Кутуйның сугыш алды прозасында тормышны бизәбрәк күрсәтү, аның матур якларына гына игътибарны юнәлтеп иҗат итү тенденциясе ачык сизелә. Мәсәлән, «Солтанның бер көне» исемле озын хикәясендә (1938) ул гаилә корырга йөрүче укытучының көндәлек эшләре, мәхәббәт кичерешләре, сөйгән кызы белән бергә күңел ачу вакыйгалары аша тормышның гүзәллегенә дан җырлый. Әдипнең «Вөждан газабы» (1939), «Нишләргә?» (1940), «Илһам» (1941) исемле хикәяләре, «Шатлык җыры» пьесасы (1935) һәм «Талантлар ватаны» исемле поэмасы да (1937) шул ук рухта язылганнар.*

*Ватан сугышы башлану белән, Г.Кутуй үзенең язучылык каләмен җиңү өчен көрәш коралына әверелдерә: патриотик шигырьләрен («Озату җыры», «Партизанка», «Батыр кабереңдә», «Яңа ел бүләге» һ.б.), «Рәссам» (1941), «Хәнҗәр» (1941) кебек хикәяләрен, «Патриот Тукай», «Партизаннар», «Җиңү хәбәрчесе» кебек зур күләмле мәкаләләрен язып бастыра. 1942 елның июнендә ул үзе дә фронтка китә, әүвәл Сталинградны саклаучы Дон фронтының авыр гвардия миномет бригадасы сәяси бүлегендә хезмәт итә, Идел буендагы мәшһүр Сталинград сугышында катнашкан өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә (соңрак фронтта күрсәткән батырлыклары өчен ул Кызыл Йолдыз орденына да лаек була).*

*Сталинградтан соң Г.Кутуй үзе хезмәт иткән гвардия бригадасы составында Волхов, Курск, Брянск, Великие Луки һәм башка бик күп шәһәрләрне азат итү сугышларында катнаша. 1944 елның көзендә Беренче Белоруссия фронтындагы татар телендә чыга торган «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә күчерелә. Авыр һәм мәшәкатьле солдат хезмәтен башкару белән бергә ул иҗат эшен дә дәвам иттерә: фронт газеталарында хәбәрләр, мәкаләләр бастыра, әдәби монтажлар төзи, 1944 елда Казанга вакытлыча иҗади ялга кайткач, балалар өчен «Рөстәм маҗаралары» исемле хыялый романын яза. Шул ук чорда аның «Без – сталинградчылар» (1944) һәм «Сагыну» (1945) исемле солдат хисләрен сәнгатьчә югарылыкта сурәтләгән атаклы нәсерләре иҗат ителә.*

*Сугыш бетәр алдыннан, 1945 елның язында, Г.Кутуй, сәламәтлеге начараеп, хәрби госпитальгә эләгә һәм 1945 елның 15 июнендә Польшадагы Згеж шәһәрендә вафат була. Кабере Згеж шәһәре зиратында.*

*Г.Кутуй – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## БАТЫР КАБЕРЕНДӘ

Ялгыз кабер тора тау башында,
Яшь бер батыр анда күмелгән.
Таңда искән кыр җилләре аңа
Күп-күп итеп чәчәк китергән.

Баш очында аның шаулый нарат,
Ә наратта кошлар сайрыйлар.
Эссе көндә аны каплый болыт,
Ә суыкта нурлар карыйлар.

Бер яшь батыр ята тау башында,
Дусты килгән аны күрергә.
Ул ант итә аның баш очында
Дошманнарга җәза бирергә:

– Мин ант итәм үбеп туфрагыңны,
Мин ант итәм синең кабреңдә,
Һич кызганмам явыз дошманнарны,
Син яшәрсең минем хәтремдә!

*1941*

## ИРТӘНГЕ УЙЛАР

Алтын колач җәеп кояш калка,
Җылы нурлар җиргә тарала;
Кояш матурлыгын кочар булып,
Мин тез чүгеп карыйм аңарга.

Окоп янындагы күл төбендә
Мин күрәмен нурлар уйнавын;
Нурда, саф һавада коенам мин,
Җиңел булсын диеп юлларым.

Мин исним дә сирень чәчәкләрен

Дошман якка карыйм һәм күләм;
Шушы сирень чәчәгендә чөнки
Җиңү музыкасын ишетәм.

Автоматым кысып, горур атлап,
Ап-ак төнле юллар үтәм мин,
Чөнки һәрбер тыныч адымымда
Җиңү музыкасы иштәм мин.

Юлларымда күрәм туп, танклар
Һәм күрәм мин халык яуларын.
Бронзадай гаскәр сафларында
Мин ишетәм хаклык яңравын.

Хыял күзем белән илгә карыйм,
Карап туймыйм – рәхәт күңелгә!
Рус шәһәрен ярсып яклаганда,
Күзләремә Казан күренә!..

*1942*

## ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР

*(Беренче хаттан өзек)*

Искәндәр!

Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт. Мин аны кат-кат укып чыктым. Бу сагыну хатыңны укыган чакта, минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан сигез ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис», – дип килеп танышкан Искәндәр иде.

Нинди матур истәлек. Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә. Миндә яңа хисләр тудырган, күңел күзләремә матурлык буяулары биргән бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм. Тормышның тискәре, усал, шакшы яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр, шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.

Исеңдәме беренче танышуыбыз?

Мин, матурлыкның нәрсә икәнен бары хыялда гына күреп, әкиятләрдән генә ишетеп килгән ятимә бер кыз, кинәт өнемдә чын матурлык диңгезенә чумып, шатлык дулкыннарында йөзә башладым. Чынлап та, корып, саргаеп беткән яз чәчәген иң тәмле хуш исләр чыгарып торган чәчәккә әйләндерү – охшашы булмаган матурлык бит. Үземне, гомумән кешеләрне чәчәккә тиңләштерү дөрес үк булмаса да, минем бу хәл ул чагында шуңа бик якын иде.

Мин элекке Кузнецк өязендә, караңгы мишәр авылында – Ялгашта туганмын. Минем атамның гомер-гомергә күргәне бары биш-алты авыл булган. Ә мин, аның кызы, Мәскәүдә тордым, Ленинградта булдым, Харьков, Ташкент, Бакуларны күрдем... Мин диңгездә йөздем, Кавказ тауларына мендем. Минем атам үз телен дә кирәгенчә белмәгән. Ә мин, аның кызы, татарча гына түгел, рус, немец телләрендә дә сөйләшәм. Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән. Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән. Ә мин, Чулак Фәхри кызы, хәзер үзем доктор.

Зур тормышны чын-чынлап белү һәм шуны белгәннән соң киң сулыш алып эшләү шатлыгын, яшисе килү матурлыгын аңлату кыен. Миңа әле күптән түгел бер яңа роман укырга туры килде. Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде. Чөнки хәзер доктор булган татар кызының нәселе дә, тормыш төбеннән югарыга, язучылык дәрәҗәсенә күтәрелгән язучының нәселе кебек үк, иске заман бизәгендә, җәфа чигү утында яшәгән нәсел.

Әйе, беренче танышуыбыз! Тәртипсез язуым өчен гафу ит, иркәм. Минем өчен тормыш хәзер шундый бай, шундый күңелле, бер әйбер турында яза башладым исә, берсе-берсеннән матур булган тойгылар, фикерләр кәгазьгә агылырга гына торалар. Менә хәзер дә үзем сиңа хат язам, үзем радио аркылы Шубертның «Язылып бетмәгән симфония»сен тыңлыйм. Бу симфониядә нинди генә авазлар юк! Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы күченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына... тагын күтәрелә. Йөрәк тә музыкага кушылып тибә башлый. Гафу ит,

Искәндәр, Шубертны тыңлап бетермичә хатымны дәвам итә алмыйм. Янымда утырган җиде яшьлек Кадриям дә:

– Әнкәем, шундый матур музыка... ә син тыңламыйсың, – дип тора.

Улым Рафаэль йоклый. Нинди тыныч йоклый ул. Рафаэль дә, синең кебек үк, учларын яңак астына куеп йоклый. Әнә ул төшендә нәрсәгәдер матур итеп елмайды. Ә без, аналы-кызлы Кадрия белән икәү, Шубертны тыңлыйбыз. Хәер, Кадрия нәрсә уйлый торгандыр – белмим. Ул бик акыллы булды. Күпне белә башлады. Шулай да бала күңелен аңламассың: йә «Әткәем ник озак кайтмый?», йә «Әнкәем иртәгә нәрсә китерер икән?» дип уйлана торгандыр. Без Шубертны эндәшмичә тыңлыйбыз. Бу музыкада сагыну моңы да, ярату-яратмау тавышы да, җил-давыл да – бар да бар. Рәхәтләнеп тыңлыйм әле. Үзәк калалардан бик ерак урнашкан Әдрәс авылында Шуберт симфониясе аеруча матур яңгырый.

Шатлыклы туган илем! Шуберт, Бетховен шикелле композиторларның иң тирән моңнарын ерак авылларга ишеттерүең өчен сиңа җылы рәхмәт яусын.

Искәндәр!

Хатымны дәвам итәм.

1923 ел иде. Ауясыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң мин Казанга килеп чыктым. Казанда университет рабфагына укырга кердем. Бу рабфак ул елларны университет белән бер бинада урнашкан иде.

Беренче дәресләрне тыңлау белән үк мин бәхеттән, шатлыктан нәрсәгә тотынырга белмичә шашып йөри башладым. Рабфакка барганда да, кайтканда да, бик еш: «Шушы урамнар, шушы коридорлар буйлап кайчандыр китап, дәфтәр тотып Ленин йөргән, шул бинада Толстой укыган. Шунда укырга дип яшь Горький хыял корган. Шул бинадан дөньяның атаклы галимнәре чыккан. Мин укый торган бүлмәләрдә аларның да тавышлары яңгыраган», – дип уйлана башладым. Рус әдәбияты буенча кергән укытучы Морозов та беренче лекциясен шул фикерләр белән башлады.

Ә кайчагында университетның ап-ак колонналарына сөялә идем дә, башымны югары күтәреп:

– Иптәшләр, күрәсезме, мин нинди бәхетле... Мин, Чулак Фәхри кызы, Ленин, Толстой укыган йортта укыйм, – дип кычкырып, бик каты кычкырып җибәрәсем килә иде.

Шушындый бөеклеккә ашуыма, тормышка юл табуыма мин шат идем. Ул елларны тормыш минем өчен ал да гөл генә, бөтен бәхетләр бергә, минем йөрәгемә җыелгандай тоела иде. Мин бары тик ирек, матурлык көчен генә хис иттем. Мин үземне чәчәкле бакчада күрдем. Бер сынык икмәк белән ике бәрәңге ашап, алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә мин шат һәм көләч идем. Чөнки мин күзләремне киләчәкне күрергә өйрәтә башладым. Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.

Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым, һәрбер сөю һәм сөелүнең «Эх, яратасы иде, сөясе... сөеләсе иде» дип хисләр ташкан чагы була. Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый. Шомырт та чәчәк ата. Сандугачлар да сайраша. Чияләр дә, вакыты җиткәч, кызаралар, тулылыктан матураялар. Мин дә үземнең матурлык тойгыларыма тулганымны сиздем. Минем дә яратасым, яраткан кешем белән:

– Без нинди бәхетле, безгә шундый рәхәт, – дип тын беткәнче кочышасым килде.

*1935*

*Мөхәммәтша Гомәр улы Мамин 1905 елда хәзерге Мордва Республикасы Зубов Аланы районы Горинка авылында урта хәлле крәстиян гаиләсендә туа. 1918 елга кадәр авыл мәктәбендә, аннан соң Пенза шәһәрендәге укытучылар әзерләү курсларында укый. 1921 елгы ачлык чорында яңадан авылына кайтып, берникадәр вакыт авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнә. 1924–1930 елларда исә укытучы булып эшли. 1930 елда Казанга килә һәм Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә. Студент елларында көндәлек матбугатта әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре белән катнаша башлый. 1936 елда Казан педагогия институтының аспирантурасын тәмамлаганнан соң, М.Мамин шунда әдәбият укыта.*

*Ватан сугышы башлану белән М.Мамин фронтка китә һәм ике ел буе алгы сызыкта фашистларга каршы сугыша. 1943 елның августында Воронеж шәһәре тирәсендә барган сугышларның берсендә өлкән лейтенант М.Мамин каты яралана һәм, шул ярадан савыга алмыйча, госпитальдә вафат була. Ул Воронеж өлкәсендәге район үзәге Воробьевка авылы зиратына күмелә.*

*М.Мамин татар әдәбияты тарихында, нигездә, үзенең «Һади Такташ поэзиясе» исемле хезмәте белән билгеле. Бу хезмәт 1941 елда аерым китап булып басылып чыга һәм Һади Такташ иҗатын тулаем алып тикшергән беренче җитди монография буларак әдәби җәмәгатьчелектә югары бәя ала. Сугыштан соң китапның икенче басмасы да дөнья күрә.*

## ҺАДИ ТАКТАШ ПОЭЗИЯСЕ

*(Фәнни хезмәттән өзек)*

Такташның беренче адымнарында ук пейзаж зур урын алып торганлыкны күреп киткән идек. Ләкин ул чор пейзажлары җитдилек белән бергә моңсулык һәм төрле дәһшәтле күренешләр белән сугарылганнар иде. Мәсәлән, «Газраилләр», «Ачлык патша», «Җир уллары» кебек әсәрләрдәге империалистик сугыш, Гражданнар сугышы чоры күренешләре пейзажлары шундыйлар.

Иҗади яктан формалашып җиткәч, Такташ пейзажларны бөтенләй икенче төстә бирә башлый. Аның пейзажларында шатлыклы тормыш күренешләре зур урын ала; ул, күбесенчә, Октябрьдән соңгы авыл күренешләрен, социалистик кырлар һәм шәһәр күренешләрен гәүдәләндерә башлый.

Такташ пейзажларының характерлы ягы шунда ки, ул аларны коры табигый күренешләр итеп кенә бирми, бәлки иҗтимагый вакыйгаларны ачыклаучы декорация итеп файдалана. Ул аларны йә төп сурәтләр белән чагыштыру өчен, йә әсәрдәге вакыйганың нинди шартларда булуын күрсәтү өчен файдалана. Мәсьәләне ачыграк күрү өчен кайбер мисалларга туктыйк. «Мокамай» әсәренең беренче бүлеген Такташ пейзаж белән башлап китә:

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге онута алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар...
Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары –
Андагыдай шаулый торганнар...

Такташ бу башланышны экспозиция урынында бирә. Монда вакыйганың урыны, шартлары гәүдәләнә. Шушы шартларга нигезләп, ул әсәрнең бөтен композициясен төзи. Анда ике баланың уйнаулары, кичерешләре, авырлык күрүләре бирелә.

Бигрәк тә бу күренешләр аларның соңгы тормышларын чагыштыруда объект булып торалар. Пейзаж вакыйгаларга органик бәйләнеп, аларны ачыклауга хезмәт итә:

Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым.

Бу строфалар һаман кабатланып баралар. Шушы пейзаж белән бәйләп, Такташ бик күп вакыйгаларны искә төшерә. Алар ярдәмендә геройларның тормыш юлы ачыла, һәм алар үткән белән хәзергене чагыштыру нәтиҗәсендә идея эчтәлеген ачуга хезмәт итәләр. Менә пейзаж шундый роль уйный.

Такташ пейзажларында җил, давыл, буран кебек күренешләр зур урын алып торалар, һәм кайвакыт Такташ аларны символик формада да куллана. Мәсәлән, «Давылдан соң» әсәренең исеме символик формада бирелә. «Давылдан соң» революциядән соң дигән мәгънәдә алына. Шагыйрь революциядән соң сыйнфый мөнәсәбәтләр турында язуны максат итеп куя. Пейзажларны материал итеп ала:

«Материалым: Буран,
давыл,
таңнар,
кичәләр», –

дип башлый Такташ һәм табигать күренешләре белән әсәрен бизи.

Бу күренешләр аркылы шагыйрь революциядән соңгы гомуми иҗтимагый тормышны чагылдыру максатын куя.

Пейзажлар «Сыркыды авылы» әсәрендә тагын да зуррак урын алып торалар. Анда җил, давыл хәрәкәт символы урынында кулланылалар.

Бу поэма баштан ахыргача җил-буран күренешләре белән баетылган.

Җил – искелекне җимерүче яңа көчләрнең хәрәкәтенә параллель куелган декорация, ул – тормыштагы хәрәкәтне күзәтү өчен китерелгән җанландыручы элемент.

Такташ, пейзажларны тормыш күренешләренә параллель куйган кебек, кайчакта контраст итеп тә бирә. Шулай ук, җитди төстә бирелгән пейзажлар белән бергә, шаярту характерында кулланылганнары да очрый. Ләкин һәркайсы кирәкле урында файдаланыла. Бу моментлар «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә бик

ачык күренә. Пейзаж поэмада декорация ролен уйный. Монда ай, җил, төнге күренешләр зур урын алып торалар. Бу пейзажлар геройларның кичерешләренә йә параллель, йә контраст куеп биреләләр.

Менә бер вакыйга: Мәхмүт белән Зөбәйдә, очрашып, икәү сөйләшәләр, алар бәхетлеләр, чөнки алар ялгыз түгелләр. Ә ялгызак ай сүгенеп йөри.

Айның ялгызлыгы Мәхмүт белән Зөбәйдәнең бергә яшәүләренә контраст итеп сурәтләнә.

Бу декорацияләр Мәхмүт белән Зөбәйдәнең тормышларын ачыклауга хезмәт итәләр. Чөнки алар вакыйгаларны көчәйтәләр. Тукай:

Яктырак йолдыз янадыр,
Төн кара булган саен, –

дигән булса, Такташ шушы формуланы практик алымга әйләндереп бирә. Айның ялгызлыгы Зөбәйдә белән Мәхмүтнең бергә булуын кабарынкы итеп күрсәтә. Ләкин Такташ поэмада айның ялгызлыгын һәрвакыт контраст итеп кенә куймый, бәлки параллель дә куя. Бу инде Зөбәйдәнең Мәхмүттән аерылганнан соң булган вакыйга эчендә бирелә:

Ай да ялгыз,
Безнең Зөбәйдә дә...
Ул тын гына
Айга карап килеп утырды,
Һаман көлеп йөргән зур күзләрен
Канлы яшьләр белән тутырды...

Такташ бу мәсьәлә буенча үзе болай ди: «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә минем төп элемент ай түгел, бәлки Зөбәйдә белән Мәхмүт. Аларның трагедияле мәхәббәтләре килешү белән бетә. Алар өйләнеп тора башлыйлар, ә ай һаман хатынсыз кала. Ай бөтен поэма буенча декорация, көлке элементы булып бара. Поэманың соңында да ул шулай кала».

*1941*

*Мөсәгыйт Мостафин 1909 елның 25 сентябрендә хәзерге Татарстан Республикасының Баулы районы Бәйрәкә авылында игенче гаиләсендә туа. 1927 елда Бәйрәкә җидееллык мәктәбен тәмамлап Казанга килә һәм рабфакка укырга керә. Шушы елларда ул әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый, очерклар, хикәяләр яза һәм аларны Ютазы район газетасында бастыра. 1931 елда яшь әдипнең Казанда биш хикәясен үз эченә алган «Очрашу» исемле китабы һәм үсмер балалар өчен «Үсү» исемле озын хикәясе басылып чыга. 1932 елда аның «Тыңлыйсыңмы, кордаш?» дигән өченче китабы да дөнья күрә. Үзенең хикәяләрендә һәм нәсерләрендә яшь автор гади хезмәт кешеләренең көндәлек тормышын тасвирларга омтыла һәм җиңелчә юмор белән алардагы искелек калдыкларын тәнкыйтьли. Аның хикәяләре лирик яңгырашлы һәм тел-сурәтләү чараларының халыкчан, образлы булулары ягыннан да игътибарга лаек.*

*Мөсәгыйт Мостафин 1941 елның август аенда үзе теләп фронтка китә һәм шул ук елның 6 декабрендә сугыш кырында батырларча һәлак була.*

## КАРЛЫГАН БАКЧАСЫ

### I

Таулардан төшкән күләгәләр сизелерлек рәвештә озыная баралар. Түгәрәкләнеп үскән карлыган куакларының төпләре эңгер-меңгерләнә. Куаклар куе яшел төскә керәләр. Чикерткәләр дә инде җырлап купшыланмыйлар, кыяк тешләп, кояш батканын көтәләр. Тик ялгыз песнәк кенә, әле бер куакка, әле икенче куакка күчеп, кемнедер юксынгандай сузып-сузып сызгырынгалый. Түбәндә, карлыган куаклары артында, тар гына, ләкин тирән буа бөгәрләнеп ята. Гүя ул көн буе малайлар коендырып арыган да соңгы тапкыр кемнедер каршы алырга әзерләнгән. Аннан да ары төтенләнеп торган басулар китә.

Тирә-якка пешеп килә торган карлыган һәм яшел яфрак исе тарала. Ул ис, бөтен тамырларга үтеп кереп, йомшак рәхәтлек бирә, каннарны уйната. Мин, җәйге табигатьнең кояш баткандагы аһәңенә зәвыкланып, яшел печән белән ябылган куыш буендагы бүтәкә үләннәре өстендә утырам. Бик тәмле итеп папирос тартам, төтен балдаклары җибәрәм һәм әледән-әле авыл башына карыйм. Бүген дә килерме ул, юкмы?

Менә ике көн инде мине ниндидер өметле тынычсызлык чорнап алды. Өченчекөн кич бакчаның буа буендагы карлыган куаклары арасында җимеше күплектән сыгыла башлаган ботакларны күтәреп йөри идем. Кинәт су чапылдаганын ишеттем. Башымны күтәреп карасам, карлыган бакчасына таба бер кыз йөзеп килә иде. Ул мине күреп алуга, яр буена килеп күренеп тә, кинәт су уртасына китеп югалган ак

балыктай, кырт кына борылып кирегә йөзә башлады. Аның артыннан су өстендә тузылган озын чәче генә дулкынланып калды. Ул, аргы як ярга җиткәч, миңа таба каерылып карады да су астыннан күренә башлаган ап-ак муенын, иңбашларын яңадан суга яшерде. Әкрен генә бөтен гәүдәсе белән минем якка таба борылып, йомшак тәпиләре белән битен юган ак песидәй, түгәрәк йөзен юа башлады. Аннан соң су өстенә таралган чәч көлтәсен җыеп алып бик озаклап сыкты. Мин, үземнең кайда икәнлегемне дә онытып, аңа һаман ахмакларча карап тора идем. Мондый вакытта яшь кешенең кайсысында таркаулык килеп чыкмый соң! Аның инде эше дә бетте. Ул, су эчендә башын гына күрсәтеп, туп-туры миңа таба карап тора башлады. Мин, исемне җыеп, аңа уңайсызламас өчен кире борылырга гына торганда, аның матур аһәңле тавышын ишеттем.

– Егет! Минем өстемдә купальный костюм да юк. Сез беразга гына теге якка карый алмассызмы?

Мин бу сүзләрне әллә тыңлап бетердем, әллә юк, әллә ул әйтә башлагач та борылдыммы – анысын хәтерли алмыйм. Тик мин яңадан борылып караганда, ул инде кызу-кызу атлап авылга таба китеп бара иде. Аның ап-ак кулларын кызу адымнарга ияртеп әле алга, әле артка тиз-тиз ташлавы ак күбәләкләр талпынуын хәтерләтә иде.

Икенче көнне дә ул, буа тирәсендә кеше аягы басылгач, берүзе генә килеп, су коенып китте. Ләкин бу юлы мин аны якыннан күрә алмадым. Куышта утырып, каравылчы бабайның әкиятләренә мавыгып, аның кайчан килүен сизми калганмын. Мин куыштан чыкканда, ул инде авылга ук кереп бара иде. Безнең куыш тау кабыргасында булганга, бик ачык чагыла: ул, тыкрык башына кереп китәр алдыннан берничә тапкыр каерылып, безнең якка таба карады. Егет кешенең күңелен канатландырырга шушы җитмимени тагы?! Нинди кыз ул? Кемгә килгән, каян килгән? Мин әле моны белмим. Тик аның бүген дә безнең карлыган бакчасы буендагы буага килеп су коенып китүен, һич тә булмаса, күренеп кенә китүен түземсезлек белән көтәм.

## II

Уйларымнан ничек итеп бушанганымны, кай арада урынымнан сикереп торганымны белмим. Мондый вакытта сүз белән әйтеп бирә алмаслык ашкыну, кызыксыну кешенең ирегеннән ала, хисләр үз эшләрен эшлиләр. Аякларым мине буа буена әйдиләр. Мин, күренмәскә тырышып, карлыган куакларына күмеләм. Минем битемә кызгылт төскә кергән карлыганнар бәрелеп калалар, мин аларга әһәмият бирмим, тик юл буйлап буага якынлашып килүче кызны гына күздән яздырмаска тырышам.

Кинәт мин йөрәккә үтеп керердәй көлү тавышы ишеттем. Бу көлүгә хәтта тын гына яткан буа да сискәнеп, калтыранып куйган төсле булды. Мин, ирексездән гәүдәмне турайтып, аптырап катып калдым. Мин дә яр буена килеп җиткәнмен, ул да нәкъ аргы як ярда басып тора иде. Бу көлүдән мин бөтенләй үземне-үзем җыя алмас бер хәлгә килдем. Кире борылып, күз күргән якка хәлдән таеп егылганчы йөгерү минем өчен күп мәртәбә җиңелрәк булыр иде. Ләкин бу көлү минем аякларга гүя таш такты. Бу хәл тагын да шулай дәвам итсә, мин нишләр идем? Ләкин ул ук мине бу хәлдән чыгарды да. «Моның өчен аңа мең рәхмәтләр булсын», – дип уйладым мин. Ул, рояль тавышы яңрап тынган шикелле, көлүен әкренәйтә барды. Соңгы тапкыр, чәчәк сабагы җилгә сыгылгандай, нәфис гәүдәсен бөгеп сулкылдап алды да тынды. Аннан йомшак кына итеп миңа дәште:

– Ә мин карлыган бакчасына карак кергән икән дип уйладым.

Бу сүзләрдән соң миңа ничектер батырлык кереп китте. Каян башка килгәндер:

– Юк, карак һич юк. Ботаклар җиргә сыгылганнар, шуларны... – дип алдап киттем.

Ләкин ул миңа алдаштырып җәфаланырга ирек бирмәде, иркәлек катыш кискен тавыш белән бүлде:

– Сез алдашасыз.

– Мондый вакытта алдашу – үзе бер ләззәт, – дип ычкындырдым мин аңа.

– Усал икәнсез сез, – дип елмайды ул миңа.

Мин дә, ул да тынып калдык. Сүзнең болай тиз бетүенә мин хафалана башладым. Җебегәнрәк шул мин, кызлар үзләре сөйләшмәсә, дәвам итәргә сүз таба алмый җәфаланам. Шундый вакытта өзлексез сүз табып торырлык, үзе сүз катарга атылып торган ачык кызны рәхәтләндерерлек тә булмагач, нигә мин тел тагып йөри торганмындыр инде. «Сүз бозау имезә» диләр дә бит, ләкин ул башка җирдә, башка вакытта шулай. Монда миңа нәкъ бозау имезерлек озак вакытны алырлык сүзләр табарга кирәк. Бәлки, әле бу минем хатын-кыз тирәсен начар белүемнән, яшьлегемнән, тәҗрибәсезлегемнән килә торгандыр. Һич булмаса, нигә үзе сөйләшми соң ул?! Аның колакка музыка булып яңраган тавышы мине бервакытта да, бервакытта да туйдырмас иде кебек...

Тагын да ул ук алчаклык күрсәтте. Буа буйларына күз сирпеп алды да елмаеп миңа карады:

– Буагыз нинди әйбәт. Тик кырыйлары лай гына. Су коенып чыкканда аяклар пычранып бетә.

Бу чынлап та шулай бит. Көн саен буада быкырдап су коенып ятабыз, ә моңа кадәр шуны да искәрмәгәнбез. Әрекмән белән аякларны корыткан булабыз да шул җитә. Хатын-кыз вак уңайсызлыкларны да бик тиз күрүчән була шул. Ул яктан безнең ирләр халкы тупасрак инде.

– Сез су коенырга телисезме? – дип сорадым мин.

– Шулай уйлап килгән идем дә... – диде ул.

– Әз генә сабыр итегез, – дидем дә буаның түбән ягындагы яр астына атылдым, аякларым җиргә әллә тиделәр, әллә юк. Үзеңнең күңелең тарткан хатын-кызга хезмәт күрсәтү, кечкенә генә нәрсә белән дә аны сөендерү җанга рәхәтлек бирсә, тәнгә батырлык та, җегәр дә кертә икән. Башка вакытта юньләп урыныннан да кузгата алмастай яссы ак ташны нинди көч белән күтәреп алганмындыр, мин аны сизмәдем. Тик, буа өстеннән икенче якка чыгып, аның янына якынлашканда: «Сез нишлисез?! Куегыз, зинһар, куегыз, үзегезне имгәтерсез!» – дигән сүзләр генә колак төбемдә яңгырап торды. Мин аның саен үземдә бетмәс-төкәнмәс көч сиздем. Ташны уңайлы гына урынга китереп салгач, ул тирән көрсенеп куйды:

– Шулай ярыймы соң инде?

Аның күксел күзләре аз гына дымланганнар, ләкин бик тирәннән үзәккә үтеп керердәй очкын сибәләр. Шул ук вакытта ул бу хәлен яшерергә дә тырыша иде. Ул күзләр миңа санап бетерә алмаслык рәхмәт яудыралар иде.

Мин якыннан гына әрекмән яфраклары өзеп алдым да таш өстенә түшәдем.

– Менә хәзер коеныгыз инде, – дип сөйләнә-сөйләнә, үз-үземнән канәгать булып, әкрен генә китә башладым.

Ул минем каршыма килеп төште: мин аның шалкан кебек ап-ак йөзендә ялкынланып уйнаган мәк чәчкәсе алсулыгына карадым, күзләренә карарга көчем җитмәде.

– Беләсезме нәрсә? Ачуланмагыз, карлыган бакчагызны күрсәтегез миңа. Мин кичке бакчаны бик яратам, – диде ул.

Каршы киләмме соң! Миңа һичшиксез яхшы күңелле булып тоелган шундый яшь кызның мөлаемлылык белән тулган мөгамәләсенә таш үзе эрер.

## III

Кояш инде күптән батты, ә без һаман утырабыз. Ул яшел үләннәр өстенә уң кулының очы белән таянган да минем якка авышарак төшкән. Мин аның матур йөзенә карап исерәм, ләкин хәзер инде аның бер генә нәрсәсен дә ачык күрә алмыйм. Төн якынлашудан түгел, ә болай башка сәбәптән минем күзләрем пәрдә белән өртелгән кебек. Әгәр хәзер миңа килеп: «Аның авызы кыек», – дисәләр, һәм бу шулай булса да, мине барыбер ышандыра алмаслар иде.

Офыктагы вак-вак болытларга асылынып калган алсулыклар да эреп югалдылар инде. Безнең һаман кузгаласыбыз килми. Без утырган яшел уйдыкны әйләндереп алган куаклар безгә карап сөенешәләр кебек тоела. Мин аңа бу карлыган куакларын ничек итеп үстерүемне, бакча-түтәлчелек техникумын бетергәч тә монда килеп эшли башлавымны сөйлим. Ул үзенең Бөгелмә шәһәрендә тимер юл мастерскоенда эшләвен, монда бертуган апасына, отпуск вакытыннан файдаланып, кунакка килүен әйтте...

Без бер-беребезгә:

– Элек сез әйтегез...

– Юк, сез әйтегез, – диешеп, матур итеп сатулаша-сатулаша, исемнәребезне дә әйтештек. Моннан соң инде ул миңа «Фәрит» дип, ә мин аңа «Мөршидә» дип дәшешә башладык.

Сөйләшә торгач (минем тел бик нык ачылып киткән иде инде), бер-беребезгә шулкадәр якынлашканбыз, мин моны Мөршидәнең кайнар, шәрә беләгенә чәчләрем тия башлагач кына сиздем. Ул кинәт тураеп утырды да үзенең сары чәченә кадаган тарагына үрелде:

– У-у, Фәрит, чәчләрең тузган синең. Кил, тарыймчы үзләрен.

Мин сабый балаларча аның иркенә бирелдем. Ул, минем каршыма тезләнеп, үргә таба чәчләремне тарарга кереште. Аның яңа гына формалашып килгән күкрәге, нәрсәгәдер чакыргандай, еш-еш бер күтәрелеп, бер төшеп тора, кайнар сулышы йөземә бәрелә башлады. Мөршидә авырттырмый гына минем чәчләремнән тартып шаяртты, мин, гүя авырткандай кыланып, аның кулларыннан тотып алдым... Өстебездән дулап сихерле бәхет өермәсе үттеме, әллә аның янган иреннәреннән мәхәббәт эчеп, акылымны җуйдыммы – берсен дә хәтерләмим. Тик аңымны каплаган томан тарала башлаганда, мин аны да, үземне дә бер-беребезгә сарылган хәлдә таптым. Мөршидә озын керфекләрен әкрен генә какты да күгелҗем уйсулыкта чиксез бәхетлелек белән янган күзләреннән мине көйдереп алырдай ялкын сипте...

Иң элек ул сикереп торды. Берничә адым читкә китеп, ике кулы белән дә карлыган куагына тотынды һәм өзелеп сулкылдый башлады:

– Гафу ит мине, Фәрит! Мин сиңа «карлыган карагы» булып килгән идем, ә син минем йөрәгемне дә, үземне дә урладың. Мәхәббәтем мине тотып бирде, гафу ит мине.

Ул бик каты йөгереп китеп барды, мин нишләргә белми аптырап калдым, күз алдымда карлыган куаклары бөтерелгәндәй булдылар...

*1941*

*Хәйретдинов Мөҗәһит Хәйретдин улы (Х.Мөҗәй) 1901 елда туа.*

*Яшьтән үк әдәбият белән кызыксына, үзе дә шигырьләр яза һәм аларны район газеталарында бастырып чыгара.*

*Х.Мөҗәй гомеренең күп өлешен Совет Армиясе сафларында үткәрә. Ул 1931–1933 елларда Урта Азиядә взвод командиры буларак басмачыларга һәм кулак бандаларына каршы көрәштә катнаша. Бу елларда ул күп яза, шигырьләре, очерклары һәм хикәяләре газета-журналларда, альманахларда әледән-әле басылып тора. Менә шул вакытта Х.Мөҗәй Татарстанда үткәрелгән әдәби ярышта катнаша һәм беренче бүләкне ала.*

*1932 елны Х.Мөҗәйнең «Мылтыклылар» дигән китабы басылып чыга. Х.Мөҗәйнең әсәрләре, әдәби яктан эшләнеп җитмәгән булсалар да, шул еллардагы тормышны, чик саклаучы совет сугышчыларының уй-фикерләрен, Ватанны саклаудагы батырлыкларын чагылдырулары белән үзенчәлекле.*

*Х.Мөҗәй Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Фронт газетасында аның батырлыклары турында язып чыгалар. Алгы сызыкта да Х.Мөҗәй язучылык эшен дәвам итә. Ул фронт хикәяләре, совет сугышчыларының батырлыкларын күрсәткән очерклар, шигырьләр яза. Аларның күбесе «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басыла.*

*Х.Мөҗәй 1944 елның 4 сентябрендә фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә.*

## ЯДКАРЬ

Дәфтәр куенында ялгыз яфрак,
Әйтче, иркәм, кемнең бүләге?
Дәфтәрдәге коры яфрак кебек
Кем саргая, өзелә үзәге?

Йөзләре дә аның,
Йөрәге дә
Шушы яфрак кебек кибәме?
Дәфтәреңә карап, үзеңне дә
Чын мәхәббәт уты күмәме?

*1932*

## МИНЕМ ШАТЛЫГЫМ

Бөдрә чәчле иркәм, шатлыгым син,
Синең өчен яши бу йөрәк.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Бу йөрәгем үзе ник кирәк?
Гөл кебек ал, матур галстуклы
Пионер син, минем шатлыгым.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Яшәвемнең ниткән шатлыгы?
Яңакларың кипкән, әби җаным,
Шатлыгым син күңел түремдә.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Нидер җитмәс иде күңелгә.
Көмеш чәчле бабай,
Шатлыгым син,
Синең өчен ага бу каным.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Боегыр иде төсле шул җаным.
Урманга бай, суга, кырларга бай,
Шатлыгым син, матур Туган ил.

Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Кемгә кирәк, нигә кирәк мин?!
Бөтен шатлык,
Кайнар мәхәббәтем
Үз халкымда, Туган илемдә.
Шулар өчен биреп бөтен дәртне,
Көлә беләм сугыш җирендә.
Көлә беләм,
Шаулап җырлый беләм,
Көрәшләрдә күңел ямь таба.
Күз алдымда каты үлем күрәм,
Җиңә беләм,
Җиңү – мәртәбә!

*Көньяк-көнбатыш фронт*
*1941*

**БҮЛӘК**

*Яулык алдым, аның уртасына*
*Кызыл җептән йөрәк чигелгән.*
*«Дошманнарны җиңеп*
*тизрәк кайт!»*
*Дигән сүзләр матур тезелгән.*

Белмим аның үзен, исемен белмим,
Тик «йөрәге» сүзе алдымда.
Канга сеңеп, изге ант шикелле,
Онтылмаска истә калдылар.

Кич утырып, аның бармаклары
Йөгергәндер җепләр эзеннән.
Белмим, бәлки, җуеп тәкатьләрен,
Түгелгәндер яшьләр күзеннән.

Күз алмасы кебек сөйгән егетен
Өзелеп-өзелеп сагынып куйгандыр.
Кош йөрәге кебек саф йөрәге
Әллә, әллә ниләр тойгандыр.

Яулык алдым, аның уртасына
Кызыл җептән йөрәк чигелгән.
«Дошманнарны җиңеп тизрәк кайт!»
Дигән сүзләр матур тезелгән.

*1942*

**НЕМЕЦ ХАЛКЫНА КОМАНДИР ҺӘМ ШАГЫЙРЬ Х.МӨҖӘЙДӘН АЧЫК ХАТ**

**1**

Сез, Гитлерны тыңлап,
Үзегезне
Гитлер чаклы ук бандит иттегез;
Планетаның тапсыз йөрәгенә
Бомба белән кереп киттегез.
Сез, Гитлерны тыңлап,
Заводларда
Көне-төне корал койдыгыз.

Кулыгыздан кайнар каннар тама,
Чирканмыйча адәм суйдыгыз.
Сез, Гитлерны тыңлап,
Планетаның
Тик бердәнбер гадел иленә
Каракортлар кебек,
Агу чәчеп,
Ябырылдыгыз гөлле җиремә.

**2**

Минем күз алдымда үлгән атлар,
Аяк-башсыз
Кеше гәүдәләре таптала.
Болар сезнең шомлык,
Немец халкы!
Керфегеңне сирпеп бер кара.
Минем күз алдымда
Җимерек шәһәр,
Янган авылларның көлләре.
Бу хәрабәләрне сезнеңме соң,
Йә, әйтегез,
Сезнең күзләрме соң күрмәде?!
Сез, Гитлерны тыңлап,
Шакаллардай
Ташландыгыз минем илемә.
Каракортлар кебек, агу чәчеп,
Ябырылдыгыз гөлле җиремә.
Зөбәрҗәттәй пакь күңелле кызның
Мәсхәрәләп барлык шатлыгын,
Шакшы ләззәт өчен,
Мунчак салып,
Фахешханәләргә тарттыгыз.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сез бөтенләй оят саттыгыз!

**3**

Немец халкы!
Синең язмыш әле үз кулыңда,
Бәр бомбаңны Гитлер башына;
Буржуйларны тотып тиресен туна,
Фашистларның кыр син барсын да!
Үзең койган үткен хәнҗәр белән
Фашистларның тура йөрәген!
Тик шул чакта синең намусың саф,
Тик шул чакта кансыз беләгең.
Минем хатым синең йөрәгеңә
Үткен хәнҗәр кебек керәдер.
Керер шул ул,
Чеметеп, чәнчеп алсын,
Хатымнан шул минем теләгем.
Тыңласаң, шәп,
Әгәр тыңламасаң,
Әйтмәдең дип үпкә булмасын,
Шан-шәүкәтең бетәр,
Фашизмны
Җимереп ташлау өчен кузгалдык!
Минем хатым Гитлер йөрәгенә
Бомба булып төшәр һавадан.

Берлин урамнарын ялкын кочар,
Кярханәләр шартлар яңадан!
Кярханәләр шартлар.
Немец халкы,
Гаебеңне юа алырсың,
Мин ышанам әле,
Киләчәктә
Якын дустым булып калырсың!

*14 декабрь, 1941*

## МАЛАЙ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

*(Парча)*

Ул малайның күзләреннән ут чәчелеп тора төсле.

– Мин сезгә Гитлерны капчыкка салып китерермен, валлаһи, китерермен, – ди ул, шаярып түгел, чын ихласы белән, үзе ышанып һәм безне ышандырырга тырышып әйтә. Әгәр җибәрсәң, бүген үк Берлинга чыгып китәргә әзер тора.

– Йә, аласызмы? Алыгыз инде, – дип тыкырдата, төпләбрәк уйларга да урын калдырмый.

– Нәселем начар түгел, курыкмагыз, атам да, агам да Кызыл Армиядә, агам разведчик, – дип, бер дә сорамасак та, чыгышын, нәсел-нәсәбен, күрше-күләнен, туган-тумачасын мактап китә.

– Теләсә кемнән сорагыз, барысы да мин сөйләгәнне әйтер... «Алыгыз» дип кенә әйтерләр.

– Анаң бармы?

– Бар.

– Бәрәңгегез бармы?

– Бар.

– Икмәгегез?

– Җитәрлек.

– Утыныгыз бармы?

– Утыныбыз да бар.

– Атыгыз?

– Ат?.. Колхозда. Нишләп булмасын.

– Шулай булгач, ни җитми?

– Җитә.

– Ник соң кычытмаган җирне кашып йөрисең, ашап-эчеп, җылы өеңдә рәхәтләнеп тик ят.

– Тик ятудан ни файда бар соң? Тик ятканчы, мин сезгә Гитлерны тотып китерермен. Йә, аласызмы инде?

– Юк, энекәш, яшьрәк әле син, – дим мин.

– Мин үскәнче, бетәр бит ул, – дип, ул миңа текәлеп карап тора.

– Нәрсә бетәр?

– Нәрсә? Сугыш.

– Бетсә соң... бик яхшы.

– Ә Гитлер?

– Гитлер... Ул да бетәр.

– Бетүен бетәр дә...

– Ә соң нәрсә кирәк?

– Мин тотып китермәм бит.

– Син китермәсәң, атаң, абыең китерер.

– Менә мин шуннан куркам да шул. Минем абыем бер генералны тотып китерде инде.

– Яхшы алай булса, бик яхшы.

– Аңа яхшы...

– Ә сиңа?

– Йә... алыгыз инде?

– Тукта, тукта. Боргаланма. Аңа яхшы, ә сиңа ник яхшы түгел?

– Тик... мин...

– Нәрсә син?

– Гитлерның үзен тотармын дип язган идем аңа.

– Ә-ә-ә... менә ничек!

– Шулай шул, мич башында ятсаң, тотып булмый ич аны... Йә, аласызмы инде?

*Хәрәкәттәге армия*
*1942*

*Сөләйман Мифтах улы Мөлекев – сугыш алды елларында әдәбият мәйданына чыгып, газета-журнал битләрендә, күмәк җыентыкларда әдәби әсәрләре белән күренә башлаган, әмма сугыш фаҗигасе аркасында үз тавышларын ныклап ишеттерә алмыйча, гомерләре бик иртә өзелгән яшь каләм тибрәтүчеләрнең берсе. Ул 1920 елның 5 гыйнварында хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районы Пыжмара авылында туып үсә. Җидееллык мәктәпне һәм Алабуга китапханә техникумындагы курсларны тәмамлаганнан соң, 1940 елга кадәр Татарстан авылларында китапханәче һәм укытучы булып эшли. 1940 елның февралендә гаскәри хезмәткә алына һәм Ватан сугышын Көнбатыш Украинада чик сакчысы булып каршылый. Сугышның беренче сәгатьләреннән үк ул алгы сызыкта була һәм 1941 елның сентябрендә Киев өчен барган сугышларның берсендә батырларча һәлак була.*

*Сөләйман Мөлекев авыл табигатенең гүзәллеген җырлаган һәм романтик яшьлекнең хис-тойгыларын гәүдәләндергән бер төркем лирик шигырьләре белән билгеле. Ул шигырьләрдән яшь шагыйрьнең образлы фикердәге зәвыгының шактый югары икәнлеген чамаларга мөмкин.*

*С.Мөлекевнең зур булмаган шигъри иҗатыннан аерым үрнәкләр сугыштан соң «Алар сафта» (1961), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Илең турында» (2000) исемле китапларда урын ала.*

## УРМАН

Урман, урман!
Синең эчеңнән
Күп мәртәбә йөргән бар минем,
Матур җәйдә тиңсез соклангыч
Ямьнәреңне күргән бар минем.
Иртә торып бала-чагалар
Сине күрү өчен омтыла.
Эчләреңә керсәң, ничектер,
Эшләнәсе эшең онтыла.
Сөям сине, сөям, урманым.
Күп кенә бар синдә булганым,
Ятып хәл җыйганым бар синдә,
Йомшак иде яшел юрганың.
Җәй көнендә синнән матур җир,
Күңелле җир таба алмыйм мин.
Үпкәләмә, минем урманым,
Көн дә сиңа бара алмыйм мин.
Мин барырмын әле сиңа бер,
Кошлар симфониясен тыңларга,
Саф һаваңны йотылып суларга,
Көчле тавышым белән җырларга...
Синдә,
Бер агачтан китеп берсенә,
Җырлар җырлап, кошлар күчәләр,
Киң илемдә синдәй урманнар
Безнең өчен гөрләп үсәләр.

*1938*

## КҮЗ НУРЫМ СИН

Күзләрең зәңгәр булганга,
«Зәңгәрем» дип атадым.
Былбылым син, күз нурым син,
Шатлыгым син, аппагым.

Сагындыра әйткән сүзең
Һәм күзең, йомшак кулың.
Күз нурым син, акыллым син,
Өметем син, матурым!

*1939*

## ГӨЛБАНУГА

Сөйгәнем, син аңла, мин сугышта
Ватан тынычлыгын сакладым.
Сөйгән халкым өчен, синең өчен,
Үзем өчен җиңеп атладым.

*1941*

*Хәбра Рахман (Хәбибрахман Габдрахман улы Габдрахманов) 1914 елда хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районы Яңгыл авылында крәстиян гаиләсендә туа. Сигез яшендә чагында әти-әнисез калып, ятим балалар йортында тәрбияләнә. 1930 елда Арча мәктәбенең җиде сыйныфын тәмамлап, авылда укытучы булып эшли башлый. Шушы елларда «Ялчы» дигән крәстиян газетасында аның беренче шигыре һәм хикәяләре басыла.*

*1931–1936 елларда Хәбра Рахман Казанда татрабфакта, аннары дәүләт педагогия институтында белем ала. Институтны тәмамлаганнан соң, аны татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп Алабуга педагогия училищесына эшләргә җибәрәләр. 1938–1940 елларда Хәбра Рахман гаскәри хезмәттә була, Халхин-Голдагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, яралана, шәхси каһарманлыгы өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.*

*Армиядән кайткач, Хәбра Рахман Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр әүвәл Алабуга педагогия училищесында һәм китапханә техникумында тел-әдәбият укытучысы, аннары Алабуга район газетасының мөхәррире булып эшли. Сугыш башлануга, ул фронтка китә һәм, Мәскәү янындагы канлы бәрелешләрнең берсендә авыр яраланып, шул ярадан савыга алмыйча, 1942 елның ноябрендә вафат була. Аның гәүдәсе хәзерге Тверь өлкәсенең Максатиха дигән тимер юл станциясе каберлегенә җирләнә.*

*Хәбра Рахманның әдәби мирасы зур түгел. Көндәлек матбугатта басылган шигырьләрен дә үз эченә алып, 1937 елда аның «Чәчәк ява» исемле бердәнбер мөстәкыйль җыентыгы дөнья күрә. Моннан башка газета-журналларда кечкенә-кечкенә хикәяләре һәм Халхин-Гол вакыйгаларына багышланган «Сугышта» («Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары»), 1940) исемле зур гына очеркы басылып чыга. Сугыш алдыннан ул шулай ук «Шомырт чәчәкләре» исемле повесть язарга керешә, ләкин әсәр тәмамланмый кала. Хәбра Рахман әсәрләренең, бигрәк тә шигъри иҗатының төп эчтәлеген күмәкләшү чоры кичергән яңа авыл тормышы һәм мәхәббәт лирикасы били.*

*Хәбра Рахманның сугыш чоры иҗатыннан аерым үрнәкләр «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961), «Илең турында уйла» (2000) исемле күмәк җыентыкларда урын ала.*

***

Елмаюлы бөдрә дулкыннар
Уйнакласа синең йөзеңдә,
Йөгерек нурлар бердән электрдай
Дөрләп кабыналар күзеңдә.
Уйлар балкый,
Хисләр актарыла,

Шатлык арта минем тагын да,
Йөрәк сикерә, күңел кытыклана,
Каным кайнап котыра тамырда.
Әгәр алсу йөзең томанланып,
Куе кара болыт йөгерсә,
Күз карашың шомлы ачу катнаш
Көчле әрнү белән төренсә,
Чырай сытыла,
Кашлар салына.
Йөрәк чәрдәкләнеп теленә,
Күңел сүрелә,
Йөз кайгыга төренә,
Күңелем моң белән күмелә.

*1932*

**СУГЫШТА**

*(Кызыл сугышчы блокнотыннан)*

Иң кирәк чакта кыр телефоны эшләми башлады. Роталар озакламый атакага ташланачаклар. Пуля яңгыры, осколоклар бураны эчендә алар инде дошман позицияләренә якынлашып киләләр. Артиллерия үзенең утын тагын да көчәйтте. Дошман окоплары арасында снарядлар тагын да ешрак шартлый, тузан өермәләре тагын да күбрәк күтәрелә башлады.

Ләкин нәкъ менә шушы вакытта, нәкъ менә шушы иң җитди, иң җаваплы моментта отделение командиры Голубицкий командалыгы астындагы элемтәчеләр группасының кыр телефоны эшләми башлады. Голубицкий үзе дә, аның иптәшләре дә моның нинди зур нәтиҗәләргә китереп чыгарачагын беләләр һәм телефонның хәзер үк эшли башларга тиешлеген ачык төшенәләр иде. Бит алар ике частьның янәшә хәрәкәт итүче батальоннары арасында элемтә алып баралар, ике частьның бер оператив планы нигезендә бердәм хәрәкәт итүе бик күп дәрәҗәдә аларга бәйле.

Телефонист, трубкага җиңелчә генә өрә-өрә, тагын бер кычкырып карады:

– 24, 24, дим, тыңла әле, 24!

Ләкин батальон штабы җавап бирмәде. Бер-ике минут чамасы телефонисттан күзен алмыйча аппарат янында чүгәләп утырган Голубицкий аз гына урыныннан кузгалып куйды. Аның калын җилкәсе окоп стенасына тиеп китте, окоп эченә шыбырдап балчык коелды.

«Мәсьәлә ачык, – дип уйлады ул эченнән, – 32 җавап бирә, 24 җавап бирми. Димәк, аппарат төзек, 24 ягындагы линия өзелгән, әле генә шул якка тягачлар киткәннәр иде. Шулар өзгәннәр».

Аннары ачык, кискен, ләкин сабыр тавыш белән кычкырды:

– Иптәш Шәрипов!

Янәшә окопларның берсеннән җавап тавышы ишетелде:

– Мин!

Шул ук секундта күрше окоптан чибәр генә бер яшь егет күтәрелде. Аның тулы түгәрәк битендә иртәнге чык кебек вак тир тамчылары җемелди. Куе кара кашлары да, яңа гына төртеп чыгып килгән кара мыеклары да тиргә чыланган. Ул җитез генә өскә сикерде һәм винтовкасын кулына тотып, шуышып Голубицкий янына килде.

– Иптәш Шәрипов, сез хәзер линия буйлап 24 ягына барыгыз, анда линиянең өзелгән урынын табыгыз һәм тизлек белән шуны ялгагыз!

– Есть линияне ялгарга!

– Барыгыз, ләкин тиз йөрегез!

Шәрипов алгарак төшә башлаган граната сумкасын тиз генә янга этәреп куйды да, винтовкасын тагын да ныграк кысып, күрсәтелгән якка таба китте. Алар урнашкан пунктның уң ягында куе яфраклы вак агачлар белән капланган калкулык, ә сул ягында болын кебек тигез җир, калкулыкның аргы ягында шундый ук вак агачлар белән капланган бер үзәнлек бар. Бу үзәнлек борылып-борылып дошман позицияләре ягына барып чыга. Линия менә шушы калкулыкның итәге буйлап бара. Шәрипов башта шуышып вак агачлар арасына керде; аннан, торып, мөмкин кадәр агачларның ботакларын, яфракларын селкетмәскә тырышып, шушы агачлар арасыннан китте. Йөз метрлар чамасы киткәч, калкулык та, аның белән бергә линия дә сулга борыла иде. Шәрипов та шунда борылды. Иптәшләре урнашкан окоплар инде күздән югалды. Ул һәрвакыт үлән өстеннән сузылып барган линияне күздән югалтмады.

Шул рәвешле байтак кына барганнан соң, ул линиянең өзелгән урынын тапты, һәр ике өзек очның башын чистартты. Линияне ялгады һәм ялганган урынны йомшак резина тасма белән төреп эшен

бетерде дә яңадан кире үз пунктларына кайтырга чыкты. Ләкин берничә адым шуышып барырга да өлгермәде, ярыйсы ук якында шартлау тавышлары ишетелә башлады. Ул бер генә секундка туктады, тавышларның граната тавышлары икәнен, аларның үзләре урнашкан пункт ягыннан килгәнен белде. Шартлау арасында кеше тавышлары да ишетелеп киткән кебек булды. Кинәт гәүдәсе буйлап жу итеп нәрсәдер йөгереп киткәндәй булды. Йөрәге тынычсызланды, еш-еш тибә башлады. Ул кәлтә еланы кебек тиз-тиз генә шуышып агачлар арасына керде. Аннары җитез генә сикереп торды да бар көченә үз пунктларына таба йөгерергә тотынды.

Менә граната тавышлары тынды. Аларны шау-шулы кеше тавышлары, ярсулы кычкырынулар алмаштырды. Барган саен тавышлар тагы да ачыграк, тагы да көчлерәк, тагы да ярсулырак булып ишетелде. Менә алар арасында барыннан да ачыграк, барыннан да көчлерәк булып саф русча сүзләр яңгырады:

– Бей гадов!

– Бей крепче!

Шәриповның йөзе тагы да җитдиләнде, тешләре кысылды, иреннәре ачулы кабарды. «Бу – Голубицкий белән линия элемтәчесе Олейнек тавышы бит. Димәк, алар һөҗүмгә тартылганнар!» Шул уй белән ул, иелгән хәлдә агачлар артына яшеренә-яшеренә бар көченә йөгереп бара торгач, бер борылмага килеп җитте. Агачларга ышыкланып, алга, үз пунктларына таба карады.

Алда, аларның окоплары тирәсендә, уналты-унҗиде дошман солдаты – самурайлар кайнаша. Алар берьялгызы калган Голубицкийны чолгап алганнар, шаулаша-шаулаша, әллә ниткән аңлашылмаган сүзләр кычкыра-кычкыра, аңа ташланалар. Голубицкий үзен әкияттәге батыр төсле тота. Үзенә якын килгән кысык күзле самурайларны искиткеч җитез хәрәкәтләр белән бер-бер артлы аудара тора; кайсының күкрәгенә төзәп атып җибәрә, кайсының кабырга араларына дүрт кырлы штыгын батырып ала, кайсын приклад белән бәреп ега. Үзе ярсулы тавыш белән кычкыра:

– Мәгез, явызлар, мәгез, еланнар!

Менә кечкенә буйлы, калын җилкәле, усал һәм хәйләкәр карашлы берсе, бөтен кыланышларына караганда кече офицер яки офицер чины алу өчен тырыша торган солдат булса кирәк, Голубицкийның каршына ук килеп, тесагын аның күкрәгенә сузды. Голубицкий үзенә юнәлгән тесакны яшен тизлеге белән астан өскә таба бәреп җибәрде дә бу хәшәрәтнең үз күкрәгенә кадады, шундый ук җитезлек белән штыгын кире суырып та алды. Самурай ачы тавыш белән кычкырып җибәрде һәм чайкалып-чайкалып әйләнеп төште.

Боларны күреп калган Шәриповның йөзе яктырып китте. Үз командирының, үзенең якын дустының мондый кыюлыгы, мондый җитезлеге, мондый искиткеч батырлыгы аны рухландырды.

Ул, агачлар арасыннан чыгып, командирына ярдәмгә ташланды. Ләкин өлгерә алмады.

Голубицкий тирәсендә тыз-быз килеп, бертуктаусыз кычкырынып һәм сүгенеп йөргән япон офицерының ачуы чиктән ашты булса кирәк, ул кабалана-кабалана артка чыкты, маузерын Голубицкийның аркасына терәде һәм атып җибәрде. Голубицкий бер генә минутка хәрәкәтсез калды, сул кулы салынып төште. Моны күргән самурай солдатлары тагын аңа ташландылар. Голубицкий тагын уң кулы белән винтовкасын югары күтәрде һәм приклад белән уңлы-суллы кизәнә башлады. Ләкин ул үзе дә чайкала башлады. Аннары, уң кулы белән винтовкасын кысып тоткан хәлдә, әкрен генә җиргә ауды. Самурайлар аны сырып алдылар...

Боларны күзәтә-күзәтә самурайлар группасына инде якынлашып килгән Шәриповның ачуы һәм нәфрәте чиктән ашты. Аның тамырлары бүртеп чыкты, күзләрендә дәһшәтле ачу уты кабынды. Ул кискен карарга килде: «Үлсәм үләм, ләкин иптәшләремнең үчен алмый калмыйм!»

Телефон аппараты урнашкан урыннан арырак, калкулыкның түбәсендә, куе агачлар арасында күзәтүчеләр өчен казылган окоп бар иде. Шәрипов, мөмкин кадәр агачларны селкетмәскә, яфракларны шыбырдатмаска тырышып, тавышсыз гына шул окопка якын килде. Окопка төште, гранаталарын чыгарып, окопның алдына тезеп куйды һәм аппарат тирәсендә кайнашкан самурайлар өстенә бер-бер артлы ике граната ыргытты. Гранаталар колак тондырырлык көчле һәм дәһшәтле тавыш чыгарып шартлады. Тузан-төтен өермәсе күтәрелде. Самурайларның берничәсе кыргый һәм ачы кычкырып егылды, калганнары төрлесе төрле якка сибелеп йөгерергә тотынды. Шәрипов алар артыннан тагын бер граната җибәрде. Тагы икесе егылды. Япон офицерының ачулы тавышы ишетелде. Ул, окоптан башын чыгармый гына, маузерын селки-селки нәрсәдер кычкырынды да йөгереп баручы самурайлар артыннан атып җибәрде. Иң алдан йөгерүчеләрдән берсе күкрәген тотып җиргә егылды. Калганнары ятып окоп казый башлады. Шәрипов аларның ешрак урнашкан җирләренә соңгы гранатасын җибәрде. Аларның тагы икесе җиргә йөзтүбән капланды. Граната осколоклары берсенең күрәген читкә алып ташлады. Шәрипов тиз генә японнарны санап алды. Алар әлеге офицер белән бергә бишәү иделәр, ул аларны винтовка белән чүпләргә уйлады. Башын куе үлән арасыннан тыгып, түше белән сузылып яткан хәлдә, окоп казып азапланучы берсенең маңгаена төзәп атып җибәрде. Пуля тиде булырга кирәк, самурай дәшми-тынмый гына җиргә капланды һәм хәрәкәтсез калды. Ул арада офицер, окоптан башын калкытып, нәрсәдер кычкырынды да, кизәнеп, Шәрипов окобына таба граната ыргытты. Шәрипов тиз

генә окопка иелде, винтовкасын үз янына алмакчы булды, әмма өлгерә алмады. Сызгырып баручы осколокларның берсе спусковой механизмны кубарып атты һәм аның әле һаман куроктан алынмаган имән бармагын өзеп китте. Шәриповның окобы тирәсендә бер-бер артлы тагын берничә граната - шартлады. Окоп тирәсе төтен белән тулды. Менә гранаталарның берсе окопның янына ук килеп төште. Шәрипов аны окопка таба тәгәрәп килгән җиреннән искиткеч җитез хәрәкәтләр ясап тотып алды да кире дошманның үзенә ыргытты. Граната самурай окоплары өстендә һавада шартлады. Шәрипов төтен һәм тузан катлавы аша аның тирә-юньгә чәчрәгән кызыл очкыннарын күреп калды. Самурайларның тагы берсе кычкырып куйды.

Озакламый самурайлар граната ыргытудан туктадылар. Кинәт бөтен тирә-як тынып калды. Бу тынлык Шәриповны шиккә төшерде. Ул җентекләп алга һәм як-якка карады. Ләкин, көн җилсез булганлыктан, вак агачлар арасында төтен һәм тузан әле таралмый иде. Кинәт аңа уң якта җиңелчә генә кыштырдау һәм коры вак балчыкның шыбырдап коелып китүе ишетелеп калды. Каршыда да шундый ук шикле кыштырдау тавышлары кабатланды. Ул самурайларның, гранаталар күтәргән тузаннан файдаланып, үзен тиз генә чолгап алырга маташуларын сизде. Уң яктагы кыштырдау тавышлары якынлашканнан-якынлашты. Шәрипов, прикладсыз һәм спусковой механизмсыз калган винтовкасын алып, окоптан өскә сикерде дә уң яктагы куе яфраклы агачлар төркеме артына кереп посты. Ул ара да булмады, инде тарала башлаган тузан һәм төтен томаны арасыннан сак кына атлап, як-ягына карана-карана бер япон солдаты килеп чыкты һәм Шәрипов поскан агачлар төркеменә таба килә башлады. Шәрипов аның каршына килеп чыкты. Самурай каушап китте, ләкин шунда ук тесагын Шәриповның күкрәгенә таба сузды. Шәрипов, Голубицкий кебек үк җитез хәрәкәтләр ясап, үзенең прикладсыз винтовкасы белән тегенең мылтыгын бер кырга бәреп җибәрде, шунда ук үз штыгын дошманның күкрәгенә батырып алды. Самурай ачы тавыш белән кычкырып куйды һәм чайкалып ава башлады.

Шәрипов прикладсыз винтовкасын агачлар арасына ыргытты һәм, егылып җитүен дә көтмәстән, тегенең кулыннан мылтыгын тартып алды да яңадан вак агачлар төркеме артына сикерде. Кинәт ату тавышы ишетелде, сул колак яныннан каты сызгырып һәм колак яфракларын көйдереп пуля үтеп китте. Чигә буйлап муенга таба ниндидер җылы, йомшак һәм юеш нәрсә шуып төшә башлады. Шәрипов тиз генә як-ягына карап алды. Каршыдан аңа таба маузерын төзәгән, ачудан тагын да ныграк кара янган офицер һәм аннан аз гына артта, мылтыгын алга сузып, петлицаларына икешәр сары йолдыз кадаган бер япон солдаты килә иде. Шәрипов, агачлар артына яшеренеп, мылтыгын офицерга төзәде. Шулчак сул яктан көчле, калын тавыш ишетелде:

– Ташла маузерыңны, кулларыңны күтәр!

Шәрипов та, офицер да, теге самурай солдаты да тавыш килгән якка борылып карадылар. Анда, вак агачлар төркеме артында, кызыл йолдызлы каска күренеп китте һәм куе яфраклар арасыннан дүрт кырлы штык сузылып килеп чыкты да офицерның күкрәгенә төзәлде. Офицер аз гына сизелерлек рәвештә агарынып китте, маузерын тиз генә шушы винтовка ягына төзәде. Ләкин нәкъ шул секундта офицерның уң ягындагы агачлар артыннан кызыл йолдызлы каска кигән тагын бер егет сикереп чыкты һәм офицерның маузерын бәреп төшерде. Маузер шартлап атылып китте, ләкин беркемгә дә тимәде. Шәрипов мылтыгын офицер артыннан килгән солдатка төзәде, тегесе, мылтыгын ташлап, кулларын күтәрде.

Шәрипов яңа килгән кызылармеецларны таныды. Алар резервтагы элемтәчеләрдән Григорьев белән Костюкевич иде. Өчәүләп офицер белән солдатны чолгап алдылар. Шәрипов аларның һәр икесен дә тентеде һәм кесәсендәге резина тышлы запас линия чыбыклары белән һәр икесенең кулларын артка каерып бәйләде.

– Бик әйбәт. Болай бәйләгәч, самурайларның кояш алласы үзе дә кулларын ычкындыра алмас инде, – дип куйды.

Григорьев белән Костюкевич елмайдылар. Офицерның кашлары җыерылды, аксыл иреннәре аз гына дерелдәп куйды.

Эш беткәч, Григорьев Шәриповка дәште:

– Ә отделение командиры кайда? Фәрдиев белән Олейнек кайда?

Шәрипов ни өчендер бераз уңайсызланып китте. Кашлары түбән салынды. Ул тирән итеп бер сулап куйды. Шуннан берничә сүз белән генә күргәннәрен сөйләп бирде. Ахырдан өстәп куйды:

– Группа башлыгы булып мин калдым.

Григорьев аңа үзләренең ни өчен килгәнен аңлатып бирде:

– 24 не чакырып-чакырып та сездән җавап ала алмагач, безне сезнең карамакка җибәрделәр. Үзебез белән запас аппарат та алып килдек.

Шәрипов аларның нәкъ шушы моментта килеп җитүләренә бик шатланды.

– Иптәш Григорьев, сез хәзер үк үзегез алып килгән аппаратны алыгыз да һәр ике як белән элемтә урнаштырыгыз!

Григорьев чыңлап торган ачык тавыш белән җавап кайтарды:

– Есть элемтә урнаштырырга!

һәм тиз генә, үзе килеп чыккан агач төбендәге аппаратны алып, окопларга таба йөгерде.

Шәрипов Костюкевичка таба борылды:

– Сез менә бу кошларны штабка илтеп тапшырыгыз! Үзегез тиз генә кире килегез.

Костюкевич та, Григорьев кебек үк, ачык тавыш белән приказны кабатлады һәм офицер белән солдатны штабка таба алып китте. Шәрипов, кулындагы яраларны бәйли-бәйли, аның артыннан искәртеп калды:

– Кире килгәндә, линияне карый-карый кил! Тагы берәр җирдән өзелеп-нитеп куймагае.

Ул окоплар янына – үзенең сөекле командиры һәм якын дусларының гәүдәләре янына юнәлде.

Менә калкулыкның итәгендә, үзенең окобы янында ук, аның якташы телефонист Фәрдиев ята. Граната осколоклары аның маңгай сөяген ваткан һәм күкрәген яралаган. Димәк, самурайлар, агачлар артына яшеренеп, калкулыкның аргы ягындагы үзәнлек буйлап килгәннәр дә калкулык өстеннән торып граната ыргыта башлаганнар. Гранаталар күбрәк Фәрдиев окобы тирәсендә шартлаган булса кирәк.

Фәрдиевтән бераз арырак, йомшак үлән арасында, линия элемтәчесе Олейнек ята. Осколоклар аның сул як балтырын һәм сул як битен яралаган. Күкрәге ике җирдән кадалган. Ул чалкан егылган, шулай да винтовкасын кулыннан ычкындырмаган. Кинәт Шәриповның күзләре аның штыгына төште. Олейнекның штыгы төбенә кадәр канга буялган, шулай ук винтовка стволына һәм мушкасына да кан тамчылары чәчрәгән. Алар инде бераз кибә дә башлаган. Димәк, Олейнек яраланганнан соң да бер яки берничә самурайны кадарга өлгергән.

Шәрипов аларның һәр икесе янында да берничә секунд тукталып торды. Иелеп аларның маңгайларыннан үпте. Аннан Олейнектан уңдарак һәм арырак ята торган Голубицкий янына килде. Әкрен генә аның янына чүгәләде: күкрәгенә һәм битенә кунган чебеннәрне куып җибәрде. Аннары, иелеп, маңгаеннан һәм иреннәреннән үбеп алды. Голубицкийның аксыллана башлаган иреннәре кинәт чак кына сизелерлек дерелдәп китте. Күз кабаклары да аз гына селкенеп куйгандай булды. Шәриповның йөзе яктырып китте, күзләренә шатлык очкыннары кабындылар. Ул, монда артык тавышланырга ярамаганлыгын да онытып:

– Исән! – дип кычкырып җибәрде. Тиз генә аның сул як иңбашы һәм уң як күкрәгендәге яраларын бәйләде. Шул ара да булмады, окоптан Григорьевның чатнап торган тавышы ишетелде:

– Иптәш группа башлыгы, мин элемтәне өр-яңадан урнаштырдым. 32 белән 24 нең берсеннән икенчесенә ашыгыч мәгълүматлар һәм приказлар тапшырдым. Хәзер 24 сезне телефонга чакыра.

Телефонда Шәрипов белән үз батальоннарының элемтә начальнигы Николаенко сөйләште. Шәрипов берничә сүз белән генә мондагы хәлләрне – Голубицкийның исән, ләкин каты яраланган булуын әйтте, һәм ашыгыч рәвештә санитар машинасы җибәрүләрен сорады. Үзе тиз генә яңадан Голубицкий янына килде.

Ул килгәндә, Голубицкий инде күзләрен ачкан, әле нәрсә булганын төшенеп җитмәгән төсле аптырап, як-ягына карана иде. Шәрипов аның янына тезләнде:

– Су эчәсегез килмиме, иптәш командир?

– Бик килә, – диде Голубицкий һәм Шәриповның флягасыннан йотлыгып-йотлыгып су эчте. Битенә дә алсу төс йөгерде. Кинәт ул нәрсәнедер исенә төшергән кыяфәт белән Шәриповка текәп карады:

– Элемтәне яңадан урнаштырдыгызмы, иптәш Шәрипов?

– Урнаштырдык, иптәш командир. Хәзер һәр ике як белән дә әйбәт сөйләшәбез. Дошман бандасы юк ителде, – дип җавап бирде Шәрипов һәм эчке дулкынлану тавышы белән өстәп куйды, – сез гаҗәп яхшы сугыштыгыз, иптәш командир, гаҗәп яхшы. Мин күреп тордым!

Ул арада санитар машинасы да килеп җитте.

Машинадан хәрби врач белән санинструктор сикереп төштеләр. Хәрби врач Голубицкийның яраларын карады.

– Кан күп киткән, – диде ул. – Шулай да терелер. Кан җибәрербез.

Алар үзләре белән алып килгән запас бинт белән аның яраларын бәйләделәр дә җайлап кына носилкага салдылар. Носилканы машинага кертеп куйдылар. Үлеләрне җыю өчен махсус машина җибәрергә булып китеп тә бардылар.

Озак та үтмәде, роталар атакага ташланды, көчле ура тавышы бөтен тирә-юньне яңгыратты. Бер ярты сәгатьтән соң әле самурайлар хөкем сөргән сопкаларда берсеннән-берсе матур булып кызыл флаглар җилферди иде инде.

*1939*

*Рәхим Саттар (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров) 1912 елның 15 августында Башкортстан Республикасының Чишмә районы Түбән Хаҗәт авылында игенче гаиләсендә туа. Ул балачактан ук әдәбиятка гашыйк булып үсә, дүртенче сыйныфта укыганда шигырьләр яза башлый. Авылдагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач, туган төбәгендә төрле эшләрдә эшли, шигырьләр язуын дәвам иттерә. Шул елларда Башкортстан һәм Татарстан көндәлек матбугатында аның яшьлек*

*хисләре белән өртелгән беренче лирик парчалары басылып чыга.*

*Урта мәктәпне Р.Саттар Уфа шәһәрендә тәмамлый. Татар теле һәм әдәбияты буенча дәресләрне анда Нәкый Исәнбәт укыткан була. Бу хәл егетнең иҗат эше белән шөгыльләнү хыялын тагын да ныгыткан булса кирәк. Урта мәктәпне тәмамлагач, Р.Саттар төрле җирләрдә йөри, Донбасска барып эшләп кайта, Башкортстанның Учалы районында урман кисү эшендә дә чыныгу ала. Шунда эшләгәндә, 1932 елны, ул гаилә корып җибәрә, бераздан исә армиягә алынып, Байкал чик буе гаскәрләрендә хәрби хезмәт вазифаларын үтәп кайта.*

*1937 елда Р.Саттар гаиләсе белән Казанга күчеп килә. Берникадәр вакыттан соң күңеленә яраклы эш тә таба: «Кызыл яшьләр» газетасында (хәзерге «Татарстан яшьләре») әдәби хезмәткәр булып эшли башлый, сугыш алды елларында газетаның җаваплы мөхәррире урынбасары вазифаларын башкара. Бер үк вакытта аның иҗат активлыгы да арта: газета битләрендә яшьләр тормышына багышланган мәкаләләре, очерк язмалары, шигырьләре, әдәби тәрҗемәләре басыла.*

*Ләкин сугыш афәте тыныч тормыш агышын да, иҗат хыялларын да кискен үзгәртә: 1941 елның җәендә Р.Саттар үзе теләп фронтка китә. Десантчы сыйфатында ул фашистлар тылында үткәрелгән күп кенә сугышчан операцияләрдә катнаша. 1942 елның маенда булган шундый операцияләрнең берсендә чолганышта калып, Р.Саттар фашистлар кулына эләгә һәм, берничә ай Смоленск, Борисов шәһәрләрендәге хәрби әсирләр лагеренда газап чиккәннән соң, Берлин янындагы Вустрау лагерена озатыла. Шунда ул Абдулла Алиш белән очраша һәм озакламый Муса Җәлил һәм аның иптәшләре тарафыннан оештырылган антифашистик оешманың иң ышанычлы әгъзаларыннан берсе булып китә. Ул әсирләр лагеренда һәм мәгълүм «Идел-Урал» легионында антифашистик листовкалар язып таратуда актив катнаша. 1943 елның август аенда яшерен оешма фаш ителеп, җәлилчеләрне кулга алганда, Р.Саттар да шул исемлектә була, әмма ул, үзе сизенепме яисә җае чыгыпмы, 1943 елның июнь аенда ук лагерьдан качып китә. Аның шуннан соңгы язмышы әлегәчә билгесез.*

*Р.Саттар 1942–1943 елларда Смоленск, Борисов, Вустрау, Радом һәм Берлиндагы хәрби әсирләр лагеренда чагында да шигырьләр яза. Ватанны, туган җирне сагыну, фашистларга нәфрәт хисләре белән сугарылган шундый шигырьләрнең ике дистәгә якыны («Ант», «Шөһрәт», «Әнкәмә хат», «Әсирләр», «Халкым өчен», «Бүленгән җыр», «Очрашу» һ.б.) «Тоткынлыкта» исемле кульязма җыентык рәвешендә туган илгә дә кайтып ирешә һәм берничә тапкыр матбугатта басылып чыга. Әдипнең зур булмаган шигъри мирасыннан үрнәкләр «Җыр дәвам итә» (1966, 1985) исемле җыентыгында, шулай ук рус теленә тәрҗемәдә «Три поэта-воина» (1979) исемле китапта да нәшер ителә.*

**ХАЛКЫМ ӨЧЕН**

Көнчыгышта алсуланып
Ата ал таң.
Күккә калкып таулар күренә,
Гүя калкан.

Алга карыйм.
Анда ята томан һаман.
Ерак Туган илдә яши
Газиз анам.

Коралдашлар яу кырында!
Кайда соң мин?
Кем мин сиңа, ятиммени?
Әйт, Туган ил!
Бар хәсрәтең, бар михнәтең
Миңа уртак.
Син генә сук, син иркәлә,
Син мине как.

Ләкин син бел: һәр сулышым,
Барлык көчем
Синең өчен, Туган илем,
Синең өчен!

## РУХЫМ ГАЛИ

Тәрбияләдең мине горур итеп,
Баш имәдем әле буй җитеп
Бер дошманга, иркен тын алам:
Кулда богау, капка йозакта,
Ләкин рухым иркен, хөр кала.

## ШӨҺРӘТ

Данны кулга алып сизеп булмый,
Күреп булмый аны күз белән.
Күкрәкләргә таккан калай түгел,
Әйтү мөмкин түгел сүз белән.

Егет яуга бара...
Командиры
Дан турында сөйли аңарга.
Ләкин аңламый ул, хис табалмый
Шөһрәт уты белән янарга.

Нәрсә ул дан? Нигә? Кемгә кирәк?
Сугышта да шулай уйлый ул.
Ярсып-ярсып һөҗүм итә егет –
Канга баткан инде ике кул.

Кешелеген җуя, арыслан сыман
Ташлана ул дошман ягына!
Үзе уйлый:
«Бакса иде иркәм
Мин ясаган мәет тавына!..»

## АНТ

Мин бу антны ОСТ лагерен күреп,
Аның соры ташы өстендә
Бирәм киләчәккә, бирәм илгә,
Коллык сөйрәп йөргән бер көндә.

Ләкин дошман белсен минем көчне,
Дошман белсен минем ачуны.
Мөмкин түгел, дуслар, мөмкин түгел
Халык нәфрәтеннән качуы.

Дошман белсен минем күкрәгемдә
Нинди ачу, нәфрәт ятканын.
Мин сизәмен шушы нәфрәтемнең
Нәфис булып чәчәк атканын.

## ӘНКӘМ

Бәлки, син дә хәсрәт чигәсеңдер,
Сатылган, дип, улым дошманга.

Юк хәбәргә һич тә ышанма!

Аяк бәйле бүген, кул богаулы,
Ашар ашлар, ширбәт агулы,
Торак суык, ләкин тәмугы
Ул гомернең. Канат кагуы
Бирелә мөмкин түгел күңелгә,
Хәсрәт ята бүген күңелдә.
Талпынса да күңел, ни файда бар
Батырларын җуйган иленә?!
Тагын кылыч тагып биленә,
Чыксаң иде дошман янына,
Байрак кагып көрәш тавына!

Дөрес түгел, ялган хәбәр ул,
Балаңа бер иманыңда бул!
Сиңа биргән изге антында,
Туган илнең ирке хакына
Биргән антын бозмас халкына!

*1942–1943*

*Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов) 1906 елның 10 октябрендә элекке Самара губернасы (хәзерге Ульянов өлкәсе Чардаклы районы) Татар Колмаеры авылында крәстиян гаиләсендә туа. Башта үз авылларында укый, аннан Самара шәһәрендәге Татар-башкорт педагогия техникумында белем ала. Шунда укыган чагында шигырьләр яза башлый. 1926 елда Казанга килеп, татрабфакка укырга керә. Шул елларда ул көндәлек матбугатта актив языша. 1929 елда инде аның «Тальян» исемле беренче шигъри җыентыгы, аннан соң, озак та үтми, «Бояр урманында» (1930), «Металл тавышлары» (1931) дигән җыентыклары басылып чыга. Шушы беренче китапларында ук ул үзен образлы фикерләүдә, тасвирда һәм шигъри формада үзенчәлекле, оригиналь стильле әдип итеп таныта.*

*Узган гасырның 30нчы еллар уртасында Д.Фәтхи Ерак Көнчыгышка китә һәм сигез елга якын төрле җирләрдә гади эшче булып эшли. Бу чор шигырьләрендә ул алтын рудникларында эшләүче эшчеләр тормышын, революция алып килгән тарихи үзгәрешләрне һәм Себер табигатенең матурлыгын сурәтли. Алтын казучы шахтерларның инкыйлабка кадәрге газаплы тормышын һәм күмәк хезмәт шартларында социаль аңнары үсүен реалистик картиналарда тасвирлаган «Алтын тайга трагедиясеннән» исемле поэмасы (1939–1940) шагыйрь иҗатында үзенең эчтәлеге, эмоциональ көче һәм тел-сурәтләүдәге шигъри образлары, көтелмәгән чагыштырулары белән аеруча күренекле урын алып тора.*

*Сугыш алдыннан Д.Фәтхи Татарстанга кайта һәм Зеленодольск шәһәрендә производствода гади эшче булып эшли, 1941 елда ул фронтка китә. Сталинград янындагы сугышларда катнаша, берничә тапкыр яралана; совет гаскәрләре белән бергә дошманны куа-куа Украина чикләренә кадәр барып җитә һәм 1943 елны Кантемирово (Воронеж өлкәсе) янындагы сугышларның берсендә батырларча һәлак була.*

*Шагыйрьнең сайланма шигырьләре, поэмалары һәм хикәяләре «Һәрвакыт сафта» исемле җыентыкта (1970) урын ала.*

*Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән язучы-солдат буларак Д.Фәтхинең исеме Татарстан Язучылар берлеге бинасына куелган мемориаль тактага языла.*

## ЯУЛЫКЛЫ ИНЖЕНЕРГА

Кайсы елның нинди ае калыккан,
Нинди ландыш үскән кайсы тугайда,
Кай чишмәләр шаулап аккан
Синең исемең җиргә туганда.

Зифа камыш калкып үскән күлдә
Үрдәк бәбкәләрен каулап йөргәнсең,

Җил тирбәгән ак кылганнар белән
Толымнарың тарап үргәнсең.

Кулларыңа әлифбалар кысып,
Кай мәктәптә укып йөргәнсең.
Кышкы төннәр китапларга күмелеп,
Кайсы вузга сынау биргәнсең.

Инженерлык дипломнарын алгач,
Ничек ашкынгандыр синең йөрәгең.
Белмим,
Моңар чаклы үткән көннәреңне
Берсен дә мин үзем күрмәдем.

Фабрик цехларында беренче кат
Исәнләштек, артык сүзләр булмады.
Киенгәннәрең бик гади иде,
Цехтан цехка кереп югалдың.

Тимер сыртлы саглам күперләр,
Небоскреб, чиксез заводлар,
Айга очар башсыз ракеталар
Эшче инженер адресына язылган.

Әнкә булып бала тудырганда,
Тик бәхетле еллар өчен үстерсәң,
Балаңа да әнкә-инженер бул син,
Шул төзелештәй матур үссеннәр!

*1930*

## АТЫШ ТЫНГАН МИНУТЛАРДА

Кичке атыш тынган минутларда,
Казан, сиңа сагынып хат язам,
Гади бер солдатның хаты итеп
Каршы ал һәм яз, Казан!

Кайсы гына адресына җибәрсәм дә,
Почта кемгә илтеп бирсә дә,
Кайсы гына гражданың укыса да,
Кемнән генә җавап килсә дә, –
Барыбер. Иске дуслар сыман
Язышырбыз. Чөнки бу көннәр
Кош теледәй хат та халкыбызның
Зур бердәмлек байрагы булып җилфердәр.

Дары исе сеңгән конвертыма
Йөрәгемнең бер бөртеген саламын,
Һәм ул илтер
Волга яры – Сталинград сугышларын
Кичкән сугышчының сагыну сәламен.

Син алып бар Дон суларын үткән
Сугышчының иң кадерле уйларын,
Почмагына кунган тузан хәтерләтсен
Украинага илткән сугыш юлларын.

Син хәтерләт Төньяк Донец суын
Сугышып кичкән канлы таңнарны,
Сандугачлы урманнарны буйлап
Тынмый йөргән туплар яңравын.

Туган илнең өч елгасын кичтем,
Һәр елгада тамды минем кан.
Якты теләк, батыр уйлар белән,
Карт Днепр, карыйм сиңа Донец ярыннан.

Атыш кыза. Хатым тагын бүленә,
Куллар тагын миномётка ябыша.
Хат бүленми! Юллар дәвам итә
Шаулап киткән мина тавышында.

*1943*

## ЯЗ КҮРЕНЕШЛӘРЕ

Еракларда тау сыртлары карала башлаган инде. Акбүзгә чиккән канва җебедәй яткан урманда тонык зәңгәр сөрмәләнгән кебек күренә.

Ә кешеләр, кар күкрәгенә бата-бата, яз хисләре белән урамнардан ашыгып үтәләр.

Өй кыекларына сырышкан карлар кояшка туры карый алмыйлар, эриләр, чып-чып тамалар. Кичләрдә тагын чулпыланып, көзгеләнеп туңалар. Көндезләрен тагын чып-чып чыпылдыйлар...

Һава нинди иркен! Шуңарга бөркелеп чыккан гудок тавышы кайларга чаклы яңгырап китә дә зыңлап кире кайта. Мин аннан тормыш язларының симфониясен тыңладым.

Шаулап капкадан чыккан фабрик кызлары шаркылдашып көлделәр... Әй көлделәр... Аларның шыңгыраган тавышлары урамнарга сыя алмады.

Урамнарда – табигать язы, кешеләрдә – тормыш язы.

Кыекларда гөлдерәшкән күгәрченнәрне күргәч, зәңгәр диңгезләр артыннан безгә кайтыр кошларны хәтерләдем. Алар юлдалардыр...

Ә бүген шәһәр өстеннән бер кошның, канат җәеп, үз артыннан тасмаландырып, зәңгәр төтен бөркегәнен күрдем.

Ул бит гаҗәп мәнзарәле Италия, Бәхре Сәфит ярларыннан түгелдер.

Аның туган җире кызыл кирпечле, шау-шулы заводлар күкрәге бит! Безнең шәһәргә кунакка килгән. Оча алмасам да, аның артыннан минем хисләрем еракларга-еракларга таба җилкенделәр.

Урамнарда табигать язы, безнең кешеләрдә тормыш язы.

Бу шулай түгелме соң?

Май төннәрендә сиреньнәргә күмеләчәк шәһәр бакчасы аша яз, яз хисләрем белән исереп үттем бүген мин.

*1928*

*Исмәгыйль Шәфи улы Шәфиев 1913 елда Башкортстан Республикасының Кыйгы районы Үрге Кыйгы авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа. 1929 елда туган авылындагы җидееллык мәктәпне һәм 1933 елда Уфа педагогия рабфагын тәмамлаганнан соң, 1935 елга кадәр Кыйгы МТСы газетасында, аннары шул районның төбәк газетасында редактор урынбасары булып эшли. 1935–1937 елларда Ерак Көнчыгышта армиядә батарея командиры булып хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан укытучылар институтында укый, соңыннан Татарстанның Сарман районы Зур Нөркәй авылына укытучы итеп җибәрелә.*

*И.Шәфиев көндәлек матбугатта басылган лирик шигырьләре белән сугыш алды елларында үзен өметле яшь шагыйрь итеп танытып өлгерә. 1941 елның язында ул Татарстан китап нәшриятына (ул вакытта Татгосиздат) бастырыр өчен үзенең беренче шигырьләр җыентыгын да тапшырган була, ләкин сугыш башлану сәбәпле, җыентык дөнья күрми кала.*

*И.Шәфиев – Такташ поэтик мәктәбе йогынтысында яза башлаган шагыйрьләрдән. Вакыйга-күренешләрне җанлы, динамикалы итеп күрсәтү, лирик җылылык, музыкальлек – аның шигырьләрен матурлый торган үзенчәлекле сыйфатлар.*

*Аның сугыш вакытында язган шигырьләре фронт газеталарында һәм Казанда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә басыла.*

*И.Шәфиев Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә һәм лейтенант-танкист сыйфатында күп кенә сугышларда катнаша. Ул 1943 елның 17 сентябрендә Смоленск өлкәсенең Кузьмиченко авылы янында батырларча һәлак була.*

*Сугыштан соңгы чорда яшь шагыйрьнең иҗатыннан аерым үрнәкләр «Татар поэзиясе*

*антологиясе»ндә (1956) һәм «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) исемле күмәк җыентыкларда басылып чыга.*

## ПОЕЗД ЧИККӘ БАРА

Станция. Шау-шу.
Халык тузгый.
Тула бара һәрбер буш вагон.
Бер ялкыннан янган ике йөрәк
Соң кат сарылдылар, хушлашып.

– Кызыл Армиягә! –
Роза көләч,
Матур елмаялар иреннәр.
Роза моңсу, –
Аерыла ул бердәнбереннән.

– Юк, боекма,
Егетем китте дип,
Шат яшә син,
Минем алтыным.
Кайда булсам да мин,
Сүрелмәс ул –
Һич сүрелмәс йөрәк ялкыны!

Әлим китте.
Озатканда,
Роза калды карап, каерылып.
Сылу кызга
Батыр егеттән,
Их, авыр шул, авыр аерылу!

Поезд китте.
Зәңгәр болыт кына
Ятып калды поезд юлына.
Әлим китте,
Сагынып сөйләр өчен
Рәсме калды Роза кулында.

Зәңгәр шәлен болгап,
Поезд җилә,
Ерак чиккә чаба паровоз.
Цехлар, басулардан яңа алмаш
Границага алып бара ул.

Вагоннар шат,
Гармун ярсып уйный,
Шаулы җырлар ерак тарала.
Эшелон гөрли...
Юлда чибәр кызлар
Яулык болгап озатып калалар.

Әй, батырлар иле, сөекле ил,
Чигең ерак синең,
бик ерак!
Шатлык ташый синдә,
Тормыш кайный,
Җыр яңгырый бөтен җирне урап.

Тәрәзәмне ачып карап барам:
Урал,
Байкал,
Амур буйларын.
Күпме сарылсам да,
Илебезнең
Матурлыгын карап туймадым.

Поезд бара...
Зәңгәр шәлен болгап,
Границага чаба паровоз.
Арысландай көчле егетләрне
Ил сакларга алып бара ул.

*1936*

## ТУКАЙ БЕЗНЕҢ БЕЛӘН

Стенада рәсем, һәрберәүгә
Таныш та ул, бик-бик якын да.
Күргән саен никтер шул рәсемне,
Сүз башлана аның хакында.
Мин сөйләмим аның кем икәнен,
Ул рәсемне таный бала да.
Күрше карты аны саклык белән,
Хөрмәт белән кулына ала да
Сөйләп китә:
– Их, Габдулла!
Исән булсаң,
Аркаңнан гел сөеп кагарга!
Менә егет,
Менә лачын идең!
Тик рәсемең калды карарга...

О, ялган бу! Тукай үлдеме соң?
Үлем бармы андый шагыйрьгә?
Син киләсең атлап безнең белән
Зур депутат булып шигырьдә.
Син Пушкинны мәңге аерылмаска
Кочагыңа кыскан шикелле,
Киң Союзның һәрбер милләтен
Син кадерле, таныш, сөйкемле.
Син йөрисең әле дә безгә булышып
Яшәү, иҗат, көрәш эшендә,
Сине үрнәк итеп,
Синең белән
Горурланып яши кешеләр.

Син үлмәгән.
Сине туган илең
Биек трибунага бастырды.
Яшә, шагыйрь! Сиңа мәңгелеккә
Тапшырдык без Совет паспортын.

*1941*

## ТУГАННАРЫМА

*(Фронттан хат)*

Сез еракта. Ә без сугышка да
Сезнең хакта уйлап барабыз.
Сезнең алда соңгы сулышкача
Турылыклы булып калабыз.
Көне-төне пуля, мина ява –
Ут яңгыры өскә коела;
Бомба ярчыклары сезнең янга
Барып җитәр төсле тоела.
Якты киләчәкне саклау өчен
Күкрәкләрдән дивар корабыз...
Үлсәк үләбез без: дошман явын
Сезгә узгармыйбыз – кырабыз!

Сау булыгыз! Сәлам Урал тауга!
Фатихада булсын улына...
Ун минуттан китәм атакага...
Язып өлгергәнем шул гына.
1942

## ВАТАН СУГЫШЫ ФРОНТЛАРЫНДАГЫ УЛЛАРЫНА ТАТАР ХАЛКЫННАН ХАТ

***Татар егетләре!***

Сезгә, туган илебезнең һәрбер карыш туфрагын Ак диңгездән алып Кара диңгезгә кадәр сузылган фронтларда җанын-тәнен аямыйча күкрәк киереп саклаучыларга, гвардия полкларының һәм дивизияләренең алгы сафларында торып һөҗүмгә баручыларга, Кызыл Армиянең 25 еллыгы көннәрендә, безнең гаскәрләребезнең гүзәл җиңүләргә ирешкән көннәрендә, татар халкы үзенең ялкынлы сәламен җибәрә.

Татар халкының курку белмәс, артка чигенмәс намуслы уллары һәм кызлары! Сезне хәләл сөте белән туендырган, җылы кочагына сыендырган шәфкатьле аналарыгыз, сезгә иң яхшы сыйфатларын биреп тәрбияләгән аталарыгыз туктаусыз алга барырга һәм явыз дошманнан рәхимсез үч алырга үзләренең фатихаларын биреп, язгы кояш кебек якты сәламнәрен тапшыралар.

Аталарыгызның каны йөрәкләрегездә дошманга карата мәңге сүнмәс нәфрәт уты булып янсын!

Аналарыгызның мәхәббәте сезне дошман укларыннан сакласын!

Батырлыгы әкият итеп сөйләнерлек, көйгә салып җырланырлык баһадирлар! Сездән үрнәк алучы, сезнең белән горурланучы газиз балаларыгыз, үзләренең язмышларын, бәхетле киләчәкләрен сезнең кулга тапшырып, өмет һәм ышаныч белән тулы сәламнәрен язалар.

Алып йөрәкле, арысландай гайрәтле ирләр! Болытлар өстендә булсын, диңгездә булсын, тауда булсын, кырда булсын, ерткычларга үлем китерүче асыл егетләр! Сезнең нурлы йөзләрегезне йөрәкләренең якты түрендә кайнар мәхәббәт белән саклаучы сөекле ярларыгыз, исемнәрегезне телдә тәсбих итеп йөртүче күрше-колан, кардәш-ыруларыгыз – күкләрдәге йолдызлар санынча, дәрьялардагы сулар санынча күптин-күп сагынычлы сәламнәрен җибәрәләр.

Совет илендәге барлык халыкларның вәкилләреннән торган батыр иптәшләрегезгә, юлдашларыгызга, олы һәм кече командирларыгызга татар халкы үзенең иң яхшы теләкләрен, туганлык һәм дуслык сәламнәрен күндерә.

Газиз улларыбыз!

Сөекле ирләребез!

Кадерле туганнарыбыз!

Барлык татар халкының өмете сезгә текәлгән. Халык йөрәге сезнең белән тибә. Иртәнге сәгатьләрдә фронт хәбәрләрен тыңлау өчен, без барыбыз да бер үк минутта уянабыз. «Безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга баралар, туган җиребезне явыз дошманнан тазарталар» дигән күңелле хәбәрне ишеткән саен, күз алларыбыз яктырып, сулышларыбыз иркенәеп китә.

Без һәркайсыгызның ничек сугышуын күңел күзе белән күреп торабыз. Алмас кылычларыгыз дошман башларын кисеп тәгәрәткән саен, корыч ядрәләрегез җир күтәрмәс явызларның кара йөрәкләренә барып кадалган саен без хәтсез куанабыз, бөтен ил белән җыелып чын күңелдән рәхмәтләр укыйбыз.

Менә егерме ай инде каты сугыш бара.

Рәхимсез сугыш бу. Канлы сугыш бу. Яшәү яки үлем сугышы бу. Бөтен Европадан җыеп китерелгән башкисәрләргә каршы, иң явыз, иң мәкерле, иң ерткыч дошманга каршы сугыш бу.

Шушы туктаусыз гөрләп торган ут давылы эчендә, өзлексез явып торган бомба, мина яңгыры астында батыр татар егетләре юлбасарлар өере өстенә атакага ташланалар, аларны юк итәләр, шәһәр артыннан шәһәрне, авыл артыннан авылны азат итеп, алга баралар.

Азатлык көрәшендәге барлык халыкларның уллары белән җан-тән бер булып, терсәккә терсәк, йөрәккә йөрәк тоташып атакага баручы татар егетләре!

Сез үлемнән курыкмыйсыз. Үлем үзе сугышта сезнең корыч калкан кебек нык торуыгыздан өркеп артка чигенә.

Сез тормышны яратасыз һәм тормыш сездән аерылмас. Тормыш сезнең белән, халык сезнең белән, иптәшләр!

«Батыр егет – яу күрке» дигәннәр борынгылар. Безнең якташыбыз Советлар Союзы Герое *Илдар Маннанов* – әнә шундый егет.

Безнең бер орудиебез урнашкан турыга дошманның дистәләрчә танклары килеп чыгалар. Туган ил өчен җаннарын да аямаучы безнең тупчылар бу тигезсез сугышта бер-бер артлы яраланалар. Туп янында Илдар берьялгызы кала һәм тупны берүзе корып, берүзе төзәп, дошман танкларына каршы берүзе ата башлый, 108 тапкыр ата ул. Котырынып килгән немец танкларын ватык тимер өеменә әйләндереп, яндырып бетергәнче ата.

«Ир барда ил хур булмас» дигәннәр безнең бабайлар. Дошман коммуникацияләрен сиксән тапкыр штурмлаган һәм һава сугышларында немецларның бик күп самолетларын бәреп төшергән батыр лачыныбыз Советлар Союзы Герое *Фәрит Фәтхуллин* – әнә шундый ир егет.

«Батыр яуда беленер» дигәннәр борынгылар. Берүзе 100дән артык гитлерчыны кырып салган якташыбыз Советлар Союзы Герое *Салават Кәримов* – әнә шундый батыр егет.

«Тәвәккәл таш ярыр» дигәннәр безнең бабайлар. Кырык гитлерчыга каршы берьялгызы сугышып җиңеп чыккан якташыбыз Советлар Союзы Герое *Геннадий Гобәйдуллин* – әнә шундый тәвәккәл егет.

Дан һәм рәхмәт халык баһадирларына!

Дан һәм рәхмәт татар халкының улларына – бөек азатлык сугышының геройларына: гайрәтле летчикларга, үткер күзле снайперларга, тәвәккәл разведчикларга, дошманның техникасын һәм җанлы көчен аяусыз кыручы бронебойщикларга, зенитчыларга, ир йөрәкле тупчыларга, миномет һәм пулемет уты осталарына, тутыкмас кылычлы атлыларга, кыю танкистларга, тау һәм диңгез сугышы пәһлеваннарына дан һәм рәхмәт!

Рәхмәт һәм дан сиңа большевик пулеметчы *Әбрар Җәләлиев*! Бер сугышта гына син 100дән артык фашистны кырып салуың белән татар егетенең үз Ватаны өчен изге көрәш кырында нинди батырлыкка, нинди гайрәткә сәләтле икәнен бөтен дөньяга таныттың.

Дан һәм рәхмәт сиңа дошманның 19 танкысын яндырып кисәүгә әйләндергән *Әхмәт Хәлимов*!

Төньяк-көнбатыш фронтта летчик *Камалетдинов*, үз самолеты дөрләп яна башлаган хәлдә, дошман сафларын бомбалаудан туктамыйча, бик күп немец солдатларын һәм офицерларын кыра. Көнбатыш фронтта танкист *Әбуталипов* үзенең дәһшәтле машинасы белән немецларның сугыш кирәк-яраклары төялгән 25 грузовигын, 6 орудиесен, 8 минометын һәм 200ләп солдат һәм офицерын юк итә. Немец самолетлары 850 тапкыр очыш ясап, 10 меңнән артык бомба ташлаган чиксез авыр шартларда Татарстан Верховный Советы депутаты *Садыйков* командалыгындагы батарея дошманның 59 дзотын җимерә һәм 2 меңнән артык фашистны кырып сала. Өстен көчләр белән һөҗүм итеп килүче дошманга каршы кече лейтенант *Шәрәфетдинев* үз сугышчыларын «Ил өчен! Сталин өчен! Ура!» авазы белән штык атакасына күтәрә һәм немецларның ике батальон пехотасын туздырып ташлый. Аларның батырлыгында: Сталинград төбендә дошманны туктатып һөҗүмгә күчкән тупчы *Хәлимов*, шофер *Фәрдиев* һәм башкаларның батырлыгында, Воронеж фронтында немецларны берәмләп һәм күпләп кыруы белән танылган автоматчы *Акчуринның* батырлыгында, Көньяк-көнбатыш фронтта дошман дзотына бәреп кергән һәм автоматтан 6 немецны үтергән, трофей пулеметтан гитлерчыларга каршы ут ачкан *Галимов Шәйхулланың* батырлыгында, Украина партизаннары сафында сугышучы *Галиев Шириязданның* батырлыгында, дошманның ерак тылындагы коммуникацияләрен тар-мар иткән өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән очучы капитан *Нурмөхәммәтовның* батырлыгында, Советлар Союзы Герое исемен алган якташларыбызның батырлыгында татар халкының җиңелмәс көче, гранит кыя кебек ныклыгы, үсә баручы куәте яши.

Бөек Ватан сугышы татар халкы эченнән йөзләрчә һәм меңнәрчә геройлар тудырды һәм тудыра. Без аларны Москвага килү юлларында дошман танкларының атакасын туктаткан гвардеецлар сафында күрдек. Без аларны Сталинград төбендәге әһәмиятле биеклекне дошманга бирмичә саклап алып калган баһадирлар сафында күрдек. Немецлар бу биеклеккә бөтен буйларына басып, автоматлардан туктаусыз атып, дулкын-дулкын ябырылып килделәр. Биеклекне саклаучы отделение командиры *Михаил Кабрибов*, һөҗүм итеп килүче фашистларның саны 300гә якын икәнлеген күргәч, үзенең татарлардан, үзбәкләрдән, казаклардан торган ун сугышчысына болай дип эндәшә:

– Кулыбыздагы һәрбер штык саен утызар дошман туры килә. Кем дә кем курка икән, хәзер үк стройдан чыксын!

Ләкин бер генә сугышчы да баскан урыныннан кузгалмый. Алар барысы да: «Үлсәк тә чигенмәбез!» – дип ант итәләр һәм, патроннары беткәннән соң да штык белән сугышып, һәркайсы унар-унбишәр немецны кадап үтерә. Алар шулай батырларча сугышып һәлак булалар, ләкин биеклекне немецларга бирмиләр. Менә шулай сакларга кирәк Туган илне!

Үзләренең үлемнәре белән мәңге сүнмәслек дан казанган гвардеецлар сафында без старшина *Курмаевны* күрәбез. Сугышның иң кызу чагында аның берүзенә биш фашист килеп ябыша. Куркусыз сугышчы беренче пулялары белән үк өч фашистны аударып ташлый, дүртенчесен яралый, бишенчесе кача. Бу бәрелештә каты яраланган Курмаевны тере килеш тотып алу өчен немец автоматчылары килеп чыгалар. Курмаев, үзенең актык көчен җыйнап, билендәге гранатасын чишеп ала һәм күкрәгенә куя. Немец автоматчылары килеп аның өстенә ташлануга, граната шартлый. Курмаев геройларча үлә, ләкин ул немец автоматчыларын кисәкләргә теткәләп үлә.

Ватан сугышы кырларында 3 меңнән артык татар кызылармеецы, командиры һәм политработнигы орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде.

Дон буендагы далада өч сугышчы: рус егете *Федор Липатов*, украинлы *Степан Михно* һәм татар егете *Фәррах Бикбулатов* кыр дзотыбызны саклый. Көтелмәгәндә аларга каршы немецларның ике танкысы һәм кырыклап автоматчысы һөҗүмгә ташлана. Совет сугышчылары бу һөҗүмгә каршы тормыйча чигенгән сурәттә күрше частьның тылына дошманның үтеп керәчәген яхшы аңлый. Өч сугышчының берсе дә каушап калмый, артка чигенми. Алар искиткеч батырлык, кыюлык белән сугышалар, һөҗүм итүчеләрнең яртысын кырып, бер танкны яндырып, калганнарын кире борылып качарга мәҗбүр итәләр. Өч рядовой сугышчы карап торуга бик гади, ләкин фронт өчен гаять әһәмиятле участокны саклап кала. Туган илебезнең һәрбер карыш туфрагын менә шулай сакларга кирәк!

Бу мисалларның һәркайсында СССР халыклары арасындагы дуслыкның җиңелмәс куәте бөтен тирәнлеге белән чагыла.

Бу мисаллар сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның ялкынлы сүзләрен күз алдыбызга китереп бастыра:

Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, логать, гадәт вә әхлак алмашып,
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?
Без туган бер жепкә бергә теркәлеп.
Без сугышта юлбарыстан көчлемез,
Без тынычта аттан артык эшлимез.

Татар халкы үз гомерендә килмешәк немец баскаклары белән беренче тапкыр гына очрашмый. Ләкин бу очрашуларның барында да һәрвакыт рус һәм татар халыкларының бердәм көче җиңеп килде.

Моннан дүрт йөз ел элек, 1558–1582 еллардагы Ливон сугышы чорында, рус армиясе сафларында бик күп татар егетләре немецларга каршы көрәште.

Көмеш иярле акбүз атларга атланып, озын сөңгеләрен, ай кылычларын кояшта ялтыратып Нарва шәһәренә бәреп кергән татар гаскәрләренең кыюлыклары турында ул замандагы немец тарихчылары котлары чыгып язган. Халкыбызның бу ярсулы көчен немецлар моннан ике йөз ел элек булган җиде еллык сугыш чорында да үз җилкәләрендә бик нык татыйлар. Ул сугышларда рус гаскәрләре белән бер сафта барган безнең бабаларыбыз бөтен дөньяны таң-хәйран калдырырлык батырлыклар күрсәтәләр.

1914–1918 еллардагы немец империалистларына каршы сугышларда, тарихка «Брусилов прорывы» дип кергән һәм гаҗәп зур осталык белән башкарылган операциядә татар солдатлары рус солдатлары белән бергә алгы сафларда барды.

«Ора алмаган олы күтәрә» ди халык мәкале. Безгә каршы сугыш башлаган саен хурлыклы җиңелүгә очраган немец юлбасарлары 1918 елда, тагын бер тапкыр күтәрелеп, яшь Советлар илен канга батырырга теләп, поход оештырдылар.

Бу сугыш Германия сугыш чукмарлары өчен уңышсыз булып бетте! Алар Советлар Союзының изге дуслык хисе белән берләшкән халыкларының көчен һәм куәтен тагын бер кат татыдылар.

Ләкин немецлар бу тарихи сабакны да онытылар! Алар, үз танкларының кысрыклавы астында безнең көчләребезне сындырырга уйлап, 1941 елда хыянәтчел рәвештә яңа сугыш башладылар. Ләкин бу юлы да алар үзләренең бронемашиналары белән җимереп булмый торган каршылыкка, ныклы отпорга очрадылар.

Безнең халыкларыбыз бөек полководец Сталин җитәкчелеге астында бердәм сугышчан лагерь булып туплandылар. Дошман безнең халыкларыбызның көчен тагын бер кат татыды. Немец ефрейторы Рудольф Вольтантның Германиядәге абзасына язган хаты шул дәһшәтнең җанлы шаһиты булып тора. Ул болай дип яза: «Биредә безгә каршы татарлар бик күп сугышалар. Татарлар белән мин өнемдә генә түгел, төшемдә дә очрашырга теләмәс идем».

Кадерле улларыбыз!

Сөйгән ярларыгызның сезне фронтка озаткан чагында:

Куркак хатыны булып яшәгәнче,
Батырдан тол калу яхшырак, –

дип җырлап, сезне батырларча көрәшергә өндәп биргән наказларын намус белән үтәвегез өчен куанып бетә алмыйбыз. «Куркак егет ир булмас», «Курыкканга куш, койрыгы белән биш» дип, куркаклыкка нәфрәт белән карауччы татар халкы сезгә бабаларыгызның сугышчан традицияләрен саклавыгыз өчен иксез-чиксез рәхмәт укый.

Хезмәт сөючән татар егете!

«Хезмәттә бәрәкәт» дип яшәгән безнең халык. Хезмәтне мактап ул әкиятләр сөйләгән, һөнәрлене күтәреп җырлар җырлаган, ялкаулыкны мәсхәрәләп бәетләр әйткән. «Тырышкан ташка кадак кагар» дип әйткән безнең бабайлар. Шушы тырышлык, намуслы гадел хезмәт татар халкын ирекле илебездәге барлык халыклар белән аралаштырып, мәңге өзелмәслек дуслык һәм туганлык төеннәре белән тоташтырды.

Татар халкы үзенең туган республикасын – Татарстанны төзеде. Татар халкы үзенең элеккеге культурасын саклап калды. Ул соңгы 25 ел эчендә танымаслык дәрәҗәдә үзгәрде, үсте, алга китте. Безнең Татарстан – алдынгы индустрия, колхоз республикасына, тоташ грамоталы илгә әйләнде.

Республикаң синең өчен меңнәрчә мәктәпләр, уннарча техникумнар һәм югары уку йортлары ачты. Син аларда укытучы булып та, агроном, врач, инженер булып та әзерләнә алдың. Республика синең өчен дистәләрчә театрлар мәйданга китерде. Син, совет әдәбиятының һәм сәнгатенең иң матур үрнәкләрендә тәрбияләнеп, югары культурага ия булдың.

Син бөек язучы Максим Горький тәрбияләнгән, Свердлов, Молотов, Киров, Бауман кебек халык улларын – ялкынлы революционерларны җитештергән, Шишкин кебек художникларга бай фантазия биргән һәм Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, - Фатих Әмирхан, Шәриф Камалның бишеге булган Идел-йортта туып үстең.

Идел-йортның ирекле шәһәрләрендә, авылларында син үзеңнең сәләтеңә тиң хезмәт, талантыңа тиң профессия, мәхәббәтеңә тиң яр сайлап алдың.

Кайчандыр синең бабаларың: «Дус-иш кирәк дөнья көтәргә...» дип җырлаганнар. Ул турылыклы дусларны син совет халыкларының тату семьясында таптың. Кайчандыр синең бабаларың: «Очар идем, юк канатым...» дип моңаеп җырлаганнар. Совет власте сиңа болытлардан югары очарлык, кешелек культурасының иң бөек тауларына күтәрелерлек көчле канатлар үстерде.

Менә шул бөек казанышларның барыннан да сине, синең семьяңны, синең халкыңны мәхрүм итәргә теләп, явыз дошман канлы балтасын күтәрде. Ул синең язмышыңа хуҗа булырга, барлык якты өметләреңне пычракка салып таптарга, сөйгән ярыңны үзләренә кәнизәк ясарга, нарасый balаңны буып үтерергә, иркен Идел буйларын каберлеккә, төрмәгә әйләндерергә омтылды.

Алар Советлар Союзындагы барлык ирекле халыкларны һәм шул рәттән безнең татар халкын да үтереп бетерергә теләделәр. Сталинград өлкәсендәге авылларның берсенә басып кергән кан эчүче немецлар Фатыйма Гыймадиеваның Марат исемле дүрт яшьлек улын ерткычларча җәзалап үтергәннәр. Алар аның нәни бармакларын берәм-берәм тураганнар. Энесенең азаплануына түзә алмыйча шашып кычкырган ун яшьлек Фәтхине немең офицеры атып үтергән.

Калинин шәһәрендә торучы ак сакаллы Гали Сәйфуллинның уналты яшьлек кызын немецлар Германиягә коллыкка озатырга уйлыйлар. Кыз аларга каршылык күрсәткәч, аны атасы күз алдында фашист офицерлары атып үтерәләр.

Калуга шәһәрендәге Ибраһим бабай Нургалиев яралы кызылармеецны яшергән өчен тереләй җиргә күмелә.

Донбасста немец оккупантлары уннарча һәм йөзләрчә татар шахтерларын ерткычларча үтерәләр. Белоруссиядә, Украинада, Балтыйк буйларында яшәүче бик күп татар семьялары һичбер гөнаһсызга атылалар. Кырымда безнең туганнарыбызның каны һәм сеңелләребезнең күз яшьләре елга булып ага.

Немец палачларының коточкыч явызлыкларыннан тәннәр чымырдый, йөрәктә дошманнан үч алу уты яна.

Совет кешеләренең каны өчен үч ал немецтан!

Һәрбер тамчы кан өчен, һәрбер тамчы күз яше өчен, һәрбер киселгән гомер өчен үч ал!

– Үтер немецны! – дип ялвара сиңа карт әнкәң.

– Үтер немецны! – дип эндәшә сөйгән кызың.

– Үтер немецны! – дип сорый синнән нәни балалар.

Син шул канга туймас албастыларны никадәрле күбрәк кырсаң, җиңү бәйрәме шулкадәр тизрәк килер.

Йөз немецны дөмектергәч, туктап калма! Йөз дә беренчесен мушкаңа ал! Йөзтүбән кадалдырып төшер мәлгуньне!

Ятим балаларның күз яшен, тол хатыннарның аһ-зарын, бәхетсез аналарның ләгънәтен, бомбага

салып, минага кушып, дошман өстенә яудыр!

Канга туймас ерткычларны үләксә өеменә әйләндереп алга – Көнбатышка баручы сафларыгызда безнең шатлыгыбыз, бәхетебез бергә атлый.

Батыр улларыбыз!

Сез фронтка киткән көннән алып байтак гомер узды. Сезнең көчле кулларыгызда очкыннар чәчрәтеп тимергә сугылган чүкечләр җирдә ятып калмады. Сез эшләгән станоклар кызу әйләнешен туктатмады. Киерелеп печән чапкан үткер чалгыларыгыз тупасланмады. Иркен кырларны гөрләтеп йөргән тракторлар, комбайннар эштән туктамады. Паровоз, пароход учакларында ут сүнмәде. Аталарыгыз, аналарыгыз, сеңелләрегез сезнең станокларыгыз янына басты, колхоз басуларына китте. Карт әбиләрегез сезнең өчен җылы бияләйләр, оекбашлар бәйләргә кереште.

Безнең шәһәрләребез йокы белмиләр. Кешеләрнең йөрәкләрендә хезмәт итү теләге яна.

Бөтен Татарстанга шаулаган токарь Фәйзи Абдрахмановның иҗат эзләнүләре сезгә җибәрелә торган сугыш припасларын ун өлеш арттырырга ярдәм итте.

Дәүләт Оборона комитетының Кызыл Байрагы белән бүләкләнгән N заводы фрезеровщигы Бирюков, производство нормаларын 2 мең процenttан артыкка үтәп, хезмәт фронтындагы батырлыкның иң югары үрнәген күрсәтте.

Хезмәт сөюче бик күп хатын-кызлар, ирләр һәм яшьләр Бөтенсоюз социалистик ярышта беренчелекне алдылар. Аларның йөрәкләрендә Ватанга кайнар мәхәббәт уты яна, дошманга каршы нәфрәт көчәйгәннән көчәя бара.

Шушы мөкатдәс тойгы Арча районы «Кызыл Тау» колхозының яшь колхозчылары Габделхак Нуриев, Вәдигъ Абдуллиннарны хезмәт батырлыгына рухландырды. Алар Татарстанда беренче буларак хезмәт вакытын тыгыз файдалану юлы белән көненә бишәр гектар җир сөрделәр.

Шушы мөкатдәс тойгы йөз меңнәрчә ялкынлы патриотларны гадел хезмәт белән тапкан акчаларына самолетлар, танклар төзеп фронтка тапшыру хәрәкәтенә күтәрде. Мул тормышлы колхозчыларыбыз «Татарстан колхозчысы» исемендә танклар төзү фондына бик аз вакыт эчендә 100 миллион сумнан артык акча туплап тапшырдылар. Сөекле юлбашчыбыз, даһи полководецыбыз иптәш Сталинның Татарстан колхозчыларына белдергән рәхмәт һәм сәлам телеграммасы белән рухланып, республикабызның хезмәт ияләре үз акчаларыннан сугышчан самолетлар эскадрильяләре төзү фондына өстәмә рәвештә 85 миллион сум акча җыеп тапшырдылар. Болардан тыш без Ватан сугышы чорында оборона фондына 39 миллион сум акча бирдек һәм фронтовикларга 24 миллион сумлык төрле бүләкләр белән берлектә 23 мең тун, 54 мең киез итек, 56 мең җылы чалбар һәм кием, 106 мең җылы күлмәкләр һәм башка әйберләр җибәрдек.

Фронт сорый! дидек без һәм көчебезне дә, байлыгыбызны да кызганмадык.

Фронт сорый! дидек без һәм атналар буе цехтан чыкмыйча эшләдек, кырдагы эш бетмичә яланнан кайтмадык. Барлык көчебезне бергә туплап, яңа заводлар, яңа фабрикалар корып ходка җибәрдек.

Фронт сорый! дидек без һәм ун меңнәрчә гайрәтле егетләрне, сугыш эшенә өйрәтеп, сезгә булышырга озаттык.

Безне җиңүгә рухландырган сугышчан байракларыбызны үбеп ант итәбез.

Без быел фронт өчен кирәкле корал һәм сугыш припасларын үткән елгы саннан ике өлеш артыграк һәм фәкать яхшы сыйфатлы итеп җитештерербез.

Без быел колхоз һәм совхоз басуларыннан үткән елга караганда мулрак иген уңышы алып дәүләткә тагын да күбрәк икмәк, яшелчә, бәрәңге, ит, сөт, йон һәм май тапшырырбыз.

Кадерле улларыбыз һәм кызларыбыз! Сез немецларга тын алырга да ирек бирмичә, аларны Көнбатышка таба куарсыз һәм немец юлбасарларын тәмам кырып бетерерсез. Без моңа нык ышанабыз.

Бүген без, сезнең белән бергәләп анабыз Идел ярларына басып, бабаларыбызның гадәте буенча Иделнең туфрагын үбеп, ант итәбез.

Кайсы гына фронтта булсак та, нинди генә коралга каршы сугышсак та, Туган илебез өчен, аның азатлыгы, бәйсезлеге, намусы өчен җаныбызны аямабыз!

Кояш шаһит, Идел-йорт! Без, Туган илебезне шакшы фашистлардан тазартып бетерми торып, кылычларыбызны кынына салмабыз.

Яшәсен һәрбер карыш туфрагы, һәрбер үләне, суларының һәрбер тамчысы изге булган ирекле Ватаныбыз!

Яшәсен данлыклы Кызыл Армия!

**Хатка кул куйдылар:**

*Зиннур Абдрахманов*, Казан Энергокомбинатының стахановчы кочегары; *А.Е.Арбузов*, СССР Фәннәр академиясенең действительный члены; *Хаҗи Әхмәтов*, Минзәлә районы «Кызыл Йолдыз» колхозы колхозчысы; *С.Әюпова*, Казан мех фабрикасының стахановчы-мехчысы; *Ф.Б.Бәдретдинов*, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре; *А.Г.Барышников*, ВКП(б)- ның Казан шәһәре комитеты секретаре;

*Сәид Бәширов*, Калинин МТСының трактор отряды бригадиры; *Рәшидә Билалова*, Апас районы «Тырышчы» колхозының ферма мөдире; *Гөлсем Болгарская*, ТАССРның халык артисткасы, РСФСРның хезмәт күрсәткән орденлы артисткасы; *Гөлсем Гафарова*, Казан шәһәренең 35 номерлы татар мәктәбенең директоры; *С.Х.Гафиятуллин*, ТАССР Халык Комиссарлары Советы председателе, СССР Верховный Советы депутаты; *С.Ш.Гафаров*, ВКП(б) өлкә комитетының пропаганда буенча секретаре; *Х.З.Гыйззәтуллин*, ТАССРның хезмәт күрсәткән врачы; *Галимә Гыззәтуллина*, Киров исемендәге завод стахановчысы; *М.И.Громова*, Ленин исемендәге заводның орденлы инженеры; *Г.А.Динмөхәммәтов*, ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе, СССР Верховный Советы Президиумының члены; *Нәҗип Җиһанов*, композитор, РСФСРның хезмәт күрсәткән сәнгать эшлеклесе; *А.Җаббарова*, Чистай районы Вахитов исемендәге колхозның кырчылык бригадасы бригадиры; *Х.С.Зәйнуллина*, N заводының стахановчысы, бригадир; *Зәбир Зарялов*, Казанбаш МТСының трактор отряды бригадиры; *А.Г.Колыбанов*, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре, СССР Верховный Советы депутаты; *Гыйлем Камай*, орденлы профессор, химия фәннәре докторы; *Кави Нәҗми*, язучы; *М.Г.Крылов*, Казан тимер юлының орденлы машинисты; *М.И.Кузьменкова*, Алабуга совхозының сыер савучысы, Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашучы; *Фатыйма Камалиева*, Әтнә районы Киров исемендәге колхозның терлекчелек фермасы мөдире; *Р.Латыйпов*, Кукмара районы Сталин исемендәге колхозның умартачысы; *Луцкер*, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре; *Г.М.Мохтарова*, Мөслим районы «Дусай» колхозы председателе; *Г.А.Мөхәммәтҗанов*, Мырты МТСының тракторчысы; *О.Никитина*, Буа районы Киров исемендәге колхозның колхозчысы; *Г.Нуретдинова*, Әлки МТСының тракторчысы; *М.Нәфыйкова*, Красный Бор районы Кичке Таң авыл советы председателе; *Н.Нуриева*, Саба районы «Игенче» колхозының кырчылык бригадасы бригадиры; *Прудников*, N заводының цех начальнигы; *Хәбир Пазиков*, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре, СССР Верховный Советы депутаты; *Р.Салахова*, Тымытык МТСының комбайнчысы; *Сафин*, Арча районы «Кызыл Ил» колхозы колхозчысы; *С.П.Спирков*, Советлар Союзы Герое; *П.Сафиуллина*, Бондюг районы «Кызыл Йолдыз» колхозы колхозчысы; *М.М.Токарева*, Югары Ослан районы Ворошилов исемендәге колхозы колхозчысы; *Әбүбәкер Терегулов*, Казан медицина институтының орденлы профессоры; *Таҗи Гыйззәт*, орденлы язучы, РСФСРның хезмәт күрсәткән сәнгать эшлеклесе; *Харисова*, Теләче районы «Кызыл Максай» колхозының дуңгыз караучысы; *Хәйруллин*, ВКП(б)ның Апас райкомы секретаре; *Хисмәтов*, хезмәт ияләре депутатларының Тәкәнеш район Советы Башкарма комитеты председателе; *Ямков*, ВКП(б)ның Октябрь райкомы секретаре; *Х.Х.Ярмөхәммәтов*, Татарстан тел-әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының директоры һәм башкалар. Бу хатка барлыгы 1 миллион 511013 кеше кул куйды.

## «ИҢ ДӘҺШӘТЛЕ УТКА КЕРӘМЕН»

Татарстан Язучылар берлеге бинасының икенче катында фирүзә төсендәге калын диварга истәлек тактасы эленгән. Анда Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучыларның исемнәре күгелҗем мәрмәргә алтынсу төсендәге хәрефләр белән уеп язылган.

1941 елның 22 июнендә немец-фашист илбасарлары илебезгә бәреп кергәч, халык белән бергә язучыларыбыз да көрәшкә күтәрелә. Сугышның беренче елында гына да 25 каләм иясе (аларның дүртесе Язучылар берлегенең идарә әгъзасы) фронтка китә: Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Әхмәт Исхак, Абдулла Алиш, Хәйретдин Мөҗәй, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри, Нури Арсланов, Гали Хуҗи, Әнвәр Давыдов, Зәки Нури, Зыя Мансур һәм башкалар.

Төньяк-көнбатыш, Беренче һәм Икенче Белоруссия, Ленинград, Беренче һәм Өченче Украина, Воронеж, Волхов һәм башка фронтларда татар телендә газеталар чыга. 1942–1943 елларда бер төркем язучылар, шул исәптән Гадел Кутуй, Афзал Шамов, Мәхмүт Максуд, Әхмәт Ерикәй, Риза Ишморат, Габдрахман Әпсәләмов, Ибраһим Гази, Абдулла Әхмәт, Гомәр Галиев, Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур, Гамир Насретдинов, Әхмәт Фәйзи, Шәрәф Мөдәррис һәм башкалар фронт газеталары редакцияләрендә эшлиләр. Аларның язмаларын, әдәби әсәрләрен бер хис, бер уй, бер максат берләштерә – Ватанны саклап калырга!

1943 елны Мәскәүдә Совет язучылары берлеге президиумы утырышы була. Көн тәртибендә төп мәсьәләләрнең берсе – татар язучыларының хисабы. Бөек Ватан сугышы барганда алар ниләр майтарып яталар икән? Докладны ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гази Кашшаф ясый. Шунда ук Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Кави Нәҗми, фронттан кайткан Гадел Кутуй, Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садрилар чыгыш ясый. Совет язучылары берлеге җитәкчесе Александр Фадеев гаҗәпкә кала. Татарстан Язучылар берлеге үзенең әгъзаларының 20 процентын сугышта югалткан да бит инде!

Дәһшәтле көннәр дәвам итә. Корбаннар саны арта тора. Бу сугышта Татарстан 31 язучысын, 22 журналистын югалта. Илебездә бу кадәр югалту кичергән Язучылар берлеге бүтән юк.

Бөек Җиңүнең 65 еллыгын каршыларга әзерләнеп йөргән көннәрдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә яу кырында һәлак булган язучылар турында китап чыгару мәсьәләсе күтәрелгәч, яңадан истәлек тактасы янына килеп бастым. М.Җәлил, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, А.Алиш, Н.Баян, Х.Мөҗәй исемнәре халкыбызның йөрәк түрендә. Д.Фәтхи, К.Басыйров, М.Вәдүт, М.Әблиев, Х.Рахман, М.Гатау, Ш.Гәрәй, Ә.Камал, М.Мостафин, М.Мамин, Х.Кавилар мөстәкыйль җыентыкларын чыгарып өлгергәннәр. К.Вахит, М.Гаяз, М.Әхмәтгалиев, Г.Галиев, Ә.Гыймадов, А.Аитов, И.Шәфиев, И.Закиров, Ә.Әминев, С.Мөлековларның иҗаты исә бөреләнеп кенә килгән чак.

Киләчәккә зур иҗади планнар белән янып, канатларны тагын да ныгытырга теләп йөргән чак. Их син, сугыш! Канлы, утлы, рәхимсез сугыш!.. Шушы тактаны ачканда, өлкән язучыларыбызның үзара сөйләшеп торулары искә төшә:

– Әблиев әйбәт драматург булыр иде.

– Мамин исә Такташ турында саллы фәнни хезмәт язды.

– Мөсәгыйть Мостафин хикәяләр остасы иде...

Сугыш барысын да үзенчә хәл итә. Каһарман-шагыйрь Фатих Кәримнең түбәндәге шигъри юлларын тетрәнмичә укып буламы?!

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен.
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Яуда һәлак булган татар язучылары турында мәгълүматларны, аларның әсәрләрен туплап китап чыгару яңалык түгел. Заманында эзтабар-язучы Самат Шакир моны эшләгән иде. Ул төзегән «Алар сафта» дигән китап чыкканга да чирек гасыр вакыт үтеп киткән икән. Бу чорда тулы бер буын үсеп җитте. Димәк, әлеге китапны яңартуны вакыт үзе сорый. Яу кырыннан әйләнеп кайта алмаган татар язучыларын, каһарман каләм ияләрен без белергә, онытмаска тиеш.

Китапта каһарман язучылар алфавит тәртибендә бирелә. Аларның биографияләре тулыландырылды, тормыш һәм иҗат юллары киңрәк яктыртылды. «Алар сафта» китабы чыкканнан соң үткән 25 елда тормыш, вазгыять бик нык үзгәрде. Бу китапка кергән шигырь, хикәяләрнең, әсәрләрдән өзекләрнең дә бүгенге көнгә, бүгенге чорга аваздаш булырлыклары сайлап алынды.

Китапның татар халкыннан татар сугышчыларына, татар сугышчыларыннан татар халкына язылган хатларыннан башлануы да зур мәгънәгә ия. Халкыбызның, шул исәптән фронттагы татар язучыларының уртак уе, гаме белән сугарылган, аларның җан авазы, күңел сүрәсе булган күләмле вә киң колачлы бу хатларга китап укучылар битараф калмас дип ышанабыз. Фронтовиклар язган хатны безгә – Татарстан Язучылар берлегенә – Әхмәт Исхакның хатыны Гөлсем Исхакова алып килеп бирде. Иренең архивын барлаганда тапкан ул аны. Рәхмәт Сезгә, Гөлсем ханым!

Дошманга каршы штык белән дә, каләм белән дә көрәшергә көч тапкан, ялкынлы йөрәкле, курку белмәс каһарман язучыларыбызның рухы шат булсын!

**Илфак Ибраһимов**,
Татарстан Язучылар берлеге рәисе

## ИКЕНЧЕ БЕЛОРУССИЯ ФРОНТЫНЫҢ ТАТАР СУГЫШЧЫЛАРЫННАН ТАТАР ХАЛКЫНА ХАТ

Әй, гакыллы, якты йөзле безнең газиз аталар,
Саф күңелле, пакь йөрәкле, мәрхәмәтле аналар!

Әй, бер сукса тимер өзгән корыч куллы агалар,
Ак яулыклы, алъяпкычлы, нурлы йөзле апалар!

Әй, аксакал, изге җанлы, тугры сүзле бабалар,
Киләчәкнең чәчәкләре – безнең сабый балалар!

Әй, безнең иркә хатыннар – тормышыбыз дуслары,
Күңел тоткан кызларыбыз – җәйге таңның нурлары!

Тибрәнеп аккан елгалар, болын, калку, чишмәләр,
Туган учак, таныш яклар, урам, тыкрык, бистәләр!

Ямьдә балкыган авыллар, сахра, урман, тугайлар,
Барча иптәш, һәммә дус-иш, күрше-колан, туганнар!

Җиңү, шатлык көннәрендә алдык кулларга каләм
Язарга сезгә җавап-хат, язарга сезгә сәлам.

Юлыксын шунда сүзебез, – урман, таулар аркылы, –
Кайда яңгырый туган тел, безнең тел, татар теле.

Ишетсен безне Идел-йорт – һәммәбезнең әнкәсе –
Кайда борын-борынгыдан бәйләнгән татар чәче.

Тыңла безне, әй, туган җир, Ленин, Сталин тудырган,
Тигез, бөек, нык семьяга әгъза булып кушылган, –

Һәм тынычта хезмәт белән иң зур орден казанган,
Хак сугышта ныклы булып, эшчән булып дан алган, –

Балкып һаман җиңүләрдән, уңыштан, казаныштан,
Гөрләп үскән республика – бәхетле Татарстан!

Октябрьдән ялкынланып, очып төшкән чаткыдан
Зур, якты һәм саф ут булып мәңгелеккә балкыган, –

Хезмәт, иҗат казанында чирек гасыр кайнаган,
Бакчаларында чут-чут итеп былбыллары сайраган, –

Кырларында бодай үскән, күлендә аккош очкан
Әй матур җир, әй газиз җир, туган җир – Татарстан!

Тыңла безне, көнгә каршы энҗедәй ялтыраган,
Шат шау-шулы кичке Казан, бәхетле таңлы Казан! –

Бөек Тукай йөрәк хисен, җырларын багышлаган
«И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!»

Җитсен сезгә уйларыбыз, якты булып, зур булып,
Ярсу солдат йөрәгеннән агып чыккан нур булып!

Барсын сезгә сәламебез, колач җәеп, киң булып,
Туган кырны сөеп, сыйпап, иртән искән җил булып!

Авыр сугышларда безгә көч, куәт, илһам салып,
Сәлам-хатыңны җибәргән кадерле туган халык! –

Бу давыллы зур көрәштә вәхши яуларга каршы
Батыр улларын күтәргән сугышчы – татар халкы!

«Сәлам сиңа, кайнар сәлам барча кызың-улыңнан,
Без зур җиңү тантанасын яулап алган урыннан, –

Йөрәк каннарыбыз аккан Кояш батыш ягыннан,
Идел-йортка ерак җирдән – ярсу Балтыйк ярыннан!

Без бүген синең улларың һәм сугышчы – кызларың,
Бик сагынып туган якның рәшәләнгән кырларын,

Саклап сиңа җылы хисләр җанда, йөрәк төбендә,
Хат язабыз бүген менә бәхетле җәй көнендә.

Шатлыгыбыз дәрья булып ярга сыймый ташканда,
Хат язабыз кыска ялда, тезеп җырга, дастанга.

Ирешсен сиңа хатыбыз мәңгелек китап булып,
Яуда җиңгән улларыңнан сугышчан хисап булып.

Юлыксын якты җырыбыз, саф көмеш күк ак булып,
Республика бәйрәмендә утырсын кунак булып.

Барсын сиңа, туган халык, безнең йөрәк җылыбыз,
Данлы бәйрәм хөрмәтенә балкып туган җырыбыз!

Җитсен дә ул горур кичеп тауны, суны, урманны,
Бәян итсен туганнарга безнең якты уйларны...

...Алган идек синең хатны язгы җепшек буранда,
Көньякта безнең җиңүнең тәүге таңы туганда.

Без ул вакыт башкаладан бик-бик якында идек,
Смоленщина кырларында, Вязьма ягында идек;

Без ул вакыт, канга батып, утлар аркыла идек,
Одер буена юллар салып, Сожга ашкына идек;

Килде синең сәлам-хатың күңел күген нурлатып,
Саф йөрәктән, пакь намустан ант иттек без шул вакыт:

Ант иттек без туган җирне явызлардан сакларга,
Соңгы тамчы канга чаклы Ватан хакын хакларга;

Башлаганны тәмамламый юлда туктап калмаска,
Җиңми торып кылычларны кыннарына салмаска;

Үч алырга фашистлардан янгын көлләре өчен,
Белоруссия, Украинаның канлы төннәре өчен;

Үч алырга, үч, канлы үч, халык кайгысы өчен,
Төрмә, богау, «җаналгыч»лар – барсы, барсысы өчен!

– Ант иттек без һәм тагын да ыргылдык утлар булып,
Барды бу үч мина, снаряд, бомба һәм уклар булып.

Үттек тарихта данлыклы киң һәм озын юллардан,
Смоленск шоссесыннан, калку, иңкел, урманнан.

Үттек алга, җиңүләрдән көч, рух алып тагын да,
Данлы маршал Рокоссовский гаскәрләре сафында.

Бардык алга батырларча, кичеп янгын кайнарын,
Һаман саен көнбатышка төртеп сугыш мәйданын.

Һәм үткән ел, июнь килгәч, чәчәкләнеп, нурланып,
Проня ярыннан һөҗүмгә – киттек алга кузгалып.

Киттек алга Днепр, Прут, Неман, Нарев аркылы,
Ургып барды Германиягә бөек һөҗүм ялкыны.

Килеп торды безгә һаман юлбашчының рәхмәте,
Күрде безне бөек Москва, бөтен совет дәүләте.

Беләккә көч, тәнгә куәт, йөрәккә илһам салып,
Һәр көн саен башкалада күкрәде безгә салют.

Онтылырмы бу эссе җәй, юллардан очкан тузан?
Коткарылды Белоруссия – хәсрәттә янган туган.

Азат итеп совет халкын, полклар алга барды,
Сарылды безнең кочакка, елап, белорус карты.

Балкыды кызыл комачтан азат совет кырлары,
Чәчкә сипте безнең өскә Гродно, Лида кызлары.

Үтеп чыгып туган илнең, газиз Ватанның чиген,
Уздык тагын озын юллар, коткарып поляк җирен.

Җитте вакыт: шатлык хисе басты шунда күңелне,
Безнең алда дошман өне – немец җире күренде.

Шушында Харис Фатыйхов, ярсый-ярсый йөрәге,
Ерак юллар үткән тубын Пруссиягә төзәде.

Гөрселдәде баһадирның бер-бер артлы туп шавы,
Төтенләнеп, актарылып, тузды немец туфрагы.

Бу шат көнне һәм бу тупны мәңге онытмас тарих,
Германиягә башлап атты Чистайда туган Харис!

Азат булды мәңгелеккә илнең соңгы карышы,
Күчте шулай Германиягә мина, снаряд тавышы.

Ерак калды Ватаныбыз – аксыл томан артында,
Көнен – якты нурлы кояш, төнен – ак ай астында.

Калды тынып аның чиксез, мөкатдәс киңлекләре,
Күчте аннан канлы сугыш, ут-ялкын диңгезләре.

Халкыбызда тагын да зур, сүрелмәс шатлык туды,
Төште соңгы җиңүләрдән балкыган таңның нуры!

Килде бу ел, суык гыйнвар, күрелмәгән дан белән,
Нарев ярыннан һөҗүмгә – киттек алга, таң белән.

Бу матур таң ядкарь булып калыр мәңге тарихта –
Колач җәйде бөек һөҗүм Бобр белән Наревта.

Актык алга ташкын булып, дошман явын җимереп,
Соңгы җиңү якынлыгын йөрәк белән сизенеп.

Киттек алга, көнбатышка, кичеп поляк җиреннән,
Уздык Млава, Дзялдоводан, үттек прусс чигеннән.

Бардык алга Пруссиядән, ачтык немец капкасын –
Кайтарырга илдә аккан күз яше һәм кан хакын.

Күтәрелде Германиягә совет халкы кылычы,
Басты болыт немец күген үлем, дәһшәт болыты.

Илтте безне, алга әйдәп, үч һәм нәфрәт ялкыны
Дойтш Эйлау, Мариенбург һәм Эльбинг аркылы.

Барды алга туган илнең мең-мең батыр баласы.
Бәрелде көйгән йөзләргә дымсу диңгез һавасы...

Үттек ут һәм кылыч белән, Балтикага юл ачып,
Нәләт төшкән прусс җирен як-ягыннан уратып.

Чапты язгы гөрләвекләр, көнгә каршы ялтырап,
Барды армия көнбатышка шөһрәт, данга яңгырап,

Үттек кичеп батырларча киң, тирән Висла суын,
Яңгыратты безнең корал урман, тау һәм яр буен.

Барды лачын-баһадирлар, уттай ташып, ярсынып,
Померания – немец җирен урталайга ярдырып.

Чигенделәр илбасарлар, күрми алда ак-кара,
Кысылды дошман диңгезгә, ныклы тимер алкага.

Онытмабыз Кезлин, Штольп, Нойштадт, Бютов янын,
Омтылдык без ярсып алга, тазартып Балтыйк ярын.

Онытмабыз дөрләп янган канлы сугыш төннәрен,
Данциг, Гдыня төпләрендә көчле штурм көннәрен,

Сугышларда азат итеп Гдыня белән Данцигны,
Ачтык кабат Польша өчен ябык торган Балтыйкны.

Артиллерия утларыннан Одер артын күкрәтеп,
Күрелмәгән баһадирлык, фидакарьлек күрсәтеп,

Юлда нинди киртә очрый – җиңеп чыгып барын да,
Ыргылдык без Штеттиннан көнбатышка тагын да.

Үттек кичеп батырларча, – җәеп һөҗүм утларын, –
Померания, Мекленбург, ерак Рюген утравын.

Үч алдык без явызлардан, нәфрәтләрне ут итеп,
Фашизмның бандаларын кырып, таптап, юк итеп.

Тәмамланды безнең поход кояш батыш ягында –
Борын-борынгыдан таныш ерак Эльба ярында.

Киң дөньяга хөр, мәһабәт совет гимны яңрады –
Күтәрелде рейхстагка безнең Җиңү Байрагы.

Бөек Җиңү – алтын кояш, безгә нурын балкытты,
Күрде шунда совет халкы иксез-чиксез шатлыкны.

Килде җиңү, сугышларда яулап алынган җиңү,
Тарих кулы белән безгә алдан язылган җиңү;

Җиңү, җиңү, алмаз нурга, ямьгә коенган җиңү,
Канлы кырда өлеш-өлеш дүрт ел җыелган җиңү!

Сөйде безнең аркабыздан тиңсез җиңү бәхете,
Тышауланды явызларның илбасарлык нәфесе.

Тарихта бу дошман өне – бу явыз җир, бу яткыр
Тетрәнде безнең куәттән инде ничәнче тапкыр!

Үтәп чыгып көрәшләрдә сугышчылык бурычын,
Төгәлләдек җиңү белән Бөек Ватан сугышын!

Авыр булды без үткән юл, йөрәкләргә сауды кан,
Үлем җиле, ялкын, тимер бәреп торды каршыдан.

Без алга, алга ыргылдык, бер чабып, бер тукталып,
Үтәп изге хәрби антны, аның белән рухланып.

Дивизияләр җиңү яулап алга агылган чакта,
Кыю, тәвәккәл коммунист барды алдынгы сафта.

Шаулый якты мактау җыры бездә кичен, таңында
Александр Жемчужников – кыю парторг хакында.

Изәп канлы кулъяулыгын, дусларын алга дәшеп,
Барды куркусыз большевик, дошманга утлар чәчеп.

Көчле, батыр арысландай, үчкә сусап, ярсынып,
Кичте шулай рус егете көчле сугыш ялкынын.

Берни түгел тән ярасы, куәт булса йөрәктә, –
Шөһрәт алды Жемчужников Ватан өчен көрәштә.

Тотып канлы партбилетын, ярсып, дошманга каршы
Батыр йөрәк – безнең Закир Җамалетдинов барды.

Алды үч, канлы каты үч, күпме немец-каһәрдән
Шөгер егете, большевик, яу күрке һәм каһарман.

Пуля тишкән партбилетын мәңгелек иткән батыр,
Сакланып телдә, дастанда, җырланып җырда калыр!

Керде ыргып сугышларга, мылтыгын алга төбәп,
Шәрифулла Хәмидуллин – коммунист, батыр йөрәк.

Барды алга сугышчылар юлбарыстай ярсынган
Шәрифулла Хәмидуллин – кыю парторг артыннан.

Үлем белән ул, бермә-бер кискен сугышка кереп,
Җиңеп чыкты әкияттәге үлмәс баһадир кебек.

Минометтан утлар чәчеп, ярсып, дошманга каршы
Кыю, сугышчан коммунист Габдерахманов барды.

Габдерахманов Шәйхинур – ул һичвакыт җиңелмәс,
Канга батар, ташка катар, бер карыш та чигенмәс.

Ул – ут йөрәк, курку белмәс, сугышта алга карар,
Туган урыны – Татарстан, милләте аның – татар.

Биреп канын, бөтен көчен, сәләтен, илһамын,
Яклый сугышчан коммунист халык хакын, ил хакын.

Ватан өчен сугышларда алып дошманның котын,
Илтте безне җиңүләргә большевик – батыр токым.

Баһадирлар алга барды, кичеп төтен болыты,
Ашкындырды йөрәкләрен изге партия билеты.

Безне җитәкли агабыз – мәңге көчле рус халкы,
Бар кабилә, бар халыкның иң тугры бер дус халкы.

Ул керде канлы сугышка, нәфрәтен хәнҗәр итеп,
Безне бергә беректереп, бербөтен гаскәр итеп.

Кичтек без аның артыннан көрәштә уттан-судан,
Командир да, дус та булды ул бөек, өлкән туган.

Үрнәк булды сугышларда, һәрвакыт алда барып,
Җитәкләде безне алга ул олуг, көчле халык!

Ул – безнең борын-борыннан бертуган кардәшебез,
Ул – безнең илдәш, табындаш, нәселдәш, кандашыбыз.

Ул бара килер тарихка, дан белән балкып бара,
Уртабыздан, мәгъруранә, тау сыман калкып бара.

Кичтек без аның артыннан гарасат ташкыннары,
Илтте безне аның шанлы сталинчыл маршаллары.

Рух бирде безгә сугышта ныгыган, үскән союз,
Бөек халыклар дуслыгы, сынауны үткән союз.

Без бер семья, таза йодрык, бергә килеп береккән –
Рус, татар, казах, молдаван, үзбәк, әрмән, төрекмән.

Бер үк безнең, аерылгысыз – һәммәбезнең теләге.
Уртак безнең Ватаныбыз – бөек дуслык терәге.

Булса расчетта биш кеше – биш өлкәдән бишесе:
Кайсы татар, кайсы таҗик, кайсы Алтай кешесе.

Калса татар яраланып, ярдәмгә чуаш килде,
Грузин ясап операция, белорус канын бирде.

Без алга, алга омтылдык, тотынышып кулга-кул,
Җомагыл, Тойвэ, Карабай, Федор, Сурен, Мулланур;

Без алга, алга ыргылдык бәхетле дөнья өчен,
Уртак идеал, уртак ватан, зур, бөек семья өчен.

Якты дуслык торды, җанга балкучан нурын сузып,
Калды җиңү, бердәмлеккә мәңгелек шаһит булып.

Рух бирде безгә сугышта, канлы кырларда һаман
Шәфкатьле иркә анабыз – мөкатдәс бөек Ватан.

Чакырды безне сугышка туган илнең быргысы,
Чакырды саф, изге тойгы – патриотлык тойгысы.

Тугры без бөек Ватанга бөтен җаныбыз белән,
Хисләребез, күз яшебез, йөрәк каныбыз белән.

Тугры без илгә – Ватанга – соңгы сулышка чаклы,
Изге безгә бөек Москва, һәм бөек совет халкы.

Ватан, ватан, алтын бишек, изге, шәфкатьле ватан,
Бөтен дөнья каршысында данлы, шәүкәтле ватан!

Җаныбыздан, каныбыздан җире кыйммәтле ватан,
Зур тарихлы, күп халыклы һәм күп милләтле ватан!

Багышладык мәңгелеккә канны-җанны шуңарга,
Аның кайгысы, шатлыгы, дәрте белән суларга.

Рух бирде безгә сугышта, хәтергә төшеп һаман,
Артта калган бөек тарих, данлыклы үткән заман.

Рәсәй-ватан башкаеннан күпме тарих кичерде,
Юк бүтән ил, күпне күргән, безнең зур ил шикелле.

Күрде һаман солдат күзе алда төнен, көндезен,
Александр Невскийның үткер очлы сөңгесен.

Күренде күзгә Альплар, Смоленщина кырлары,
Суворовның, Кутузовның зур, мәһабәт сыннары.

Басса да киң тугай өстен ут-төтен пәрдәләре,
Балкыды шунда аларның тылсымлы шәүләләре.

Торды безгә сугышларда, рух, куәт, илһам салып,
Рәсәйдә үткән тарихың синең дә, туган халык!

Торды хәтердә борынгы Идел-йорт лачыннары –
Данлы Ливон, Бородино, Перекоп батырлары.

Акбүз атның дагасыннан ташта чаткы чәчрәтеп,
Үткен йөзле кылычларын яшен кебек яшьнәтеп, –

Бу көндә дә барды сыман атка менгән улларың,
Рус белән бергә Берлинга ярып кергән улларың.

Сугышкан безнең балалар туган җир өчен янып,
Рус белән бергә тарихның гүзәл битләрен язып.

Тарих аларның даннарын язган алтынга каеп,
Үттек авыр сугыш юлын булып шуларга лаек.

Шул тарих балкып һаман да безнең күзгә чагылды;
Рәсәй өчен, киң ил өчен сугышларга чакырды.

Зур мирас калды үткәннән, – йөзгә кабатлап шуны,
Бөек Ватан сугышында меңнәрчә батыр туды.

Яңгырый безнең фронтта батыр егетләр даны,
Күктә йолдыз күпме булса – шунча аларның саны.

Алар тиңсез дан алдылар бу зур сугыш көнендә,
Пултуск, Торунь, Грауденц, Лауэнбург төбендә.

Дан алдылар, танылдылар бөтен дөнья алдында,
Штеттин, Росток, Пренцлау, Ангермюнде астында.

Һәм тагын да бар дөньяга, киң тарихка балкыды
Константин Рокоссовский – зур һөҗүмнәр маршалы.

Илтте безне җиңүләргә, шанда, шөһрәттә шаулап,
Рокоссовский – полководец, сталинчыл батыр солдат.

Җитәр өчен җиңү дигән изге, гадел теләккә,
Безне батыр генераллар алып барды көрәшкә.

Барып җитеп сезгә бу җыр горурланып сөйләсен
Сталинчыл оста, тапкыр генераллар шөһрәтен.

Сулап явыз Германиягә ут, тимер дәһшәтләре,
Барды генерал-лейтенант Чанышев гаскәрләре.

Илтте безне солдатларда якты хөрмәт казанган
Якуб Чанышев – генерал һәм сугышчы-каһарман.

Бу зур көрәш, бөек еллар күтәрде аның намын,
Гражданнар сугышында яктырып туган даны.

Кичеп поход чакрымнары һәм сугыш мәхшәрләре,
Барды гайрәтле генерал Булатов гаскәрләре.

Омтылдык без ярсып алга кургаш яңгыр астыннан,
Фатыйх Булатов – генерал һәм сугышчы артыннан.

Кертте ул безне сугышка чыныктырып, ныгытып, –
Мактан, Казан, аның белән, һәм горурлан, Тымытык!

Вөҗдан безне, «Үч ал!» диеп, сугышка-яуга илтте,
Хәбиб Ганиев – генерал җитәкләп алга илтте.

Бирде рух безгә көрәштә җитәр өчен максатка,
Ул – большевик, нык җитәкче, ул – якын дус солдатка.

Баһадирлар Германиягә кистереп, ярып керде,
Безне батыр офицерлар сугышка алып керде.

Ашкындык без алар белән, үчкә – үч, канга кан сорап,
Каһәр төшкән дошман җире торды алда калтырап.

Күп алар бездә данлылар һәм озын ул бездәге
Оста, тапкыр офицерлар, генераллар тезмәсе.

Җырлыйбыз без җырыбызда, шаулатып гасырларны, –
Бездәге Алтын Йолдызлы шөһрәтле батырларны.

Менә Герой Гыйззәтуллин, батыр егет Хамазан,
Күкрәгенә Алтын Йолдыз – данлы билге кадаган.

Ул – киң Днепр елгасыннан башлап кичкән баһадир,
Көчле егет, корыч өзгән, броня тишкән баһадир;

Дошманның күпме танкысын, тубын ваткан баһадир,
Хак сугышта, зур һөҗүмдә шөһрәт тапкан баһадир.

Менә Герой Гайнетдинов, егет җитез, фидакарь.
Җиңеп чыкты дошман өерен күп булса да никадәр.

Гайнетдинов Мөхәммәтдин – Герой булган сугышчы,
Су өстеннән, ут астыннан чыбык сузган сугышчы,

Һәм иң алдан, горурланып, ярга менгән сугышчы;
Уттан – суга, судан тагын утка кергән сугышчы.

Менә Герой Габдуллаҗан Булатов – сабыр егет,
Сугышта – шашкын баһадир, гайрәтле, батыр егет.

Пулеметының көпшәсен кызарганчы кыздырып,
Көчле уттан немецларны дистә-дистә кырдырып,

Авыр сугышлар юлыннан давылдай үткән кеше,
Балтачта туып, сугышта Геройга үскән кеше.

Менә Герой безнең Вилдан Хәбиев – ашкын егет,
Җиңелмәс, артка чигенмәс, гайрәтле, ялкын егет.

Минометының дәһшәтен дошманнарга күкрәтеп,
Сугышларда алдан барып, безгә үрнәк күрсәтеп,

Дошман явын бик күп кырып, җимергән, куган кеше,
Булып нурлы Алтын Йолдыз, балкырга туган кеше.

Күп алар бездә, Геройлар, сугышларда калкучы,
Даннары Алтын Йолдызда еракларга балкучы.

Җырлыйбыз без җырыбызда горурлык белән тагын,
Меңнәрчә якташ батырлар, каһарман уллар данын.

Гөрләсен җыр, шауласын җыр, данга күмеп мактасын
Гади укчы, тупчы, сапер, гади совет солдатын.

Бар бездә бөтен фронтта данлы исеме шаулаган,
Танк белән дистә-дистә гитлерчыны таптаган,

Дошман җирен басып үтеп, көрәшләрдә дан алган,
Әсәт Шахманов – сугышчы, танкчы егет, каһарман.

Бар аның якын дуслары, өч батыр һәм нык егет:
Лаптев, Мищинин, Игумнов – барсы арыслан кебек.

Лаптев – танк командиры, каны – кайнар, рус каны.
Татар, казах һәм белорус – кырындагы дуслары.

Барды аларның танкысы, киң юл салды чылбыры, –
Тапталды, җирдә сытылды фашист – үләт кыргыры.

Барды аларның танкысы, сулап бөтен сулышка,
Дүрт кыю дус, игзәк туган, керде бергә сугышка.

Кем дисәгез – очып барып эскадрилья алдыннан,
Штурм ясап, дошман явын кырган, изгән, яндырган? –

Ул – офицер Хәлиуллин Мисбах, егет, яшь батыр,
Бөгелмәдән яуга килгән, көрәштәш, якташ батыр.

Бар бездә – сугып яшендәй, дошман явын җимергән,
Аркылы фронт сызыгын, «тел»ләр тотып китергән,

Төннәрендә пычак булып, дошманнарга кадалган,
Данлы Әскәров Гарәфи – разведкачы каһарман.

Бар аның якын дуслары – игзәк туганнар төсле,
Берсе Емченко Николай, Салихов Әхәт берсе.

Берсе ятып саклап калды, икесе «тел»гә ташланды,
Шулай итеп, бу өч батыр кыен эшләр башкарды.

Шулай алар бергә-бергә булып батыр һәм чыдам,
Суктылар барып дошманга җанлы яшеннәр сыман.

Алдылар бергә дошманнан ярсулы солдат үчен,
Емченконың Украинасы, семьясы, йорты өчен.

Кем дисәгез – дошман өчен үлем тынын сулаткан,
Төзәп немец танкларына һәлак иткеч туп аткан? –

Ул – безнең Гариф Харисов, бездә данлы, хөрмәтле,
Омтылышлы зур һөҗүмнәр аның исемен гөрләтте.

Самолетның винты белән төнге күкне ярдырган,
Һәлак иткеч бомбаларын дошманнарга яудырган

Ул – Мәгубә Сыртланова, гвардияче батыр кыз,
Идел-йортта канат ярган лачын йөрәк, лачын кыз.

Бар аның бер көрәштәше, юлдаш, иптәш, дус кызы,
Тоня Розова – штурман, курку белмәс рус кызы.

Ирек, шатлык, хокук, бәхет, азатлыкны саклауда,
Рус кызы һәм татар кызы барды алгы сафларда.

Суктылар алар дошманга, ут-яшен күк булдылар;
Мәгубә – илтте очкычны, Тоня – койды бомбалар.

Кичтеләр алар бергәләп бөек сугыш ялкынын,
Кара төннәр караңгысын, болыт, томан, яңгырын.

Дәһшәтле сугыш алласы – артиллерия көченнән
Күп фашистны, күп киртәне кырып, ватып бетергән

Ул – Җиһаншин, ул – Габдулла, туган яктан бер батыр,
Дивизионын алга илткән, чыныккан, тимер батыр.

Пехота – кырлар патшасы, бар шунда бер сугышчы,
Уттан-судан алга барды, үтәп барлык бурычны.

Бик күп кырды дошманнарны бу пехота укчысы.
Ул – Габдулла Насыйбуллин, җитез егет, ут кеше.

Бар аның бер көрәштәше, бер яшь егет, мут егет,
Чыныктылар алар бергә сугыш кырында йөреп,

Ул яшь егет – азәрбайҗанлы Мөхәррәм Кәрим углы.
Үттеләр алар бергәләп жиңүгә илткән юлны.

Барды алга бу ике дус, барын бергә кичереп,
Яуның барлык бетон өнен, киртәләрен җимереп.

Барды алга бу ике дус, үтеп чит-ят басудан,
Берсе – безнең туган яктан, берсе килгән Бакудан.

Өстә һаман бер-бер артлы мина, снаряд улашты,
Шунда да нык, батыр сапер батальонга юл ачты.

Бу – үлемсез, көчле егет, гвардиянең саперы
Ваһап Шаһиев – сугышчы, Татарстан батыры.

Барды сугыш бер тынып та, бер кабынып яңадан,
Шунда Завьялов – командир ауды җиргә ярадан.

Килде шулчак Рәхмәтуллин аңар ярдәм бирергә,
Карамыйча өстән яуган ут, ялкын һәм тимергә.

Каршы яктан нинди көчле утлы җилләр исмәсен,
Килде Касыйм коткарырга командирын, иптәшен.

Алсу каннан ап-ак карлар бизәкләнгән урыннан
Алып чыкты русны татар, йолып дошман утыннан.

Батыр егет, командирын калдырмады әҗәлгә,
Калды Завьялов исән-сау, тагын йөз ел яшәргә.

Безнең Касыйм Рәхмәтуллин – җитез, батыр, чыдамлы,
Утлы кырдан берне түгел, йөзне йолып чыгарды.

Бөтәрләнеп утлы давыл купты бөтен якларда,
Шәмси Вәлиев – рядовой, пулеметтан атканда.

Кырды шулай палачларны Шәмси – татар солдаты,
Ураз Җаббаров – төрекмән бирде патрон тасмасы.

Күбәү алар баһадирлар, безнең сафта барсы да,
Күкрәкләрен өчәр-дүртәр орден, медаль балкыта.

Әй сез, безнең көрәштәшләр, уйдаш, якташ, илдәшләр,
Ата-ана, кардәш, дус-иш, тугрылыклы иптәшләр!

Безгә ярдәм иттегез сез, гайрәт, куәт китереп,
Бергә янып, бергә сулап, барын бергә кичереп.

Безгә ярдәм иттегез сез, бик күп авырлык күреп,
Көнне-төнне бергә ялгап, маңгай тирләре түгеп;

Батырларча чыдам булып, ял-йокыдан ваз кичеп,
Заводларда, кырда эшләп, юллар төзеп, таш кисеп.

Улларыгыз Ватан өчен батырларча сугышты,
Тоеп сезнең мәхәббәтне, сезнең җылы сулышны.

Торды безнең күз алдында фабрика корпуслары,
Арча, Сарман, Әлки, Кайбыч, Азнакай колхозлары.

Эшләдегез бер семьяга, бер отрядка тупланып,
Безнең бөек җиңүләрдән канатланып, рухланып.

Гөрләде күктә очкычлар, күкрәде тупларыбыз,
Рәхмәт сезгә болар өчен, сугышчан дусларыбыз!

Күз ачкысыз кышкы буран китсә дә кырны күмеп,
Туңдырмады сезнең кием, сезнең колаклы бүрек.

Булды һаман безнең өчен сезнең йөрәк хисегез,
Илһам, сәләт, талантыгыз, бөтен гакыл көчегез.

Фән, техника, культурада алтын битләр яздыгыз,
Килеп торды безгә һаман сезнең иҗат яктыгыз.

Шушы сезнең фидакарьлек, хезмәттәге батырлык –
Мәңге-мәңге онтылмаслык, тарихларда калырлык!

Шулай, дуслар, батырларча хезмәт итеп тагын да,
Ватан өчен, халык өчен багышлагыз барын да!

Илгә һәр көн үсеш бирсен сезнең эшчән кулыгыз,
Яуда җиңгән батырларга лаеклылар булыгыз!

Борылмагыз каршы яктан көчле җилләр бәрсә дә,
Артсын хезмәт җимешегез тагын өч-дүрт мәртәбә!

Яулагыз колхоз кырында, яхшы эшләп, зур уңыш,
Һичвакыт та, һичкайда да күрелмәгән мул уңыш!

Тормышыбыз – киң туган ил, данлы, кадерле ватан,
Корычланып, колач җәеп, ныгысын, үссен һаман!

Без, үтәп сезнең наказны, илгә шатлык китердек,
Явыз фашист урдаларын изеп, таптап бетердек!

Үч алдык без явызлардан, үтәп вөҗдан кушканын,
Яптык барып Берлиндагы ут һәм сугыш вулканын!

Үттек кичеп кылыч белән барлык утлы сызыктан,
Германияне мәңгелеккә биздерергә кылычтан.

Без, үтәп маршал, юлбашчы, бөек Сталин боерыгын,
Күтәрдек изге, мәңгелек, тиңсез Җиңү байрагын.

Өстебездә җилфердәгән шушы байракка карап
Ант итәбез, сугышчан ант, халкыбыз, сиңа кабат:

Йөрсәк тә без туган илдән ерак җирдә, читләрдә –
Изге булып, якты булып, Ватан торыр хисләрдә!

Туган Кызыл Армия өчен бөтен көчне салырбыз,
Аның барлык кануннарын төгәл үтәп барырбыз!

Биек тотып җиңүченең мәртәбәсен һәм данын,
Хәзер торырбыз үтәргә илнең бөтен фәрманын!

Мең яшәсен ныклы Союз – якты бәхет терәге!
Башкалабыз бөек Москва – туган илнең йөрәге!

Мең яшәсен туган җирдә канат ярган лачыннар!
Рус коралын данга күмгән һәм җиңүчән батырлар!

Мең яшәсен Кызыл Армия – тимер куллы сакчыбыз!
Эштә тырыш, яуда батыр һәм патриот халкыбыз!

**Хатка кул куйдылар:**

Генерал-лейтенант *Якуб Чанышев*, Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, II дәрәҗә Суворов, I дәрәҗә Кутузов орденнары һәм «ЭККАның XX еллыгы» медале белән бүләкләнгән; генерал-майор *Фатыйх Булатов*, Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, II дәрәҗә Суворов һәм «Мактау билгесе» орденнары кавалеры; генерал-майор *Хәбиб Ганиев*, Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; Советлар Союзы Герое өлкән лейтенант *Габдуллаҗан Булатов*; Советлар Союзы Герое лейтенант *Хамазан Гыйззәтуллин*; Советлар Союзы Герое кече лейтенант *Вилдан Хәбиев*; Советлар Союзы Герое өлкән сержант *Сәетнәфи Сәетвәлиев*; Дан орденының тулы кавалеры кызылармеец *Хөсәен Зарипов*; Дан орденының тулы кавалеры кызылармеец *Даян Булатов*; подполковник *Солтан Газизов*, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз һәм «Мактау билгесе» орденнары кавалеры; подполковник *Сергей Кожевников*, Ленин ордены, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм ике Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; подполковник *Нургали Байбиков*, ике II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм өч медаль иясе; майор *Кәшшаф Юмаев*, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; Татарстан АССР Верховный Советы депутаты майор *Алексей Марков*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; майор *Гани Гыйльманов*, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; майор *Шәриф Булатов*, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан

сугышы орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; майор *Хикмәт Моратов*, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сталинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; капитан *Хаҗи Фәттахов*, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сталинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; фронтовик-шагыйрь *Шәрәф Мөдәррис*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия капитаны *Насыйп Гобәйдуллин*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; капитан *Җиһанша Кашшапов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; капитан *Хаҗи Булатов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; кызылармеец *Миңлезариф Шадаев*, II һәм III дәрәҗә Дан, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Мөхәммәт Сөбханкулов*, III дәрәҗә Дан ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Вәли Җиһаншин*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; капитан *Сөләйман Хәеров*, Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; кызылармеец *Габделхәй Кәбиров*, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм ике Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; кече лейтенант *Каюм Габдерәхимов*, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; кече лейтенант *Ибраһим Әхмәров*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; фронтовик-язучы *Хатип Госман*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Гаделша Алешин*, II һәм III дәрәҗә Дан, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; гвардия старшинасы *Кутуз Галиев*, II дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм дүрт медаль иясе; гвардия өлкән лейтенанты *Мәгубә Сыртланова*, Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм «Кавказ оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Әлтәф Гайнетдинов*, III дәрәҗә Дан ордены кавалеры; кызылармеец *Муллый Ягъфәров*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; кызылармеец *Әхәт Салихов*, II һәм III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән сержант *Габдерахман Галимов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; медицина хезмәте өлкән лейтенанты *Ләлә Габбасова*, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән; капитан *Абдулла Әхмәдиев*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Галим Нуретдинов*, I дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры; кызылармеец *Равил Гайнетдинов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән лейтенант *Сәмигулла Мөхәммәтдинов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия старшинасы *Рөстәм Халитов*, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; фронтовик-язучы *Гамир Насрый*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; старшина *Шамил Хәйруллин*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Хәмит Хөсәенов*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; кызылармеец *Хәйретдин Айзәтов*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Әхмәтҗан Хәсәншин*, Кызыл Байрак ордены кавалеры; кече сержант *Мөсәтдика Шаһиәхмәтова*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия өлкән лейтенанты *Фәрваз Хөсәенов*, Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры; сержант *Ирек Халиков*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия өлкән лейтенанты *Дәминдар Паскиев*, ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән; сержант *Петр Сафронов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Касыйм Рәхмәтуллин*, Кызыл Байрак ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; майор *Абдулла Янбарисов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; лейтенант *Габделхәй Салеев*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры; кече сержант *Җәүһәр Шакирова*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән сержант *Сәгыйть Бәдретдинов*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән; старшина *Якуб Мостафин*, III дәрәҗә Дан ордены һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; Татарстан АССР Верховный Советы депутаты сержант *Рәхим Шәрипов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; өлкән сержант *Каюм Фәсхетдинов*, II һәм III дәрәҗә Дан орденнары, «Батырлык өчен» һәм «Ленинград оборонасы өчен» медальләре белән бүләкләнгән; кызылармеец *Гариф Шәймурзин*, Кызыл Йолдыз ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия кызылармеецы *Рәхимҗан Әхмәдиев*, III дәрәҗә Дан ордены һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Нурмөхәммәт Мәһдиев*, ике медаль иясе; кызылармеец *Шакир Вәлиев*, өч медаль иясе; фронтовик-язучы *Атилла Расих*; сержант *Әнвәр Байтимеров*, II дәрәҗә Ватан сугышы, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Җәүһәр Гәрәева*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; гвардия сержанты *Заһидулла Фәтхуллин*, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; ефрейтор *Хатип Сәхабетдинов*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; өлкән сержант *Муллагали Мостафин*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; гвардия сержанты *Габдулла Едиханов*, I дәрәҗә Ватан сугышы, III дәрәҗә Дан, Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры һәм ике медаль иясе; өлкән сержант *Нигъмәт Фәррахов*, Кызыл Йолдыз һәм III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры; өлкән сержант *Тәзкирә Әхмәдиева*,

«Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; сержант *Хаҗи Фәезов*, III дәрәҗә Богдан Хмельницкий ордены кавалеры; старшина *Мансур Мостафин*, III дәрәҗә Дан ордены кавалеры һәм ике медаль иясе; медицина хезмәте капитаны *Гөлйөзем Хәмидуллина*, «Сугышчан хезмәтләр өчен» медале белән бүләкләнгән; фронтовик-художник *Мәхмүт Усманов*; кече лейтенант *Сәхи Галиуллин*, II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән; кызылармеец *Сабур Хуҗасәетов*, Кызыл Йолдыз ордены кавалеры һәм ике медаль иясе һәм башкалар.

Хатка барлыгы 4000 нән артык кеше кул куйды.

*Шагыйрь Аитзәк Аитов 1908 елның декабрендә хәзерге Саратов өлкәсенең Дергач районы Алтата авылында крәстиян гаиләсендә туа. Сабый чакта ук әтисез калып, җиде яшеннән үз көнен үзе күреп үсә: көтү көтә, ялчылыкта йөри. Октябрь инкыйлабыннан соң, хакимият вәгъдә иткән яңа тормыш кору идеяләре белән рухланып, авылда беренчеләрдән булып комсомолга языла. 1928 елда район комсомол комитеты яшь егетне Мәскәүгә кыска мөддәтле курсларга укырга җибәрә. Укуын тәмамлап кайтканнан соң, А.Аитов туган төбәгендә төрле җаваплы урыннарда эшли, 30нчы еллар башында берникадәр вакыт авыл советы рәисе булып та тора. Аннары Донбасска китеп, шахтер хезмәтен башкара. Шушы елларда ул бик мавыгып әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый: шигырьләр, очерклар, мәкаләләр яза. Алар шул елларда (1930–1937) Донбасста (Сталино шәһәрендә) татар шахтерлары өчен чыгып килгән «Пролетар» газетасында даими басылып торалар.*

*Ватан сугышы башлануга, А.Аитов фронтның алгы сызыгында. 1941 елның 23 октябрендә Смоленск өлкәсендәге Демидов шәһәре өчен барган сугышларның берсендә ул дошман пулясыннан һәлак була.*

*Аитзәк Аитовның зур булмаган шигъри иҗатында шул чор өчен характерлы темалар – авылны күмәкләштерү, илне саклау, комсомол яшьләр тормышы, хезмәт темалары яктыртыла. Шагыйрь иҗат мирасыннан аерым үрнәкләр 1961 һәм 1985 елларда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкларда урын ала.*

## САКТА

Саргылт бөдрә чәчле,
Соры күзле,
Шат күңелле егет син идең.
Кулыңа мылтык алып постка бастың,
Кызылармеец дустым, син бүген.
Мин беләмен сине, трактор заводында
Деталь әзерләдең, егетем,
Аерылдың син сөйгән станоктан,
Теләп алдың сакчы билетын...

* * *

Ярга бәрелә, ярга таба чәчелә,
Ярның битен үбә дулкыннар,
Ярдан ашып, ярны узмак була,
Ярга сузыла шаулы дулкыннар...
Исмә, давыл, тукта!
Тынлык сакласыннар дулкыннар!
Әнә кемдер төннең уртасында
Яр битендә утыра явыз уй уйлап...
Әллә, караңгы төннән файдаланып,
Бандит сер алырга чыкканмы?
Әллә адашканмы?
Әллә аны кемдер
Бугазыннан барып тотканмы?
Әй, якын килмә!
Юкса сакчы мылтык төзи кара шәүләгә...
Бу – безнең чик!

Никадәрле дулкын котырса да,
Сакчы сизгер тора ил өчен,
Чигенмәс ул дошманнардан куркып,
Үлсә үләр туган җир өчен!
Караңгы төн сезгә файда бирмәс,
Без җуябыз кара шәүләне,
Ай качса да болыт астына,
Сакчы күрер качкын гәүдәне.

*1935*

**ЧАҢГЫДА**

Кышны ямьсез диләр,
Ялганлыйлар,
Булдыксызлар гына шулай ул,
Ударникка салкын кыш та дус:
– Чаңгың белән кил, ди,
Суза кул.
Ябалактай ак кар төшкәч тә,
Бизәк ясап аңар,
Чаңгычылар үтә болыннан,
Ерак юллар тиз-тиз якынлаша,
Җил дә керми безнең куенга.
Выж... киләсең,
Чаңгың алга йөгерә,
Тән кызыша, күкрәк киңәя,
Даулап китсә чаңгың,
Ауналасың,
Йөрәк батырлана, сөенә...
Вәлине әйтәм,
Рабфак егетен,
Откатчица Мәрьям белән бергәләп
Киң яланда
Ап-ак кар өстендә
Чаңгы шуалар аунап-тәгәрәп.
Мәрьям – тырыш кыз ул,
Откаткада вагон куган күк,
Чаңгыда да шуа-өйрәнә,
Кара чәчен җил тарата,
Кабаланып шуып килгәндә.
Вәли белән кулга-кул тотынып,
Карны үбә алар чаңгысы,
Әй күңелле,
Парлап йөгерәсең,
Бер-берең нән артта калышмый.
Эшчән кызлар,
Эшчән егетләр
Кышның ямен шулай табалар,
Кыр казлары кебек
Сафка тезелеп,
Чаңгычылар кырга китәләр.

*1938*

*Совет чоры татар балалар әдәбиятының күренекле вәкиле һәм 1941–1945 еллардагы Ватан сугышы каһарманы Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Спас районы) Көек авылында урта тормышлы игенче гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. Аның ата ягыннан бабасы Нурулла шушы авылның нәселдән килгән указлы мулласы булып, әтисе Габделбари абзый, дүрт*

*ел солдат хезмәтендә йөреп кайтканнан соң, ата йортында күбрәк хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгән – иген иккән, умарта караган. Табигате белән киң күңелле һәм үз заманы өчен алдынгы фикерле кеше буларак, ул өйгә төрле газета-журналлар алдырган, балаларын кече яшьтән үк хезмәткә өйрәтергә, белемле һәм тәрбияле итәргә тырышкан. Абдулланың әнисе Газизә апа да авыл халкы арасында укымышлы хатын булып саналган, әдәбиятны бик яратып, шигырьләр һәм бәетләр чыгарырга һәвәс булган. Абдулла шушы тату, хөр фикерле һәм хезмәт сөючән ишле гаиләдә кечкенәдән үк зирәк һәм зиһенле малай булып үсә, алты-җиде яшьләрендә әнисеннән укырга-язарга өйрәнә, аннары авылдагы ибтидаи (башлангыч) мәктәптә укый.*

*1917 елда тугыз яшьлек Абдулланы әтисе үзләреннән унбиш чакрым ераклыктагы Ямбакты авылы мәдрәсәсенә илтеп бирә. Абдулла монда 1919 елга кадәр укый. 1919–1921 елларда туган авылларына күрше Бураково дигән рус авылында яңа ачылган совет мәктәбендә укуын дәвам иттерә, аннан Спастагы (1991 елдан Болгар шәһәре) педагогия техникумы каршында оештырылган җидееллык рус мәктәбен тәмамлый (1927). Мәктәптә уку елларында, фәннәрне бик яхшы үзләштерү белән бергә, драма һәм әдәбият түгәрәкләре, музыкаль кичәләр оештыру, стена газеталары, кульъязма журналлар чыгару кебек мәдәни эшләрдә башлап йөрүчеләрнең берсе була, үзе дә шигырьләр, кечкенә күләмле хикәя-парчалар язуда каләмен тибрәтә башлый.*

*1927 елның җәендә А.Алиш Казанга килә һәм Казан җир төзү техникумына укырга керә. Техникумда уку чорында (1927–1930) аның әдәбият белән кызыксынуы тагын да арта: ул шәһәрдәге әдәбият түгәрәкләренә мавыгып йөри, техникумда кульъязма рәвешендә чыгып килгән «Кызыл төзүче» исемле газета һәм «Яңа белгеч» дигән журнал идарәсенең актив әгъзасы була, техникум һәм яшьләр тормышы турында язган хәбәрләре, мәкаләләре белән республика көндәлек матбугатында да катнаша башлый. 1929 елда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында «Абдул Алишев» имзасы белән яшь авторның «Әти, эчмә!» дигән беренче хикәясе басылып чыга. Аннан соң күп тә үтми, балалар тормышын, аларның җәмгыятькә файдалы хезмәттә катнашуларын һәм күңелле ял итүләрен тасвирлаган «Бозлар акканда», «Нәни кооператор», «Отряд умартасы» кебек кечкенә хикәяләре дөнья күрә.*

*Җир төзү техникумын тәмамлагач, 1930 елның гыйнварыннан көзенә кадәр А.Алиш Минзәлә кантоны җир бүлегендә мелиоратор булып эшли, аннан, 1931–1932 елларда, янә Казанга кайтып, Казгрэс (ТЭЦ №1) төзелешендә гидротехника буенча десятник һәм Казан шәһәр канализациясе төзелешендә техник-бригадир вазифаларын башкара. 1933 елда әдәби зәвыкка ия булган яшь белгечне Казанда татарча чыга торган «Техника» журналының җаваплы сәркәтибе итеп билгелиләр. 1937 елдан Ватан сугышы башланганга кадәр А.Алиш «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы редакциясендә һәм Татарстан радиокомитетында әдәби мөхәррир хезмәтендә. 1936 елдан башлап, төп эшеннән аерылмыйча, Казан педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Бер үк вакытта А.Алиш балалар арасында әдәби түгәрәкләр оештыру юнәлешендә бик актив эшли. 1933 елдан ул җәмәгать эше тәртибендә әүвәл Мулланур Вахитов исемендәге завод каршындагы, аннары Казанның Үзәк пионерлар клубы, Идел буе районының балалар китапханәсе, 1936 елдан «Пионер каләме» журналы редакциясе каршындагы әдәби түгәрәкләргә җитәкчелек итә, өлкән дус һәм остаз буларак, дистәләрчә балаларның әдәби сәләте ачылуга эчкерсез ярдәмен күрсәтә. Казаннан читтә яшәүче яшь каләмнәр белән хатлар алыша, әдәби иҗат эшенең серләре хакында аларга үзенең фикер-карашларын, киңәш-теләкләрен язып җибәрә, матбугатта махсус балалар иҗатына багышланган мәкаләләр бастыра. Соңыннан әдәбиятта исемнәре танылган Җәвад Тәрҗеманов, Гарәфи Хәсәнов, Рафаил Төхфәтуллин, Мәхмүт Хөсәен, Самат Шакирлар нәкъ менә Абдулла Алишның турыдан-туры иҗади ярдәме һәм киңәшләре белән рухланып әдәбият мәйданына аяк басалар.*

*30нчы еллар – Абдулла Алишның әдип буларак иң күп язган, әсәрләре белән үзен яшь укучыларга таныткан чор буларак та үзенчәлекле. Аның балалар өчен «Отряд флагы» (1931), «Дулкыннар» (1934), «Ант» (1935) исемле хикәя җыентыклары, «Йолдыз» (1935), «Кечкенә торкын» (1941) исемле пьеса-лары (беренчесе А.Әхмәт белән берлектә язылган), 1940 елда «Илгиз белән икебез» һәм «Минем абый» исемле ике шигырь китабы басылып чыга. Язучы зурлар өчен дә нәтиҗәле эшли: күмәк хезмәт темаларына багышланган күпсанлы очеркларын, яшьләр арасында мәхәббәт, гаилә кору кебек әхлакый мәсьәләләрне яктырткан «Яңа килен» (1931), «Тиздән туй» (1939), «Кыйммәтле җәүһәр» (1940) исемле хикәяләрен, «Күршеләр» (1934, А.Әхмәт белән берлектә язылган) исемле дүрт пәрдәле пьесасын язып бастыра, 1932 елда исә аның Татарстандагы шул чор зур төзелешләреннән Казгрэсны аякка бастыруда хезмәт энтузиазмын чагылдырган, шул хезмәт киеренкелеге шартларында кешеләр арасында яңача мөнәсәбәтләр формалашуын заманга хас идея-эчтәлек таләпләре яссылыгында шактый җанлы итеп, романтик күтәренкелек белән сурәтләгән «Якты күл буе» (1933) исемле күләмле повесте дөнья күрә.*

*Шулай да Абдулла Алишны балаларның сөекле язучысы итеп таныткан әдәби өлкә ул әкият-хикәят жанры әсәрләредер. Әдипнең «Капкорсак патша» исемле беренче әкияте 1934 елгы «Пионер каләме» журналының 2 нче санында басылып чыга һәм нәни укучылар арасында бик тиз популярлык казана.*

*Шуннан соңгы биш-алты ел эчендә (1935–1941) А.Алиш ике дистәдән артык әкият һәм хикәятләр иҗат итә («Нечкәбил», «Сертотмас Үрдәк», «Койрыклар», «Мактанчык Чыпчык белән тыйнак Сыерчык», «Песиләр һәм Күселәр», «Чуар тавык», «Бал Корты һәм Шөпшә», «Кем көчле?», «Бикбатыр белән Биккуркак», «Чукмар белән Тукмар», «Куян кызы», «Бик яхшы сабак алды Ябалак», «Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык» һ.б.). Нигездә, рифмалы ритмик проза калыбында, балалар психологиясенең бөтен нечкәлекләрен тоеп, композицион яктан төзек-җыйнак, уку өчен кызыклы-маҗаралы, музыкаль яңгырашлы итеп, сурәтләү чараларына бай, образлы тел белән язылган бу әкиятләр һәм хикәятләр нәниләрнең акыл сәләтен, фантазияләрен үстерүдә, кечкенәдән үк балаларда хезмәтне ярату, ата-анага, олыларга ихтирам саклау, гадел, намуслы булу, әйләнә-тирә табигатькә, терек дөньяга сак караш булдыру кебек әхлакый, әдәплелек сыйфатларын тәрбияләүдә бүгенге нәни укучылар өчен дә үзләренең әдәби-сәнгати әһәмиятләрен югалтмыйлар. А.Алиш әкиятләренең зур тиражлар белән кат-кат басылулары һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп уңыш казанулары да шул хакта сөйли.*

*Ватан сугышы башлангач, А.Алиш 1941 елның июль аенда армиягә алынып фронтка озатыла һәм солдат-радист сыйфатында Орел өлкәсендә барган оборона сугышларында катнаша. Шул елның 12 октябрендә Брянск шәһәре тирәсендәге канлы бәрелешләр вакытында чолганышта калып, ул немецларга әсир төшә. 1941 елның кышын Литвадагы хәрби әсирләр лагеренда торганнан соң, 1942 елның язында фашистлар аны Чехословакиядәге Сандау шәһәренә күчерәләр. Ахырда ул Польшадагы Седльце шәһәренә, аннан Берлин янындагы Вустрауга килеп эләгә. Монда А.Алиш Германия гаскәри көчләре составында татар әсирләреннән төзелгән «Идел-Урал легионы»нда антифашистик яшерен оешма әгъзасы Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, аларга кушылып, тиз арада яшерен оешманың иң актив әгъзаларының берсенә әверелә. Бераздан ул татар легионерлары өчен Берлинда рәсми чыгарыла торган «Идел-Урал» газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша һәм, шундагы урыныннан файдаланып, типография ысулы белән антифашистик листовкалар, өндәмәләр бастыруны җайга сала. «Идел-Урал легионы»ның немец офицерлары җитәкчелегендә белорус, украин, поляк, француз партизаннарына каршы сугышка җибәрелә торган гаскәри берәмлекләрен баш күтәрергә, партизаннар ягына чыгарга өндәгән бу листовкалар татар легионерлары арасында А.Алиш аша, турыдан-туры аның катнашында таратылалар. Җәлилчеләр оешмасының антифашистик актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар әсирләреннән төзелгән батальоннарның яртысына якыны партизаннар ягына күчеп, партизан отрядлары белән бергә фашист гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша, ә легионерларның калган гаскәри берәмлекләрен немец командованиесе таратырга яисә чит илдәге төбәкләргә күчерергә мәҗбүр була.*

*1943 елның августында яшерен оешманың эше ачылып, А.Алиш һәм башка җәлилчеләр кулга алына һәм төрмәләргә ябыла. Яшерен оешманың үзәген тәшкил иткән унбер җәлилчене әүвәл Берлиндагы Моабит төрмәсендә тоталар, аннары Дрезден шәһәрендәге Плетцензее төрмәсенә күчерәләр. 1944 елның февралендә шунда А.Алишка һәм аның көрәштәшләренә суд була. Фашистик хәрби суды аларны «дәүләткә каршы җимерү эше» алып баруда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында хөкем карары гамәлгә ашырылып, әсирлектә фашизмга каршы тиңсез көрәш алып барган унбер татар каһарманының (Абдулла Алиш, Әхәт Атнашев, Абдулла Баттал, Галләнур Бохараев, Фуад Булатов, Муса Җәлил, Гайнан Курмаш, Фуад Сәйфелмөлеков, Әхмәт Симаев, Зиннәт Хәсәнов, Гариф Шабаев) гомерләре өзелә.*

*Абдулла Алишның тоткынлыкта әдәби иҗат эше белән шөгыльләнгәнлеге дә мәгълүм. Сугыштан соң 50нче елларда ук аның унбишләп шигыре хәрби әсир Нигъмәт Терегулов күчермәләрендә илгә кайтып ирешә. Боларга тагын әсирләр лагеренда А.Алиш белән аралашкан һәм аның кайбер шигырьләрен ядка алып, хәтерләрендә саклап кайткан элеккеге әсир Газыйм Кадыйров һәм Тәлгать Гыймрановларның күчермәләрен («Сагынам илемне», «Иркәм хаты», «Тормыш дустыма», «Кыр казлары», «Төн. Бүлмәдә тыныч кына утырам ялгыз...» һ.б.) өстәргә мөмкин. Алар үз вакытында һәммәсе дә матбугатта басылалар, ә Н.Терегулов алып кайтканнары, рус теленә дә тәрҗемә ителеп, «Три поэта-воина» (1979) исемле җыентыкта дөнья күрәләр. Болар, әлбәттә, тоткынлыкта А.Алиш иҗат иткән әсәрләрнең кечкенә бер өлеше генә. Әдипнең «Бик күп уйланылган һәм язылган әсәрләр безнең белән мәңгелеккә китәләр...» дигән сүзләре дә шуны раслый. А.Алишның тоткынлыкта язган һәм безгә инде билгеле булган шигырьләре туган илгә, туган халкына тугрылык, мәхәббәт хисләре белән сугарылган, аларны үзләренең идея-эчтәлекләре белән Муса Җәлилнең мәшһүр «Моабит дәфтәрләре»ндәге шигырьләр белән аваздаш дияргә мөмкин.*

*Әсирлектә фашизмга каршы алып барган тиңсез батырлыгы өчен Абдулла Алиш вафатыннан соң I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.*

*Абдулла Алишның әсирлектә фашизмга каршы шәхси көрәше батырлык, фидакарьлек үрнәге буларак халкыбыз күңелендә яши бирә, әдәби мирасы татар балалар әдәбиятының җуелмас рухи хәзинәсен тәшкил итә. Туган авылы Көектә аңа һәйкәл куела, мемориаль музее эшли, Казанда Республика балалар иҗаты үзәге (1961–1991 елларда А.Алиш исемендәге Пионерлар һәм укучылар*

*сарае) әдипнең исемен йөртә. 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге идарәсе карары белән балаларга атап язылган иң күренекле әсәрләр өчен Абдулла Алиш исемендәге еллык бүләкләр булдырыла.*

*А.Алиш – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҖЫР

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.

Әйтсәләр дә: алтын сарайда тор син,
Ләкин илең ирексез калсын, дип.
Әйтер идем: мине зинданга сал,
Фәкать илем ирекле булсын, дип.

Ничек тели җаның, шулай яшә,
Кара кашлы кызлар үзеңә,
Дисәләр дә, әйтер идем: кирәк түгел,
Кайтам мин, дип, зәңгәр күземә.

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөжданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

## ТУГАН ИЛГӘ

Булгач давыл ничек шауламасын,
Чайкалмасын камышы,
Ярсый йөрәк, дулкынлана, –
Авыр-авыр сагышы!

Беренче кат күзем кояш күргән
Җирләр ерак калды.
Тирә-ягым, көзге болыт кебек,
Кайгы чорнап алды.

Туган илем, барлык рухым сиңа,
Барсы синең өчен!..

Якынлыгың синең белмәдем мин
Ерак китми торып,
Ничек яшьлек тәмен без белмибез
Картлык килми торып!

## ИКЕ УЛЫМ БАР

*Алмаз белән Айвазга*

Һәрбер эшне җитез эшли торган
Корыч кебек ике кулым бар,
Ике кулым кебек үсеп килгән

Булышчым бар: ике улым бар.

Ике күзем минем – үткен күз,
Күрә кайда дошман посканын,
Ике күзем кебек ике улым
Сизгер саклар илнең постларын!

Шуышмасын дошман тирә-якта,
Колакларым яхшы ишетә,
Мин үлсәм дә, ике улым кала,
Алар ишетер икесе ничек тә.

Ике аягым минем чыдам булды,
Ерак поход чыккан чакларда.
Аякларым кебек ике улым да
Сынатмаслар әле ятларга!

## НИЧЕК КИЛЕР ҮЛЕМ

Көрәш куа утлы давыл бөркеп,
Үлем кайный тирә-ягымда.
Ничек килер үлем? дигән сорау
Һич килмәде минем башыма.

Шаян угы кургаш кисәгенең
Туры килсә минем йөрәккә,
Калган булыр идем авып шунда,
Ирешә алмыйча изге теләккә.

Явыз ачлык үзенең канлы кулын
Күп уйнатты минем тирәмдә,
Тимерчыбык белән уратылган
Хәтфә кебек яшел чирәмдә.

Үлеп калган булсам инде күптән,
Азык булыр идем кортларга,
Тоткын булып кабат килмәс идем
Менә мондый салкын йортларга.

Хәзер үлем тагын басып тора,
Баш очымда кайрый хәнҗәрен,
Тик белә алмыйм, тешне кысып
Сыкрый-сыкрый, дуслар, үләрмен.

Китмәс, ахры, бер кат минем яннан,
Шартлап тора һаман кичләрен.
Янгын чыгып янып үләрменме?
Белмим инде, ничек үләрмен.

Гильотинмы кисәр газиз башны,
Искәртмәстән яки атарлар,
Ачлык белән буып үтерерләрме
Яки биек дарга асарлар.

Ничек килер үлем – белеп булмый,
Тик билгеле шунсы хәзергә:
Тынмас, ахры, мине алып китми
Үзе белән салкын кабергә.

Ни булса да – горур үлем бит ул,
Европаның урта өлешендә.
Мондый үлем – бәхет. Теләсә дә,
Тими әле бик күп кешегә.

Күпме кәгазь языла безнең хакта,
Бәлки, кабат аны укырлар.
Иптәше өчен кеше корбан була,
Шундый инде безнең гасырлар.

Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә, ахры, кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхете өчен бирергә.

## КӨТМӘ ИНДЕ, КӨТМӘ...

*Әнигә багышлыйм*

Әнә үрдәк бәбкәләре белән,
Ә син ялгыз үзең барасың,
Син, көнләшеп аның бәхетеннән,
Моңсу гына озатып каласың.

Кая китте синең балаларың,
Арслан күк батыр улларың?
Өмет белән һаман күзәтәсең,
Кайтырлар, дип, киткән юлларын.

Былтыр койган алма какларын син,
Чикләвекләр җыеп киптереп,
– Аларга! – дип, һаман саклыйсыңмы,
Сагыш белән көтеп, тилмереп?

Төшләреңдә һаман алар белән,
Көндезләрен укып хатларын,
Теткәләнгән кәгазь битләренең
Һәрбер сүзен инде ятладың.

Язлар килер, чәчәк исе бөркеп,
Сыерчыклар кире кайтырлар.
Яңарырлар шунда йөрәгеңдәге
Бертуктаусыз янган кайгылар.

Бал кортлары очар, күбәләкләр
Берсен-берсе куышып уйнарлар.
Чәчәкләргә күмелеп торсалар да,
Куандырмас сине тугайлар.

Җир тетрәткән давыл уты, бәлки,
Карлар белән эреп югалыр,
Дөнья тынып калыр. Йөрәкләрдә
Кавышу хисе кабат кузгалыр.

Өчесенең берсе кайтмасмы, дип,
Син көтәрсең һаман аларны,
Ишек каккан саен кочакларга
Хәзерләнеп сөйгән балаңны.

Көтмә инде, көтмә, изге карчык,
Җир куенында ята улларың,
Чәчәкләргә биреп, илгә булган
Мәхәббәтле керсез уйларын.

**КЫР КАЗЛАРЫ**

Бүген иртән күрдем кыр казларын,
Көнчыгышка таба киттеләр.
Канат җилпи-җилпи каңгылдашып,
Тигез сафка тезелеп үттеләр.

Юллар озын сезнең, кыр казлары,
Урал таулары аша чыгарсыз.
Канатыгыз юлда тузанланса,
Агыйделгә төшеп юарсыз.

Әйтер идем, әгәр телен белсәм,
Әманәтем алып кит, диеп,
Туган авылым аша юллар тотсаң,
Сөйгәнемә сәлам әйт, диеп.

* * *

Төн. Бүлмәдә тыныч кына утырам ялгыз,
Күк йөзендә минем кебек ялгыз йолдыз.

Ул сүнмәде таң атканчы, Чулпан микәнни?
Көтте, ашыгып, алсу Кояш кайтып җиткәнне.

Һәр көнне ул таң атканчы тора постында,
Тапшыра җаваплы эшне Кояш дустына.

Әй син, Чулпан, серле йолдыз, ничек армыйсың?
Күп йөзләгән еллар кичеп сүнеп калмыйсың?

Күр син мине: әгәр кичтән йокым туймаса,
Җуямын исәнлегемне, күзем кан баса.

Әйтегезче, иң бәхетле кем соң дөньяда?
Нигә мин дә йолдыз түгел йә гөнаһсыз яшь бала?

Син биектә, син иректә, иң бәхетле син генә!
Күк йөзендә урын булса, ал яныңа мине дә.

Тәүбә, тәүбә, тәүбә итәм, менмимен мин биеккә,
Бар теләгем: сөйгән халкым чыксын иде иреккә.

*Мөхәммәт Шәриф улы Әблиев 1900 елның 15 июлендә Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы Даныш авылында крәстиян гаиләсендә туып үсә. Кече яшьтән үк, авыл мәдрәсәсендә уку белән бергә, төрле яллы эшләрдә көнлекче булып эшли. 1915 елда Казанга килеп, 1917 елга кадәр бай йортларында хезмәт итә. Хакимият башына большевиклар менгәч, заводта ташчы, туку фабрикасында эрләүче һөнәрен үзләштерә. 1920–1921 елларда партия-совет мәктәбендә укып аны тәмамлагач, берникадәр вакыт яңадан туку фабрикасында яшьләр арасында укыту-тәрбия эшләре алып бара. 1921*

*елда большевиклар партиясенә әгъза булып кереп, үзе теләп Кызыл Армиягә языла һәм 1922 елда тарихта басмачылар дип йөртелгән, асылда, Урта Азиядәге милли азатлык хәрәкәте тарафдарларына каршы юнәлтелгән сугышларда катнаша, соңыннан Төньяк Кавказдагы гаскәри берәмлектә элемтә буенча партия вәкиле булып хезмәт итә.*

*1923–1928 елларда М.Әблиев әүвәл Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбен, аннары Мәскәүдә икееллык хәрби-сәяси курсларны тәмамлый. Шуннан соң аны янә Урта Азиягә җибәрәләр. Ул анда рота политругы һәм рота командиры булып хезмәт итә, басмачыларның актык көчләрен юк итү операцияләрендә актив катнаша.*

*1932–1936 елларда М.Әблиев – Ленинградтагы Хәрби-сәяси академия курсанты. Аны уңышлы тәмамлагач, ул Казандагы укчылар полкында инструктор һәм хәрби комиссар сыйфатында гаскәри хезмәтен дәвам иттерә, 1939–1940 елларда исә СССР җитәкчелеге провокация юлы белән башлаган совет-фин сугышы хәрәкәтләрендә катнаша.*

*М.Әблиев Ватан сугышының беренче көннәреннән үк укчы дивизиянең сәяси бүлек комиссары сыйфатында фронтның алгы сызыгында сугыша һәм, күп тә үтми, дошман пулясыннан һәлак була.*

*Каләм иясе буларак М.Әблиев 20нче елларда яза башлый. Башта ул проза жанрында көчен сынап карый: «Минем дустым сугышта» исемле хикәя, «Ком улы», «Итекче кызы» исемле повестьларын иҗат итә. Соңга таба драматургия жанрына игътибарын юнәлтә. Аның 1923–1925 елларда язылган «Ике туй» пьесасы 1925 елда Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбенең драма түгәрәге тарафыннан сәхнәгә куелып, матбугатта уңай бәя ала. Шулай да М.Әблиевне драматург итеп таныткан әсәр – «Шәмсекамәр» драмасы. XIX гасырның икенче яртысындагы татар авылы тормышын, андагы социаль тигезсезлек, дини фанатизм шартларында тирән хисле, яшь, чибәр крәстиян хатынының фаҗигале язмышка дучар ителүен оста итеп, җанлы картиналарда сурәтләгән бу драма 1937–1938 елгы театр сезонында Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелып зур уңыш казана һәм аннан соң да озак еллар буе профессиональ һәм үзешчән театр сәхнәләреннән төшми уйналып килә. Дөрес, 30нчы елларның урталарында – авылны күмәкләштерү, кулакларны сөргенгә сөрү, дингә, дин әһелләренә каршы репрессияләр көчәйгән чорда язылып, укучы һәм тамашачы күңелендә сыйнфый күралмаучылык тойгысын уятуны максат итеп куйган бу әсәрнең халыкны диннән биздерүдә, аңарда дини нигилизм, рухи ярлылык тәрбияләүдә тискәре роль уйнавын да бу урында әйтеп үтәргә кирәктер.*

*Ватан сугышы алды елларында М.Әблиев «Лейтенант» исемле яңа пьеса яза башлый, ләкин ул аны ахыргача эшләп бетерә алмый.*

*М.Әблиев – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## ШӘМСЕКАМӘР

*(Драмадан өзек)*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Камәр.
Разия.
Сәләхи.
Гарәфи.
Галим.

Идел буенда болынлык. Кызыл, сары чәчәкләр арасында арба тәртәләренә төяп печәннән ясалган куыш. Бер читтә чәй кайнату өчен таган. Артта ара-тирә дулкынлы суның ярлары күренә. Пәрдә күтәрелгәндә, Камәр кабык арбага салган баласын тартып эштән кайта. Ара-тирә кошчыклар тавышы белән еракта чалгы кайрау ишетелгәли.

Камәр, баласын йоклатып, аш әзерләргә кайткан.

Камәр. Әлли, бәлли, бәлли-бәү,
Әлли, бәлли, бәлли-бәү,
Ай син, балам, кечкенәм,
Баллы балам, төш кенәм,
Дәү булып үс тизрәк,
Безгә кул көче кирәк.
Эм, эм, йокла, балам, җан бәгърем,
Йокла, йокла син тизрәк,
Әлли, бәлли, бәлли-бәү.

Шул вакыт еракта Разияның җыр тавышы ишетелә.

Жыр. Сандугачым, былбылым, быел кайгылы елым,
Кайгырмас идем быелын, читкә китә былбылым.
Камәр (*елмаеп*). Йоклады.

Баланың өстенә яба. Шул вакыт Разия күренә. Ул, аяк очларына гына басып, җитез генә Камәрнең күзләрен каплый.

Камәр. Әбәү!.. Кем бу?
Разия. Көнме, төнме?
Камәр (*Разияның кулларын тотып*). Разия?
Разия. Көнме, төнме? Әйт, җибәрмим.
Камәр. Төн.
Разия. Төн, сөйгәнең кем?
Камәр. Аларны такмаклар вакытым үткән инде. Җибәр әле, Разия.
Разия. Иң элек әйт, әйтмәсәң, җибәрмим.
Камәр (*Разияны кытыклый башлый*). Җибәр, дим...
Разия. Җибәрмим, җибәрмим. Иң элек әйт. Мин уйладым, шулмы?
Камәр. Әйе, шул.

Разия, көлеп, кулларын җибәрә.

Чү, шаркылдама, баланы уятасың.

Разия. Бетте, бетте. Камәр апай, җаным, ачулана гына күрмә. Мин җүләр, мин тиле, мә! Дөнгечлә, кирәгемне бир шуның өчен. (*Аркасын бирә.*)

Камәр. Фу, тинтәк. (*Елмаеп, китә.*)

Разия. Минем әле чыбык-чабык җыярга дип баруым иде.

Камәр. Шунда миңа да җыярсың әле, Разия. Әсгатьне ташлап китеп булмый.

Разия. Ярый, Камәр апай. Әсгать йокладымыни? (*Килеп ачып карый.*)

Камәр. Тимә инде, уятырсың.

Разия. Бетте, бетте, Камәр апай. Мин яратып кына... Кайчан минем дә шул Әсгать төсле кечкенәм булыр икән, әй. (*Көлә.*)

Камәр (*елмаеп, йомшак кына*). Җүләр.

Разия чыгып китә. Камәр көйләп йөри, шул вакыт Сәләхи килеп керә.

Сәләхи. Нихәл, Камәр, исәнме? (*Камәр куышка кереп китә, Сәләхи артыннан бара.*) Ник дәшмисең, авырыйсыңмы әллә?

Камәр (*куыштан атылып чыгып, бала янына бара*). Сәләхи абый, йомышың булса, зинһар, эткәй үзе кайткач килерсең.

Сәләхи. Камәр, мин сине кызганам. Хафизың инде ташлады да китте үзеңне, ул зимагур кайтмаска уйлый, диләр.

Камәр. Кирәкми, Сәләхи абый, бар, кит.

Сәләхи. Белмим, миңа карата мондый салкынлык сиңа каян килә торгандыр. Гел генә караңгы чырай күрсәтәсең. Заманында мин синең баең идем бит.

Камәр. Алла хакы өчен бар, кит, Сәләхи абый. Бәйләнмә миңа.

Сәләхи. Камәр, мин синең бәхетле булуыңны күрәсем килә. Өйләренә җил керсә, бәрелерлек әйберләре булмаган Юныс картларда яшьлегеңне әрәм уздырасың. Син яхшы аргамакларда утырып, асыл күлмәкләр киясе хатын.

Камәр. Үзең киеп утырып йөр. Мине асыл күлмәкләрең белән кызыктыра алмассың.

Сәләхи. Ташла, Камәр, шул зимагурыңны, ә баладан ничек котыласын без беләбез.

Камәр. Синдә байлык эчендә изелгәнче, Хафиз белән ярлылыкта булса да рәхәтләнеп тору мең өлеш артык.

Сәләхи. Әгәр дә мине аңласаң, мин сине хур итмәм, Камәр... (*Камәрне эләктереп ала.*)

Камәр. Син нишлисең, оятсыз! (*Тартылып ычкынып китә.*) Асрау чагымда интектерүләрең җитмәгән, хәзер балам бар өстенә мыскылларга телисеңмени?!

Сәләхи. Юк, җаным, юк. Мыскыллау турында уйламыйм да, мин сиңа асыл ефәк белән...

Камәр. Оятсыз син, пычрак кеше...

Сәләхи. Камәр! Минем кем икәнне беләсеңме?

Камәр. Бик беләм. Гөлбануның матурлыгын алдың да, матурлыгы беткәч, биләнке ясап аерып җибәрдең. Миңсылуны, йөкле чагында тибеп, вакытсыз гүргә керттең. Сәлимәнең синең белән яманаты чыгып хур булды. Хәзер мине дә алар эзеннән җибәрмәкче буласыңмы? Юк, һичбер вакытта да.

Сәләхи. Камәр, син телеңне алай бик озынайтма. Әгәр минем ачуыма туры килсәгез, тончыгасыгызны бел дә тор. Усаллыкка киткәндә, мин сезгә барыбер рәхәт күрсәтмәм.

Камәр. Ике күземнән аерылырга риза булырмын, әмма Хафизны ташлап андый кабахәтлеккә барырга гомеремдә дә риза булмам.

Сәләхи. Уйла, Камәр, мин бит сиңа яхшылыкка әйтәм... (*Разия килгәнне күреп, тиз генә чыгып китә.*)

Камәр. Минем арттан эт шикелле ияреп йөрмә.

Разия җырлап керә.

Разия. Менә, Камәр апай, чыбыкларның менә дигән яхшыларын җыйдым. Икебезгә дә җитәр.

Камәр. Ярый, Разия, рәхмәт.

Разия. Менә, Камәр апай, азрак җиләк тә җыйдым, авыз ит.

Гарәфи Хафизның сандыкларын күтәреп керә.

Камәр. Гарәфи абый, кемнеке ул сандык?

Гарәфи. Ха-ха-ха... Сөенче, Шәмсекамәр. Сөенче...

Камәр. Ә?..

Гарәфи. Хафизыңны алып кайттым... Ха-ха-ха... Сезнең монда икәнне белгәч, авылга да кайтмаган. Перевоздан чыккач, минем арбага салды да үзе печәнчеләр янында калды.

Камәр. Кайда дисең?

Гарәфи. Сәйфулла староста җир турында язган прошениеләрен алып кайткан диме шунда...

Камәр. Ул бит көзсез кайтмам дигән иде! Нигә кайтты икән?

Гарәфи. Ха-ха-ха... юл эше ул, чорт знает, белер хәл юк.

Камәр. Хатында да кайтуы турында бернәрсә дә язмаган иде.

Гарәфи. Сине сагынгандыр, сине юл буе авызыннан төшермәде, бик сорашты, ни эшләп йөри, ди. Безнең бай бик тузып йөри, ярый, мин китим әле. (*Китә.*)

Камәр. Рәхмәт, Гарәфи абый, рәхмәт.

Разия. Нинди шатлык! Камәр апай, Хафиз абый да кайткач, сез кыр эшләрен тиз бетерерсез инде.

Камәр. Шатлыгым эчемә дә сыймый, үзен күрәсем килде, әллә нәрсәләр сөйләшермен төсле. (*Бала янына килеп.*) Балам, бәгърем, атаң кайткан, диләр.

Разия. Камәр апай, ул нәрсә белә соң? Тимә, йокласын.

Камәр. Әллә ни эшләп йөрәгем сикерә башлады. (*Пауза.*) Нигә болай кинәт кайтырга булды икән?

Разия. Хафиз абый яхшы кеше ул. Син дә акыллы шул, ярлы булса да егетнең менә дигәнен сайлагансың. Синең хакта аңа никадәр яман сүзләр ишеттермәделәр. Ул аларга әйләнеп тә карамады. Менә шундый ирең булса икән.

Камәр. Нәрсә сөйлисең син, Разия?

Разия. Билләһи менә, Камәр апай, дөресен әйтәм.

Камәр (*көлеп*). Әллә Хафиз абыеңа үзеңнең күзең төшә башладымы, бик тырышып мактыйсың?

Разия. Менә кирәк булса. (*Пауза.*) Кит аннан. Камәр апа, җаным, ни эшләп алай дип әйтәсең? Башыма да килгәне юк. Икмәктер, кояштыр әгәр. Матурны матур дип кенә әйтүем.

Камәр. Мин аны үзем дә бик яратам шул, Разия. Менә әле бу салга киткәчтен дә сагынып үлә яздым. Ярый әле юанычка Әсгать булды.

Разия. Хафиз абыйны бөтен авыл ярата. Ул батыр, гайрәтле кеше бит. Аннан Сәләхиләр дә куркып торалар.

Камәр. Шулай шул. (*Пауза.*) Тик менә нигә кайтты икән ул, Разия? Киткән чакта сал эшләре беткәч затонда урнаша алсам, яхшы гына эшли башлагач та сезне дә алдырырмын дип киткән иде. Кайчан гына котылырбыз бу авыр көнкүрештән.

Разия. Анысы инде, Камәр апай, эш табу кайда да бик җиңел түгел, диләр. Югары очның шәһәрдән кайткан Әхмәтҗан Сафасы әйтә: «Дөнья кайда да бер, кайда барсаң да бер эттәхият», – ди.

Камәр. Шулайдыр инде. (*Пауза.*) Әле тик менә шушы Сәләхи эттән котылыр идем дип тора идем. Җаныма тиде бит. Хафиз кайткач кирәген бирер иде үзенең.

Разия. Хафиз абыйны бик көнче дип сөйлиләр. Камәр апай, шулаймыни?

Камәр (*көлеп*). Белмим. Нигә кайтмый инде үзе? (*Юлга чыгып карый.*)

Разия. Күренмиме?

Камәр. Галим ялгыз гына кайтып килә.

Разия. Нәрсә булды икән соң?

Галим керә.

Камәр. Нәрсә булды? Ни эшләп болай вакытсыз кайттың, Галим?

Галим. Әти кайтмадымы әле?

Камәр. Юк шул әле. Нәрсә булды, Галим?

Галим. Эшләр сүтелде, җиңги. Үрәдник җир сорап язган кәгазьләрне алып килгән. Үлгәннәрнең җирләре тагы тугыз елсыз биреләчәк түгел, ди, пүчтәк, үлгәннәрнеке түгел, тере калганнарның җире дә Сәләхи кулына кереп бетә язган. Халык тоже башын ими, бугазга-бугаз ябышып кычкырышалар.

Сәләхи белән старостаны кыйный яздылар.

Разия. Дөмпәчлисе калган үзләрен. (*Үзе дә сизми җиңен сызгана.*)

Камәр. Галим, Хафиз нигә кайтмый инде? Әллә инде җир турында эткәйгә булышырга кайтканмы?

Галим. Ну... абый молодец соң, җиңги. Сәләхи кебек эт җаннарга махы бирми. Крестьяннар старостаны чорнап алган җиргә җиткәч, арбадан сикереп төшеп калды да, эшнең нәрсәдә икәнен сорашып белеп, менә кыздыра башлады тегене, ул арада Сәләхи дә килеп җиткән. Нигә кайттың, зимагур, ди. Шуннан абый кызды. Синең башыңны юк итәргә, дип аңа ташланган иде, Сәләхи старостага әйтеп, абый белән бер унлап кешене кулга алдыртты. Синең әтиең дә алар белән эләкте, Разия.

Камәр. Шулайдыр дип кенә башыма килгән иде аны.

Разия. Әтием, бәгырем, харап кына булган икән. (*Елап җибәрә.*)

Галим. Әнә сезнең шул елау да сыкрау булыр инде. Тукта әле, ичмасам, син елап йөрәккә тоз салма, пүчтәк ул елау.

Камәр. Елама, бәгырем, елама, Разия. Алар юлбасарлар түгел бит. Җәмәгать өчен талашалар.

Разия. Ә аларны җибәрерләрме икән, Галим?

Галим. Җибәрмәсәләр, без аларны үзебез коткарырбыз.

*1929–1936*

*1941–1945 еллардагы Ватан сугышында һәлак булган зур бер төркем татар язучыларының берсе Әхтәм Әмин улы Әминев 1918 елда хәзерге Башкортстан Республикасының Илеш районы Әнәс (Әнәч) авылында крәстиян гаиләсендә туа. 1933 елда җидееллык авыл мәктәбен тәмамлагач, Свердловск (хәзерге Екатеринбург) шәһәрендәге педагогия техникумына укырга керә. Шул елларда Свердловск шәһәрендә татар телендә чыга торган «Социализм юлы» газетасында язышa башлый, шунда беренче шигырьләрен бастыра.*

*1937 елны Ә.Әминев укуын дәвам итәр өчен Казанга килә һәм Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтихан тотып, сугыш башланган елны институтны тәмамлап чыга. Шул ук елның декабрендә ул фронтка китә һәм берничә айдан, 1942 елның апрелендә, Калуга өлкәсендә барган бәрелешләрнең берсендә каты яраланып, аңына килә алмыйча вафат була.*

*Ә.Әминевнең зур булмаган шигъри иҗатыннан аерым үрнәкләр Татарстан китап нәшрияты 1961 һәм 1985 елларда нәшер иткән «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкларга һәм «Оч, Галия!», «Ил чигендә» дип аталган ике шигыре «Татар поэзиясе антологиясе»нең икенче томына (Казан, 1992) кертелә.*

## ОЧ, ГАЛИЯ!

Кара бөдрә чәчең кыңгыр салып,
Мәктәбеңнән кайткан чагында,
Сөйләдең син миңа укуыңда
Булган уңышларың хакында:
– Зур шатлык бу миңа, зачетымны
Отличнога бирдем бүген дә.
Тиздән менә, тиздән мин очармын
Илебезнең зәңгәр күгендә...
Данлы эшкә булган ашкынуың
Чыккан иде алсу йөзеңә,
Йөрәгеңнән чыккан шатлык нуры
Балкый иде матур күзеңдә.
Бүген, Галия, синнән хәбәр алдым,
Син язасың миңа хатыңда
Укуыңны яхшы тәмамлавың
Һәм очучы булуың хакында...
Әйе, Галия, безнең илебез генә
Данлы эшкә дәрт һәм көч бирә.
Бездә генә мөмкин белем алу,
Бездә генә хөрмәт кешегә.
Очучы кыз!
Эшең белән котлыйм!

Син очасың илебез күгендә.
Оч, Галия, җитез лачыннардай,
Оч, Галия, канат үзеңдә!

*1937*

**ИЛ ЧИГЕНДӘ**

Ярларыннан ташкан
Ташкыннардай,
Амур ага, Амур чайкала.
Күбекләнеп аккан елга суы
Дулкыннарын бәрә ярларга.
Батыр егет илнең чиген саклый
Шаулап аккан елга янында,
Горурлана постта торуы белән
Чәчәк аткан яшьлек таңында.
Батыр егет илнең чиген саклый,
Винтовкасын тоткан кулына.
Ерткыч фашистларга каршы булган
Нәфрәт уты яна канында.
Ул каршылый сызылып аткан таңны
Постта килеш, Амур янында.
Горурлана постта торуы белән
Чәчәк аткан яшьлек таңында.

*1937*

*Шагыйрь Мөхәммәт Ибраһим улы Әхмәтгалиев 1920 елның 21 февралендә Казан шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1938 елда Яңа бистәдәге 13 нче номерлы татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1938–1941 елларда Казан дәүләт педагогия институтының биология факультетында белем ала. Ватан сугышы башлангач, 1941 елның көзеннән 1942 елның гыйнварына кадәр Татарстанның Буа районында ныгытмалар казу эшендә була, аннары берничә ай Ленинградтан Казанга күчерелгән Калинин исемендәге заводта станочник булып эшли. 1942 елның 22 маенда фронтка җибәрелә һәм 1943 елның 21 августында Смоленск шәһәре тирәсендә барган каты сугышлар вакытында дошман пулясыннан һәлак була.*

*М.Әхмәтгалиев 1934 елда яза башлый. Беренче шигырьләре 1935 елда «Мехчы», «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында, «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналы битләрендә дөнья күрә, соңга таба «Туган ил» (1938), «Шат балалык» (1938), «Очкыннар» (1940) кебек күмәк җыентыкларда һәм альманахларда басыла. 1941 елда ул үзенең шигырьләре тупланган беренче җыентыгын басмага әзерли, әмма сугыш башлану сәбәпле, җыентык матбугатка чыкмый кала. Бары тик сугыштан соң гына яшьли һәлак булган шагыйрьнең балалар өчен «Балык тотканда» (1957), «Тегүче куян» (1959), «Елак батыр» (1960) исемле кечкенә-кечкенә өч шигъри китабы нәшер ителә. Шигырьләре шулай ук Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйрьләре әсәрләреннән төзелгән «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкларга һәм «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) басмаларына да кертелә.*

*М.Әхмәтгалиевнең шигырьләре эчтәлек ягыннан бәхетле балачак, комсомол, илне саклау, котыпны җиңү кебек шул чор поэзиясе өчен характерлы темаларга багышлана. Аның шагыйрьлек сәләте бигрәк тә кече яшьтәге балалар өчен язган шигырьләрендә («Ата һәм бала», «Балык тотканда», «Бишек җыры», «Үгез», «Сеңлем бәхете» һ.б. ) ачык күренә.*

**БЕРЕНЧЕ КӨН**

Әтәч кычкырды күптән,
Кояш елмайды күктән.

Тәмле төшләр күрдек без,
Күктә очып йөрдек без.
Бүген иртә уяндык,
Көнгә карап куандык.
Их, сикердек, шатландык,
Кош кебек канатландык.
Сентябрьнең бере ич,
Бүген уку көне ич,
Сикерешеп тордык без,
Бит-кулларны юдык без.
Ашап-эчеп киендек,
Шау-гөр килдек, сөендек.
Яңа сумканы алдык,
Китап-дәфтәрләр салдык.
Бик күңелле сөйләшеп,
Шаулашып та гөрләшеп,
Иң беренче мәртәбә
Җыйналдык без мәктәпкә.

*1939*

**МИҢА УНСИГЕЗ ЯШЬ**

Бүген миңа унсигез яшь тулды.
Унсигез кыш туган көнемә.
Алсу яшьлегемә карап көләм,
Бәхетемне уйлап сөенәм.
Йөрәктәге тиңсез шатлыгымны
Сөйлим сезгә, якын туганнар.
Мин китәрмен Кызыл Армиягә
Егерме яшь тулгач туганга.

Мин шатланып киләм урам буйлап,
Мамык карлар ява юлыма.
Миңа бар да шатлык белән карап
Елмаешкан кебек тоела.
Ә урамда бүген февраль җырлый,
Горурланып февраль елмая:
Кызыл Армияне котлап бүген,
Чәчәкләнеп мамык кар ява.

Корыч адым белән атлап килгән
Кызыл сакчыларның авазы
Җиргә генә сыймый, күтәрелә,
Яңгырата зәңгәр һаваны.
Ат өстендә килә яшь егетләр,
Шлемнарда йолдыз яндырып,
Алар үтә яшьлек җырын җырлап,
Яңгыратып якты дан җырын.
Биешәләр елгыр аргамаклар,
Тузгыталар мамык карларны.
Иртән искән йомшак кына җилдә
Дулкынлана ефәк яллары...
Их... Нинди гүзәл йомшак кышкы көн,
Чәчәкләнеп мамык кар ява.
Февраль котлый данлы армияне –
Горурланып февраль елмая.
Миңа бүген унсигез яшь тулды.
Ике елдан ярсу атларда
Мин китәрмен сөйгән Ватанымның

Якты тынычлыгын сакларга!

*1940*

## АТА БЕЛӘН БАЛА

– Бирче, әткәй, орденыңны,
Матурлап тагыйм әле.
Бөтен җирдә, синең кебек,
Мин дә макталыйм әле.
– Юк шул, улым, күчми һич тә
Балага ата даны,
Үзең укуда һәм эштә
Яулап алмасаң аны.
Үсәрсең дә, сумка тотып,
Мәктәпләргә барырсың.
Яхшы укыгач, яхшы эшләсәң,
Син дә орден алырсың!

*1940*

*Хикәяләр авторы һәм тәрҗемәче Кәшфи Басыйров (Кәшшаф Хәбир улы Басыйров) 1906 елның 17 апрелендә хәзерге Башкортстан Республикасының Бәләбәй районы Мәтәүбаш авылында туа. 1917–1921 елларда Бәләбәй шәһәрендәге алты еллык рус-татар мәктәбендә, 1922–1927 елларда Бәләбәй педагогия техникумында укый, аннары алты ел чамасы Дүртөйле (Башкортстан), Кукмара (Татарстан) төбәкләре авылларында һәм Казанда балалар укыта. 1934 елның көзеннән 1942 елга кадәр Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият бүлегендә корректор, техник редактор һәм тәрҗемәче булып эшли.*

*1942 елның гыйнварында К.Басыйров армиягә алына һәм 1943 елның 16 гыйнварында фашистларга каршы сугышта һәлак була.*

*Кәшфи Басыйров әдәбиятка хикәяче булып килә. Аның «Сәлимҗан», «Алар онытылмыйлар», «Авылда» исемле беренче хикәяләре 1925 елда басылып чыга. Аннан соң «Безнең юл» журналында «Минем сөюем» дигән шактый күләмле әсәре, 30нчы елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары»), «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналларында «Ликвидаторлар», «Секретарь», «Көзге юллар буйлап» исемле, нигездә, авылдагы күмәкләшү чоры вакыйгаларын тасвирлаган хикәяләре дөнья күрә. Соңыннан, 1958 елда, бу хикәяләр «Танышлар» исемле аерым җыентыкка тупланып яңадан басылып чыга.*

*К.Басыйровның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге аеруча мактауга лаек. Кыска гына иҗат гомере эчендә ул татар теленә шактый гына матур әдәбият әсәрләре тәрҗемә итә. Алар арасында Ю.Лебединскийның «Неделя» («Бер атна», 1936), немец язучысы В.Бредельнең «Испытание» («Сыналу», Г.Хәбиб белән уртак тәрҗемә, 1936), М.Лермонтовның атаклы «Герой нашего времени» («Безнең заман герое», 1937), Н.Гогольнең мәшһүр «Мертвые души» («Үле җаннар», 1947) романнары, В.Короленко, А.Чехов һ.б. рус язучыларының проза әсәрләре бар.*

*Кәшфи Басыйровның аерым тәрҗемәләре (Н.Гогольнең «Үле җаннар»ы) китап булып вафатыннан соң гына басылып чыга.*

## СЕКРЕТАРЬ

Эш сәгате үткән. Йомышларын үтәргә килүче кешеләр дә юк. Канцеляриянең үзендә эшләнәсе эшләр дә тәмам булган, хәтта барлык әйберләр дә җыеп куелган иде. Шулай да Гали утыра бирде. Ул башта әле генә үзе җыештырган бүлмәсендәге әйберләрнең: рәсемнәрнең, плакатларның, игъланнарның, шкафларның урнашу рәвешен караштырды. Аларның кайберсен яңадан барып төзәтте, сыпырып-сыпырып алды. Ә соңыннан, һәммәсе тәмам булгач, ишеккә табарак китте дә инде бүлмәдәге әйберләрнең урынлы тору-тормауларын тикшереп түгел, ә бүлмәнең җыйнаклыгына, күңелгә ягымлылыгына рәхәтләнеп, рәхәткә чумып басып торды. Стеналар елмайдылар. Гали үзе дә көлеп куйды. Ул, арлы-бирле йөренеп, инде күптән үк кайтып киткән председатель белән телефоннан сөйләшеп алды. Аннан соң стена буендагы диванга барып утырды.

Гаҗәп кеше бу председатель. «Йә, кайт инде, Гали, ял алды көнне вакытында кайт, әниең тәмле ашлар да пешергәндер», – диде ул Галигә. Тәмле ашлар шикелле үк, тәмле уйлар да булганын белмиме

икәнни соң ул? Менә хәзер канцеляриягә Калинин килеп керсен иде дә карасын иде. Нәрсә әйтер иде икән? «Бу бүлмәдә бер минут торасым килми» дип әйтер идеме икән яки «синең бүлмәдә, Гали, эштән соң ял итеп, рәхәт уйларга чумып утырырга да була» дип әйтер идеме икән? Председательчә уйласаң, эшләнәсе эш эшләнгән, бүлмә дә яхшылап җыештырылган булса, артык берни дә кирәкми булып чыга. Җыйнак җыештырылган бүлмәдә вакыт-вакыт ялгыз калып, шулай ук үз уйларыңны да җыйнаклап алуның тәмле аш шикелле үк тәмле булуын белми, ахрысы, бу председатель.

Каршы яктагы ачык форточкадан җил Галинең йөзенә үк искәндәй булды. Шунда ук форточка аша тыштан тавыш та бәреп керде. Күрше Галимулла хатыны Бәдәр тавышы. Әмма тәмле телле дә бу хатын. Таныш кешеме, түгелме, олымы, кечеме – һәркайсына тәмле тел белән дәшә. Әнә әле дә ул, кемнедер үгетләп: «Шулай итә күр инде, аппагым», – дип сөйли. Ә кызы, Камәр, алай түгел. Бу яктан ник әнисенә охшамады икән ул?

Көз көне, беренче кар яву белән, Галинең бүлмәсен, канцелярияне, алар менә шушылай бүгенге кебек яңабаштан Камәр белән икәүләп җыештырганнар иде. Шунда Камәр Галигә әйтә куйды:

– Бүлмәңне җыештыра башладың исә, мине искә төшерерсең, Гали, яме?! Ләкин менә бу плакатны алмаштырма, мин кайтканчы шунда үз урынында торсын. Мине сагындың исә, шуңа карап куярсың. Әнә теге уртадагы тракторчы кыз миңа бераз охшаган бит, әйеме? Әгәр инде мин кайтуга бу плакат урынында булмаса... мин үпкәләрмен...

Гали аның бу сүзләрен яратты, әлбәттә. Аларны искә төшергәч, ул менә әле дә елмаеп куйды. Ләкин шул көнне үк Камәр тагын икенче бер сүз дә әйтте. Бүлмәне җыештырып бетергәннән соң ул үзенең пилоткасын, перчаткаларын кигәч, иң элек кулын кулга, ә аннан соң сулагай куллап Галинең аркасына сукты. Галинең анысына да исе китми, андый сугу иптәшләрчә, яратып сугу гына ул. Ләкин шунда ук Камәр аңа болай диде:

– Их, Гали, Гали... нинди егет син... Ник син шундый ябык? Үзең ап-аксың...

Күптән әйтелгән шул сүзләр өчен менә хәзер кинәт кенә Галинең кәефе кырылып киткәндәй булды. Ул гына да түгел. Шулай ук бер мәктәптә укып үскән Яхъя үткән көздән элекке көзне армиягә алынган иде. Ул да алынып кайтуы белән бер карыш үсте. Ни өчендер менә хәзер Гали Камәрне дә, Яхъяны да мактанып торалар төсле фараз итте. Камәрне дә, Яхъяны да «ачы теллегә» санады. Үз-үзен, секретарь кешене, кечкенәгә санап куйды.

Ләкин мондый уйлар тиз киттеләр. Форточка аша Галимулла хатыны Бәдәрнең тавышы тагын очып керде. Ул бу юлы инде тәмле телләнеп сөйләми, ә үзенең кече кызын шактый коры сүзләр белән генә кыздыра иде. «Шуның өчен дә елап торасыңмы? Синең урыныңда Камәр апаң булса, моңа елау түгел, йөзен дә чытмас иде...» – дип сөйләнде ул. Гали, бер ноктага текәлгән күзләрен күтәреп, тирә-ягына, стеналарга карап алды. Стенадагы тракторчы кыз, тракторда барган килеш артына борылып, елмаеп кул болгый иде. Галигә ул бу юлы, чынлап та, Камәрдер кебек тоелды. Гали әле хәзер генә үзенең башына килеп киткән юләр уйлардан көлеп куйды. Ул, җиңеләеп, урыныннан торды да йөреп китте. Канцеляриянең түрендә торган Калинин, башын әле бер якка, әле икенче якка борып, бүлмәне күзәтте. Соңыннан, Гали туктагач, ул аңа туры карап торды. Аннары, аз гына елмаеп, баш каккандай булды. Галинең күңеленә тагын рәхәт булып китте. Ул форточканы япты да кайтырга чыкты.

Биби, җидееллыкны шулай ук Галиләр белән бергә тәмамлаган кыз, өч ел инде каникулга кайтмаган иде. Урамда Галигә әнә шул Биби очрады. Бибинең, аттан төшеп, чемоданнарын күтәргән килеш, өенә кайтып барышы иде. Тыкрыктан менгәндә, Гали аның чемоданын күтәрешеп менде. Шул арада сөйләшкәндә, Биби: «Мин сезгә бүген үк барырмын әле, Гали, синең белән сөйләшәсе сүзем бар», – дип әйтте. Иң элек Галине күрүенә шатланганлыгын белдерде, йөзе дә нурлы иде. Көлеп, елмаеп сөйләште.

Гали укудан, тормыштан артка калырга тырышмый һәм үзен артка калган итеп санамый иде. Ләкин Бибине күргәннән соң аңа бераз гына икенче уй төште. Дөресрәге, литфак студентыннан яхшы ук тартынып куйды ул. Шуңа күрә ул өенә кайткач та, Биби белән очрашырга әзерлекнең башы итеп, стенадагы кечкенә бер бит исемлекне алып, өстәл тартмасына яшерде. Анда, бу бер бит исемлектә, дөнья әдәбияты классиклары һәм аларның һәркайсының берәр әсәренең исеме язылган иде. «Литфак студенты көләр», – дип уйлады Гали. Биби аңа: «Бары сигез генә язучыны, аларның да берәр генә әсәрен беләсеңме?» – дип әйтер төсле тоелды. Чынлап та, Биби шул кичне үк килде. Билгеле, ул Галигә үзенең «сөйлисе сүзен» шунда ук сөйли башламады. Башта, якын танышларча итеп, исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сөйләштеләр. Гали Бибигә: «Син бик үскәнсең, тазаргансың», – дип, Биби Галигә: «Син бик чибәрләнгәнсең», – дип якыннарча, эчкерсез, күңелле һәм көлкеле сүзләр әйтешеп алдылар. Ул арада Камәр килеп керде. Ул да шулай ук дусларча ачык йөз белән һәм кулын ерактан китереп сугып күрешергә, кайчан һәм ничек кайтуы турында әйтергә генә өлгерә алды. Мәктәп директоры килеп керде. Директор сүз өчен кесәгә кермә торган кеше түгел иде. Биби белән таныш түгеллегенә карамастан, ул аның белән дә танышларча күреште, юмарт сөйләште. Галинең тәкъдим итүенә генә канәгатьләнмичә, үзе турында һәм Гали турында яңа титуллар өстәп куйды:

– Таныш булыгыз, авылның драмтүгәрәк җитәкчесенең иң өлкәне булам. Ә менә бу, Гали иптәш,

безнең маэстро һәм нәфис сүз остасы. Аның концертларын һәм чыгышларын радиодан быел, шаять, ишеткәнсездер. Бер чүлмәкче, бер чиләкче бүген безгә килмәкче дигәндәй, без аның белән менә шулай очрашабыз да торабыз инде...

Шуннан соң директор, бик кадерле нәрсә шикелле итеп, үз кулындагы китапны ике куллап Галигә тоттырды. Бу кыланыш Гали өчен яңа түгел. Директор яңа чыккан китапларны күп кешедән алда белә, башта ала һәм алган саен дус итеп Галигә күрсәтә. Гали яратып куйса, ялынып сораса, үзе яңадан алмакчы булып, хәтта аңа биреп тә куя. Ләкин бүгенге китап, «Крылов мәсәлләре» исемле бу татарча китап, директор белән Галинең икесе өчен дә чынлап та бертигез кадерле китап иде. Егетләр сөенештеләр. Гали шунда ук этажеркадан бер-ике бит кульязма суырып алып кызларга күрсәтте. Болар авылдагы көчләр белән тәрҗемә ителгән мәсәлләр, тетелеп беткән кәгазьләр иде.

Директор, Галигә карап:

– Әллә соң сөенечтән «Карга»ны хәзер үк сөйләп ташлыйсыңмы? – дип сөйләнеп алды. Ә үзе, көлдереп, очынып, мәсәлләрне берәмләп укып чыкты.

Вакыт менә шулай үтте дә китте. Биби үз сүзләрен Галигә бары урамга чыккач кына, кайтканда гына сөйли алды. Ләкин бу вакытта да ул Гали белән ялгыз гына түгел иде. Галине уртага алып, Камәр белән өчәүләп атлыйлар иде.

– Гали, – диде Биби, – мин синнән шуны сорамакчы идем: мин быел тәмамлыйм бит. Миңа Карамалы авылын тәкъдим итәләр, шуңа син ничек карыйсың?

Гали үзенең хор түгәрәге белән Карамалыга концерт бирергә баруын, аның колхоз председателен сөйләп көлдерде. Халыкка һәм бигрәк тә председательгә Галиләрнең чыгышы бик ошаган, күрәсең. Ул артистларны өйләренә озатканда килгән чаналары белән түгел, ә яхшы чана, яхшы атлар җигеп озаттырган. Карамалының Совет председателе күргән саен Галине үзләренә чакыра икән. Безгә бик шәп клуб мөдире кирәк, акчасын кызганмыйм, тиешле органнар белән үзем сөйләшермен, ризалык кына бир, дип үгетли икән.

Биби Галине үзенәрәк кысты:

– Чынлап та, Гали, менә шәп булыр иде... Мин вәгъдә бирәм алайса... Ләкин синең баруыңа ышанып... – дип сөйләнде ул.

Капка төпләренә җитеп саубуллашканда да шул ук сүзләрне кабатлады.

Ә Камәр моңа ышанып җитмәде. Ул Галине шаярып сөйли дип уйлады. Курста чакта Камәр янына МТС директоры үзе килгән иде. Ул МТСка киләсе яңа механизаторлар турында, шул исәптән Галине дә МТСка алу турында сөйләгән иде. Гали белән икәү генә калгач, Камәр сүзне шул турыда алып барды. Капкага җитеп аерылышканда, Галинең кулын җибәрми торды.

– Әйеме, акыллым, барасың бит? Бергәләп эшләрбез, вәгъдә, яме, аппагым? – дип сөйләнде.

Камәр ишектән кереп киткәнчегә хәтле Гали китми торды. Аз гына шаку белән, ишектә Галимулла хатыны Бәдәрнең: «Синме, җаным?» – дип сораган тавышын Гали тагын ишетте. Ә юлда кайтканда ул бер генә турыда, Камәрнең «Яме, акыллым...» дигән йомшак тавышы турында гына уйлады. Рәхәт иде.

Кайту белән Гали яңа хат ачты. Яхъядан иде.

«Гали, шушы айларда гына мин ике тапкыр сине тыңладым. Безнең авыл концерты бу, ә җитәкчесе минем иптәшем, дип әйткәч, иптәшләрем бигрәк күңел куйдылар. Алар бигрәк синең сөйләвеңне яраталар. Барысы да сиңа шушы хатны язып җибәрергә үтенделәр. Сезнең җырлар безне дәртләндерделәр. Мин авыл советында сезнең ничек эшләвегез турында да укып барам. Зур булмаса да, үземнең дә уңышларны язып җибәрергә булдым. Иң күңеллесе шул: төрле урында, төрле эштә эшләсәк тә, бер эш өчен янабыз. Эшлә, яхшы эшлә, дустым. Совет кешеләренең тыныч хезмәтен өзәргә теләүчеләрнең берсенә дә ирек бирмәбез! Кече командир Яхъя».

Галигә тагын рәхәт булып китте. Шушы минутта аның канцеляриядә утырасы килде. Күңеле белән ул берара шунда китте. Бер-бер артлы килеп торучы колхозчыларның, хатын-кызларның, укытучыларның, врачларның, ясле хезмәткәрләренең сорауларына шулай ук бер-бер артлы җавап биреп тору, йомышларын үтәп, канәгатьләндереп җибәрү аның үз күңелендә дә канәгатьләнү, үзенә, үзенең көченә ышаныч тудырды. Мондый тойгы бер үк вакытта аны тынычсызландырып та җибәрде. Ул өстен чишенде, өстәл тартмасындагы исемлекне яңадан үз урынына, стенага элеп куйды, галстугын бушатты да укырга утырды. Белмим Бибидән, белмим Камәрдән калган тойгылар аны дулкынландыра иде.

*1939*

## АРТИСТКА ҺӘМ ШАХТЕР

*(Артель председателе авызыннан)*

Минем артельдә шундый егетләр бар, шәһәрдән йөреп кайттың исә, күңелле итеп, дусларча итеп сорашырга керешәләр.

– Йә, шәһәрдә ни хәлләр бар, кемнәрне күрдең, без ясаган изделиеләр турында нәрсәләр ишеттең, аларны алалармы, яраталармы, нindиләрен күбрәк алалар, сөйләп җибәрче, председатель, – диләр.

Аларның шулай сорашуларына күңелем бик була. «Сөйләп җибәрче, председатель» дигән сүзләрендә үземне якын күреп дәшүләрен ишетәм, «без ясаган изделиеләрне яратып алалармы?» дигән сүзләрендә производствога үз итеп караганлыкларын, эш белән кызыксынуларын ишетәм. Шуңа күрә шәһәрдән йөреп кайткан саен аларның һәрбер соравына озаклап, озын-озын итеп, күңелләре булганчы җавап кайтарам, сөйләп бирәм. Ваклыкларына хәтле калдырмыйм. Әйтик, безнең артель ясаган пеналны магазиннан алып чыгып баручы берәр укучы баланы күрсәм, кайткач, шунысына хәтле сөйлим. Иптәшләремнең дә күңелләре бик була. Шундый «әһәмиятсез» сүзләрне дә, экият тыңлаучы балалар шикелле, нык күңел биреп, керфек тә какмый тыңлыйлар. «Ә син аны ныклабрак карамадыңмы, бер почмагында минем инициал юк идеме, ул мин ясаган пенал булгандыр әле...» – диләр.

Алар миннән үзебез ясаган изделиеләр турында гына түгел, ә шәһәрдәге яңалыклар турында да сорашалар.

Безнең авыл шәһәргә бик үк якын түгел югыйсә. Ике йөз егерме километр. Шулай да артельдәшләрем республикабызның үзәк шәһәрен яхшы беләләр. Анысына да күңелем була. Әйтик, алар, мин шәһәрдән кайткан саен: «Театрда булдыңмы?» – дип сорыйлар. Әгәр спектакль аларга таныш булса, актерлар турында, кайсы рольне нинди артист башкаруы турында сорашалар. Аннары шул спектакльне, шул спектакльдә уйнаучы республика артистларының үзләрен, уеннарын тикшерергә керешеп китәләр. Безнең авылның артель членнары республика артистларының фамилияләрен генә түгел, ә үзләрен дә ничек алай беләләр соң? Бик гади. Театрга йөрү – безнең членнарның көндәлек ихтыяҗларына кергән нәрсәләрнең берсе ул. Ә инде республика театрларын карарга омтылу бигрәк тә шулай. Була отпуск вакытлары, була ял көннәре. Ике йөз егерме километр ара безнең машиналар өчен дүрт сәгатьлек юл ул. Икенчедән, үзәк шәһәрнең артистлары, яхшы уйнаулары белән дан чыгарган артистлар, безнең авыл шикелле авылларга үзләре үк килеп спектакльләр куялар лабаса. Үткән җәйне генә, әйтик, Академия безнең авылга бөтен составы белән килде. Унбиш грузовик, унике легковой. Утырдылар да килделәр. Нәрсә әйтерсең? Безнең илдә машинага кытлыкмы әллә? Җәйнең күкрәп торган матур чагы иде. Икәвесен фатирга үземә үк алып кайттым. Хатыным ояла төште. Өем җыелмаган. Шундый зур кешеләргә уңайсыз туры килмәгәе, ди. Буламы соң? Килеп кергән уңай белән чишенеп ташладылар. Киттеләр буага. Минем анда көймәм бар. Тал төбеннән өстерәп тә чыгардым. Киттек йөзеп. Судагы төнбоекларга, ярдан, биек үлән араларыннан суга салынып торган чәчәк көлтәләренә карап җырлап җибәрделәр. Су уртасында көймәгә басып, башлары белән суга чумышырга тотындылар. Атказанган зур артистлар дип берәү дә әйтмәс. Мин дә чумам. Балалар шикелле уйныйбыз. Ә кичен, бөтен тирә-як авылларны таңга калдырып, спектакль бирделәр. Халыкның яше-карты, артистларның уйнауларын күрүгә генә канәгать итмичә, иртәгесен урамда, су буенда үзләрен күрергә, үзләре белән бергә йөрергә, сөйләшергә, бергә булырга тырыша.

Күңелле әнә шулай яшәү. Хәер, төп мәсьәләгә кайтыйк.

Шәһәргә бу килүемдә мин концертка бардым. Менә бу юлы булды соң артельдәшләремә сөйләр сүз!.. Баштан ук сөйләп биргәндә, менә ничек булды ул.

Антрактта халыкның бөтенесе дип әйтерлек запас ишектән, җәйге ишектән, бакчага чыкты. Битне, башны, бөтен гәүдәне иртә җәй төненең тәмле исле саф һавасы сыйпап алды. Шуның белән бергә биредә кинәт тын булып калгандай тоелды: аяк тавышлары ишетелмәс булды, ишектән тыгылып чыккан халык та, тавышсыз-тынсыз, сизелмәстән эрегән шикелле, каядыр таралды. Мин хәзер генә өзелгән концертның, бигрәк тә соңгы номерларны башкарган җырчының, зифа буйлы, чибәр һәм яшь артистканың, соклангыч моңы тәэсире астында яши идем әле. Күңелем матур, нечкә хисләр белән тулган иде, шул хисләрдән аерыласым килми иде. Шау-шуны, хәтта төрле якларга күз йөртеп мавыгуны да теләми идем. Хәер, башкалар да шундый ук кичерештә иделәр булса кирәк. Алар да өелешеп түгел, ә тарау йөрергә, тын йөрергә тырышалар иде бугай. Көчле лампалар белән яктыртылган яшел һәм яшь яфраклы акация, чаган куаклары арасыннан, зәңгәр буяулы яңа беседкалар арасыннан аларның берәм-сәрәм үтеп-үтеп китүләре генә күренә иде миңа. Тагын да дөресрәк итеп әйткәндә, бакча һәм андагы халык минем күз алдымда менә болай сурәтләнә иде: бакча үзе – бик көчле лампа белән яктыртылган зур өстәл өсте, бакчадагы куаклар, агачлар, беседкалар – өстәлне тутырып торучы букетлар, вазалар, кувшиннар, ә бакчадагы халык шул өстәл өстендәге лампа яктысында, чәчәк араларында талгын гына, тавыш-тын чыгармый гына очып йөрүче төрле төстәге күбәләкләр шикелле иде.

Мин, егерме-утыз яшәр бер тирәккә сөялеп, сукмак буенда басып тора идем. Тартып торуымны күреп булса кирәк, кемдер ут сорады. Тиз генә кабыздым. Башында өр-яңа очлы түбәтәй, өстендә яңа гына үтүкләнгән кыйммәтле костюм, буе-сыны матур, йөзе кояшка, җилгә каралган, чыраенда, гәүдәсендә тазалык, көчлелек сизелә, ләкин адымнары гамьсез... Бу кешедә дә чын мәгънәсе белән ял итеп йөрү сизелә иде. Менә ул каршыдан килгән ике кеше белән очрашты. Аңа дусларча сүз куштылар.

Карасам, берсе – җырчы, артистка. Алар озак күрешми торган якын дусларча ялкынланып күрештеләр. Сылу артистка күз керфекләрен сирпеп елмайды, шатланды. Алар култыклашып йөреп киттеләр. Бер круг кешеләредер, монысы командировкадан яки отпускыдан, курорттан кайткандыр, кайткач шулай күрешәсең инде аны, дип уйлап алдым мин...

Икенче көнне иртә белән мин кайтырга чыктым. Поезд озак кузгалмый торды. Минем әллә ни багажым бармыни, бер чемодан гына, тоттым да платформага – иркенгә чыктым. Карасам, перронда җырчы артистка. Өстендә дулкынланып торган, мул, юка ал күлмәк. Тигез асфальттан җилфердәп, сәхнәдәге шикелле очыныбрак атлап, берүзе киң юл ярып, туп-туры вагон тәрәзәсенә таба бара. Тәрәзәдә – кичәге очлы түбәтәйле кеше. Ул гәүдәсен күкрәгенәчә тышка чыгарган. Тәрәзә алдында аның кызылсу кыйгач буйлы матур галстугы җилферди. Ул, рәхәт елмаеп, кулларын артисткага таба сузып тора. Мин тәрәзәгә якын гына идем. Артистканың вагонга таба сузылган кулында кечерәк агач шкатулка күргәч, йөрәгем кинәт әллә нишләде.

Шкатулка өр-яңа, ул магазиннан гына чыккан, ул безнең артель изделиесе – шахмат тартмасы иде. Күз ачып йомган арада минем хәтеремә артельдәшләремнең «Син аның почмагындагы инициалын карамадыңмы, ул мин ясаган әйбер түгелме икән?» дигән сораулары килеп төште. Чынлап та, бу, бәлки, мин ясаган шахматтыр? Тагын бер генә секунд ара булса, мин аның почмагын карамастан ук, тик капкач өстендәге гравюрага күз төшереп алганда да, кем эше икәнен аера алачак идем. Ләкин вакыт көтмәде, тартманы вагон тәрәзәсендәге куллар кочаклап алды. Артистка икенче кулы белән шул ук очлы түбәтәйле кешегә зур чәчәк букеты тапшырды. Вагонның барлык тәрәзәләрендәге йөзләр елмайды, андагы кешеләрнең һәммәсе дә артисткага баш иде, саубуллашып кул болгады. Очлы түбәтәйле кеше артистка белән берничә тапкыр күңелле сүз алышты, кат-кат хушлашып баш иде. Менә ахырда ул кеше елмая биреп миңа да баш каккандай булды, мин дә аңа баш идем һәм, башкача ни дип әйтергә дә белмәгәнлегемнән, үзем дә белештермәстән:

– Ул шахмат – безнең авыл артеленең изделиесе, аны без эшләдек, уйнаганда безне дә искә алыгыз... – дип әйтеп җибәрдем һәм шунда ук артисткага таба борылдым.

Артистка керфекләрен сирпеп елмайды.

– Шулаймыни? Алайса, мин аны үзебезнең авыл кешесенә бүләк итеп бирдем. Әнә теге көлеп торганы, түбәтәйлесе, безнең авылныкы, минем авылдаш, шахтер ул, авылга кайткан, тагын да шахтерлар алып китә... – диде.

Моңа ялгап сүз кушарга миндә запас сүз табылмады. Ашыгып, каушап, чемоданымны ачтым. Анда шундый ук фасонда, ләкин кесәгә сыярлык кечкенә һәм тагын да пөхтәрәк эшләнгән шахмат гарнитурасы бар иде. (Мин шәһәргә үрнәккә дип аларны берничәләп алып килгән идем.) Тартманы алдым да артисткага суздым.

– Мин менә монысын сезнең үзегезгә бүләк итимче, кабул итеп алыгызчы, – дидем.

Артисткам тагын елмайды.

– Сез соң үзегез кайдан? – дип сорады ул.

Мин тартманың эчендәге маркага, анда язылган авыл исеменә күрсәттем, шул артельнең председателе икәнемне әйттем, ахырда: «Мин кичә сезнең концертыгызда булдым, чын күңелдән үтенәм», – дип өстәдем. Ул тартманы алды. Матурлыгын, кечкенәлеген әйтеп, сокланып карап торды да, менә монысын минем үземә бүләк иттеләр, дип, тартманы шахтерларга күрсәтте.

Мин вагоныма йөгердем.

Менә бу күңелле булды соң...

Әмма артельдәшләрем сорашырлар да инде. Алар барыннан да бигрәк артисткага тапшырылган гарнитураның кем эше булганлыгы белән кызыксынырлар. Ләкин, минемчә, мәсьәлә анда түгел. Тартма кайсыбыз тарафыннан эшләнгән булса да – барыбер. Аны, безнең авылда ясалган тартманы, - артистка кеше – сәнгать кешесе – бүләккә дип, яратып сатып алган. Аның бүләгән алыр кешеләр шахтерлар булган. Хикмәт әнә шунда! Сылу артисткалар ярата торган сәнгать әйберләре шахтерларның көндәлек тормышларына – табыннарына керә. Хикмәт әнә шунда!

*1939*

*XX гасыр совет чоры татар шигъриятенең күренекле вәкиле Нур Баян (Нур Галим улы Баянов) 1905 елның 15 маенда хәзерге Татарстан Республикасының Актаныш районы Әнәк авылында колхозчы гаиләсендә туа. Хуҗалык көчсез, тормыш авыр булганлыктан, Нурның әтисе Галим абзый үз балаларын җәйге айларда читкә акча эшләргә җибәрә торган була. Нур да, мәктәптә укулар бетеп каникул җитүгә, ел саен диярлек читкә китеп, төрле җирләрдә яллы эшләрдә йөреп кайта. 1921 елгы ачлык аны туган авылыннан бөтенләй чыгып китәргә мәҗбүр итә. Ул Пермь шәһәренә барып, кара эшче булып яллана, ә 1923 елда укуын дәвам итү теләге белән Казанга килә һәм Татар-башкорт хәрби мәктәбенә курсант булып языла. Шушында укыганда аның әдәби иҗат эше дә башланып китә. Ул авыл тормышы, Гражданнар сугышы, илне саклау темаларына беренче шигырьләрен яза. 1925 елдан башлап матбугатта аның исеме инде тәмам үз булып китә.*

*1928 елда Нур Баян Казанда чыга торган «Кызылармеец» исемле хәрби газета редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша. Шул ук елда аның «Уракчы кызлар», «Җимерелгән окоплар» исемле тәүге ике шигъри җыентыгы басылып чыга.*

*1929–1930 елларда Н.Баян «Колхоз яшьләре» журналы редакциясендә сәркәтип булып эшли, аннары аны Чаллы төбәк газетасына баш редактор итеп билгелиләр. Газетада эшләү, авылларга чыгып йөрү аңа авыл җирендәге үзгәрешләргә, крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүгә караган бай фактик материал тупларга мөмкинлек бирә. Соңыннан, шуларга таянып, ул үзенең «Клеверлы кырлар» (1929), «Яңгырлы төн» (1933) кебек поэмаларын һәм күпсанлы лирик-публицистик шигырьләрен иҗат итә.*

*1932 елда Н.Баян яңадан Казанга кайта һәм 1932–1938 еллар арасында әүвәл Татарстан Язучылары берлеген оештыру комитетында эшли, аннары Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир һәм матур әдәбият бүлегенең өлкән редакторы-мөдире вазифаларын башкара. 1938 елдан Ватан сугышы башланганчыга хәтле ул фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Бу елларда ул «Гөләндәм» исемле шигъри повестен (1939), «Җимерелгән дворец янында» (1940), Г.Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»ына ияреп «Карәхмәт» (1940) поэмаларын яза, нәшриятта «Язгы төн» (1939), «Туган авыл» (1941), «Шат җырлар» (1941) дигән шигъри җыентыклары басылып чыга. Әдәби иҗат эшчәнлегендәге уңышлары өчен һәм Совет Татарстаны төзелүенә егерме ел тулу уңае белән совет хөкүмәте аны «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкли.*

*Нур Баян Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә һәм ахырга кадәр диярлек әүвәл полк партия оешмасының сәркәтибе, аннары дивизия газетасы редакторы һәм, ниһаять, полк командирының сәяси эшләр буенча урынбасары сыйфатында фронтның алгы сызыгында хезмәт итә, сугыш кырында күрсәткән батырлыклары өчен I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. Сугыш шартларында да ул әдәби иҗат эшен туктатмый, ватандарлык хисләре белән сугарылган шигырьләрен яза («Өч бөркет» җыентыгы, 1942), поэма һәм либретто язуын дәвам итә. Ләкин Җиңү көненә нибары унбиш көн кала, 1945 елның 23 апрелендә, Австрияне азат итү өчен барган соңгы сугышларның берсендә подполковник, шагыйрь Нур Баян дошман пулясыннан һәлак була.*

*Формасы ягыннан Һ.Такташ шигъри традицияләре йогынтысында үсеп, үз заманының тормыш сулышын, бигрәк тә күмәкләшү чорында татар авылындагы иҗтимагый-социаль үзгәрешләрне публицистик пафос белән чагылдырган Нур Баянның иҗат мирасы XX гасыр совет чоры татар поэзиясенең үзенчәлекле бер өлешен тәшкил итә.*

*Н.Баян – 1934 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

* * *

Минем өстән пуля яуса да,
Җәрәхәттән каннар тамса да,
Халкым өчен постта торырмын,
Халкым өчен туры булырмын.

Авырлыклар миңа килсә дә,
Барыр юлым дошман киссә дә,
Терелләй бирелмәмен дошманга,
Хыянәт итмәм Татарстанга!

Кая гына аяк бассам да,
Тик бер генә пуля атсам да,
Сөйгән халкым өчен барысы да,
Туры улың, халкым, мин сиңа.

*1943*

## САНДУГАЧКА

Кызык кош син, сандугачым-дустым,
Туп ярыла, ә син сайрыйсың,
Тормыш итәр өчен туган илдә,
Ояң өчен куак сайлыйсың.

Матур ил шул безнең илебез,
Ал чәчәкле безнең җиребез.
Их, яшисе килә илемдә,
Һич үләсе килми тигенгә.

*Көньяк-көнбатыш фронт*
*1943*

## САНИТАРКА

Елмаясың миңа, очрашканда,
Иркәләнеп кулың сузасың,
Ә кайчакта, урман кызы сыман,
Букет тотып яннан узасың.

Яратам мин сине ут кырында
Шат булганың өчен һаман да,
Җырлыйсың син, күңел юатасың,
Синә киләм артык арганда.

Хәтерлимсең, кичә командирны
Коткардың син авыр үлемнән,
Ут кырыннан аны алып чыктың,
Кан тамчылый иде йөзеннән.

Син коткарган егет герой иде,
Сөеклесе иде Ватанның,
Сакчы улы һәм якчысы иде
Тиз киләчәк матур ал таңның.

Ут көрәше бетеп, ялан тынгач,
Очрашсак без бер үк табында,
Хәтерләрбез көрәш барган чакны
Текә таулы Донец ярында.

*1943*

* * *

Тирә-якта үлән чәчәк аткан,
Каен яфрак ярган урында
Кара күзем алга төбәп ятам
Тирән окоп һәм киң болында.

Кулымдагы җитез автоматның
Алга төбәп куйдым көпшәсен,
Мин хат яздым, тизрәк җитсен хатым,
Зәңгәр күзем яшен түкмәсен.

Хатым китте йомшак таңгы җил күк,
Гомер дустым, сөйгән ярыма,
Ә мин калдым сугыш яланында,
Караңгы төн. Бомба ярыла.

Яңгыр сыман өскә пуля ява,
Бала елый кебек еракта,
Гүя үкси анда хәлсез ана,
Иркәм тавышы килә колакка.

Ярсып-ярсып атам һәр пулямны,
Ватан өчен, туган ил өчен,
Балам өчен, атам-анам өчен,
Назлап сөйгән нечкә бил өчен.

*1942*

* * *

Хат язсам да инде бармас төсле,
Ахры, ерак киттем илемнән,
Бала чакларымда уйнап йөргән,
Чия чәчәк аткан җиремнән.

Ерак киттем. Бөдрә чәчле таллар
Көтәләрдер таныш җырчысын,
Көтәләрдер кырлар, биек таулар,
Шат күңелле еллар юлчысын.

Борчылмагыз, мине белгән дуслар,
Шат җырчыгыз сезне онытмас,
Бер кайтыр ул, якты кояш сыман,
Дошманнарны җирдән корыткач.

*Май, 1943*
*Донец*

## УЙЛАНГАНДА

– Сау бул... – диден чыгып киткән чакта,
Күзләремә тутырып карадың.
Килми миңа хәзер сәлам хат та.
– Сөям, – диден, нигә алдадың?

Иреннәрең минем битләремне
Яндырырдай итеп үпкәндә,
Мин ышандым сиңа. Мәхәббәтем
Калдырдым мин чыгып киткәндә.

Акларсыңмы минем мәхәббәтне?
Ә мин сине өзелеп сагынам,
Ник сагынам сине мин бу хәтле,
Рәсемеңә синең табынам.

Тәүфыйгыңны әгәр бозмасаң син,
Кабат әле бергә булырбыз.
Алма кебек уллар үстерербез,
Матур тормыш, иркәм, корырбыз.

*Май, 1943*
*Донец*

*Касыйм Вахит (Касыйм Мисбах улы Вахитов) 1916 елның 16 мартында хәзерге Башкортстан Республикасының Әлшәй районы Нигъмәтулла авылында урта хәлле крәстиян гаиләсендә туа. 1935 елда Дәүләкән педагогия техникумын тәмамлап, шул ук төбәкнең Искәндәр авылындагы тулы булмаган урта мәктәптә (ТБУМ) укытучы булып эшли башлый. 1937 елда Казанга килә һәм педагогия институтына укырга керә. Ватан сугышы башлануга, әле яңа гына институтның татар филологиясе бүлеген тәмамлаган Касыйм Вахит үзе теләп фронтка китә һәм сугышның беренче көннәреннән үк алгы сызыкта булып, 1942 елның 4 октябрендә Сталинград өчен барган канлы бәрелешләрнең берсендә дошман пулясыннан һәлак була. Сугышчан иптәшләре аны Шелемка дигән авыл янындагы туганнар каберлегенә җирлиләр.*

*К.Вахитның беренче шигырьләре 1932–1933 елларда Уфадагы «Коммуна» исемле өлкә газетасында (хәзерге «Кызыл таң») басыла башлый. Соңрак ул Татарстандагы көндәлек матбугатта – «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан*

*утлары»), «Чаян», «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналларында актив языша. Аның шигъри тезмәләре шулай ук яшь язучыларның «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940), «Очкыннар» (1940) исемле күмәк җыентыкларына да кертелә. Яшь шагыйрь, өйрәнү чоры кичереп, шигъри форманы төрләндерү юнәлешендә тәҗрибәләр ясый, поэзиянең төрле жанрларында көчен сынап карый. Аның зур булмаган әдәби мирасыннан «Сөйләнмәгән әкият» исемле поэмасын, Көнбатыш Украинаны СССРга кушу вакыйгасын хуплап язган «Егет турында баллада»сын, юмористик шигырьләрен һәм кечкенә лирик парчаларын атап үтәргә мөмкин. Касыйм Вахитның иҗат мирасыннан аерым үрнәкләр сугыштан соңгы чорда нәшер ителгән «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) һәм «Утлы еллар поэзиясе» (1972) исемле басмаларында урын ала.*

## УЛ

Авырлыклар килсә миңа, ул булыша,
Бөтен кешеләрдән якын ул;
Тормышымны нурландырып тора,
Минем өчен гәүһәр, алтын ул.
Бар шатлыкны бергә бүлешәбез,
Тамчы суны бүлеп эчәбез,
Ут, ялкынны бергә без үтәбез,
Агым суны бергә кичәбез.
Көне буе аны күрми торып,
Кайттым исә яллар итәргә,
Битләремнән сыйпап сөя-сөя,
Күмелдерә кайнар хисләргә.
Аның белән бергә чакларымда
Урын бетә авыр хисләргә,
Кайгым булса, чынлап кайгыралмыйм,
Аптырадым, хәзер нишләргә?
Ул дигәч тә гаебемә кереп,
Еракларга сузма уеңны.
Кызыксынсаң әгәр, сиңа әйтим,
Ул – анасы минем улымның.

*1941*

## ҮЧ

Ял итәргә килеп туктый гаскәр,
Каршы ала колхоз өйләре.
Карап тора буйга җиткән сылу,
Урам киртәсенә сөялеп.

Озын походларны үткән гаскәр
Килеп туктый сусап, талчыгып.
Йөгерә-йөгерә безгә ул китерә
Чишмә суларының салкынын.

Сугышчының шаян сүзенә дә
Илтифатсыз, дәшми, җавапсыз.
Сугышчылар һаман сүз сузалар:
«Бигрәк эре, бигрәк гаҗәп кыз!»
Йөзләрендә шиңгән алсулыклар,
Күзләренең боек карашы.
Әллә ничек сиңа серле бага –

Һәм терелтә йөрәк ярасын...

*

Немец бандалары басып алды
Гөрләп торган шаулы авылны,
Хурладылар көчләп хатын-кызны,
Таладылар соңгы кабымны.

Урам буйлап камчы хөкем сөрде,
Авыл торды канлы яшь түгеп...
Безнең Валя, Валя, гүзәл Валя
Югалтты шул үзенең яшьлеген.

Багалмадай йөзле сылу Валя
Чандыр офицерга ошаган.
Шакшы фашист,
Гүзәл рус кызының
Ачы күз яшенә сусаган.
Ак кар битен саргылт ай үпкәндә,
Валя үткән авыл урамын.
Һәм шул көнне сакчы ишетеп торган
Яп-яшь кызның үксеп елавын.
Күкселләнеп кышкы таң атканда,
Кыз чагында үткән урамын
Хатын булып үтеп киткән Валя,
Кайнар күз яшенә уралып.
Шулай Валя өйгә кире кайткан,
Тик яшьлеге кире кайтмаган,
Уйчанланган, йөзе аксылланган,
Ашамаган, берни капмаган.

Озын походларны үтеп гаскәр
Ял итәргә бүген туктаган.
Яшь комиссар күптән эш өстендә,
Кояш әле, ялкау, чыкмаган.
Күзен алмый карап торган кебек
Сөйгән кызын артык яратып,
Ак кәгазьгә төшеп эрегәндәй
Комиссарның үткер карашы.
– Иптәш комиссар!
Мине частегызның
Сугышчысы итеп алыгыз!
Намусым даулап барам үч алырга,
Пулеметчик итеп языгыз...

*

Колонналар булып безнең гаскәр
Көнбатышка узган чагында,
Күзләрендә ачы нәфрәт тоткан
Уйчан кызны күрдем тагын да.
Пар ат җиккән җиңел тачанкада
Пулеметы белән ялгызы:
Ил алдында үзенең намусын яулап,
Үч алырга китте ил кызы.

*1942*

* * *

Яшьлегемнең асыл чәчәгенә,
Тормышымның асыл гөленә,
Нинди генә җылы сүзләр әйтим,
Тәбрик итеп, туган көнеңә.

Күкрәгемә кочып сөяр идем,
Җитми анда, иркәм, колачым,
Яннарына очып кайтыр идем,
Булсам таулар гизгән бер лачын.

Татыр идем иренең кайнарлыгын,
Якын булсам әгәр яныңда,
Минем теләк: күрешергә булсын
Килер майның шушы таңында.

*1942*

## ТӘРӘЗӘҢНЕ АЧ ТА

Яшеренмә син яшеннән,
Давылдан качма.
Җәйнең хәтәр көннәрендә
Тәрәзәңне ач та.
Күкне күзәт, тибрәндерми
Керфек очыңны.
Бик якын итеп хәтерлә
Ерак дусыңны.
Яшен алсын бүлмәңдәге
Төннең карасын,
Сибелдереп чәчләреңне
Давыл тарасын.
Давыл, давыл, ул бит минем
Тере хәбәрем,
Якын яшен, ялкын яшен –
Минем сәламем.
Мин сулармын, давыл җирдә
Тынмаса әгәр,
Мин янармын соңгы яшен
Сүнгәнгә кадәр.

*Вәдүт Кашшаф улы Мифтахов 1915 елның 20 ноябрендә Татарстан АССРның Сарман районы Яхшы Каран авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа. 1931 елны Сарман җидееллык мәктәбен тәмамлый. Шул ук елны Лубян урманчылык техникумына укырга керә. Аннан соң Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.*

*Мифтах Вәдүт озак еллар Питрәч районы Шәле урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Беренче шигырьләре 1933–1934 елларда газета-журналларда басылып чыга. Яшь шагыйрьнең беренче китабы 1939 елны дөнья күрә.*

*Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк шагыйрь гади солдат булып туган илен саклауда катнаша. Фронтта ул, комсомол-шагыйрь буларак, командованиенең һәртөрле җаваплы заданиеләрен үти, гади солдаттан полк комсоргы булып күтәрелә.*

*М.Вәдүт Мәскәү янындагы сугышларда катнаша, Ватаныбызның йөрәге булган Мәскәү шәһәрен күкрәген куеп саклый.*

*М.Вәдүтнең тормышы аның иҗаты чәчәк атып килгән вакытта өзелә. Ул 1942 елның 30 мартында сугыш кырында батырларча һәлак була. Яшьлеккә дан җырлаучы солдат-шагыйрь М.Вәдүтнең җәсәде Тула өлкәсе Арсеньев районы Рыдань авылында җирләнә.*

## ҖЫР

Тал-тирәктә сайрый сандугач,
Сызылып алтын таңнар атканда,
Тавышкае өзә үзәкне,
Моңаясың өзелеп сагынгач;
Гыйшык уты дөрләп капканга,
Басып кына булмый йөрәкне,
Басып кына булмый йөрәкне.
Сандугачкай, сайра, туктама,
Кояш алтын нурын сипкәнче,
Мин тыңлармын сине, йокламам,
Күрешер минутларым җиткәнче.
Тирбәләдер җилгә тал-тирәк,
Сандугачкай канат кагына:
Яшь йөрәккә сөйгән яр кирәк,
Яшь йөрәккәй ярын сагына.
Сандугачкай канат кагына,
Сайрый-сайрый яшел тирәктә,
Тавышкае өзә үзәкне.
Җанашымны өзелеп сагынам,
Гыйшык уты яна йөрәктә,
Басып кына булмый йөрәкне,
Басып кына булмый йөрәкне.
Тирбәләдер җилгә тал-тирәк,
Яшь йөрәккә сөйгән яр кирәк,
Сөяр өчен ярлар күп була,
Саф күңелле чын дус – пар кирәк.

## ТИМЕРЧЕЛӘР

Тирән-тирән сулап, һава өргеч
Кара күмерләрне яндыра.
«Чакы-чокы» чүкеч чыңгылдавы
Бертуктаусыз тора яңгырап.
– Өрдер өргечләреңне,
Яндыр күмерләреңне лә,
Күтәр чүкечләреңне,
Һап!..
Чакы-чокы-чак!..
Очкын оча утлы күмерләрдән,
Алтын йолдыз сибелә диярсең.
Алмаш-тилмәш суга өлгер куллар,
Чүкечләргә тик күз иярсен!
Егет булсаң,
Хезмәт итеп,
Күрсәт син көчләреңне лә,
Күрсәт син көчләреңне!
Һап!..
Чакы-чокы-чак!..
Чагылып китә маңгай тирләреңдә
Күмерләрдән төшкән яктылык.
Җыр кушыла чүкеч тавышына,
Беләкләрнең көчен арттырып.
Өрдер өргечләреңне,

Яндыр күмерләреңне лә,
Күтәр чүкечләреңне,
Һап!
Чакы-чокы-чак!

*Габдулла Гали улы Галиев 1920 елның 20 июнендә Татарстан Республикасының Теләче районы Шәдке авылында мөгаллим гаиләсендә туа. 1935 елда Шәдкедәге җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанга килеп педагогия институты каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы чорда аның әдәби иҗат эшчәнлеге башлана. 1939 елда Татарстан дәүләт нәшриятында яшь авторның «Яшел бөреләр» исемле зур булмаган шигъри китабы дөнья күрә, тагын бер елдан (1940) «Үсәбез» дигән озын шигыре аерым китапчык булып басылып чыга.*

*Габдулла Галиев, 1939 елда гаскәри хезмәткә алынып, Ватан сугышының беренче көннәреннән үк сугыш хәрәкәтләренең алгы сызыгында була. 1941 елның сентябрь аенда Украинадагы Каменец-Подолский шәһәрен саклау өчен барган бәрелешләрнең берсендә ул дошман пулясыннан һәлак була.*

*Г.Галиевнең әдәби иҗатыннан бер төркем шигырьләр С.Шакир төзеп чыгарган «Алар сафта» (1961, 1985) исемле җыентыкта урын ала.*

## БАТЫРЛАРГА

Табигатьнең усал көчләренә
Буйсынмыйча, безнең кешеләр
Томанлы һәм салкын боз иленә
Самолетта барып төштеләр.

Батырларның алсу йөзләрендә
Җиңү дәрте – шатлык уйнады,
Пропеллерга килеп бәйләнсә дә
Карт Котыпның әче бураны.
Кызыл флаг бозлар уртасында
Дулкынлана Котып җиленнән.
Котыптагы тиңсез батырларга
Кайнар сәлам бәхет иленнән.

Шуып йөргән бозлар төркеме дә,
Әче суык җилле буран да
Киртә була алмый дан эшенә,
Бөтен шартлар бездә булганга.

Дан эшләре һаман күтәрелә,
Тиздән инде безнең батырлар
Хыял булып торган бөек эшкә –
Марска да барып кайтырлар.

*1937*

## АК КАЕН

Мул уңышлы кырның уртасында
Үсеп тора ялгыз ак каен.
Яфрак ярып һәр ел каршы ала
Чәчәкле һәм матур май аен.

Бер истәлек булып каен үсә
Яшь батырның кабере өстендә.
Якты кояш аңа нурын сибә,
Җыр җырлана аның исменә.

Давыл елы иде, Камил дигән
Яшь көрәшче ялкын эченнән
Җиңеп, яулап алгы сафта барган,
Ләкин шунда гомере киселгән.

Ирек өчен сугыш кырларында
Тынган аның кайнар йөрәге.
Гайрәт биргән көрәш улларына
«Алга!» дигән соңгы сүзләре.

Ирек таңы безнең күгебезгә
Нурлар чәчеп җәйгәч канатын,
Сафа бабай аның каберенә
Утырткан бер каен агачын.

Җәелеп киткән кырның күкрәгендә
Мактау биреп якын-тирәгә,
Яфракларын селкеп әкрен генә
Хозурланып каен тирбәлә.

Егерме ел узган, каен үскән,
Еллар саклый батыр юлларын.
Каен җырлый хәзер шаулап үскән
Яшь батырның кайнар җырларын:

«Кызганмабыз данлы гомерне дә
Хезмәт халкы өчен көрәштә.
Ирек алып, давыл көннәрендә
Без ирештек бөек теләккә!»

*1937*

*Шагыйрь Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин) 1913 елда хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән районы Тозау авылында игенче гаиләсендә туа. Башлангыч мәктәпне туган авылында, җиде сыйныфны Әлмән крәстиян яшьләре мәктәбендә укып тәмамлагач, 1931 елда шул төбәктәге Мартыново авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Ләкин, матди хәле авыраю сәбәпле, укуын ташларга мәҗбүр булып, шул ук Мартыноводагы ятим балалар йортының мөдире сыйфатында хезмәт юлын башлый. 1934 елда аны Сафакүл район үзәгендәге башлангыч үрнәк мәктәбенә мөдир итеп куялар. Шунда эшләгәндә, ул «Колхозчылар тавышы» дигән төбәк газетасында актив язышa – шигырьләрен, көндәлек тормыш вакыйгаларына багышланган мәкаләләрен бастыра. Яшь шагыйрь һәм хәбәрченең исеме Чиләбе һәм Свердловск шәһәрләрендә чыга торган «Коммунист» һәм «Социализм юлы» газеталары битләрендә дә күренә башлый. Озакламый аны Чиләбегә «Коммунист» газетасы редакциясенә эшкә чакырып алалар. 1937 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының читтән торып уку бүлегенә кабул ителә. 1938 елда «Коммунист» газетасы чыгудан туктагач, Макс Гатау Чиләбедәге татар мәктәпләренең берсендә директор булып эшли, ә 1940 елның көзендә әти-әнисе яшәгән Сафакүлгә кайтып, Ватан сугышы башланганчыга хәтле урындагы татар урта мәктәбендә тарих фәне укыта, бер үк вакытта мәктәпнең директоры вазифаларын да башкара. 1939 елда Казанда Макс Гатауның Урал табигатен, Уралдагы индустриаль төзелеш күренешләрен, күмәк хезмәт тантанасын чагылдырган лирик шигырьләре тупланган «Урал мәхәббәте» исемле кечкенә җыентыгы басылып чыга. Шагыйрь икенче җыентыгын да басмага әзерли, ләкин, сугыш башлану сәбәпле, китап чыкмый кала.*

*Макс Гатау 1941 елның июлендә фронтка китә һәм шул ук елның 20 ноябрендә Калинин (хәзерге Тверь) өлкәсендәге Гаврилово авылы янында барган сугышларның берсендә һәлак була.*

*Макс Гатауның зур булмаган әдәби мирасыннан бер төркем шигырьләр 1961, 1985 елларда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкка һәм ике шигыре («Безнең нәсел», «Комбайнчы») «Татар поэзиясе антологиясе»нең икенче томына (1992) кертелә.*

## БЕЗНЕҢ НӘСЕЛ

Көрәшләрдә җиңеп яшәр өчен,
Бәхет өчен туган кеше без.
Йөз еллардан соңгы буыннарны
Таң калдырыр безнең эшебез.

Бездә кеше йөз ел гомер итеп,
Агарса да кара чәчләре;
Йөрәгендә саклап алып бара
Яшьлегенең алсу чәчәген.

Безнең нәсел өчен каберләр юк,
Мәңге үлмәс данлы эшебез.
Көрәшләрдә җиңеп яшәр өчен,
Бәхет өчен туган кеше без!

## КОМБАЙНЧЫ

Җый, комбайнер, җый
Иген уңышын!
Чәчәккә бизә
Илнең тормышын.
Арыш башлары
Түбән иелгән.
Дулкынлана ул
Җәйге җил белән.
Шаула, комбайн,
Шаула көн саен!
Сине киң кырлар
Көтте масаеп.
Мул уңышыбыз
Чиста җыйналсын!
Бер генә башак та
Җирдә калмасын!
Шаулат, комбайнчы,
Шатлык җырларын.
Яңгырап торсын
Иген кырлары.
Җый, комбайнчы, җый
Иген уңышын!
Уңышлар бизи
Илнең тормышын.

*Шагыйрь Мансур Гаяз (Мансур Гаяз улы Гаязов) 1917 елның 5 октябрендә Мари Республикасының (хәзерге Мари Эл) Бәрәңге районы Бәрәңге авылында дөньяга килә. Бәрәңге педагогия техникумында белем ала, аннары шул ук Бәрәңге авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. 1938–1940 елларда армиядә хезмәт итә. Ватан сугышы башлану белән фронтка китеп, фашизм илбасарларына каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, берничә тапкыр яралана. Ләкин аңа җиңү көннәрен күрергә насыйп булмый: 1943 елның 19 ноябрендә Белоруссиянең Витебск өлкәсе Усково авылы өчен барган бәрелешләрнең берсендә егерме алты яшьлек шагыйрь дошман - пулясыннан һәлак була. Мансур Гаяз – сугыш алды елларында әдәбият мәйданына чыгып, кыска гына вакыт эчендә исемнәрен танытып өлгергән, ләкин, иҗади талантларын ахыргача ача алмыйча, Ватан сугышы фронтларында халыклар азатлыгы өчен гомерләрен биргән зур бер төркем татар*

*әдипләренең берсе. Ул 1936 елда яза башлый. Алты еллык иҗат гомерендә (шуның ике елы фронт шартларында) ул чордашларының җанлы образларын, уй-хисләрен сурәтләгән күп кенә лирик шигырьләр, «Тормышны сөю», «Испанка» исемле ике поэма иҗат итә. Алар сугышка кадәр яшь язучыларның «Алмаш» (1938), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Дуслык» (1940) исемле күмәк җыентык һәм альманахларында басылып чыга. Иҗат эшчәнлеген ул сугыш шартларында да алып барырга тырыша: фронт газеталарында ватандарлык хисләре белән сугарылган публицистик шигырьләрен һәм очерк язмаларын бастыра.*

*1959 елда Татарстан китап нәшрияты, шагыйрьнең иҗат мирасыннан сайлап алынган әсәрләрне туплап, аерым китап бастырып чыгара. Аның бер шәлкем шигырьләре шулай ук Ватан сугышында һәлак булган язучыларның әсәрләре тупланган «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) исемле күмәк җыентыкларда һәм «Татар поэзиясе антологиясе» (1956, 1992) басмаларында да урын ала.*

## ЧИКТӘ

Чик.
Салкынча һәм җилсез көзге иртә.
Биек таулар... Нарат урманы...
Тирән тынлык күңелләрне борчый,
Хисләр тынгысызлый уйларны.
Өстә шаулап торган күксел урман.
Аста кара, тирән упкыннар.
Сөзәк кенә төшкән ташлы ярлар.
Үзәнлекләр. Уйсу урыннар.
Сузыла атлас кебек зур җәйләүләр,
Күгелҗем вак күлләр тезмәсе
Һәм күренә күл өстендә уйнап
Җитез үрдәкләрнең йөзгәне.
Дымлы һава рәхәт кенә тибри,
Нинди ямьле, матур яшел көз!
Болытлардан вак энҗеләр коела,
Күк күкрәүсез, якты яшенсез.
Һичбер нәрсә бозмый чик тынлыгын
Һәм күренми күзгә беркем дә.
Пограничник ята посып кына
Шунда, яшел куак төбендә.
Күзәтә ул чикнең тынычлыгын,
Шуңа биреп уен, күңелен,
Озатып кала күздән югалганчы
Хәтта очкан кошлар төркемен...

*1939*

## ЭСКАДРОН БАРА

Эскадрон бара.
Һава тын, коры.
Яңгырап кала
Тояклар җыры.

Егетләр тыныч,
Шәп аргамакта.
Билләрдә – кылыч,
Башларда – каска.

Җиңеп дошманның
Канлы сафларын,

Чистартып илнең
Изге туфрагын,

Далалар буйлап
Эскадрон чаба,
Барган юлында
Киртә юк аңа.

Каршылый безне
Авыллар, өйләр,
Түземсез көткән
Апа, әниләр.

Ягымлы караш
Һәм җылы сүзләр.
Яшь белән балкый
Шатлыклы күзләр.

Егетләр батыр,
Мактауга ия.
Бу сафта бара
Комсомолия!

*1944*

## АНА ВАСЫЯТЕ

Озын юл буйлап сузыла
Ямь-яшел болын.
Шул юлдан ана көрәшкә
Озата улын.

Чагыла сабыр йөзендә
Борчулы төсе,
Җемелди керфек очында
Бөртек энҗесе.

Улының батыр йөзенә
Юнәлтә күзен,
Һәм сөйли аңа иң соңгы
Кадерле сүзен:

«Барасың изге көрәшкә,
Якты күз нурым,
Кызганма каның, кирәксә,
Ак булсын юлың!

Таза тәнеңдәге куәт
Һәм яшәү көчең
Бир көрәшкә үзең теләп
Илебез өчен.

Син күңелемдәге куаныч
Һәм йөрәк парәм,
Яшьнәсен кулыңда кылыч
Сафларда алдан.

Сез күрсәтегез илемнең
Көчен, куәтен,

Дошман өстендә дәһшәтле
Үлем күкрәсен.

Зур көрәш юлында гомерең
Чикләнсә әгәр,
Сөелеп телдә йөрерсең
Һәм даның яшәр.

Бөек көрәштә бергә без –
Күп түгел ара,
Сезнең йөрәктә аналар
Җылысы бара.

Тар-мар ит дошманны, улым,
Таза-сау йөре,
Җиңү белән үтсен юлың,
Аннан кайт кире...»

*1941*

**САГЫНУ**

Син мәктәптә кердең аңыма
Шигырьләрең җылысы аркылы,
Йөрәгемдә туды шул вакыт
Сиңа булган сөю ялкыны.

Уйларымны биләп алдың син,
Бөтен тынычлыгым югалттың,
Иң беренче башлап күңелдә
Саф шигъри көчләр уяттың.

Авыр булды... үлем хәбәрең
Килеп җиткәч газет битендә.
Шул вакытта түккән яшьләрем
Бүгенгедәй әле исемдә.

Ара ерак булса, хат йөри,
Күңелеңне шулар юата.
Сине югалтуның ярасы
Кайгырып та бетми, елап та.

Нинди генә адрес язсам да
Беләм хатым барып җитмәсен,
Ахрысы, син шулай гомергә...
Сагынып яшәр якын иптәшем!

Кулларыңны кысар идем бер,
Күрсәм әгәр исән чагыңда,
Алып килер идем шигырьләр
Ярдәм сорап синең яныңа.

Ләкин синең белән булырга
Туры килмәс инде гомергә,
Күрешсәк тә икәү без, абый,
Очрашырбыз бары шигырьдә.

Чикләнмәде әле яшәвең,

Синдә яңа гомер кабынды,
Күчердең син бөек сәнгатькә
Каләм белән йөрәк каныңны.

Син – халыкның мәңге онытылмас
Шат күңелле сөйгән шагыйре,
Әле синең зәңгәр күзләреңдә
Күпме яшәү дәрте бар иде!

Син йөрәктән алып җырладың,
Якын иде шуңа уйларың,
Әле бит син азат тормышның
Матурлыгын сөеп туймадың.

Килеп чыккан идең кояшка,
Үтә-үтә авыр юлларны,
Тавышың киткән саен еракка,
Күтәрелә бардың югары.

Дошманнарга булдың аяусыз.
Тынгы бирмәдең һич аларга,
Белә идең үткен сүзләрне
Кай җиренә, ничек кадарга.

Әле синең язар җырларың,
Тагы да матур булыр иделәр,
Тик гомерең белән киселде
Чишмә булып агар шигырьләр.

Шаулы тормыш белән шигырьләрең
Ерак юллар аша барырлар
Һәм яшьләрне иҗат эшенә
Чакыру тавышы булып яңгырар.

*1941*

**ТЕТРӘСЕН ДОШМАН**

Туган илнең ике ягыннан без,
Юлларыбыз бергә очрады.
Бер дошманга карап юнәлтелгән
Кулда үткен штык очлары.

Көрәшләрдә җиңү өчен кирәк
Ихтыяр һәм тимер чыдамлык.
Бар ул бездә! Туплар гөрселдәгән
Үлем кырларында сыналдык.

Дошман тәнгә кызу тимер басты
Һәм чыгарды чукып күзләрне.
Күкрәкләргә йолдыз рәсемен уйды,
Тәндә калды итек эзләре.

Күрелмәгән мондый җинаятьне
Хәтерләргә күңел тарсына,
Безнең йөрәкләрдә булмас аңа
Кызганулы хис бер тамчы да!!

Сыялмыйча кайный күкрәкләрдә
Тирән ачу, ачы нәфрәт,

Бәр башына – чикәләрен җимер,
Чыксын ике күзе чәчерәп!!

Тетрәт аны, һич аяма көчең,
Чумсын канга – тура, телгәлә!
Үзе башта тешләгәне өчен
Эткә күсәк таза эләгә.

*1943*

*Шамил Гәрәй (Шамил Мөхәммәтгали улы Гәрәев) 1916 елның 31 декабрендә Казан шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа. Бик яшьли әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Җиденче сыйныфта укыган чагында, 1931 елда, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында аның балалар өчен язган шигыре басылып чыга, тагын бер елдан «Сигналчы җыры» исемле китабы дөнья күрә. Шуннан соң, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә (1931–1941), Шамил Гәрәй Татарстан дәүләт нәшриятында тагын дүрт шигъри җыентыгын («Звено җыры», «Флюра», «Тормыш иртәсе», «Тормыш чәчәкләре») һәм балалар өчен бер очерк китабын («Яңа совхозда») бастырып чыгара. Нигездә, яшь укучыларга адресланган һәм туган ил, бәхетле балачак, туган табигать турындагы уй-хисләрен шактый тәэсирле итеп чагылдырган бу шигырь китаплары белән Ш.Гәрәй үзен үсеп килүче өметле шагыйрь итеп таныта. Ул шулай ук әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә сәләтен күрсәтә. «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналларында аның тәрҗемәсендә А.Чехов хикәяләре, М.Лермонтов шигырьләре, украин фольклорыннан үрнәкләр һәм аерым басма рәвешендә Л.Квитконың «Бишек җыры» (1940), А.Бартоның «Уенчыклар» (1941) исемле китапчыклары басыла.*

*Ватан сугышы башлангач, Ш.Гәрәй фронтка китә. Мәскәү янында барган каты сугышларның берсендә сугышчан иптәшләре белән чолганышта калып, ул фашистлар кулына әсир төшә һәм фашизм коллыгының бөтен авырлыкларын башыннан кичерә. Инде җиңү көне килеп, әсирлектән йолып алынса да, аңа туган каласы Казанга кайтып яшәргә һәм әдәби иҗат хыялларын тормышка ашырырга насыйп булмый – 1946 елның 22 мартында Польшаның Гливице шәһәрендә әсир тоткыннарны тикшерү лагеренда вафат була. Китапларыннан тыш Шамил Гәрәйнең шигъри иҗатыннан үрнәкләр «Алар сафта» (1961, 1985) һәм «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) басмаларына да кертелә.*

## ИКЕ ТУГАН

*(Баллада)*

Барыгыз да аягүрә торыгыз!
(Корбаннарны искә алабыз.)
Әй, бәхетле яшьләр, якты көннең
Тарихын сез кайтып карагыз!
Сез күрерсез алар түккән канның
Ел да кызыл чәчәк атканын,
Сөякләренең бөек ил нигезендә
Гранит ташы булып ятканын.

### I

Алар һаман минем күз алдымда
Ирек өчен сугышып йөриләр...
...Язгы бер кич иде. Менә алар
Шаулап өйгә кайтып керделәр.
– Әнкәй! Без фронтка барабыз,
үзебез теләп,
Бүген кичен, ахры, китәрбез,
Син тыныч бул, әнкәй,
Деникинны
Җиңгәч тә без кайтып җитәрбез.

Әйтерсең лә менә яшен сукты,
Сикереп торды ана сискәнеп,
Сизмәде ул хәтта кулындагы
Кашыгының төшеп киткәнен.
– Ах, Ходаем! Әллә син дәме? – дип,
Унбиш яшьлегенә карады.
Кайнар яшьләр...

яшьләр барыбер басмас

Йөрәктәге авыр яраны!
Күңеле тулып, ана үкси иде,
Тәрәзәгә табан борылып.
Яңгыр тамчылары пыяладан
Төшә иде аска егылып.
Гөрләшәләр иде күгәрченнәр
Шул чагында кәрниз астында,
Моңсулык бар иде ниндидер бер
Аларның да бүген тавышында.
Зурысы килеп сөйде аркасыннан:
– Елама син, әнкәй, елама,
Хәл кылынган чакта ил язмышы,
Елаудан соң эшләр буламы?!
Бер үтенеч әйтте кечесе,
Юлга әзерләнеп эш беткәч:
– Күгәрченнәр... әнкәй, син аларны
Туйдырырсың инде, мин киткәч...

**II**

Зур походлар кичеп, хәл җыйганда,
Яңгырады сугыш җырлары,
Кечесенең нечкә саф авазы
Аерым-аерым булып чыңлады.

*

Сабый чакларында сөекле ана
Җәйгән җылы йомшак урында
Алар тыныч-рәхәт йоклый иде,
Берни белми кайгы турында.
Яңгыр койган төндә шинель ябынып
Менә тагын бергә яттылар.
Җылылыкны бүген бер-берсенә
Елышып яткач кына таптылар...

*

Әйтерсең лә яңгыр юып киткән,
Шундый якты зәңгәр күк йөзе,
Йомшак искән җилләр тирбәлдерә
Болындагы чәчәк диңгезен.
Агып ята елга үзенә яуган
Снарядлар белән болганып.
Көймә өсләренә күпер салып,
Батальон кичте елганы.
Дошман явы килә... Өлкәне
Пулеметын корды аларга,
Ә кечесе җитез кулы белән
Лента биреп торды аңарга.
Тамак чатнап кибә...
Басар өчен

Пулеметның кызып ярсуын,
Үз авызыннан өзеп эчерде аңа
Флягада булган бар суын.

Тукта, бу нинди хәл булды әле,
Без җиңәбез менә дигәндә,
Канатлары сынган лачын төсле
Авып төште кечесе чирәмгә.
Туган каны өчен тамырларда
Үч ялкыны дөрләп кабынды,
Авыр кайгы килгән бу минутта
Шундый зур көч каян алынды?
Чалгы белән чабып үтелгән күк,
Бер-бер артлы дошман кырылды...
Тукта, бу нинди хәл булды соң бу,
Өлкәне дә ауды, егылды...

## III

Масайдылар аклар штабында,
Кызылларны, имеш, җиңгәннәр:
Кан эчендә һушсыз яткан җирдән
Туганнарны алып килгәннәр.
Пенсне аша карый карт офицер,
Китерергә тырышып сүз җаен,
Мәсхәрәле көлеп, өлкәненә
Соңгы тапкыр бирә соравын:
– Хәшәрәт җан!
Шулай, бернәрсә дә
Әйтмим сезгә, дисең инде син,
Ләкин оныта күрмә, моның хакын
Яшь гомерең белән түлисең...

Илгә биргән антын үтәде ул,
Эчендәге серен чишмәде.
Энҗе бөртеге күк тешләрен
Ныграк кысты, бер сүз дәшмәде.
Күтәрелде маузер көпшәсе...
Кечесе сикереп алга ташланды:
– Син үзең... син үзең хәшәрәт!.. –
Утлы сүзләр шулай башланды.
Кычкырды ул:
– Ерткыч!.. Буржуй нәгъләт!
Дөмегерсең барыбер тиз көннән! –
Ачы күз яшьләре канга кушылып,
Ермачланып акты битеннән.
Ул: «Яшәсен...» – диде, тәмамларга
Бирмәделәр, курок тарттылар,
«Коммунизм!» – диеп яңгырады
Өлкәненең тавышы...
Аттылар...

## IV

Алар һаман минем күз алдымда
Ирек өчен сугышып йөриләр...
...Сагынып үзләренең яшь дусларын,
Күгәрченнәр әле дә гөрлиләр...

*1938*

## БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

Җәй иртәсе,
Торып,
бакча якка
Тәрәзәмне ачсам киереп:
Син үтәсең көлеп
күз алдымнан,
Дулкынланып, ташып, сөенеп.

Бакчадагы шомырт
Көлеп торган
Күзләреңне искә төшерә...
Ахры,
Бу табигать
бөтен матурлыгын
Сиңа гына биреп бетерә!

Унсигезенче язым үтеп китте...
Болай булырмын дип сизмәдем,
Бүген минә килдең,
Синең белән
Бергә китә язды күзләрем.

Иделдә дә йөздем,
Курку белми,
Дулкыннарны кисеп атылдым.
Бүген синең төпсез күзләреңә
Батып калмаммы соң, акыллым?

Көрәшләрдә янып,
Корыч төсле
Ныгыган иде минем йөрәгем,
Ә син бүген шундый йөрәккә дә
Мәхәббәтнең тамырын җибәрдең...

Күрәм,
шундый җитезлек белән син
Резецыңда винтлар кырасың.
Кызыл байрак алган цехыгызның
Тиңсез күрке булып торасың.

Күрдем синең,
спорт мәйданында
Йөгереп өстен чыккан көчекне,
Күрдем
Батырлык һәм матурлыкның
Командиры булган кешене!

Киләчәкне күбрәк сөйгән саен,
Бүгенге көн эшне сөйдерә,
Һәм эшемне күбрәк сөйгән саен,
Өзелеп сөям минә сине дә.

Шуңа мәллә,
Көн дә киң тормышка

Тәрәзәмне ачсам киереп,
Син үтәсең көлеп
күз алдымнан,
Дулкынланып, ташып, сөенеп...

*1934*

**УРМАН БУЕНДА**

Җәйге урман.
Нарат агачлары
Гаскәр кебек тезелеп киткәннәр.
Җиләк урыны –
Яшел куаклыклар
Урман буен бизәп үткәннәр.
Салмак кына
Йомшак искән җилләр
Яфракларны селкеп шаулата,
Җырчы кошлар
Агач арасыннан
Сузып җырлап урман яңгырата.
Без үтәбез
Көн дә шул урманнан,
Сигнал белән бергә җырлашып,
Яңрап кала урман,
Без киткәндә
Алга таба кырлар буйлатып.
Рәт-рәт булып,
Менә бүген дә без
Җырлап үттек урман арасын.
Урман матур,
Таза алмаш өчен,
Тәрбияли һәрбер баласын.

*1937*

*Әхмәт Гыймадов – 1941–1945 еллардагы Ватан сугышында һәлак булган яшь татар язучыларының берсе. Ул 1915 елда Казан шәһәрендә басмаханә эшчесе (хәреф җыючы) гаиләсендә туа. Казанның Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә җиде сыйныф белем алгач, фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбенә укырга керә һәм аны тәмамлаганнан соң Казан заводларында слесарь булып эшли. Шул елларда ул производство, эшчеләр хезмәтен яктырткан хикәя-язмалары, хәбәр-мәкаләләре белән көндәлек матбугатта катнаша башлый. 1937 елда яшь хәбәрчене үзе эшләгән заводның күптиражлы газетасына редактор итеп куялар. Хикәяләрендә ул әдәби чаралар белән яңа тормыш төзүче эшче образларын, аларның хезмәт энтузиазмын гәүдәләндерергә омтыла. Бер үк вакытта ул балалар әдәбиятында да көчен сынап карый, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында героик-романтик рухтагы хикәяләрен («Пионер Владик», «Мигуэль» һ.б.) бастыра. Аның революциягә кадәрге Казан һөнәрчеләре тормышы турында «Юллар» исемле повесть язарга керешүе дә мәгълүм.*

*1943 елның башында Әхмәт Гыймадов фронтка җибәрелә һәм шул ук елның октябрь аенда сугыш кырында һәлак була. Язучының зур булмаган әдәби иҗатыннан бер әсәр – узган гасырның 30нчы елларында Испаниядә барган гражданнар сугышы хәлләрен СССРда сыену урыны тапкан испан баласы авызыннан сөйләтү рәвешендә 1938 елда язылган «Мигуэль» дигән хикәя С.Шакир төзеп чыгарган «Алар сафта» (1961, 1985) исемле җыентыкка кертелгән. Ә.Гыймадов турында өстәмә мәгълүматларны һәм бәяләмәләрне шулай ук Ә.Синегуловның «Туплар һәм музалар» (1969), З.Мәҗитовның «Сугышчан поэзия» (1975) дигән китапларыннан да табарга мөмкин.*

**МИГУЭЛЬ**

Диңгезнең биек ярында тау өстенә салынган зур таш йорт күренә. Диңгезгә карап торган террасаны кипарис, пальма, мандарин агачларының яшеллеге урап алган. Йортның мәрмәр колонналары, ак таш стеналары кояшнең нурын алырлык булып җемелдиләр. Тирә-якның маягы шикелле булып тора бу йорт. Аның зәңгәр күккә таба сузылган башнясы өстендә кызыл флаг җилферди. Бу йортка балалар санаторие урнашкан.

Террасага ял итүче балалар төркеме җыйналган; алар зур кызыксыну белән диңгез өстен күзәтәләр.

Кара диңгез өсте эреле-ваклы көзге кисәкләре шикелле ялтырый. Көнбатышның горизонт сызыгына кереп китәргә торган кояштан нур көлтәсе сибелә. Алар алсу тасма булып диңгез өстенә сузылалар.

Өстенә кыска җиңле ак күлмәк кигән түгәрәк йөзле үзбәк кызы белән кыйгач кара кашлы әрмән пионеры шул матурлыкны сокланып карыйлар иде.

Залдан террасага чыга торган ишек ачылды. Аннан шаулый-шаулый тагын бер төркем балалар килеп чыкты. Балалар өстенә матроска кигән, коңгырт бөдрә чәчле, кояшта янып бронза төсенә кергән йөзле испан малае Мигуэль тирәсендә кайнашалар. Аларның Мигуэльдән Испаниядәге вакыйгалар турында сөйләтәселәре килә. Мигуэль янында аның белән бергә СССРга килгән башка испан балалары да күп. Алар да аның сөйләвен сорыйлар. Террасадан торып диңгез өстен күзәтүче балалар да Мигуэльне Испания турында сөйләргә кыстаучыларга кушылдылар.

Мигуэль Росасның СССРда тора башлаганына бер ел инде. Ул Испаниядән III Интернационал исемендәге үрнәк балалар йортына килеп төште. Бу санаторийда аның икенче кат ял итүе иде. Ул башка испан балаларына караганда рус телен яхшырак белә. Күп вакыт, куллары белән тезен кочып, зур кара күзләрен кайда булса да төби дә уйланып утыра. Мондый вакытларда аның күңеле еракка – фашистлар золымы, капиталистлар изүе астында бөлгенлеккә төшерелгән испан хезмәт ияләре янына китә. Ул аларның бер сынык каткан икмәк өчен тилмереп йөргән төссез, ябык, хәлсез балаларын күз алдына китерә дә үзенә:

– Менә бөтен җирдә Совет илендәге шикелле мул, бәхетле тормыш булса иде! – ди. Һәм бөтен дөнья пролетариаты революциясе өчен көрәшкәндә үзенең зур буласын уйлап горурлана: – Без бирербез ерткыч фашистларның кирәкләрен! – дип куя.

Ул хәзер дә, санаторийдагы балалар үзенең сөйләвен үтенгәч тә, Испаниядә булган канлы көрәш кырларын күз алдына китерде. Аның йөзен уйчанлык басты, ләкин ул уйчанлык бу юлы тиз югалды. Аның үзен һәм иптәшләрен кадерләп тәрбияләүче Советлар иленә хезмәт итәсе килде. Үзенең ялгыз булмавын, СССРда яшәвен хәтерләп, күбәләк шикелле очынды, шатланды ул. Һәм бераздан тирә-ягын урап алган иптәшләренә карады.

Балалар Мигуэльнең сөйләвен тыңларга әзерләнделәр. Аларның һәркайсы малай тирәсенәрәк урнашырга тырышты. Мигуэль, иптәшләрен бераз шаяртып алырга теләп, диваннан торды да чыбыктан үрелгән дуга табанлы креслога күчеп утырды. Балалар, кинәт дулкынланган диңгез өсте шикелле кайнашып, җанлы кыршау ясап, Мигуэльне әйләндереп алдылар.

Мигуэль креслода тирбәлә-тирбәлә сөйли башлады:

– Кара болытлар айсыз төндә күк йөзенә яктылык шәүләсе сибүче йолдызларны да капладылар. Бискайя провинциясенең көнчыгыш ягы куркыныч караңгылыкка уралды.

Май аеның болытлы иртәсе иде. Мин каты шартлау һәм челпәрәмә килеп ватылган тәрәзә пыялалары, шүрлектән коелган савыт-сабалар тавышына куркып йокымнан уяндым. Бу вакытта өйдәгеләрнең барысы да аяк өстендә иде инде. Бабай кулына кыска көпшәле мылтык тоткан һәм калтыранган куллары белән аңа патрон тутыра. Дәү апам белән кече апам Амалия түрдәге зур кәрзин янында кабаланалар: аларның берсе кәрзиннән күлмәкләрне алып идәнгә ташлый, ә икенчесе аларны кулына ала да озын тасма сыман итеп телә; аларның ашыкканлыклары күренеп тора. Сүзләреннән мин апаларымның яралылар өчен бинт әзерләгәнлекләрен аңладым. Амалия минут саен: «Тизрәк бул, җаным», – ди иде.

Әнием кечкенә энем Адроданы күкрәгенә кыскан да бүлмәнең бер башыннан икенче башына туктаусыз йөреп тора. Адрода йөрәк өзгеч тавыш белән елый. Ул каты курыккан иде.

Мин йокы исереклегеннән тиз айныдым һәм безнең Дуранго шәһәрен фашистларның күп мәртәбәләр һавадан бомбага тотуларын, берничә атнадан бирле шәһәр тирәсендә каты сугышлар баруын хәтерләдем. Мин шунда ук урынымнан сикереп тордым да барып бабайны кочакладым.

– Бабай, кая барасың? – дип сорадым мин аңардан.

Ул, кулын алга таба сузып, гайрәтле тавыш белән:

– Фашист этләре, кара күлмәклеләр безнең актык сыныкларны тартып алырга киләләр. Мин, улым, аларга каршы көрәшергә барам, – диде.

Ул минем маңгаемнан үбәргә дип иелде. Мин аның көмешләнгән чәчен сыйпадым.

– Йә, хуш, улым, – диде ул, аркамнан сыйпый-сыйпый, һәм чыгып китте.

Бабай киткәч, мин әбием янына килдем. Аның эчкә баткан тонык кара күзләре яшькә чыланган иде.

– Җир упса иде шул кара күлмәклеләрне, – ди иде ул ике сүзнең берендә.

Аның яшьле күзләренә карап мин дә чак кына елап җибәрмәдем. Тик үземнең ир бала булуымны

хәтерләп, түздем, иренемне тешләрем белән кыстым да:

– Елама, әби, елама, – дидем.

Әби күз яшенә йотлыга-йотлыга сөйләп китте:

– Ничек еламаска, семьябызның соңгы ир кешесе – бабаң да китте бит. Хәзер ничек яшәрбез инде?

Ничек кирәк алай мин аның елавын туктатырга теләдем. Ләкин аның йөрәгендәге тирән сагышларны кузгаткан нәфрәтле яшь чишмәсен коры сүзләр, иркәләүләр белән генә тыеп булмауны мин аңламаганмын. Ул елый-елый өй эчендәге әйберләрне йорт алдында торган җигүле атка ташуында дәвам итте.

Мин нишләргә белми торганда, яныма кече апам Амалия килеп чүгәләде. Ул, Кызыл Хач билгесе бәйләгән кулын миңа сузып:

– Йә, хуш, Мигуэль, мин дә китәм, – диде. Һәм сыңар кулы белән мине күкрәгенә кысып, маңгаемнан, бит алмаларымнан кат-кат үпте. Соңыннан ул әни каршысына барып басты да нидер әйтергә теләде. Шунда аның кара күзләре әнинең кайгылы йөзенә төбәлде, аның йөрәге әрнеп китте, ул:

– Кайгырма, әнием, хуш, – диде дә батыр адымнар белән ишеккә таба атлады. Бераздан ватык тәрәзәләр аша Амалия сөеп көйләгән җыр тавышы ишетелде.

Ул арада дәү апам да бер бәйләм киң тасма кисәкләре алып урамга ашыкты.

Мин, кая барырга белми, идән уртасында катып калдым.

Урамнан пулемет тыкылдаган, мылтык атылган тавышлар өзлексез ишетелә. Бомбага тоту көчәйгәннән-көчәя бара. Урамнарның буеннан-буена яшен вакытындагы кебек күзне чагылдыргыч утлы сызыклар чагылып үтә. Сирәк-сирәк кенә снарядлар шартлый. Ул, җир белән иркен күктә йөзгән болытларны кушарга теләгән шикелле, төшкән урынындагы бөтен нәрсәне һавага чөя. Югарыга күтәрелгән утлы чаткылар арасында таш, туфрак, агач кисәкләре күзгә чалына. Куркыныч. Ватык тәрәзәләрдән кергән төтен катыш дары исе сулышны кыса. Ул да булмый, дошман өстенә арысланнар шикелле ташланучы халык армиясе сугышчыларының көчле тавышлары яңгырый. Бу тавышлардан фашистларга, интервентларга каршы көчле нәфрәт аңкый.

«Аделанде[1]» тавышлары мине җанландырды. Мин дә, баррикадаларга ташланырга теләп, ишеккә таба йөгердем. Ләкин әбием минем юлыма төште.

– Кая барасың? – диде ул. – Миңа әйберләрне чыгарышырга булышыр идең.

Нәкъ шул вакытны ишектән әтием күренде. Мин аны өч айдан бирле күргәнем юк иде инде. Ул мин йокыдан торганчы өйдә булган, күрәсең, аңа әби дә, әни дә гаҗәпсенүле караш ташламады, тик мин генә әтинең кочагына атылдым. Ул мине сөйде, иркәләде. Аннан соң кесәсеннән апельсин алып бирде. Әти белән әни бераз сөйләшеп тордылар.

Әти зур кәрзинне чыгарырга булышу өчен генә өйгә кергән икән. Ул озак тормады, аның «Тизрәк булыгыз, безнең патроннарыбыз бетте, чигенәбез» дигән сүзләре әле дә минем колак төбемдә яңгырый. Бик аянычлы итеп әйткән иде ул шул сүзләрне.

Минем күңелем нәрсәдер сизгән шикелле булды. Мин як-ягыма каранып алдым да әти артыннан урамга чыктым. Үзебез торган йорттан бераз җир киткәч, күзләрем бомбовозга төбәлделәр. Кинәт ул безнең өй турында бомбалар яудыра башлады. Берничә минуттан соң фашист козгынын безнекеләр кадалдырып төшерделәр төшерүен, ләкин...

Мигуэль сөйләвеннән туктады. Аның авызыннан чыккан соңгы «ләкин» сүзе башка сүзләре шикелле көчле яңгырамады. Ул сүз аның йөзенә кинәт бәреп чыккан сагышы белән бергә йотылган шикелле булды. Бу вакыт террасада бермә-бер арткан, Мигуэльнең сөйләгәнен тыңлаучы балалар авызларын ярым ачып аңа карап торалар иде. Соң гына килгәнгә, утырырга урын калмаганлыктан, барьерга атланган зәңгәр күзле рус пионеры, түземсезләнеп:

– Йә, йә, шуннан? Әниләрең нишләде? – дип сорады Мигуэльдән.

Мигуэль җавап бирмәде. Аның йөзенә карарга да куркыныч. Бәлкем, ул үкси-үкси елаган да булыр иде, ләкин иптәшләре аның күңелен күтәрделәр. Испан балалары аның Советлар илендә яшәвен исенә төшерделәр. Шуннан соң малайның күңеле яңадан күтәрелеп китте. Ул сөйләвен дәвам иттерде:

– Ләкин бу вакыт без тора торган йорт җир белән тигезләнгән иде инде. Мин: «Әни!.. Әби!.. Адрода!..» – дип кычкыра-кычкыра йортыбыз янына кире чаптым һәм, йорт урнашкан урынны чама белән билгеләп, әниләрне эзләргә керештем. Башым әйләнә, кулларымны җәеп, кемнедер кочакларга теләгән шикелле барам. Күзләрем бернәрсә дә күрми, чөнки алар яшь белән тулган. Тыным кысыла иде. Кинәт мин нәрсәгәдер абынып егылдым. Шуннан теземә тезләнеп, кулым белән яшем сөрттем. Өстемә кинәт бозлы су коелган шикелле булды. Калтырандым, елый да алмас булдым. Минем каршымда теткәләнгән гәүдә ята иде. Гәүдәнең йөзеннән бернәрсә дә танырлык түгел. Кара чәч кан белән аралашкан. Бары кием-салымнарыннан, ничектер гәүдәдән аерылып бетмәгән аяк кисәкләреннән генә мин аны таныдым. Ул минем әнием иде. Мин һушымнан язып бик озак шунда аунап ятканмын. Кояш төшлеккә авышкач, ява башлаган яңгыр мине тәмам чылаткач, йөрәккә үткән салкын мине аңыма кайтарды. Әниемнең канлы иткә әйләнгән гәүдәсе янында мин озак утырдым... Аны ташлап китәсем

килмәде. Мин, аның белән берни дә эшли алмаслык кечкенә булуыма көенеп, әбиемне эзләргә киттем.

Ләкин аның гәүдәсенең кисәкләрен дә таба алмадым. Шуннан, хәсрәт белән тулы башымны түбән иеп, билгесез юнәлеш белән урам буенча атладым...

Бу вакыт шәһәрдә атыш тавышлары сирәгәйгән иде инде. Минем күзләрем югары урам чатыннан килеп чыккан атлылар төркеменә төште. Төркемнең алдыннан ике немец офицеры белән бер итальян фашисты килә. Алар миннән 9–10 адымнар гына ераклыкта җыелып торган иптәшләрем өстенә кылычлар белән ташландылар.

Мин, аларның миңа да тиюләреннән куркып, ташландык йортларның берсенә чаптым, һәм соңыннан шул йортның чормасына мендем дә ерактан урамга карадым. Мин иң элек теге балаларның туракланып ташланган гәүдәләрен күрдем.

Шәһәргә басып кергән канечкеч фашистларның саны арткannan-арта барды. Алар ач бүре шикелле бер йорттан икенче йортка йөгерәләр. Аларның кайсылары кергән йортларыннан мендәр, одеял, кайсылары төрле киемнәр, кыйммәтле җиһазлар сөйрәп чыгаралар иде.

Менә мин яткан чормага каршы яктагы йортның капка төбенә бер төркем фашистлар килеп туктады. Ул йортта итекче Хосе тора. Ул күзгә күренерлек зур бай түгел. Шулай да яхшы тормышлы. Хосе хөкүмәт белән фашистлар арасында сугыш башланганнан бирле бер якка да катнашмаучыларның берсе иде.

– Безнең өчен барыбер, – ди торган иде ул.

Ә менә бүген фашистлар аның мастерскоен ватып керделәр. Йорт эчендәге әйберләрен таладылар. Соңыннан Хосеның буйга җиткән ике кызын, ялынуларына, аһ-зарларына карамастан, ташландык йортларның берсенә сөйрәделәр. Аларның йөрәк өзгеч ачы тавышлары, елаулары, кемнәндер ярдәм сораган авазлары, ә соңрак дәһшәтле тавыш белән гырылдаулары минем чәчләремне үрә торгызды. Йөрәгем чемердәде. Варварларның гаепсез хатын-кызларны, балаларны болай мәсхәрәләвенә чыдый алмый:

– Этләр! Бандитлар! – дип кычкырып җибәрдем. Шуннан соң мин үзем белән ни булганын да белмим.

Мин бары тик бер-бер артлы ярылган снаряд тавышына уянып киттем. Тышта кич якынлашып килә иде инде. Тирә-ягым ярым караңгы. Эчем борып-борып авырта. Ашыйсым килә башлады. Тамак та кипкән, эчәсе килә.

«Әтиләр кайда икән? Алар шәһәргә кире һөҗүм итмиләр микән?» дигән фикер белән әлеге ярыктан тагы урамга карадым.

Бу вакытта урамнан зур-зур броневикларга, автомобильләргә төялгән, баштанаяк коралланган герман, итальян интервентлары һәм марокколылар шәһәргә керәләр иде.

Шәһәр бераз тынычланган шикелле булды. Мин чормадан төштем дә Хосеның фашистлар газаплаган кызларын эзләргә тотындым һәм күршедәге йортның ишегалдында ул кызларны эзләп таптым. Аларның берсе сарай астында, икенчесе йортка керә торган баскыч янында ята иде. Аларның авызларына чүпрәк тутырганнар. Теш казналарын көчләп каерганга, авыз читләре ертылган. Кеше чыдый алмаслык газаплаудан күзләре атылып чыгардай булып зур ачылган һәм калайланган, икесенең дә куллары артка каерып бәйләнгән. Тәннәре нәкъ көл төсле. Шул минутта мин әбием сөйләгән җен-пәриләрне хәтерләдем. Мине курку чолгап алды. Күзләремне кулым белән томалаган хәлдә, алар янынннан урамга ташландым.

Шул көннән башлап мин урам малае булып киттем.

Яңгырлы көн. Мин Дуранго шәһәренең зур базары чатында калтыранып торам. Узган-барганнарга кулларымны сузам да: «Бер сынык икмәк бирсәгезче», – дим.

Кайбер кешеләр, кара күлмәклеләр күрүдән куркыпмы, ялт-йолт итеп як-якларына караналар да кулыма ни булса да төртеп китәләр. Ә кайсылары миңа бөтенләй игътибар итми, кырын карап узалар. Баштарак тамагымны туйдырырлык ризык таба алдым, ә соңга таба бер валчык икмәк күрмәгән көннәрем дә күп булды.

Шулай ачлыктан бөрешеп чат башында утырган киң маңгайлы һәм гаҗәеп калын, куе кара кашлы, башына салам эшләпә, өстенә тузган блуза кигән, култык таякларына таянган бер кеше минем каршыма килеп туктады. Ул миңа исемем белән дәште.

– Мигуэль, әйдә, тиз бул! Минем белән... – диде ул.

Мин ул кешене башта танымадым. Тик аның квартирасына кергәч кенә Амалия янына килеп йөргән комсомолецлар арасында шушы кешенең дә булуын хәтерләдем. Ул хәзер бик нык үзгәргән. Аның балавыз шикелле саргайган йөзе, арык гәүдәсе фашистлар тарафыннан җәзаланган булуын әйтеп тора. Ә теге чакта ул таза, ять-яшь егет иде.

Фашистлар җәзалаганнан соң гарипләнгән хәлендә дә Рафаэльнең комсомол исеменә тап төшермәве, халык ирке өчен көрәшүе миндә аңа карата чын мәхәббәт уятты. Бу кеше дә, апам да – икесе дә комсомол эшчеләре иде. Ул апамны белә торгандыр, бәлки, ул минем әтием турында да берәр нәрсә әйтер дип уйлап алдым мин һәм:

– Рафаэль абый, әйтегез әле, минем әтием кайда? – дип сорадым.

Ул минем соравыма җавап бирергә ашыкмады. Башта минем өстемдәге ертылып беткән күлмәкләрне салдырды, миңа юынырга булышты. Соңыннан яңа күлмәк кидертте, кара сукно чалбар бирде. Ул да булмады, Рафаэль абыйның сеңлесе Мария кулына ике пар балалар башмагы белән носкилар күтәреп кайтып керде. Ул башмакларның бер парын һәм носкиларны миңа бирде. Минем элек шулай матур киенгәнем юк иде. Әле артыма, әле яныма әйләнеп карыйм, матур ашыйсы килү дә онытыла язды, шатлык эчкә сыймый иде. Шул вакыт: «Бу әйберләр кемнеке?» – дип сорыйсым килде минем.

Рафаэль абый миңа туганнарча матур караш ташлап елмайды да:

– Бу киемнәрне безгә Советлар иленнән җибәргәннәр, Мигуэль, кара, алар безне ничек кайгырталар, – диде, һәм ул киемнәрнең Дуранго шәһәрен фашистлар басып алыр алдыннан гына бирегә җибәрелүен, бу көнгә кадәр аларны яшергән урыныннан чыгарырга мөмкинлек булмавын, шулай ук шәһәрдә калган балаларга да берничек тә ярдәм итә алмаганлыкларын аңлатты.

Күп тә үтмәде, Рафаэль абый минем белән Марияне ашарга дәште. Өчәүләп тәмле аш ашаганда гына ул миңа әтием турында сөйләде:

– Ул югалмас. Арнольд белән мин сезне очраштырырмын әле. Тик син беркемгә дә берни дә сөйләмә, – диде. Соңыннан: – Ә Амалия турында ни дә әйтә алмыйм, – дип өстәде.

Мин нигәдер күпне белергә, сорашырга яратам. Аш янында Мариянең әнисе күренмәгәч, аның турында да сораштым.

Рафаэль абый бер сеңлесенә, бер миңа уңайсызланып карады да, көрсенеп:

– Аның инде унбиш көннән бирле өйгә кайтканы юк. Көн саен диярлек эзлим мин аны, тик таба алмыйм. Әллә фашистлар берәр нәрсә эшләтеп ташладылар инде үзен, – диде.

Мариянең күзләреннән энҗе бөртеге кебек яшь тамчысы тәгәрәде. Ул, күзен куллары белән каплап:

– Әнием, күз нурым, әгәр алар сине үтергән булсалар, мин синсез ничек яшәрмен? – дип, елый-елый, анасының стенага эленгән рәсемен барып кулына алды. Ул карточканы бер кулы белән яңагына кысты, икенче кулы белән аны акрын-акрын гына иркәләгән күк сыйпады.

Мин Рафаэль абыйдан Мариянең әнисе турында соравыма үкендем. Үземнең дә күңел тулды. Бәлки, мин дә елап җибәргән булыр идем, тик Рафаэль абый:

– Елама, сеңлем, әнә Мигуэльдән үрнәк ал, – дип әйтергә өлгерде.

Мин батыраеп киттем һәм Рафаэль абыйга Марияне юатырга булыша башладым.

Икенче бер вакытта, Мария юк чагында, Рафаэль абый миңа Мариянең әнисе Кормель Соловарраның фашистлар тарафыннан күптән үтерелүен әйтте.

Мин Рафаэль абыйның сөйләгәннәреннән кабахәт фашистларның, Дурангоны басып алганнан соң, Мариянең әнисе Кормель Соловарраның лабораториясенә кереп, ничә еллар буе эшләгән тәҗрибәләрен ватып-җимереп чыгуларын һәм соңыннан аны газаплап үтерүләрен аңладым...

Мигуэль сөйләвеннән туктады да, үзе утырган креслога таянып торган иптәшенең иңбашына төртеп:

– Әсгать, утны кабыз әле. Мин сезне күрмим. Бәлки, сез йоклый торгансыздыр, – дип куйды.

Мигуэльнең сөйләгәннәрен бирелеп тыңлый торгач, хәтта үзләрен аның белән бергә Испаниядә йөрүче итеп хис итә башлаган балалар, фикер юнәлешләрен рәтләү өчен, берничә секундка гына тынып тордылар да бердән гөрләделәр:

– Ник тыңламаска, әйдә сөйлә, сөйлә!

Кайсыдыр электр лампочкасының включателен борып җибәрде. Караңгыланып килгән терраса эченә аксыл яктылык сибелде. Иптәшләренең үзен тыңлавына ышанган Мигуэль дәвам итте:

– Әнә шул көннән бирле мин Рафаэль абыйда тора башладым. Мария белән дә аерылмас дуслар булып киттек.

Рафаэль абый өйгә бик сирәк йә биш көнгә бер генә, анда да кичләрен генә кайткалап киткәли торган иде. Ул өйгә кайткан араларда безгә шәһәрдәге фашистларның кабахәтлекләре турында сөйли торган иде.

Шулай көннәрнең берендә Рафаэль абый өйгә кайтты да мине бер читкә дәшеп алды. Һәм, кулыма язулы кәгазь тоттырып:

– Мә, шушы кәгазьне әтиең янына еш килеп йөри торган Бартельгә илтеп тапшыр! – диде. – Тик кара, андый-мондый эш булса, һичкемгә берни әйтәсе булма. Язуны юк ит!

Мин, үземнең шундый зур эшкә яравыма шатланып, урамга ташландым.

Урамнар бүген гадәттәгегә караганда да тын. Шәһәр халкы бар да өйләренә кереп бикләнгән. Алар тавышсыз-тынсыз гына нәрсәгәдер әзерләнәләр кебек. Кайбер кешеләр, йорт алдына чыгып, ары-бире карап алалар да тагын өйләренә кереп югалалар. Фашист дружинниклары үзләренең вәхшәтлекләренең, ерткычлыкларының тантанасын итәләр. Алар кабакларга җыелганнар. Эчәләр. Анасын суйган бозау тавышлары чыгарып акыралар... Кабакларга якынрак урнашкан кешеләр эчләреннән генә: «Эчегез, эчегез, актык эчүләрегез булыр», – дигән кебек, тәрәзәдән урамга серле караш ташлыйлар.

Безнең йорт белән Бартель өе арасындагы ерак юлны мин озак йөрдем. Өстемә йөкләнелгән эшне үтәп өйгә кайтканда, капка төбендә күзәтчелектә торган Мария миңа:

– Җыелыш бара, бик шаулап йөрмә! – диде.

Мин аяк очларыма гына басып ян бүлмәгә кердем. Рафаэль абыйны дәшеп, аңа үзем күргәннәрне сөйләдем дә тәрәзә төбенә килеп утырдым.

Күп тә үтмәде, җыелышта катнашучыларның берсе, комсомолец Педро, капкадан атылып чыкты да шәһәр читенә таба йөгерде. Аның шәһәрдән берничә километр ераклыкта урнашкан зур партизаннар отрядының һөҗүмгә әзерлеген белү өчен җибәрелгән булуын мин соңыннан гына белдем.

Мин кайтканга байтак вакыт узгач, өй яныннан Бартель узып китте. Күп тә үтмәде, якында гына гырылдаган тавыш ишетелде. Мин ирекле-ирексез башымны ачык тәрәзәдән урамга суздым. Минем тәнем эсселе-суыклы булып китте. Бартель Марияне капка баганасына сөягән дә, ач бүре шикелле, тырнакларын аның бугазына батырганнан-батыра иде... Мин, үземне-үзем белешмичә:

– Ал пычрак кулыңны! Эт! – дип кычкырып җибәрдем.

Минем тавышны ишетеп Бартель каушады булса кирәк. Ул Мариянең бугазыннан кулын кинәт тартып алды. Ләкин соң иде инде. Мария чалгы белән киселгән зәңгәр чәчәк кебек егылды. Бартель аңа беренче ярдәм күрсәтергә җыенган кеше шикелле кылана башлады. Ул, кулы белән ишарә ясап, шыпырт кына:

– Монда төш әле, су алып чык... – дип эндәште.

Мин башта бу хәлгә ничек дип тә карый алмадым.

Тик башымны тәрәзәдән тартып алганда бер төркем кара күлмәклеләрнең монда таба килүен күргәч кенә, вакыйганың нигезенә төшендем.

«Кара, хыянәтчене, фашист олтанын ялаучыны, Марияне буып үтерүе җитмәгән, мине дә...» дигән фикер яшен тизлегендә минем башымнан узды. Шунда ук мин Рафаэль абыйлар утырган бүлмәгә атылып кердем. Беренче секундта бераздан туачак куркынычлы вакыйганы күз алдына китерүдән минем күз кабакларым җемелдәделәр. Икенче секундта мин ишеккә каршы якка урнашкан кечкенә көзгедә үземнең гадәттән тыш куркыныч төс алган йөземне күрдем. Хәзер ул бер кыза, бер боз шикелле салкыная иде. Үз-үземне белешмәстән мин канатын җәйгән лачын шикелле үземә таба килгән озын буйлы, түгәрәк кара сакаллы бер коммунистның биленнән кочып алдым һәм куркудан, Марияне кызганудан елый башладым.

Ул, аркамнан сыйпый-сыйпый:

– Нигә елыйсың? – дип әйтеп бетерергә өлгермәде, мин Бартельнең фашистлар яклы булуын, әле генә аның Марияне буып үтерүен, фашистлар төркеменең өйгә таба килүен әйттем. Өстәл тирәсенә урнашкан кешеләр кинәт аякларына бастылар. Рафаэль абыйның туганы Базилло, Мариянең үтерелүе турындагы сүзне ишетү белән, йорт алдына ташланды. Озын буйлы, бөдрә кара чәчле, базык таза гәүдәле Больманте өстәлдәге листовкаларны җыеп кесәсенә тыкты.

Мин моннан берничә көн генә элек ул листовкаларны таратып йөргәнне хәтерләдем. Ул листовкалар фашистлар тылындагы халыкны варварларга каршы көрәшкә чакыра иде.

Шул арада тышта шартлау тавышы ишетелде. Шунда ук кара түгәрәк сакаллы, озын буйлы кеше ишегалды ягына караган тәрәзәгә яшен тизлегендә ташланды.

– Базиллоны үтерделәр! – диде ул, тәрәзә янында басып торган хәлдә, ачу катыш нәфрәтле тавыш белән.

– Их, кабахәт шпион Бартель, эт токымы!!! – диде кайсыдыр.

Бу вакыт Больманте тыштагы ишекләрне бикләр өчен бүлмәдән чыгып киткән иде инде. Базиллоның үтерелү хәбәрен ишетү белән, җансыз әйбер шикелле катып калган җиремнән калтыранып китеп, мин дә тәрәзә янына килдем. Базилло баскыч төбендә чалкан ята, күгелҗемләнеп калган тәнле Мария аның уң беләгенә йөзтүбән капланган. Кайсыдыр:

– Аны атканнар, – диде.

Базиллоның аркасына аткан булсалар кирәк. Ул газапланып җиргә ауган да чалкан төшкән. Аның күкрәк сөякләре чәрдәкләнгән, тәнендәге ит кисәкләре умырылып чыккан. Мин ачынып Базилло өстенә карап торганда, Больмантеның көчле тавышы яңгырады:

– Бирелергә ярамый... Безне халык көтә... Тезләнеп яшәгәнче, аягүрә торып үлү яхшырак!!! – диде ул. – Бәлки, Педро фашистларга эләкмәгәндер.

Рафаэль абый бик ерактан йөгереп килгән кебек тыны беткән, әлсерәгән кыяфәт белән миңа карады да:

– Кара күлмәклеләр кайсы яктан килделәр? – дип сорады.

– Педро киткән яктан килделәр, – дидем мин.

Озынча борынлы, җәрәхәтле башын марля белән бәйләгән Астурия эшчесе сакалын кашый-кашый стенадагы кечкенә түгәрәк тәрәзәгә карап торган җиреннән чак кына ишетелерлек тавыш белән:

– Һавадагы торнага ышанып булмый! – диде һәм, кинәт җанланып, батыр ир тавышы белән:– Әйтегез әле, менә бу түгәрәк тәрәзә...

Ул кулларын тәрәзәгә сузганда, мин үземнең шул тәрәзәдән кереп Мариягә ишек ачканымны хәтерләдем һәм шул секундта ук:

– Мин тәрәзәдән сыя алам бит, – дидем шатлыклы тавыш белән.

Ишекләрне бикләп кергәннән соң, ишегалдына караган тәрәзә янына сыенып, тышкы ишек янына килгән фашистларга отпор бирергә әзерләнгән Больманте, тәрәзәдән күзләрен алмый гына:

– Мигуэль, син ул тәрәзәдән чыгып котыла алырсың! Бәлки, безне дә коткарырсың, – диде.

Мин, гаҗәпсенеп:

– Ничек?! – дип кычкырып җибәрдем.

Түгәрәк кара сакаллы, озын буйлы кеше белән берничә яшь егет мине урап алдылар да бүлмә уртасындагы өстәл янына алып килделәр һәм кыска-кыска гына җөмләләр белән миңа партизаннар отряды урнашкан урынны әйттеләр.

Мин кечкенә тәрәзәдән ишегалдына, аннан койма аша тыкрыкка төштем дә бар хәлемә йөгерергә тотындым. Артымнан бер-бер артлы аткан, сүгенгән тавышлар ишетелеп калды.

Менә эшчеләр бистәсенең кара урамнары: җимерек, кыегайган, кыйшайган йортлар... Кайбер урыннарда снаряд төшеп шартлаудан казылган зур воронкалар караңгыда төпсез упкын шикелле булып күзгә чалыналар. Әнә әле моннан берничә генә көн элек фашистлар кулы белән җимерелгән шахта. Күпме аталар, аналар калды бу шахта астында. Бу шахта тирәсендә акылдан язып елаучыларның күз яшен җыйсаң, бер күл булыр иде.

Мин йөгерәм. Урамдагы коточкыч вакыйгаларны искә төшерә торган урыннар артта калды. Менә мин анда-монда үсеп утырган агачлыклар буена җиттем. Бу урында әле күптән түгел генә куе яшеллеккә уралган ял паркы иде.

– Бу ерткычлар агачларны да корыталар, – дип куйдым мин үз-үземә.

Менә мин патрульдә торган үзебезнең кеше янына якынайдым. Мин аңа өйдәгеләр биргән язуны калдырдым. Анда аңа телеграф, телефон чыбыкларын кисү эшен башкарырга әйтелгән иде.

Аның яныннан киткәч, шактый вакыт түш белән шуышып барганнан соң, мин аякларыма бастым һәм тагы бар хәлемә йөгерергә тотындым. Тау аралыгына җитеп килә идем, кинәт:

– Тукта, кем килә?! – дигән тавыш яңгырады.

Мин калтыранып киттем. Ни дип тә әйтергә белмәдем. Хәрәкәтсез калдым. Ә икенче секундта үз-үземне тыя алмый алга атладым. Капкынга эләкмәгәем, партизаннар отрядына җитү өчен мин бу тау аралыгын узарга тиеш дигән уй башымнан яшен тизлегендә узды.

– Тукта! – диде ул, кабатлап.

Мин туктамадым. Менә безнең арабыз да якын гына калды. Шул вакыт дозорда торган теге кеше миңа өченче мәртәбә:

– Тукта! – дип кычкырды. Ул шунда ук мылтык көпшәсен миңа төбәде.

Мин ирекле-ирексез кулларымны югары күтәрдем дә туктадым. Теге кеше мылтыгын төбәгән хәлдә минем каршыма килеп туктады да:

– Сиңа ни кирәк? – дип сорады.

– Мине начальнигыгызга җибәрегез, – дидем мин аңа туры гына.

Ул, мине икенче кеше кулына тапшырып, штабка озатты. Анысы мине җиргә кертеп эшләнгән чатырларның берсенә урнашкан штабка китерде. Бу вакыт мин партизаннар отрядына эләгүемә тәмам ышанган идем инде.

Штабта мин өстенә регуляр халык армиясе киеме кигән, тәбәнәк буйлы, җыйнак кына мыеклы кешене күрдем һәм аннан:

– Партизаннар отрядының командиры сез буласызмы? – дип сорадым.

Ул җавап бирәсе урында башта үзе миңа сорау бирде:

– Син кайдан? Кем син?

Мин, ашыгуымнан сүзләремнең берсен икенчесенә кушып:

– Дуранго шәһәреннән мин. Арнольд улы Мигуэль.

Кара мыеклы кешенең йөзенә шатлык кабынды. Ул ишек төбендә торган сакчыга:

– Тизрәк комиссар Арнольдны монда чакырырга! – дип боерды.

Мин әтиемне хәтерләдем. Аның портретын күз алдына китереп бастырган хәлдә, дулкынланып:

– Сез кем соң? – дип кабат сорадым.

– Мин – партизаннар отряды командиры, – диде ул.

Мин командирга шәһәрдә булган вакыйгалар турында ашыгып сөйли башладым. Соңыннан кара сакаллы, озын буйлы коммунист биргән язуны күлмәгемнең җиеннән алып аңа суздым.

Партизаннар белән шәһәрдәге коммунистлар һәм эшчеләрнең алдан ук бәйләнеше булган икән. Командир, мин сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, язуны күзен йөртеп кенә укыды.

– Никадәрле зур көч куелган әзерлекнең һәм кыйммәтле, акыллы кешеләрнең харап булуы бар... Тизрәк, тизрәк, аларга ярдәмгә! – диде ул. Һәм чатырдан йөгереп чыкты. Шунда ук аның калын базык тавышы ишетелде. Ул арада палаткага әтием атылып килеп керде. Мин бу очрашу шатлыгыннан

нишләргә дә белми калдым. Әтиемнең дә беренче секундта йөзендә гаҗәпсенүле караш бар иде. Ул мине кулларын җәеп килеп кочты да иң җылы сүзләр белән иркәли башлады.

Мин Амалия турында сорыйм дип авызымны гына ачкан идем, әтием, алдан ук сизгән кеше шикелле:

– Мигуэль, апаң Амалия дә монда бит. Ул – пулеметчы. Әйе, әйе, пулеметчының да нindие генә әле, – диде. Аның соңгы сүзләре көчлерәк, яңгыравыклырак ишетелде.

– Дәү апа? – дидем мин.

Әтием, бер ишеккә таба, бер миңа карап:

– Ул да монда, сиңа аның белән калырга туры килер, – диде. Һәм, кулларымны кысып:– Ярый, улым, без очрашырбыз әле, – диде дә чатырдан чыгып китте.

Бу вакыт партизаннарның барысы да стройга тезелгән иде инде. Күп тә үтмәде, ат тояклары тавышы ишетелде. Ә берничә секундтан, җир өстенә эленеп торган кара пәрдәне ертып, ак ат өстенә атланган яшь егет командиры каршына килеп туктады. Ул, еш-еш сулыш алып:

– Шәһәрдә фашистлар паникага бирелгән. Телефон, телеграф чыбыклары өзелгән. Провинциянең партия комитеты секретаре Больманте безнең тизрәк килеп җитүебезне таләп итә. Алар камалып алынган йорттан эшчеләр һәм шәһәр халкы ярдәме белән бәреп чыкканнар.

Менә әтием белән бергә читтә басып торган командирның бер-бер артлы бирелгән корыч командасы яңгырады.

Мин чатыр буенда басып торам. Каршымнан җанлы соры колонна үтә. Җиңүгә ышанган күңел сөенә. Кулларым үзлегеннән югары күтәреләләр. Менә янымнан гына җигүле тачанка үтә. Тачанкада берничә кеше күренә. Аларның берсе минем апам. Аның башында кызыл яулык. Өстендә, элеккечә, гимнастерка.

– Җиңгәнче сугыш, апам. Комсомол билетыңны пуля ертмасын. Но пассаран![1] Пассаремос![2] – дип кычкырдым мин...

Мигуэль сөйләвеннән туктаганнан соң, тыңлаучыларның күбесе беразга тынып калды. Балаларның барысының да куллары фашизмга нәфрәт белән йомарланган иде. Бу вакыт куе зәңгәр күккә тулган ай күтәрелеп килә иде инде. Кинәт, тынлыкны ярып, ял итүче балаларны кичке ашка дәшеп, санаторийның сигналчысы быргы уйный башлады. Балалар гөрләшеп кузгалдылар.

*1938*

*Татар халкының каһарман улы, герой-шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә.*

*Муса укуын башта авыл мәктәбендә, аннары Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Мәдрәсәдә уку елларында (1914–1917) матур әдәбият белән кызыксына, Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев әсәрләре белән якыннан танышып, шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кульязма журналга урнаштыра бара.*

*Большевиклар хакимияткә килгәч, «Хөсәения» мәдрәсәсе Мәгариф комиссариаты карамагындагы урта педагогик белем бирү мәктәбе итеп үзгәртелә, Муса бу мәктәпнең алдынгы укучыларыннан берсе була.*

*1919 елны, Гражданнар сугышы чорында, унөч яшьлек Мусаның «Бәхет» исемле шигыре «Кечкенә Җәлил» имзасы белән фронт газетасында басылып чыга. Шуннан соң аның көрәш рухы белән сугарылган романтик шигырьләре матбугат битләрендә еш күренә башлый.*

*1919–1921 елларда яшь шагыйрь туган авылында һәм Оренбургта яшүсмерләр арасында эшли, бер үк вакытта Оренбург хәрби-сәяси мәктәбендә алты айлык курсларда укый. Аны тәмамлагач, 1922 елның көзендә Казанга килеп, «Татарстан» газетасы идарәсенә эшкә урнаша, ә 1923 елдан Татрабфакта (эшче яшьләрнең югары уку йортларына керү өчен әзерләнү факультеты) укый башлый. Газета-журналларда даими рәвештә шигырьләре, мәкаләләре басыла, 1925 елда исә Казанда «Барабыз» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә.*

*1925–1927 елларда М.Җәлил коммунистик яшьләр оешмасының Орск шәһәр комитетында һәм Оренбург губерна комитетында инструктор булып эшли. 1927 елда аны комсомолның Бөтенсоюз киңәшмәсенә Мәскәүгә делегат итеп җибәрәләр. Киңәшмәдә ул Үзәк Комитетның татар-башкорт бюросына әгъза итеп сайлана һәм шунда эшләү өчен Мәскәүдә калдырыла. Бюроның тапшыруы буенча, М.Җәлил беренче совет татар балалар журналларын («Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы») оештыруда якыннан катнаша һәм 1932 елның ахырына кадәр («Октябрь баласы», Казанга күчеп, «Пионер каләме» исеме белән чыга башлаганчы) шул журналларның җаваплы мөхәррире булып эшли. Бер үк вакытта (1927–1931) ул Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать бүлегендә укып югары белем ала.*

*1933–1934 елларда М.Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли, газетачы-хәбәрче буларак, күп кенә сәнгать остаханәләрендә,*

*авыл җирләрендә була, халык тормышы белән таныша, Мәскәү төбәгендә яшәүче татарлар белән якыннан аралаша. 1934 елда шагыйрьнең шигырьләре һәм поэмалары тупланган күләмле җыентыгы («Орденлы миллионнар») дөнья күрә, шул ук елны сайланма шигырьләре рус теленә тәрҗемәдә дә («Стихи Мусы Джалиля») аерым китап булып басыла.*

*1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театрына профессиональ кадрлар әзерләү өчен Татар опера студиясе оештырылгач, М.Җәлилне шунда әдәби бүлек мөдире итеп эшкә чакыралар. Шагыйрь үзе өчен яңа бу хезмәткә дәртләнеп тотына, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә опера сәнгатенең специфик үзенчәлекләрен, классик опера һәм балет либреттоларының язылыш хасиятләрен профессионал-белгеч дәрәҗәсендә үзләштереп, студиядә зур оештыру эшләре алып бара: үз тирәсенә татарлардан дистәләрчә шагыйрьләрне һәм композиторларны туплый, аларны сәнгатьнең әлеге катлаулы тармагында иҗат итәргә рухландыра, либреттолар язарга булыша, беренче милли татар операларының тууына турыдан-туры иҗади ярдәмен күрсәтә. 1938 елда студиядә укуларны тәмамлап Казанга кайткач та, ул яңа ачылган Татар опера һәм балет театрының әдәби бүлек җитәкчесе булып эшләвен дәвам иттерә.*

*Композиторлар белән аралашу, музыка дөньясы белән тыгыз бәйләнеш шагыйрьнең үз иҗатында да яңа үзгәрешләр тууга китерә: әсәрләрендә лирик җылылык, музыкальлек, нәфислек, халыкчан табигыйлек хасиятләре көчәя, җыр һәм романслар иҗат итүгә игътибары арта. «Сагыну», «Җир җиләгем», «Җырым булсын бүләгем», «Карашларың» кебек, хисләрнең сафлыгы һәм тирәнлеге белән аерылып торган шигырьләр, композиторлар тарафыннан музыкага салынып, халыкның яраткан җырларына әвереләләр. Әдипнең иҗатында бөтенләй яңа жанр – драматик поэма жанры да барлыкка килә. «Алтынчәч» (1935–1941), «Илдар» (1940) драматик поэмалары нигезендә композитор Нәҗип Җиһанов соңыннан үзенең атаклы операларын иҗат итә. Шагыйрьнең 1934–1941 еллар арасында язган лирик шигырьләре, җырлары, «Алтынчәч» һәм «Хат ташучы» (1938) кебек поэмалары сугышка кадәрге татар поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы буларак тәкъдир ителәләр.*

*Сугыш алдыннан берникадәр вакыт М.Җәлил Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе вазифаларын да башкара. 1939 елны Казан хезмәт ияләре аны шәһәр Советына депутат итеп сайлыйлар. Ватан сугышын ул шушы җаваплы урыннарда хезмәт иткән җәмәгать эшлеклесе һәм популяр җырлары, дистәгә якын шигъри китабы белән халыкка танылган әдип сыйфатында каршылый.*

*1941 елның июлендә аны гаскәри хезмәткә алалар. Башта ул Казан гарнизонында хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге хәрби сәясәтчеләр әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә немецлар якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә күчерелә. 1941 елның декабрендә укуны тәмамлагач, өлкән политрук М.Җәлил Мәскәү аша фронтка озатыла (февраль, 1942). Ул Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган русча «Отвага» («Батырлык») исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби мөхбире итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә, Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, хезмәттәшләре белән бергә чолганышта калып, М.Җәлил каты яраланган хәлендә фашистлар кулына эләгә. Шул көннән аның тоткынлыктагы газаплы һәм каһарманнарча кыюлык белән узган кыска гомер этабы башлана.*

*М.Җәлил һәм җәлилчеләрнең, яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы алып барган каһарманлыклары турында дистәләрчә китаплар – романнар, кыйссалар, драма әсәрләре һәм поэмалар языла, кинофильмнар төшерелә. Иң мөһиме, Җәлил һәм аның көрәштәшләре, ахыргы сулышларына кадәр туган халкына турылыклы калып, тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр.*

*1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә (барысы да татарлар) Дрезден шәһәрендә хөкем оештырыла. Хәрби мәхкәмә аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше алып бару»да гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләре Абдулла Алиш, Гайнан Курмаш, Фуад Сәйфелмөлекев, Фуад Булат, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Зиннәт Хәсәнов, Абдулла Баттал, Әхәт Атнашев һәм Галләнур Бохараевларның гомерләре өзелә.*

*Тоткынлык шартларында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен М.Җәлилгә вафатыннан соң (1956 елда) «Советлар Союзы Герое» дигән исем бирелә, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты – бөтен дөньяга мәгълүм «Моабит дәфтәрләре» – СССРның ул вакыттагы иң зур бүләге – Ленин премиясенә лаек була.*

*«Моабит дәфтәрләре» – Җәлил шигъриятенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына тирән ышанычы, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп тәэсирле, эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә. Моабит шигырьләре, Россиядәге барлык милли телләргә тәрҗемә ителүдән тыш, инглиз, француз, испан, алман, гарәп, төрек, кытай, япон, мадьяр, румын, чех һәм башка чит ил халыклары телләрендә дә кат-кат матбугатта басылалар.*

*Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗаттагы батырлыгына багышлап йөзләрчә мәкаләләр, фәнни хезмәтләр, монографияләр язылган, әдәби әсәрләр-шигырьләр, поэмалар, романнар, драмалар һәм сәнгать әсәрләре иҗат ителгән. Әдәби һәм сәнгать әсәрләреннән, мәсәлән, Шәйхи Маннурның «Муса» (1968), Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла болыт» (1977) романнарын, Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» (1956), Риза Ишморатның «Үлмәс җыр» (1955), Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» (1981) драмаларын, Сибгат Хәкимнең «Торыгыз, Мусалар», «Немец дәфтәреннән» исемле шигъри циклларын, Әнвәр Давыдовның «Муса абый» повестен (1964), Нәҗип Җиһановның Әхмәт Фәйзи либреттосына язылган «Җәлил» операсын (1957) һәм башка сәнгатькәрләрнең Муса Җәлил образын сынлы сәнгатьтә тудырган күп кенә әсәрләрне күрсәтеп үтәргә мөмкин. 1966 елда Казан Кремле каршындагы мәйданга каһарман шагыйрьгә һәйкәл куела. 1968 елда Муса Җәлил исемендәге Республика яшьләр премиясе булдырыла, 1970 елда Минзәлә шәһәрендә мемориаль музее, Казанда музей-квартирасы ачыла.*

*М.Җәлилнең әдәби мирасы, бигрәк тә тоткынлыкта иҗат иткән шигырьләре бөтендөнья поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы булып тора. Аның әсәрләре кешеләрдә матур, гуманистик тойгылар уята, аларны яшәешнең матурлыгын күрергә, аны кадерли белергә һәм аның өчен көрәшергә чакыра.*

## ӘЙДӘ, ҖЫРЫМ

Җырым, синдә минем гәүдәләнде
Илне сөйгән йөрәк тибешем.
Җырым иде антым:
«Яшәсәм дә,
Үлсәм дә тик туган ил өчен!»
Ал кояшлы бәхет бакчасында
Чәчәк аткан нәфис гөл төсле,
Сугарылып халкым назы белән,
Җимешләнеп җырым җитеште.
Чагылдырды җырым шат илемдә
Данлы, иркен, рәхәт яшәүне.
Чишмә төсле җырым тамчысыннан
Яшь күңелләр үсте, яшәрде...

Килде фашист...
Дуңгыз борны белән
Керде җимереп илем капкасын.
Эшкә җикте
бөтен Европаны
Ваткан, кискән канлы балтасын.
Вакыт җитте...
хәзер ярты юлда
Куеп торып тыныч эшемне,
Багышларга Ватан сугышына
Үземне һәм каләм көчемне.

Аргамагым, әйдә канатлан да
Җил булып оч сугыш кырына.
Җырым утын корыч сөңге итеп
Мин күтәрдем хәзер кулыма.

Каләмемне салдым юл сумкама,
Автоматым тактым аркама.
Фашистларга каршы пуля һәм җыр
Бил каешымда бергә саклана.

Җыр таратса эфир дулкынына
Илнең данлы хезмәт тавышын,
Фашистларның хәзер баш очында

Бомба булып җырым ярылсын!..

Яңгыра, җыр, хаклык байрагының
Утлы сүзе булып һавада.
Канатландыр җиңү дәрте белән
Йөрәкләрне кырда, калада.

Әйдә, җырым, безгә вакыт җитте
Сугыш кырын айкап үтәргә.
Кара җанын тетеп фашизмның,
Үләксәсен ташлыйк этләргә.

Әйдә, җырым,
батыр җиңү дәртен
Алып керик ялкын эченә.
Мин калмасам җирдә,
син калырсың
Һәйкәл булып үлмәс эшемә.

## КИЧЕР, ИЛЕМ!

Кичер мине, илем, синең бөек
Исемең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмалмадым
Бу тәнемне соңгы сулышта.

Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомрем өчен сатмадым.
Волхов шаһит: изге сугыш антын
Соң чиккәчә керсез саkладым.

Мин курыкмадым өстән яңгыр төсле
Яуганда да туплар, ядрәләр,
Каушамадым кан һәм үлек белән
Тулганда да тирә-әйләнәм.

Алда, артта, уңда һәм сулымда
Киселсә дә юлым күкрәгем
Яраланып канга төренсә дә,
Көчсезләнеп, мин яшь түкмәдем.

Мин алдымда күрдем шыр сөяктән
Котылгысыз үлем шәүләсен.
Кил син миңа, үлем, бары гомрем
Коллык белән төгәлләнмәсен!

Мин түгелме дуска хат язучы
«Борчылма, дип, тормыш юлдашым,
Соңгы тамчы каным тамса тамсын,
Тик антыма таплар кунмасын!»

Мин түгелме шигырь утым белән
Ант итүче канлы сугышта?
«Үлемгә, дип, ачы нәфрәт белән
Елмаермын соңгы сулышта».

«Соң чиктә, дип, синең мәхәббәтең
Җиңеләйтер үлем газабын,
Илемне һәм сине сөюемне
Каным белән җиргә язармын».

«Тыныч булыр йокы, тормышымны
Бирсәм, диеп, туган ил өчен».
Ышан, илем, шушы ант сугарды
Йөрәгемнең соңгы тибешен!

Язмыш көлде, үлем кагылмыйча
Үтте яннан, минем тирәләп.
Нишлим, нишлим, соңгы минутымда
Пистолетым итте хыянәт!

Чаян чага үзен соңгы чиктә,
Бөркет ярдан түбән ташлана.
Мин соң бөркет түгел идеммени
Баш ияргә шуннан башкага!

Ышан, илем, шундый бөркет идем
Мин дә соңгы минут килгәндә,
Әзер идем, мәгърур канат җәеп,
Ташланырга ярдан түбәнгә.

Нишлим, сугыш дустым-пистолетым
Соңгы сүздән кинәт баш тартты.
Богау салды дошман кулларыма
Һәм хурлыклы юлдан атлатты.

Тоткынлыкта хәзер мин... һәр көнне
Көн чыгышын комсыз күзәтәм.
Шигырь булып чыга үч ялкыны
Яраланган лачын йөрәктән.

Көн чыгышы дуслар кулындагы
Байрак булып көн дә кызара.
Белмисез лә, дуслар, тоткын күңел
Күкрәктәге җәрәхәттән түгел,
Канлы үчтән шулай кыза ла!

Тик бер өмит: кара август төне
Илтер мине шунда җитәкләп.
Өстен килер түбән әсирлеккә
Үч һәм илгә керсез мәхәббәт.

Тик бер өмит, дуслар: сезнең сафта
Табар соңгы көрәш теләген
Яраланган, ләкин тар коллыкка
Баш имәгән керсез йөрәгем.

**ШАГЫЙРЬ**

Төн утырып шагыйрь шигырь язды,
Ак кәгазьгә тамды яшьләре.
Тышта давыл иде: бертуктаусыз
Күк күкрәде, яшен яшьнәде.

Җил ишектән кереп өстәлдәге
Кәгазьләрне чәчте, туздырды.
Аннан, чыгып тышка, йөрәк яргыч
Ачы тавыш белән сызгырды.

Тау-тау булып дәрья дулкынланды,
Яшен сукты калын имәнне.
Эчпошыргыч шомлы тынлык басты
Тирәдәге карсак өйләрне.

Тик төн буе шагыйрь бүлмәсендә
Ут балкыды көннән яктырак.
Давылланып, аның йөрәгеннән
Ак кәгазьгә хисләр актылар.

Шагыйрь торды тынып таң алдыннан,
Язганнарын җыйнап яндырды.
Үзе китте чыгып...
Җил басылды,
Давыл тынды, ал таң кабынды.

Төн утырып шагыйрь нәрсә язды?
Нинди хисләр аны ярсытты?
Язганнарын биреп җил иркенә,
Таңда үзе кая ашыкты?

Сез сорагыз аны исәр җилдән,
Яшеннәрдән, дулкын тавыннан
Һәм сорагыз ямьсез төнне куып,
Таң тудырган көчле давылдан.

## БҮРЕЛӘР

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.

Күпме кан, күпме яшь ат ите!
Ялтырый бүренең күзләре.
Бит моны, төн буе атышып,
Тураган кешеләр үзләре.

Бүреләр башлыгы карт бүре,
Исереп кешеләр канына
Йөргәндә, сискәнеп туктады
Бер авыр яралы янына.

Яралы ыңраша, саташа,
Каенга терәгән башкаен.
Кызганып егетне, җил белән
Тибрәнеп сыкрана ак каен.

Кызганып егетне, елыйлар
Миләүшә һәм лалә чәчәге.
Тәгәри үләнгә чык түгел,
Гөлләрнең гөнаһсыз яшьләре.

Карт бүре егетне иснәде,
Аптырап күзенә карады,
Һәм кинәт нидәндер сискәнеп,
Бер читкә тайпылды яралы.

Яралының зәгыйфь сулышы
Бәрелде бүренең борнына.
Юк, бүре тимәде,
сак кына
Борылып юнәлде юлына.

Таң белән килделәр кешеләр,
Күрделәр яралы егетне.
Яртылаш ул тайган исеннән,
Шулай да яшәве өмитле.

Кешеләр егетнең тәненә
Кыздырып шомполлар бастылар.
Туйганчы җәфалап,
соңыннан
Ялгыз ак каенга астылар.

Кешеләр сугыша, кан коя,
Киселә меңнәрчә гомерләр.
Төн буе улашып якында
Иснәнеп йөриләр бүреләр.

Бүреләр, аһ... ләкин бүреләр
Бу кадәр үк ерткыч түгелләр.

## ЯШЬ АНА

Авыл яна... шәфәкъ нуры булып
Уйный күктә янгын шәүләсе.
Күмерләнгән өйнең тупсасында
Аунап ята ана гәүдәсе.

Алты айлык бала елый-елый
Капшый аның сулган күкрәген!
Ятып суыра, туктап карап тора,
Үксеп уа аннан күзләрен.

Палач үзе кача көн[батышка],
Өстерәлә ватык көймәсе.
Куа аны арттан ядрә булып
Ана каны, бала күз яше.

Күрше кызы Сәрвәр базда иде,
Иштеп чыкты бала тавышын.
Кинәт, куркып, сүзсез катып калды,
Үлгән килеш күреп танышын.

Ул баланы алды кочагына,
Яшен сөртте, үпте, юатты.
Алып кайтты, җылы сөт эчерде,
Кулларына алып уйнатты.

Ул сикертте аны тезләрендә,
Ана дәрте анда кабынды.
Бала көлде, аннан: «Әннә!» – диеп,
Күкрәгенә аның сарылды.

Сәрвәр әле бары унҗидедә,
Тормыш аңа яңа башлана.
Ул елмая ана назы белән,
Ана бәхте белән шатлана.

Сез күрерсез, шундый матур итеп
Ул баланы карар, үстерер.
Тәрәзәдән һәр кич яшь ананың
Дәртле бишек җыры иштелер.

Күңлем оча минем канатланып,
Аның җырын тыңлап узганда.
Рәхмәт сиңа, илем! Шундый йөрәк
Биргән өчен безнең кызларга.

**ДУСКА**

*А. А.*

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип,
Без алмадык сатып гомерне,
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?!

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?!

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне.
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Шатландыра безне көн дә илнең
Бер-бер яңа уңышын ишетү;
Нинди зур көч читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү!

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп,
Ил битемә минем төкерсә?!

Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,
Йөрәк минем моңа үчекмәс.
Кешеме мин илем үги иткәч,
Җирдә миңа эчәр су беткәч?!

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер
Ил гомренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бары аның яктысы.

Батырлык һәм илгә турылыкны
Шушы үлем белән белдерик.
Безнең яшьлек шушы хисләр белән
Данлы иде, көчле иде бит!

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда!

## ИШЕК ТӨБЕНДӘ

Үтеп барам шулай урам буйлап,
Парадныйда күрәм бер бала.
Звонокка үрелә, буе җитми,
Аптырагач, карап уйлана.

Мин балага киләм:
– Әллә, – димен, –
Звонокка буең җитмиме?
– Җитми шул, – ди.
– Кая, үзем басыйм.
Бернеме, – дим, – әллә икеме?

– Биш, – ди. Басам.
Шуннан бала әйтә:
– Абзыкай, син нинди йөрәкле!
Әйдә качыйк хәзер, хуҗа чыкса,
Икебезгә дә бирер кирәкне!

## ҖЫРЛАРЫМ

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онтылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе.
Шигъремдәге чынлык, ут һәм сөю –
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигъремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,

Үлемем дә яңрар җыр булып.

*Шагыйрь Исхак Кадыйр улы Закиров 1911 елның 14 сентябрендә Казан шәһәрендә туа. Мулланур Вахитов исемендәге татар урта мәктәбендә укый. Шунда укыганда, бер төркем укучылар үндүрт яшьлек Исхак Закиров мөхәррирлегендә «Ислам баласы» исемле иҗтимагый-сәяси һәм дини-милли эчтәлектәге кульязма журнал чыгара башлыйлар. Журнал 1925 елдан 1928 елга кадәр дәвам итеп (барлыгы 37 сан), җирле ОГПУ органнары тарафыннан туктатыла, балигъ яшьтә булмаган укучы авторлары мәктәптән куыла, өлкәннәрдән 12 нче мәчет имам-хатибы Якупов, мөәзин Ш.Ибраһимов, Исхакның әтисе Кадыйр Закиров һәм журналның соңгы балигъ яшьтәге мөхәррире З.Абдуллин хөкемгә тартылалар. Тикшерү барышында журналга «Хакыйкать йолдызы» исемле яшерен оешманың органы булган дигән сәяси мөһер сугыла һәм гаепләнүчеләрнең һәркайсына хөкем карары чыгарылып төрлечә җәза бирелә.*

*Мәктәптән куылган Исхак шулай да урта белем алуга ирешә, аннан соң читтән торып укып Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый. 1934–1941 елларда ул әүвәл Татарстан дәүләт нәшриятында, соңыннан Татарстан Язучылар берлегендә бухгалтер булып эшли.*

*Бөек Ватан сугышы башлану белән, Исхак Закиров фронтка җибәрелә, бик күп канлы бәрелешләрнең шаһиты була, совет гаскәрләре белән бергә Белоруссия җирләрен азат итү сугышларында катнаша, шәхси батырлыклары өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. 1944 елның 14 июлендә Витебск өлкәсенең Гордилово авылы янында барган бәрелешләрнең берсендә Исхак Закиров, ротаны һөҗүмгә күтәреп, дошман ныгытмаларын атакалаганда каһарманнарча һәлак була. Аның соңгы батырлыгы үлеменнән соң II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән билгеләп үтелә.*

*И.Закировның шигырьләре көндәлек матбугатта 1929 елдан басыла башлый. Шагыйрьнең иҗат мирасы зур түгел, ләкин шул кечкенә мираста да аның поэтик фикер йөртә белүе, тормыш күренешләрен, кеше йөрәгендәге хис-тойгыларны шигъри тел белән әйтеп бирергә омтылуы ачык күренә. Шигырьләренең күпчелеге патриотизм, интернационализм, батырлык темаларына багышланган. Бу темалар шагыйрьнең Ватан сугышы чорында иҗат иткән шигырь һәм очерк язмаларында аеруча калку төс ала. Сугыш елларында аның шигырьләре һәм очерк язмалары «Алга, дошман өстенә!» дигән фронт газетасында һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә басыла.*

*Шагыйрьнең шигъри иҗатыннан аерым үрнәкләр «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) һәм «Утлы еллар поэзиясе» (1972) кебек җыентыкларда урын ала.*

## АНАГА

Син сөйдең ике балаңны,
Зур өметләргә төреп.
Иркәләдең, төн йокыңнан
Тәмлерәк итеп үбеп.

Үстеләр алар чәчәктәй,
Гөл кебек тормышыңа.
Һәр эшеңдә зур таяныч –
Пар канат булып сиңа.

Инде фашист этләренә
Ут сибә бөркетләрең.
Син дә батырлан, чыгарма
Күз яшең бөртекләрен.

Зур көрәштән бит үзең дә
Читтә калмыйсың, ана.
Улларың белән фронтка
Үз йөрәгең дә бара.

*1941*

## КОМАНДИР

Бер великан каты баскан кебек

Бергә атлый рота адымын.
Ә командир тыңлый шатлык белән
Ротасының җырлап баруын.

Колоннасы аңа бала кебек,
Аталарча сизгер күңеле,
Дошманнарны кыйнап бер сыналган
Ротасына бәйле гомере.

Белеп тора һәрбер көрәшченең
Ни эшләвен, ничек яшәвен.
Тотып ала, оста аучы кебек,
Моңаюның серле сәбәбен.

Йөрәгендә аның хаклык яна,
Туры әйтә йөзгә гаебен,
Син белмәгән җирдән күрә белә
Вөҗдан белән эшләү кадерен.

Сугышчылар, бәлки, туганын да
Алай сөя алмый торгандыр,
Кирәк икән, аңа яшәвеңне
Бирә торган якын туган ул.

Бервакытта шулай караңгы төн,
Ярып кердек дошман сафына.
Приклад белән штык ут уйната,
Салкын карга агып кан туңа.

Ә командир шунда өч дошманны
Юлбарыстай кире какканда,
Җилкәсенә аның, ялт-йолт килеп,
Дүртенче бер мылтык ташлана.

Моны күргән өч-дүрт сугышчыдан
Командирга ярдәм сузылды,
Тик дошманның саны күп булганга,
Һич бушатып булмый кулыңны.

Юл арчуны шунда бер армеец
Штык көче белән башкарды,
Шул секундта үз гәүдәсен куеп,
Сөйгән командирын саклады.

Ул армеец шулай һәлак булды...
Ә командир үчле ачудан
Рота белән дошман сафын таптый,
Зур шәһәргә юллар ачыла.

Дәртләндерә аның командасы,
Нинди бәхет аңа иптәшлек.
Бриллиант күк аның вөҗданы саф,
Дуслык уты мәңге сүнмәслек.

*1941*

**АВТОМАТЫМ**

Автоматым минем, якын дустым,

Аның белән булган чагында,
Мин үземдә сәләт, көч табамын
Фрицларны кырып салырга.

Ул һәрвакыт бергә үзем белән,
Төн үткәрә җылы кочакта,
Ә көндезен кайнар чәй эчкәндә,
Ул да карый янган учакка.

Салкын көндә, яңгыр яуган чакта,
Палаткага бергә сыена,
Минем белән бергә утка керә,
Агым суда бергә коена.

Серләребез килешә, телен аңлыйм.
Иркәләргә үзен иренмим,
Аның уты, көчле тавышы аша
Җиңү тавышын тыңлыйм илемнең.

Автоматым минем, якын дустым,
Ышанычым аңа какшамас,
Һичкайчан ул миңа хыянәт итмәс,
Беркайчан да мине ташламас.

*1944*

*Рахман Ильяс (Габдрахман Вәкил улы Ильясов) 1908 елның 15 мартында элекке Казан губернасының Зөя өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Апас районы) Карамасар авылында туа. Аның әтисе Вәкил абзый, нәсел шәҗәрәсе буенча игенче катлавыннан булса да, бөтен гомерен диярлек Грозный нефть учакларында нефтьче булып уздыра. 1919 елның җәендә ул үзенең гаиләсен дә шунда алып китә. Яшүсмер Габдрахман Грозныйда гомуми белем алуын дәвам иттерә, 1924 елда нефть чыгару вахтасында слесарь өйрәнчеге булып эшли башлый, ә 1925–1927 елларда ФЗӨ мәктәбендә укый. Аны тәмамлагач, яңадан вахтадагы эшенә кайта. 1929 елда аны Грозныйдагы Шәрекъ халыклары клубы идарәсенә рәис итеп билгелиләр.*

*1931 елда Р.Ильяс Казанга килә һәм Татар коммунистлары университетына (ТКУ) укырга керә. Ел ярым укыгач, яңадан Грозныйга кайта һәм 1933 елга кадәр нефтьчеләр өчен чыга торган газета редакциясендә әдәби хезмәткәр һәм хәбәрче булып эшли.*

*1933 елда Р.Ильяс, татар язучылары даирәсенә якынрак булу өчен, бөтенләйгә Казанга кайтып төпләнә. Ул газета редакцияләрендә, Татарстан радиокомитетында әдәби хезмәткәр, мөхәррир, 1934 елда барлыкка килгән Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант, аннары Главлит вәкиле булып эшли. Ватан сугышы башлангач, үзе теләп фронтка китә һәм рота командиры сыйфатында Украина җирләрендә барган канлы бәрелешләрдә катнаша. Харьков шәһәре тирәсендәге шундый бәрелешләрнең берсендә, 1943 елның 23 августында, Рахман Ильяс батырларча һәлак була. Совет хөкүмәте аны вафатыннан соң Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкли.*

*Рахман Ильяс әдәбият мәйданына 30нчы елларның башында нефтьчеләр һәм тау халыклары тормышыннан алып язылган хикәяләре белән килеп керә («Кем гаепле?», «Таулар арасында», «Мин синең белән», «Чыныгу», «Шәрифҗамал» һ.б.). Нефть чыгару учакларында хезмәт энтузиазмын, социалистик ярыш һәм заманында бик актуаль саналган «корткычлыкка каршы көрәш» темаларын яктырткан «Горизонт» (1933–1934) повесте язучының иҗатында аеруча күренекле урын тота. Әсәрдә эшчеләр тормышы реалистик вакыйгалар һәм үзенчәлекле кеше образлары аша шактый киң һәм ышандырырлык итеп яктыртыла. Әдипнең шушы ук нефтьчеләр һәм тау халыклары тормышына багышланган берничә сәхнә әсәре дә бар («Фонтан», «Танышлар», «Таулар тетри»). Аның соңгы әсәрләреннән булган «Таулар тетри» (1941) пьесасында Грозный нефтьчеләренең Гражданнар сугышында катнашуы күрсәтелә.*

## ГОРИЗОНТ

*(Повестьтан өзек)*

Батырҗан белән Нәгыймәне пулемет командасы командиры якындагы бер казак авылына сөт алырга җибәрде. Ул вакыт Батырҗан унтугызынчы яше белән генә бара иде. Нәгыймә егерме бишләрдән узган иде инде. Шулай булуына да карамастан ул бик яшь чырайлы, нәфис буйлы, зур зәңгәр күзле кыз иде. Озакка сузылган канлы көрәш Батырҗан белән Нәгыймәнең йөрәген бергә нык бәйләде. Алар берсенә берсе «әшнә» дип исем бирделәр. Бөтен команда аларны «әшнәләр» дип йөри башлады.

Ике әшнә авылга якынлашканда, чиркәү колоколы кичке бишкә сукты. Ә авылдан кире кайтканда, кояш баткан иде инде. Кич караңгы, һава шактый тын. Тик сирәк-сирәк ишетелгән мылтык тавышлары белән артта калган авылда эт өрүләре генә тынлыкны бераз бозалар иде.

Нәгыймә:

– Әшнә, мин арыдым, бераз ял итмибезме? – диде.

Батырҗан каршы килмәде.

Юлдан берничә метрлардагы куаклык артына барып ятты. Әшнәсе артыннан Нәгыймә дә калмады. Ул да Батырҗанга якын ук килеп яшел чирәмгә сузылды.

Батырҗан, сүзсез озак ятканнан соң, Нәгыймәгә таба борылды.

– Нигәдер бик күңелсез, әшнә, – диде.

Нәгыймә елмаеп куйды:

– Ә миңа киресенчә... – Ул Батырҗанның кулын тотты: – Син тирә-ягыңа кара, Батырҗан, әнә нинди биек таулар, аларның башларын калын кар катлавы каплаган. Анданиләр генә юк дип уйлыйсың...

Нәгыймә Батырҗанның күзләренә карады. Батырҗан карашын болытлы күккә төбәгән дә нәрсәдер уйлана кебек. Гүя ул Нәгыймәнең сүзләрен тыңламый. Нәгыймә, хәтере калгандай, Батырҗанның кулын ычкындырды.

– Син мине тыңламыйсың да, – диде ул.

– Киресенчә, рәхәтләнеп тыңлыйм. – Батырҗан Нәгыймәнең кулын сыйпады. Аның күзләренә карап нәрсәдер әйтергә теләде. Ләкин Нәгыймә моны сизмәде булса кирәк. Ул үз уйларына баткан иде. Һәм кинәт кенә торып утырды.

– Беләсеңме нәрсә, Батырҗан? – диде.

– Әйтеп кара, әшнә.

– Минем Казбек тавы башына менәсем килә. Мин сугыш беткәч тә аның башына менәрмен, юк, мин үзем генә түгел, без синең белән икәү...

Нәгыймә сүзләрен әйтеп бетерә алмады, Батырҗан кинәт кенә сузылып аның муеныннан кочаклап алды да үзенә тартты.

– Мин риза, синең белән кая барырга да риза. Яратам мин сине, Нәгыймә, – диде.

Бу беренче мәхәббәт иде. Батырҗан үзенең яратуын, матур буяуларга буямыйча һәм тартынып тормыйча, гади сүзләр белән аңлатты. Ләкин бу гади сүзләр астында күңел сафлыгы, чын мәхәббәт сизелә иде.

Нәгыймә үзенең Батырҗаннан берничә яшь олы булуын уйлап алды да сискәнеп киткәндәй булды. Ләкин муеныннан Батырҗанның кулларын алып ташламады, киресенчә, аңа елышарак төште.

Батырҗан белән Нәгыймә, бер-берсенә нәрсә әйтергә белмәгән төсле, сүзсез озак тордылар.

Берникадәр вакыттан соң Нәгыймә Батырҗанның чәчләреннән сыйпады да:

– Әйдә киттек, Батырҗан, соңга калмыйк, – диде.

...Шушы вакыйга Батырҗанның күңелендә озак еллар буена онытылмаслык хатирәләрнең берсе булып калды. Шул кичтән соң алар тагын да дуслана төштеләр, бер-берсенә тагын да якынайдылар. Ләкин ул вакыйга артык кабатланмады. Алар бер-берсен иркәли алмадылар. Канлы көрәш, күпләрне аерган кебек, аларны да аерды.

Юк, Нәгыймәгә Казбекка менү насыйп булмады. Бу гади хыял гамәлгә ашмады. Грозный шәһәреннән чигенгән вакытта Батырҗан Нәгыймәнең канлы гәүдәсен генә күреп калды. Снаряд ярчыгы аның башына тигән һәм ул кан эчендә ята иде.

Батырҗанга Нәгыймә әле дә менә шул хәлендә ята кебек күренде. Ул, күзләрен йомып, битен кулы белән каплады.

*Ватан сугышына кадәр совет чоры татар әдәбиятында фәнни-популяр, сәнгатьле-документаль жанр әсәрләре белән танылган Хәмит Кави 1906 елны хәзерге Чуашстан Республикасының Козлов районы Әлмән авылында укытучы гаиләсендә туа. 1920–1926 елларны Казанда педагогия техникумында, аннары читтән торып Көнчыгыш педагогия институтының биология факультетында (1926–1931) белем ала. 1926 елдан бирле Казандагы урта мәктәпләрдә, техникумнарда биология һәм география фәннәре укыта.*

*Х.Кави, бик яшьтән география, геология фәннәре белән кызыксынып, студент чагында һәм укытучылык эше белән шөгыльләнгән елларында ук илнең төрле почмакларына сәяхәтләр ясый, үзенең күргәннәре турында фәнни-популяр характердагы очерклар, маҗаралы хикәя-повестьлар яза. 1929–*

*1939 еллар арасында аның унлап китабы басылып чыга. Шундыйлардан «Кавказ таулары аркылы җәяү» (1930), «Идел буенда йөрү юллары» (1931), «Боз диңгезенә таба» (1932), «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) исемле китаплары яшүсмерләр һәм мәктәп укучылары арасында популярлык казаналар. Язучы республиканың географик үзенчәлекләре, казылма байлыклары, халыкның көнкүреше, мәдәнияте турында көндәлек матбугатта дистәләгән очеркларын һәм хикәяләрен бастыра.*

*1941 елның сентябрендә Хәмит Кави фронтка китә һәм Совет Армиясе командиры сыйфатында Идел буеннан көнбатыш чикләргә кадәр сугышчан юл уза. 1944 елның 15 июлендә Украинаның Волынск өлкәсендәге Друженополь дигән авыл тирәсендә барган сугышларның берсендә ул батырларча һәлак була.*

## КИЛЬДИН АТАВЫ

Кооператив әйберләрен алырга килгән кеше кырыйга безне дә алып чыкты. Шушы төшү белән Кильдин атавында бер атна тордык. Килгән кешеләр мәктәп йортына урнашалар икән, без дә шунда кереп урнаштык. Мәктәпнең бер бүлмәсендә ике өстәл, бер карават бар иде. Караватка Соловьев, өстәлләргә Фиш белән мин урнаштык. Шулай итеп, тын гына тора башладык. Атау буйлап көне буе йөргәч, кичке унберләрдә кайтып мич ягып җибәрә идек. Мич янып кызгач кына, тагын утын салып, йокларга ята идек. Бары беренче көн генә дөрес эшләмәдек. Мич сәгать унда ягылды, сәгать уникеләрдә бүлмә тәмам кызу иде. Без сәгать икегә кадәр укып яттык. Яткан вакытта бүлмә җылы булса да, иртәнге сәгать сигезләрдә мин суыкка калтырап уянып киттем. Бу суыкта артык ятарга мөмкин булмагач, утын ярып тагын мичне ягып җибәрдек. Шуннан соң гына тагын йоклап китеп булды. Минем юрганым юка булганга күрә, ахрысы, суык миңа катырак тәэсир итә иде. Беренче көнне суыкның тәмен татыганга, икенче көнне кичке унда мичне ягып, йокларга ятканда да сүндермәдек.

Ашау мәсьәләсе дә Кильдинда уңай хәл ителде. Күршедә генә тора торган бер хатын безгә ашлар пешереп бирергә булды. Монда балыкка аптырау юк. Балык кирәк булса, диңгез кырыена барабыз да яңа гына тотып кайткан балыкчылардан балык алабыз. Иң яратып ашаган балыгыбыз – камбала балыгы. Камбаланың бер ягы ак, икенче ягы коңгырт төстә була. Ике күзе дә коңгырт төсле ягында урнашкан. Камбаланың бер ягы ак булу диңгез төбендә бер ягы белән ятып азык сагалавыннан килә. Менә шул балыкны сатып алып (аның берсе өч-дүрт килограмм чамасы була) аш пешерүчегә бирә идек. Алып кайтканда, камбалалар әле тере булалар, кулдан сикереп төшеп аптыраталар. Аш бөтенләй диярлек шул балыктан пешерелә иде. Беренчегә балык шулпасы бирелә, ә икенчесенә шул ук балык кыздырыла иде. Көн дә балык ашларын төрләндереп тә ашадык. Кайбер көннәрдә треска балыгы да алгаладык.

Кильдин атавы бик кечкенә атау түгел. Аның озынлыгы – 15, киңлеге 5 километрлар бар. Шуның көньяк-кояш чыгышы ягындарак авыл урнашкан. Торучыларның күбесе руслар, аз гына Норвегия кешеләре дә бар. Атауның тарихы кызык кына. Монда иң элек Соловки атавындагы монахлар килеп урнашканнар. Алар берникадәр торгач, диңгез караклары аларны үтереп киткәннәр. Аларның каберләре исеме белән аталган бер күл белән атау борыны бар. Авыл тора торган борынны «Кабер борыны» дип йөртәләр. Монахлардан соң монда Ириксин исемле Норвегия кешесе килеп урнашкан. Аның нәселе атауда әле дә бар. Монахларның кабере булган кебек, аның нәселеннән булган кешеләрнең дә атауда каберләре саклана. Монда Ириксин салдырган йортлар калган. Хәзер ул йортларда госторг конторы урнашкан. Аннан соң Кильдинга руслар килгәннәр. Хәзер авылда күп йортлар салынган. Җәй көне кышкыга караганда атауда кешеләр күбрәк булалар. Җәен монда балык тотар өчен төрле җирләрдән балыкчылар җыела. Кыш айлары җитеп, балык сезоны үткәч, алар өйләренә таралалар.

Атау табигый яктан да бай. Күп җирдә ярыйсы гына үлән дә үсә. Кильдин кешеләре аны чабалар, сарык, сыер кебек хайваннар да асрыйлар. Мичкә ягар өчен атауда торф бик күп. Торф катлавының 3 метрга җиткән җирләре бар, диләр. Шифер, сланец исемле промышленностька кирәкле ташлар да бар. Җиргә сузылып кына үсә торган булса да, агачлар да бар. Су кырыенда очып йөри торган кошларның исәбе-хисабы юк. Акчарлаклар Иделдә кечкенә булалар бит, монда алар каз зурлыгында. Кырыйдагы зур-зур ташларда утырган яки су өстендә очып йөри торган акчарлаклар санап бетергесез. Алар көндез диңгездә балык тоталар, кич кырыйдагы зур ташларга кунаклап йоклыйлар. Кильдинда үрдәкләр дә аз түгел. Башка төрле кошлар да монда иркен торалар. Аларны атучы юк. Бары бер мәртәбә генә госторг кешесенең акчарлак атканын күрдем. Аның итен яратмыйлар, бары йоны өчен генә аталар икән.

Кильдинның һавасы да яхшы. Монда җәй көне түгел, кыш көне дә зур суыклар булмый. Баренц диңгезенә кадәр агып килә торган җылы агым – Гольфстримның[1] монда да тәэсире җитә. Кильдин 70 нче төньяк янәшә сызыгына[2] берничә минутлар гына җитмәгән урында торса да, Гольфстрим агымының тәэсире белән аның тирәсендә диңгез кыш көне дә катмый. Гольфстрим җылылыгы тәэсире белән Кильдин үсемлекләргә дә бай.

Монда җәй көне 2–3 ай кояш бер дә баемыйча, кыш көннәрендә 2–3 ай бер дә чыкмыйча тора. Без

җәйге озын көннең актыкларындарак килгәнбез икән. Алай булса да, без кояш батамы, юкмы икәнлеген карарга бардык. Ачык диңгез атауның төньягында, ә авыл көньягында урнашкан булганга, бөтен атауны аркылы үтеп барырга туры килде. Атауның авыл урнашкан җирләре тәбәнәк. Ә калган урыннары таулардан тора. Шуңа күрә элек озак кына тауга менәргә туры килде. Тау менү бераз ардырса да, тирә-якта матур күренешләр ачылганга, урман өстеннән барган шикелле сырышып үскән йомшак агачлар өстеннән барганга, рәхәт тоелды. Юлда берничә күл һәм алар тирәсендә сазлыклар очрады. Мин бер җирдә болан мөгезе таптым. Кильдинда хәзер боланнар булмаса да, элек булган, - ахрысы.

Тау башына менеп җиткәч, ачык Баренц диңгезенә матур күренеш ачылды. Алда да, уңда да, сулда да җир күренми. Ерактан караганда, дулкыннар диңгезне шадраландырып торалар. Офыкка якынлашып килә торган кояшның озын яктылыгы дулкыннарның селкенүен тагын да матуррак итеп күрсәтә. Җиргә якынрак урыннарда әкрен генә шуышып балыкчы көймәләре бара. Аларның кайберсе җилкәннәрен төшергән дә бер урында торып балык тота.

Тау башында бераз карап торгач, тауның төньяк кырына да төштек. Төньяк кырында мүкләр дә үсми. Ялангач ташлар гына. Ташлар өстеннән озак бармадык, кояшның батуын карарга әзерләндек. Бу вакытта сәгать төнге 12 иде. Кояш офыкка якынлашкан, озакламый батарга тора. Кояшның бата башлаган урынын билгеләп ташлар куйдык та, батуны карарга әзерләнеп, ташлар өстенә утырдык. Кояш һаман кояш чыгышына таба бара-бара офыкка бата башлады. Элек аз гынасы офыкка керде. Шул арада көнчыгышка таба әллә никадәр җир күчеп тә өлгерде. Тагын бераз карап торгач, кояшның өч чиреге офыкка батты. Бу вакытта сәгать икенче яртылар булганга, йокларга кайтырга гына тора идек, моңа кадәр батып килә торган кояш тагын күтәрелә башлады. Шулай итеп, кояшның чиреге дә батып җитә алмады. Без килгәнчегә кадәр кояш бөтенләй батмый торган көннәр булган. Хәзер исә озын төньяк көненең актыгы якынлашып килә.

Атау буйлап без, кояш карарга барганда гына түгел, башка вакытларда да йөргәли идек. Шулай бер мәртәбә атауның көнчыгыш ягына таба да барган идек. Көнчыгыш ягында таулар 80 метрлар биеклегендә бик текә дарлар белән бетә икән. Көн ягыннан шул тауларга менеп, текә ярларның кырыена килеп карадык. Без килә генә башлаган идек, ярдан берничә кош, очып китеп, кычкырып очып йөри башладылар. Шул тирәдә генә аларның оялары бар, без аларны куркытып чыгарганбыз икән. Без, читкәрәк китеп, шуышып барып, ярның кырыена ук килдек. Текә яр өстеннән карау бераз куркытса да, күңеллелек тә бирә икән. Биек ярның бер кырыенда зур-зур ташлар ята. Кайбер урыннарда ул зур ташларны суүсемлекләре чолгап алган. Дулкын шаулап зур ташларга бәрелә. Кошлар шул тирәдә генә балык тотар өчен очалар. Таштан ташка сикереп, бер ак төлке – песец (төлкедән кечерәк, тиресе кыйммәтле бер җәнлек) йөри. Ул килгән урыннан кошлар читкәрәк очалар. Качып кына барган шикелле, шуып кына бер җилкәнле балыкчы көймәсе дулкыннарга менә.

Буш вакытларда шулай атауда йөрү күңелле. Төньяк табигатенең матурлыгына исең китәр. Кабер күлен үтеп, бераз көнчыгышка табарак баргач, агачтан бер маяк ясап куйганнар. Кайвакытларда шуның янына барып та диңгезгә карап утыра идек.

Буш вакыт булдымы, Соловьев шигырь яза. Ул кайвакыт Шолом Алейхем исемле язучының хикәяләрен укый. Бервакыт Фиш аңар:

– 70 нче төньяк дәрәҗәсендәı син Шолом Алейхемның беренче укучысыдыр, – диде. Шуннан соң миңа карады да: – Син 70 нче төньяк дәрәҗәсенә килеп җиткән беренче татар туристы, – диде.

Мин көлдем дә:

– Сез татарлардан миннән башка 70 нче дәрәҗәгә килеп җиткән кешеләр юк дисезмени? – дидем.

Аннан соң Фиш:

– Без монда бер интернационал икәнбез. Син – татар, мин – еврей, Соловьев – рус, – диде.

Соловьев белән Фиш Кильдинга карап йөрер өчен генә килмәгәннәр. Аларны Ленинградтагы кичке кызыл газета хәбәрчесе итеп мондагы тормышны язарга җибәргәннәр. Кильдинда халык өч төрле кәсеп белән тора. Күбесе, балык тотып, аны кооперативның шхуналарына илтеп сата. Кайберсе йод табу эшендә эшли. Кайберләре ак төлке (песец) үстерә.

Атауда күп кеше балык тоту белән шөгыльләнә. Диңгездә, авыл турысында һәрвакыт төрле балыкчы көймәләре тора. Аларның барысын да бер исем белән монда халык «савыт» дип йөртә. Савытлар төрле-төрле була. Әгәр дә зур җилкәнле көймә булса, аны «шхуна» яки «скутир» диләр. Моторлы һәм җилкәнле зуррак көймәләрне «бот» дип атыйлар. Боттан кечерәк моторсыз җилкәнле көймәләр «йола» дип атала. Бер-ике кеше генә утырырлык көймә «пашка» дип атала. Балыкчылар балык тотарга күбрәк йола белән йөриләр. Көн матур булып, диңгездә дулкын булмаса, авылда бер генә балыкчы да калмый. Алар атау тирәсендә генә диңгездә йөреп балык тоталар.

Аз гына давыл чыга башлагач, балыкчылар авылга кайталар. Балыкны тоту белән генә аның эше бетми. Кырыйга чыкмыйча гына балыкның эчен чистартып суга ташлыйлар. Шул вакытта йола тирәсенә акчарлаклар җыелып очып йөри башлыйлар. Балыкларның башы да кисеп алына. Ләкин ул суга ташланмый. Балыкның башы, киптерелеп онга тартылгач, җир ашлау өчен яхшы нәрсә була. Шуңа

күрә аны киптереп, түкләргә бәйләп, Россиягә яки чит илләргә җибәрәләр. Балыкларның эче чистартылып, башы өзеп алынгач, аны кооператив шхунасына китереп салалар. Шхунаның командасы аны шунда ук тозлап куя. Балык сатылгач, балыкчылар, өйләренә кайтып, йокларга яталар. Җәтмәләре бозылган булса, аларны ямыйлар. Йолаларда йөреп балык тоту эше колхоз кешеләре яки аерым кешеләр кулында. Моңардан башка балыкны күп тота торган рыбтрестларның тралерлары бар. «Тралер» дип конус формасындагы җәтмәне корыч бау белән диңгез төбенә төшереп, өстерәп барып балык тота торган көймәгә әйтәләр.

Трал белән диңгез төбендәге балыкларны гына тоталар. Баренц диңгезендә треска, пикша, камбала балыклары тотыла. Россия бу эшкә күптән түгел генә керешкән. 1910 елдан 1915 елга кадәр Баренц диңгезендә бары 4 тралер булган. 1920 елда исә 12 тралер, 1927 елда аларның саны 17 гә җиткән. Хәзерге вакытта тралерларның саны тагын да күбрәк. Трал базасы Мурманск шәһәрендә урнашкан. Кильдинда күбрәк йолаларда йөреп балык тотучылар гына тора.

Беренче бөтендөнья сугышына кадәр Баренц диңгезендә Англия, Германия, Бельгия, Голландия тралерлары балык тотканнар. Аларның иң күп тоткан балыклары камбала булган. 1914 елгы сугыш алдыннан инглизләр Баренц диңгезеннән 13000 тонна камбала тотканнар. Камбала балыгы шуннан соң бу диңгездә бик нык кимегән.

Тралерларның йола белән балык тотуга караганда тагын бер уңайлы яклары бар. Балыкны тоту, эчен чистарту, башын өзү, тозлау – барысы да үзендә эшләнә. Траллы көймәләр күп кенә механизмнар белән җиһазландырылган. Шуның өчен анда эшләве җиңел, балык та күп эләгә.

Кильдин атавындагы халык балык тоту белән генә тормый. Монда Советлар Союзы өчен әһәмияте зур булган йод чыгару эше бар. Чит илдән йод алу өчен безнең әллә никадәр акчабыз китә. Ә тырышканда, шул ук йодны үзебездә дә табып була. Без көн саен диярлек йөрергә маяк янына бара торган идек. Аның янына барганда, «Кабер күле» исемле күл яныннан үтәргә туры килә. Беренче көнне үк шул күл тирәсендә эшчеләрнең, печән җәйгән шикелле, тырмавычлар белән нәрсәдер таратып йөргәннәрен күрдек. Бу кызык эш күренгәнгә, туктап карап тордык. Сораша торгач, аларның йодлы суүсемлекләрен таратып киптереп йөрүләре аңлашылды. Күлдән ерак түгел, диңгез кырыенда зур гына шомарып беткән ташлар ята. Давыл вакытында диңгез дулкыннары кырыйга күп кенә суүсемлекләрен чыгарып ташлый икән. Шул үсемлекләрне барып карап йөрдек. Монда төрле-төрле үсемлекләр бар. Коңгырт төстәге фукус исемле үсемлекләрнең урман чикләвеге зурлыгында һава капчыклары була. Диңгездән алты сәгать су керә (прилив), алты сәгать су кире диңгезгә чыга (отлив). Су кергән вакытта фукуслар үсә торган ташлар да су астында кала. Шул вакыт һава капчыклары үсемлекләрне күтәреп тора. Су чыга башлагач, үсемлекләр әкренләп егыла барып, су чыгып беткәч, ташлар өстендә ятып кала. Менә шул фукуслардан йод табыла. Коңгырт үсемлекләрдән башка шул ук ташларда тагын яшел суүсемлекләре белән багрянка исемле суүсемлекләре дә үсә. Су чыккач ачык калган урында үскән суүсемлекләренә «литораль үсемлекләре» диләр. Ул диңгез өстеннән алып 4,1 метр тирәнлеккә кадәр төшеп үсә. Йод ясала торган үсемлекләрдә литораль аз була. Йод күбрәк диңгезнең сублитораль исемле икенче катлавында. Сублитораль катлавы 4,1 метрдан башлап 55–65 метрларга кадәр бара. Давыл вакытларында сублитораль катлавында үсә торган ламинария суүсемлеге кырыйга ыргытыла. Шул үсемлекләрне эшчеләр җыеп алып киптерергә тараталар. Кибеп өлгергәч, яндыралар, көле заводка йод эшләү өчен җибәрелә. Эшчеләрнең суүсемлекләрен таратып киптереп йөргәннәрен озак кына карап торгач, йод эшенең мөдире Зиминга киттек. Ул безне бик яхшы каршы алды. Хәзерге вакытта эш ничек барганын сөйләп бирде. Йод табу эше монда быел гына оештырылган икән. Хәзер 16 эшче эшли. Юештә эшләрлек яхшы кием бирелә. Кильдин атавы йод ясарга яраклы ламинария суүсемлегенең күплеге ягыннан СССРда беренче урында тора икән. Көзгә таба атауда йод заводы салынырга тиеш. Кипкәч, ламинариядән 20 % коры үсемлек, коры үсемлектән 5 % ка якын йод чыга.

Зимин эшнең авырлыгы турында зарланып алды:

– Кайвакытта киптерергә дип ламинарияне җиргә таратып куясың, яңгыр явып китә яки томан була. Аны тагын киптерергә кирәк була. Үсемлекләрне коры җиргә салмыйча, берәр җәймәгә салып, яңгыр вакытларында лапас астына кертеп торсаң яхшы булыр иде. Әгәр дә чи көенчә яндыра торган булса, тагын да яхшырак булыр иде. Ул вакытта лапаслар да ясап торырга кирәк булмас. Ленинградтан бер шундый мич җибәрделәр. Монда без аның белән эшләп карадык, мич эшкә ярамады. Мин үзем дә бер мич уйлап чыгардым. Аны язып җибәрдем әле, ни диярләр.

Зимин – 45 яшьләрдәге кеше, сөйләгән сүзләренә караганда, акыллы кеше булырга охшый. Үзе тотынган йод табу эшен ничек булса да яхшырак куярга тырыша.

Без аңардан:

– Нигә соң тизрәк үзегезнең уйлаган лапасларыгызны ясамыйсыз? Нигә тизрәк завод салмыйсыз? СССРга йод бик кирәк бит, – дип сорадык.

Зиминның үзенең дә бу эшләрне тизрәк эшләтәсе килә, ләкин аның сәбәпләре бар икән.

– Хәл кылынмаган бер нәрсә бар әле. Монда ак төлке кыйммәт тора. Аның тиресен чит илдә 400 тәңкәләргә кадәр алалар. Шуның өчен Кильдинда ак төлке үрчетеп, аның тиресен чит илгә сатарга

алып китәчәкләр (аннан алынган акчага чит илдән машиналар алачаклар, билгеле). Менә шул ак төлке яшәгәндә, бу атауда башка бернәрсә дә яшәмәскә тиеш, диләр госторг кешеләре. Ак төлке сарыкларны үтергәләде, өйләргә кереп, төрле әйберләрне алып чыгып китә иде. Халык, шуңа ачуланып, аны куып йөри башлады. Кешеләр ак төлкегә төрле нәрсәләр ашаталар. Шуңа күрә госторг, Кильдин атавындагы бөтен кешене башка җиргә күчереп, Кильдинда ак төлкеләр белән аларны караучы берничә кеше генә калдырырга уйлый. Ә минемчә, киресенчә эшләргә кирәк. Ак төлке белән аларны караучылар үзләре башка берәр атауга күчәргә тиешләр. Менә моннан ерак түгел генә кечкенә Болан атавы бар. Аларны шунда күчерергә мөмкин. Ул вакытта атауда балыкчылар да, йод заводы да кала ала. Ул вакытта монда сыер, сарык асрарга да мөмкин булачак. Кильдин атавында тагын шифер, сланец, торф табу эшләрен дә оештырырга мөмкин булачак.

Ул бераз уйланып торды һәм өстәп куйды:

– Минемчә, шулай. Белмим, үзәктә ничек хәл кылырлары, – дип сүзен бетерде.

Без дә, аның сүзләренә кушылып, чыгып киттек.

Ак төлке атауга төшкәч үк безнең күзебезгә чалынган иде. Авыл урамында бер мәче тын гына ята иде. Аның янына коңгырт төстә, төлкедән аз гына кечерәк, мәче шикелле шома басып йөри торган бер җәнлек – ак төлке килде дә өстенә сикермәкче булды. Мәче сикереп торды да үзе ак төлкегә карады. Ак төлке мәченең койрыгыннан эләктереп алырга никадәр тырышса да булдыра алмады. Ул мәченең койрык ягыннан килә генә башлый, мәче алды белән әйләнә. Шулай озак кына маташкач, еракта нечкә генә улаган тавыш ишетелде. Әлеге ак төлкене иптәше чакыра икән. Мәче шуннан соң гына котыла алды.

Ак төлкеләр авылга күбрәк кич белән киләләр икән. Аларга теләсә нәрсә ашатырга ярамый, без печенье белән шикәр ашатып карадык. Печеньене беренче ыргытканда бераз кимерде дә ташлап китте. Шуннан соң бер шакмак шикәр ыргыттык. Ул арада икенче ак төлке килеп, беренчесеннән шикәрне талап алды...

Икенче бервакыт мин урамда китап укып ята идем. Китапка бирелеп, яныма ак төлке килгәнне сизми дә калганмын. Ак төлке тын гына килде дә минем китапны алып китә башлады. Мин сикереп тордым. Ул алай да китмәде. Минем китабым белән маташа бирде. Китапка аягымны каты итеп китереп баскач кына бераз читкә китте. Читтә дә, күп кенә вакыт китмичә, минем арткы яктан килергә маташты. Бары икенче якта иптәшен күргәч кенә шул якка чапты...

Тавык асрарга мөмкин булмаганга, аны асрамыйлар икән. Ә эт асрарга бөтенләй кушылмаган. Төнлә ак төлкеләр үзләренең нечкә итеп улаулары, яшь этләр шикелле өрүләре белән һаваны яңгыраталар.

Ак төлкене асрау эше белән кызыксынып, госторгка бардык. Алар ак төлке асрауга зур әһәмият бирәләр. Практикага килгән студент Васильев үз эшләре турында сөйләде:

– Кильдин атавы ак төлкеләр үрчетергә бик уңай. Тирә-якта су кыш көне дә катмаганга, аларның качып китүләреннән куркыныч юк. Монда аларга ояларга да урыннар күп. Аларга ашарга кошлар да, балыклар да күп. Шуңар күрә госторг монда ак төлке питомнигы ясарга булды. Командор атауларыннан 100 пар зәңгәр песец китереп, монда җибәрдек. Урамда йөри торган ак төлкеләр җәй көне генә коңгырт төстә булалар. Кыш көне алар ак төскә керәләр. Менә шул вакытта аларның тиресе кыйммәт йөри. Командор атауларыннан китерелгән 200 ак төлке 40000 сум тора. Алар, монда килгәч, быел 150 % ка арттылар. Хәзер безгә, чыгымнарын исәплләгәндә, һәр ак төлке 349 сумга төшә. 1938 елда аларның саны 2544 башка җитәчәк. Ул вакытта бер песец үзебезгә 42 сумга гына төшәчәк. Соңгы елларда бер генә ак төлкене дә үтермәскә уйланыла. Чөнки башка җирләрдә дә оештырыла торган питомникларга тере ак төлкеләр кирәк булачак. Күршедәге кечкенә Болан атавына да ак төлкеләр җибәрергә уйланыла. Чөнки Кильдин атавы 1500 баштан артык ак төлкене сыйдыра алмас кебек. Ак төлкеләрдән башка, Кильдинга кара-коңгырт көмеш сыман төлкеләр дә җибәрү уе бар.

*1932–1934*

*Әгъзам Камал (Әгъзам Камалетдин улы Камалетдинов) 1918 елның 21 гыйнварында Татарстан Республикасының Апас районы Үтәмеш авылында крәстиян гаиләсендә туа. 1931–1934 елларда үз авылларындагы җидееллык мәктәптә (ТБУМ) укый, аны тәмамлагач, Казанга килеп, финанс-экономика техникумында белем ала. 1937 елда техникумны тәмамлап, берникадәр вакыт Татарстанның Тәкәнеш районында үз белгечлеге буенча эшләгәннән соң, ул яңадан Казанга кайта һәм 1938–1939 елларда «Чаян» журналы һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1939 елның көзендә армия сафларына чакырылып хәрби курсларны тәмамлагач, сугыш башланганга кадәр анда кече командир булып хезмәт итә.*

*Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Әгъзам Камал алгы сызыкта сугыша. Канлы бәрелешләрнең берсендә яраланып, шактый вакыт госпитальдә дәвалана, аннары Саратов шәһәрендәге хәрби училищега укырга җибәрелә. Училищены офицер дәрәҗәсе алып тәмамлаганнан соң, Әгъзам Камал кабат үз гаскәри берәмлегенә – Сталинград фронтына кайта һәм, андагы*

*хәлиткеч сугыш операцияләрендә күп мәртәбәләр катнашып, 1943 елның 16 маенда дошман пулясыннан һәлак була.*

*Ә.Камал мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый. Казанга килгәч, аның шигырьләре республика көндәлек матбугатында, альманахларда, күмәк җыентыкларда еш басыла. 1938 елда яшь шагыйрьнең «Җилфердә, байрак!», ә 1939 елда «Һәйкәл янында җыр» дигән шигырь җыентыклары дөнья күрә.*

*Ә.Камалның кырыс сугыш шартларында язган шигырьләре фронт газеталарында, «Кызыл Татарстан»да һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында да басыла.*

*Фронтовик шагыйрьнең аерым иҗат үрнәкләре һәм үзе турында мәгълүматлар «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) исемле җыентыкларда урын ала.*

## ИЮЛЬ КИЧЕНДӘ

*Кеше – ул горур яңгырый.*
*М.Горький*

Мин беренче тапкыр түгел инде
Басып торам сирень төбендә.
Әй табигать, яшел яфракларың
Җырым кебек якын күңелгә.

Шаулагыз сез, усак яфраклары,
Шаулагыз сез, бөдрә каеннар,
Сезнең кебек мин дә бәхетлемен,
Тик йөрәктә кайгы эзе бар:

Бу кабердә йоклый комсомолец –
Утлы давылларны кичүче,
Яшь гомерен халык бәхте өчен,
Ирек таңы өчен бирүче.

Теләкләре аның бөреләнеп
Чәчәк атты безнең елларда;
Чайковский язган көй шикелле,
Исме яңгырый безнең җырларда.

Һәр яз саен кабер өстендә
Матур кызыл гөлләр үсәләр,
Ә аларны сөеп, тирбәлдереп,
Йомшак җылы җилләр исәләр.

Нурларына айның төренеп,
Мин шушында киләм кичләрен,
Мин йотылып карыйм үзәннәргә,
Дулкынлана минем хисләрем.

Сандугачкай сайрый очынып,
Ә мин җырлыйм аңа кушылып:
«Без бергә үстек,
Без бергә кичтек
Ядрәләр яуган
Дәһшәт кырларын;
Без яулап алдык

Бәхетле гомер,
Себердек илдән
Дошман яуларын.

Син күрә алмадың
Безнең көннәрне,
Бу кабер сине
Вакытсыз алды,
Гасырлар буе
Балкып янарга
Күкрәгеңдәге
Йолдызың калды».

Мин уйларга чумып йөрим монда
Хыялга бай июль кичендә,
Һәм мин үткән көннәр истәлеген
Күз алдыннан бер кат кичерәм.

Ә шул хисләр белән бөреләнеп
Чәчәк ата минем җырым да,
Орден таккан яшьлек сафларында,
Байракларның алсу нурында.

Яңгыра, җыр, таулар киңлегендә,
Яңгыра, җыр, безне чакырып,
Дошман өсләренә дәһшәтле көч –
Утлы яшен булып яктырып!

*1938*

## БРОНЕПОЕЗД

*«Кызыл Татарстан»*
*бронепоездына*

Кайчагында шундый вакыт була,
Үлем каршысында ятасың,
Тамырларга бетмәс дәртләр тула,
Килеп чыкса шунда якташың.

Бара иде сугыш тимер юлда,
Җирне казып фашист урнашкан.
Пулеметлар юлны буды сулда,
Автоматлар буды уң яктан.

– Менә-менә алка ябылыр да
Без калырбыз дошман кулында.
Санга артык дошман ябырылыр да
Һәлак булыр күпләр шушында, –

Дип торганда, бронепоезд килде,
Алга куеп көчле күкрәген,
Йөрәкләргә шатлык тулган иде,
Тыңлаганда аның күкрәвен.

Блиндажлар ишелделәр кинәт,
Күккә очты башлар, ак ташлар,
Әйтеп куйды яшь сугышчы Зиннәт:
– Рәхмәт сезгә, рәхмәт, якташлар!

Бронепоезд һәр көн безнең сафта,

Ишеткәнсең инде хәбәрне.
Ул катнашты азат иткән чакта
«Н» дип исемләнгән шәһәрне.

Без беләбез: аның һәр винтында
Халык көче, халык сумнары.
Без фронтта, ә сез тирән тылда,
Һәм байраклар безнең югары!

Бәлки, җырым сезгә барып җитәр,
Ул сөйләсен сезгә, мактасын.
Һәрвакытта безгә ярдәм итәр
Бронепоезд – минем якташым!

*1942*

**КҮПЕР**

Ул күрде дә ике текә ярны
Тоташтырып торган күперне:
«Үз эшеңнән кыйммәт нәрсә бармы?» –
Дип уйлады... аннан төкерде.
Кул селтәде...
«Партизаннар, аңлыйм,
Тотыналар авыр бу эшкә...
Тик дошманга кичү итә алмыйм,
Совет күперен...
Алга, җиңешкә!»
Күпер буйлап көчле кукрәү үтте,
Куркып очты күлдән үрдәкләр.
Чыш-пыш килеп суга авып төште
Кинәт кызган тимер өрлекләр.
Поезд оча игътибарсыз дулап,
Бәреләә пар,
Килә мең аваз.
Ләкин юкка...
Туктый алмый, улап
Су төбенә китте паровоз,
Һәм вагоннар изелделәр чатнап,
Кайдандыр ут ачты пулемет.
Тимер юлдан тантаналы атлап,
Зур һәлакәт үтте бу минут.
Су айкалды.
Язгы бозлар сыман
Калкып чыкты астан үлекләр.
Гөмбә кебек йөзеп йөрде озак
Үрмәкүчле тимер бүрекләр.
– Украина, – дип, бер партизан әйтте, –
Дошман өчен, ай-яй, яман җир!
«Тәртип белән» безнең кулдан үтте
Дүрт эшелон, иптәш командир!

*1943*

*Совет чоры татар поэзиясенең күренекле вәкиле Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов) 1909 елның 9 гыйнварында Россиянең элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан Республикасының Бишбүләк районы) Ает авылында мулла гаиләсендә туа. Мәктәпкә кергәнче үк укырга-язарга өйрәнә, аннан авыл мәктәбенең ике сыйныфын тәмамлый. 1922 елда абыйсы Габдулла Кәримов (шагыйрь Ярлы Кәрим, 1901–1937) аны үзе белән Бәләбәй шәһәренә алып китә һәм педагогия техникумының әзерлек сыйныфына укырга урнаштыра. Монда ике ел укып әзерлек курсын тәмамлагач (1924), шул ук абыйсы ярдәмендә Казанга килеп, бер ел яшүсмер балалар йортында тәрбияләнә. 1925–*

*1929 елларда Казан җир төзелеше техникумында укый. Әдәби иҗат эше белән җитди шөгыльләнә башлавы да шушы студентлык елларына карый. 1926 елдан республика газеталарында яшь каләм тибрәтүченең көндәлек яшьләр тормышына багышланган мәкаләләре, фельетоннары, соңга таба балалар өчен хикәяләре һәм шигырьләре күренә башлый. 1928 елдан Казанда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») дигән махсус газета чыгарыла башлагач, унтугыз яшьлек студент-әдипне газетаның редколлегиясе составына кертәләр һәм идарәнең җаваплы сәркәтибе итеп билгелиләр. Техникумдагы укуын дәвам иткән хәлдә, Ф.Кәрим бу газетада бер ел эшли, аннары, 1929 елда техникумны тәмамлагач, «Крәстиян гәзите» идарәсенә әдәби хезмәткәр булып күчә. 1930–1931 елларда ул «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Атака» (татар пролетар язучылары оешмасының басмасы) журналларында җаваплы сәркәтип хезмәтендә була. 1931 елның көзендә армиягә алынып, 1933 елның гыйнварына кадәр Идел буе хәрби округының Казанда татар телендә чыга торган «Кызылармияче» дигән газетада хәбәрче-корреспондент булып хезмәт итә.*

*Армия хезмәтеннән кайткач, Ф.Кәримне Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегенә җитәкче итеп билгелиләр. Монда ул 1937 елның маена кадәр эшли. Бу – Ф.Кәримнең иҗат һәм җәмәгать эшендә кайнап, әдип буларак үсү һәм формалашу еллары. 1929 елдан хәвефле 1937 елга кадәрге чагыштырмача кыска вакыт эчендә аның ун китабы басылып чыга (икесе – проза, сигезе – шигъри җыентыклар). Иҗатта туктаусыз эзләнү, уку һәм тормышны өйрәнү аңа, беренче әсәрләрендә әле нык сизелгән декларативлыктан арынып, уй-хисләрен шигырьдә торган саен үтемлерәк, табигыйрәк яңгырашта, камилрәк формада чагылдыру юнәлешендә осталыгын үстерергә юл ача. 30нчы еллардагы күмәк хезмәт, яшьлек һәм мәхәббәт романтикасын ихлас садәлек, эмоциональ күтәренкелек белән гәүдәләндергән лирик шигырьләре, «Яшен яктысы» (1932), «Җиденче мич» (1932), «Тавышлы таң» (1933), «Илле егет» (1934), «Аучылар» (1934), «Аникин» (1936) кебек поэмалары белән ул үзен татар поэзиясенең үзенчәлекле шигъри моң-авазга ия булган талантлы бер вәкиле итеп таныта.*

*Иҗат дәрте белән шулай илһамланып, совет хакимияте төзегән тормыш тәртипләренә, яңа җәмгыятьнең гаделлегенә ихластан ышанган һәм үзенең шагыйрьлек талантын, бөтен иҗади көчен бөтенләе белән шул «гадел» җәмгыять хакына сарыф итәргә әзер булып яшәгән егерме тугыз яшьлек шагыйрьне 1938 елның 3 гыйнварында кинәт кулга алалар. Тентү вакытында барлык язулы дәфтәрләрен, кульязмаларын җыеп төяп алып китәләр. Аларның күп өлеше соңыннан НКВД подвалларында юкка чыга. Әдип өстенә бернинди дәлилсез-нисез, фәкать НКВД кабинетларында махсус уйлап чыгарылган «фактлар» нигезендә «милләтче», «пантөрекче», «буржуазия ялчысы», «Советка каршы коткы таратучы», әдәби әсәрләрендә «кулаклар идеологиясен үткәрүче халык дошманы» шикелле коточкыч нахак гаепләр ташлана. Шул «гаепләре» өчен тоталитар режимның урындагы мәхкәмәсе 1939 елның 14 мартындагы ябык утырышында Ф.Кәримне ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм, шуңа өстәп, тагын биш елга гражданлык хокукларыннан чикләргә дигән хөкем карарын игълан итә. Бу карар белән килешмичә, әдип, берничә тапкыр кассацион гаризалар язып, үзенең гаепсез икәнлеген исбатлап карый, ләкин аның гаризаларына игътибар итүче булмый. Нәтиҗәдә шагыйрьне озак та үтми этап белән төньякка – сәяси тоткыннар лагерена (совет концлагерена) озаталар. Бары тик шундый ук «гаепләр» белән төрмәләрдә утырып, соңыннан акланып чыккан язучы Кави Нәҗми һәм генерал Якуб Чанышевларның Ф.Кәримне гаепсез итеп күрсәткән гаризалары бер-бер артлы барып ирешкәч кенә, СССР Югары мәхкәмәсе Ф.Кәримнең «җинаять эше»н яңадан тикшерүгә куярга мәҗбүр була. Бу тикшерү барышында шагыйрьне төньяктагы ерак лагерьдан Казан төрмәсенә кире кайтаралар. Ниһаять, 1941 елның 1 декабрендә, инде Алмания белән канлы сугышлар барган көннәрдә, Ф.Кәримне иреккә чыгаралар. Ләкин бер шарт белән: ул «үз теләге белән» фронтка китәргә тиеш була. Чыннан да, бер үк вакытта сәер дә, кешелексез дә булган бу шартны үтәп, шул ук декабрь аеның утызында Ф.Кәрим фронтка чыгып китә.*

*1942 елның февраленнән 1945 елның февраленә кадәр, ягъни өч ел буена, Фатих Кәрим фронтның алгы сызыгында була, солдат һәм кече офицер, взвод командиры сыйфатында Мәскәү янынннан алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сугышчан юл уза, Украинаны, Белоруссияне, Карпат илләрен азат итүдә катнаша, ике тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Ә сугыш бетәргә санаулы көннәр калганда, 1945 елның 19 февралендә, Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә утыз алты яшьлек шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була. Күмелгән урыны шундагы туганнар каберлегендә.*

*1941–1945 еллар арасында ул тугыз поэма, ике повесть, бер драма әсәре һәм йөздән артык исемдә шигырь иҗат итә. Сан ягыннан гына түгел, сыйфат һәм идея-эчтәлек ягыннан да шагыйрьнең бу чор әсәрләре иҗатта яңа биеклеккә күтәрелү, камиллеккә ирешү мисалы булып торалар. Аның поэзиясендә сугыш чынбарлыгының катлаулы фәлсәфәсе, фашизмга каршы җанын кызганмый көрәшкә күтәрелгән гади солдатның сугыш кырындагы батырлыгы, эчке кичерешләре, ватандарлык хисләре, сөйгәненә, гаиләсенә, апа-сеңелләренә, абый-энеләренә, әти-әнисенә, туган җиренә, туган халкына булган олы мәхәббәте, тыныч тормышка сусау-җирсү сагышлары гаҗәеп тәэсирле,*

*эмоциональ тирәнлек белән сурәтләнәләр. Ф.Кәримнең төрмә камераларында күңел дәфтәренә теркәп саклап калдырган, сугыш тынган араларда солдат землянкалары, окоп ышыкларында иҗат иткән лирик шигырьләре, «Гөлсем» (1942), «Идел егете» (1942), «Кыңгыраулы яшел гармун» (1942), «Үлем уены» (1942), «Партизан хатыны» (1943), «Өмет йолдызы» (1944) поэмалары, «Тимер һәм тимерче» кебек балладалары (1942), Муса Җәлилнең Моабит циклы шигырьләре белән бергә сугыш чоры татар поэзиясенең иң югары ноктасын тәшкил итәләр.*

*Фронтта Ф.Кәрим үзенең әдәби мирасын чәчмә әсәрләр белән дә баета: «Шакир Шигаев» исемле драма (1943), «Разведчик язмалары» (1942) һәм «Язгы төндә» (1943) исемле ике повестен иҗат итә. Бу әсәрләр дә, поэзиясе кебек үк, сугыш афәтенә, фашизмга, тираниягә каршы юнәлтелгән нәфрәт хисләре белән сугарылган.*

*Ф.Кәрим – 1934 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## АНТ

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә – балам. Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...

Бәлки, соңгы тапкыр күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.

Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!» – ди ул күңеленнән,
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.

Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм.

*1942*

## ВАТАНЫМ ӨЧЕН

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында,
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен

Сугыш кырларында үлүе.

*1942*

## БЕЗДӘ ЯЗДЫР

Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы, төннәр айлыдыр,
Идел буендагы бакчаларда
Сыерчыклар ярсып сайрыйдыр.

Кошлар моңы уятадыр сине,
Челтәр-пәрдәләрне күтәреп,
Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз
Чәчәк аткан гөлләр үтәли.

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман-кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изрәп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

Фашист тырнагына капкан кеше
Сыкрамыйча монда тын алмый,
Янган авылларның төтеннәре
Язгы таңның нурын томалый.

Фашист илгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.
Яшен уты белән күккә язып әйтәм:
Язы юкның яшәү хакы юк!

*1942*

## КЫР КАЗЫ

Тирән окопта каршылыйм
Икенче язны;
Язгы таңда безнең якка
Кайта кыр казы;

Кайта диңгез артындагы
Ерак илләрдән,
Һәм яши ул төнбоеклы
Тонык күлләрдә.

Әй, кыр казы, түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,
Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Каләм ясап каурыеңнан,
Язгы ялкында

Ут эченнән языйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Дәһшәтле сугыш кырында
Сөйгән халкымның
Мин кояшым итеп йөртәм
Йөрәк ялкынын.

Халкыма бәхет, дан даулап
Үтә көннәрем;
Анабыз-җирне кочаклап,
Бәлки, үләрмен.

Үлсәм, җырларымда калыр
Сөю, сагышлар;
Кыр казы йөзгән күлләрдә
Шаулар камышлар.

*1944*

## РАЗВЕДЧИК ЯЗМАЛАРЫ

*(Повестьтан өзек)*

Көзге кояшның салмак алтын нурлары таңгы офык артыннан югарыга сибелгән вакытта, без урман эчендәге аланда яңа гына казылган кабер янында тора идек. Ак тактадан ясалган гробта баштанаяк хәрби кием кигән Акморат ята. Яралы башы ак марля белән бәйләнгән. Гроб янына Акморатның разведка кораллары куелган: бер ягында автомат, икенче ягында күп фашистларның йөрәгенә кадалган үткер хәнҗәр...

Йомшак кар өстеннән акрын гына кыштырдап подполковникның автомашинасы килеп туктады. Подполковник машинадан төшеп кабер янына килде. Аннары без аның кабер өстенә басып сөйләгән ялкынлы сүзләрен тыңладык. Алар Акморат һәм, Акморат кебек, Ватан өчен сугыш кырында батырларча корбан булган йөрәкле егетләр турында иде.

Без, Акморатның якын иптәшләре, батыр егетнең гробын кабергә төшерергә әзерләндек. Шул вакыт түбәннән генә, нәкъ безнең баш турыбыздан, канатлары кызыл йолдызлар белән бизәлгән тиз йөрешле өч бомбардировщик очып үтте. Алар элекке төнне дошман тылында без Акморат белән икәү актарып йөргән урманга таба юл тоттылар.

Без Акморатны кабергә төшердек. Төшерүебез булды, еракта, дошман тылында, каты гөрселдәгән тавышлар ишетелде. Бөтенебез дә борылып шул якка күз салдык. Акморат белән икәү планын төшергән урман эченнән, ургылып-ургылып, ялкын катнаш кара төтен күтәрелә, урманның көле күккә оча иде. Минем йөрәк әллә ни эшләп җилкенеп китте. Тын гына борылып, мин кабердә яткан Акморатка күз төшердем. Түзмәдем, тирән дулкынлану белән Акморатка – сугыш кырындагы иң якын дустыма соңгы аерылышу сүзләремне әйттем:

– Тыныч йокла, иптәш! Үлсәк тә, бушка үлмибез без. Каһәрле дошманның көлен күккә очырып үләбез. Күрәсеңме, без синең белән эзебезне калдырып үткән дошман тылындагы урманда дошман, аның көче, корал белән тутырылган складлары бер-бер артлы шартлыйлар. Алар кара төтен булып күккә күтәреләләр. Җил аны ерактагы таулар артына илтеп тарата, юк итә.

Ә без калабыз! Ата-аналар, туганнар, иптәшләр, якын дуслар кала!

Сөйгән халык кала. Туган ил кала!

Туган илнең күкрәп торган урманнары, шаулап аккан елгалары, яңгырап торган таулары, киң тугайлары кала. Без төзегән яшәп туймаслык матур тормыш кала!

*1942,*
*Көнбатыш фронт*

*Язучы Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев) 1903 елның 28 ноябрендә элекке Саратов губернасының Кузнецк өязе (хәзер Пенза өлкәсенә керә) Татар Кынадысы авылында мул тормышлы крәстиян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала. 1912 елда әтисе Нурмөхәммәт абзый, игенчелек хезмәтен ташлап, гаиләсе белән Самара губернасындагы Алексеевка*

*дигән авылга күчә һәм бертуган Кутуевларның күн заводында эшли башлый. Гаделша шунда рус мәктәбендә белем алуын дәвам иттерә. 1917 елда бертуган Кутуевлар дүрт гаилә бергә Самара шәһәренә күчеп киләләр. Булачак язучының белем алуы һәм әдәби сәләтенең ачылып китүе өчен монда шартлар тагын да уңайлана төшә. Мәктәптә уку белән бергә ул шәһәрдәге мәдәни клубларның берсендә рус язучысы Александр Неверов оештырган әдәби түгәрәккә йөри, рус телендә өйрәнчек беренче шигырьләрен яза, ныклап торып шул чордагы яңа рус поэзиясе, аерым алганда, В.Маяковский иҗаты белән якыннан таныша.*

*1920 елда унҗиде яшьлек Г.Кутуй белем алуын дәвам иттерү һәм бигрәк тә татар әдәбиятына якынрак булу өчен Казанга килә һәм политехника институтының химия факультетына укырга керә. Ләкин ике курсны тәмамлагач, төгәл фәннәргә күңеле ятмыйча, институтта укуын ташлый да Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбендә әдәбият укытучысы булып эшли башлый. Шушы чорда аның әдәби иҗат эшчәнлеге дә активлашып китә. 1923 елгы «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының дүртенче-бишенче саннарында «Яшь футурист шагыйрь» дигән баш белән Г.Кутуйның бер бәйләм шигырьләре басылып чыга. 1924 елда исә «Көннәр йөгергәндә» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Нигездә, рус футурист шагыйрьләренә һәм В.Маяковский шигырьләренең тышкы формасына ияреп язылган, аерым уңышлы чагыштырулары, образлы тәгъбирләре булса да, тулаем аңлаешсыз һәм сәер яңгыраган бу шигырьләр ул заманның әдәби тәнкыйтендә зур шау-шу кузгаталар, татар шигъриятенең үткәндәге уңай традицияләрен инкяр итү сыйфатында каты тәнкыйтькә очрыйлар. Тора-бара иҗатындагы бу мавыгуларны Г.Кутуй үзе дә таный һәм, алардан әкренләп арына барып, 20нче елларның икенче яртысында иҗат иткән шигъри әсәрләрендә үзенең уй-хисләрен реалистик сурәтләү чаралары ярдәмендә бирергә омтыла башлый.*

*1925 елда Г.Кутуй Казан шәрекъ педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1929 елда институтны тәмамлап чыккач, 30нчы еллар дәвамында Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтында гыйльми сәркәтип, мәктәпләрдә һәм Казан авиация техникумында әдәбият укытучысы булып эшли.*

*Әдипнең 20нче еллардагы әдәби иҗаты жанр төрлелеге белән аерылып тора. Ул шигырьләр, хикәяләр, пьесалар яза, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»), «Красная Татария» (хәзерге «Республика Татарстан») газеталарында, «Безнең юл», «Яңалиф», «Авыл яшьләре», «Чаян» журналларында күпсанлы фельетоннар, очерклар, мәкаләләр бастыра, Татар академия театрының һәр яңа спектакленә диярлек рецензияләр язып бара. Үз чорының төрле иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләренә багышланган «Балдызкай» (1926), «Директор Җәмилев» (1926), «Күк күгәрчен» (1929), «Җавап» (1929), Мулланур Вахитовның тарихи шәхесен сәхнәдә гәүдәләндерүне максат итеп куйган «Казан» (1927) исемле пьесалары Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала. Кызганыч ки, бу биш пьесадан өчесенең («Директор Җәмилев», «Җавап», «Казан») текстлары сакланып калмаган. Әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә, публицистикасында әдип совет хакимияте тудырган яңа дәүләтчелек шартларында әдәбият-сәнгатьнең торышы, иҗтимагый роле, үсеше мәсьәләләренә караган, кайбер очракларда ул заман өчен шактый субъектив яңгыраган фикерләрен дә әйтеп чыга. Дөрес, әдипнең шигырьдә формаль сурәтләү чаралары белән мавыгулары, башлыча шәһәр зыялылары – укытучылар, студентлар, музыка, сәнгать кешеләре тормышыннан алып, нигездә, әхлакый темаларны яктырткан пьесалары, хикәяләре, публицистикасында алга сөргән фикер-карашлары үз чиратында рәсми идеологиягә буйсындырылган матбугатта еш кына каты тәнкыйть утына да очрый. Алай гына да түгел, тарихта «Җидегән» исеме белән мәгълүм нindидер, соңыннан ачыкланганча, дөньяда бөтенләй булмаган яшерен милли-сәяси оешмада әгъза булып торуда гаепләнеп, 30нчы еллар башында Гадел Кутуй һәм тагын биш «җидегәнче» (Н.Исәнбәт, Г.Минский, С.Кудаш, Т.Ченәкәй, С.Агиш) җавапка да тартылалар. Гадел Кутуй, каләм хезмәте белән яшәү мөмкинлегеннән мәхрүм калып, шактый еллар укытучылык эше белән шөгыльләнергә мәҗбүр була. Бары тик 1935 елда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының тугыз-уникенче саннарында атаклы «Тапшырылмаган хатлар» повесте басылып чыккач кына, әдипнең абруйлы исеме яңадан матбугат ирөгө ала.*

*Г.Кутуйның сугыш алды прозасында тормышны бизәбрәк күрсәтү, аның матур якларына гына игътибарны юнәлтеп иҗат итү тенденциясе ачык сизелә. Мәсәлән, «Солтанның бер көне» исемле озын хикәясендә (1938) ул гаилә корырга йөрүче укытучының көндәлек эшләре, мәхәббәт кичерешләре, сөйгән кызы белән бергә күңел ачу вакыйгалары аша тормышның гүзәллегенә дан җырлый. Әдипнең «Вөҗдан газабы» (1939), «Нишләргә?» (1940), «Илһам» (1941) исемле хикәяләре, «Шатлык җыры» пьесасы (1935) һәм «Талантлар ватаны» исемле поэмасы да (1937) шул ук рухта язылганнар.*

*Ватан сугышы башлану белән, Г.Кутуй үзенең язучылык каләмен җиңү өчен көрәш коралына әверелдерә: патриотик шигырьләрен («Озату җыры», «Партизанка», «Батыр каберендә», «Яңа ел бүләге» һ.б.), «Рәссам» (1941), «Хәнҗәр» (1941) кебек хикәяләрен, «Патриот Тукай», «Партизаннар», «Җиңү хәбәрчесе» кебек зур күләмле мәкаләләрен язып бастыра. 1942 елның июнендә ул үзе дә фронтка китә, әүвәл Сталинградны саклаучы Дон фронтының авыр гвардия миномет бригадасы*

*сәяси бүлегендә хезмәт итә, Идел буендагы мәшһүр Сталинград сугышында катнашкан өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә (соңрак фронтта күрсәткән батырлыклары өчен ул Кызыл Йолдыз орденына да лаек була).*

*Сталинградтан соң Г.Кутуй үзе хезмәт иткән гвардия бригадасы составында Волхов, Курск, Брянск, Великие Луки һәм башка бик күп шәһәрләрне азат итү сугышларында катнаша. 1944 елның көзендә Беренче Белоруссия фронтындагы татар телендә чыга торган «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә күчерелә. Авыр һәм мәшәкатьле солдат хезмәтен башкару белән бергә ул иҗат эшен дә дәвам иттерә: фронт газеталарында хәбәрләр, мәкаләләр бастыра, әдәби монтажлар төзи, 1944 елда Казанга вакытлыча иҗади ялга кайткач, балалар өчен «Рөстәм маҗаралары» исемле хыялый романын яза. Шул ук чорда аның «Без – сталинградчылар» (1944) һәм «Сагыну» (1945) исемле солдат хисләрен сәнгатьчә югарылыкта сурәтләгән атаклы нәсерләре иҗат ителә.*

*Сугыш бетәр алдыннан, 1945 елның язында, Г.Кутуй, сәламәтлеге начараеп, хәрби госпитальгә эләгә һәм 1945 елның 15 июнендә Польшадагы Згеж шәһәрендә вафат була. Кабере Згеж шәһәре зиратында.*

*Г.Кутуй – 1939 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.*

## БАТЫР КАБЕРЕНДӘ

Ялгыз кабер тора тау башында,
Яшь бер батыр анда күмелгән.
Таңда искән кыр җилләре аңа
Күп-күп итеп чәчәк китергән.

Баш очында аның шаулый нарат,
Ә наратта кошлар сайрыйлар.
Эссе көндә аны каплый болыт,
Ә суыкта нурлар карыйлар.

Бер яшь батыр ята тау башында,
Дусты килгән аны күрергә.
Ул ант итә аның баш очында
Дошманнарга җәза бирергә:

– Мин ант итәм үбеп туфрагыңны,
Мин ант итәм синең кабреңдә,
Һич кызганмам явыз дошманнарны,
Син яшәрсең минем хәтремдә!

*1941*

## ИРТӘНГЕ УЙЛАР

Алтын колач җәеп кояш калка,
Җылы нурлар җиргә тарала;
Кояш матурлыгын кочар булып,
Мин тез чүгеп карыйм аңарга.

Окоп янындагы күл төбендә
Мин күрәмен нурлар уйнавын;
Нурда, саф һавада коенам мин,
Җиңел булсын диеп юлларым.

Мин иснim дә сирень чәчәкләрен
Дошман якка карыйм һәм көләм;
Шушы сирень чәчәгендә чөнки
Җиңү музыкасын ишетәм.

Автоматым кысып, горур атлап,

Ап-ак төнле юллар үтәм мин,
Чөнки һәрбер тыныч адымымда
Җиңү музыкасы иштәм мин.

Юлларымда күрәм туп, танклар
Һәм күрәм мин халык яуларын.
Бронзадай гаскәр сафларында
Мин ишетәм хаклык яңравын.

Хыял күзем белән илгә карыйм,
Карап туймыйм – рәхәт күңелгә!
Рус шәһәрен ярсып яклаганда,
Күзләремә Казан күренә!..

*1942*

## ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР

*(Беренче хаттан өзек)*

Искәндәр!

Дусларча язылган җылы хатың өчен рәхмәт. Мин аны кат-кат укып чыктым. Бу сагыну хатыңны укыган чакта, минем күз алдымда аерылышкан көннәрдәге тар холыклы, бозык күңелле Искәндәр түгел, бәлки моннан сигез ел элек: «Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис», – дип килеп танышкан Искәндәр иде.

Нинди матур истәлек. Әйе, минем беренче мәхәббәтем дә, кешеләр белән аралаша башлаудан туган беренче шатлыгым да сиңа, синең белән танышу вакытына барып бәйләнә. Миндә яңа хисләр тудырган, күңел күзләремә матурлык буяулары биргән бу кадерле минутларны мин бик еш искә төшерәм. Тормышның тискәре, усал, шакшы яклары белән көрәшкәндә туңсам, арысам әгәр, шул рәхәт минутларны хәтерләп җылынам һәм көч җыям.

Исеңдәме беренче танышуыбыз?

Мин, матурлыкның нәрсә икәнен бары хыялда гына күреп, әкиятләрдән генә ишетеп килгән ятимә бер кыз, кинәт өнемдә чын матурлык диңгезенә чумып, шатлык дулкыннарында йөзә башладым. Чынлап та, корып, саргаеп беткән яз чәчәген иң тәмле хуш исләр чыгарып торган чәчәккә әйләндерү – охшашы булмаган матурлык бит. Үземне, гомумән кешеләрне чәчәккә тиңләштерү дөрес үк булмаса да, минем бу хәл ул чагында шуңа бик якын иде.

Мин элекке Кузнецк өязендә, караңгы мишәр авылында – Ялгашта туганмын. Минем атамның гомер-гомергә күргәне бары биш-алты авыл булган. Ә мин, аның кызы, Мәскәүдә тордым, Ленинградта булдым, Харьков, Ташкент, Бакуларны күрдем... Мин диңгездә йөздем, Кавказ тауларына мендем. Минем атам үз телен дә кирәгенчә белмәгән. Ә мин, аның кызы, татарча гына түгел, рус, немец телләрендә дә сөйләшәм. Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән. Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да докторны күрмәгән. Ә мин, Чулак Фәхри кызы, хәзер үзем доктор.

Зур тормышны чын-чынлап белү һәм шуны белгәннән соң киң сулыш алып эшләү шатлыгын, яшисе килү матурлыгын аңлату кыен. Миңа әле күптән түгел бер яңа роман укырга туры килде. Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде. Чөнки хәзер доктор булган татар кызының нәселе дә, тормыш төбеннән югарыга, язучылык дәрәҗәсенә күтәрелгән язучының нәселе кебек үк, иске заман бизәгендә, җәфа чигү утында яшәгән нәсел.

Әйе, беренче танышуыбыз! Тәртипсез язуым өчен гафу ит, иркәм. Минем өчен тормыш хәзер шундый бай, шундый күңелле, бер әйбер турында яза башладым исә, берсе-берсеннән матур булган тойгылар, фикерләр кәгазьгә агылырга гына торалар. Менә хәзер дә үзем сиңа хат язам, үзем радио аркылы Шубертның «Язылып бетмәгән симфония»сен тыңлыйм. Бу симфониядә нинди генә авазлар юк! Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы көченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына... тагын күтәрелә. Йөрәк тә музыкага кушылып тибә башлый. Гафу ит, Искәндәр, Шубертны тыңлап бетермичә хатымны дәвам итә алмыйм. Янымда утырган җиде яшьлек Кадриям дә:

– Әнкәем, шундый матур музыка... ә син тыңламыйсың, – дип тора.

Улым Рафаэль йоклый. Нинди тыныч йоклый ул. Рафаэль дә, синең кебек үк, учларын яңак астына куеп йоклый. Әнә ул төшендә нәрсәгәдер матур итеп елмайды. Ә без, аналы-кызлы Кадрия белән икәү,

Шубертны тыңлыйбыз. Хәер, Кадрия нәрсә уйлый торгандыр – белмим. Ул бик акыллы булды. Күпне белә башлады. Шулай да бала күңелен аңламассың: йә «Әткәем ник озак кайтмый?», йә «Әнкәем иртәгә нәрсә китерер икән?» дип уйлана торгандыр. Без Шубертны эндәшмичә тыңлыйбыз. Бу музыкада сагыну моңы да, ярату-яратмау тавышы да, җил-давыл да – бар да бар. Рәхәтләнеп тыңлыйм әле. Үзәк калалардан бик ерак урнашкан Әдрәс авылында Шуберт симфониясе аеруча матур яңгырый.

Шатлыклы туган илем! Шуберт, Бетховен шикелле композиторларның иң тирән моңнарын ерак авылларга ишеттерүең өчен сиңа җылы рәхмәт яусын.

Искәндәр!

Хатымны дәвам итәм.

1923 ел иде. Ауясыз тормыш камчысы астында төрле шәһәр, авылларны гизеп туйганнан соң мин Казанга килеп чыктым. Казанда университет рабфагына укырга кердем. Бу рабфак ул елларны университет белән бер бинада урнашкан иде.

Беренче дәресләрне тыңлау белән үк мин бәхеттән, шатлыктан нәрсәгә тотынырга белмичә шашып йөри башладым. Рабфакка барганда да, кайтканда да, бик еш: «Шушы урамнар, шушы коридорлар буйлап кайчандыр китап, дәфтәр тотып Ленин йөргән, шул бинада Толстой укыган. Шунда укырга дип яшь Горький хыял корган. Шул бинадан дөньяның атаклы галимнәре чыккан. Мин укый торган бүлмәләрдә аларның да тавышлары яңгыраган», – дип уйлана башладым. Рус әдәбияты буенча кергән укытучы Морозов та беренче лекциясен шул фикерләр белән башлады.

Ә кайчагында университетның ап-ак колонналарына сөялә идем дә, башымны югары күтәреп:

– Иптәшләр, күрәсезме, мин нинди бәхетле... Мин, Чулак Фәхри кызы, Ленин, Толстой укыган йортта укыйм, – дип кычкырып, бик каты кычкырып җибәрәсем килә иде.

Шушындый бөеклеккә ашуыма, тормышка юл табуыма мин шат идем. Ул елларны тормыш минем өчен ал да гөл генә, бөтен бәхетләр бергә, минем йөрәгемә җыелгандай тоела иде. Мин бары тик ирек, матурлык көчен генә хис иттем. Мин үземне чәчәкле бакчада күрдем. Бер сынык икмәк белән ике бәрәңге ашап, алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә мин шат һәм көләч идем. Чөнки мин күзләремне киләчәкне күрергә өйрәтә башладым. Ә киләчәкне күрү, шуны күрәм дип хис итү иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.

Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым, һәрбер сөю һәм сөелүнең «Эх, яратасы иде, сөясе... сөеләсе иде» дип хисләр ташкан чагы була. Алмагач та, тула һәм пешә башлагач, хуш исле алмаларын җиргә ыргытып, җир белән шаяра башлый. Шомырт та чәчәк ата. Сандугачлар да сайраша. Чияләр дә, вакыты җиткәч, кызаралар, тулылыктан матураялар. Мин дә үземнең матурлык тойгыларыма тулганымны сиздем. Минем дә яратасым, яраткан кешем белән:

– Без нинди бәхетле, безгә шундый рәхәт, – дип тын беткәнче кочышасым килде.

*1935*

*Мөхәммәтша Гомәр улы Мамин 1905 елда хәзерге Мордва Республикасы Зубов Аланы районы Горинка авылында урта хәлле крәстиян гаиләсендә туа. 1918 елга кадәр авыл мәктәбендә, аннан соң Пенза шәһәрендәге укытучылар әзерләү курсларында укый. 1921 елгы ачлык чорында яңадан авылына кайтып, берникадәр вакыт авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнә. 1924–1930 елларда исә укытучы булып эшли. 1930 елда Казанга килә һәм Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә. Студент елларында көндәлек матбугатта әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре белән катнаша башлый. 1936 елда Казан педагогия институтының аспирантурасын тәмамлаганнан соң, М.Мамин шунда әдәбият укыта.*

*Ватан сугышы башлану белән М.Мамин фронтка китә һәм ике ел буе алгы сызыкта фашистларга каршы сугыша. 1943 елның августында Воронеж шәһәре тирәсендә барган сугышларның берсендә өлкән лейтенант М.Мамин каты яралана һәм, шул ярадан савыга алмыйча, госпитальдә вафат була. Ул Воронеж өлкәсендәге район үзәге Воробьевка авылы зиратына күмелә.*

*М.Мамин татар әдәбияты тарихында, нигездә, үзенең «Һади Такташ поэзиясе» исемле хезмәте белән билгеле. Бу хезмәт 1941 елда аерым китап булып басылып чыга һәм Һади Такташ иҗатын тулаем алып тикшергән беренче җитди монография буларак әдәби җәмәгатьчелектә югары бәя ала. Сугыштан соң китапның икенче басмасы да дөнья күрә.*

## ҺАДИ ТАКТАШ ПОЭЗИЯСЕ

*(Фәнни хезмәттән өзек)*

Такташның беренче адымнарында ук пейзаж зур урын алып торганлыкны күреп киткән идек. Ләкин ул чор пейзажлары җитдилек белән бергә моңсулык һәм төрле дәһшәтле күренешләр белән сугарылганнар иде. Мәсәлән, «Газраилләр», «Ачлык патша», «Җир уллары» кебек әсәрләрдәге империалистик сугыш, Гражданнар сугышы чоры күренешләре пейзажлары шундыйлар.

Иҗади яктан формалашып җиткәч, Такташ пейзажларны бөтенләй икенче төстә бирә башлый. Аның пейзажларында шатлыклы тормыш күренешләре зур урын ала; ул, күбесенчә, Октябрьдән соңгы авыл күренешләрен, социалистик кырлар һәм шәһәр күренешләрен гәүдәләндерә башлый.

Такташ пейзажларының характерлы ягы шунда ки, ул аларны коры табигый күренешләр итеп кенә бирми, бәлки иҗтимагый вакыйгаларны ачыклаучы декорация итеп файдалана. Ул аларны йә төп сурәтләр белән чагыштыру өчен, йә әсәрдәге вакыйганың нинди шартларда булуын күрсәтү өчен файдалана. Мәсьәләне ачыграк күрү өчен кайбер мисалларга туктыйк. «Мокамай» әсәренең беренче бүлеген Такташ пейзаж белән башлап китә:

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар...
Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары –
Андагыдай шаулый торганнар...

Такташ бу башланышны экспозиция урынында бирә. Монда вакыйганың урыны, шартлары гәүдәләнә. Шушы шартларга нигезләп, ул әсәрнең бөтен композициясен төзи. Анда ике баланың уйнаулары, кичерешләре, авырлык күрүләре бирелә.

Бигрәк тә бу күренешләр аларның соңгы тормышларын чагыштыруда объект булып торалар. Пейзаж вакыйгаларга органик бәйләнеп, аларны ачыклауга хезмәт итә:

Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым.

Бу строфалар һаман кабатланып баралар. Шушы пейзаж белән бәйләп, Такташ бик күп вакыйгаларны искә төшерә. Алар ярдәмендә геройларның тормыш юлы ачыла, һәм алар үткән белән хәзергене чагыштыру нәтиҗәсендә идея эчтәлеген ачуга хезмәт итәләр. Менә пейзаж шундый роль уйный.

Такташ пейзажларында җил, давыл, буран кебек күренешләр зур урын алып торалар, һәм кайвакыт Такташ аларны символик формада да куллана. Мәсәлән, «Давылдан соң» әсәренең исеме символик формада бирелә. «Давылдан соң» революциядән соң дигән мәгънәдә алына. Шагыйрь революциядән соң сыйнфый мөнәсәбәтләр турында язуны максат итеп куя. Пейзажларны материал итеп ала:

«Материалым: Буран,
давыл,
таңнар,
кичәләр», –
дип башлый Такташ һәм табигать күренешләре белән әсәрен бизи.

Бу күренешләр аркылы шагыйрь революциядән соңгы гомуми иҗтимагый тормышны чагылдыру максатын куя.

Пейзажлар «Сыркыды авылы» әсәрендә тагын да зуррак урын алып торалар. Анда җил, давыл хәрәкәт символы урынында кулланылалар.

Бу поэма баштан ахыргача җил-буран күренешләре белән баетылган.

Җил – искелекне җимерүче яңа көчләрнең хәрәкәтенә параллель куелган декорация, ул – тормыштагы хәрәкәтне күзәтү өчен китерелгән җанландыручы элемент.

Такташ, пейзажларны тормыш күренешләренә параллель куйган кебек, кайчакта контраст итеп тә бирә. Шулай ук, җитди төстә бирелгән пейзажлар белән бергә, шаярту характерында кулланылганнары да очрый. Ләкин һәркайсы кирәкле урында файдаланыла. Бу моментлар «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә бик ачык күренә. Пейзаж поэмада декорация ролен уйный. Монда ай, җил, төнге күренешләр зур урын алып торалар. Бу пейзажлар геройларның кичерешләренә йә параллель, йә контраст куеп бирeләләр.

Менә бер вакыйга: Мәхмүт белән Зөбәйдә, очрашып, икәү сөйләшәләр, алар бәхетлеләр, чөнки алар ялгыз түгелләр. Ә ялгызак ай сүгенеп йөри.

Айның ялгызлыгы Мәхмүт белән Зөбәйдәнең бергә яшәүләренә контраст итеп сурәтләнә.

Бу декорацияләр Мәхмүт белән Зөбәйдәнең тормышларын ачыклауга хезмәт итәләр. Чөнки алар вакыйгаларны көчәйтәләр. Тукай:

Яктырак йолдыз янадыр,
Төн кара булган саен, –

дигән булса, Такташ шушы формуланы практик алымга әйләндереп бирә. Айның ялгызлыгы Зөбәйдә белән Мәхмүтнең бергә булуын кабарынкы итеп күрсәтә. Ләкин Такташ поэмада айның ялгызлыгын һәрвакыт контраст итеп кенә куймый, бәлки параллель дә куя. Бу инде Зөбәйдәнең Мәхмүттән аерылганнан соң булган вакыйга эчендә бирелә:

Ай да ялгыз,
Безнең Зөбәйдә дә...
Ул тын гына
Айга карап килеп утырды,
Һаман көлеп йөргән зур күзләрен
Канлы яшьләр белән тутырды...

Такташ бу мәсьәлә буенча үзе болай ди: «Мәхәббәт тәүбәсе»ндә минем төп элемент ай түгел, бәлки Зөбәйдә белән Мәхмүт. Аларның трагедияле мәхәббәтләре килешү белән бетә. Алар өйләнеп тора башлыйлар, ә ай һаман хатынсыз кала. Ай бөтен поэма буенча декорация, көлке элементы булып бара. Поэманың соңында да ул шулай кала».

*1941*

*Мөсәгыйт Мостафин 1909 елның 25 сентябрендә хәзерге Татарстан Республикасының Баулы районы Бәйрәкә авылында игенче гаиләсендә туа. 1927 елда Бәйрәкә җидееллык мәктәбен тәмамлап Казанга килә һәм рабфакка укырга керә. Шушы елларда ул әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый, очерклар, хикәяләр яза һәм аларны Ютазы район газетасында бастыра. 1931 елда яшь әдипнең Казанда биш хикәясен үз эченә алган «Очрашу» исемле китабы һәм үсмер балалар өчен «Үсү» исемле озын хикәясе басылып чыга. 1932 елда аның «Тыңлыйсыңмы, кордаш?» дигән өченче китабы да дөнья күрә. Үзенең хикәяләрендә һәм нәсерләрендә яшь автор гади хезмәт кешеләренең көндәлек тормышын тасвирларга омтыла һәм җиңелчә юмор белән алардагы искелек калдыкларын тәнкыйтьли. Аның хикәяләре лирик яңгырашлы һәм тел-сурәтләү чараларының халыкчан, образлы булулары ягыннан да игътибарга лаек.*

*Мөсәгыйт Мостафин 1941 елның август аенда үзе теләп фронтка китә һәм шул ук елның 6 декабрендә сугыш кырында батырларча һәлак була.*

## КАРЛЫГАН БАКЧАСЫ

### I

Таулардан төшкән күләгәләр сизелерлек рәвештә озыная баралар. Түгәрәкләнеп үскән карлыган куакларының төпләре эңгер-меңгерләнә. Куаклар куе яшел төскә керәләр. Чикерткәләр дә инде җырлап купшыланмыйлар, кыяк тешләп, кояш батканын көтәләр. Тик ялгыз песнәк кенә, әле бер куакка, әле икенче куакка күчеп, кемнедер юксынгандай сузып-сузып сызгырынгалый. Түбәндә, карлыган куаклары артында, тар гына, ләкин тирән буа бөгәрләнеп ята. Гүя ул көн буе малайлар коендырып арыган да соңгы тапкыр кемнедер каршы алырга әзерләнгән. Аннан да ары төтенләнеп торган басулар китә.

Тирә-якка пешеп килә торган карлыган һәм яшел яфрак исе тарала. Ул ис, бөтен тамырларга үтеп кереп, йомшак рәхәтлек бирә, каннарны уйната. Мин, җәйге табигатьнең кояш баткандагы аһәңенә зәвыкланып, яшел печән белән ябылган куыш буендагы бүтәкә үләннәре өстендә утырам. Бик тәмле итеп папирос тартам, төтен балдаклары җибәрәм һәм әледән-әле авыл башына карыйм. Бүген дә килерме ул, юкмы?

Менә ике көн инде мине ниндидер өметле тынычсызлык чорнап алды. Өченчекөн кич бакчаның буа буендагы карлыган куаклары арасында җимеше күплектән сыгыла башлаган ботакларны күтәреп йөри идем. Кинәт су чапылдаганын ишеттем. Башымны күтәреп карасам, карлыган бакчасына таба бер кыз йөзеп килә иде. Ул мине күреп алуга, яр буена килеп күренеп тә, кинәт су уртасына китеп югалган ак балыктай, кырт кына борылып кирегә йөзә башлады. Аның артыннан су өстендә тузылган озын чәче генә дулкынланып калды. Ул, аргы як ярга җиткәч, миңа таба каерылып карады да су астыннан күренә башлаган ап-ак муенын, иңбашларын яңадан суга яшерде. Әкрен генә бөтен гәүдәсе белән минем якка таба борылып, йомшак тәпиләре белән битен юган ак песидәй, түгәрәк йөзен юа башлады. Аннан соң

су өстенә таралган чәч көлтәсен җыеп алып бик озаклап сыкты. Мин, үземнең кайда икәнлегемне дә онытып, аңа һаман ахмакларча карап тора идем. Мондый вакытта яшь кешенең кайсысында таркаулык килеп чыкмый соң! Аның инде эше дә бетте. Ул, су эчендә башын гына күрсәтеп, туп-туры миңа таба карап тора башлады. Мин, исемне җыеп, аңа уңайсызламас өчен кире борылырга гына торганда, аның матур аһәңле тавышын ишеттем.

– Егет! Минем өстемдә купальный костюм да юк. Сез беразга гына теге якка карый алмассызмы?

Мин бу сүзләрне әллә тыңлап бетердем, әллә юк, әллә ул әйтә башлагач та борылдыммы – анысын хәтерли алмыйм. Тик мин яңадан борылып караганда, ул инде кызу-кызу атлап авылга таба китеп бара иде. Аның ап-ак кулларын кызу адымнарга ияртеп әле алга, әле артка тиз-тиз ташлавы ак күбәләкләр талпынуын хәтерләтә иде.

Икенче көнне дә ул, буа тирәсендә кеше аягы басылгач, берүзе генә килеп, су коенып китте. Ләкин бу юлы мин аны якыннан күрә алмадым. Куышта утырып, каравылчы бабайның әкиятләренә мавыгып, аның кайчан килүен сизми калганмын. Мин куыштан чыкканда, ул инде авылга ук кереп бара иде. Безнең куыш тау кабыргасында булганга, бик ачык чагыла: ул, тыкрык башына кереп китәр алдыннан берничә тапкыр каерылып, безнең якка таба карады. Егет кешенең күңелен канатландырырга шушы җитмимени тагы?! Нинди кыз ул? Кемгә килгән, каян килгән? Мин әле моны белмим. Тик аның бүген дә безнең карлыган бакчасы буендагы буага килеп су коенып китүен, һич тә булмаса, күренеп кенә китүен түземсезлек белән көтәм.

## II

Уйларымнан ничек итеп бушанганымны, кай арада урынымнан сикереп торганымны белмим. Мондый вакытта сүз белән әйтеп бирә алмаслык ашкыну, кызыксыну кешенең иреген ала, хисләр үз эшләрен эшлиләр. Аякларым мине буа буена әйдиләр. Мин, күренмәскә тырышып, карлыган куакларына күмеләм. Минем битемә кызгылт төскә кергән карлыганнар бәрелеп калалар, мин аларга әһәмият бирмим, тик юл буйлап буага якынлашып килүче кызны гына күздән яздырмаска тырышам.

Кинәт мин йөрәккә үтеп керердәй көлү тавышы ишеттем. Бу көлүгә хәтта тын гына яткан буа да сискәнеп, калтыранып куйган төсле булды. Мин, ирексездән гәүдәмне турайтып, аптырап катып калдым. Мин дә яр буена килеп җиткәнмен, ул да нәкъ аргы як ярда басып тора иде. Бу көлүдән мин бөтенләй үземне-үзем җыя алмас бер хәлгә килдем. Кире борылып, күз күргән якка хәлдән таеп егылганчы йөгерү минем өчен күп мәртәбә җиңелрәк булыр иде. Ләкин бу көлү минем аякларга гүя таш такты. Бу хәл тагын да шулай дәвам итсә, мин нишләр идем? Ләкин ул ук мине бу хәлдән чыгарды да. «Моның өчен аңа мең рәхмәтләр булсын», – дип уйладым мин. Ул, рояль тавышы яңрап тынган шикелле, көлүен әкренәйтә барды. Соңгы тапкыр, чәчәк сабагы җилгә сыгылгандай, нәфис гәүдәсен бөгеп сулкылдап алды да тынды. Аннан йомшак кына итеп миңа дәште:

– Ә мин карлыган бакчасына карак кергән икән дип уйладым.

Бу сүзләрдән соң миңа ничектер батырлык кереп китте. Каян башка килгәндер:

– Юк, карак һич юк. Ботаклар җиргә сыгылганнар, шуларны... – дип алдап киттем.

Ләкин ул миңа алдаштырып җәфаланырга ирек бирмәде, иркәлек катыш кискен тавыш белән бүлде:

– Сез алдашасыз.

– Мондый вакытта алдашу – үзе бер ләззәт, – дип ычкындырдым мин аңа.

– Усал икәнсез сез, – дип елмайды ул миңа.

Мин дә, ул да тынып калдык. Сүзнең болай тиз бетүенә мин хафалана башладым. Җебегәнрәк шул мин, кызлар үзләре сөйләшмәсә, дәвам итәргә сүз таба алмый җәфаланам. Шундый вакытта өзлексез сүз табып торырлык, үзе сүз катарга атылып торган ачык кызны рәхәтләндерерлек тә булмагач, нигә мин тел тагып йөри торганмындыр инде. «Сүз бозау имезә» диләр дә бит, ләкин ул башка җирдә, башка вакытта шулай. Монда миңа нәкъ бозау имезерлек озак вакытны алырлык сүзләр табарга кирәк. Бәлки, әле бу минем хатын-кыз тирәсен начар белүемнән, яшьлегемнән, тәҗрибәсезлегемнән килә торгандыр. Һич булмаса, нигә үзе сөйләшми соң ул?! Аның колакка музыка булып яңраган тавышы мине бервакытта да, бервакытта да туйдырмас иде кебек...

Тагын да ул ук алчаклык күрсәтте. Буа буйларына күз сирпеп алды да елмаеп миңа карады:

– Буагыз нинди әйбәт. Тик кырыйлары лай гына. Су коенып чыкканда аяклар пычранып бетә.

Бу чынлап та шулай бит. Көн саен буада быкырдап су коенып ятабыз, ә моңа кадәр шуны да искәрмәгәнбез. Әрекмән белән аякларны корыткан булабыз да шул җитә. Хатын-кыз вак уңайсызлыкларны да бик тиз күрүчән була шул. Ул яктан безнең ирләр халкы тупасрак инде.

– Сез су коенырга телисезме? – дип сорадым мин.

– Шулай уйлап килгән идем дә... – диде ул.

– Әз генә сабыр итегез, – дидем дә буаның түбән ягындагы яр астына атылдым, аякларым җиргә әллә тиделәр, әллә юк. Үзеңнең күңелең тарткан хатын-кызга хезмәт күрсәтү, кечкенә генә нәрсә белән дә аны сөендерү җанга рәхәтлек бирсә, тәнгә батырлык та, җегәр дә кертә икән. Башка вакытта юньләп урыныннан да кузгата алмастай яссы ак ташны нинди көч белән күтәреп алганмындыр, мин аны

сизмәдем. Тик, буа өстеннән икенче якка чыгып, аның янына якынлашканда: «Сез нишлисез?! Куегыз, зинһар, куегыз, үзегезне имгәтерсез!» – дигән сүзләр генә колак төбемдә яңгырап торды. Мин аның саен үземдә бетмәс-төкәнмәс көч сиздем. Ташны уңайлы гына урынга китереп салгач, ул тирән көрсенеп куйды:

– Шулай ярыймы соң инде?

Аның күксел күзләре аз гына дымланганнар, ләкин бик тирәннән үзәккә үтеп керердәй очкын сибәләр. Шул ук вакытта ул бу хәлен яшерергә дә тырыша иде. Ул күзләр миңа санап бетерә алмаслык рәхмәт яудыралар иде.

Мин якыннан гына әрекмән яфраклары өзеп алдым да таш өстенә түшәдем.

– Менә хәзер коеныгыз инде, – дип сөйләнә-сөйләнә, үз-үземнән канәгать булып, әкрен генә китә башладым.

Ул минем каршыма килеп төште: мин аның шалкан кебек ап-ак йөзендә ялкынланып уйнаган мәк чәчкәсе алсулыгына карадым, күзләренә карарга көчем җитмәде.

– Беләсезме нәрсә? Ачуланмагыз, карлыган бакчагызны күрсәтегез миңа. Мин кичке бакчаны бик яратам, – диде ул.

Каршы киләмме соң! Миңа һичшиксез яхшы күңелле булып тоелган шундый яшь кызның мөлаемлылык белән тулган мөгамәләсенә таш үзе эрер.

## III

Кояш инде күптән батты, ә без һаман утырабыз. Ул яшел үләннәр өстенә уң кулының очы белән таянган да минем якка авышарак төшкән. Мин аның матур йөзенә карап исерәм, ләкин хәзер инде аның бер генә нәрсәсен дә ачык күрә алмыйм. Төн якынлашудан түгел, ә болай башка сәбәптән минем күзләрем пәрдә белән өртелгән кебек. Әгәр хәзер миңа килеп: «Аның авызы кыек», – дисәләр, һәм бу шулай булса да, мине барыбер ышандыра алмаслар иде.

Офыктагы вак-вак болытларга асылынып калган алсулыклар да эреп югалдылар инде. Безнең һаман кузгаласыбыз килми. Без утырган яшел уйдыкны әйләндереп алган куаклар безгә карап сөенешәләр кебек тоела. Мин аңа бу карлыган куакларын ничек итеп үстерүемне, бакча-түтәлчелек техникумын бетергәч тә монда килеп эшли башлавымны сөйлим. Ул үзенең Бөгелмә шәһәрендә тимер юл мастерскоенда эшләвен, монда бертуган апасына, отпуск вакытыннан файдаланып, кунакка килүен әйтте...

Без бер-беребезгә:

– Элек сез әйтегез...

– Юк, сез әйтегез, – диешеп, матур итеп сатулаша-сатулаша, исемнәребезне дә әйтештек. Моннан соң инде ул миңа «Фәрит» дип, ә мин аңа «Мөршидә» дип дәшешә башладык.

Сөйләшә торгач (минем тел бик нык ачылып киткән иде инде), бер-беребезгә шулкадәр якынлашканбыз, мин моны Мөршидәнең кайнар, шәрә беләгенә чәчләрем тия башлагач кына сиздем. Ул кинәт тураеп утырды да үзенең сары чәченә кадаган тарагына үрелде:

– У-у, Фәрит, чәчләрең тузган синең. Кил, тарыймчы үзләрен.

Мин сабый балаларча аның иркенә бирелдем. Ул, минем каршыма тезләнеп, үргә таба чәчләремне тарарга кереште. Аның яңа гына формалашып килгән күкрәге, нәрсәгәдер чакыргандай, еш-еш бер күтәрелеп, бер төшеп тора, кайнар сулышы йөземә бәрелә башлады. Мөршидә авырттырмый гына минем чәчләремнән тартып шаяртты, мин, гүя авырткандай кыланып, аның кулларыннан тотып алдым... Өстебездән дулап сихерле бәхет өермәсе үтteme, әллә аның янган иреннәреннән мәхәббәт эчеп, акылымны җуйдыммы – берсен дә хәтерләмим. Тик аңымны каплаган томан тарала башлаганда, мин аны да, үземне дә бер-беребезгә сарылган хәлдә таптым. Мөршидә озын керфекләрен әкрен генә какты да күгелҗем уйсулыкта чиксез бәхетлелек белән янган күзләреннән мине көйдереп алырдай ялкын сипте...

Иң элек ул сикереп торды. Берничә адым читкә китеп, ике кулы белән дә карлыган куагына тотынды һәм өзелеп сулкылдый башлады:

– Гафу ит мине, Фәрит! Мин сиңа «карлыган карагы» булып килгән идем, ә син минем йөрәгемне дә, үземне дә урладың. Мәхәббәтем мине тотып бирде, гафу ит мине.

Ул бик каты йөгереп китеп барды, мин нишләргә белми аптырап калдым, күз алдымда карлыган куаклары бөтерелгәндәй булдылар...

*1941*

*Хәйретдинов Мөҗәһит Хәйретдин улы (Х.Мөҗәй) 1901 елда туа.*

*Яшьтән үк әдәбият белән кызыксына, үзе дә шигырьләр яза һәм аларны район газеталарында бастырып чыгара.*

*Х.Мөҗәй гомеренең күп өлешен Совет Армиясе сафларында үткәрә. Ул 1931–1933 елларда Урта*

*Азиядә взвод командиры буларак басмачыларга һәм кулак бандаларына каршы көрәштә катнаша. Бу елларда ул күп яза, шигырьләре, очерклары һәм хикәяләре газета-журналларда, альманахларда әледән-әле басылып тора. Менә шул вакытта Х.Мөҗәй Татарстанда үткәрелгән әдәби ярышта катнаша һәм беренче бүләкне ала.*

*1932 елны Х.Мөҗәйнең «Мылтыклылар» дигән китабы басылып чыга. Х.Мөҗәйнең әсәрләре, әдәби яктан эшләнеп җитмәгән булсалар да, шул еллардагы тормышны, чик саклаучы совет сугышчыларының уй-фикерләрен, Ватанны саклаудагы батырлыкларын чагылдырулары белән үзенчәлекле.*

*Х.Мөҗәй Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, полковник дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Фронт газетасында аның батырлыклары турында язып чыгалар. Алгы сызыкта да Х.Мөҗәй язучылык эшен дәвам итә. Ул фронт хикәяләре, совет сугышчыларының батырлыкларын күрсәткән очерклар, шигырьләр яза. Аларның күбесе «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басыла.*

*Х.Мөҗәй 1944 елның 4 сентябрендә фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелә.*

## ЯДКАРЬ

Дәфтәр куенында ялгыз яфрак,
Әйтче, иркәм, кемнең бүләге?
Дәфтәрдәге коры яфрак кебек
Кем саргая, өзелә үзәге?

Йөзләре дә аның,
Йөрәге дә
Шушы яфрак кебек кибәме?
Дәфтәреңә карап, үзеңне дә
Чын мәхәббәт уты күмәме?

*1932*

## МИНЕМ ШАТЛЫГЫМ

Бөдрә чәчле иркәм, шатлыгым син,
Синең өчен яши бу йөрәк.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Бу йөрәгем үзе ник кирәк?
Гөл кебек ал, матур галстуклы
Пионер син, минем шатлыгым.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Яшәвемнең ниткән шатлыгы?
Яңакларың кипкән, әби җаным,
Шатлыгым син күңел түремдә.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Нидер җитмәс иде күңелгә.
Көмеш чәчле бабай,
Шатлыгым син,
Синең өчен ага бу каным.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Боегыр иде төсле шул җаным.
Урманга бай, суга, кырларга бай,
Шатлыгым син, матур Туган ил.
Син булмасаң,
Әйе, син булмасаң,
Кемгә кирәк, нигә кирәк мин?!
Бөтен шатлык,

Кайнар мәхәббәтем
Үз халкымда, Туган илемдә.
Шулар өчен биреп бөтен дәртне,
Көлә беләм сугыш җирендә.
Көлә беләм,
Шаулап җырлый беләм,
Көрәшләрдә күңел ямь таба.
Күз алдымда каты үлем күрәм,
Җиңә беләм,
Җиңү – мәртәбә!

*Көньяк-көнбатыш фронт*
*1941*

**БҮЛӘК**

*Яулык алдым, аның уртасына*
*Кызыл җептән йөрәк чигелгән.*
*«Дошманнарны җиңеп*
*тизрәк кайт!»*
*Дигән сүзләр матур тезелгән.*

Белмим аның үзен, исемен белмим,
Тик «йөрәге» сүзе алдымда.
Канга сеңеп, изге ант шикелле,
Онтылмаска истә калдылар.

Кич утырып, аның бармаклары
Йөгергәндер җепләр эзеннән.
Белмим, бәлки, җуеп тәкатьләрен,
Түгелгәндер яшьләр күзеннән.

Күз алмасы кебек сөйгән егетен
Өзелеп-өзелеп сагынып куйгандыр.
Кош йөрәге кебек саф йөрәге
Әллә, әллә ниләр тойгандыр.

Яулык алдым, аның уртасына
Кызыл җептән йөрәк чигелгән.
«Дошманнарны җиңеп тизрәк кайт!»
Дигән сүзләр матур тезелгән.

*1942*

**НЕМЕЦ ХАЛКЫНА КОМАНДИР ҺӘМ ШАГЫЙРЬ Х.МӨҖӘЙДӘН АЧЫК ХАТ**

**1**

Сез, Гитлерны тыңлап,
Үзегезне
Гитлер чаклы ук бандит иттегез;
Планетаның тапсыз йөрәгенә
Бомба белән кереп киттегез.
Сез, Гитлерны тыңлап,
Заводларда
Көне-төне корал койдыгыз.
Кулыгыздан кайнар каннар тама,
Чирканмыйча адәм суйдыгыз.
Сез, Гитлерны тыңлап,
Планетаның

Тик бердәнбер гадел иленә
Каракортлар кебек,
Агу чәчеп,
Ябырылдыгыз гөлле җиремә.

**2**

Минем күз алдымда үлгән атлар,
Аяк-башсыз
Кеше гәүдәләре таптала.
Болар сезнең шомлык,
Немец халкы!
Керфегеңне сирпеп бер кара.
Минем күз алдымда
Җимерек шәһәр,
Янган авылларның көлләре.
Бу хәрабәләрне сезнеңме соң,
Йә, әйтегез,
Сезнең күзләрме соң күрмәде?!
Сез, Гитлерны тыңлап,
Шакаллардай
Ташландыгыз минем илемә.
Каракортлар кебек, агу чәчеп,
Ябырылдыгыз гөлле җиремә.
Зөбәрҗәттәй пакь күңелле кызның
Мәсхәрәләп барлык шатлыгын,
Шакшы ләззәт өчен,
Мунчак салып,
Фахешханәләргә тарттыгыз.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сез бөтенләй оят саттыгыз!

**3**

Немец халкы!
Синең язмыш әле үз кулыңда,
Бәр бомбаңны Гитлер башына;
Буржуйларны тотып тиресен туна,
Фашистларның кыр син барсын да!
Үзең койган үткен хәнҗәр белән
Фашистларның тура йөрәген!
Тик шул чакта синең намусың саф,
Тик шул чакта кансыз beləгең.
Минем хатым синең йөрәгеңә
Үткен хәнҗәр кебек керәдер.
Керер шул ул,
Чеметеп, чәнчеп алсын,
Хатымнан шул минем теләгем.
Тыңласаң, шәп,
Әгәр тыңламасаң,
Әйтмәдең дип үпкәң булмасын,
Шан-шәүкәтең бетәр,
Фашизмны
Җимереп ташлау өчен кузгалдык!
Минем хатым Гитлер йөрәгенә
Бомба булып төшәр һавадан.
Берлин урамнарын ялкын кочар,
Кярханәләр шартлар яңадан!
Кярханәләр шартлар.
Немец халкы,

Гаебеңне юа алырсың,
Мин ышанам әле,
Киләчәктә
Якын дустым булып калырсың!

*14 декабрь, 1941*

## МАЛАЙ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

*(Парча)*

Ул малайның күзләреннән ут чәчелеп тора төсле.

– Мин сезгә Гитлерны капчыкка салып китерермен, валлаһи, китерермен, – ди ул, шаярып түгел, чын ихласы белән, үзе ышанып һәм безне ышандырырга тырышып әйтә. Әгәр җибәрсәң, бүген үк Берлинга чыгып китәргә әзер тора.

– Йә, аласызмы? Алыгыз инде, – дип тыкырдата, төпләбрәк уйларга да урын калдырмый.

– Нәселем начар түгел, курыкмагыз, атам да, агам да Кызыл Армиядә, агам разведчик, – дип, бер дә сорамасак та, чыгышын, нәсел-нәсәбен, күрше-күләнен, туган-тумачасын мактап китә.

– Теләсә кемнән сорагыз, барысы да мин сөйләгәнне әйтер... «Алыгыз» дип кенә әйтерләр.

– Анаң бармы?

– Бар.

– Бәрәңгегез бармы?

– Бар.

– Икмәгегез?

– Җитәрлек.

– Утыныгыз бармы?

– Утыныбыз да бар.

– Атыгыз?

– Ат?.. Колхозда. Нишләп булмасын.

– Шулай булгач, ни җитми?

– Җитә.

– Ник соң кычытмаган җирне кашып йөрисең, ашап-эчеп, җылы өеңдә рәхәтләнеп тик ят.

– Тик ятудан ни файда бар соң? Тик ятканчы, мин сезгә Гитлерны тотып китерермен. Йә, аласызмы инде?

– Юк, энекәш, яшьрәк әле син, – дим мин.

– Мин үскәнче, бетәр бит ул, – дип, ул миңа текәлеп карап тора.

– Нәрсә бетәр?

– Нәрсә? Сугыш.

– Бетсә соң... бик яхшы.

– Ә Гитлер?

– Гитлер... Ул да бетәр.

– Бетүен бетәр дә...

– Ә соң нәрсә кирәк?

– Мин тотып китермәм бит.

– Син китермәсәң, атаң, абыең китерер.

– Менә мин шуннан куркам да шул. Минем абыем бер генералны тотып китерде инде.

– Яхшы алай булса, бик яхшы.

– Аңа яхшы...

– Ә сиңа?

– Йә... алыгыз инде?

– Тукта, тукта. Боргаланма. Аңа яхшы, ә сиңа ник яхшы түгел?

– Тик... мин...

– Нәрсә син?

– Гитлерның үзен тотармын дип язган идем аңа.

– Ә-ә-ә... менә ничек!

– Шулай шул, мич башында ятсаң, тотып булмый ич аны... Йә, аласызмы инде?

*Хәрәкәттәге армия*
*1942*

*Сөләйман Мифтах улы Мөлекев – сугыш алды елларында әдәбият мәйданына чыгып, газета-журнал битләрендә, күмәк җыентыкларда әдәби әсәрләре белән күренә башлаган, әмма сугыш фаҗигасе аркасында үз тавышларын ныклап ишеттерә алмыйча, гомерләре бик иртә өзелгән яшь каләм тибрәтүчеләрнең берсе. Ул 1920 елның 5 гыйнварында хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районы Пыжмара авылында туып үсә. Җидееллык мәктәпне һәм Алабуга китапханә техникумындагы курсларны тәмамлаганнан соң, 1940 елга кадәр Татарстан авылларында китапханәче һәм укытучы булып эшли. 1940 елның февралендә гаскәри хезмәткә алына һәм Ватан сугышын Көнбатыш Украинада чик сакчысы булып каршылый. Сугышның беренче сәгатьләреннән үк ул алгы сызыкта була һәм 1941 елның сентябрендә Киев өчен барган сугышларның берсендә батырларча һәлак була.*

*Сөләйман Мөлекев авыл табигатенең гүзәллеген җырлаган һәм романтик яшьлекнең хис-тойгыларын гәүдәләндергән бер төркем лирик шигырьләре белән билгеле. Ул шигырьләрдән яшь шагыйрьнең образлы фикердәге зәвыгының шактый югары икәнлеген чамаларга мөмкин.*

*С.Мөлекевнең зур булмаган шигъри иҗатыннан аерым үрнәкләр сугыштан соң «Алар сафта» (1961), «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Илең турында» (2000) исемле китапларда урын ала.*

## УРМАН

Урман, урман!
Синең эчеңнән
Күп мәртәбә йөргән бар минем,
Матур җәйдә тиңсез соклангыч
Ямьнәреңне күргән бар минем.
Иртә торып бала-чагалар
Сине күрү өчен омтыла.
Эчләреңә керсәң, ничектер,
Эшләнәсе эшең онтыла.
Сөям сине, сөям, урманым.
Күп кенә бар синдә булганым,
Ятып хәл җыйганым бар синдә,
Йомшак иде яшел юрганың.
Җәй көнендә синнән матур җир,
Күңелле җир таба алмыйм мин.
Үпкәләмә, минем урманым,
Көн дә сиңа бара алмыйм мин.
Мин барырмын әле сиңа бер,
Кошлар симфониясен тыңларга,
Саф һаваңны йотылып суларга,
Көчле тавышым белән җырларга...
Синдә,
Бер агачтан китеп берсенә,
Җырлар җырлап, кошлар кучәләр,
Киң илемдә синдәй урманнар
Безнең өчен гөрләп үсәләр.

*1938*

## КҮЗ НУРЫМ СИН

Күзләрең зәңгәр булганга,
«Зәңгәрем» дип атадым.
Былбылым син, күз нурым син,
Шатлыгым син, аппагым.

Сагындыра әйткән сүзең
Һәм күзең, йомшак кулың.

Күз нурым син, акыллым син,
Өметем син, матурым!

*1939*

**ГӨЛБАНУГА**

Сөйгәнем, син аңла, мин сугышта
Ватан тынычлыгын сакладым.
Сөйгән халкым өчен, синең өчен,
Үзем өчен җиңеп атладым.

*1941*

*Хәбра Рахман (Хәбибрахман Габдрахман улы Габдрахманов) 1914 елда хәзерге Татарстан Республикасының Балтач районы Яңгыл авылында крәстиян гаиләсендә туа. Сигез яшендә чагында әти-әнисез калып, ятим балалар йортында тәрбияләнә. 1930 елда Арча мәктәбенең җиде сыйныфын тәмамлап, авылда укытучы булып эшли башлый. Шушы елларда «Ялчы» дигән крәстиян газетасында аның беренче шигыре һәм хикәяләре басыла.*

*1931–1936 елларда Хәбра Рахман Казанда татрабфакта, аннары дәүләт педагогия институтында белем ала. Институтны тәмамлаганнан соң, аны татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп Алабуга педагогия училищесына эшләргә җибәрәләр. 1938–1940 елларда Хәбра Рахман гаскәри хезмәттә була, Халхин-Голдагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, яралана, шәхси каһарманлыгы өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.*

*Армиядән кайткач, Хәбра Рахман Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр әүвәл Алабуга педагогия училищесында һәм китапханә техникумында тел-әдәбият укытучысы, аннары Алабуга район газетасының мөхәррире булып эшли. Сугыш башлангач, ул фронтка китә һәм, Мәскәү янындагы канлы бәрелешләрнең берсендә авыр яраланып, шул ярадан савыга алмыйча, 1942 елның ноябрендә вафат була. Аның гәүдәсе хәзерге Тверь өлкәсенең Максатиха дигән тимер юл станциясе каберлегенә җирләнә.*

*Хәбра Рахманның әдәби мирасы зур түгел. Көндәлек матбугатта басылган шигырьләрен дә үз эченә алып, 1937 елда аның «Чәчәк ява» исемле бердәнбер мөстәкыйль җыентыгы дөнья күрә. Моннан башка газета-журналларда кечкенә-кечкенә хикәяләре һәм Халхин-Гол вакыйгаларына багышланган «Сугышта» («Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары»), 1940) исемле зур гына очеркы басылып чыга. Сугыш алдыннан ул шулай ук «Шомырт чәчәкләре» исемле повесть язарга керешә, ләкин әсәр тәмамланмый кала. Хәбра Рахман әсәрләренең, бигрәк тә шигъри иҗатының төп эчтәлеген күмәкләшү чоры кичергән яңа авыл тормышы һәм мәхәббәт лирикасы били.*

*Хәбра Рахманның сугыш чоры иҗатыннан аерым үрнәкләр «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961), «Илең турында уйла» (2000) исемле күмәк җыентыкларда урын ала.*

***

Елмаюлы бөдрә дулкыннар
Уйнакласа синең йөзеңдә,
Йөгерек нурлар бердән электрдай
Дөрләп кабыналар күзеңдә.
Уйлар балкый,
Хисләр актарыла,
Шатлык арта минем тагын да,
Йөрәк сикерә, күңел кытыклана,
Каным кайнап котыра тамырда.

Әгәр алсу йөзең томанланып,
Куе кара болыт йөгерсә,
Күз карашың шомлы ачу катнаш
Көчле әрнү белән төренсә,
Чырай сытыла,
Кашлар салына.
Йөрәк чәрдәкләнеп теленә,
Күңел сүрелә,
Йөз кайгыга төренә,
Күңелем моң белән күмелә.

*1932*

## СУГЫШТА

*(Кызыл сугышчы блокнотыннан)*

Иң кирәк чакта кыр телефоны эшләми башлады. Роталар озакламый атакага ташланачаклар. Пуля яңгыры, осколоклар бураны эчендә алар инде дошман позицияләренә якынлашып киләләр. Артиллерия үзенең утын тагын да көчәйтте. Дошман окоплары арасында снарядлар тагын да ешрак шартлый, тузан өермәләре тагын да күбрәк күтәрелә башлады.

Ләкин нәкъ менә шушы вакытта, нәкъ менә шушы иң җитди, иң җаваплы моментта отделение командиры Голубицкий командалыгы астындагы элемтәчеләр группасының кыр телефоны эшләми башлады. Голубицкий үзе дә, аның иптәшләре дә моның нинди зур нәтиҗәләргә китереп чыгарачагын беләләр һәм телефонның хәзер үк эшли башларга тиешлеген ачык төшенәләр иде. Бит алар ике частьның янәшә хәрәкәт итүче батальоннары арасында элемтә алып баралар, ике частьның бер оператив планы нигезендә бердәм хәрәкәт итүе бик күп дәрәҗәдә аларга бәйле.

Телефонист, трубкага җиңелчә генә өрә-өрә, тагын бер кычкырып карады:

– 24, 24, дим, тыңла әле, 24!

Ләкин батальон штабы җавап бирмәде. Бер-ике минут чамасы телефонисттан күзен алмыйча аппарат янында чүгәләп утырган Голубицкий аз гына урыныннан кузгалып куйды. Аның калын җилкәсе окоп стенасына тиеп китте, окоп эченә шыбырдап балчык коелды.

«Мәсьәлә ачык, – дип уйлады ул эченнән, – 32 җавап бирә, 24 җавап бирми. Димәк, аппарат төзек, 24 ягындагы линия өзелгән, әле генә шул якка тягачлар киткәннәр иде. Шулар өзгәннәр».

Аннары ачык, кискен, ләкин сабыр тавыш белән кычкырды:

– Иптәш Шәрипов!

Янәшә окопларның берсеннән җавап тавышы ишетелде:

– Мин!

Шул ук секундта күрше окоптан чибәр генә бер яшь егет күтәрелде. Аның тулы түгәрәк битендә иртәнге чык кебек вак тир тамчылары җемелди. Куе кара кашлары да, яңа гына төртеп чыгып килгән кара мыеклары да тиргә чыланган. Ул җитез генә өскә сикерде һәм винтовкасын кулына тотып, шуышып Голубицкий янына килде.

– Иптәш Шәрипов, сез хәзер линия буйлап 24 ягына барыгыз, анда линиянең өзелгән урынын табыгыз һәм тизлек белән шуны ялгагыз!

– Есть линияне ялгарга!

– Барыгыз, ләкин тиз йөрегез!

Шәрипов алгарак төшә башлаган граната сумкасын тиз генә янга этәреп куйды да, винтовкасын тагын да ныграк кысып, күрсәтелгән якка таба китте. Алар урнашкан пунктның уң ягында куе яфраклы вак агачлар белән капланган калкулык, ә сул ягында болын кебек тигез җир, калкулыкның аргы ягында шундый ук вак агачлар белән капланган бер үзәнлек бар. Бу үзәнлек борылып-борылып дошман позицияләре ягына барып чыга. Линия менә шушы калкулыкның итәге буйлап бара. Шәрипов башта шуышып вак агачлар арасына керде; аннан, торып, мөмкин кадәр агачларның ботакларын, яфракларын селкетмәскә тырышып, шушы агачлар арасыннан китте. Йөз метрлар чамасы киткәч, калкулык та, аның белән бергә линия дә сулга борыла иде. Шәрипов та шунда борылды. Иптәшләре урнашкан окоплар инде күздән югалды. Ул һәрвакыт үлән өстеннән сузылып барган линияне күздән югалтмады.

Шул рәвешле байтак кына барганнан соң, ул линиянең өзелгән урынын тапты, һәр ике өзек очның башын чистартты. Линияне ялгады һәм ялганган урынны йомшак резина тасма белән төреп эшен бетерде дә яңадан кире үз пунктларына кайтырга чыкты. Ләкин берничә адым шуышып барырга да өлгермәде, ярыйсы ук якында шартлау тавышлары ишетелә башлады. Ул бер генә секундка туктады, тавышларның граната тавышлары икәнен, аларның үзләре урнашкан пункт ягыннан килгәнен белде.

Шартлау арасында кеше тавышлары да ишетелеп киткән кебек булды. Кинәт гәүдәсе буйлап жу итеп нәрсәдер йөгереп киткәндәй булды. Йөрәге тынычсызланды, еш-еш тибә башлады. Ул кәлтә еланы кебек тиз-тиз генә шуышып агачлар арасына керде. Аннары җитез генә сикереп торды да бар көченә үз пунктларына таба йөгерергә тотынды.

Менә граната тавышлары тынды. Аларны шау-шулы кеше тавышлары, ярсулы кычкырынулар алмаштырды. Барган саен тавышлар тагы да ачыграк, тагы да көчлерәк, тагы да ярсулырак булып ишетелде. Менә алар арасында барыннан да ачыграк, барыннан да көчлерәк булып саф русча сүзләр яңгырады:

– Бей гадов!

– Бей крепче!

Шәриповның йөзе тагы да җитдиләнде, тешләре кысылды, иреннәре ачулы кабарды. «Бу – Голубицкий белән линия элемтәчесе Олейнек тавышы бит. Димәк, алар һөҗүмгә тартылганнар!» Шул уй белән ул, иелгән хәлдә агачлар артына яшеренә-яшеренә бар көченә йөгереп бара торгач, бер борылмага килеп җитте. Агачларга ышыкланып, алга, үз пунктларына таба карады.

Алда, аларның окоплары тирәсендә, уналты-унҗиде дошман солдаты – самурайлар кайнаша. Алар берьялгызы калган Голубицкийны чолгап алганнар, шаулаша-шаулаша, әллә ниткән аңлашылмаган сүзләр кычкыра-кычкыра, аңа ташланалар. Голубицкий үзен әкияттәге батыр төсле тота. Үзенә якын килгән кысык күзле самурайларны искиткеч җитез хәрәкәтләр белән бер-бер артлы аудара тора; кайсының күкрәгенә төзәп атып җибәрә, кайсының кабырга араларына дүрт кырлы штыгын батырып ала, кайсын приклад белән бәреп ега. Үзе ярсулы тавыш белән кычкыра:

– Мәгез, явызлар, мәгез, еланнар!

Менә кечкенә буйлы, калын җилкәле, усал һәм хәйләкәр карашлы берсе, бөтен кыланышларына караганда кече офицер яки офицер чины алу өчен тырыша торган солдат булса кирәк, Голубицкийның каршына ук килеп, тесагын аның күкрәгенә сузды. Голубицкий үзенә юнәлгән тесакны яшен тизлеге белән астан өскә таба бәреп җибәрде дә бу хәшәрәтнең үз күкрәгенә кадады, шундый ук җитезлек белән штыгын кире суырып та алды. Самурай ачы тавыш белән кычкырып җибәрде һәм чайкалып-чайкалып әйләнеп төште.

Боларны күреп калган Шәриповның йөзе яктырып китте. Үз командирының, үзенең якын дустының мондый кыюлыгы, мондый җитезлеге, мондый искиткеч батырлыгы аны рухландырды.

Ул, агачлар арасыннан чыгып, командирына ярдәмгә ташланды. Ләкин өлгерә алмады.

Голубицкий тирәсендә тыз-быз килеп, бертуктаусыз кычкырынып һәм сүгенеп йөргән япон офицерының ачуы чиктән ашты булса кирәк, ул кабалана-кабалана артка чыкты, маузерын Голубицкийның аркасына терәде һәм атып җибәрде. Голубицкий бер генә минутка хәрәкәтсез калды, сул кулы салынып төште. Моны күргән самурай солдатлары тагын аңа ташландылар. Голубицкий тагын уң кулы белән винтовкасын югары күтәрде һәм приклад белән уңлы-суллы кизәнә башлады. Ләкин ул үзе дә чайкала башлады. Аннары, уң кулы белән винтовкасын кысып тоткан хәлдә, әкрен генә җиргә ауды. Самурайлар аны сырып алдылар...

Боларны күзәтә-күзәтә самурайлар группасына инде якынлашып килгән Шәриповның ачуы һәм нәфрәте чиктән ашты. Аның тамырлары бүртеп чыкты, күзләрендә дәһшәтле ачу уты кабынды. Ул кискен карарга килде: «Үлсәм үләм, ләкин иптәшләремнең үчен алмый калмыйм!»

Телефон аппараты урнашкан урыннан арырак, калкулыкның түбәсендә, куе агачлар арасында күзәтүчеләр өчен казылган окоп бар иде. Шәрипов, мөмкин кадәр агачларны селкетмәскә, яфракларны шыбырдатмаска тырышып, тавышсыз гына шул окопка якын килде. Окопка төште, гранаталарын чыгарып, окопның алдына тезеп куйды һәм аппарат тирәсендә кайнашкан самурайлар өстенә бер-бер артлы ике граната ыргытты. Гранаталар колак тондырырлык көчле һәм дәһшәтле тавыш чыгарып шартлады. Тузан-төтен өермәсе күтәрелде. Самурайларның берничәсе кыргый һәм ачы кычкырып егылды, калганнары төрлесе төрле якка сибелеп йөгерергә тотынды. Шәрипов алар артыннан тагын бер граната җибәрде. Тагы икесе егылды. Япон офицерының ачулы тавышы ишетелде. Ул, окоптан башын чыгармый гына, маузерын селки-селки нәрсәдер кычкырынды да йөгереп баручы самурайлар артыннан атып җибәрде. Иң алдан йөгерүчеләрдән берсе күкрәген тотып җиргә егылды. Калганнары ятып окоп казый башлады. Шәрипов аларның ешрак урнашкан җирләренә соңгы гранатасын җибәрде. Аларның тагы икесе җиргә йөзтүбән капланды. Граната осколоклары берсенең көрәген читкә алып ташлады. Шәрипов тиз генә японнарны санап алды. Алар әлеге офицер белән бергә бишәү иделәр, ул аларны винтовка белән чүпләргә уйлады. Башын куе үлән арасыннан тыгып, түше белән сузылып яткан хәлдә, окоп казып азапланучы берсенең маңгаена төзәп атып җибәрде. Пуля тиде булырга кирәк, самурай дәшми-тынмый гына җиргә капланды һәм хәрәкәтсез калды. Ул арада офицер, окоптан башын калкытып, нәрсәдер кычкырынды да, кизәнеп, Шәрипов окобына таба граната ыргытты. Шәрипов тиз генә окопка иелде, винтовкасын үз янына алмакчы булды, әмма өлгерә алмады. Сызгырып баручы осколокларның берсе спусковой механизмны кубарып атты һәм аның әле һаман куроктан алынмаган имән бармагын өзеп китте. Шәриповның окобы тирәсендә бер-бер артлы тагын берничә граната -

шартлады. Окоп тирәсе төтен белән тулды. Менә гранаталарның берсе окопның янына ук килеп төште. Шәрипов аны окопка таба тәгәрәп килгән җиреннән искиткеч җитез хәрәкәтләр ясап тотып алды да кире дошманның үзенә ыргытты. Граната самурай окоплары өстендә һавада шартлады. Шәрипов төтен һәм тузан катлавы аша аның тирә-юньгә чәчрәгән кызыл очкыннарын күреп калды. Самурайларның тагы берсе кычкырып куйды.

Озакламый самурайлар граната ыргытудан туктадылар. Кинәт бөтен тирә-як тынып калды. Бу тынлык Шәриповны шиккә төшерде. Ул җентекләп алга һәм як-якка карады. Ләкин, көн җилсез булганлыктан, вак агачлар арасында төтен һәм тузан әле таралмый иде. Кинәт аңа уң якта җиңелчә генә кыштырдау һәм коры вак балчыкның шыбырдап коелып китүе ишетелеп калды. Каршыда да шундый ук шикле кыштырдау тавышлары кабатланды. Ул самурайларның, гранаталар күтәргән тузаннан файдаланып, үзен тиз генә чолгап алырга маташуларын сизде. Уң яктагы кыштырдау тавышлары якынлашканнан-якынлашты. Шәрипов, прикладсыз һәм спусковой механизмсыз калган винтовкасын алып, окоптан өскә сикерде дә уң яктагы куе яфраклы агачлар төркеме артына кереп посты. Ул ара да булмады, инде тарала башлаган тузан һәм төтен томаны арасыннан сак кына атлап, як-ягына карана-карана бер япон солдаты килеп чыкты һәм Шәрипов поскан агачлар төркеменә таба килә башлады. Шәрипов аның каршына килеп чыкты. Самурай каушап китте, ләкин шунда ук тесагын Шәриповның күкрәгенә таба сузды. Шәрипов, Голубицкий кебек үк җитез хәрәкәтләр ясап, үзенең прикладсыз винтовкасы белән тегенең мылтыгын бер кырга бәреп җибәрде, шунда ук үз штыгын дошманның күкрәгенә батырып алды. Самурай ачы тавыш белән кычкырып куйды һәм чайкалып ава башлады.

Шәрипов прикладсыз винтовкасын агачлар арасына ыргытты һәм, егылып җитүен дә көтмәстән, тегенең кулыннан мылтыгын тартып алды да яңадан вак агачлар төркеме артына сикерде. Кинәт ату тавышы ишетелде, сул колак яныннан каты сызгырып һәм колак яфракларын көйдереп пуля үтеп китте. Чигә буйлап муенга таба ниндидер җылы, йомшак һәм юеш нәрсә шуып төшә башлады. Шәрипов тиз генә як-ягына карап алды. Каршыдан аңа таба маузерын төзәгән, ачудан тагын да ыграк кара янган офицер һәм аннан аз гына артта, мылтыгын алга сузып, петлицаларына икешәр сары йолдыз кадаган бер япон солдаты килә иде. Шәрипов, агачлар артына яшеренеп, мылтыгын офицерга төзәде. Шулчак сул яктан көчле, калын тавыш ишетелде:

– Ташла маузерыңны, кулларыңны күтәр!

Шәрипов та, офицер да, теге самурай солдаты да тавыш килгән якка борылып карадылар. Анда, вак агачлар төркеме артында, кызыл йолдызлы каска күренеп китте һәм куе яфраклар арасыннан дүрт кырлы штык сузылып килеп чыкты да офицерның күкрәгенә төзәлде. Офицер аз гына сизелерлек рәвештә агарынып китте, маузерын тиз генә шушы винтовка ягына төзәде. Ләкин нәкъ шул секундта офицерның уң ягындагы агачлар артыннан кызыл йолдызлы каска кигән тагын бер егет сикереп чыкты һәм офицерның маузерын бәреп төшерде. Маузер шартлап атылып китте, ләкин беркемгә дә тимәде. Шәрипов мылтыгын офицер артыннан килгән солдатка төзәде, тегесе, мылтыгын ташлап, кулларын күтәрде.

Шәрипов яңа килгән кызылармеецларны таныды. Алар резервтагы элемтәчеләрдән Григорьев белән Костюкевич иде. Өчәүләп офицер белән солдатны чолгап алдылар. Шәрипов аларның һәр икесен дә тентеде һәм кесәсендәге резина тышлы запас линия чыбыклары белән һәр икесенең кулларын артка каерып бәйләде.

– Бик әйбәт. Болай бәйләгәч, самурайларның кояш алласы үзе дә кулларын ычкындыра алмас инде, – дип куйды.

Григорьев белән Костюкевич елмайдылар. Офицерның кашлары җыерылды, аксыл иреннәре аз гына дерелдәп куйды.

Эш беткәч, Григорьев Шәриповка дәште:

– Ә отделение командиры кайда? Фәрдиев белән Олейнек кайда?

Шәрипов ни өчендер бераз уңайсызланып китте. Кашлары түбән салынды. Ул тирән итеп бер сулап куйды. Шуннан берничә сүз белән генә күргәннәрен сөйләп бирде. Ахырдан өстәп куйды:

– Группа башлыгы булып мин калдым.

Григорьев аңа үзләренең ни өчен килгәнен аңлатып бирде:

– 24 не чакырып-чакырып та сездән җавап ала алмагач, безне сезнең карамакка җибәрделәр. Үзебез белән запас аппарат та алып килдек.

Шәрипов аларның нәкъ шушы моментта килеп җитүләренә бик шатланды.

– Иптәш Григорьев, сез хәзер үк үзегез алып килгән аппаратны алыгыз да һәр ике як белән элемтә урнаштырыгыз!

Григорьев чыңлап торган ачык тавыш белән җавап кайтарды:

– Есть элемтә урнаштырырга!

Һәм тиз генә, үзе килеп чыккан агач төбендәге аппаратны алып, окопларга таба йөгерде.

Шәрипов Костюкевичка таба борылды:

– Сез менә бу кошларны штабка илтеп тапшырыгыз! Үзегез тиз генә кире килегез.

Костюкевич та, Григорьев кебек үк, ачык тавыш белән приказны кабатлады һәм офицер белән солдатны штабка таба алып китте. Шәрипов, кулындагы яраларны бәйли-бәйли, аның артыннан искәртеп калды:

– Кире килгәндә, линияне карый-карый кил! Тагы берәр җирдән өзелеп-нитеп куймагае.

Ул окоплар янына – үзенең сөекле командиры һәм якын дусларының гәүдәләре янына юнәлде.

Менә калкулыкның итәгендә, үзенең окобы янында ук, аның якташы телефонист Фәрдиев ята. Граната осколоклары аның маңгай сөяген ваткан һәм күкрәген яралаган. Димәк, самурайлар, агачлар артына яшеренеп, калкулыкның аргы ягындагы үзәнлек буйлап килгәннәр дә калкулык өстеннән торып граната ыргыта башлаганнар. Гранаталар күбрәк Фәрдиев окобы тирәсендә шартлаган булса кирәк.

Фәрдиевтән бераз арырак, йомшак үлән арасында, линия элемтәчесе Олейнек ята. Осколоклар аның сул як балтырын һәм сул як битен яралаган. Күкрәге ике җирдән кадалган. Ул чалкан егылган, шулай да винтовкасын кулыннан ычкындырмаган. Кинәт Шәриповның күзләре аның штыгына төште. Олейнекның штыгы төбенә кадәр канга буялган, шулай ук винтовка стволына һәм мушкасына да кан тамчылары чәчрәгән. Алар инде бераз кибә дә башлаган. Димәк, Олейнек яраланганнан соң да бер яки берничә самурайны кадарга өлгергән.

Шәрипов аларның һәр икесе янында да берничә секунд тукталып торды. Иелеп аларның маңгайларыннан үпте. Аннан Олейнектан уңдарак һәм арырак ята торган Голубицкий янына килде. Әкрен генә аның янына чүгәләде: күкрәгенә һәм битенә кунган чебеннәрне куып җибәрде. Аннары, иелеп, маңгаеннан һәм иреннәреннән үбеп алды. Голубицкийның аксыллана башлаган иреннәре кинәт чак кына сизелерлек дерелдәп китте. Күз кабаклары да аз гына селкенеп куйгандай булды. Шәриповның йөзе яктырып китте, күзләренә шатлык очкыннары кабындылар. Ул, монда артык тавышланырга ярамаганлыгын да онытып:

– Исән! – дип кычкырып җибәрде. Тиз генә аның сул як иңбашы һәм уң як күкрәгендәге яраларын бәйләде. Шул ара да булмады, окоптан Григорьевның чатнап торган тавышы ишетелде:

– Иптәш группа башлыгы, мин элемтәне өр-яңадан урнаштырдым. 32 белән 24 нең берсеннән икенчесенә ашыгыч мәгълүматлар һәм приказлар тапшырдым. Хәзер 24 сезне телефонга чакыра.

Телефонда Шәрипов белән үз батальоннарының элемтә начальнигы Николаенко сөйләште. Шәрипов берничә сүз белән генә мондагы хәлләрне – Голубицкийның исән, ләкин каты яраланган булуын әйтте, һәм ашыгыч рәвештә санитар машинасы җибәрүләрен сорады. Үзе тиз генә яңадан Голубицкий янына килде.

Ул килгәндә, Голубицкий инде күзләрен ачкан, әле нәрсә булганын төшенеп җитмәгән төсле аптырап, як-ягына карана иде. Шәрипов аның янына тезләнде:

– Су эчәсегез килмиме, иптәш командир?

– Бик килә, – диде Голубицкий һәм Шәриповның флягасыннан йотлыгып-йотлыгып су эчте. Битенә дә алсу төс йөгерде. Кинәт ул нәрсәнедер исенә төшергән кыяфәт белән Шәриповка текәп карады:

– Элемтәне яңадан урнаштырдыгызмы, иптәш Шәрипов?

– Урнаштырдык, иптәш командир. Хәзер һәр ике як белән дә әйбәт сөйләшәбез. Дошман бандасы юк ителде, – дип җавап бирде Шәрипов һәм эчке дулкынлану тавышы белән өстәп куйды, – сез гаҗәп яхшы сугыштыгыз, иптәш командир, гаҗәп яхшы. Мин күреп тордым!

Ул арада санитар машинасы да килеп җитте.

Машинадан хәрби врач белән санинструктор сикереп төштеләр. Хәрби врач Голубицкийның яраларын карады.

– Кан күп киткән, – диде ул. – Шулай да терелер. Кан җибәрербез.

Алар үзләре белән алып килгән запас бинт белән аның яраларын бәйләделәр дә җайлап кына носилкага салдылар. Носилканы машинага кертеп куйдылар. Үлеләрне җыю өчен махсус машина җибәрергә булып китеп тә бардылар.

Озак та үтмәде, роталар атакага ташланды, көчле ура тавышы бөтен тирә-юньне яңгыратты. Бер ярты сәгатьтән соң әле самурайлар хөкем сөргән сопкаларда берсеннән-берсе матур булып кызыл флаглар җилферди иде инде.

*1939*

*Рәхим Саттар (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров) 1912 елның 15 августында Башкортстан Республикасының Чишмә районы Түбән Хаҗәт авылында игенче гаиләсендә туа. Ул балачактан ук әдәбиятка гашыйк булып үсә, дүртенче сыйныфта укыганда шигырьләр яза башлый. Авылдагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач, туган төбәгендә төрле эшләрдә эшли, шигырьләр язуын дәвам иттерә. Шул елларда Башкортстан һәм Татарстан көндәлек матбугатында аның яшьлек хисләре белән өртелгән беренче лирик парчалары басылып чыга.*

*Урта мәктәпне Р.Саттар Уфа шәһәрендә тәмамлый. Татар теле һәм әдәбияты буенча дәресләрне анда Нәкый Исәнбәт укыткан була. Бу хәл егетнең иҗат эше белән шөгыльләнү хыялын тагын да*

*ныгыткан булса кирәк. Урта мәктәпне тәмамлагач, Р.Саттар төрле җирләрдә йөри, Донбасска барып эшләп кайта, Башкортстанның Учалы районында урман кисү эшендә дә чыныгу ала. Шунда эшләгәндә, 1932 елны, ул гаилә корып җибәрә, бераздан исә армиягә алынып, Байкал чик буе гаскәрләрендә хәрби хезмәт вазифаларын үтәп кайта.*

*1937 елда Р.Саттар гаиләсе белән Казанга күчеп килә. Берникадәр вакыттан соң күңеленә яраклы эш тә таба: «Кызыл яшьләр» газетасында (хәзерге «Татарстан яшьләре») әдәби хезмәткәр булып эшли башлый, сугыш алды елларында газетаның җаваплы мөхәррире урынбасары вазифаларын башкара. Бер үк вакытта аның иҗат активлыгы да арта: газета битләрендә яшьләр тормышына багышланган мәкаләләре, очерк язмалары, шигырьләре, әдәби тәрҗемәләре басыла.*

*Ләкин сугыш афәте тыныч тормыш агышын да, иҗат хыялларын да кискен үзгәртә: 1941 елның җәендә Р.Саттар үзе теләп фронтка китә. Десантчы сыйфатында ул фашистлар тылында үткәрелгән күп кенә сугышчан операцияләрдә катнаша. 1942 елның маенда булган шундый операцияләрнең берсендә чолганышта калып, Р.Саттар фашистлар кулына эләгә һәм, берничә ай Смоленск, Борисов шәһәрләрендәге хәрби әсирләр лагеренда газап чиккәннән соң, Берлин янындагы Вустрау лагерена озатыла. Шунда ул Абдулла Алиш белән очраша һәм озакламый Муса Җәлил һәм аның иптәшләре тарафыннан оештырылган антифашистик оешманың иң ышанычлы әгъзаларыннан берсе булып китә. Ул әсирләр лагеренда һәм мәгълүм «Идел-Урал» легионында антифашистик листовкалар язып таратуда актив катнаша. 1943 елның август аенда яшерен оешма фаш ителеп, җәлилчеләрне кулга алганда, Р.Саттар да шул исемлектә була, әмма ул, үзе сизенепме яисә җае чыгыпмы, 1943 елның июнь аенда ук лагерьдан качып китә. Аның шуннан соңгы язмышы әлегәчә билгесез.*

*Р.Саттар 1942–1943 елларда Смоленск, Борисов, Вустрау, Радом һәм Берлиндагы хәрби әсирләр лагеренда чагында да шигырьләр яза. Ватанны, туган җирне сагыну, фашистларга нәфрәт хисләре белән сугарылган шундый шигырьләрнең ике дистәгә якыны («Ант», «Шөһрәт», «Әнкәмә хат», «Әсирләр», «Халкым өчен», «Бүленгән җыр», «Очрашу» һ.б.) «Тоткынлыкта» исемле кульязма җыентык рәвешендә туган илгә дә кайтып ирешә һәм берничә тапкыр матбугатта басылып чыга. Әдипнең зур булмаган шигъри мирасыннан үрнәкләр «Җыр дәвам итә» (1966, 1985) исемле җыентыгында, шулай ук рус теленә тәрҗемәдә «Три поэта-воина» (1979) исемле китапта да нәшер ителә.*

## ХАЛКЫМ ӨЧЕН

Көнчыгышта алсуланып
Ата ал таң.
Күккә калкып таулар күренә,
Гүя калкан.

Алга карыйм.
Анда ята томан һаман.
Ерак Туган илдә яши
Газиз анам.

Коралдашлар яу кырында!
Кайда соң мин?
Кем мин сиңа, ятиммени?
Әйт, Туган ил!
Бар хәсрәтең, бар михнәтең
Миңа уртак.
Син генә сук, син иркәлә,
Син мине как.

Ләкин син бел: һәр сулышым,
Барлык көчем
Синең өчен, Туган илем,
Синең өчен!

## РУХЫМ ГАЛИ

Тәрбияләдең мине горур итеп,
Баш имәдем әле буй җитеп
Бер дошманга, иркен тын алам:
Кулда богау, капка йозакта,
Ләкин рухым иркен, хөр кала.

## ШӨҺРӘТ

Данны кулга алып сизеп булмый,
Күреп булмый аны күз белән.
Күкрәкләргә таккан калай түгел,
Әйтү мөмкин түгел сүз белән.

Егет яуга бара...
Командиры
Дан турында сөйли аңарга.
Ләкин аңламый ул, хис табалмый
Шөһрәт уты белән янарга.

Нәрсә ул дан? Нигә? Кемгә кирәк?
Сугышта да шулай уйлый ул.
Ярсып-ярсып һөҗүм итә егет –
Канга баткан инде ике кул.

Кешелеген җуя, арыслан сыман
Ташлана ул дошман ягына!
Үзе уйлый:
«Бакса иде иркәм
Мин ясаган мәет тавына!..»

## АНТ

Мин бу антны ОСТ лагерен күреп,
Аның соры ташы өстендә
Бирәм киләчәккә, бирәм илгә,
Коллык сөйрәп йөргән бер көндә.

Ләкин дошман белсен минем көчне,
Дошман белсен минем ачуны.
Мөмкин түгел, дуслар, мөмкин түгел
Халык нәфрәтеннән качуы.

Дошман белсен минем күкрәгемдә
Нинди ачу, нәфрәт ятканын.
Мин сизәмен шушы нәфрәтемнең
Нәфис булып чәчәк атканын.

## ӘНКӘМ

Бәлки, син дә хәсрәт чигәсеңдер,
Сатылган, дип, улым дошманга.
Юк хәбәргә һич тә ышанма!

Аяк бәйле бүген, кул богаулы,

Ашар ашлар, ширбәт агулы,
Торак суык, ләкин тәмугы
Ул гомернең. Канат кагуы
Биредә мөмкин түгел күңелгә,
Хәсрәт ята бүген күңелдә.
Талпынса да күңел, ни файда бар
Батырларын җуйган иленә?!
Тагын кылыч тагып биленә,
Чыксаң иде дошман янына,
Байрак кагып көрәш тавына!

Дөрес түгел, ялган хәбәр ул,
Балаңа бер иманыңда бул!
Сиңа биргән изге антында,
Туган илнең ирке хакына
Биргән антын бозмас халкына!

*1942–1943*

*Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов) 1906 елның 10 октябрендә элекке Самара губернасы (хәзерге Ульянов өлкәсе Чардаклы районы) Татар Колмаеры авылында крәстиян гаиләсендә туа. Башта үз авылларында укый, аннан Самара шәһәрендәге Татар-башкорт педагогия техникумында белем ала. Шунда укыган чагында шигырьләр яза башлый. 1926 елда Казанга килеп, татрабфакка укырга керә. Шул елларда ул көндәлек матбугатта актив языша. 1929 елда инде аның «Тальян» исемле беренче шигъри җыентыгы, аннан соң, озак та үтми, «Бояр урманында» (1930), «Металл тавышлары» (1931) дигән җыентыклары басылып чыга. Шушы беренче китапларында ук ул үзен образлы фикерләүдә, тасвирда һәм шигъри формада үзенчәлекле, оригиналь стильле әдип итеп таныта.*

*Узган гасырның 30нчы еллар уртасында Д.Фәтхи Ерак Көнчыгышка китә һәм сигез елга якын төрле җирләрдә гади эшче булып эшли. Бу чор шигырьләрендә ул алтын рудникларында эшләүче эшчеләр тормышын, революция алып килгән тарихи үзгәрешләрне һәм Себер табигатенең матурлыгын сурәтли. Алтын казучы шахтерларның инкыйлабка кадәрге газаплы тормышын һәм күмәк хезмәт шартларында социаль аңнары үсүен реалистик картиналарда тасвирлаган «Алтын тайга трагедиясеннән» исемле поэмасы (1939–1940) шагыйрь иҗатында үзенең эчтәлеге, эмоциональ көче һәм тел-сурәтләүдәге шигъри образлары, күтелмәгән чагыштырулары белән аеруча күренекле урын алып тора.*

*Сугыш алдыннан Д.Фәтхи Татарстанга кайта һәм Зеленодольск шәһәрендә производствода гади эшче булып эшли, 1941 елда ул фронтка китә. Сталинград янындагы сугышларда катнаша, берничә тапкыр яралана; совет гаскәрләре белән бергә дошманны куа-куа Украина чикләренә кадәр барып җитә һәм 1943 елны Кантемирово (Воронеж өлкәсе) янындагы сугышларның берсендә батырларча һәлак була.*

*Шагыйрьнең сайланма шигырьләре, поэмалары һәм хикәяләре «Һәрвакыт сафта» исемле җыентыкта (1970) урын ала.*

*Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән язучы-солдат буларак Д.Фәтхинең исеме Татарстан Язучылар берлеге бинасына куелган мемориаль тактага языла.*

## ЯУЛЫКЛЫ ИНЖЕНЕРГА

Кайсы елның нинди ае калыккан,
Нинди ландыш үскән кайсы тугайда,
Кай чишмәләр шаулап аккан
Синең исемең җиргә туганда.

Зифа камыш калкып үскән күлдә
Үрдәк бәбкәләрен каулап йөргәнсең,
Җил тирбәгән ак кылганнар белән
Толымнарың тарап үргәнсең.

Кулларыңа әлифбалар кысып,

Кай мәктәптә укып йөргәнсең.
Кышкы төннәр китапларга күмелеп,
Кайсы вузга сынау биргәнсең.

Инженерлык дипломнарын алгач,
Ничек ашкынгандыр синең йөрәгең.
Белмим,
Моңар чаклы үткән көннәреңне
Берсен дә мин үзем күрмәдем.

Фабрик цехларында беренче кат
Исәнләштек, артык сүзләр булмады.
Киенгәннәрең бик гади иде,
Цехтан цехка кереп югалдың.

Тимер сыртлы саглам күперләр,
Небоскреб, чиксез заводлар,
Айга очар башсыз ракеталар
Эшче инженер адресына язылган.

Әнкә булып бала тудырганда,
Тик бәхетле еллар өчен үстерсәң,
Балаңа да әнкә-инженер бул син,
Шул төзелештәй матур үссеннәр!

*1930*

## АТЫШ ТЫНГАН МИНУТЛАРДА

Кичке атыш тынган минутларда,
Казан, сиңа сагынып хат язам,
Гади бер солдатның хаты итеп
Каршы ал һәм яз, Казан!

Кайсы гына адресына җибәрсәм дә,
Почта кемгә илтеп бирсә дә,
Кайсы гына гражданың укыса да,
Кемнән генә җавап килсә дә, –
Барыбер. Иске дуслар сыман
Язышырбыз. Чөнки бу көннәр
Кош теледәй хат та халкыбызның
Зур бердәмлек байрагы булып җилфердәр.

Дары исе сеңгән конвертыма
Йөрәгемнең бер бөртеген саламын,
Һәм ул илтер
Волга яры – Сталинград сугышларын
Кичкән сугышчының сагыну сәламен.

Син алып бар Дон суларын үткән
Сугышчының иң кадерле уйларын,
Почмагына кунган тузан хәтерләтсен
Украинага илткән сугыш юлларын.

Син хәтерләт Төньяк Донец суын
Сугышып кичкән канлы таңнарны,
Сандугачлы урманнарны буйлап
Тынмый йөргән туплар яңравын.

Туган илнең өч елгасын кичтем,
Һәр елгада тамды минем кан.

Якты теләк, батыр уйлар белән,
Карт Днепр, карыйм сиңа Донец ярыннан.

Атыш кыза. Хатым тагын бүленә,
Куллар тагын минометка ябыша.
Хат бүленми! Юллар дәвам итә
Шаулап киткән мина тавышында.

*1943*

**ЯЗ КҮРЕНЕШЛӘРЕ**

Еракларда тау сыртлары карала башлаган инде. Акбүзгә чиккән канва җебедәй яткан урманда тонык зәңгәр сөрмәләнгән кебек күренә.

Ә кешеләр, кар күкрәгенә бата-бата, яз хисләре белән урамнардан ашыгып үтәләр.

Өй кыекларына сырышкан карлар кояшка туры карый алмыйлар, эриләр, чып-чып тамалар. Кичләрдә тагын чулпыланып, көзгеләнеп туңалар. Көндезләрен тагын чып-чып чыпылдыйлар...

Һава нинди иркен! Шуңарга бөркелеп чыккан гудок тавышы кайларга чаклы яңгырап китә дә зыңлап кире кайта. Мин аннан тормыш язларының симфониясен тыңладым.

Шаулап капкадан чыккан фабрик кызлары шаркылдашып көлделәр... Әй көлделәр... Аларның шыңгыраган тавышлары урамнарга сыя алмады.

Урамнарда – табигать язы, кешеләрдә – тормыш язы.

Кыекларда гөлдерәшкән күгәрченнәрне күргәч, зәңгәр диңгезләр артыннан безгә кайтыр кошларны хәтерләдем. Алар юлдалардыр...

Ә бүген шәһәр өстеннән бер кошның, канат җәеп, үз артыннан тасмаландырып, зәңгәр төтен бөркегәнен күрдем.

Ул бит гаҗәп мәнзарәле Италия, Бәхре Сәфит ярларыннан түгелдер.

Аның туган җире кызыл кирпечле, шау-шулы заводлар күкрәге бит! Безнең шәһәргә кунакка килгән. Оча алмасам да, аның артыннан минем хисләрем еракларга-еракларга таба җилкенделәр.

Урамнарда табигать язы, безнең кешеләрдә тормыш язы.

Бу шулай түгелме соң?

Май төннәрендә сиреньнәргә күмеләчәк шәһәр бакчасы аша яз, яз хисләрем белән исереп үттем бүген мин.

*1928*

*Исмәгыйль Шәфи улы Шәфиев 1913 елда Башкортстан Республикасының Кыйгы районы Үрге Кыйгы авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа. 1929 елда туган авылындагы җидееллык мәктәпне һәм 1933 елда Уфа педагогия рабфагын тәмамлаганнан соң, 1935 елга кадәр Кыйгы МТСы газетасында, аннары шул районның төбәк газетасында редактор урынбасары булып эшли. 1935–1937 елларда Ерак Көнчыгышта армиядә батарея командиры булып хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан укытучылар институтында укый, соңыннан Татарстанның Сарман районы Зур Нөркәй авылына укытучы итеп җибәрелә.*

*И.Шәфиев көндәлек матбугатта басылган лирик шигырьләре белән сугыш алды елларында үзен өметле яшь шагыйрь итеп танытып өлгерә. 1941 елның язында ул Татарстан китап нәшриятына (ул вакытта Татгосиздат) бастырыр өчен үзенең беренче шигырьләр җыентыгын да тапшырган була, ләкин сугыш башлану сәбәпле, җыентык дөнья күрми кала.*

*И.Шәфиев – Такташ поэтик мәктәбе йогынтысында яза башлаган шагыйрьләрдән. Вакыйга-күренешләрне җанлы, динамикалы итеп күрсәтү, лирик җылылык, музыкальлек – аның шигырьләрен матурлый торган үзенчәлекле сыйфатлар.*

*Аның сугыш вакытында язган шигырьләре фронт газеталарында һәм Казанда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә басыла.*

*И.Шәфиев Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә һәм лейтенант-танкист сыйфатында күп кенә сугышларда катнаша. Ул 1943 елның 17 сентябрендә Смоленск өлкәсенең Кузьмиченко авылы янында батырларча һәлак була.*

*Сугыштан соңгы чорда яшь шагыйрьнең иҗатыннан аерым үрнәкләр «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1956) һәм «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961, 1985) исемле күмәк җыентыкларда басылып чыга.*

**ПОЕЗД ЧИККӘ БАРА**

Станция. Шау-шу.
Халык тузгый.
Тула бара һәрбер буш вагон.
Бер ялкыннан янган ике йөрәк
Соң кат сарылдылар, хушлашып.

– Кызыл Армиягә! –
Роза көләч,
Матур елмаялар иреннәр.
Роза моңсу, –
Аерыла ул бердәнбереннән.

– Юк, боекма,
Егетем китте дип,
Шат яшә син,
Минем алтыным.
Кайда булсам да мин,
Сүрелмәс ул –
Һич сүрелмәс йөрәк ялкыны!

Әлим китте.
Озатканда,
Роза калды карап, каерылып.
Сылу кызга
Батыр егеттән,
Их, авыр шул, авыр аерылу!

Поезд китте.
Зәңгәр болыт кына
Ятып калды поезд юлына.
Әлим китте,
Сагынып сөйләр өчен
Рәсме калды Роза кулында.

Зәңгәр шәлен болгап,
Поезд җилә,
Ерак чиккә чаба паровоз.
Цехлар, басулардан яңа алмаш
Границага алып бара ул.

Вагоннар шат,
Гармун ярсып уйный,
Шаулы җырлар ерак тарала.
Эшелон гөрли...
Юлда чибәр кызлар
Яулык болгап озатып калалар.

Әй, батырлар иле, сөекле ил,
Чигең ерак синең,
бик ерак!
Шатлык ташый синдә,
Тормыш кайный,
Җыр яңгырый бөтен җирне урап.

Тәрәзәмне ачып карап барам:
Урал,

Байкал,
Амур буйларын.
Күпме сарылсам да,
Илебезнең
Матурлыгын карап туймадым.

Поезд бара...
Зәңгәр шәлен болгап,
Границага чаба паровоз.
Арысландай көчле егетләрне
Ил сакларга алып бара ул.

*1936*

## ТУКАЙ БЕЗНЕҢ БЕЛӘН

Стенада рәсем, һәрберәүгә
Таныш та ул, бик-бик якын да.
Күргән саен никтер шул рәсемне,
Сүз башлана аның хакында.
Мин сөйләмим аның кем икәнен,
Ул рәсемне таный бала да.
Күрше карты аны саклык белән,
Хөрмәт белән кулына ала да
Сөйләп китә:
– Их, Габдулла!
Исән булсаң,
Арканнан гел сөеп кагарга!
Менә егет,
Менә лачын идең!
Тик рәсемең калды карарга...

О, ялган бу! Тукай үлдеме соң?
Үлем бармы андый шагыйрьгә?
Син киләсең атлап безнең белән
Зур депутат булып шигырьдә.
Син Пушкинны мәңге аерылмаска
Кочагыңа кыскан шикелле,
Киң Союзның һәрбер милләтен
Син кадерле, таныш, сөйкемле.
Син йөрисең әле дә безгә булышып
Яшәү, иҗат, көрәш эшендә,
Сине үрнәк итеп,
Синең белән
Горурланып яши кешеләр.

Син үлмәгән.
Сине туган илең
Биек трибунага бастырды.
Яшә, шагыйрь! Сиңа мәңгелеккә
Тапшырдык без Совет паспортын.

*1941*

## ТУГАННАРЫМА

*(Фронттан хат)*

Сез еракта. Ә без сугышка да
Сезнең хакта уйлап барабыз.
Сезнең алда соңгы сулышкача
Турылыклы булып калабыз.
Көне-төне пуля, мина ява –
Ут яңгыры өскә коела;
Бомба ярчыклары сезнең янга
Барып җитәр төсле тоела.
Якты киләчәкне саклау өчен
Күкрәкләрдән дивар корабыз...
Үлсәк үләбез без: дошман явын
Сезгә узгармыйбыз – кырабыз!

Сау булыгыз! Сәлам Урал тауга!
Фатихада булсын улына...
Ун минуттан китәм атакага...
Язып өлгергәнем шул гына.
1942

**ФРОНТОВИК ЯЗУЧЫЛАР***

1. **Аитзәк Аитов (1908–1941)**
2. Әсгать Айдар (Әсгать Харис улы Айдаров) (1906–1959)
3. **Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) (1908–1944)**
4. Нури Арсланов (Нури Газиз улы Арсланов) (1912–1991)
5. **Мөхәммәт Әблиев (Мөхәммәт Шәриф улы Әблиев) (1900–1941)**
6. **Әхтәм Әминев (Әхтәм Әмин улы Әминев) (1918–1942)**
7. Юныс Әминев (Юныс Шәрип улы Әминев) (1921–1982)
8. Мирсәй Әмир (Мирсәяф Мәсәлим улы Әмиров) (1907–1980)
9. Габдрахман Әпсәләмов (Габдрахман Сафа улы Әпсәләмов) (1911–1979)
10. Абдулла Әхмәт (Абдулла Сафиулла улы Әхмәтов) (1905–1976)
11. **Мөхәммәт Әхмәтгалиев (Мөхәммәт Ибраһим улы Әхмәтгалиев) (1920–1943)**
12. Локман Бадыйкшан (Локман Әхмәтхан улы Бадыйкшан) (1919)
13. Госман Бакиров (Госман Фәтхулла улы Бакиров) (1896–1982)
14. **Кәшфи Басыйров (Кәшшаф Хәбир улы Басыйров) (1906–1943)**
15. Салих Баттал (Салихҗан Вазыйх улы Батталов) (1905–1995)
16. **Нур Баян (Нур Галим улы Баянов) (1905–1945)**
17. Гомәр Бәширов (Гомәр Бәшир улы Бәширов) (1901–1999)
18. Юрий Белостоцкий (Юрий Вячеславович Белостоцкий) (1922–1983)
19. Ислам Беляев (Ислам Габделхак улы Беляев) (1926–1986)
20. **Александр Бендецкий (Александр Григорьевич Бендецкий) (1911–1943)**
21. **Касыйм Вахит (Касыйм Мисбах улы Вахитов) (1916–1942)**
22. Хәй Вахит (Габделхәй Каюм улы Вахитов) (1918–1978)
23. **Мифтах Вәдүт (Вәдүт Кәшшаф улы Мифтахов) (1915–1942)**
24. **Лотфи Вәли (Лотфулла Вәлимөхәммәт улы Вәлимөхәммәтов) (1910–1943)**
25. Әзһәр Габиди (Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин) (1926–2001)
26. Ибраһим Гази (Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев) (1907–1971)
27. Нур Гайсин (Нурулла Әхияр улы Гайсин) (1914–1995)
28. Әнәс Галиев (Әнәс Касыйм улы Галиев) (1920–1996)
29. **Габдулла Галиев (Габдулла Гали улы Галиев) (1920–1941)**
30. Гариф Галиев (Гариф Закир улы Галиев) (1903–1985)
31. Фәйзи Галиев (Фәйзи Әхмәт улы Галиев) (1925)
32. **Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин) (1913–1941)**
33. **Мансур Гаяз (Мансур Гаяз улы Гаязов) (1917–1943)**
34. **Шамил Гәрәй (Шамил Мөхәммәтгали улы Гәрәев) (1916–1946)**
35. Хатип Госман (Хатип Госман улы Госманов) (1908–1992)
36. Таһир Госман-Сулмаш (Таһир Госман улы Госманов) (1900–1983)
37. Гыйз-әл-Габид (Гыйззәтулла Лотфулла улы Габидуллин)

(1918–1955)
38. Бәян Гыйззәт (Фәтхелбәян Нурлыгаян улы Гыйззәтуллин) (1918–1991)
39. Сафа Гыйльфан (Сафа Гыйльфан улы Гыйльфанов) (1902–1950)
40. **Әхмәт Гыймадов (Әхмәт Зыятдин улы Гыймадов) (1915–1943)**
41. Әнвәр Давыдов (Әнвәр Мортаза улы Давыдов) (1919–1968)
42. Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин) (1910–1989)
43. Павел Евгеньев (Павел Кузьмич Евгеньев) (1909–1972)
44. Әмирхан Еники (Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев) (1909–2000)
45. Әхмәт Ерикәй (Әхмәт Фазыл улы Ерикиев) (1902–1967)
46. Сергей Ефремов (Сергей Иванович Ефремов) (1917–1965)
47. Тихон Журавлев (Тихон Кононович Журавлев) (1913–1985)
48. Кәрим Җаманаклы (Кәрим Рәшид улы Рәшидов) (1905–1965)
49. **Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) (1906–1944)**
50. **Исхак Закиров (Исхак Кадыйр улы Закиров) (1911–1944)**
51. Изаил Зарипов (Изаил Харис улы Зарипов) (1927–1999)
52. Шаһиморат Зәйни (Зәйни Әхмәт улы Шаһиморатов) (1913–1980)
53. Якуб Зәнкиев (Якуб Камали улы Зәнкиев) (1917–2003)
54. Газиз Иделле (Габделгазиз Сәлахетдин улы Усманов) (1905–1985)
55. **Рахман Ильяс (Габдрахман Вәкил улы Ильясов) (1908–1943)**
56. Рәмзи Илялов (Рәмзи Ибраһим улы Илялов) (1923–2009)
57. Әхмәт Исхак (Әхмәт Габдулла улы Исхаков) (1905–1991)
58. Риза Ишморат (Риза Фәхретдин улы Ишморатов) (1903–1995)
59. **Хәмит Кави (1906–1944)**
60. Сәет Кальметов (Сәет Гани улы Кальметов) (1918–1992)
61. **Әгъзам Камал (Әгъзам Камалетдин улы Камалетдинов) (1918–1943)**
62. Хисам Камалов (Хисам Нуретдин улы Камалов) (1926)
63. Әнәс Кари (Әнәс Кари улы Кариев) (1920–1954)
64. **Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов) (1909–1945)**
65. Әбрар Кәримуллин (Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин) (1925–2000)
66. **Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев) (1903–1945)**
67. Кави Латыйп (Кави Таһир улы Латыйпов) (1927–2008)
68. Константин Лебедев (Константин Васильевич Лебедев) (1921–?)
69. Мөнир Мазунов (Мөнир Хәсән улы Мазунов) (1918–1987)
70. Мәхмүд Максуд (Мәхмүд Гыйсаметдин улы Максудов) (1900–1962)
71. Әдип Маликов (Әдип Малик улы Маликов) (1921–2009)
72. **Мөхәммәтша Мамин (Мөхәммәтша Гомәр улы Мамин) (1905–1943)**
73. Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров) (1905–1980)
74. Зыя Мансур (Зыя Мансур улы Мансуров) (1916–1965)
75. Аркадий Мельников (Аркадий Михайлович Мельников) (1926)
76. Габдрахман Минский (Габдрахман Мөхәммәт улы Аллаһбирдиев) (1906–1983)
77. **Мөсәгыйт Мостафин (1909–1941)**
78. Шәрәф Мөдәррис (Шәрәф Хасиятулла улы Мөдәррисов) (1919–1963)
79. **Хәйретдин Мөҗәй (Мөҗәһит Хәйретдин улы Хәйретдинов) (1901–1944)**
80. **Сөләйман Мөлекев (Сөләйман Мифтах улы Мөлекев) (1920–1941)**
81. Гамир Насрый (Гамир Гариф улы Насретдинов) (1916–1959)
82. Мәгъсүм Насыйбуллин (Мәгъсүм Нәҗип улы Насыйбуллин) (1925–2009)
83. Әхәт Нигъмәтуллин (Әхәт Зәйнетдин улы Нигъмәтуллин) (1921–?)
84. Мостафа Ногман (Мостафа Ногман улы Ногманов) (1912–1976)
85. Зәки Нури (Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов) (1921–1994)
86. Ибраһим Нуруллин (Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин) (1923–1995)
87. Геннадий Паушкин (Геннадий Александрович Паушкин) (1921–2007)
88. Атилла Расих (Атилла Кадыйр улы Рәсүлев) (1916–1996)

89. **Хәбра Рахман (Хәбибрахман Габдрахман улы Габдрахманов) (1914–1942)**
90. Мәҗит Рәфыйков (Мәҗит Мәгъсүм улы Рәфыйков) (1925–1986)
91. Мәрди Рәфыйков (Мәрди Галләм улы Рәфыйков) (1927–2009)
92. Бари Рәхмәт (Бари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин) (1897–1957)
93. Сафа Сабиров (Сафа Сабир улы Сабиров (Нәзыйров)) (1915–2004)
94. Г.-Халикъ Садри (Габделхаликъ Гариф улы Садретдинов) (1890–1955)
95. Мөхәммәт Садри (Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов) (1913–1999)
96. **Рәхим Саттар (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров) (1912–1943)**
97. Үзбәк Саттаров (Үзбәк Газиз улы Саттаров) (1922–1982)
98. Сирин (Сирин Хәниф улы Батыршин) (1896–1969)
99. Максуд Сөндекле (Садыйк Мөбин улы Максудов) (1904–1981)
100. Дмитрий Сычев (Дмитрий Степанович Сычев) (1918–?)
101. Гурий Тавлин (Гурий Иванович Тавлин) (1925–1998)
102. Рафаил Төхфәтуллин (Рафаил Газиз улы Төхфәтуллин) (1924–1994)
103. Идрис Туктаров (Идрис Ильяс улы Туктаров) (1896–1982)
104. Сәхаб Урайский (Сәхабетдин Камалетдин улы Мәүлютов) (1907–1957)
105. Әхмәт Фәйзи (Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзуллин) (1903–1958)
106. **Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов) (1906–1943)**
107. Сибгат Хәким (Сибгат Таҗи улы Хәкимов) (1911–1986)
108. Мәхмүт Хөсәен (Мәхмүт Хафиз улы Хөсәенов) (1923–1993)
109. Фатих Хөсни (Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов) (1908–1996)
110. Гали Хуҗи (Гали Хуҗи улы Хуҗиев) (1912–1966)
111. Самат Шакир (Самат Фәтхерахман улы Шакиров) (1924–1998)
112. Афзал Шамов (Афзалетдин Шиһабетдин улы Шамов) (1901–1990)
113. Шамил Шаһгали (Шамил Шаһгали улы Миңлегалиев) (1920–1987)
114. Сәет Шәкүров (Сәет Габделхәй улы Шәкүров) (1917–1989)
115. Габдулла Шәрәфи (Габдулла Шәрәфетдин улы Шәрәфетдинов) (1926–1997)
116. **Исмәгыйль Шәфиев (Исмәгыйль Шәфи улы Шәфиев) (1913–1943)**
117. Әхмәт Юныс (Әхмәт Юныс улы Юнысов) (1916–1976)
118. Миргазиян Юныс (Миргазиян Мөхәммәтзакир улы Юнысов) (1927)

## ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ ФРОНТТА КАТНАШКАН ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ

1. **Альмашев Л.Н.**
2. **Арсланов Ш.Б**
3. **Әхмәдиев Т.А.**
4. Әхмәтов М.И.
5. Бадамшин Ш.Б.
6. Бакиров Г.Ф.
7. **Басыйров К.Х.**
8. **Баянов Н.Г.**
9. Бәширов Г.Ф.
10. **Вәлиева М.Н.**
11. **Бендецкий А.Г.**
12. Гайфуллин Р.С.
13. **Гаффаров Х.Х.**
14. Григорьев П.Н.
15. **Гыймадов А.З.**
16. Гыймадиев М.Г.
17. **Ильясов Г.В.**

18. Ишеев Д.Ш.
19. Камалетдинов А.М.
20. **Карпов Н.Л.**
21. **Кәримов Ф.А.**
22. Минһаҗиев И.З.
23. **Мусин Г.Я.**
24. Рәхимов М.З.
25. Садретдинов М.Х.
26. **Төхвәтуллин А.Р.**
27. **Фәтхуллин М.Н.**
28. Хәкимов С.Т.
29. Хәйруллин Х.Х.
30. Шамов А.Ш.
31. **Шәйхетдинов К.Ш.**
32. Шәрәфетдинов Б.Б.
33. Шәрипов Г.Ф.
34. Юнысов А.Ю.

ЭЧТӘЛЕК


«Иң дәһшәтле утка керәмен». *Илфак Ибраһимов* ....................................
Ватан сугышы фронтларындагы улларына татар халкыннан хат .......
Икенче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хат ..................................................................................................................
**Аитзәк Аитов** ..............................
Сакта .......................................
«Ярга бәрелә, ярга таба чәчелә...» .....................................
Чаңгыда ..................................
**Абдулла Алиш** ............................
Үзем турында җыр ..............
Туган илгә ..............................
Ике улым бар ........................
Ничек килер үлем ...............
Көтмә инде, көтмә... ............
Кыр казлары .........................
«Төн. Бүлмәдә тыныч кына утырам ялгыз...» ...................
**Мөхәммәт Әблиев** .....................
Шәмсекамәр ..........................
**Әхтәм Әминев** ............................
Оч, Галия! ..............................
Ил чигендә .............................
**Мөхәммәт Әхмәтгалиев** ..........
Беренче көн ...........................
Миңа унсигез яшь ...............
Ата белән бала .......................
**Кәшфи Басыйров** .....................
Секретарь ................................
Артистка һәм шахтер ...........
**Нур Баян** ....................................
«Минем өстән пуля яуса да...» .........................................
Сандугачка .............................
Санитарка ..............................
«Тирә-якта үлән чәчәк аткан...» .......................................
«Хат язсам да инде бармас төсле...» ...................................
Уйланганда ............................
**Касыйм Вахит** ............................
Ул ............................................
Үч .............................................
«Яшьлегемнең асыл чәчәгенә...» ........................................
Тәрәзәңне ач та .....................
**Мифтах Вәдүт** ...........................
Җыр ........................................
Тимерчеләр ............................
**Габдулла Галиев** .........................
Батырларга ............................
Ак каен ...................................
**Макс Гатау** .................................
Безнең нәсел ..........................
Комбайнчы ............................
**Мансур Гаяз** ................................

Чиктә .......................................
Эскадрон бара .......................
Ана васыяте ...........................
Сагыну ....................................
Тетрәсен дошман .................
**Шамил Гәрәй** ..............................
Ике туган ...............................
Беренче мәхәббәт ..................
Урман буенда .........................
**Әхмәт Гыймадов** ........................
Мигуэль ..................................
**Муса Җәлил** ................................
Әйдә, җырым ..........................
Кичер, илем! ...........................
Шагыйрь .................................
Бүреләр ...................................
Яшь ана ...................................
Дуска .......................................
Ишек төбендә .........................
Җырларым ..............................
**Исхак Закиров** ..........................
Анага .......................................
Командир ................................
Автоматым ..............................
**Рахман Ильяс** ............................
Горизонт .................................
**Хәмит Кави** .................................
Кильдин атавы .......................
**Әгъзам Камал** .............................
Июль кичендә .......................
Бронепоезд ............................
Күпер .......................................
**Фатих Кәрим** ..............................
Ант ...........................................
Ватаным өчен ........................
Бездә яздыр ............................
Кыр казы .................................
Разведчик язмалары .............
**Гадел Кутуй** ................................
Батыр каберендә ...................
Иртәнге уйлар .......................
Тапшырылмаган хатлар ....
**Мөхәммәтша Мамин** ................
Һади Такташ поэзиясе ........
**Мөсәгыйт Мостафин** ................
Карлыган бакчасы ................
**Хәйретдин Мөҗәй** ....................
Ядкарь ....................................
Минем шатлыгым ................
Бүләк ......................................
Немец халкына командир һәм шагыйрь Х.Мөҗәйдән ачык хат .................................
Малай белән сөйләшү .........
**Сөләйман Мөлекев** ..................
Урман ....................................
Күз нурым син ......................
Гөлбануга ...............................
**Хәбра Рахман** ............................
«Елмаюлы бөдрә дулкыннар...» .......................................
Сугышта .................................
**Рәхим Саттар** .............................
Халкым өчен ..........................
Рухым гали ............................
Шөһрәт ..................................
Ант ...........................................
Әнкәм ......................................
**Демьян Фәтхи** ............................
Яулыклы инженерга ............
Атыш тынган минутларда ..
Яз күренешләре .....................
**Исмәгыйль Шәфиев** .................

Поезд чиккә бара ..................
Тукай безнең белән ..............
Туганнарыма ........................

Фронтовик язучылар ...............
Татарстан китап нәшриятының
фронтта катнашкан хезмәткәрләре ..................................

Литературно-художественное издание

Составители:
***Нуриев** Вакиф Вакилович*, ***Сафиуллина** Лилия Наиловна*

**СЛОВО ГЕРОЯ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Төзүчеләре:
***Нуриев** Вакыйф Вәкил улы*, ***Сафиуллина** Лилия Наил кызы*

**КАҺАРМАН КАЛӘМЕ**

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.04.2010. Форматы 84х108 1/32. Шартлы басма табагы 11,76. Тиражы 2000 д. Заказ О-449.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru E-mail: tki@tatkniga.ru.**
«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.